Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

***Таһир Кәримов***

# АЗНАКАЙ ТӨБӘГЕ АВЫЛЛАРЫ ҺӘМ НӘСЕЛЛӘРЕ ТАРИХЫ

## (ИСТОРИЯ ПОСЕЛЕНИЙ И ГЕНЕАЛОГИИ АЗНАКАЕВСКОГО КРАЯ)

Казан – 2023

УДК 94(470.4+470.5)
ББК 63.3(235.5)
К 95

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

**Фәнни мөхәррир**
*Р.Р. Салихов,* тарих фәннәре докторы,
ТР Фәннәр академиясе академигы

**Рецензентлар:**
*Ф.Г. Ислаев*, тарих фәннәре докторы
*Р.Р. Әминов*, тарих фәннәре кандидаты

***Кәримов Т.Т.***

К 95 **Азнакай төбәге авыллары һәм нәселләре тарихы (История поселений и генеалогии Азнакаевского края).** – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2023. – 316 б., ил.

ISBN 978-5-94981-389-8

Галимнең чираттагы хезмәте Азнакай төбәге авыллары һәм нәселләре тарихына багышлана. Китапның төп өлеше автор 1994–1997 елларда язган, соңрак тулыландырган һәм төзәтмәләр керткән тарихи очерклардан тора, аерым бүлектә шәҗәрәләр тәкъдим ителә. Яңа мәгълүмат һәм фәнни караш төбәк тарихын тирәнтен һәм күпкырлы ачып салырга ярдәм итә. Китап төбәк тарихы белән кызыксынучыларга, галимнәргә, Азнакай районы мәктәпләренә һәм музейларына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-389-8
УДК 94(470.4+470.5)
ББК 63.3(235.5)

© Кәримов Т.Т., 2023
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2023

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз ........................................ 4

**I бүлек. Азнакай төбәге һәм татар авыллары тарихын өйрәнү проблемалары** ........................................ 6

**II бүлек. Азнакай төбәге авыллары тарихы** ........................................ 8

§ 1. Азнакай ........................................ 8
§ 2. Әгерҗе ........................................ 28
§ 3. Әсәй ........................................ 39
§ 4. Балтач ........................................ 53
§ 5. Зур Сукаеш, Түбән Сукаеш, Банки Сукаеш ........................................ 64
§ 6. Илбәк ........................................ 83
§ 7. Карамалы ........................................ 94
§ 8. Кәкре Елга ........................................ 104
§ 9. Күктәкә ........................................ 118
§ 10. Мәлбагыш һәм Түбән Якый ........................................ 140
§ 11. Мәндәй ........................................ 154
§ 12. Мәсгут ........................................ 166
§ 13. Митрәй ........................................ 180
§ 14. Сәпәй ........................................ 192
§ 15. Тымытык ........................................ 204
§ 16. Туйкә ........................................ 223
§ 17. Уразай ........................................ 234
§ 18. Үчәлле ........................................ 245
§ 19. Чубар Абдул ........................................ 255
§ 20. Чемодурово ........................................ 266
§ 21. Чекан ........................................ 276

**III бүлек. Азнакай төбәге нәселләре тарихы (История родов Азнакаевского края)** ........................................ 286

§ 1. Шеджере Туеша (д. Какре-Елга; генеалогические древа Р.Г. Гильманова, Р.З. Тимерзянова, Р.Г. Салахова) ........................................ 286
§ 2. Шеджере К.С. Галимова по отцовской (д. Масягутово) и материнской (д. Катимово) линии ........................................ 288
§ 3. Шеджере Р.Х. Зарипова по отцовской (с. Тумутук и с. Сарлы) и материнской (с. Балтачево и с. Кук-Тяка) линии ........................................ 297
§ 4. Шеджере Р.Р. Сабирова по отцовской (д. Тойкино) и материнской (д. Балтачево) линии ........................................ 303

Йомгак урынына ........................................ 313
Кыскартмалар / Сокращения ........................................ 314
Автор турында мәгълүмат ........................................ 315

# КЕРЕШ СҮЗ

Азнакай төбәге тарихын җентекләп һәм фәнни яктан өйрәнү проблемасын бу юлларның авторы 1994 елда кузгатты. Ул чордагы район хакимияте (җитәкчесе Ә.Г. Исхаков) мәсьәләнең әһәмиятен аңлап, минем тәкъдим буенча район карарын кабул итте. Менә шулай район төбәк тарихын өйрәнү музее белән берлектә зур эшкә керештем. Бу хакта район гәзите түбәндәгеләрне язды.

«Үзебезнең якның һәм торак пунктларның тарихы әлегәчә халыкка аз билгеле. Моңа бәйле рәвештә район һәм шәһәр хакимияте Азнакай районы торак пунктлары тарихын өйрәнү һәм торгызуны оештырды.

Төбәкне өйрәнүчеләргә һәм белгечләргә ярдәм итү максатыннан, хакимият башлыгы җитәкчелегендә оештыру комитеты төзелде. Комитет составына районның төбәкне өйрәнү музее директоры Г. Хисамиева һәм Казан шәһәренең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Т. Кәримов җитәкчелегендәге эзләнү һәм тикшеренү группасы керә.

Эзләнү группасы Мәлбагыш, Уразай, Тымытык, Карамалыда, Актүбә эшчеләр поселогында булып, иң өлкән яшьтәге кешеләр, авыл тарихын өйрәнүчеләр белән күрештеләр, мәктәп музейларында булдылар.

Эзләнү эшләренә шулай ук укучылар, эшче яшьләр дә тартылачак һәм группа материаллары укыту процессында, класстан тыш эшләрдә киң файдаланылачак. Шуның өчен эзләнү группасы тарих укытучылары белән очрашты. Группа мәгариф идарәсе каршында оешкан яшь туристлар станциясенең тәҗрибәсен һәм материалларын куллана.

Барлык теләүчеләрне бу кызыклы һәм изге эштә катнашырга чакырабыз. Әлеге мәсьәлә буенча редакциягә (телефон [...]), төбәкне өйрәнү музеена (телефон [...]), район һәм шәһәр комитетына (телефон [...]) мөрәҗәгать итәргә»[1].

Менә шулай Азнакай төбәге тарихын җитди һәм фәнни яктан өйрәнергә керештем. Бу эшне башлап җибәрү бары тик район хакимияте башлыгы Әнәс Гатуф улы Исхаковның мәсьәләнең әһәмиятен аңлап, бу юллар авторы белән килешү төзүе аркасында мөмкин булды. 1994 елның август башында Казаннан ук үзенең машинасына утыртып алып кайтып, шул вакыттан төбәк тарихын өйрәнү башлансын өчен бөтен шартлар тудыручы ул булды.

Азнакай төбәге тарихын өйрәнә башлаганда галим буларак фәнни яктан әзерлегемнән тыш, берникадәр мәгълүматларым бар иде. Мәскәү һәм Уфа архивлары чыганакларын өйрәнеп, кайбер авылларның барлыкка килү тари-

[1] Туган ягыбыз тарихы // Маяк. 1994 ел. 20 сентябрь.

хын ачыклаган идем. Район җитәкчесенең кызыксынуы һәм ярдәме булгач, авыллар тарихын өйрәнү күпкә җиңелләште.

Берничә ел эчендә егермедән артык авылның тарихын өйрәнеп, зур фәнни мәкаләләр-очерклар яздым, аларның шактые гәзит-журналларда дөнья күрде, соңрак башка авторларның дистәдән артык китапларында кулланылды.

Азнакай районы авыллары тарихын 1994 елда өйрәнә башлауның гаять зур әһәмияте шунда булды, бу вакытта инкыйлапка чаклы туган әби-бабайларның шактые исән, алардан истәлекләр һәм риваятьләр язып алу мөмкинчелеге бар иде. Район авылларында йөргәндә моннан тулысынча файдаланырга, алар сөйләгәннәрне тарихи очерклар язганда кулланырга тырыштым.

Соңгы ике дистә елдан артык вакыт эчендә дә Азнакай төбәге тарихына игътибарым кимемәде, чыганаклар ачыклауны һәм өйрәнүне дәвам итеп, элек язганнарга яңа мәгълүмат өстәп аерым китап чыгарырга булдым. Мондый китапның төп әһәмияте шунда, аерым-аерым авыл тарихларын укып, төбәкнең үткәнен тулырак күзаллау мөмкинчелеге туа.

Авыллар тарихын шәҗәрәләр тулыландыра төшә. Шуны истә тотып, китапның соңгы бүлеген шәҗәрәләргә багышладым. Нәсел тарихларын өйрәнә-өйрәнә, без ата-бабаларыбызның кайсы чорларда һәм нинди шартларда яшәвен, берникадәр тормыш рәвешен күз алдына китерә алабыз. Билгеле, моның өчен үз авылыңның тарихы турында тулырак мәгълүматлы булу кирәк. Шулай итеп, авыл һәм нәсел тарихлары бер-берсен тулыландыра, белем офыкларын киңәйтә.

Бүгенге көндә авыллар тарихын өйрәнү ни дәрәҗәдә? Кемнәр һәм ничек өйрәнә? Бүген дә актуаль булып калган бу сорауларга, шул теманы даими өйрәнгән галим һәм дистәгә якын китап авторы буларак фикеремне әйтми кала алмыйм. Шуңа күрә китабымның беренче бүлеген шул мәсьәләгә багышладым. Автор мөнәсәбәте бу китапны кулларына алган укучы өчен кызыклы булыр, кайбер нәрсәләр турында уйланырга мәҗбүр итәр.

# I БҮЛЕК.
# АЗНАКАЙ ТӨБӘГЕ ҺӘМ ТАТАР АВЫЛЛАРЫ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Азнакай төбәге авылларының ничек барлыкка килүен тирәнтен күзаллау өчен Юрмый, Ирехтә, Кыргыз һәм Нәдер волостьлары тарихын өйрәнү кирәк. Әлеге волостьлар биләмәчеләрдән (вотчинниклардан) һәм алар рөхсәте белән яисә аннан башка килеп утырган халыктан торган. 1916 елгы хуҗалыклар санын алу документларында Азнакай төбәге биләмәчеләренең сословиесе – башкорт, милләте татар дип языла. Моңарчы беркем игътибар бирмәгән һәм җитди өйрәнелмәгән әлеге документларның копияләрен туплап, автор 1994–1997 елларда Азнакай төбәкне өйрәнү музеена тапшырды, бу чыганакны үзенең мәкаләләрендә һәм тарихи очеркларында беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертте.

Биләмәчеләрнең сословиесе – башкорт, милләте татар дип язылуны белү бик әһәмиятлеме соң? Бүгенге көн күзлегеннән караганда, төбәк тарихын дөрес һәм гадел өйрәнү шуңа барып тоташа. Ни өчен дигәндә, кайбер авторлар гаделсезлек һәм тарихны бозу юлына басып, архив документларындагы «башкорт» сүзен милләт итеп күрсәтмәкче булалар. Азнакай төбәге караган Кама арьягында һәм хәзерге Башкортостанның күпчелек территориясендә алар күз алдында торткан «башкорт»ларның бөтенләй булмавын белә торып, тарихны бозып язган китаплары белән татарның милли аңына зыян салмакчы булалар. Әмма интернет челтәре тормышыбызга тирән үткән заманда, акны карадан аеру җиңел, архив чыганакларын, татар галимнәренең (шул исәптән бу юллар авторының) гадел аңлатмаларын-язмаларын һәркем таба һәм укый ала.

Милли аңга зыян күбрәк булсын диптерме, гаделсезлекне алга сөрүче авторлар «типтәр» сословиесенә кергән татарларны, алар татарлар түгел, «типтәр» милләте итеп күрсәтмәкчеләр. Хәтта аларның бер өлешен «башкорт»лар тәшкил иткән дип яза башладылар. Билгеле, моны исбатлар өчен алар архив документларына таянмыйлар (чөнки андый чыганаклар юк), фараз кылып кына әйтәләр. Типтәр сословиесенә, мәсәлән, зур төркем марилар да кергән, әмма бу хакта алар язмыйлар. Чөнки моны язсалар, ачык күренәчәк: әлеге сословиегә кергән татарлар – татар, марилар мари булып калган. Шул ук марилар «башкорт» сословиесенә дә кергәннәр[1], әмма

[1] Каримов Т. Как марийцы стали башкирами-вотчинниками и продавали земли // Восточное Закамье как один из очагов этногенеза и культуры татарского народа: Материалы Межрегиональной научно-практической конференции, посвященной 90-летию Актанышского района и 310-летию основания Актаныша. Казань, 2020. С. 222–228.

барыбер мари булып калганнар. Нинди сословиедә торуга карамастан, милләт үзенең сыйфатларын, гореф-гадәтләрен, телен, үзаңын югалтмый. Мариларга сез «башкорт» булгансыз дип әйтсәләр, алар моңа сәерсенеп карарлар иде. Татарлар белән дә шул ук хәл, алар тарихны бозып башкортлыкны алга сөргән адәмнәргә гаҗәпләнеп кенә түгел, нәфрәтләнеп карыйлар. Ни өчен дигәндә, милләт ана сөте белән бирелгән, шуңа күрә ана теле милләт теле дип әйтелә. Милләтебезгә кагылучыларга битараф кала алмыйбыз, һәр халык санын алу алдыннан шул мәсьәләгә бөтенләй кирәкмәгән сәяси төсмер бирүчеләрне тәнкыйть утына тотабыз. Бүгенге татар белән башкортның төп проблемасы – милләтләрне бетеп барудан саклап калу, игътибар шуңа юнәлгән булырга тиеш. Татар исәбенә «башкорт»ны арттырырга омтылучылар гаделсезлектән туктарга тиеш, чөнки бу милләтара татулыкка, үзара мөнәсәбәткә зыян сала.

Архив документларында биләмәчеләрнең сословиесе – «башкорт», милләте татар дип язылу турында әйттек. Азнакай төбәгендә яшәүче типтәр сословиесендәгеләрнең дә милләте бары тик татар дип языла. Төбәк тарихын өйрәнүчеләргә бу документлар яңалык түгел, боларны ялган тарих язучылар гына күрмәмешкә салыша. Тарихыбыз әнә шундый чыганакларга таянып, гадел язылырга тиеш.

Бүгенге көндә Азнакай районы авыллары тарихы буенча берничә дистә китап чыккан. Анда тарих никадәр гадел, дөрес һәм тирәнтен яктыртыла? Әйе, ул китапларның дистәдән артыгында бу юллар авторының 1994–1997 елларда язган тарихи очерклары тулысынча кулланыла. Болай әйткәндә Әсәй, Кәкре Елга, Күктәкә, Митрәй һәм кайбер авылларның борынгы тарихларын күз алдында тотабыз. Ә менә калган китапларда 1917 елга чаклы тарих тиешле дәрәҗәдә гадел һәм тулы яктыртылган дип әйтеп булмый. Автор-төзүчеләрнең төбәк тарихы буенча әзерлекләре һәм белемнәре җитеп бетми.

Татар тарихының төп бәласе – авыллар тарихы өлешчә булса да тулы һәм җентекле, фәнни яктан аз өйрәнелгән. Азнакай төбәге авыллары тарихы буенча бу китапны басмага әзерләгәндә, авыллар тарихын фәнни дәрәҗәдә өйрәнү актуаль булуына мин кабат инандым. Төбәк тарихына багышланган язмалардагы хаталардан арынырга вакыт җитте, бу хезмәтем шул яктан күпмедер булса да ярдәм итәр кебек.

Азнакай төбәге авыллары тарихы буенча бу китабымның фәнни яктан әһәмияте югарыда әйтелгән әдәбияттагы хаталарны күрсәтеп үтү белән генә чикләнми, әлбәттә. Китаптагы яңа мәгълүмат татар халкы тарихын тулырак күзалларга ярдәм итә һәм аны фәнни яктан баета, сословиеләр буенча дөрес фикер йөртергә җирлек тудыра. Безнең тарихыбыз авыллардан башлана, шуңа күрә алар һәрдаим игътибар үзәгендә булырга тиеш.

# II БҮЛЕК.
# АЗНАКАЙ ТӨБӘГЕ АВЫЛЛАРЫ ТАРИХЫ

## § 1. Азнакай

Бу атаманы телгә алуга ук укучы, беренче чиратта, Татарстанның көньяк-көнчыгышында урнашкан нефтьчеләр шәһәрен күз алдына китерер. Аның шәһәр чоры тормышы, газета-журналларда гел язып торганга, күпләргә мәгълүм. Ә кайчандыр аның авыл булып барлыкка килү һәм үсү тарихы моңарчы өйрәнелмәде. Архив һәм башка чыганакларга таянып, әйдәгез, гасырлар катламына күз салыйк.

Азнакай җирләренә ясаклы татарлар ике төркем булып килеп утыра. Аларның кайсысыдыр, 1743 елның 1 июнендә Юрмый волосте биләмәчеләре (вотчинниклары) белән килешү төзегән[1]. Әлеге документ ясаклы татарларга мондагы җирләргә хокук бирә, соңыннан аларның типтәр сословиесенә күчерүләренә сәбәп була.

1743 елны Азнакай тарихында иң әһәмиятле даталарның берсе итеп карарга кирәк, әмма авыл аңарчы да яшәп килгән. Моңа басым ясап әйтүемнең сәбәбе шунда, кемдер бу юллар авторы 1995 елда язган Азнакай тарихын игътибарсыз укып, авыл 1762 елда нигезләнгән дигән ялгыш нәтиҗәгә килә, район хакимиятенә шул датаны тәкъдим итә һәм ахыр чиктә ул рәсми дата булып китә. Соң булса да уң булсын дигәндәй, Азнакай 1762 елда нигезләнгән[2] дип язудан туктарга кирәк.

1748 елгы ревизия документы сакланмаганлыктан, Азнакайда кемнәр яшәгәнен беренче тапкыр 1762 елгы исемлекләрдән беләбез. Аның халкы бу чорда Байлар волостена караган ике командада күрсәтелә. 16 ир-ат – старшина Мәсәй Хәсәнов, тагын 56 ир-ат старшина Сөендек Тукбаев командасы исемлегендә бирелә. Шул ук документта авылның Мәнәүс елгасы буенда урнашканлыгы турында да әйтелә[3].

1762 елда старшина Мәсәй Хәсәнов командасында теркәлгән Азнакай ир-атларын атап үтик. Болар – Айдагол Аднаголов (81 яшь; уллары Мөстәкыйм һәм Сәгыйть; оныклары Сәлимҗәүһәр, Габдессәлам, Сөендек (барысы

---

[1] Малоизученные источники по истории Башкирии. Уфа, 1986. С. 90.

[2] Азнакай 1762 елда нигезләнгән дип язуның бер мисалын кара: Мөхәммәтҗанова Л.Х. Исеме үк җырлап торган Азнакай ул! // Туган җир. 2020. №3–4. 209–220 б.

[3] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3801 сакл. бер., 527–528, 937–941 б.

да Мөстәкыймнең уллары)), Биктимер Кошумбаев (35; уллары Йөзәй һәм Хөсәен), Сарманай Миңлебаев (42; уллары Миңлегол һәм Юмагол)[4].

Исемлектә беренче булып күрсәтелгән Айдаголның атасы **Аднагол** (Азнагол) булган. Шул исемдәге Азна (атна – җомга) сүзенә “кай” иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып Азнакай дигән диалекталь исем барлыкка килгән, дип уйларга кирәк. Мондый исем атна көнне туган ир балага кушыла торган булган[5].

Айдагол 1681 елда дөньяга килгән, димәк, аның атасы Азнакай (Азнагол) бу якларга чама белән XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башларында килеп утырган булып чыга. Моны тагын да дәлилләр өчен чыганакларны өйрәнүне дәвам итәргә кирәк.



*Азнакай авылының 1762 елгы исемлегендә беренче булып Айдагол Аднаголов теркәлгән*

Азнакайлыларның икенче төркеме 1762 елда старшина Сөендек Тукбаев командасына керә дип әйттек. Болар түбәндәге ир-атлар: 1) Котлымәт Исмәгыйлов (50 яшь; уллары Котлы, Йосыф); 2) Йөзәй Ишмәкәев (45; уллары Абдул (30; анықы Әмин, Хәлил), Илмәт (16) һәм Рәфикъ); 3) Балтай Ишмәкәев (64; уллары Габдүкәй, Габдрахман (31; анықы Мөэмин, Әмин), Габдерәззак (25), Габдерәшит (27; анықы Габдерәхим)); 4) Гадел Ишмәкәев (мәрхүм; уллары Колшәрип (27; анықы Ягъфәр, Ярмөхәммәт), Бакый (25; анықы Ишмөхәммәт), Якый (21), Сәлим (4)); 5) Тукташ Тукаев (75; уллары Бикбау, Ибрай); 6) Биккол (57; уллары Бикчура, Сәгыйть, Салих, Хәмит, Вәлит) һәм Юлдаш (10) Кадермәтовлар; 7) Гомәр (40; уллары Госман, Әхмәр, Тимеркәй) һәм Бакир (16) Мәмәтәевлар; 8) Хәлил Бохаров (37; уллары Җәлил, Рәфикъ, Рамай, Аднагол); 9) Биккенә Чәмкәев (45; улы Бикмөхәммәт); 10) Ишбулат Ишмәтов (85); 11) Юлдаш (33; улы Мәвлүкәй), Кинҗә (24), Хәсән (18) Мерәсовлар; 12) Габдүкәй (30; уллары Габ-

[4] Шунда ук, 527–528 б.

[5] Саттаров Г. Татар исемнәре сүзлеге. Казан, 1981. 26 б.

делкадыйр, Габделҗәлил, Габделваһап), Мәвлүкәй (26), Мәвлүм (?14) Хәсәновлар. Ревизия исемлегенең соңгы битенә староста Котлымәт һәм үз араларыннан сайланган («выборной») Габдүкәй Хәсәнов тамгаларын салганнар[6].



*Азнакайлыларның икенче төркеме (1762 ел)*

Шулай итеп, 1762 елда Азнакайда барлыгы 72 ир-ат ясаклы татар исәпләнә. Моннан соңгы халык санын алу документларында алар бары тик типтәр сословиесендә теркәлә.

Емельян Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы (1773–1775 еллар) төбәкне читләтеп үтми. 1775 елның февралендә Уфа провинциаль канцеляриясеннән Оренбург губерна канцеляриясенә җибәрелгән документта («ведомость»та) күп кенә баш күтәрүче авыллар санап үтелә. Шулар арасында Азнакайны һәм төбәкнең дистәләгән татар авылларын күрәбез.

Риваятьләргә караганда, пугачевчылар мондагы Чатыртауда чатырлар корып, хөкүмәт гаскәрләре белән сугышларга әзерләнеп ятканнар. Ике-өч дистә еллар элек таудагы мәгарәдән шпага һәм кылычлар табылуы хакында бу юлларның авторына берничә кешедән ишетергә туры килде. Хәзер дә халыкта «Емельян куаклыгы» дигән урын турында истәлек саклану шул чорда төбәкнең пугачевчылар хәрәкәте белән тыгыз бәйләнештә булуына ишарәли.

[6] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3801 сакл. бер., 937–941 б.

1795 елда Азнакайда 46 хуҗалык исәпләнә. Өч сословиегә бүленгән халыкның төп өлешен типтәр сословиесендәге татарлар (161 ир-ат һәм 163 хатын-кыз) тәшкил итә. Башкорт сословиесендәге (6 ир-ат һәм 18 хатын-кыз) һәм ясаклы (4 ир-ат һәм 4 хатын-кыз) татарлар бик аз санда була. Беренчеләре «типтәр»ләрдән соң килеп утырган дип уйларга кирәк.

5 нче ревизия (1795 ел) документы Азнакайга әлеге ясаклы татарларның кайчан күчеп утыруларына ачыклык кертә. Сәйфелмәлек Мөслимов (44 яшь) һәм Гапсәлам Мостафин (28) гаиләләре (4 ир-ат һәм 4 хатын-кыз) монда Уфа казна палатасы указы (1795 ел, 11 июль) нигезендә Бәләбәй округының Кинҗәкәй[7] авылыннан килеп утыра. Азнакайга терәлеп торган Мәнәүстамак (архив чыганагында «Араслан Мелеус Тамак тож») авылында 8 ир-ат һәм 10 хатын-кыз яши. Болар берара сәүдәгәрлектә йөреп яңадан ясаклы татар булып язылган («из купцов в ясашные татары») Мәди (1716–1786; уллары Габделкәрим (55), Саткол (40), Мөхәммәт (33)) һәм Даут (1717–1794; улы Мөхәммәт) Имангуловларның гаиләләреннән тора[8].

1816 елга халык саны тагын да арта. Типтәр сословиесендәге татарлар 82 хуҗалык булып яшәүче 223 ир-ат һәм 219 хатын-кыздан тора. Ревизия исемлегендә беренче булып Котлы Котлыматов (1814 елда мәрхүм) һәм Ибраһим Котлыев (27 яшь) хуҗалыклары теркәлгән[9]. Башкорт сословиесендәге татарлар нибары 13 ир-ат һәм 3 хатын-кыз (3 хуҗалык) тәшкил итә[10].

1816 елда шулай ук лашман бурычын (чыганакта «лашманная повинность») башкаручы ясаклы татарлар да (11 ир-ат һәм 8 хатын-кыз; 4 хуҗалык) яши. Болар Сәйфелмөлек Мөслимов (64 яшь), Габделбәшир (41) һәм Габдерәшит (37) Сәйфелмөлековлар, Гапсәлам Мостафин (46) гаиләләреннән тора. Соңгысы бу мәгълүматны тапшыручы («податель») буларак ревизия документына татарча кул куйган[11]. Азнакайга терәлеп торган Арыслан (Мәнәвезтамак) авылында 8 ир-ат һәм 7 хатын-кыз (2 хуҗалык; Габделкәрим Мәдиев һәм Мөхәммәт Давыдов гаиләләре) яши. Алар да лашман бурычын башкаручы ясаклы татарлар булалар[12].

1855 елгы реформа буенча типтәр сословиесендәгеләрне «Башкорт» гаскәренә кушалар. Шул чордан Азнакай «типтәр»ләре дә «башкорт» дип атала башлыйлар һәм Кәкре Елга, Кәтем, Зур Сукаеш, Түбән Сукаеш, Банки Сукаеш, Арыслан (Мәнәвезтамак) авылларының шул сословиеләрдәге татарлары белән 23 нче кантонның 6 нчы юртасына керәләр.

[7] Хәзерге Башкортстанның Туймазы районы Райман авылы берара шулай аталган.
[8] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 67, 159–160 б.
[9] Шунда ук, 168 сакл. бер., 656–671 б.
[10] Шунда ук, 172 сакл. бер., 71 б. а.–72 б.
[11] Шунда ук, 197 сакл. бер., 520 б. а.–521 б.
[12] Шунда ук, 531–533 б.

1859 елның 16 маендагы ревизия документы буенча, Азнакайда югарыда әйтеп үткән «Башкорт» гаскәре карамагына караучы 477 ир-ат, 497 хатын-кыз (76 хуҗалык) исәпләнә. Халыкның күпчелеген типтәр сословиесендәге, әмма 1855 елдан «башкорт» саналган татарлар тәшкил итә. Болар исәбенә Исхак Исмәгыйлов (46 яшь), Фәррукша Габбәсов (31), ике хатынлы Йосыф Габделвахитов (57; аның улы Шаһимәрдан, чыганакта «урядник, в должности старшинского помощника»), Якуп Әминов (50; ике хатынлы), Дәүләтбай Тимербаев (41; «отставной солдат»), указлы мулла Габделгалим Зәйнелгабидинов (52; өч хатынлы) һәм башкалар керә. Башкорт сословиесендәгеләр 25 ираттан һәм 21 хатын-кыздан (5 хуҗалык), Габделгафар Габделваһапов (39 яшь), Гыйззәтулла Хисмәтуллин (27), Хисаметдин Исхаков (65), Төхвәтулла Исхаков (52) һәм Гайнулла Исхаков (48) гаиләләреннән тора. «Типтәр» сословиесендәгеләр бу ревизия документында «типтәрдән башкорт» (чыганакта – «*башкиры из тептярей*») дип язылган[13]. Азнакайда яшәүче дәүләт крестьяннары (элеккеге ясаклы татарлар) аерым исәпләнә, шуңа күрә бу документтагы 76 хуҗалык исәбенә кермиләр.

«Типтәр»ләрнең 1855 елдан «башкорт» булып китүе Самара губернасы буенча белешмә әдәбиятта да чагыла башлый. Шуның иң беренчесенә күз салсак, 1859 елда Азнакайда 549 ир-ат һәм хатын-кыз (213 хуҗалык) «башкорт»лар һәм дәүләт (казна) крестьяннары яши булып чыга[14]. Шулай итеп, «типтәр»ләр бөтенләй телгә алынмый: 1855 елда «Башкорт» гаскәре карамагына күчерелгәнлектән, статистик чыганакларда боларның сословиеләрен дә «башкорт» дип яза башлыйлар. Хуҗалыклар саны ике тапкырдан артык күбрәк булу, 16 майда ревизия булып үткәч яшь гаиләләрнең яңа хуҗалыклар булып теркәлүе белән аңлатыла.

Ревизия документына кайтыйк. 1859 елның 16 маенда Азнакайдан соң Арыслан (Мәнәвезтамак) авылы теркәлгән. Монда «Башкорт» гаскәре карамагына караучы нибары бер хуҗалык исәпләнә. Болар – Габделнасыйр Габделкәримовның варислары (уллары Исмәгыйль, Миңлегали һәм кызы Таҗенниса). Аларның сословиесе шулай ук «типтәрдән башкорт» (чыганакта – «*башкиры из тептярей*») дип язылган[15].

1885 ел ахыры – 1886 ел башына караган мәгълүматлар буенча, волость үзәге Азнакайда 293 хуҗалык, 746 ир-ат һәм 765 хатын-кыз була. Азнакай волостена тагын алты татар (Әсәй, Сәпәй, Уразай, Балтач, Әгерҗе, Туйкә) һәм бер рус (Холмовка) авылы кергән.

Азнакай авыл җәмгыятенең бу чорда 3830,4 дисәтинә – эшкәртергә уңайлы (чыганакта – «удобная земля»), 151,6 дисәтинә уңайсыз җирләре («не-

---

[13] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 757д. сакл. бер., 52–90 б.

[14] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

[15] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 757д. сакл. бер., 91–93 б.

удобная») була. Сөрүлекләр – 995,6, урман-куаклыклар – 979,2, печәнлекләр – 349,1, йорт яны җирләре һәм көтүлекләр 332,6 дисәтинәне алып тора.

Күренгәнчә, авыл җәмгыятенең биләмәсе зур. Әмма, сословиеләргә карап, аның күләме шактый аерыла. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-ат «башкорт»ка – 25, дәүләт крестьянына, ягъни элеккеге ясаклы татарга – 10,9, «типтәр»гә – 10 дисәтинә туры килә[16].

1889 елда Азнакайда 315 хуҗалык булып, 1610 кеше яши. Монда 2 мәчет эшли. Гыйбадәтханәнең икенчесе 1873 елда салына. Авыл җәмгыятенең 3891 дисәтинә – уңайлы, 45 дисәтинә уңайсыз биләмәләре була[17].

Гасыр ахырына Азнакай шактый зурая. 1897 елда андагы 371 хуҗалыкта 960 ир-ат һәм 972 хатын-кыз яши. Бу күрсәткечләр буенча ул волостьта беренче урында тора. Әсәйдә – 279 хуҗалык (719 ир-ат һәм 731 хатын-кыз), Сәпәйдә – 254 (705 һәм 687), Уразайда – 233 (630 һәм 606), Балтачта – 202 (531 һәм 516), Әгерҗедә – 156 (443 һәм 451), Туйкәдә 154 хуҗалык (429 һәм 393) исәпләнә. Волостьтагы бердәнбер рус авылы Александровкада ул вакытта 15 хуҗалык булып, анда 50 ир-ат һәм 55 хатын-кыз яши.

Әйтеп үтелгән Александровка – хәзерге Холмовка авылы ул. Холмовка атамасы документларда еш телгә алына. Әмма, бу кечкенә авылга нигез салучы Александр исемле алпавыт булганлыктан, кайбер очракта Александровка атамасы да кулланышта йөри. Авыл чама белән 1858–1860 елларда барлыкка килгән.

Авыллардан тыш, Мәнәвез (чыганакта Мәнәүс) елгасында бер утар (усадьба) һәм хуторлар була. «Шкаповка» дип аталган утар хуҗасы – дворян Ильин. Монда 32 ир-ат һәм 26 хатын-кыз гомер итә. Алпавытның 470 дисәтинә җир биләмәсе була[18].

«Шкаповка» атамасы Азнакай төбәгендә яшәүче өлкән буын кешеләренә яхшы таныш. Әмма аның ничек барлыкка килүен күпләр, мөгаен, белми дә торгандыр. Шуңа күрә ачыклык кертеп үтик.

1867 елда Самарада басылган бер китапта А.И. Шкапский телгә алына. Аның Бөгелмә өязендә өч урында биләмәләре булган. Берсе – 192, икенчесе – 444, өченчесе 462 дисәтинә зурлыкта. Әлеге биләмәләр еш кына аның исеме белән йөртелгән. Азнакай янындагы «Шкаповка» утары аныкы булып, ул аны дворян Ильинга саткан булуы бик мөмкин. Ильин үзе китапта күрсәтелми, димәк, ул бу тирәгә соңрак килеп төпләнә[19].

---

[16] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 12–17.

[17] Список населенных мест Самарской губернии по сведениям 1889 г. Самара, 1890. С. 59; БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер.

[18] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 110–112.

[19] Список гг. дворян, владеющих землею в Самарской губернии в 1867 г. Самара, 1867. С. 130.

Хуторларга тукталып үтик. Дворянка Герасимова биләгән хутор Шкаповкадан зуррак – 550 дисәтинә. Әмма монда нибары 11 кеше яши.

Герасимова хуторыннан соң, зурлыгы буенча икенче урында Шонкаров биләмәсе (431 дисәтинә) тора. Стәрле елгасы буенда урнашкан ул хуторда бер йорт булып, анда аның хезмәтчесе яшәгән. Монда ул тегермән дә тоткан.

Пискунов хуторы да (311 дисәтинә) Стәрле елгасында урнашкан. Әмма, башкалардан аермалы буларак, җир аның үз милке түгел, аны ул казнадан арендага алган. Пискунов шул җирләрнең бер өлешен тирә-як авыл кешеләренә арендага биреп, калган мәйданда, эшчеләр яллап, иген иккән.

Бу чорда Азнакай волостенда күп кенә (барлыгы – 17) су тегермәннәре була. Алар волость аша агучы өч елгада (Мәнәүс, Стәрле, Тегермән Елга) урнашканнар. Авыллар буенча алганда, Азнакай һәм Балтачка – дүртәр, Уразай һәм Әсәйгә – өчәр, Туйкә һәм Әгерҗегә икешәр тегермән туры килә[20].

Азнакайда игенчелекнең торышын тасвирлаучы мәгълүматларга тукталып үтик. 1900 елның 28 сентябрендә төзелгән документтан күренгәнчә, авылда арыш, солы, карабодай, борай, бодай һәм тары иккәннәр. Балчыксыл кара туфраклы һәм ашланган басуларда төп культура – арыш уңышы бер дисәтинәдән 40 (начар), 90 (уртача) һәм 150 (яхшы) потлап чыккан. Ә менә шундый ук туфракта, әмма тирес кертелмәгән басуларда яхшы уңган арыш 100 пот тирәсе генә чыга.

Икенче төп культура – солы – уңышы белән дә шундый закончалык күзәтелә. Беренче очракта уңышның түбәне – 40, уртачасы – 80, яхшысы 150 пот тәшкил итә. Икенче очракта исә шундый ук тәртиптә 35, 70 һәм 100 потлар.

Калган культуралар (карабодай, борай, бодай, тары, ясмык, борчак), арыш һәм солы белән чагыштырганда, шактый аз игелә. Карабодайны, яхшы уңганда, 1 дисәтинәдән 80 пот алганнар. Начар уңыш 25–30 пот тирәсе була.

Борай һәм бодай уңышы бертигез дәрәҗәдә. Начар уңыш – 40, уртачасы – 70, яхшысы 130 пот булган. Тарыныкы шундый ук тәртиптә 30, 60 һәм 90 потлар тәшкил итә.

Азнакай тирәсендәге җирләрнең бер өлеше чуерташлы кара туфрактан тора. Шуңа күрә монда уңыш та түбәнрәк. Мәсәлән, тирес кертелмәгән урыннарда арыш, солы һәм карабодайның чагыштырмача яхшы уңышы 80 пот булган.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, Азнакай игенчеләренең бөртеклеләрдән уңыш алуда яхшы гына күрсәткечләргә ирешүен билгеләп үтәргә кирәк. Уңыш мул булган елны икмәк гаиләне туйдыруга да, сатарга да җиткән. Әлбәттә, табигатьнең вакыт-вакыт көйсезләнүе аларны да зур сынаулар алдына куйган. Мондый елларны җитәрлек икмәк запасы булмаганнарга аеруча авырга туры килә.

[20] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 110–113.

Игенчелек кораллары гадилеге белән аерылып тора. Җирне гадәттә сукалаганнар. Яткын җирләр булса, аны сабан белән сөргәннәр. Күбрәк сука куллануны туфракның йомшак булуы белән генә аңлату дөрес булмас. Моның төп сәбәбе – атлар җитмәүдә. Сукалаганда бер ат җиксәләр, сабанга ике ат таләп ителгән.

Җирне 3,5 карыш (1 карыш = 4,4 см) тирәнлектә сөргәннәр. Аннан соң өчтән сигезгә кадәр эз калдырып яхшылап тырмалаганнар. 3 аты булган игенче, аларны алыштыра-алыштыра, көнгә 1 дисәтинә җир эшкәрткән.

Язгы кыр эшләре гадәттә 20–21 апрельләрдә башланып, майның 17 ләренә чаклы дәвам иткән. Бу чорда солы, карабодай, борай, тары, бодай, ясмык һәм борчак чәчкәннәр.

Арыш чәчеләсе җирләр 15 нче июньдә дә, август башларында да сөрелгән. Беренче сөрүдән соң шунда ук тырмаласалар, икенчесендә атна үткәч тырмалаганнар. Уҗым бодае өчен җирләрне сентябрьдә эшкәрткәннәр. Сөреп чыгуга тырмалаганнар, аннары кул белән чәчкәннәр.

Шулай итеп, кыр эшләре вакытында төп кораллар – сука, сабан һәм тырма. Тимер сабаннар һәм чәчкечләр Азнакайда әле булмый. Игенчелек хезмәтен күпкә җиңеләйтердәй башка төр эш кораллары, өч җилгәргечне исәпләмәгәндә, юк дәрәҗәдә.

1900 елда Азнакайда 348 хуҗалык исәпләнә. Аларның барлык җирләре 3981,8 дисәтинә тәшкил итә. Биләмәләрнең шактый өлешен сөрүлекләр (995,5 дисәтинә), урман (979,2), йорт яны җирләре һәм көтүлекләр (332,6) алып торган[21].

Мең дисәтинәгә якын сөрүлекләр Азнакай кебек зур авыл өчен аз, билгеле. Шуңа күрә күп кенә хуҗалыклар вакыт-вакыт казна җирен арендага алгалаганнар. Мәсәлән, Мөхәммәтсадыйк Сираҗетдинов – 10, Габдерәшит Фазуллин – 8, Василий Астафьев – 8, Мөхәммәтвәли Сираҗетдинов – 7, Миргали Әхмәтҗанов – 7, Мөхәммәди Искәндәров – 7, Мостафа Ибәтуллин – 7,5, Галиулла Гомәров 6 дисәтинә җирне арендага алалар. Калган хуҗалыкларның мондый җирләре азрак була. Казнадан арендага алган барлык җир участогы 150 дисәтинәдән арта. Арендага алган җир исәбенә хуҗалыклар чәчүлекләр яисә печәнлекләр мәйданын киңәйткәннәр[22].

Умартачылык аерым игътибарга лаек. Аның белән шөгыльләнүчеләр Азнакайда шактый гына була. Статистик мәгълүматлардан күренгәнчә, авылда 32 хуҗалык 122 баш умарта тота.

Умартачылык турында сүз чыккач, әйләнә-тирә табигатьнең матур һәм бай булуын искә төшереп үтү урынлы булыр. Авыл Мәнәүс елгасының уң як ярында урнашкан. Якындагы тау тирәләрендә чылтырап чишмәләр агып яткан. Чишмәләрнең генә түгел, елганың суын да, саф һәм чиста булганлыктан,

[21] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 16 сакл. бер.
[22] Шунда ук, 30 сакл. бер.

эчәргә кулланганнар. Авылдан ерак түгел урман башланган, хуш исле чәчәкле киң болыннар җәйрәп яткан. Моңа тагын җәен басуларда карабодай чәчәк атуын да өстәсәң, умартачылык өчен шартларның искиткеч уңай булуын күз алдына китерү кыен булмас.

XIX гасыр ахырында Азнакайда ике мәчет барлыгы хакында әйтелгән иде. 1900 елда авылның указлы муллалары булып Мөхәммәтшакир Фәттахетдинов һәм Мөхәммәтфатыйх Шакировлар торалар. Мөхәммәтшакир хәзрәт 46 яшьлек типтәр сословиесендәге татар була. Ул Уфа губернасы Бәләбәй өязе Сарсаз авылыннан (хәзерге вакытта Башкортстанның Шаран районына керә) күчеп килгән. Гаиләсе зур түгел – хатыны (30 яшь) һәм ике кыз баласы гына. Хуҗалыгында биш эш аты, 4 сыер һәм башка вак-төяк маллар асрый. Аның шактый гына имана һәм арендага алган җирләре була. Ул андагы 20 дисәтинәгә якын мәйданда иген игә. Хәзрәтнең умарталыгы да шактый зур (28 баш) була.

Мөхәммәтфатыйх Шакиров (35 яшь) – төп Азнакай кешесе, шулай ук типтәр сословиесендәге татар була. Ул хатыны (27 яшь), улы (1) һәм 2 кызы белән яши. Хуҗалыгында 4 эш аты, 6 баш мөгезле эре терлек (шуның икесе сыер) һәм 4 сарык асрый. Аның да имана һәм арендага алган җирләре зур була. Монда иген мәйданы 15,67 дисәтинә тәшкил итә. Йортында 2 хезмәтче эшли.

Ике хәзрәт тә Зәкиҗан Шаһгәрәевнең «Төрмәләр хатирәсе» исемле китабында телгә алына. Автор һәм аның китабы турында Күктәкә тарихында әйтелә, шуңа күрә махсус тукталып тормыйбыз. Безне кызыксындырганы – Зәкиҗан Шаһгәрәевнең Бөгелмә төрмәсенә этап белән барганда Азнакайда тукталуы. Бу хакта китабының икенче битендә ул болай яза: «*Юлда Азнакай авылында туктап минем үтенечем буенча кардәшем Фатыйх әфәнде ханәсенә төштек. Кардәшләрем мәсьәләне аңлап байтак кына мөтәәссир (кайгы-хәсрәтле. – Т.К.) улмышлар иде. Бигрәк тә икенче мәхәллә имамы карт хәзрәтнең (Шакир хәзрәтнең) хис вә мәрхәмәт илә кызгануы, йөзендән вә хәрәкәтендән мәгълүм булуы илә бергә доносчик А ... ны (автор бу кешенең исем-фамилиясен, цензура таләбен үтәп булса кирәк, күрсәтми. Архив документларын өйрәнү аның Тымытык мулласы Адылов Шаһиморат булуын раслый. – Т.К.) кылуында илә мәгълүм булмакта иде*».

Бу юллардан Мөхәммәтфатыйх хәзрәтнең – беренче, Мөхәммәтшакир хәзрәтнең икенче мәхәллә имамы булуы аңлашыла. Өстәвенә, икенчесен автор белән кардәшлек җепләре дә бәйләгән. Бөгелмә төрмәсендә ятканда һәм этап белән барганда Зәкиҗан Шаһгәрәев аның һәрдаим ярдәмен тоеп яшәгән. Хәер, бер Мөхәммәтфатыйх хәзрәт кенә түгел, бик күпләр Зәкиҗан хәзрәткә теләктәшлек белдерә, кулдан килгәнчә ярдәм итә. Моның шулай икәнлеге китапның 22 нче битеннән алынган түбәндәге юлларда ачык чагыла: «*Бу көн ахшамнан соң минем ихласлы дусларымнан Һади әфәнде (безнең уебызча, монда Һади Атласи турында сүз бара. – Т.К.) килде. Миңа булган ихласны, мине кызгануны күзеннән мөлдер-мөлдер туктаусыз аккан яшьләре тәгъриф*

*итмәктә иде. Безне иптәшләр илә бергә ашка чакырды, безнең иптәш солдатлар «Бу көн кич инде, иртәрәк булса, барган булыр идек» диеп йомшак сүз [...] илә юатып җибәрделәр. Берәр ярты сәгатъ үтмәде, әлеге Һади әфәнде ярты каз, ике булки, әллә никадәр акмай-коймак китерде».*

Документларга кайтып, мөәзиннәр турында әйтеп үтик. Аларның өлкәне – Шиһабетдин Зәйнелгабидинов (57 яшь). Аның гаиләсе хатыны (45), 4 улы, бер кызы, туганының кызы һәм килененнән тора. Ул күп мал-туар (5 эш аты, 4 сыер һәм башкалар) асрый, 21,72 дисәтинә мәйданда иген игә. Болардан тыш, аның 20 баш умартасы да була. Хуҗалыкта шактый эшне хезмәтчесе башкарган.

Мөәзиннәрнең икенчесе – Габдрахман Фазуллин (44 яшь). Ул хатыны (33), 2 улы һәм 2 кызы белән яши. Эш аты, 8 мөгезле эре терлек һәм 24 сарык асрый. Имана һәм арендага алган җирләрнең 10,27 дисәтинәсендә иген иккән.

Алдарак Азнакайда мәктәп булуы хакында әйтелгән иде. 1900 елгы мәгълүматлар Закирҗан Галимовның (30 яшь) елга 6 ай укытучылык белән шөгыльләнүен күрсәтә. Ул Азнакайда туып-үскән, гаиләсе һәм хуҗалыгы зур түгел. З. Галимовтан башка, ул чорда тагын укытучылар булганмы-юкмы, тәгаен әйтүе авыр.

Авылда сәүдә эшчәнлеге киң үсеш ала. Азнакай сәүдәгәрләрне волость үзәге һәм зур авылларның берсе буларак та җәлеп иткән. Аларның кайберләре монда лавка тотканнар. Шунысы күзгә ташлана, мондый сәүдәгәрләрнең барысы диярлек – Бөгелмә мещаннары. Алар монда кайчаннан яши башлаганнардыр, билгесез.

Лавка тотучылар арасында Хәмидулла Дәминов (40 яшь) төп Азнакай кешесе булуы белән аерылып тора. Аның гаиләсендә хатыны (30), 3 улы һәм кызы була. Ул 2 эш аты, 5 мөгезле эре терлек (шуның икесе сыер), 9 сарык һәм 3 кәҗә тота. Хәмидулла сәүдәгәр 10 дисәтинәдән артык иманадан файдаланган. Шуның 6,87 дисәтинәсендә ул иген иккән, 4,65 дисәтинәсен парга калдырган. Моннан тыш, 1,13 дисәтинә арендага алган участогында да чәчүлекләре була. Сәүдә эшен ул тулысынча үзе алып бара. Бары кыр эшләре вакытында гына эшчеләр яллаган.

Сәүдәгәрләрнең икенчесе – Хәсәнша Баязитов (25 яшь). Ул үзенең һәм абыйсының гаиләсе белән бер хуҗалык булып яши. Әлбәттә, һәрберсенең монда зур йортлары була. Баязитовларның хуҗалыгы сәүдәгәрләр арасында гына түгел, гомумән Азнакайда иң эре хуҗалык санала. Аларның сатып алган җир участогының 164,5 дисәтинәсен – сөрүлекләр, 8 дисәтинәсен – печәнлекләр һәм 9 дисәтинәсен урман алып тора. Калган 43,5 дисәтинә җир эшкәртелми, шуның 7 дисәтинәсен алар арендага биргәннәр. Баязитовлар арыш (15 дисәтинә), бодай (4,5), солы (4), тары (2), борай (1,5), карабодай (1,5) һәм борчак чәчкәннәр. Хуҗалыкларында 4 эш аты, 5 сыер, 30 сарык һәм 5 кәҗә асраганнар. Көндәлек эшләрне 2 ир-ат хезмәтче башкарган. Кыр эшләре вакытында аның басуларында көнлекчеләр дә бил бөккәннәр.

Лавка тотучыларның калганнары – Бөгелмә мещаннары. Болар арасында хуҗалыгының зурлыгы белән Мөхәммәди Искәндәров (40 яшь) аерылып тора. Ул хатыны (19), 2 улы (15 һәм 9 яшьләрдә) һәм кызы белән яши. Хуҗалыгында 8 эш аты, 8 сыер, 58 сарык һәм 1 кәҗә асрый. Читтән килгән булгач, аның Азнакайда иманасы булмый. Шунлыктан ул иген игәр өчен шактый җирне (14,24 дисәтинә) арендага ала. Ел әйләнәсенә сәүдә эше белән мәшгуль булганлыктан, үз хуҗалыгына аның вакыты аз кала. Мондагы эшләрнең күпчелеген хезмәтчесе башкарган, ә инде игеннәр өлгергәч, кыр эшләренә ул эшчеләр дә яллый торган булган. Сәүдәгәрнең 10 баш умартасы да була.

Тагын бер сәүдәгәр – Гәрәйша Искәндәров (46 яшь) – ел әйләнәсенә Сәпәйдә сәүдә иткән. Анда аның лавкасы була. Хуҗалыктагы авыр эшләрне 2 улы (25 һәм 19 яшьләрдә) башкарган. Гәрәйша сәүдәгәрнең мал-туары һәм чәчүлекләре аз була.

Лавка тотмыйча, аерым төр сәүдә белән шөгыльләнүчеләр дә игътибарга лаек. Беренче чиратта, икмәк сәүдәсенә тукталып үтик. Азнакайда моның белән шөгыльләнүче – Миргали Әхмәтҗанов (30 яшь). Ул да, югарыда телгә алынган сәүдәгәрләр кебек, чыгышы буенча Бөгелмә мещаннарыннан санала. Азнакайда анасы, энесе, хатыны, 2 улы һәм кызы белән яши. Икмәк сәүдәсе белән кыш айларында шөгыльләнгән. Моннан тыш, ул Азнакай земство стансасын тота. Аның атлары (11) почта ташыган, земствоның эреле-ваклы чиновникларын йөрткән. Әлбәттә, бу хезмәт өчен ул тиешле хак алган.

Ат кына түгел, башка мал-туары да күп була Миргали Әхмәтҗановның. Мәсәлән, сыерлары гына 6 баш исәпләнә. Имана җире булмый, шуңа күрә иген игәр өчен ул якын-тирә авыл кешеләреннән барлыгы 9,82 дисәтинә һәм казнадан 13,85 дисәтинә җир арендага ала. Кыш җиткәч, үзеннән арткан икмәкне сатуга алып чыга торган булган.

Миргали бер хезмәтче тоткан, кыр эшләре вакытында 300 көнлекче яллаган. Моннан тыш, берничә айга ялланган 3 эшчесе дә була. Земство стансасына бәйле эшләрне ул Җиһангир Әхмәтҗанов (45 яшь) белән бергә башкарган, ахры. Чөнки икенчесе документта ямчы (ямщик) дип күрсәтелә. Алар бертуганнармы-юкмы, монысын тәгаен ачыклап булмады.

Җиһангирның хуҗалыгы зур түгел, шуңа карамастан ул хезмәтче тота. Ям чабу хуҗалык эшләре өчен вакытны аз калдырган, күрәсең. Бу вакытта аның өлкән улына 16 яшь кенә була.

Г. Мөхәммәтҗанов (55 яшь) Сәпәй базарында тоз, дегет һәм керосин белән даими сату иткән. Шаһиәхмәт Рәхмәтуллин (53 яшь) дә бу базарга сатарга тоз алып чыккалаган. Әмма, Г. Мөхәммәтҗановтан аермалы буларак, моның белән ул кыш айларында гына шөгыльләнә. Аларның икесен дә урта хәллеләр рәтенә куярга була. Сату өчен кирәк-яракны Бөгелмәдән алып кайтканнар.

Мортаза Исмәгыйлов (40 яшь) йомырка сәүдәсе белән шөгыльләнгән. Ул чыгышы буенча Оренбург губернасы мещаны, хатыны (50) белән яши. Тормышы бай түгел: 2 кәҗә һәм 0,38 дисәтинә чәчүлек.

1897 елгы чыганактан Азнакайда 4 тегермән булуы хакында белгән идек. Тегермән хуҗаларының икесе (Ибәтуллин, Реутов) турында мәгълүматлар биреп үтик.

Мостафа Ибәтуллинга 1900 елда 63 яшь була. Ул хатыны (45 яшь), 3 улы һәм 4 кызы белән яши. Хуҗалыгында 6 эш аты, 7 сыер һәм башка вак-төяк маллар була; барлык чәчүлекләре 20 дисәтинәгә якын. Тегермәндә һәм йортында хезмәтчеләре (2) эшли.

Василий Реутов (43 яшь) авылга Вятка губернасы Алабуга шәһәреннән күчеп килә. Документта аның Азнакай авыл җәмгыятенең бер ташлы тегермәнен арендага алуы хакында әйтелә. Димәк, тегермән В. Реутовның үз милке булмый. Гаиләсе хатыны (36), 4 улы, 3 кызыннан тора. Ул 6 эш аты, 6 сыер һәм башка мал-туар асрый. Чит авыл кешеләреннән һәм казнадан арендага 15,63 дисәтинә җир алып иген игә. Хуҗалыгында бер хезмәтче тота.

Азнакайда төрле һөнәр белән шөгыльләнүчеләрнең күп булуы күзгә ташлана. Балта осталарын гына алыйк. Бу һөнәр белән даими шөгыльләнүчеләргә Дәмин Кәримов (67 яшь) һәм аның улы (исеме күрсәтелмәгән), Таҗетдин Гыйлаҗетдинов (65), Хәмидулла Хәйруллин (45) һәм Әхмәди Мөхәммәдиев (40) керә. Калган балта осталарының (Зәйдулла Заһиров, Хәлиулла Фәйзуллин, Гани Хәкимов, Нургали Хөснетдинов, Заһидулла Хәйруллин, Сәгыйдулла Хәйруллин, Солтангәрәй Шәнгәрәев) эш сезоны 2–6 ай тәшкил иткән. Вилдан Хәлиуллин (47) җәй көне көпчәкләр ясап саткан.

Төбәктән кайбер балта осталары Богырыслан өязенә, Уфа якларына, Чулман һәм Идел буендагы авылларга барып, агач әзерләү эшенә яллангannар. Мондыйлар Әсәй һәм Уразай авылларыннан аеруча күп була. Азнакайдан исә бер генә кеше (Сәлим Шәнгәрәев) күрсәтелә[23].

Статистик әдәбиятта алар хакында шундый юллар бар: «*С собой пильщики захватывают только пилу на плечо, подпилок за пояс и крюк, да на первое время немного хлеба в мешок. Работа с ходьбой в общей сложности продолжается не более 2 месяца и в течение этого времени зарабатывают на пару рублей 20 и 10 на человека. Подряжаются пилить с бревна длиною в 8 аршин по 5–6 коп. «с реза», с более короткого бревна 2–3 коп. «с реза». Но как в этом, так и в других промыслях, размер самого промысла и заработка зависят вполне от урожайности хлебов, так как строительная горячка в селениях настает большею частию после момента уборки хлебов. Случает-*

[23] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 20, 30 сакл. бер.

*ся, что татары исколесив «по стороне» верст 100–200 приносят домой каких-нибудь 4–5 рублей»*[24].

Агач кисүчеләрнең югарыда күрсәтелгән хезмәт хаклары зурмы соң? Моны белү өчен бер санга игътибар итик. Ул чакта эш аты уртача 25 сум торган. Димәк, мондый ат алу өчен бер кешегә биш айга якын урман кисәргә кирәк. Әле ярый, елы әйбәт килеп, бөтенесе уңышлы булса.

Йон тетү һәм киез итек басу шулай ук киң таралган һөнәрләрдән санала. Йон тетүчеләрнең (Халикъ Газизов, Харис Узиев) эш сезоны бер-ике айдан артмый. Киез итек басучылар арасында исә бу эш белән 2–3 айдан 8 айга кадәр шөгыльләнүчеләр була. Болардан Гатиятулла Гыйззәтуллин, Сәхипгәрәй Шәнгәрәев һәм Шәйхелвәли Гыйльмановларның исемнәре билгеле.

Тегүчеләр – авылда ике кеше. Аларның өлкәне – Хафиз Галимов (40 яшь). Ул ел буена бөтен авылга күлмәк-ыштан һәм башка кием-салым тегә торган булган. Икенчесе (Заһидулла Хәбибуллин) исә, тегүчелек белән кыр эшләреннән соң, елга 5–6 ай чамасы шөгыльләнгән.

Бүрек тегү остасы авылда берәү генә. Гыйльман Хәлиуллин (55 яшь) аны бары кыш айларында гына теккән.

Башка һөнәрчеләрдән тимерчеләрне (Әхмәтгәрәй Гәрәев, Котлыкай Гәрәев), чабатачыларны (Аллабирде Габдрахманов, Мөхәммәди Хәмидуллин), мич чыгаручыны (Бәдретдин Габсаттаров) һәм ташчыны (Гали Бадыкшанов) күрсәтеп үтәргә кирәк. Шулай итеп, 1900 елда авылда күп төрле һөнәр ияләре яши.

Һөнәрчелек югарыда телгә алынган кайбер кешеләр өчен төп керем чыганагы булып тора. Андыйлар аз-маз җирләрен арендага биреп, бөтен вакытларын һөнәрләренә багышлаганнар. Әмма һөнәрчелек белән кыр эшләреннән соң гына шөгыльләнүчеләр күбрәк. Алар моңа бары өстәмә керем чыганагы итеп кенә караганнар.

Шунысына игътибар итик, авыл хуҗалыгы эшләренә яллану да кайберәүләр өчен төп яисә өстәмә керем чыганагы. Көнлекче яисә хезмәтче булып яллanучылар арасында җирсезләр дә була, әмма бик аз – берничә генә кеше (берсе урыс милләтеннән).

Зиннәтулла Гайнуллин (48 яшь) һәм Шәнгәрәй Хәбибуллиннар ел буена диярлек авылда көнлекчелектә йөргәннәр. Аларның кәҗәдән башка малтуарлары булмый. Беренчесенең җире 5 дисәтинәдән арта. Шуның 3,27 дисәтинәсенә иген чәчкән, тагын 2,46 дисәтинәсен парга калдырган. Ш. Хәбибуллинның чәчүлекләре бераз азрак (2,39 дисәтинә). Мондый мисалларны тагын да китерергә була.

Якын-тирә хуторларга һәм усадьбаларга да көнлекчелеккә йөрүчеләр күзәтелә. Шуларның берсе – Хәйрулла Гайнуллин (40 яшь). Ул көзен бер ай

[24] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 100.

Микулин волостенда алпавыт Елачич имениесендә эшли торган булган. Үзенең исә чәчүлек җире аз (1,63 дисәтинә).

Елачичлар – төбәктә бай мал-мөлкәтле алпавытларның берсе. Бөгелмә өязендә иң зур җир биләмәсе аларныкы була. 1866 елгы исемлектән Франц Осипович Елачичның җир биләмәсе 10121 дисәтинә тәшкил итүен беләбез. Аның Бөгелмәдә һәм Петербургта йортлары була.

Елачичлар турында 1890 елгы мәгълүматларга тукталыйк. Ф.О. Елачич вафат булган, шуңа күрә телгә алынмый. С.К. һәм А.Ф. Елачичларның Бөгелмәдә һәм Микулин волостендагы Павловка авылында ике аракы куу заводы була. 1897 елда аларның Микулин һәм Сумароково волостьларындагы җир биләмәсе 10275 дисәтинә тәшкил итә[25].

Бөгелмә өяз земство җыелышы шәһәрне Самара-Златоуст тимер юлы белән тоташтыру турында карар кабул иткәч, Петербургта яшәүче статский советник (генерал-майорга тиң гражданский чин) А.Ф. Елачич ярдәм итәргә алына. Бөгелмә өяз управасы йомышы буенча, ул хөкүмәт даирәләрендә бу эш артыннан йөри[26].

Шулай итеп, төбәк тарихын кай яктан карасаң да, аның Елачичлар белән тыгыз бәйле икәнен күрәсең.

Сүз уңаеннан әйтик, югарыда телгә алынган Микулин волосте атамасы алпавыт Микулиннарга барып тоташа. Җир биләмәләренең зурлыгы буенча, Микулиннар бары Елачичлардан гына калыша. 1866 елда аларның барлык җирләре 6763 дисәтинә исәпләнә. Өлкән Микулин (Федор Федорович) – коллежский советник (полковникка тиң чин) дәрәҗәсендә, Михаил һәм Дмитрий исемле уллары була. Михаил Микулинның улы Николай 1890 нчы елларда Бөгелмә өяз земствосына гласный итеп сайлангач, шул земствоның Управа әгъзасы булып торуы мәгълүм. Бер үк вакытта Дмитрий Микулинның улы Александр да земствога сайлана. XIX гасыр ахырында аларның Микулино волостенда ике хуторы була. Аларның берсе – 20134 (?) дисәтинә зурлыкта, анда 2 су тегермәне була. Микулиннарның өченче биләмәсе (298 дисәтинә) Сумароково волостенда урнашкан.

Күренгәнчә, Елачичлар кебек, Микулиннар да төбәк тарихында билгеле роль уйный. Микулино авылының барлыкка килүе дә фәкать аларның эшчәнлеге белән бәйле. XVIII гасыр ахырында авылга бертуган Парфир һәм Павел Микулиннар нигез сала. Алар мондагы җирләрне 1788 елны полковник

[25] Самарский спутник на 1890 г. Самара, 1889. С. 225.

[26] Журналы с приложениями Бугульминского Уездного Земского Собрания сессии: чрезвычайных на 10 сентября и 2 декабря и 29 очередной с 25 сентября по 1 октября 1893 г. Казань, 1894. С. 88.

Н.Л. Сумароковтан 2500 сумга сатып алалар. 1859 елда Микулинода 39 хуҗалыкта 299 кеше яши, чиркәү һәм завод була[27].

Азнакайның 1900 елгы тормышын тасвирлауны дәвам итик. Авылда ике көтүче булган. Фәхретдин Афзалетдинов (35 яшь) – атлар, Идиятулла Фәйзуллин (30) сыер һәм сарыклар көткән. Көтү сезоны алты ай ярым-җиде айга сузылган.

Авылда тегермәнче булып эшләүчеләрне дә күрәбез. Мәсәлән, Газизулла Мөхәммәдиев (50 яшь) ел буена күрше Уразай авылы тегермәнендә эшләгән, анда ашлык салып торган.

Умартачылык турында сүз булса да, бу шөгыльгә бәйле кешеләрнең барысы да әйтелмәде. Алдарак телгә алынмаганнарын атап үтик. Госман Әхмәтҗанов – 35, Шәрәфетдин Әхмәтҗанов – 15, Гыйззәтулла Габбәсов – 15, Фазулла Вәлиев – 10, Мөхәммәди Хәмидуллин – 7, Хәйрулла Кәлимуллин – 6, Габдерәхим Ибраһимов 3 баш умарта тоталар[28].

Тормыш бит, төрле бәла-казалары да әледән-әле булып тора. Алар арасында еш кабатланып торганы – янгын чыгу. Статистик мәгълүматларга күз салсак, 1905–1912 еллар эчендә Азнакайда 19 янгын чыгу очрагы теркәлгәнен күрербез. Шуның нәтиҗәсендә 197 хуҗалыкка зур зыян килгән, күпләре йортсыз калган. Мәҗбүри страхование буенча взнос түләп барганлыктан, килгән зыянны каплау өчен бу хуҗалыкларга барлыгы 4414,13 сум акча бүленә[29].

1905–1907 еллардагы аграр хәрәкәт төбәкне читләтеп үтми. Бөгелмә өязендә аз җирле крестьяннар алпавытларның җирләрен, урманнарын бүлү турында ешрак сүз кузгата башлыйлар. Кайбер урыннарда, мәсәлән, Бәйрәкәдә, халык хәрәкәтен бастыру өчен хөкүмәт гаскәр куллана. Нәтиҗәдә, ике арада бәрелешләр була, кан коела.

Азнакай тирәсендәге авылларда крестьяннарның ничек җир даулауларын бер документ аеруча ачык чагылдыра. Ул «Представление Самарского губернатора 9 апреля 1907 г. министру внутренних дел» дип атала. Анда шундый юллар бар: «[...] *Засим бугульминский уездный исправник доложил мне, что 28-го марта в деревне Тетвель, Микулинской волости, Бугульминского уезда состоялся тайный неразрешенный сход жителей соседних селений: Чемодуровки, Алферовки, Оводовки, Старой Зверевой, Тимяшевой, Монашкиной, Ивановки, Владимировки, Александровки, Микулина, Малой и Большой Федоровок, Дмитриевки, Бирючевки, Старой Сумароковой, Фаев-*

---

[27] Список гг. дворян, владеющих землею в Самарской губернии в 1866 г. Самара, 1867. С. 67; МИБ. Т. 5. М., 1960. С. 238–239; Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 21.

[28] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 20, 30 сакл. бер.

[29] Поселенные данные о пожарности за 10 лет. 1903–1912 гг. Самара, 1914. С. 26–27.

*ского товарищества и Окружновки, на котором обсуждались аграрный и рабочий вопросы, при чем постановлено: если государственная дума не удовлетворит землей населения весной текущего года, то все население должно самовольно пахать владельческие земли, экономии разграбить, а рабочих перед началом полевых работ снять, и тем лишить владельцев возможности обрабатывать свои поля. Есть указания, что сход этот состоялся по инициативе члена государственной думы от Бугульминского уезда Атласова, который в письме своем советует составлять приговоры, излагая в них всю надобность в земле и другие нужды, и присылать эти приговоры ему. Кому было послано Атласовым письмо и какого именно содержания пока не выяснено. Дознание по сему делу производится»*[30].

Чыннан да, авыллар зурайган саен, җир җитмәүчәнлек торган саен үзен сиздерә башлый. Алпавытлардан һәм казнадан җир сатып алу бик азларның гына көченнән килгән. Хөкүмәт исә крестьяннарның хәлен яхшырту турында аз гына да уйлап карамый. Менә шундый шартларда аграр хәрәкәт башлануга җирлек туа.

Документта Һади Атласи фамилиясе телгә алыну очраклы түгел. Дәүләт думасына халык тарафыннан сайланган депутат буларак, ул аграр хәрәкәттән читтә кала алмый. Әлеге вакыйга (сход) Атласиның күпкырлы эшчәнлегенең бер ягын һәм, гомумән, Азнакай төбәгендәге авылларга аның йогынтысы зур булуын күрсәтә.

1910 елгы мәгълүматлар буенча, Азнакай 438 хуҗалыктан тора, анда 1024 ир-ат һәм 1017 хатын-кыз яши. Монда земство стансасы, волость идарәсе, хәрби хезмәткә чакыру пункты, урядникның фатиры урнашкан. 2 мәчет, мәктәп, 5 су тегермәне эшли. Ул элеккечә Самара губернасының Бөгелмә өязенә керә[31].

1891, 1892 һәм 1897–1898 еллар кебек, 1911 ел да авыл халкы өчен гаять авыр ел була. Җәйнең коры килүе аркасында, игеннәр башакка бөреләнмичә көя. Нәтиҗәдә, игенченең яңа уңышка өмете тәмам сүрелә, авыр, ач айлар башлана.

Иген уңмау Самара губернасының бөтен территориясен диярлек чолгап ала. Бу бәхетсезлек белән көрәшү өчен хөкүмәт шактый сумма акча бүлә, ачка интегүче халыкка төрле ярдәм оештыра. Әмма ул ярдәм ихтыяҗның бер өлешен генә канәгатьләндерерлек булганлыктан, аерым кешеләрдән һәм җәмәгать оешмаларыннан кергән иганә исәбенә ашханәләр ачып, бушлай туклану оештырырга кирәк була.

Шуны күздә тотып, Самара губернасында «Шәхси оешмаларның берләштерелгән комитеты» («Объединенный комитет частных организаций»)

---

[30] Аграрное движение в 1905–1907 гг. Том 1. М.-Л., 1925. С. 24.

[31] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1910. С. 92.

оештырыла. 1912 елның гыйнваренда аның беренче утырышы булып уза. Анда, комитетка ярдәмчел орган буларак, махсус комиссия төзелә.

Комитет кабул иткән карар буенча, ачлыктан интегүче халыкка фәкать азык-төлек белән ярдәм итү күздә тотыла. Бу максаттан ашханәләр ачып, бушлай тукланулар оештыру, андый мөмкинчелек булмаган очракта, он, тары ярмасы һәм май паеклары өләшү карала.

Ашханәләр ачу өчен иң башта вәкил яисә контролер урынга барып, халыкның күпме дәрәҗәдә ярдәмгә мохтаҗ икәнлеген ачыклаган. Аннан соң мохтаҗларның гаилә һәм матди хәле күрсәтелгән исемлек төзелгән. Бу исемлек махсус комиссиядә каралып, аның бәяләмәсе белән комитетка тапшырылган.

Баштарак, иген уңмау Бөгелмә өязенә, башкалар белән чагыштырганда, азрак зарар китергән дип уйлыйлар. Өяздә зәңгелә авыруы башланган дигән хәбәрләр Самарага барып ирешкәч кенә, апрель ахырында ярдәм оештырыла.

Азнакай ягындагы авылларга ярдәм оештыру гомум земство оешмасына (общеземская организация) йөкләнә. Аның җитәкчесе язмабызда телгә алынган С.А. Елачич була.

Азнакай волостеның Азнакай, Әгерҗе һәм Балтач авылларында ашханәләр ачыла. Волостька вәкил (Бирюзов), ашханәләр мөдирләре (Рязанова, Майкова һәм Горшенина) билгеләнә. Азнакайда 150 кеше – 31, Әгерҗедә 150 кеше – 26, Балтачта 150 кеше 37 көн дәвамында бушлай ашханәләрдә туклана. Азнакайда – 4650, Әгерҗедә – 3900, Балтачта 3550 порция өләшенә. Бер порция яисә паекның бәясе 3,5–4,1 тиен торган[32].

Азнакайда аерым кешеләрнең сәүдә эшчәнлеге хакында алдарак шактый әйтелде. Чираттагы мәгълүмат «Вся Россия» исемле белешмә әдәбияттан. Якуп Ильясов һәм Фәхретдин Исмәгыйловлар 1911–1912 елларда Азнакайда икмәк сәүдәсе белән шөгыльләнгәннәр. Әгерҗедән Гыймадетдин Галиуллин бакалея һәм мануфактура товарлары белән сәүдә иткән.

1913 елда Азнакай һәм төбәктәге башка авыл кешеләрендә зур кызыксыну уяткан вакыйга була. «Самара крестьян хуҗалыгын яхшырту җәмгыяте» («Самарское общество улучшения крестьянского хозяйства») Туйкә кредит ширкәте аркылы Туйкә, Уразай, Әсәй һәм Балтач авыллары хуҗалыкларына мал чөгендере орлыклары өләшеп, аны игүне оештыра. Көз көне бу авылларда, гомумән, төбәктә беренче тапкыр, чөгендер уңышы җыеп алына.

Чөгендерне барлыгы 44 хуҗалык чәчә. Аларның 13 ендә, шытымнар зарарлану сәбәпле, уңыш булмый. Калган хуҗалыклар югары уңыш алалар. Уразайдан Исламгали Солтангалиев иң югары уңыш алучы була. Ул 0,5 кадак (Россиядә фунт (кадак, гөрәнкә) – 409,5 граммга тигез булган үлчәү берәм-

[32] Отчет Самарской губернской земской управы по оказанию благотворительной помощи населению Самарской губернии, пострадавшему от неурожая из сумм частных пожертвований, при посредстве Объединенного комитета в продовольственную компанию 1912 года. Самара, 1913. С. 8, 102–103.

леге) орлык чәчеп, 40 пот чөгендер ала. Әлеге уңышны күпме мәйданнан алган, әйтеп булмый, бу хакта мәгълүмат юк. Орлык куе итеп чәчелгәнне искә алганда, чәчүлек мәйданы зур булмаган дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Туйкәдән Миңлегали Тәхаутдинов – 24, Балтачтан Исламголов – 16, Заһидулла Яруллин – 13, Әхмәтҗан Мөхәммәтҗанов – 10, Гыймаделислам Фәхрелисламов 10 пот чөгендер үстерәләр.

Самара крестьян хуҗалыгын яхшырту җәмгыяте турында берничә сүз. Ул 1907 елның 7 ноябрендә оеша. Аның максаты турында әдәбиятта болай әйтелә: «*Возникшее до введения участково-агрономической организации, Самарское Общество Улучшения Крестьянского Хозяйства поставило себе задачей доказать необходимость и целесообразность приближенной к населению агрономической помощи. С самого начала оно, естественно, направило свою деятельность на наиболее элементарные формы агрикультурного воздействия на крестьянское хозяйство и сосредоточило ее на довольно ограниченном круге технических приемов, выработанных местными сельскохозяйственными опытными учреждениями или установленными практикой наиболее культурных частных хозяйств...*».

Әйтергә кирәк, земство һәм дәүләт агрономия хезмәте күрсәтүне үз өстенә алгач, Җәмгыять үзенең эшчәнлеген үзгәртә төшеп төп игътибарны кооперативлаштыру хәрәкәтенә юнәлтә. Кредит ширкәтләре аркылы ул чәчкечләр, тырмалар һәм башка камилләштерелгән эш кораллары сатуны оештыра, кукуруз һәм чөгендер игүне пропагандалый, авыл кооперативларына акчалата ярдәм күрсәтеп, май заводлары төзергә ярдәм итә. Кооперативларда җитештерелгән продуктларны сатуны оештыру буенча да Җәмгыять кайбер эшләр башкара. 1910 елдан башлап ул «Самарский земледелец» исемле журнал чыгара. Анда авыл тормышы төрле яклап яктыртыла, әледән-әле абунәчеләрнең сорауларына җаваплар бастырыла. Журнал хезмәткәрләре үзләренең максатын түбәндәгечә күрсәтәләр: «[...] *Ознакомить своих читателей, в возможно доступной форме, с достигнутыми агрономической наукой результатами, уделяя преимущественное внимание опытным данным, добытых в условиях Самарской губернии. Злободневные вопросы агрономической теории и техники также не оставлялись неосвещенными на страницах журнала*»[33].

Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Азнакайда тагын бер мәчет салына. Аны төзергә рөхсәт 1910 елның 15 июлендә бирелә. 1913 елда өченче мәхәлләгә хатыйплыкка – Фәтхелбәян Насретдин улы Ярмәков, мөәзинлеккә Әгъләметдин Шиһабетдинов раслана[34]. Сугыш авылның социаль-икътисади үсешенә гаять тискәре йогынты ясый. Билгеле дәрәҗәдә бу 1916 елда

[33] Самарское Общество Улучшения Крестьянского Хозяйства. Отчет о деятельности и состоянии средств общества за второе трехлетие его существования (с 7 ноября 1910 г. по 7 ноября 1913 г.). Самара, 1914. С. 3, 11, 161–162.

[34] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер.

үткәрелгән авыл хуҗалыклары исәбен алу материалларыннан ачык күренә. Азнакайда 477 хуҗалык, 989 ир-ат һәм 1261 хатын-кыз теркәлә. Сугыш тәмамланмаган, шуңа күрә ир-атлар хатын-кызларга караганда күпкә аз.

Сугыш елларында Азнакай волостенда качаклар күренә башлый. Алар Азнакай (18 кеше), Уразай (15), Балтач (4), Әгерҗе (3), Сәпәй (2) һәм Әсәй (3) авылларына килеп утыралар. Азнакайда качакларның барысы да хатын-кызлар була.

Авыр сугыш елларында да авыл халкы күп мал-туар тота. Азнакайда барлыгы 876 ат (шул исәптән 711 эш аты), 927 мөгезле эре терлек һәм башка вак-төяк маллар, 3547 сарык һәм 875 кәҗә теркәлә[35].


Особое совѣщаніе для обсужденія и объединенія мѣропріятій по продовольственному дѣлу.
ВСЕРОССІЙСКАЯ СЕЛЬСКОХОЗЯЙСТВЕННАЯ ПЕРЕПИСЬ 1916 ГОДА.
Губернія, область: Самарская. Уѣздъ, округъ: Бугульминский
Волость: Азнакаевская. Общество (сельское, поселковое, аульное и пр.).
Селеніе (селокъ, аулъ, улусъ, имѣніе и пр.): Азнакаево
Фамилія, имя и отчество домохозяина: Шигабутдинъ Шарафутдиновъ
Сословіе или разрядъ крестьянъ: типтяръ. Національность: татаринъ
Приписной, посторонній, бѣженецъ. (Подчеркнуть).
№ по списку домохозяевъ: 140

*Азнакай буенча 1916 елгы документ фрагменты.*
*Сословиесе – типтәр, милләте татар дип язылган*

Билгеле, хуҗалыкларга карап мал-туар саны аерылган. Бигрәк тә гаилә башлыклары сугышка киткән хуҗалыкларга авыр була. Аларның мал-туарлары һәм чәчүлекләре азая.

Әлеге авыл хуҗалыгы исәбен алу документларында типтәр һәм башкорт сословиеләрендәге азнакайлыларның милләте татар дип язылган[36]. Патша хөкүмәте чорында бик сирәк очракта гына милләт күрсәтелә, шуңа күрә бу чыганак аерым игътибарга лаек.

Шулай итеп, Азнакайның 1917 елга чаклы тормышы күп кенә вакыйгалар, татар дөньясында билгеле кайбер шәхесләр белән тыгыз бәйле. Патша

[35] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 38 сакл. бер.
[36] Шунда ук, 35 сакл. бер.

хөкүмәтенең милли һәм икътисади изүе, башка авырлыклар аның яшәү көчен сындыра алмаган, гасырдан-гасырга үскән ул.

Совет чоры – Азнакайның үсешендә аерым, зур этап. 1918 ел ахырында авыл комиссары вазыйфасын Зарип Садыйков башкара. Волость башкарма комитеты рәисе итеп Газизулла Вәлиуллин сайлана. Закирҗан Габдуллаҗанов, Хәсән Кәримов, Миңлегали Вәлиев монда әгъза булып тора[37].

1920 елда Азнакайда 490 хуҗалыкта 2225 кеше яши. 1921 елгы ачлыктан күп гаиләләр кырыла, авыл кечерәеп кала. 1926 елда нибары 361 хуҗалык, 1578 кеше исәпкә алына. Авыл элеккечә волость үзәге булып тора, тик бу юлы – Бөгелмә кантонында[38].

Бөгелмә кантоны бетерелеп, бер ел вакыт үткәч, 1931 елның 30 октябрендә Азнакай районы оештырыла. Шул чордан авыл район үзәге булып китә. Тымытык районы бетерелгәч, аның территориясе дә Азнакай районына кушыла.

Утызынчы-кырыгынчы еллар авылны тагын сынаулар, фаҗигаләр алдына куя. Репрессияләр, аннары сугыш вакытында авыл йөзләрчә асыл ир-егетләрен югалта. Дөньялар тынычлана төшкәч, авылның йөзе үзгәрә, матур-матур йортлар төзелә, кешеләрнең дә күңеле көрәя төшә.

1956 елдан Азнакай – шәһәр тибындагы поселок. Төбәктә нефть чыгара башлау поселокның үсешен тизләтә. Кыска вакыт эчендә йөзләрчә йортлар, дистәләгән социаль-көнкүреш объектлары төзелә. 1987 елда Азнакай шәһәр статусын ала. 1997 елда монда 36,6 мең кеше яши, 9 урта һәм музыкаль мәктәпләр, профессиональ лицей, мәчет эшли. 1991 елның 2 декабрендә җөмһүриятебезнең Мәдәният министрлыгы приказы белән Азнакай төбәкне өйрәнү музеена нигез салына.

Азнакай шәһәре – төбәкнең промышленность (сәнәгать) үзәге дә. Монда «Азнакайнефть» нефть-газ чыгару берләшмәсе идарәсе урнашкан, «Нефть машиналары» тәҗрибә заводы, УАЗ автомобильләрен ремонтлау заводы, май җитештерү, ипи пешерү заводлары, тегү фабрикасы эшли.

Азнакай төбәгенең социаль-икътисади үсеше Әнәс Гатуф улы Исхаков эшчәнлеге белән тыгыз бәйле. 1971 елдан ук ул монда партия һәм административ-хуҗалык эшендә була. 1983–1992 елларда – район башкарма комитеты, ә 1992 елдан район халык депутатлары Советы рәисе вазифаларын башкара. Бүгенге көндә Әнәс Гатуф улы – Азнакай шәһәре һәм районы хакимияте башлыгы (1992 елдан), халык депутатларының берләштерелгән Советы рәисе (1995 елдан). Бер ук вакытта ул Татарстан Югары Советы депутаты (1990–1995 елларда), аннары Татарстан халык депутаты (1995 елда) булып сайлана.

Соңгы дистә ел эчендә район игенчелек һәм терлекчелек продуктларын, промышленность тауарларын җитештерүне сизелерлек арттырды. Нефтьче-

[37] Шунда ук, Р–1167 фонд, 1 тасв., 160 сакл. бер., 793–795 б.

[38] Шунда ук, Р–1296 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 107 б.

ләрнең дә эшләре көйле бара, «кара алтын» чыгаруда зур уңышларга ирештеләр. Мондый күтәрелешкә Әнәс Гатуф улының тынгысыз хезмәте һәм тырышлыгы аркасында ирешелде.

Төбәкнең рухияте дә читтә калмады. Язучыларның иҗат кичәләрен оештыру, аларның китапларын чыгаруга ярдәм итү – болар барысы да шәһәр һәм район хакимияте башлыгының турыдан-туры катнашлыгы белән башкарылды.

Монда туган-үскән халык үзенең тарихын да белергә тиеш бит әле. Димәк, тарих тирәнтен өйрәнелергә тиеш. Район хакимияте бу хакта карар кабул итеп, аның үтәлешен тәэмин итү өчен дә күп эшләде. Дистәләрчә авылларның тарихы язылу, төбәкне өйрәнү музеен ачу – соңгы елларда башкарылган эшләр. Тарих дәрьясы киң, бу өлкәдә тагын да күбрәк хезмәт куярга кирәк әле. Шул чакта без үзебезнең тарихыбызны мөмкин кадәр тулы белербез[39].

## § 2. Әгерҗе

Әгерҗе – Азнакайдан көньяк-көнбатышта, Әлмәткә баручы юлның сул ягында урнашкан уртача зурлыктагы авыл. Якындагы урман, Мәнәүс елгасы авылга ямь өстәп тора. Моннан шәһәргә алты чакрымлык төзек юл илтә.

Архив чыганагыннан күренгәнчә, 1732 елда монда Казан өязе Әгерҗе авылы ясаклы татарлары (30 ир-ат) күчеп килә. Болар Мәүлекәй Илмәтов (уллары Әмир, Хәлил, Искис[40]), Ибрай Акманов (улы Абдул), Мусай Акманов (уллары Абрек[41], Хәсән), Акманай Акманов, Бохар[мәт] (улы Бакый) һәм Кадермәт Тимәшовлар, Сөләйман Ишмәтов (улы Бакир), Киләй Ярмәчкин, Кәмәй Илмәков, Даут Ибраев, Гадел һәм Ишкенә Тимәшовлар, Мүкәй Сөләйманов, Аймәт Уразбахтин (улы Гомәр), Әхмәр Дусмәтов, Хөсәен Акманов, Мансур Кутуев, Абдулла Дусмәтов, Илкә[й] Бохармәтов, Кулай Әминков, Ишбулды Урманов була[42].

Төп халкы чыгышы белән Әгерҗедән булганлыктан, яңа барлыкка килгән авыл да шул исем белән атала. Шул чордагы чыганакларда «яңа нигезләнгән Әгерҗе» (документта «новопоселенная Агрыз») дип күрсәтелә ул.

Әмма яңа барлыкка килгән Әгерҗедә (Җөри юлы, Туйкә Абдулов йөзлегенә (сотнясына) керә) теркәлгән Әмир (41), Мәхмүт (35), Биктаһир (23) Мәүлекәевләр, Мансур Кутуев (59), Бакый Бохаров (39), Кадермәт Тимәшов (59), Абдул Ибраев (40) һәм башка ясаклы татарлар 1749 елда кире үз авыл-

---

[39] Бу юллар 1995 елда язылды. Бүгенге чорга караган мәгълүмат өстәүне кирәк тапмадык.

[40] 1762 елгы документта исемен Фәезгә төзәтәләр.

[41] 1762 елгы документта исеме Габбәс дип тә күрсәтелә.

[42] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1154 сакл. бер., 261 б. а.–262 б. а.

ларына, Арча юлындагы Иске Әгерҗегә кайталар. Ул авылда барлыгы 80 ир-ат һәм 69 хатын-кыз исәпләнә[43].

1748 елгы халык санын алу документында яңа барлыкка килгән Әгерҗедә (чыганакта «новопоселенная Агрыз») 69 ир-ат ясаклы татарлар теркәлгән. Алар барысы Казан өязе Әгерҗе авылыннан күчеп килгәннәр һәм Илбакый Исмәгыйлов йөзлегендә (сотнясында) торалар[44].



*Авылның 1732 елда нигезләнүен раслаучы документ фрагменты*

3 нче ревизия (1762 ел) вакытында Әгерҗедә 74 ир-ат ясаклы татар исәпкә алына. Шуларның берсе – Сөләйман Ишмәтов. Ул авылга нигез салучылар исемлегендә күрсәтелгән иде, озын гомер кичереп 1760 елда 85 яшьтә вафат була. Документта уллары Мөхәммәт (1762 елда 46 яшь), Бәкер (42), Биккол (20) турында да мәгълүматлар бирелә. Мәсәлән, Мөхәммәт йөзбашы («сотник») дәрәҗәсенә ирешкән. Тоба, Барҗы Омга һәм тагын ике авылдан 1758 елда берничә гаилә килеп утырган. Җөри юлының Иске Әгерҗе авылыннан да күченүчеләр була[45].

Моңарчы бу җирләр Юрмый волосте биләмәчеләре (вотчинниклары) кулында була. Шуңа күрә үзара килешү төзелә: хуҗалар күченүчеләрдән берьюлы 40 сум оброк, ә соңгылары исә җиргә тулы хокук ала.

Емельян Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы (1773–1775 еллар) башлангач, төбәктәге күпчелек авыллар, шул исәптән Әгерҗе, баш күтәрүчеләргә кушыла. Монда старшина Габдулла Ягъфәровның роле зур була. Чөнки фетнәгә чаклы авыл халкы аның кул астында булган. Старшина

[43] Шунда ук, 1188 сакл. бер., 352–359 б. а.
[44] Шунда ук, 1142 сакл. бер., 670–673 б. а.
[45] Шунда ук, 3795 сакл. бер., 335–342 б.

беренче көннән пугачевчылар сафына баса, карательләргә каршы сугышларда катнаша, әсирлеккә төшә һәм 1774 елның җәендә асып үтерелә.

Гасыр ахырында (1795 ел) Әгерҗе төбәктә уртача зурлыктагы авыллардан санала. Анда 34 хужалык булып, 103 ир-ат һәм 87 хатын-кыз яши. Ярмөхәммәт Габбәсов гаиләсе Уфа казна палатасы указы нигезендә 1795 елда Оренбург янындагы Каргалы (Сәет) бистәсенә сәүдәгәр булып күченә. Биктимеровлар (2 гаилә) Түбән Сукаеш авылына күчеп утыралар. Шуңа күрә Әгерҗедә 1782 ел (128 ир-ат һәм 109 хатын-кыз) белән чагыштырганда, халык саны кимрәк була[46].

Шунысы игътибарга лаек, бер гаилә (Таһир Бимәтов варислары) аерым теркәлгән. Болар берара Бөгелмә мещаннары булып саналып, Уфа казна палатасы указы нигезендә 1795 елда ясаклы татар сословиесенә күчәләр.

XIX гасырның беренче яртысында авылның үсешендә зур үзгәрешләр күзәтелми. 1816 елда, мәсәлән, монда 35 хуҗалык, 110 ир-ат һәм 112 хатын-кыз исәпләнә.

Авыл биләмәләрендә 2 су тегермәне була. Тегермән Елгада урнашканын – Зөбәер Әхмәров, Мәнәүстәгесен Урманайдан Абдул исемле кеше тота[47].

1834 елда Әгерҗедә беренче тапкыр типтәр сословиесендәге татар – Габдрахман Мәхмүтов (35 яшь) гаиләсе (3 ир-ат һәм 5 хатын-кыз) теркәлә. Бу нәсел монда 1775 елдан бирле яшәсә дә, моңарчы Бөгелмә өязенең Әлмәт авылында исәпләнгән[48].

1859 елда Әгерҗедә типтәр сословиесендәге татарлар 11 ир-ат һәм 16 хатын-кыз (4 хуҗалык) була. Исемлектә беренче кеше булып указлы мулла Габдрахман Мәхмүтов (60; ике хатынлы) күрсәтелә, аннары яңа килеп утыручылар – Ибәтулла Габдерәхимов (44; Кәкре Елгадан), Габделгани Сәйфуллин (39; Бөгелмә өязе Әлмәтмулла авылыннан), бертуганнар Әхмәтгали (22) һәм Сәфәргали (19) Корбангалиевләр (Чакмагыш авылы; 20 нче кантон). Алар документның титул битендә «башкорт», эчке битендә «типтәрдән башкорт» («башкиры из тептярей») дип язылган[49].

Типтәр сословиесендәге татарларның 1855 елдан «башкорт» дип языла башлавы Самара губернасы белешмә әдәбиятында да чагыла. Аның мәгълүматы буенча, 1859 елда Әгерҗедә 218 ир-ат һәм 207 хатын-кыз (65 хуҗалык) казна крестьяннары һәм «башкорт»лар санала[50]. Монда казна (дәүләт) крестьяннары дип элеккеге ясаклы татарлар аталган.

---

[46] БР МА, И–138 ф, 2 сакл. бер., 23 сакл. бер., 267–278 б.

[47] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 290 б. а.

[48] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 578 сакл. бер., 348–349 б.

[49] Шунда ук, 757 сакл. бер., 125–128 б.

[50] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

Шулай итеп, типтәр сословиесендәге татарлар саны бик аз була. Ревизия чыганакларын белмәү дип уйларга кирәк, кайбер авторлар сословиеләрне күрсәтеп үткәндә беренче итеп аз санлы «типтәр»ләрне язалар.

Авылда элеккечә бер мәчет эшли. 1862 елдан имам-хатыйп һәм мөгаллим вазифасын Габдрахман Габдерәхимов башкара[51].

1884 ел ахыры – 1885 ел башында Әгерҗе Азнакай волостенда (аңа тагын Азнакай, Әсәй, Балтач, Туйкә, Сәпәй, Холмовка керә) уртача зурлыктагы авыллардан санала. 132 хуҗалыкта 341 ир-ат һәм 337 хатын-кыз яши. 2 лавка, 19 хуҗалыкта 70 баш умарта була.

Авыл җәмгыяте ул чорда 1496,5 дисәтинә уңайлы һәм 93,9 дисәтинә унайлы булмаган җир биләгән. Аның 814,3 дисәтинәсен сөрүлекләр алып торган. Монда җан башына тигән җир күләме волостьның башка авылларына караганда шактый түбән була. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка бүлгән очракта ул 9,3 дисәтинә туры килә. Бу күрсәткеч кайбер башка авыллар (мәсәлән, Азнакай, Сәпәй) белән чагыштырганда түбән.

Әмма хуҗалыклар буенча җирнең күләме, ягъни иманалар саны шактый аерыла. Авылда 126 хуҗалыкның иманасы була. Шуларның 60 ында ул – берәр, 45 ендә – икешәр, 14 ендә – өчәр, 7 сендә дүртәр яисә аннан артыграк. Мондагы бер имана чагыштырмача түбән – 6,9 дисәтинә, шуңа күрә шактый хуҗалыклар аз җирлеләр төркеменә керә. 6 гаиләнең (хуҗалыкның) иманасы бөтенләй булмый. Аларның бер өлеше (12 ир-ат һәм 13 хатын-кыз) читтә яшәгән.

Җир сыйфатлы һәм вакытында эшкәртелсен өчен, беренче чиратта, эш кораллары кирәк. 102 хуҗалыкта алар җитәрлек, калганнарында – өлешчә (3) яисә бөтенләй булмый (17). Соңгылары кирәкле коралларны авылдашларыннан хак түләп яисә башка шартка килешеп ала торган булган.

Игенчелектән тыш, терлекчелек тә зур урын тота Әгерҗедә. Эш аты (239), мөгезле эре терлек (186), сарык (456) һәм кәҗә (236) асраучылар күп була.

Бу очракта да зур аерма күзәтелә. Эш атларын гына алыйк. 88 хуҗалык – берәр, 25 хуҗалык – икешәр-өчәр, 2 хуҗалык – дүртәр, 4 хуҗалык дүрттән дә күбрәк ат тотса, 6 хуҗалыкта алар бөтенләй булмый.

Шул ук вакытта 5 хуҗалыкның эш аты гына түгел, сыеры да булмый. Өстәвенә, бер гаилә йортсыз (соңгы 10 елда янгыннардан 29 хуҗалык зыян күрә). Андыйлар бик зур авырлык белән тормыш иткән.

Башка авыллардагы кебек, монда да игенчелек эшләренә яллanучылар (36 кеше) һәм һөнәрчеләр (4) була[52].

---

[51] БР МА, И–295 фонд, 3 тасв., 5662 сакл. бер., 8 б.

[52] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 10, 17.

1889 елда Әгерҗедә 137 хуҗалыкта 880 кеше яши. Элеккечә бер мәчет була. Уразай, Балтач, Әгерҗе, Туйкә, Холмовка һәм Шкапское авыллары белән Азнакай волостена керә ул. Соңгы икесе – XIX гасырның икенче яртысында барлыкка килгән рус авыллары. Беренчесендә – дворянка А.Т. Герасимова, икенчесендә дворяннар П.Н. Ильин һәм А.А. Соловьев утарлары урнашкан[53].

Гасыр ахырына Әгерҗе беркадәр зурая. 1897 елда 156 хуҗалыкта 443 ир-ат, 451 хатын-кыз исәпләнә. Элеккечә мәчет һәм 2 су тегермәне була. Аларның беренчесе Тегермән Елгада урнашкан, ул мещан Бобров карамагында, икенчесе – Мәнәүс елгасында, Галиуллинныкы[54].

Моннан алдарак төп игътибар хуҗалыклар һәм халык саны үсешен тасвирлаучы мәгълүматларга бирелде. Авыл тормышын тулы күз алдына китерү өчен, аның кешеләре турында сөйләп үтү әһәмиятле. Бу җәһәттән хуҗалыклар санын алу документлары игътибарга лаек.

Әгерҗедә бик күптәннән мәчет эшләп килүе хакында әйтелгән иде. 1900 елда монда Хикмәтулла Нигъмәтуллин (аңа 39 яшь) муллалык итә. Ул хатыны (26) һәм кызы белән яши. Мулланың хуҗалыгы зур түгел. Анда икешәр эш аты, сыер, бозау һәм 5 сарык була. Авыл җәмгыяте бүләк иткән 8,5 дисәтинә җирдә ул арыш (4,22 дисәтинә) һәм солы (4,56) игә. Моннан тыш, читтән дә арендага җир участогы (5 дисәтинәдән артык) ала. Анысы күбрәк печәнлек буларак файдаланыла. Хикмәтулла хәзрәтнең хезмәтчеләре юк, кирәк булганда вакытлыча эшчеләр яллый.

Авылның мөәзине – Габдерәүф Габдрахманов (50 яшь). Хатыны (51) һәм буй җиткән 3 улы белән яши. 3 эш аты, 2 колын асрый. Ике иманасында һәм арендага алган басуларында чәчүлекләре 7 дисәтинәдән арта. Хуҗалыкта барлык эшләрне үз көче белән башкара.

Югарыда телгә алынган дин әһелләре, башка авыллардагы кебек, балалар укыту белән дә шөгыльләнгәннәрме, билгесез. Ә менә Фәхриҗамал Галләмова (50 яшь) ел саен 6 ай балаларга сабак биргән. Хезмәте өчен ата-аналар түләгән. Мөгаллимә улы һәм 2 кызы белән яши. 2 иманасы, берничә баш малы була.

Авылда күптәннән 2 лавка эшләп килүе мәгълүм иде. Кемнәрнеке соң алар? Беренче лавканың хуҗасы – Гыймадетдин Галиуллин (42 яшь). Ул вак-төяк тауарлар белән сәүдә итә. Моннан башка, су тегермәне дә була. Гаиләсе анасы (80), хатыны (40), 3 улы һәм кызыннан тора. Гыймадетдин бай күп терлек тота (4 эш аты, 3 сыер, 15 сарык һәм башка вак маллар) һәм зур мәйданда (20 дисәтинәдән артык) иген игә. 2 иманасы була, калган басуларны авыл-

[53] Список населенных мест Самарской губернии по сведениям 1889 г. Самара, 1890. С. 59.

[54] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900.

дашларыннан һәм читтән арендага алган. Хуҗалыктагы эшләрне, башлыча, хезмәтче башкара.

Икенче лавка – Мөхәммәтгали Мөхәммәтгәрәевнеке (40 яшь). Монысында да вак-төяк тауарлар сатыла. Хуҗа хатыны (35), 3 улы һәм 2 кызы белән яши. Аның да мал-мөлкәте күп. 4 эш аты, 2 сыеры, 15 сарыгы һәм башка вак маллары була. 4 иманасында һәм арендага алган басуларында чәчүлекләре 28 дисәтинә тәшкил итә. Ул гадәттә кыска срокка гына, башлыча, җәй айларында эшче яллый.

Әгерҗедә Гыймадетдин белән Мөхәммәтгали байлар кебек күп эре мал асраган хуҗалыклар дистәгә якын. Тәхаутдин Сәйфетдиновның (аңа 75 яшь) дүртәр эш аты һәм сыеры, Садретдин Баһаутдиновның (35) 4 эш аты һәм 3 сыеры була. Мәһди Вәлиев (53), Баһаутдин Габидуллин (45), Баһман Галимов (28), Габделгалим Габделганиев (55), Мөхәммәтҗан Мөхәммәдиев (57), Хөснулла Нигъмәтуллиннарның (62) эш атлары гына өчәр. Алар урта хәллеләрдән санала.

Җан башына бүленә торган җирнең күләме аз булу сәбәпле, Әгерҗедә урта хәлле хуҗалыклар күп түгел. Алар, иманалары күпме булуга карамастан, арендага җир алган. Соңрак кайберләре кулак хуҗалыкларына әверелә.

Әмма авылда күпчелекне очын-очка көчкә ялгап баручы хуҗалыклар тәшкил итә. Аларның мал-туары да, чәчүлекләре дә аз була. Тора-бара бер өлеше бөлгенлеккә төшә: иманасын арендага биреп, көнлекчелеккә йөри яисә ел буена батраклыктан кайтып керми.

Батраклар исемлегенә Вәлиулла Гайфуллин (63 яшь), Гафур Кәримов (45), Сәйфулла Ваһаповны (60) һәм тагын берничә хуҗалыкны кертергә мөмкин. Исемнәре аталганнар ел буена дворян Ильин имениесендә бил бөгә. Аңа һәм төбәкнең башка эре җир биләүчеләренә (Рязанов, Головинская) көнлекчелеккә йөрүчеләр тагын да күбрәк була.

Әйтергә кирәк, 1897 елгы корылык Әгерҗедәге күп кенә хуҗалыкларның хәлен тәмам начарайта. Шаһи Вәлиев (45 яшь) һәм Хәлим Ханнановлар (35) 1898 елда барлык мал-мөлкәтләрен сатып, эш эзләп читкә чыгып китәргә мәҗбүр була. Сәфәргали Корбангалиевнең (63) да улы авылны ташлап китә, Чиләбегә барып эшкә керә.

Билгеләп үткәнчә, игенчелек һәм терлекчелек – авыл халкының төп шөгыле. Шул ук вакытта һөнәрчелек тә зур урын тота. Беренче чиратта, агач эше осталарын күрсәтеп үтик. Алар арасында балта осталары (Хәлиулла Хәйбуллин, Госман Хәмидуллин, Шәрәфетдин Әхмәтшин) һәм тәгәрмәч ясаучылар (Әхмәди Вәлиев) була. Габделкәрим Гыйззәтуллин пыялачы буларак билгеле.

Тегү эше осталары да була Әгерҗенең. Кием-салым тектерергә Шәрип Биктимеровка (68 яшь) яисә Шаһиәхмәт Әхмәтҗановның улына йөргәннәр. Соңгысы, өстәвенә, тегү машинасы сатып алгач, Азнакайда ширкәт оештыра һәм компаньоны белән күпләп тегә башлый.

Итекчеләр авылда икәү. Алар – Мөхәммәтсадыйк Шәрипов һәм Шәрәфетдин Садыйков – яшьтәшләр (40). Садыйк Кәримов (50), Мөхәммәтшакир Мөхәммәтҗанов (50) һәм соңгысының улы чабата үрә, еш кына Сәпәй базарына да илтеп сата.

Төбәктә сирәк очрый торган һөнәр иясен – кирпеч сугучыны (Хөснетдин Хисаметдинов) күрсәтеп үтәргә кирәк. Кирпеч күбесенчә мич чыгару өчен кулланылган.

Шулай итеп, Әгерҗедә авыл тормышы өчен кирәкле һөнәр төрләренең күпчелеге була. Югарыда телгә алынган кешеләрнең төп өлеше өчен һөнәрчелек өстәмә табыш чыганагы булып тора. Ә менә чәчүлексез хуҗалыкларда ул – яшәү чыганагы.

Авылда умартачылар күп түгел, берничә кеше генә була. Болар – Шәйдулла Миңлеголов, Ибраһим Мөхәммәтҗанов, Нәбиулла Гыйззәтуллин, Миргариф Габделгалләмов һәм Садретдин Баһаутдинов. Соңгысының, башкалар белән чагыштырганда, умарталыгы зуррак (12 баш).

Кайбер хуҗалыклар кыш җитү белән чаналарын җигеп байларга һәм сәүдәгәрләргә икмәк ташырга яллланган. Мәсәлән, Вилдан Мотыйгуллин (31 яшь) сәүдәгәрләрнең йөген өязнең Сок Карамалысы авылына ташыган. Җәйләрен исә җидешәр көн Рязанов һәм Ильин имениеләрендә көнлекчелектә үткәргән.

Авылның социаль-икътисади торышын тасвирлауны төгәлләр алдыннан тагын бер мәгълүматка тукталып үтик. 1900 елда Әгерҗедә 174 хуҗалык исәпләнә.

Аларның җидесе читтән күчеп килгән, бише – татар, икесе – рус. Русларның берсе – Никон Бобров – Бөгелмәдән килеп урнаша, авыл тегермәнен арендага ала. Монда 23 яшьлек улы белән чиратлашып эшли, көнлекчелеккә дә йөриләр[55].

Сугыш алды елларында Әгерҗедә байтак кына үзгәрешләр була. Шуларның берсе – авылның ике мәхәлләгә бүленүе. 302 ир-ат һәм 280 хатын-кыздан торган беренче мәхәлләдә мулла булып Хикмәтулла Нигъмәтуллин кала. Ул 1861 елның 12 июнендә туган, 1896 елның 4 апрелендә муллалыкка расланган. 1912 елның кышында Хикмәтулла мулла вафат була, аның урынына Шәрәфетдин Габделгалимовны куялар. Бу мәхәлләдәге җәмигъ мәчет бинасы 1791 елда төзелгән була.

Икенче мәхәллә 1905–1906 елларда, яңа мәчет салынган чорда барлыкка килә. Монда 184 ир-ат, 186 хатын-кыз исәпләнә. Имам-хатыйп итеп Фәхретдин Садретдин улы Ярмәков билгеләнә. 1879 елның 15 мартында туган, 1906 елның 15 маеннан әлеге вазифаны үти башлый. Шул ук елның 29

[55] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 32 сакл. бер.

маенда мөәзин итеп 25 яшьлек Гайса Баһаветдиновны куялар. Берара Нурмөхәммәт Нургалиев та мөәзинлек итә[56].

1910 елда Әгерҗедә 194 хуҗалык, 504 ир-ат һәм 493 хатын-кыз исәпләнә. Авылның 1446 дисәтинә уңайлы, 52 дисәтинә уңайлы булмаган җирләре була. Икешәр мәчет, мәктәп һәм су тегермәне эшләгән[57].

Сугыш башланды дигән хәбәр тиз арада таралып, бөтен авыл халкын хафага сала. Озак та үтми, беренче мобилизацияләнүчеләр дә билгеле була. 1914 елда авыл күп кенә ир-егетләрен сугышка озата. Татарстан дәүләт архивында саклanучы документка таянып, түбәндә аларның исемлеген китерәбез[58].

Таблица 1. Беренче бөтендөнья сугышына алынган
Әгерҗе ир-атлары (1914 ел)

| № | Мобилизацияләнүчеләр | Хуҗалык башында калучылар |
|---|---|---|
| 1 | Гыйльман Игътисамов | Сорур Габитова (хатыны) |
| 2 | Шәрәф Шәяхмәтов | Шәмсеруй Әбүбәкерова |
| 3 | Хәйретдин Ихсанов | Ихсан Игътисамов (атасы) |
| 4 | Шәмсулла Хәлиуллин | Хәлиулла Хәбибуллин (атасы) |
| 5 | Мөхәммәтгали Мәһдиев | Мәлиха Хәмидуллина (хат.) |
| 6 | Әхмәтҗан Мәһдиев | Шаһидә Мөхәммәтсадыйкова |
| 7 | Шәкүр Шакиров | Кафия Фәхретдинова (хат.) |
| 8 | Хәбибулла Габделгафуров | Габделгафур Кәримов (ат.) |
| 9 | Мөхибрахман Габдрахманов | Мәхтүмә Габдрахманова |
| 10 | Әшрәфетдин Бикколов | Биккол Биктимеров (ат.) |
| 11 | Динмөхәммәт Бикмөхәммәтов | Бәдигылҗамал Шәмсиева |
| 12 | Гайнемөхәммәт Ильясов | Гайнижамал Ситдыйкова (хат) |
| 13 | Мөхәммәтгалим Мөхәммәтлатыйпов | Һәдия Хәйруллина |
| 14 | Нургали Ибраһимов | Фатыйма Гыйлажетдинова |
| 15 | Габделислам Габделгалимов | Шәмсенур Вәлиуллина |
| 16 | Мөхәммәтвәли Әхмәтов | Әхмәт Корбангалиев (ат.) |
| 17 | Хәбир Фәйзрахманов | Фәйзрахман Хәбибрахманов (ат.) |
| 18 | Вафиулла Рәхмәтуллин | Мәбрүрә Шәнгәрәева (ан.) |
| 19 | Габделхәким Корбангалиев | Зарифа Габделҗаббарова (хат.) |
| 20 | Шәйхулла Хөснуллин | Зәкия Хисаметдинова (хат.) |
| 21 | Сабир Әбүбәкеров | Мөгаллифә Галимова (хат.) |

[56] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер.; 14 тасв., 11 сакл. бер.
[57] Списки населенных мест Самарской губернии. Самара, 1910. С. 92.
[58] ТР ДА, 1124 фонд, 1 тасв., 28 сакл. бер., 39, 214–215 б.

| | | |
|---|---|---|
| 22 | Зиннур Әбүбәкеров | Зөбәйдә Мөхәмммәтвәлиева (хат.) |
| 23 | Сәлахетдин Шәрәфетдинов | Шәрәфетдин Садыйков (ат.) |
| 24 | Әхмәтҗан Зәйнуллин | Гыйльмиҗамал Шәрифуллина (хат.) |
| 25 | Латыйфулла Хәйруллин | Хәйрулла Вәлиев (ат.) |
| 26 | Нуретдин Шәйхетдинов | Ш. Игътисамова (ан.) |
| 27 | Нурмөхәммәт Нургалиев | Нургали Муллагалиев (ат.) |
| 28 | Шаһидулла Зәйнуллин | Шәмсеҗамал Шәрәфетдинова (хат.) |
| 29 | Габдерәкыйп Габдерәүфов | Габдерәүф Габдрахманов (ат.) |
| 30 | Хәбибулла Шаһидуллин | Шәйдулла Миңлеголов (ат.) |
| 31 | Зыятдин Фәхретдинов | Мәстүрә Шәрәфетдинова (хат.) |
| 32 | Гыйльфан Вилданов | Вилдан Гашимов (ат.) |
| 33 | Габделвәли Габделгалимов | Габделгалим Габделганиев (ат.) |
| 34 | Хәбир Кадыйров | Мәрҗәм Җәләлетдинова (хат.) |
| 35 | Газизҗан Әхмәров | Әхмәр Гайнуллин (ат.) |
| 36 | Җиһангир Фазуллин | Шәмсекамал Шаһимәрдәнова (хат.) |
| 37 | Әхмәтҗан Әхмәдиев | Миңлеҗамал Сәлимгәрәева (хат.) |
| 38 | Сәетгәрәй Асылгәрев | Асылгәрәй Мөхәммәдиев (ат.) |
| 39 | Мостафа Мөхәммәтҗанов | Шәмсенур Гәрәйшина (хат.) |
| 40 | Гомәр Хәмидуллин | Мөкәррәмә Шәрипова (хат.) |
| 41 | Миргалим Галләмов | Сорур Ногманова (хат.) |
| 42 | Нургасим (Мөхтәсим) Галләмов | Фәрхизадә Әхмәтсафина (хат.) |
| 43 | Фәхразый Фәхретдинов | Фәхретдин Гайнетдинов (ат.) |
| 44 | Сәлимгәрәй Ибраһимов | Шәмсениса Ибраһимова (?) |
| 45 | Нәбиулла Галиәскәров | Әсхәпҗамал Фәхрелисламова (хат.) |
| 46 | Бәдретдин Тәхаутдинов | Сабира Әхмәтшина (хат.) |
| 47 | Сәлимгәрәй Әхмәтшин | Сабира Гатауллина |
| 48 | Харис Галиуллин | Фатиха Гобәйдуллина (ан.) |
| 49 | Мөхәммәтсафа Мөхәммәтгалиев | Мөхәммәтгали Гәрәев (ат.) |
| 50 | Солтангәрәй Шәрәфетдинов | Шәрәфетдин Ситдыйков (ат.) |
| 51 | Мөхәммәтзакир Рәхимҗанов | Фәрхисорур Гобәйдуллина |

Әлеге исемлек 1915 елның 13 февралендә төзелгән. Аннан күренгәнчә, дәһшәтле сугыш җиле авылда күп кенә хуҗалыкларга кагыла. Берәүләрнең гаилә башлыклары – ирләре, калганнарның уллары мобилизациягә эләгә. Ирләре сугышка алынган хуҗалыкларда төп авырлык хатын-кызларга (алар исемлектә кыз чактагы фамилияләре белән күрсәтелә) төшә.

Югарыда китерелгән исемлек 1914 елда мобилизацияләнүчеләрдән тора. 1915 елда авыл тагын 37 ир-атны сугышка озата. Кемнәр соң алар? Ачыклык кертер өчен шул ук документка мөрәҗәгать итәбез.

Таблица 2. Беренче бөтендөнья сугышына алынган
Әгерҗе ир-атлары (1915 ел)

| № | Мобилизацияләнүчеләр | Хуҗалык башында калучылар |
|---|---|---|
| 1 | Гасыйм Латыйпов | Газия Хәйруллина (хатыны) |
| 2 | Мөхәммәтгали Галимов | Галим Вәлиев (атасы) |
| 3 | Таһиркол Бикколов | Мәгърифә Габдерәхимова (хат.) |
| 4 | Җиһангир Ибраһимов | Зәкия Галимҗанова (хат.) |
| 5 | Габдерәкыйп Кадыйров | Йөзлеҗан Шәрәфетдинова (хат.) |
| 6 | Закир Мөхәммәтҗанов | Халидә Ильясова (хат.) |
| 7 | Закир Кадыйров | Миңлекамал Муллагалиева (хат.) |
| 8 | Миңлерахман Хәбибрахманов | Миңлегаян Шакирова (хат.) |
| 9 | Нәгыймулла Кәлимуллин | Мөшәрәфә Фазуллина (хат.) |
| 10 | Гали Гомәров | Миңлеҗиһан Шиһабетдинова (хат.) |
| 11 | Кашшафетдин Фәттахетдинов | Фәттахетдин Мифтахетдинов (ат.) |
| 12 | Шаһиморат Шаһиәхмәтов | Фаидә Сәлимгәрәева (хат.) |
| 13 | Сабирҗан Гомәров | Гомәр Галиуллин (ат.) |
| 14 | Шаһидулла Хәлиуллин | Гашия Нәфыйкова (хат.) |
| 15 | Мостафа Гәрәев | Камилә Әхмәтҗанова (хат.) |
| 16 | Багис Гарифуллин | Гөлбану Хәйруллина (ан.) |
| 17 | Фатыйх Габдерәхимов | Таифә Сәфәргалиева (хат.) |
| 18 | Насыйр Кадыйров | Мәүлиха Әхмәткәримова (хат.) |
| 19 | Әхмәт Мәүлетов | Маһибәдәр Хәбирова (хат.) |
| 20 | Гасыйм Мәгъсүмов | Мәгъсүм Галләмов (ат.) |
| 21 | Солтангәрәй Зарифуллин | Зарифулла Сафиуллин (ат.) |
| 22 | Мөхәммәтгали Миндубаев | Камилә Госмангалиева (хат.) |
| 23 | Каюм Галләмов | Галләм Ганиев (ат.) |
| 24 | Хәсән Ибраһимов | Ибраһим Галиуллин (ат.) |
| 25 | Хәйретдин Хәсәнов | Хәсән Исхаков (ат.) |
| 26 | Сәхәбетдин Хәбибуллин | Хәбибулла Сафиуллин (ат.) |
| 27 | Муса Латыйпов | Гайниҗамал Миңлекәева (ан.) |
| 28 | Габдрахман Кәримов | Кәрим Гыйззәтуллин (ат.) |
| 29 | Латыйфетдин Фәхретдинов | Шәмселбанат Батыршина (хат.) |
| 30 | Хөсәен Госманов | Шәмсениса Кәлимуллина (хат.) |
| 31 | Сәхәбетдин Хөснуллин | Хөснулла Хәмидуллин (ат.) |
| 32 | Харис Шәйхетдинов | Шәйхетдин Шәмсетдинов (ат.) |
| 33 | Миңлегали Зарипов | Мөкәррәмә Исламова (хат.) |
| 34 | Мөхәммәтгариф Баһаутдинов | Баһаутдин Галиуллин (ат.) |
| 35 | Солтангир Әхмәткәримов | Маһисорур Шәрипова (хат.) |
| 36 | Мөхәммәтсафа Гәрәев | Камилә Гарифуллина ( хат.) |
| 37 | Насретдин Сәгъдетдинов | Сәгъдетдин Нәфыйков (ат.) |

Шулай итеп, ике ел эчендә авылдан 88 кеше мобилизацияләнгән. 1916 һәм 1917 еллар буенча мәгълүматлар юк, әмма бу чорда да илледән артык кеше хәрби хезмәткә чакырылган булса, ир-улларын сугышка озатмаган гаиләләр бик аз кала түгелме?

Сугыш авылның социаль хәлен начарайта. Бу беркадәр 1916 елда үткәрелгән авыл хуҗалыклары исәбен алу материалларыннан да күренә. Әгерҗедә 212 хуҗалыкта 746 ир-ат һәм 962 хатын-кыз теркәлә. Саннар арасында аерма зур булуның сәбәбе мәгълүм – сугыш.

Бу чорда төбәктә качаклар да күренә башлый. Алар Әгерҗедән (3 кеше) башка, волостьның Азнакай (18), Уразай (15), Балтач (4), Сәпәй (2), Әсәй (3) авылларына килеп утыра. Әгерҗедә качакларның берсе – ир-ат, икесе – хатын-кыз.

Авыр сугыш елларында да терлекчелеккә һәм игенчелеккә игътибар кимеми. Әгерҗедә 420 ат (шул исәптән 355 эш аты), 511 мөгезле эре терлек (250 сыер), 1135 сарык һәм 264 кәҗә исәпләнә. Чәчүлек мәйданы 824,45 дисәтинә тәшкил итә. Шуның яртысыннан артыграгын арыш (438 дисәтинә), калган өлешен солы (146,25), карабодай (78,5), борай (57,30), тары (48,15), бодай (37,5), борчак (18,25) һәм ясмык (0,5) алып тора[59].

Октябрь инкыйлабыннан соң авылларда, шул исәптән Әгерҗедә, җирле хакимияткә сайлаулар үткәрелә. Авыл башкарма комитетына Габделгани Корбангалиев – комиссар, Әшрәфетдин Бикколов, Садретдин Баһаутдиновлар комитет әгъзасы итеп сайлана. Барлык сайлаучылар 600 кеше исәпләнә. Әлеге мәгълүматлар 1918 елның декабрендә алына[60].

Ике елдан халык санын алу үткәрелә. Әгерҗедә 294 хуҗалык һәм 1103 кеше теркәлә. Әмма 1921 елгы ачлыктан күп гаиләләр кырыла. Шуңа күрә чираттагы халык санын алуга (1926 ел) әлеге күрсәткечләр шактый кимрәк – 203 һәм 913. Авыл Бөгелмә кантоны Азнакай волостена керә[61].

1930 елга караган бер документта Гәрәев Мөхәммәтнең икенче категория белән раскулачивать ителүе хакында әйтелә. Мал-мөлкәтен тартып алып үзен авылдан сөрергә карар чыгарыла[62]. Репрессиягә, билгеле, кайбер башка кешеләр дә дучар була, архивларны өйрәнеп аларның да исемнәрен ачыклау таләп ителә.

1931 елда Әгерҗе авыл советы җирләрендә «Берек» һәм «Ирек» күмәк хуҗалыклары оеша, соңыннан алар кушыла, 1967 елдан «Октябрьнең 50 еллыгы» дип атала. Авылда атаклы бакчачы Шәйморат Әхмәтов яшәгән, Мичурин белән хат алышкан, колхоз бакчасында төрле сорт яшелчә-җимешләр, кавын һәм карбызлар үстергән.

---

[59] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 37 сакл. бер.

[60] Шунда ук, Р–1167 фонд, 1 тасв., 160 сакл. бер., 792 б. а.–793 б.

[61] Шунда ук, Р–1296 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 108 б.

[62] Шунда ук, Р–1221 фонд, 3 тасв., 25 сакл. бер., 123 б.

Бүгенге көндә авылда биш йөзгә якын кеше яши. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты була. Халыкның күпчелеге күмәк хуҗалыкта, бер өлеше нефть тармагында эшли[63].

## § 3. Әсәй[64]

Азнакай районының бай тарихлы авыллары арасында Әсәй үзенең гадәти булмаган исеме белән аерылып тора. Укучы күңелендә, башкортлардагы кебек, ана кешене күз алдында тотмыймы икән бу исем, дигән уй-фикер туарга мөмкин.

Авыл картларының хәтерендә сакланган риваятьләрнең берсе бу урынга беренчеләрдән булып Әсәй картның килеп утыруы турында сөйли. Димәк, шундый исемле кеше булган һәм, әйтергә кирәк, бу шик уятмый. Әсәй – Исәкәй (Әсәкәй) исеменең диалекталь варианты. XVII–XVIII гасыр чыганакларында татарлар арасында мондый исемле кешеләр, еш булмаса да, очрый. Шуңа күрә авылга нигез салучының исеме Әсәй булуы гаҗәп түгел.

Әсәй кайдан һәм кайчан әлеге төбәккә килеп утырган соң? Бу сорау күпкә катлаулырак. Риваятьләрнең берсендә Әсәйнең якындагы Имән авылыннан килүе турында әйтелә. Мондый атамалы авыл (ул Иске Имән дип йөртелә) Сарман районында була. Авылга нигез салучының шуннан булуы ихтимал. Болай фикер йөрткәндә, без аз билгеле бер документка таянабыз.

Иске Имән авылы тарихын язганда, бу документ хакында әйткән идек. «Татарстан» журналында (1994 ел, № 7–8) басылып чыккан ул язма белән күпләр таныш булмаска да мөмкин. Шунлыктан документның Әсәйгә кагылышлы урынына кыскача тукталабыз.

Башкортстан Милли архивында саклаучы бу документның тулы исеме – «Дело об установлении родопроисхождения и исключения из подушного оклада Юсупова Тимиркея». Анда Оренбург губернасы Минзәлә өязе Катысаз (Имән) авылы (Иске Имән элек шулай аталган) кешесе Тимеркәй Йосыповның 1798 елның 13 июлендә губерна хакимиятенә язган гаризасы теркәлгән. Ул анда түбәндәгеләрне яза (текст оригиналдагыча бирелә): «[... ] я происхождения рода башкирского по которому и оказалась, что я справедливо башкирского роду ибо прапращер мой Байрамгузя пращур Аккузя, прадед

---

[63] Узган гасырда язган бу тарихи очеркның баштагы битләренә кайбер яңа мәгълүмат бирүне кирәк таптык. Аерым алганда, яңа чыганакка таянып авылның 1732 елда нигезләнгәнен күрсәтеп үттек. Текстның 1859 елдан соңгы чорны эченә алган өлеше үзгәрешсез калды.

[64] Бу мәкалә журналда басылды: Кәримов Т. Әсәй (Авыллар тарихын язабыз) // Татарстан. 1995. № 11–12. 57–64 б.

Исяк и Кушай есть настоящия башкирцы. Но дед мой Уразман и отец Юсуп как я остался малолетним какими путями попались в ясашной оклад я уже неизвестен. Отца ж моего Есупа брата родной Абиш Уразманов состоит и поныне з детьми своими как и в родословной значится в башкирцах, а я в подушном окладе [...], доказательством служит, что я имею во владении своем землю по грамоте во 104 года (1596/97 гг. – *Т.К.*) прапращеру моему Байрамгузе жалованную...»[65].

Әлеге гаризадан аңлашылганча, Тимеркәй Йосыпов үзен привилегияле башкорт сословиесенә кайтаруларын сорый. Документта безнең өчен әһәмиятлесе шул, анда Т. Йосыповның ерак бабаларыннан берсе булган Исәк телгә алына. Исәк (Исәкәй яисә Әсәкәй) – 1596–97 елларда грамота нигезендә җир алган Бәйрәмхуҗаның оныгы. Ул чама белән XVII гасыр урталарында туган булырга тиеш. Шул гасырның икенче яртысында Исәкнең кайдан да булса җир алуы мөмкин. Әгәр дә аның зур биләмәсе хәзерге Әсәй авылы урынында булса, яңа барлыкка килгән авылның аның исеме белән Әсәкәй яисә Әсәй дип атала башлавы гаҗәп түгел. Шулай итеп, авылга нигез салучыны югарыда күрсәтелгән кеше дип фараз кылсак, Әсәйгә XVII гасырның икенче яртысында нигез салынган булып чыга.

Авылның башлангыч чорына ачыклык кертүче икенче документ 1840 елның 19 мартында төзелгән. Анда Әсәй авылы «типтәр»ләре (ир-атлар – 218 кеше) турында «жительствуют по припуску башкир без всякого документа более 150 лет»[66] дип әйтелә. Димәк, бу документ та авылның XVII гасырның икенче яртысында нигезләнүенә ишарәли.

Өченче документ авылның беренче мәчете турында. Ул 1704 елда ук төзелә, хәтта XX гасыр башында да исән була[67].

Югарыда телгә алынган документлар түбәндәге нәтиҗәләр ясарга мөмкинчелек бирә. Беренчедән, Әсәй авылы XVII гасырның икенче яртысында нигезләнгән. Ике документ белән дәлилләнгән бу факт шик уятми. Икенчедән, Әсәй карт бу урында беренчеләрдән булып яши башлый һәм авыл шуңа күрә аның исеме белән йөртелә. Әлеге кешенең нәкъ Бәйрәмхуҗа карт оныгы булуы бик мөмкин. Чөнки Әсәй яшәгән чор белән авылга нигез салынган чор үзара тәңгәл килә. Бу фикергә өстәмә дәлил итеп Әсәйнең башкорт сословиесендә булуын да өстәргә кирәк. Ә бу сословие кешеләре авылда беренчеләрдән булып яши башлыйлар.

---

[65] БР МА, И–2 фонд, 1 тасв., 13 сакл. бер., 1–4 б.
[66] Малоизученные источники по истории Башкирии. Уфа, 1986. С. 89.
[67] БР МА, И–295 фонд, 14 тасв., 11 сакл. бер.

XVII гасырның икенче яртысында нигезләнсә дә, Әсәй авылы телгә алынган иң борынгы чыганак 1729 елга карый. Патша хакимияте вәкиле сорау алганда Дусай-Кичү (хәзерге Минзәлә районы авылы) авылы татары Чирү Теләшев җан башыннан түли торган салым («подушный оклад»), ә Әсәйдә «типтәр ясагы» түләве турында әйтә (чыганакта болай язылган: «допросом показал, что он Чирю во оной деревне Досай Кичю в подушной оклад також и в Уфимском уезде в деревне Асаевой написан в одну куницу в тептярский ясак»). Шул ук сүзләрне аның авылдашы Мөслим Ишбулатов та кабатлый. Алар Әсәйгә 1728 елда килеп утырганнар[68]. Гасыр ахырында Әсәй авылы биләмәчеләре (вотчинниклары) арасында Мөслимов фамилияле кеше булуын искә алсак, соңгысы сословиесе буенча «башкорт» булып киткән дип фараз кыла алабыз.



*Әсәй авылы ясаклы татарлары теркәлгән 1762 елгы документ фрагменты*

XVIII гасыр уртасында Әсәй авылы ясаклы татарлары Уфа өязе Казан юлы Юрмый волостенда күрсәтелә. Россия борынгы актлар дәүләт архивында саклаучы 1762 елның 2 июнендә төзелгән документта 47 ир-ат теркәлгән. Алар старшина Хасбулат Мөтеков командасында исәпләнә, яртысыннан күбрәген Мостафа (9 ир-ат), Наратлы (7) һәм Сабай (8) авылларыннан күчеп килүчеләр тәшкил итә[69].

Ыкның уң ягыннан күчеп килүчеләр турында истәлек картлар хәтерендә бүгенгәчә саклана. Аерым алганда, бу хакта Гариф Харис улы Әхмәдиев (1904 елгы) күп мәгълүматлы булып чыкты. Аның истәлекләренә караганда, монда яшәгән авыл кешеләре арасында хәтта марилар да булган. Алар җирле

[68] РБАДА, 248 фонд, 13 тасв., 712 сакл. бер., 191–191 б. а.

[69] Шунда ук, 350 фонд, 2 тасв., 3801 сакл. бер., 475–478 б. Сабай бер чыганакта Идәш, икенчесендә Әврәс елгасы буенда диелгән.

халык белән яши-яши татарлашканнар, үзенең дә ерак бабасы мари булган, имеш. Әмма бу риваять архив документлары белән расланмады.

Башкортстанның Бакалы ягыннан татарларның күпләп бу тирәләргә күчүенең җитди сәбәбе була. 1736 елда Нугайбәк крепосте төзелгәч, урыс миссионерлары тирә-як халыкны көчләп христиан диненә күчерү буенча актив эш алып баралар. Ә инде крепостька әледән-әле килеп-җибәрелеп торган чукындырылган кавемнәргә урындагы халыкның уңдырышлы җирләрен тартып алып бирә башлыйлар. Дини кысуларга-мәсхәрәләүләргә түзә алмаган татарларның бер өлеше хәзерге Азнакай районына күчеп утырган.

Е. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы (1773–1775 еллар) башлану төбәктәге авылларга да кагылып үтә. Баш күтәрүчеләрнең отрядларына Юрмый волосте старшинасы Биккенә Яушев командасында торучы Әсәй ясаклы татарлары да кушыла[70]. Старшина үзе дә, улы Исмәгыйль Биккенин дә 1773 елның декабреннән алып 1774 елның апреленә кадәр яуда актив катнашалар. Нугайбәк крепостендагы В. Торновка буйсыналар[71].

1794 елның 1 октябренә караган документта Бүләк Таһиров, Алканай Айдашев, Баязит Мостаев, Габдул Карагулов, Габделшәфи Бакиров, Госман Карагулов, Имангол Карагулов, Габдерәхим Гобәев, Шәрип Карагулов, Мәхмүт Аккулов, Базан Мөслимов, Атлис Исәнбаев, Күгәш Исәнбаев, Тимерша Базанов, Бикташ Исәнбаевлар күрсәтелә. Болар Әсәйдә яшәүче биләмәчеләр (вотчинниклар) буларак телгә алына[72]. Биләмәчеләр булганлыктан, башка документларда сословиеләре «башкорт» дип языла.

1795 елда авыл 35 хуҗалыктан тора. Халыкның төп өлешен «типтәр»ләр (моңарчы алар ясаклы татар сословиесендә иде; 94 ир-ат һәм 84 хатын-кыз), калганын «башкорт»лар (башкорт сословиесендәге татарлар; 43 ир-ат һәм 29 хатын-кыз) тәшкил итә[73]. 1798 елда кантоннар оештырылгач, Әсәй «башкорт»лары 12 нче башкорт кантонында күрсәтелә. «Типтәр»ләр 5 нче типтәр командасына карый.

Авылның үсүе җир бүлүдә кыенлыклар китереп чыгара. Якын-тирәдә кулланылмый яткан җирләр калмый, ә волостьның башка буш җирләре авылдан ерактарак урнашкан була. «Типтәр»ләр күпчелекне тәшкил иткәнлектән һәм, өстәвенә, җан башына аларга җир азрак та таләп ителгәнлектән, аларны авылдан кузгатмыйлар, ә буш җирләргә азсанлы «башкорт»ларны күчерергә карар кылалар. Менә шулай XIX гасыр башында моннан күченүчеләр исәбенә икенче авыл – Карамалы барлыкка килә.

Башкорт сословиесендәге татарлар яңа урынга күченү белән, монда рәсми рәвештә «типтәр»ләр генә кала. Шулай да бер чыганакта 1816 елда

---

[70] Крестьянская война на территории Башкирии. Уфа, 1975. С. 282.
[71] Вахит Имамов. Татарлар Пугачев явында. Яр-Чаллы, 1994. 466 б.
[72] БР МА, И–2 фонд, 1 тасв., 7031 сакл. бер., 33–33 б. а.
[73] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 287 б. а.–294 б.

Әсәйдә 2 хуҗалыкта 4 ир-ат «башкорт» яшәве хакында әйтелә, әмма шунда ук аларның ревизия исемлеге буенча Карамалыга караганы искәртелә[74]. Димәк, болар күченгән саналсалар да, Әсәй авылыннан китмәгәннәр.

1816 елгы ревизия мәгълүматлары аерым игътибарга лаек. Әсәй халкын типтәр сословиесендәге татарлар тәшкил итә. Алар 131 ир-ат һәм 141 хатын-кыз (48 хуҗалык) исәпләнә. Ревизия исемлеген хакимияткә үзенең имзасын куеп йөзбашы («сотник») Араптан Габдрахманов (63 яшь; өч хатынлы) тапшыра[75]. 1814 елгы манифест нигезендә типтәр сословиесенә язылган, Оренбург казна палатасының 1818 елның 17 август карары белән читтән килеп утырган 2 ир-ат һәм 3 хатын-кыз (2 гаилә) аерым ревизия документында теркәлгән. Алар Ибәтулла Динмөхәммәтов белән Камалетдин Габбәсовның хатыннары һәм балалары дип күрсәтелә[76]. Соңгыларын да кушсак, Әсәйдә типтәр сословиесендә барысы 133 ир-ат һәм 134 хатын-кыз (50 хуҗалык) була.

Бер чыганакта ир-атлар – 138, хуҗалыклар 50 дип күрсәтелә[77]. Әмма югарыда күрсәтелгән ревизия документы төгәллеге белән аерылып тора, шуңа күрә аңа төп чыганак итеп карарга кирәк.

1859 елгы ревизия исемлеге буенча Әсәйдә типтәр сословиесендә 366 ир-ат һәм 381 хатын-кыз (50 хуҗалык) татар исәпләнә. Габделкадыйр Габделваһапов – Кәтемгә, Мөхәммәтшәрип Габдулгалләмов – Сөеюндеккә (4 нче юрта), Габдерәхим Хәмитов Туйкәгә күчеп утырганнар. Минһаҗетдин Гибәтуллин ясаклы татар сословиесенә язылып, 1855 елда Вятка губерниясенә күченә («*по указу Самарской казенной палаты от 16 июля 1855 года № 3753* ***перечислен*** *в Вятскую губернию* ***в число государственных крестьян***», дип әйтелә чыганакта). Соңгы булып Кәкре Елгадан указлы мулла булып килгән Шәрәфетдин Габделвахитов (42 яшь) теркәлгән. Бер гаилә 1863 елда Себергә сөрелә. Ревизия документының титул битендә барлык халык «башкорт» дип язылган[78]. Чөнки «типтәр»ләрне 1855 елда «Башкорт» гаскәренә кушкач, алар «башкорт» («яңа башкорт») булып китәләр.

Типтәр сословиесендәге татарларны «башкорт» дип яза башлау Самара губернасы буенча белешмә китапларда да чагыла. Шуларның иң беренчесендә (1859 ел) Әсәйдә 381 ир-ат һәм 413 хатын-кыз (115 хуҗалык) «башкорт» күрсәтелә[79]. Күргәнебезчә, 1859 елгы ревизия исемлеге белән чагыш-

---

[74] БР МА, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 124–126 б. Бер автор 1816 елда 22 йортта 98 «башкорт» яши дип яза (Асфандияров А.З. Аулы мензелинских башкир. Уфа, 2009. С. 561). Әмма иң ышанычлы һәм бернинди бәхәссез чыганак – 7 нче ревизия документы (1816 ел) – Әсәйдә бары тик «типтәр»ләрнең генә теркәлүен күрсәтә.

[75] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 168 сакл. бер., 542–567 б.

[76] Шунда ук, 568–569 б.

[77] БР МА, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 124–126 б.

[78] Шунда ук, И–138 фонд, 2 тасв., 757 сакл. бер., 76–122 б.

[79] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

тырганда халык саны күбрәк язылган. Димәк, шул ел ахырында тагын бер тапкыр халык санын, яңа гына зур хуҗалыклардан аерылып чыгучыларны исәпкә алганнар.

Имана җире ревизия исемлегендәге ир-ат санына карап һәм сословиене күз алдына тотып бүленә, ул җан башына 6,9 дисәтинә туры килә. Бу чорда авылда имам һәм мөгаллим булып (1853 елдан) Әхмәтҗан Шаммасов тора[80].

1885 ел ахырында – 1886 ел башында Әсәй Азнакай волостенда зур авыллардан санала. Анда 238 хуҗалыкта 629 ир-ат һәм 629 хатын-кыз яши. Бу күрсәткечләр буенча ул волостьта бары Азнакайдан һәм Сәпәйдән генә калыша.

Авылның иманасы 2942,5 дисәтинә тәшкил итә. Шуның 716 дисәтинәсен – сөрүлекләр, 489,8 дисәтинәсен – йорт яны җирләре һәм көтүлекләр, 382,3 дисәтинәсен – урман һәм 66 дисәтинәсен печәнлекләр алып торган. Моннан тыш, 3 хуҗалыкның сатып алган җире (300 дисәтинә) була.

Авылда 233 хуҗалыкның имана җире була. Әмма аның күләме, хуҗалыкларга карап, нык аерыла. Күпчелек хуҗалыкларның (136) имана җире – 6,9-дан 12,8-гә, ә 16 хуҗалыкның исә 12,9 дисәтинәдән 20,7 дисәтинәгә кадәр булган. 20,8 дисәтинә һәм аннан күбрәк җирле хуҗалыклар аз (6) була. Хуҗалыклар арасында сөрүлек җирне һәм печәнлекләрне арендага алу киң кулланыла. Барлыгы 208 хуҗалыкның 150 дисәтинә сөрүлекне арендага алуы мәгълүм. Җир хуҗалары яисә казна (әгәр дә җир анықы булса) белән исәп-хисап, гадәттә, акчалата башкарылган. Мәсәлән, печәнлекләрне арендага алган өчен генә дә Әсәй кешеләре 1390 сум акча түлиләр.

Авылда 182 хуҗалык эш кораллары белән тулысынча тәэмин ителгән. Ә менә 28 хуҗалыкта исә алар өлешчә генә була. Мондый һәм бөтенләй эш кораллары булмаган (19 хуҗалык) хуҗалыклар аларны башкалардан нинди дә булса шартларга үзара килешеп алып торганнар.

Әсәйдә 37 хуҗалыкның эш атлары бөтенләй булмый. Күп кенә хуҗалыкларда (79) алар бердән артмый. Шул ук вакытта башкалары ике-өч (78 хуҗалык), дүрт (16) һәм дүрттән күбрәк эш атлары тоткан.

Эш атларын гына түгел, башка мал-туарны да авыл халкы күп асраган. Хуҗалыкларда мөгезле эре терлек 487, сарыклар 1181 һәм кәҗәләр 420 баш исәпләнә. Әмма 36 хуҗалыкның эш аты да, сыеры да булмый. Билгеле, андыйларга авылда көн итү шактый авырга төшкән.

Кайберәүләргә гаиләләрен туйдыру һәм салым түләү өчен үз хуҗалыкларының гына кереме җитми. Шунлыктан алар кыр эшләре вакытында төрле эшләргә ялланганнар (59 кеше) яисә һөнәрчелек белән шөгыльләнгәннәр. 16 хуҗалык 102 баш умарта тоткан.

Авылда берничә хуҗалык сәүдә иткән. Азнакай волостенда (ул Азнакай, Балтач, Сәпәй, Туйкә, Уразай, Әгерҗе һәм Әсәй авылларыннан торган) тугыз

[80] БР МА, И–295 фонд, 3 тасв., 5662 сакл. бер.

лавка булса, шуның өчесе Әсәйнеке. Кибет хуҗалары күпчелек тауарларны Сәпәй базарыннан һәм Бөгелмәдән алып кайтканнар[81].

1889 елда Әсәйдә 241 хуҗалыкта 1225 кеше яши. Авылда 2 мәчет була. Аларның берсе 1858 елдан соңгы чорда төзелгән. Уңайлы җирләр – 2794, эшкәртергә яраксызлары (чокыр-чакыр, ташлы урыннар һ. б.) 150 дисәтинә тәшкил итә.

Гасыр ахырына (1897 ел) Әсәйдә хуҗалыклар саны шактый арта. Анда 279 хуҗалык, 719 ир-ат һәм 731 хатын-кыз исәпләнә. Бу күрсәткечләр буенча ул волость үзәге Азнакайдан гына калыша.

Авылда 2 мәчет һәм мәктәп эшли. Мул сулы Стәрле елгасында авыл кешеләре 3 тегермән тотканнар. Тегермән хуҗалары – Әхмәтҗанов, Зәбиров һәм Габделкәримов[82].

Югарыда телгә алынган кешеләрнең икесе – Әхмәтҗанов һәм Габделкәримов турында Татарстан дәүләт архивында саклanучы 1900 елгы документлар өстәмә мәгълүмат бирәләр. Шуларның Әхмәтшакир (исеме шулай күрсәтелә) Әхмәтҗановка караганына тукталыйк. 1900 елда аңа 29 яшь була. Хатыны (28 яшь), балалары (4 улы һәм 1 кызы), анасыннан (55 яшь) башка, хуҗалыгында энесе (25 яшь) һәм аның хатыны (19 яшь) да яши. Анасыннан кала, өлкәннәрнең барысы да укый-яза белгәннәр. Стәрле елгасындагы тегермән авылдашы Якуп Җәләлетдинов белән икесенеке, ягъни уртак була. Ул сәүдә белән дә шөгыльләнә, лавка тота.

Әйтергә кирәк, Әхмәтшакир Әхмәтҗановның хуҗалыгы зурлыгы ягыннан башкалардан аерылып торган. Имана җире аз булу сәбәпле, ул шактый җирне сатып яисә арендага ала. Имана җирендә чәчүлеге – 5 дисәтинә 1500 кв. сажин, арендага алган басуда 49 дисәтинә 1500 кв. сажин тәшкил итә. Сатып алган җире 100 дисәтинәдән торган утар була. Бу утарның 52 дисәтинәсен – басу, 10 дисәтинәсен – мал йөртү урыны, 24 дисәтинәсен – печәнлек, 22 дисәтинәсен урман алып торган. Шакир бай күп санлы мал-туарын (19 эш аты, 33 мөгезле эре терлек, 80 сарык һәм 6 кәҗә) яз, җәй һәм көз айларында шунда асраган. Әлбәттә, шундый зур хуҗалыкны алып бару күп хезмәт куюны сорый, шунлыктан ул 4 хезмәтче тота һәм һәр җәйне көтүче яллый. Болардан тыш, кыр эшләре вакытында дистәдән артык ир-ат һәм хатын-кыз Шакир байга ялланып эшләгән. Кайбер ярлы хуҗалыклар аның сыерларын (7 баш) сөте бәрабәренә ашатырга-карарга алып торганнар. Сыерларның бозаулары булса, алар хуҗаныкы исәпләнгән һәм аңа тапшырылган.

1900 елгы документларда тегермән тотучылар арасында 1897 елда телгә алынган Зәбиров фамилияле кеше күрсәтелми. Аның тегермәне улларына мирас булып күчкән, ахры. Исәп буенча өченче тегермәнне Латыйф Исмә-

[81] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 10–17.

[82] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 111–112.

гыйлов (43 яшь) үзенең 3 авылдашы (берсе Мотыйгулла Исмәгыйлов) белән тоткан. Тегермәндә һәм зур булмаган хуҗалыгында берәр хезмәтчесе була.

1900 елда авыл элеккечә ике мәхәлләдән тора. Муллалар Шәрәфетдин Вахитов, Әхмәтша Әхмәтҗанов һәм Мөхәммәтгәрәй Садыйков, мөәзиннәр Гәрәйша Шәрәфетдинов һәм Латыйфулла Әхмәтҗанов була.

Шәрәфетдин Вахитов муллалар арасында иң өлкәне – аңа 90 яшь, хатынына – 75 яшь. Алар улының (43 яшь) гаиләсе белән бер хуҗалык булып яшиләр. Хуҗалыгы, башка муллаларныкы белән чагыштырганда, зурлыгы белән аерылып тора. Имана җирендә 9 дисәтинә, үз авылдашларыннан арендага алган басуда – 4 дисәтинәгә якын, башка урында 8 дисәтинә чәчүлекләре була. Алар 8 эш аты, 6 сыер, 30 сарык һәм 5 кәҗә асрыйлар. Әлбәттә, шундый зур хуҗалыкны алып бару өчен хезмәтче тоталар, ә кыр эшләре вакытында алтмышлап көнлекче яллыйлар.

58 яшьлек Мөхәммәтгәрәй мулла документта сукыр дип күрсәтелә. Мөәзиннәрдән Гәрәйшага – 48, Латыйфуллага 41 яшь була. Алар мал-мөлкәте ягыннан урта хәлле авылдашларыннан әлләни аерылмыйлар.

Гарифулла Хәйруллин ул чорда авылның старостасы булып тора. Аның үзенә – 30, хатынына 25 яшь; аларның ике уллары була. Яңа гына өйләнгән энесе (26 яшь) хатыны белән аларның йортында яши. Ә бер энесе (21 яшь) солдатка алынган була.

60 яшьлек Сәрвәли (?) Җиһаншина документта укытучы дип күрсәтелә. Ул ялгызы яши, мал-туар тотмый. Укытучылык аның төп яшәү чыганагы булып тора.

Төрле һөнәрләр белән шөгыльләнүчеләрнең күпсанлылыгы күзгә ташлана. Алар арасында таш чыгаручылар һәм эшкәртүчеләр дә була. Мондый төр һөнәрчеләр булу аркасында башка төзелеш материаллары (агач, кирпеч һ. б.) белән беррәттән, таш та еш кулланыла башлый. Таштан амбарлар һәм башка каралтылар салу гадәти күренешкә әйләнә.

Башка төр һөнәрчеләр арасында балта осталарын, пыялачыларны, киез итек басучыларны, тегүчеләрне, чабатачыларны, тимерчеләрне әйтеп үтәргә кирәк.

Шунысына игътибар итик, югарыда күрсәтелгән кешеләрнең күпчелеге өчен һөнәрчелек төп яшәү чыганагына әйләнгән, шуңа күрә алар моның белән ел буе диярлек шөгыльләнәләр. Гадәттә аларның җирләре аз яисә бөтенләй юк, мал-туарлары да шундый дәрәҗәдә. Мәсәлән, киез итек басучы Әхмәтгәрәй Ситдыйковны алыйк. Аның мал-туары юк, ә чәчүлек җире ташка үлчим, бер дисәтинәдән аз гына арта.

Кайбер һөнәрчеләр иманаларының зур өлешен арендага бирүне кулай күргәннәр. Моның өчен алар, әлбәттә, хак алганнар, ә үзләре исә күп вакытларын һөнәрләренә багышлаганнар.

Авылда аз җирле хуҗалыклар күп була. Андыйларның бер өлеше 8 нче санлы Чалтаймас казна участогыннан 9 елга һәм алпавытлардан (Пискунов,

Докшин) бер елга арендага җир алганнар. Пискунов арендачыларга үстергән уңышның яртысын ("исполу") аңа бирү шартын куйган. Азнакайдан, Урманайдан, Митрәйдән, Карамалыдан һәм кайбер башка авыллардан да арендага җир алучылар була.

Имана җире булмаган хуҗалыклар да шактый гына. Болар башлыча яшь хуҗалыклар. Андыйларның бер өлеше җирне арендага алса, икенчеләре көнлекчеләр булып ялланган. Киресенчә, имана җирен арендага биреп, үзләре исә башка кешеләргә көнлекче булып эшләүчеләр дә булган.

1907 елда Әсәй халкы тагын бер мәчет салырга рөхсәт ала. Әлеге 207 ир-ат һәм 192 хатын-кыздан торган өченче мәхәлләдә имам-хатыйп һәм мөгаллим булып Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтзарипов (1881 елда туган) сайлана. Мөәзин хезмәтен Мөхәммәтәмин Габдерәхимов (1869) башкара.

Бу чорда беренче мәхәлләдә имам-хатыйп һәм мөгаллим булып Әхмәтша Әхмәтҗанов (1883 елдан алып) белән Мөхәммәтгәрәй Мөхәммәтсадыйковлар (1882) хезмәт итә. Мөәзинлеккә 1902 елда Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтшәрипов килә.

Икенче мәхәлләдә Мәхмүт Шәрәфетдинов (имам-хатыйп һәм мөгаллим, 1874 елдан) һәм Фазлыәхмәт Шаһимөхәммәтовларны (имам һәм мөгаллим, 1902 елдан) күрәбез[83].

Истәлекләргә караганда, әлеге мәчетне Габдерәхим хаҗи Габделкәримов салдырган. Мәчетләр каршында 3 мәктәп эшли. Беренче һәм икенче мәчеттә укыту иске методта (ысулы кадим), ә өченче мәчеттә яңа методта (ысулы җәдид) алып барыла. Яңача укытуны Чупайдан (хәзерге Минзәлә районы авылы) килгән Габделхәй исемле укытучы башлап җибәрә. Ул теләгән кешеләрне русча да өйрәткән, кайбер дөньяви фәннәр белән таныштырган, үзе бик гыйлемле булган. Авылда аның, шәкертләре белән мәчет манарасына менеп, «Туган тел»не җырлавын әле дә искә алалар. Әсәйдән ул 1915–1916 еллар тирәсендә китә. Аннары Казанда яши, хәрби чинда була (бу хакта Габделхәй укытучының язмышы белән кызыксынган Гариф Харис улы Әхмәдиев сөйләде).

Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан мәчетләрдә кайбер үзгәрешләр була. Мәхмүт Шәрәфетдинов муллалыктан китә, аның урынына имам-хатыйп һәм мөдәррис итеп 1914 елның февралендә Ризаэтдин Мәхмүтов (1886 елда туган) раслана. Өченче мәхәллә мулласы Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтзарипов 1912 елны дөнья куя, имам-хатыйп һәм мөдәррис итеп Мөхәммәтшаһит Мөхәммәтзарип улы Батыршин сайлана[84].

1916 елда Бөгелмә өязендә хуҗалыклар исәбен алалар. Әсәйдә 359 хуҗалык, 746 ир-ат һәм 962 хатын-кыз теркәлә. Беренче бөтендөнья сугышы тәмамланмаган, шуңа күрә ир-атлар хатын-кызларга караганда күпкә аз була.

---

[83] БР МА, И–295 фонд, 14 тасв., 11 сакл. бер.

[84] Шунда ук, 2 тасв., 3 сакл. бер., 156 б. а.–157 б.

Бу сугышта авылның шактый ир-аты катнаша. Сугыш башлангач, Азнакай волостенда качаклар күренә башлый. Алар Сәпәй (2 кеше), Уразай (10), Азнакай (15), Балтач (4), Әгерҗе (3) һәм Әсәй (3) авылларына килеп утыралар. Әсәйдә 3 качакның берсе – ир-ат.

Авыр сугыш елларында да авыл халкы күп мал-туар асраган. Әсәйдә барлыгы 752 ат, шул исәптән 587 эш аты, 884 мөгезле эре терлек, 1652 сарык һәм 533 кәҗә була[85].

Билгеле, хуҗалыкларга карап мал-туар саны нык аерылган. Бигрәк тә гаилә башлыклары сугышка киткән хуҗалыкларга авыр була. Аларның мал-туары һәм чәчүлек җирләре азая.

Нинди генә авырлыклар булмасын, халык дин таләпләрен тайпылышсыз үтәп барган. Дүртенче мәхәллә булдыру мәсьәләсен сугыш елларында күтәреп чыгу – моның ачык мисалы. Самара губерна идарәсе яңа мәчет салырга рөхсәтне 1916 елның 29 апрелендә бирә. Шактый гына төзелеш эшләре башкарылып ятканда, хакимият алышына, гражданнар сугышы башлана. Шул сәбәпле эшләр ярты юлда туктап кала, имам сайлау да кичектерелә. 1918 елны гына әлеге вазифага Хәмзә Әхмәтшин раслана[86].

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Хәмзә мулла Митрәйдән күчеп килгән. Бу мәхәлләдә Заһидулла Мотыйгуллин мөәзин хезмәтен башкарган.

Беренче бөтендөнья сугышы бетеп, Россиядә хакимияткә большевиклар килгәч, 1918 елда авылда ярлылар комитеты төзелә. Комитетның беренче рәисе булып Зарип Садыйков эшли, сәркәтип итеп Пашков фамилияле рус кешесе китерелә.

Бу чорда авыл башкарма комитеты да оештырыла. Беренче авыл комиссары Фәррахетдин Шәрифуллин була. Комитет әгъзалары булып Габделгазиз Бәдигов, Миңлезакир Хәсәншиннар тора[87].

Гражданнар сугышы чорында авыл аша акларның һәм кызылларның отрядлары үтә. Әмма бу тирәдә зур сугыш хәрәкәтләре булмый.

1920 елның кышында продотрядлардан аеруча җәфа чиккән авыллар «сәнәклеләр» фетнәсенә кушыла. Әлеге отрядлар Әсәйдән дә олау-олау икмәк ташыйлар, бик күп кешеләр запассыз кала. Менә шул запас булмау аркасында 1921 елда авылда күп кеше ачтан үләчәк. Продотрядлар Әсәй кешеләрендә зур ачу тудырса да, ни сәбәпледер, восстаниегә кушылучылар булмый.

Баш күтәрүчеләр тирә-як авылларда продотрядларга ярдәм күрсәткән коммунистларны һәм активистларны эзәрлеклиләр. Яңача укыткан хәлфәләргә дә аларның беркадәр ачуы була. Шунлыктан Әсәйдә Шәет хәлфәне «сәнәклеләрдән» саклап калу өчен Митрәйгә озатып куялар. Шуннан соң аның турында хәбәр булмый.

---

[85] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 38 сакл. бер.

[86] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер., 156 б. а–157 б.

[87] ТР ДА, Р–1167 фонд, 1 тасв., 160 сакл. бер., 793 б. а.–794 б.

Башка авыллар кебек, 1921 елгы ачлыкны Әсәй дә авыр кичерә. Кешеләр агач кайрысы һәм тамыры, үлән ашыйлар, иске тиреләрне пешереп карыйлар. Әмма болар гына ач үлемнән коткара алмый, күпләр кырыла.

Билгеле булганча, Америка хөкүмәте, Герберт Гувер җитәкчелегендә, Россиянең ачлыктан интегүчеләренә булышлык оештыра. Америка ярдәме Әсәйгә дә килеп җитә. Ашханә ачып, авылда бушлай ашатулар оештырыла. Күп кешеләргә ул ярдәмнән өлеш чыгарыла. Әмма ашханә озак эшләми, кешеләр ачлык белән бергә-бер калалар. Нәтиҗәдә, ачтан үлүчеләр саны тагын да арта башлый.

Беренче бөтендөнья, аннан гражданнар сугышы һәм 1921 елгы ачлык авылның социаль-экономик үсешенә гаять тискәре йогынты ясый. Күп кенә хуҗалыклар таркала, халык саны бик аз арта.

1921 елда авылдан берничә хуҗалык яңа урынга күчеп утыра – Таллы Бүләк поселогы барлыкка килә. 1922 елның көзендә поселок халкы мәчет салырга рөхсәт ала. Имам итеп Харис Хәйрелислам улы Сәйфуллин раслана[88].

1926 елда Россия буенча халык санын алу үткәргәндә, Әсәйдә нибары 1236 кеше исәпләнә (1916 елда 1708 кеше иде). Бу күрсәткеч буенча ул Азнакай волостенда дүртенче урында тора.

Егерменче елларның беренче яртысы авылга шактый яңалыклар алып килә. Шуларның икесенә аерым тукталып үтик. 1922 елның язында авылда элек эшләп килгән мәктәп бетерелеп, аның урынына совет мәктәбе ачыла. Беренче укытучылар – Сөнәгать Хәйруллин һәм Гамилә исемле хатын-кыз (фамилиясе билгесез). Укучылар күбәйгәч, 1934 елдан уку ике сменада оештырыла. Бишенче-җиденче классларга Уразай, Митрәй, Урманай, Карамалы, Көчле Бүләк, Галимовка, Маратовка, Октябрь Бүләге, Таллы Бүләк авылларыннан килеп укыйлар. Ул чорда мәктәпнең директоры булып Мөнир Садриев эшли.

Икенче зур яңалык – авылда кулланучылар кооперациясе оештырылу (1924 ел). Аны оештыруда Садри Насрыев актив катнаша һәм кооперациянең беренче рәисе итеп сайлана; бухгалтеры булып Иван Панин эшли. Кооперациягә керү взносы – 50 тиен, пай взносы – 2 сум 50 тиен була. Шул акча исәбенә авылда таштан кибет салына. Тауарны Бөгелмәдән алып кайтканнар.

Башка авыллардагы кебек, Совет законы нигезендә 1920 елларда Әсәйдә дә мәхәлләләр теркәлү үтә. Авылда 1917 елга чаклы өч мәхәллә булса, хәзер аларның саны дүрткә җитә.

Беренче һәм икенче мәхәллә муллалары һәм мөәзиннәре хакында 1900 елгы мәгълүматларга таянып әйтеп үткән идек. Совет чорында аларның исән булганнары (беренче мәхәлләдә Әхмәтша хәзрәт) вазифаларын башкаруны дәвам итәләр. Беренче мәхәлләдә тагын Гәрәй хәзрәт, ә совет чорында Бәйрәкәдән күчеп килгән Хәсәнҗан Әхмәтҗанов та мулла булып тора.

[88] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер., 155 б. а.

Икенче мәхәлләдә мөәзин булып Гәрәйша Шәрәфетдинов тора. Ул бик көчле, матур тавыш белән азан укыган. Аның укыганы хәтта Карамалыга ишетелә, дип сөйләгәннәр.

Дини эшчәнлек тыелгач, югарыда телгә алынган мулла-мөәзиннәрнең күбесе репрессиягә эләгәчәк. Мәсәлән, Хәмзә мулланың, Әмин һәм Заһидулла мөәзиннең мал-мөлкәте тартып алынып, гаиләләре белән авылдан куылуы мәгълүм. Соңгысы, эзәрлекләүләргә карамастан, Башкортстанның Октябрьск шәһәрендә дини эшчәнлеген дәвам итә һәм шунда вафат була. Кайбер дин әһелләре репрессияләр башланганчы ук дөнья куйган була, шунлыктан каһәрле язмыш – куылу – аларның балаларына яисә туганнарына төшә. Әлбәттә, Сталин режимы оештырган репрессияләргә мулла-мөәзиннәр генә түгел, авылның элеккеге бай һәм кайбер башка хуҗалыклары да дучар була.

Билгеле булганча, Октябрь инкыйлабы җиңгәч тә, Советларның икенче съездында «Җир турында декрет» кабул ителә. Алпавытларның җирләрен шул декрет нигезендә крестьяннарга өләшәләр. Әсәй авылы кешеләренә Чалпы һәм Туйкә тирәләрендәге алпавыт җирләре бүлеп бирелә.

Ләкин бөтен тырышлыгын куеп иген иккән крестьянның ашлыгын хөкүмәт, хәрби коммунизм игълан итеп, бушлай тартып ала барган. НЭП игълан ителгәч, крестьяннарга тагын ирек бирелә. Амбарлар тиз арада ашлык белән тула. Егерменче еллар урталарында иген уңышы җыеп алу революциягә чаклы дәрәҗәгә күтәрелә. НЭП чорында Әсәй авылы кешеләренең икмәге мул була, алар аны базарда да саталар. Күпләр яңа өйләр сала, малтуарын ишәйтә, моңарчы күрелмәгән муллыкта яши башлый.

Әмма хәлләр тиздән тагын үзгәрә. Совет хөкүмәте илне индустрияләштерү планын игълан итә. Аны тормышка ашыру өчен гаять зур чыгымнар сорала. Промышленность тауарлары бик аз чыгарылганга күрә, ул чорда акчаны бары тик чит илгә икмәк сату исәбенә генә табарга мөмкин була. Шуның өчен хөкүмәт үзенең төп игътибарын авылга юнәлтә. Большевиклар, авыл халкыннан күбрәк һәм арзан хакка икмәк алу өчен иң кулай юл – күмәк хуҗалыклар (колхоз) оештыру, дигән фикергә киләләр. 1929 елда колхозлар оештыру хәрәкәте башлана.

Коллективлашу башлангач, 1929 елда Әсәйдә 29 хуҗалык коммунага берләшә. Коммунага Сарсаз ягыннан иң яхшы җирләр бирелә. Колхозлашу киң колач алгач, коммунага (ул инде колхоз дип йөртелә башлый) керүчеләр күбәя. Яз көне колхозда 87 хуҗалык исәпләнә. Беренче рәис итеп Садри Насрыев сайлана. Колхозга «Кичү» исеме бирелә. Коммунага тәүге җирләр авыл белән түбән тегермән арасындагы Стәрле елгасы аша кичүлек тирәсендә бүленгәнлекне күз алдында тотып, колхозга да шундый исем бирергә булганнар, ахры. Бу исемнең искелектән ваз кичүне аңлатуы да мөмкин.

1930 елның башында колхозга калган хуҗалыклар да керә. Әмма шул елның 15 мартында ВКП(б) Үзәк Комитетының «О борьбе с искривлениями партийной линии в колхозном движении» карары чыккач, яңа кергән хуҗалыклар колхоздан чыга башлыйлар. Шулай итеп, анда 300 хуҗалыктан нибары 87 се кала. Бу хәл турында Казанга хәбәр иткәч, аннан ике уполномоченный килеп төшә. 1931 елда халык яңадан гариза яза, 300 дән артык хуҗалыктан торган колхоз оеша.

Бу елларда җирне ат белән эшкәрткәннәр. Атларны, тырма-сабаннарны күмәкләштереп, колхоз милке итәләр. Беренче елда иген колхозчылардан җыеп алынган симәнә хисабына чәчелә. Эшләгән кешегә, нормага карап, көнлек азык биргәннәр. Күчмә ашханәләр эшләгән. Ул чакта 7 кырчылык бригадасы булган. Бригадирлар кеше саен кереп эшкә әйтеп йөргәннәр.

1931 елда Әсәй авылы аша Тымытык ягына 12 «Фордзон» тракторыннан торган колонна үтә. Халык аларны күреп бик гаҗәпләнә. Арада куркып, тегермәнгә, мунча мичләренә кереп качучылар була. Трактор турында «шайтан арбасы» дигән сүзләр тарала. Әлеге тракторлар яңа оештырылган Тымытык машина-трактор станциясенә (МТС) җибәрелгән була. Шул елдан МТС, колхозлар белән килешү төзеп, төрле кыр эшләрен башкарырга керешә.

Озакламый авылга да техника кайта башлый. Колхоз башта катлаулы сугу машинасы белән ашлык суктыручы «Фордзон» тракторы сатып ала. Аннан соң, колхозның машина-трактор паркын ур һәм көлтәне үзе бәйли торган «самовязка» машиналары тулыландыра. Билгеле, болар барысы иген уңган елларда ашлык саткан акчага алына.

Мулла-мөәзиннәрне авылдан кугач, чират шомлы тынлыкка чумган мәчетләргә җитә. 1934 елда аларның манараларын кисеп төшерәләр. Өч мәчетнең биналарыннан мәктәп салалар, ә дүртенчесеннән клуб ясыйлар. Шулай итеп, авылның дини һәм милли йөзен чагылдырган истәлекләр бер селтәнүдә юкка чыгарыла.

Колхоз оешып күп тә үтми, Әсәйдә (татар авыллары арасында беренчеләрдән түгелме?) дуңгызчылык тармагы булдыралар. Татарстан игенчелек халык комиссариатының (Татнаркомзем) 1935 елның декабрендә төзелгән авыл хуҗалыгында стахановчылар нормасын үтәүчеләр исемлегендә «Кичү» колхозы дуңгыз караучысы Г.Р. Рахмановны да күрәбез[89]. Дуңгыз үрчетә башлауны ул чор татар җитәкчеләрнең үзләрен кыю, хәтта төрле дини чикләүләрдән дә бик тиз ваз кичкән итеп күрсәтәсе килгәннән туган гамәл дип бәяләргә кирәктер.

[89] Коллективизация сельского хозяйства Татарской АССР (1927–1937). Документы и материалы. Казань, 1968. С. 283.

1934–1935 елларда колхозда игеннәр әйбәт уңа, һәр хезмәт көненә колхозчылар шактый ашлык алалар. Ә менә 1936 елда, киресенчә, уңыш түбән була, бик күп мал-туар үлә.

1937 елда колхоз алдагы елларга караганда да күбрәк уңыш җыя. Колхозчыларның һәр хезмәт көненә икмәк белән мулдан түлиләр. Хәтта хуҗалык саен кереп, олау-олау икмәк аударып йөриләр. Аннан соңгы елларда да тотрыклы уңыш алына. Әмма тыныч еллар санаулы гына калган була.

1941 елда Германия сугыш башлагач, Әсәйдән бик күп ир-ат (200 дән артык) фронтка китә. Аларның шактые (134 кеше дип тә әйттеләр) сугыш кырларында ятып кала.

Сугышта һәлак булучылар исемлегендә элеккеге колхоз рәисе Насриев Садри да күрсәтелә. Аның кызы – Хәбибуллина Тәнзилә (1936 елда туган) – күптомлык «Хәтер» китабын төзүчеләрнең берсе (ул берүзе аның барлык томнарын татарчага тәрҗемә итә, шул вакытта редакцияли дә), баш редактор урынбасары була.

1941–1945 елларда һәм аннан соңгы чорда колхоз рәисләре булып Асия Сабирова, Гали Шәймөхәммәтов эшли. Авыл советы рәисе вазифасын – Сабирҗан Гыйззәтуллин, Камәр Вәлиева, Галим Рахманов, Миннаял Садриев, Шакир Шәрипов, ә сәркәтип вазифасын Банат Шәйхетдинова, Мәгъсум Хәкимовлар башкаралар.

1953–1979 елларда колхоз белән Сабах Гәрәй улы Хәсәншин җитәкчелек итә. Илленче еллардагы кебек, алтмышынчы елларның икенче яртысында колхозларны эреләндерү башлана. «Кичү» колхозын 1968 елда күршедәге Чапаев исемендәге колхозга кушалар. Берләштерелгән колхозга Чапаев исеме бирелә. Колхоз рәисе итеп югарыда телгә алынган С.Г. Хәсәншин сайлана.

1979 елдан колхозга Әсәй авылында туып-үскән Илсөяр Вагыйз улы Закиров җитәкчелек итә. Озакламый (1981 ел) «Чапаев» колхозы «Әсәй» совхозына үзгәртелә. Дистәдән артык ел җитәкче булып эшләү чорында И.В. Закиров авылның социаль-икътисади базасын ныгытуга зур көч куя. Авыл юлларына асфальт түшәлә, йортларга газ керә.

1994 елның чалт аяз 23 сентябре көне исә бик күпләрнең хәтерендә гомерлеккә сакланыр. Алты дистә ел элек дүрт мәчетен югалткан авыл, ниһаять, берсен кайтарды. Һәм, бу кайтару-кайту озакка, мәңгелеккә булсын, дигән уй-теләк күпләрнең күңелендә булгандыр ул көнне[90].

[90] Авыл тарихы 1994 елда язылды.

## § 4. Балтач

Мондый атамалы авыллар Татарстанда берничә. Берәрсенең Азнакай төбәгендәге Балтачка катнашы бармы дигән сорау туарга мөмкин. Чөнки башка авыллар мисалында төбәккә Казан якларыннан килеп утыручылар күп булуы күзгә ташлана.

Белешмә әдәбиятта Балтачның ничек барлыкка килүе тасвирланмый, бары XVIII гасырда нигезләнгән авыл булуы гына күрсәтелә. Шуңа күрә, борынгы архив документларын тирәнтен өйрәнмичә, авылның барлыкка килү тарихын ачыклау мөмкин түгел.

Төбәктәге дистәләрчә авыллар кебек, Балтач та Казан өязе ясаклы татарлары тарафыннан нигезләнә. Җөри юлыннан мондагы җирләргә иң беренчеләрдән булып 1740 елда Якуп Тимәшкин, Балтач Уразмәтов[91], Т. Бакыев, Имәш Уразкин, Биккол Уразкаевлар (барысы 7 ир-ат) күчеп килә. Беренчесе Әхтиял (хәзерге Менделеевск районының Татар Әхтиялы авылы) авылыннан, калганнары Текәштән (хәзерге вакытта Менделеевск районында Татар Текәше исеме белән билгеле авыл) була[92]. 1741 елда шул ук төбәкнең Ижтамак авылыннан Рысмәт Бигәшов, Зәет Сәетов һәм башкалар (барысы 7 ир-ат) килеп утыра[93]. Тагын бер чыганакта Кече Чүмән авылыннан Ишмәмәт Азнаголов һәм Якуп Уразов гаиләләре күчеп килүе турында әйтелә[94].



*Авылга 1740 елда нигез салучыларның берсе Балтач [Уразмәтов] теркәлгән документ фрагменты*

Яңа барлыкка килгән авыл баштарак Кыпчак (документта «новопоселенная Кипчак»), аннары Балтач Уразмәтов исеме белән Балтач дип атала. «Кыпчак», «нугай» атамалары төбәк тарихында еш очрый, хәзер дә

[91] Бу чыганакта фамилиясе хаталы («Ураскеков») язылган, 2 нче ревизиядән (1747 ел) Уразмәтов языла.

[92] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1155 сакл. бер., 474 б. а.–475 б.

[93] Шунда ук, 478–478 б. а.

[94] Шунда ук, 1142 сакл. бер., 661–663 б.

халык хәтерендә өлешчә сакланган. Алар кайчандыр монда безнең кыпчак бабаларыбыз яшәгәнен искәртеп тора.

Ясаклы татарлар килеп утырганда бу җирләр Юрмый волосте карамагында булган. Шуңа күрә аның биләмәчеләре белән 1742 елда договор төзелгән. Берьюлы 40 сум оброк түләп, күченүчеләр җиргә хокукларын беркетә[95].

1748 елда Балтачта барлыгы 37 ир-ат исәпләнә. Балтач Уразмәтов (чыганакта «Уразмеев»; 48 яшь) уллары Бакый (25), Бикмәт (20), Мәсгут (10) һәм Сәет (5) белән яши[96]. Алар белән бергә теркәлгән Якуп Тимкин (62) һәм Якуп Уразов (30) гаиләләре 1748 елдан соң Туйкәгә күчеп утыра[97].

1762 елгы ревизия документында авыл беренче тапкыр хәзерге исеме белән теркәлә[98]. Анда ясаклы (100 ир-ат) һәм йомышлы (5) татарлар яши. Авыл халкының төп өлешен Балтач[99] Уразмәтов (1696–1755; уллары Бакый, Биккенә, Мәсгут, Сәет) белән бергә килгән Җөри юлы ясаклы татарлары тәшкил итә. 1758 елда авылга Казан өязе Арча юлына кергән Шәмәрдәннән Әмир Исаев гаиләсе (6 ир-ат; икенче хатыны Бәзәкә авылының башкорт сословиесендәге татар кызы), шул ук территориядәге Кәвәлдән Пулатай Ахманаев гаиләсе (4 ир-ат) килеп утыра. 1755 елда Арча юлының Олы Шыңар авылыннан йомышлы татар Бакый Рысмәтов гаиләсе дә (5 ир-ат; уллары Нәзир, Зөбәер, Әлкәш, Зәбир) монда күченә. Әлеге кешедән соң зур төркем ясаклы татарлар (27 ир-ат, шул исәптән Сәфәр Мәмәдәлин (74 яшь), Миңлебай Бикмәтов (59), Госман Балтаев (40), Юлдаш Сөешев (36) һәм башкалар) күрсәтелә, алар да Олы Шыңарга карыймы-юкмы, бу хакта әйтелми. Ревизия мәгълүматын раслап Ишмәмәт Аднаголов үзенең нәсел тамгасын салган[100]. Нәкъ шундый нәсел тамгасы бу юллар авторына Бәләбәй өязе Катай авылы биләмәчеләре (вотчинниклары) тарихын өйрәнгәндә очраган иде[101].

Балтачлыларның ерак авылларда яшәүче башкорт сословиесендәге татарлар белән элемтәсе күзәтелә. Мәсәлән, бер кешенең хатыны Тансык Ишәева Имән (хәзерге Сарман районындагы Иске Имән авылы) «башкорты» кызы була. Болар кызларын Кәлшәле (хәзерге Туймазы районындагы авыл) «башкорты» Даут Корбанаевка кияүгә бирәләр. Шул ук Кәлшәледән ясаклы татар Зәет Шитимов Балтач авылы кызы белән гаилә кора[102].

---

[95] БР МА, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 193 б.
[96] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1142 сакл. бер., 661 б. а.
[97] Шунда ук, 3795 сакл. бер., 378 б.
[98] Чыганакта «Болтасево Кипчак тож» дип язылган.
[99] Бу чыганакта исеме ялгыш «Болтай» дип язылган.
[100] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3795 сакл. бер., 343–349 б. а.
[101] Таһир Кәрим. Җиде бабаңны бел, катайлым. Казан, 2020.
[102] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3795 сакл. бер., 344 б. а.–346.

1762 елда Балтачта йомышлы («служилый») татарлар бары бер гаиләдән торса, 1782 елга алар күчеп килүчеләр исәбенә шактый арта. Болар турында тулы мәгълүмат беренче тапкыр 1795 елгы ревизия документында бирелә.

1795 елда Балтачта (чыганакта «Балтачево, что на речке Стерлибаш Купчак тож») 53 ир-ат һәм 55 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 63 һәм 60 була) йомышлы татар яши. Бертуганнар Мәҗит, Бәхет (?) һәм Нәзир 1794 елда Уфа казна палатасы указы нигезендә Каргалы бистәсенә сәүдәгәрләр булып күченәләр. Мактамабаш һәм Миндубай авылларына да күчүчеләр була. Ревизия исемлеге ахырында бертуганнар Зөбәер (45 яшь), Әлкәш (41) һәм Зәбир (38) Моратовлар теркәлгән. Алар 4 нче ревизия вакытында ясаклы татарлар булсалар, 1787 елда казна палатасының указы нигезендә ясаклыдан йомышлы татар сословиесенә күчерелә[103].

Балтач авылының (чыганакта «Балтачево Кипчат тож») икенче исемлегендә 1795 елда 46 ир-ат һәм 31 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 76 һәм 49) ясаклы татар теркәлгән. Халык саны нык кимүнең сәбәбе – 1795 елда Уразай (чыганакта «Уразаево Тигирмень Илга вершина речки Стерля тож») һәм Татар Кандызы авылларына күченеп китүчеләр булу. Беренче авылга күченүчеләр сөрүлекләр һәм печәнлекләр аз булуны сәбәп итеп күрсәтәләр. Бу чыганакта да Зөбәер, Әлкәш һәм Зәбир Моратовларның йомышлы татар сословиесенә күчүе турында әйтелә[104].

Югарыда әйтеп үткән Уразай (Тегермән Елга) авылында 37 ир-ат һәм 35 хатын-кыз ясаклы татар исәпләнә. Монда бары тик Балтачтан һәм Стәрлетамак округының Аллагуват авылыннан күченүчеләр генә яши. Соңгы авылдан Аднагол Бикколов (59), Уразман Аитов (55), Сәгыйть Балтачев (55), Мәхмүт (39) һәм Гобәйдулла (33) Мәксүтовлар күчеп киләләр[105].

Аллагуват (Башкортстанның Стәрлетамак районына керә) Ногай юлының Юрматы волостена керә. Бу факт ике татар волостеның (Юрмый һәм Юрматы) тыгыз элемтәләре булуын өлешчә дәлилли.

1816 елда Балтач Кәкре Елга волостена карый. Сословиеләре буенча халык лашман бурычын башкаручы (чыганакта «исправляющие лашманную повинность») йомышлы һәм ясаклы татарларга бүленә. Беренчеләре – 67 ир-ат һәм 81 хатын-кыз (24 хуҗалык; Мөхәммәтшәрип һәм Рәхимкол Мөхәммәдьяровлар, Әс[ф]әндияр Нө[р]кәев, [Г]омәр, Тимербулат, Бикбулат Котлымәтовлар, Мәксүт Мансуров, Бикбулат Биктимеров, Зөбәер һәм Зәбир Моратбакиевлар һәм башкалар)[106]. Икенчеләре – 33 ир-ат һәм 27 хатын-кыз (14 хуҗалык; Мәнәй һәм Мәннан Сәгыйтовлар, Зөбәер Зәетов, Корбанай Морадымов, Габдерәшит һәм Габҗәлил Габдерәззаковлар, Бикташ Колмәмәтов,

---

[103] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 22 сакл. бер., 129–133 б. а.
[104] Шунда ук, 23 сакл. бер., 238–241 б. а.
[105] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 248 б. а.–249 б. а.
[106] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 197 сакл. бер., 334–345 б.

Токтар һәм Мәҗит Тимәшовлар, Габделнасыр Ишмөхәммәтов, Ильяс Гамбәров, Хәбибулла Тимеркәев, Хәбибулла Мәүлекәев, Надырша Гаделшин, Ишмөхәммәт Ишмәнов)[107].

Бер чыганакта якындагы Уразай (Тегермән Елга) авылы исеме белән теркәлгән ясаклы татарлар төркеме (39 ир-ат һәм 44 хатын-кыз; Галикәй һәм Кормангали Биккениннәр, Бикчәнтәй Бикколов һәм башкалар)[108] Балтачка карый дип күрсәтелә. Анда шулай ук тагын бер солдат улы да аерым телгә алына[109]. Ревизия документында бу хакта әйтелми, әмма башка чыганаклар Балтач халкын һәрвакыт Уразай (Тегермән Елга) дип аталган урында яшәүчеләрне дә кертеп исәплиләр.

Шулай итеп, 1816 елда Балтач халкы 140 ир-ат һәм 152 хатын-кыздан тора. Бу чорда авылда мәчет, Стәрле елгасында (4) һәм Тегермән Елга исемле инештә (1) тегермәннәр була. Аларның хуҗалары – Әлкәй Биккенин, Ильяс Гамбәров, Бикбулат Биктимеров, Мәксүт Мансуров һәм Габҗәлил Бикчәнтәевләр.

1858 елгы ревизия вакытында Балтач кешеләре сословиеләренә карап элеккечә аерым-аерым теркәлә. Бер документта дәүләт крестьяннары (135 ир-ат һәм 152 хатын-кыз; 26 хуҗалык) һәм кантонистлар (5 и 4; 4 хуҗалык) бирелә, икенчесендә – шулай ук дәүләт крестьяннары (47 ир-ат һәм 49 хатын-кыз; 12 хуҗалык, шул исәптән 67 яшьлек Минәй Сәгыйтов) һәм отставкадагы солдатлар (3 ир-ат һәм 6 хатын-кыз; 3 хуҗалык)[110]. Әлеге дәүләт крестьяннары дип язылганнар (барысы 182 ир-ат һәм 201 хатын-кыз) элеккеге йомышлы һәм ясаклы татарлардан тора.

Балтачның өченче төркем дәүләт крестьяннары (64 ир-ат һәм 86 хатын-кыз; 13 хуҗалык, шул исәптән Байбуре Галикәев) Уразай (Тегермән Елга) дип аталган урында яшәүчеләрдән тора[111].

Болардан башка, 1859 елгы ревизия документында типтәр сословиесенә караган указлы мулла Габделхәким Мостафин (57 яшь; уллары Габделгалим һәм Габделбәдыйг) күрсәтелә. Аның гаиләсе 4 ир-ат һәм 7 хатын-кыздан тора. Алар документның титул битендә «башкорт», эчке битендә «типтәрдән башкорт» («башкиры из тептярей») дип язылган[112].

Статистик әдәбиятка күз салсак, 1859 елда Балтачта 260 ир-ат һәм 306 хатын-кыз (84 хуҗалык) яши. Алар сословиеләре буенча дәүләт крестьяннары һәм «башкорт»лар дип күрсәтелгән[113]. Ревизия документыннан күрдек,

---

[107] Шунда ук, 535–540 б.

[108] Шунда ук, 712–718 б.

[109] Шунда ук, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 123 б.–123 б. а.

[110] СӨҮДА. 190 сакл. бер., 145 б. а.–164, 170 б. а.–177, 181, 405–415 б.

[111] Шунда ук.

[112] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 757 сакл. бер., 137–139 б.

[113] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. г. С. 35.

«башкорт» дип язылганы указлы мулла гаиләсенә генә туры килә. «Типтәр»ләр (шул исәптән әлеге мулла гаиләсе) 1855 елдан «Башкорт» гаскәрендә саналгач, рәсми чыганакларда сословиеләре буенча «башкорт» дип языла башлый.

Югарыда сүз барган документлардан күренгәнчә, Балтач авылында беркайчан да биләмәчеләр яшәмәгән. Шуңа күрә кайбер авторларның аны Юрмый волосте биләмәчеләре авылы дип язулары аңлашылмый. Алар ул авылга нигез салмаганнар һәм анда яшәмәгәннәр.

1889 елда Балтачта 165 хуҗалыкта 825 кеше күрсәтелә. Гасыр ахырынарак авыл тагын да зурая: 1897 елда 202 хуҗалык, 531 ир-ат һәм 576 хатын-кыз була. Мәчет, мәктәп һәм 4 су тегермәне эшли.

XIX гасырның соңгы дистәсе игенчелекне әледән-әле авыр сынаулар алдына куя. 1891–1892 елларда корылык аркасында игеннәр уңмый, халык, мал-туар ачлыктан интегә. Аннан соңгы дүрт елда исә икмәк яхшы уңа. 1894–1895 елларда уңыш, 1893 елгыга караганда, югарырак була. Әмма 1898 елны тагын корылык булып, ачлык килә.

Әлеге афәт Балтачтан дистәдән артык гаиләне читкә бәхет эзләп чыгып китәргә мәҗбүр итә. Берәүләрен – кыска срокка, икенчеләрен исә бөтенләйгә. Мөхәммәтгали Сәфәргалиев, мәсәлән, Чиләбедә эшләп кайта. Шакирҗан Вәлиев һәм Әфләтүн Айчуаков 1899 елның кыш-яз айларында Курск губернасына ук барып чыгалар.

Әмма иң зур тәэсир калдырганы – дистәдән артык кешенең Төркиягә күченеп китүе. Болар – Габдулла Кәримов (хатыны һәм 3 баласы белән), Әһлиулла Габделхәбиров (гаиләсе юк), Гарифулла Габделхәбиров (хатыны, 4 баласы), Хәйрулла Рәхмәтуллин (хатыны юлда вафат була), Хәлиулла Рәхмәтуллин (гаиләсе юк, үзе өлкән яшьтә), Якуп Юнысов (гаиләсе юк), Йосыф Юнысовлар (гаиләсе юк)[114].

Балтачта бик күптәннән мәчет эшләп килүе хакында әйтелгән иде. 1882 елдан бирле монда указлы мулла булып Әхмәтвәли Габделбәдигъ улы Баязитов (44 яшь) тора. Ул хатыны (19), 3 улы (зурысы 16 яшьтә) һәм 2 кызы белән яши. Мулланың хуҗалыгында 3 эш аты, 4 сыер, 30 сарык һәм төрле вак маллар була. Барлык чәчүлекләре 13,48 дисәтинә тәшкил итә. Шуларның бик азы гына (3,10 дисәтинә) үз иманасында, калганнары авылдашларыннан (5,50) һәм читтән (4,88) арендага алган басуларда. Өстәвенә, Әхмәтвәли хәзрәт зур умарталык (19 баш) хуҗасы да була. Хуҗалыктагы эшләрне башкару өчен үз көче генә җитми, әлбәттә, шунлыктан ул даими хезмәтче тота.

Авылның мөәзине (1889 елдан) – Мөхәммәтзакир Гобәйдуллин (40 яшь). Гаиләсе хатыны (25), 2 улы һәм кызыннан тора. Мулладан аермалы буларак, аның хуҗалыгы зур түгел. Анда 2 эш аты, 3 сыер, төрле вак маллар һәм умарталык (3 оя) була. Барлык чәчүлекләре 10 дисәтинәдән аз гына арта.

---

[114] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 31 сакл. бер.

Мәктәпкә турыдан-туры кагылышлы мәгълүматлар юк. Әмма ләкин авылда ике кешенең укытучылык белән шөгыльләнүе билгеле. Укытучыларның беренчесе – Шәйхулла Нигъмәтуллин (37 яшь). Документтан күренгәнчә, бу шөгыль аның елга 5 ай вакытын алган. Хезмәте өчен балаларның ата-аналары хуҗалыкта җитештергән продуктлар белән түләгәннәр. Укытучының хуҗалыгы ярлы: сыер һәм бозау, 3 сарык һәм нибары 1,55 дисәтинә чәчүлек. Җәйләрен ул еш кына көнлекчелеккә йөрергә мәҗбүр була.

Кыз балаларны шулай ук 5 ай – көз (1 ай), кыш (3) һәм яз (1) Әсхәпҗамал Габделгафурова (50) укыта. Аңа 24 яшьлек кызы ярдәм иткәли. Алар икесе генә яшиләр, бер кәҗәне исәпләмәгәндә башка мал-туары да, чәчүлекләре дә булмый. Бары укытучылык һәм җәй айларында көнлекчелек исәбенә яшиләр.

Ул чордагы авыл тормышын сәүдәгәрләрсез күз алдына китерү кыен. Монда берьюлы 3 хуҗалык лавка тота. Алар арасында Габдулла Мөхәммәтҗанов (37 яшь) аерылып тора. Ул әнисе (85), хатыны (35), 2 улы һәм 2 кызы белән көн итә. Хуҗалыгы зур: өчәр эш аты һәм сыер, 2 үгез, төрле вак маллар асрый, күп (20,45 дисәтинә) иген игә. Болардан тыш, 22 баштан торган умарталыгы да була аның. Хуҗалыкта күп эшләрне хезмәтчесе башкара.

Калган 2 лавка хуҗалары – Хәлиулла Бикмөхәммәтов (35 яшь) һәм Дилмөхәммәт Зөлмөхәммәтов (38). Мал-туардан берәр эш аты тоталар; чәчүлекләре зур түгел (6–7 дисәтинә).

Лавкалардан чәй-шикәр һәм көндәлек тормыш өчен кирәкле башка товарлар бер дә өзелмәгән. Кирәк-яракны Бөгелмәгә барып Шакир байдан һәм аның кебек эре сәүдәгәрләрдән әледән-әле алып кайткалаганнар. Кайсы лавкага нинди товар кайткан, бу хәбәр шунда ук өйдән-өйгә тарала торган булган. Күбрәк бертөрлелек хас авыл тормышы өчен үзенә күрә вакыйгага тиң яңалык булган ул.

Балтачта, волостьның кайбер башка авылларына караганда, тегермәннәрнең күбрәк булуы хакында әйткән идек. Алар турында тулырак мәгълүмат биреп үтик.

1900 елгы документлардан күренгәнчә, авылда 3 су тегермәне була. Шуларның берсе – Балтач авыл җәмгыяте тегермәне, ул Стәрле елгасында урнашкан. Аны Бөгелмә мещаны Демьян Игнатьев (57 яшь) арендага алган. Тегермәнче монда 4 улы белән яши, хуҗалыгы зур түгел.

Икенче тегермән – Григорий Севастьяновныкы (56 яшь). Ул Балтачка Бөгелмә өязенең Павловка авылыннан күчеп утырган. Монда хатыны (56) һәм улы белән яши, тегермәндә үзе эшли. Аның 2 эш аты, сыеры, төрле вак маллары һәм 3 дисәтинә чәчүлекләре (авыл кешеләреннән арендага алган басуларда) була.

Исәп буенча өченче тегермән – Михаил Ключиков (43 яшь) милке. Ул тумышы буенча Бөгелмә өязенең Сумароково авылыннан була. Гаиләсе хатыны (43) һәм 4 кызыннан тора. Аның мал-туары һәм чәчүлекләре югарыда

телгә алынган Г. Севастьяновныкы белән чагыштырганда азрак. Тегермәндә үзе эшли.

1900 елны авыл старостасы булып Муллагали Мөхәммәтгалиев (48 яшь) тора. Бу вазифаны башкарган өчен ул хак алмаган. Староста хатыны (45), улы (22), 3 кызы һәм килене белән көн күрә. 2 эш аты, сыер, 3 сарык асрый һәм 12,08 дисәтинә мәйданда иген игә.

Җәләлетдин Фазлытдинов (54 яшь) десятник вазифасын үти. Аның гаиләсе ярлы яши. 23 яшьлек өлкән улы Ивановка авылында эшкә ялланган, калган 2 улы Балтачта көтү көтә. Мал-туары булмый, чәчүлекләре нибары 2,73 дисәтинә тәшкил итә.

Балтачта, кайбер тирә-як авыллар белән чагыштырганда, умартачылык белән шөгыльләнүчеләрнең күп булуы күзгә ташлана. Кайбер умартачылар турында алдарак әйтеп үткән идек. Алардан башка, тагын берничә хуҗалыкны күрсәтеп китәргә кирәк. Мөхәммәдьяр Мөхәммәтҗанов (44 яшь) – 31, Әхмәтгали Мөхәммәтгалиев (30) – 20, Мөхәммәтгали Миңлекәев (29) – 15, Хәлфетдин Мөхәммәтәминов (40) 7 баш умарта тота. 4 хуҗалыкта (Әсхәпҗамал Габделгафурова, Мөхәммәтситдыйк Мөхәммәтҗанов, Нурмөхәммәт Мәнәев, Әхмәтша Мөхәммәтгалиев) исә бу күрсәткеч зур түгел ( 2 дән 5 кә кадәр).

Әмма хуҗалыкларның төп шөгыле элеккечә игенчелек һәм терлекчелек була. Иманаларының күләме зур булмаганлыктан, казнадан һәм якын-тирә алпавытлардан арендага җир алучылар күбәя. Шул ук вакытта кайбер ярлы хуҗалыклар үз иманаларын арендага биреп ел әйләнәсенә көнлекчелеккә йөриләр яисә батрак булып эшлиләр. Мәсәлән, Сәлимгәрәй Айчуаков (35 яшь) Чемодуровка авылы янындагы алпавыт Головинская имениесендә 1899 елның 1 мартыннан 15 октябрьгә чаклы бил бөгә. Әхмәтвәли Габделвәлиевнең (61) улы Сумароково авылы тирәсендәге Шпилев хуторына ялланган. Берничә кеше Елачич имениесенә көнлекчелеккә йөргән.

Балтачта күп мал-туар асраучы хуҗалыклар шактый. Бу яктан бигрәк тә Әхмәтһади Габделбәдигов (33 яшь) аерылып тора. Ул 5 эш аты, 4 сыер, 2 үгез, 36 сарык һәм 7 кәҗә асрый. Хезмәтче яллаган.

Дүртәр эш аты һәм берничә (икедән алып дүрткә кадәр) баш сыеры булган хуҗалыкларга тукталып үтик. Бу исемлеккә Мөхәммәтгали Вәлиев (52 яшь), Мөхәммәтситдыйк Мөхәммәтҗанов (56), Гафиятулла Вәлиуллин (35), Гыйльфан Вилданов (30), Юныс Шәрәфетдинов (48), Фәхретдин Мөхәммәтәминов (46), Хәлфетдин Мөхәммәтәминов, Мөхәммәдьяр Мөхәммәтҗанов һәм Сәетбаттал Шәрәфетдинов (43) керә. Соңгы өчесенең хезмәтчеләре була.

Югарыда телгә алынган хуҗалыклар авылда иң эреләрдән санала. Балтачта күп иген игүчеләр – алар. Хәлфетдин Мөхәммәтәминовның, мәсәлән, чәчүлекләре 17 дисәтинәдән арта. Болар инде таза хәлле хуҗалыклар катлавын тәшкил итә.

Өчәр эш аты һәм берәр-дүртәр сыер тотучы хуҗалыклар тагын да күбрәк. Алар исәбенә (язмабызда телгә алынганнардан тыш) Әхмәтгали Мөхәммәтгалиев, Шәйхетдин Латыйфуллин (40 яшь), Нурмөхәммәт Мәнәев, Әхмәтгали Мәнәев, Габделгалим Сәгыйтов (60), Мөхәммәди Мөхәммәтҗанов (55), Гыймадетдин Ихсанвәлиев (44), Габдулла Мөхәммәтҗанов, Мөхәммәтгали Миңлекәев, Хәйрулла Вәлиуллиннар (40) керә. Аларның берничәсе хезмәтче тота; күпчелегенең чәчүлекләре 10 дисәтинәдән арта. Боларны чын мәгънәсендә урта хәллеләр дип атарга була.

Авылның югарыда күрсәтелгән ике катлавы базар белән аеруча тыгыз бәйләнгән. Аларның төп өлеше үзләреннән арткан мал-туарны һәм икмәкне сатарга алып чыгалар, байыйлар. Капиталистик Россиядә авыл хуҗалыгы продуктларына кытлык бөтенләй булмауны менә шул катлауларның эшчәнлеге, тырышлыгы белән аңлатырга кирәктер.

Авылдагы өченче, ярлы катлау (чәчүлекләре 4 дисәтинәгә кадәр) базар белән аз бәйләнгән. Аларның җитештергәне гаиләне туйдырырга көчкә җитеп барган. Еш кына алпавыт һәм кулак хуҗалыкларына төрле эшләргә ялланганнар.

Иң түбән катлау – авыл пролетарийлары. Аларның чәчүлек җирләре бик аз (0,15 дисәтинәгә кадәр) яисә бөтенләй булмый. Шуңа да күп вакыт көнлекчелеккә йөриләр яисә батрак булып эшлиләр.

Билгеле дәрәҗәдә Балтачта һөнәрчелек тә үсеш ала. Беренче чиратта, агач эше осталарын билгеләп үтәргә кирәк. Алар арасында балта осталарын (Вәлиулла Габитов, Сәлахетдин Йосыпов, Мөхәммәтсафа Гәрәев, Хәбибулла Шәрифуллин, Әфләтүн Айчуаков, Йосыф Шәрәфетдинов, Нәбиулла Кәлимуллин, Мөхәммәтзарип Ихсанвәлиев) һәм столярны (Габделбәдигъ Габделвәлиев; ул балта остасы да) күрәбез. Мөхәммәтзарип Шәриповның 25 яшьлек улы кирпеч сугу белән шөгыльләнә. Хәйрулла Әхмәдиев (54) итекче буларак билгеле. Хәсәнша Гыймазетдинов (36) – йон тетү остасы.

Балтачка читтән килеп төпләнгән һөнәрчеләр дә була. Беренчесе – тимерче Гайфетдин Хәйретдинов (26), Тәйсуганда туып-үскән. Монда Сәлахетдин Йосыповка айга 50 тиен түләп квартирада тора. Аның аттан башка малмөлкәте юк.

Тегүче Хәбибулла Әдһәмов (37 яшь) ерактан, Казан шәһәреннән килеп яши башлый. Үз йортында хатыны (30), улы һәм кызы белән тора. Аның аты, сыеры, 3 сарыгы, 1,88 дисәтинә чәчүлеге була. Тегүчелек белән күп вакытын – яз (2 ай), җәй (1), көз (3) һәм кыш (3) айларында шөгыльләнә.

Кышка керү белән Гайфулла Габделхәбиров (41), Фазулла Мәндикәевлар (46) кәйлә, чүкеч, лом, тимер чөй, көрәк, канат, кыршау һәм чиләкләр алып тирә-як авылларга, якындагы хутор-имениеләргә кое казырга чыгып китә торган булганнар. Башкалары кебек, бу шөгыль дә үзенә күрә осталык-тапкырлык таләп иткән. Теләсә кайдан түгел, су өстәрәк яткан катламны белеп-өйрәнеп казырга кирәк бит. Югыйсә, хезмәтең юкка чыгуны көт тә тор.

Читтә йөреп эшләүчеләрдән тагын Кашшафетдин Әхмәткәримовны (35 яшь) күрсәтергә кирәк. Ул Бөгелмәдә кучер булып урнашкан. Хатыны белән 2 кызы авылда яши. Мал-туары юк, ә читтән арендага алган басуда арыш һәм борай чәчүлекләре нибары 0,94 дисәтинә була.

Шулай итеп, Балтачта халыкның игенчелек һәм терлекчелектән тыш та шөгыльләре күп булуы күзгә ташлана. Югарыда телгә алынган кешеләрнең күпчелеге өчен һөнәрчелек өстәмә табыш чыганагы булып тора. Ә менә чәчүлексез хуҗалыкларда ул – төп яшәү чыганагы.

Авылның социаль-икътисади хәлен тасвирлауны төгәлләр алдыннан тагын бер-ике мәгълүматка тукталыйк. 1900 елда Балтачта 207 хуҗалык исәпләнә. Аларның бише (исемнәре югарыда телгә алынды) читтән күчеп килгән. Авыл этап юлында урнашкан. Шунлыктан монда этап фатиры була. Тоткыннар һәм аларны озатучы конвой тукталган анда. Әлеге фатир Габдулла Ярмөхәммәтов (21 яшь) йортында урнашкан була. Моның өчен ул елга 40 сум күләмендә аренда хакы алган[115].

1908 елның көзендә Балтач халкы икенче җәмигъ мәчет салырга рөхсәт ала. Яңа мәхәлләгә 1910 елның язында мөәзин һәм мөгаллим булып Таҗетдин Хәйретдинов раслана. Ә көзгә кергәч хатыйплыкка Габделгали Әхмәтвәлиев указ ала.

Әлеге яшь хәзрәт – беренче мәхәллә хатыйбы Әхмәтвәли Габделбәдигъ улы Баязитовның улы. Әхмәтвәли хәзрәт үзе Мофаздал Мөхәммәтвафа улы Динмөхәммәтов (ул 1909 елдан имам һәм мөгаллим) белән бергә эшләгән[116].

Яңа мәчет ачылу үзе бер зур вакыйга булса, икенчесе – кырчылыкка мал чөгендере культурасын кертү. 1913 елда «Самара крестьян хуҗалыгын яхшырту җәмгыятенең» турыдан-туры катнашы белән башкарыла бу эш. Моның өчен җәмгыять Туйкә кредит ширкәте аша Туйкә, Уразай, Әсәй һәм Балтач авылларындагы 44 хуҗалыкка бушлай ярты пот мал чөгендере орлыгы өләшә. Балтачта чөгендер 9 хуҗалыкта үстерелә. Аларга 0,12 фунттан 0,25 фунтка (фунт – кадак, гөрәңкә, ягъни 409,5 граммга тигез булган үлчәү берәмлеге) кадәр орлык өләшенә. Габделвәли Исламголов, Заһидулла Яруллин, Мөхәммәди Мөхәммәтҗанов, Әхмәтҗан Мөхәммәтҗанов, Гыймаделислам Фәхрелисламовлар 10–16, Шәфыйгулла Галиуллин, Минһаҗетдин Низаметдинов, Габдулла Мөхәммәтҗанов, Закир Габделвәлиевләр 2–7 пот чөгендер уңышы алуга ирешә. Беренче ел өчен әйбәт кенә күрсәткеч, дигән нәтиҗәгә килә статистиклар[117].

---

[115] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 31 сакл. бер.

[116] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер., 154–155 б.

[117] Самарское общество улучшения крестьянского хозяйства. Отчет о деятельности и состоянии средств общества за второе трехлетие его существования (с 7 ноября 1910 г. по 7 ноября 1913 г.). Самара, 1914. С. 161–162.

Әмма аның икенче елында сугыш башлана. Дистәләгән балтачлылар беренче айларда ук мобилизациягә эләгә. 1915 елның апреленә 73 кеше (Миңлегали Айчуаков, Якуп Әхмәдиев, Хабибрахман Әхмәтгалимов, Ибраһим Әхмәтҗанов, Исхак Әхмәтҗанов, Зәки Габделлатыйпов, Әхмәтлатыйф Галиев, Миңлехәлим Галиев, Нургали Габделвәлиев, Габдрахман Галимов, Әхмәтзарип Галимов, Фазулла Гарифуллин, Ибраһим Гафиятуллин, Кашшафетдин Гыймадетдинов, Котдус Йосыпов, Газизулла Кәлимуллин, Нигъмәтулла Латыйфуллин, Фазулла Латыйфуллин, Габделислам Миңлебаев, Солтангали Миңлекәев, Мостафа Мөхәммәдиев, Мөстәкыйм Мөхәммәдиев, Вәлиулла һәм Мөсәгыйть Нәбиуллиннар, Габделбәдигъ Нәфыйков, Сабир Нәфыйков, Әхмәтлатыйф Низаметдинов, Закир Рәхимҗанов, Шакир Рәхимҗанов, Садретдин Низаметдинов, Габделгали Нургалиев, Габдулла Сафиуллин, Баһман Сафиуллин, Ногман Сафиуллин, Насретдин Сәетбатталов, Садретдин Сәетбатталов, Фазулла Сәйфуллин, Хәйрулла Сәйфуллин, Миңлегали Сәлимгәрәев, Корбангали Сәфәргали, Мәүләви Ситдыйков, Әхмәтгали Ситдыйков, Габдулла Фазуллин, Заһид Хәбибрахманов, Латыйфулла Хәбибрахманов, Мөхәммәтгали Хәбибрахманов, Шәфыйгулла Хәбибрахманов, Мөхәммәтшакир Хәйдәров, Миңлегали Хәйруллин, Миңлевәли Хәйруллин, Заһидулла Хәлиуллин, Җиһангир Шаһивәлиев, Хәбибулла Шаһидуллин, Шәйхулла Шаһидуллин, Җиһангир Шаһидуллин, Миңлегали Шаһиев, Исмәгыйль Шаһимәрданов, Мәүлетислам Шәйхелисламов, Насретдин Шәйхетдинов, Солтангир Шәйхетдинов, Минаҗетдин Шәрәфетдинов, Сәлахетдин Шәрәфетдинов, Нигъмәтулла Шәфыйгуллин, Габдулла Ярмөхәммәтов, Шаһимөхәммәт Ярмөхәммәтов, Шәмсулла Ярмөхәммәтов, Галиулла Яруллин, Заһидулла Яруллин, Гариф Җаббаров, Мөхәммәтгали Җаббаров, Тәхаутдин Җамалетдинов) герман сугышына китә.

Әлеге исемлектә бертуганнар күп булуы күзгә ташлана. Галиев, Мөхәммәдиев, Низаметдинов, Рәхимҗанов, Сафиуллин, Сәетбатталов, Сәйфуллин, Хәбибрахманов, Ярмөхәммәтовлардан һәм кайбер башка нәселләрдән берьюлы икешәр яисә аннан күбрәк кеше сугышка алына. Күпчелеге – 1914 елда, калганнары 1915 елның апрель аенда мобилизацияләнә.

1915 елның көзендә авыл тагын 26 ир-атны сугышка озата. Болар – Габделгалим Әхмәтҗанов, Насыйбулла Вәлиуллин, Закир Габделвәлиев, Габделкадыйр Галимов, Зиннур Гарифуллин, Шаһидулла Гарифуллин, Гыймаделислам Гафиятуллин, Әхмәтвәли Зөлмөхәммәтов, Рухылбаян Мөхәммәтзакиров, Мөхәммәтсабир Мөхәммәтсафин, Шәфыйгулла Мөхәммәтшакиров, Фәхрулла Нәбиуллин, Хәйдәргали Нургалиев, Габделихсан Сафиуллин, Хәбибулла Сафиуллин, Сәлимҗан Сәлимгәрәев, Миңлегали Сөләйманов, Садретдин Фәхретдинов, Миңлегали Харисов, Ширияздан Йосыпов, Шаһидулла Рави-

лов, Шакир Шаһидуллин, Миңлегали Шәйхетдинов, Хәйретдин Шәйхетдинов, Хөснулла Шәфыйгуллин, Миңнулла Яруллин[118].

Шулай итеп, 14 ай эчендә Балтачтан 99 кеше мобилизацияләнә. Калган чор буенча мәгълүматлар юк, шулай да 1917 елга чаклы тагын шул чама кеше хәрби хезмәткә алынган дип фараз кылсак, ир-атларын сугышка озатмаган гаиләләр авылда бик аз кала түгелме? Шуннан гына да бу сугыш күпме кайгы-хәсрәт һәм авырлыклар алып килгәнлеген чамаларга була.

1916 елда Балтачта 250 хуҗалык, 568 ир-ат һәм 664 хатын-кыз була. Күргәнебезчә, ир-атлар күпкә азрак, әмма сугыш әле бетмәгән. Төбәккә качаклар да килеп урнаша. Балтачта дүрт ир-ат качактан тыш, 2 сугыш тоткыны да яши.

Авыр сугыш елларында да балтачлылар күп терлек асрый һәм мул иген үстерә. Монда 522 ат (шул исәптән 435 эш аты), 607 мөгезле эре терлек (305 сыер), 1631 сарык һәм 198 кәҗә исәпләнә. Чәчүлекләр мәйданы 863,95 дисәтинә тәшкил итә. Шуның яртысыннан күбрәген арыш (415,15 дисәтинә), калган өлешен солы (127,20), карабодай (101), борчак (55,5), тары (48,10), бодай (44), борай (35) алып тора[119].

Россиядә большевиклар хакимияте урнашкач, Балтачта авыл башкарма комитеты оештырыла. 1918 елда Шакир Хәйруллин – комиссар, Шакир Җомаголов һәм Габдулла Галиевлар комитет әгъзалары итеп сайлана. Ул вакытта сайлаучылар 800 кешедән торган[120].

1920 елда монда 291 хуҗалыкта 1363 кеше (шул исәптән 15 рус) яши. 1926 елда әлеге күрсәткечләр шактый кимрәк – 232 хуҗалык һәм 1037 (шул исәптән 10 рус) кеше. Авыл Бөгелмә кантоны Азнакай волостена керә[121].

Утызынчы елларда балтачлылардан беренче репрессия корбаны Абдулла Ярмөхәммәтов була. Аны икенче категория белән раскулачивать итәләр. Мал-мөлкәтен хөкүмәткә алалар, үзен авылдан сөрәләр[122].

Гасыр ахырынарак (1995 ел) Балтачта дүрт йөзләп кеше яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, почта бүлеге, медпункт һәм кибет эшли.

---

[118] ТР ДА, 1124 фонд, 1 тасв., 28 сакл. бер., 53–54, 229–230 б.
[119] Шунда ук, 993 фонд, 1 тасв., 37 сакл. бер.
[120] Шунда ук, Р–1167 фонд, 1 тасв., 160 сакл. бер., 792–793 б.
[121] Шунда ук, Р–1296 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 3 б.
[122] Шунда ук, Р–1221 фонд, 3 тасв., 25 сакл. бер.

## § 5. Зур Сукаеш, Түбән Сукаеш һәм Банки Сукаеш

Сукаеш атамасы белән бәйле авыллар өчәү: Зур Сукаеш, Банки Сукаеш (халыкта Югары авыл) һәм Түбән Сукаеш (Түбән авыл). Алар – гадәти булмаган исеме белән генә түгел, бай тарихы белән дә шактый үзенчәлеккә ия авыллар.

Бу авылларның иң борынгысы Зур Сукаеш санала. Монда яшәүче типтәр сословиесендәге татарларның 1714 елгы җир документы була. Бу документ шулай ук Чалпыда яшәүче «типтәр»ләргә дә карый[123], ике авыл халкы тарихында күпмедер уртаклык булуы турында сөйли. Гасыр башыннан яшәп килгән авыл 1734 елның 8 сентябренә караган документта беренче тапкыр телгә алына[124].

Югарыда күрсәтелгән чыганакта Зур Сукаеш һәм Чалпы авылы «типтәр»ләренең 1740 елга караган договорлары булу турында да әйтелә. Зур Сукаеш һәм Түбән Сукаеш «типтәр»ләренең Юрмый волосте биләмәчеләре белән 1742 елда да килешү төзүләре мәгълүм[125].

Әлеге документларда Уфа өязенә караган һәм типтәр булып киткән ясаклы татарлар турында сүз бара. Алар белән бергә монда Казан өязе ясаклы татарлары да яши, 1762 елдан Уфа өязендә исәпләнсәләр дә, сословиеләре үзгәрми.



*Зур Сукаеш һәм Чалпыдагы типтәр сословиесендәге татарларның 1714 һәм 1740 елларга караган җир документлары булган*

[123] БР МА, И–172 фонд, 1 тасв., 180 сакл. бер., 50 б.

[124] Добросмыслов А.В. Материалы по истории России. Сб. указов и других документов, касающихся управления и устройства Оренбургского края. 1734. Т. 1. С. 159.

[125] Малоизученные источники по истории Башкирии. Уфа, 1986. С. 90.

Казан өязе ясаклы татарлары Сукаешка кайчан килгән? Бер чыганакта яңа нигезләнгән Уразайга 1738 елда Арча юлы Колмәт Котлыгошев йөзлегенә кергән ясаклы татарлар килеп утыруы турында әйтелә. Болар Таулыяр (чыганакта «Тавлуар») авылында туып-үскән Мөслим Мөслимов, Йөзекәй һәм Йосып Үтәгәновлар, Уразай, Уразмәт и Мәксүт Ирмәшовлар («Ирмәчкин»), Дусай Мөслимов (барысы 7 ир-ат) була. 1762 елда бу кешеләрне Сукаеш авылы исемлегендә күрәбез[126]. Димәк, берара боларның авылы Уразай Ирмәшов исеме белән Уразай, ә 1762 елгы ревизиядән Сукаеш дип атала башлый.

«1740 елда Минзәлә ягыннан 170 кешелек берничә хуҗалык Югары авыл юлының югары ягындагы ачыклыкка, «Кыек тау чишмәсе» турына килеп утырганнар. Аннан юлның түбән ягына күчеп, кар баскач, чокырның бу ягына чыгып, хәзер Авзалов Әбүзәрләр утырган урыннан «Галләм» чишмәсенә кадәр бер урам булып утырганнар. Безнең борынгы бабаларыбыз Әлкәй, Галкәй, Дусай, Ишмән булып, шулардан безнең Сукаеш кешеләре таралган», дип әйтелә авыл советы тутырган бер анкетада.

Әлеге риваятьтәге дата (1740 ел) Юрмый волосте биләмәчеләре белән төзегән килешүләрнең берсен күз алдында тота дип уйларга кирәк. Минзәлә ягыннан дип әйтү дә шик уятмый, чөнки типтәр сословиесендәге татарларның шактые Азнакай төбәгенә шуннан килеп утыра.

1762 елгы ревизия документында Сукаешка башлап килеп утыручы ясаклы татарлар Юрмый волостеның Хасбулат Мөтеков командасында теркәлгән. Әлеге чыганакта Ярмәк Сәфәров (68 яшь; уллары Габделкәрим, Габдерәшит, Габдрахман), Смак Госманов (32; уллары Рәфикъ, Мәхмүт, Мәсгут), Якуп Өметәев (72; Корбанай, Сөбханкол, Ягъфәр, Йосыф, Яхья, Ибәкәй, Монасыйп, Морадым), мәрхүм Айдиш Әхмәтовның улы Бакый (22), барысы 18 ир-ат күрсәтелә[127]. Болар соңыннан Түбән Сукаеш «типтәр»ләре буларак билгеле.

Шул ук 1762 елгы ревизиянең башка документында Сукаешка Казан өязеннән килеп утырган, алдарак телгә алынган ясаклы татарларны да күрәбез. Алар хәзер 22 ир-ат тәшкил итә, Юрмый волостеның Хасбулат Мөтеков командасына карамаса да, волость биләмәчеләре (вотчинниклары) белән билгеле бер мөнәсәбәттә торган (шуңа чыганакта «близ старшины Каспулата Мутюкова» дип әйтелә).

Әлеге ясаклы татарлар исемлеге Уразай Ирмәшов (65 яшь) белән башлана. Ул 4 хатыны, Кадермәт (15), Биктимер (10), Йөзекәй (1,5) исемле уллары белән яши. Дүртенче хатыны Зәбидә Ярмәкова (45) Сукаеш ясаклы татары кызы була.

Йөзекәй Үтәгәнов (1754 елда мәрхүм) нәселе дә зур санала. Әлеге нәселне уллары Йомагол (36) һәм Бикчәнтәй (15) дәвам итә. Йомагол Тойма

---

[126] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1154 сакл. бер., 321–321 б. а.

[127] Шунда ук, 3801 сакл. бер., 486–487 б.

авылы ясаклы татары кызына өйләнгән, улы Габделҗәлил (10) һәм кызы Хәбибә була.

1762 елда Сукаешта яшәүчеләр исемлегендә тагын Исмәгыйль Йөзекәев (25; улы Исхак), Үтәй Урмачев (50; уллары Үтәмеш, Атнагол, Исмәгыйль), Мансур Мәксүтов (13), Дусай (25) һәм Мостафа (15) Мөслимовлар күрсәтелә. Ревизия мәгълүматының төгәллеген раслап Уразай Ирмәшов нәсел тамгасын салган, Мәксүт Мансуров талмач булган. Аерым исемлек белән Үзбәк Мостаев (10) бирелә[128]. Алдарак Уразай Ирмәшов исеме белән авылның берара Уразай дип аталуы турында әйткән идек.

Әлеге исемлеккә карап шуны әйтергә була, монда Дусай дигән кеше чыннан да бар (ул анкетада телгә алынган иде). Димәк, аның нәселе зур булган, шуңадыр, исеме дә узган гасыр ахырына кадәр диярлек сакланган. Әлкәй, Галкәй, Ишмәннәр безгә очрамады, алар башка исемлектә бирелгән я булмаса бераз соңрак күчеп килгәндер.

1773–1775 елгы Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында төбәктәге авыллар, шул исәптән Сукаеш та катнаша. Күпме кеше катнашкан, төгәл мәгълүмат юк, документта бары 1763 елгы теркәү кенәгәсеннән алынган халык саны гына күрсәтелә. Монда Сукаешта 44 ир-ат булуы турында әйтелә. Бу вакытта Банки Сукаеш булмый, димәк, бу авыл соңрак, XVIII гасыр ахырындарак барлыкка килгән.

4 нче ревизия (1782 ел) вакытында Сукаеш һәм беренче тапкыр Банки Сукаеш, Түбән Сукаешлар исәпкә алына. Авыллардагы халык берничә исемлеккә бүлеп бирелә. Бер исемлектә Сукаешта – 23, Банки Сукаешта 101 ир-ат «типтәр» күрсәтелә. Алар старшина Аитмәмәт Ишмәмәтов командасында торалар. Түбән Сукаеш «типтәр»ләре (алар барысы 24 ир-ат) старшина Нугайбәк Хәсәнов командасында була. Ясаклы татарлар Сукаешта (39 ир-ат), тагын бер Сукаешта (ул Коры Елга дип тә бирелә; 9 ир-ат) һәм Банки Сукаешта (8) күрсәтелә[129].

1795 елда [Зур] Сукаешта типтәр сословиесендәге 126 ир-ат һәм 93 хатын-кыз исәпләнә[130]. Ясаклы татарлар 35 ир-ат һәм 29 хатын-кыз тәшкил итә. Бер гаилә 1791 елда Бәләбәй округының Ташлы авылына күчеп утыра. Исемлек ахырында Сукаештан килеп утырган 2 ир-ат һәм 2 хатын-кыз теркәлгән[131]. Бер чыганакта ясаклы татарлар күбрәк күрсәтелә.

Түбән Сукаешка күчәбез. 1795 елда типтәр сословиесендәге татарлар 1795 елда 31 ир-ат һәм 48 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 24 һәм 34 була) тәшкил итә. Болар Габделкәрим Ярмәков (1841–1794; уллары Сәйфетдин, Габделваһап, Сәфәргали, Төхвәтулла), Габдерәшит Ярмәков (43 яшь; улы

[128] Шунда ук, 3795 сакл. бер., 365–367 б.
[129] Россия дәүләт тарих архивы, 558 фонд, 2 тасв., 294 сакл. бер., 68–70 б.
[130] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 24 сакл. бер., 460–468 б.
[131] Шунда ук, 23 сакл. бер., 192 б. а.

Габделмәннаф), Сөбханкол Якупов (74; уллары Морадым, Бикташ, Ильяс, Бакир, Мәүлекәй, Габидулла), Ягъфәр Якупов (53; уллары Әюп, Рахманкол, Имангол), Йосыф Якупов (53; Юмагол), Габделлатип (25) һәм Халит (21) Яхиннар, Ибниямин Якупов (42), Монасыйп Якупов (37; уллары Вәлиша, Гаделша, Мөхәммәтша), Шахма Якупов (30; уллары Габделхаликъ, Габделгаффар, Габделҗәббар) була. Халыкның бер өлеше Ирәкте («Минзәлә округы»), Исмәгыйль («Бәләбәй округы»), Сарлы, Сасыкүл, Туйкә авылларының башкорт сословиесендәге татарлары белән никах мөнәсәбәтләрендә тора[132].

1795 елда Түбән Сукаешка якындагы Әгерҗедән 23 ир-ат һәм 20 хатын-кыз ясаклы татар күчеп утыра. Исемлектә Биктимер (1730–1785; уллары Әмин, Рәхмәтулла, Рәфикъ, Габдерәфикъ), Мәһди (60 яшь; уллары Котлыяр, Котлымөхәммәт, Фәйзулла), Габдулла (26; улы Сәйфулла), Ишмөхәммәт (28) Габбәсовлар, Даут (1726–1791; улы Төхфәтулла) и Аптикәй (61; уллары Нигъмәтулла, Гобәйдулла) Биктимеровлар теркәлгән. Никах мөнәсәбәтләре географиясе турында мәгълүмат төрле территорияләрдәге авыллар исемлеген үз эченә ала: Әгертамак (Бәләбәй округы), Айтуган (Казан округы), Бәйрәкә (мондагы округ), Бәтке (Бәләбәй округы), Кәүҗияк (Минзәлә округы), Тегермән (Минзәлә округы) һәм башкалар. Мәһди Габбәсов кызы Рабиганы Акбаш авылының башкорт сословиесендәге татарына кияүгә бирә, ревизия документына «скаскоподатель» буларак нәсел тамгасын сала[133].

Авылларның өченчесе – Банки Сукаеш – бер чыганакта Югары Сукаеш («Верхний Сукаеш») дип тә күрсәтелә. 1795 елда монда типтәр сословиесендәге 16 ир-ат һәм 13 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 18 һәм 11) исәпләнә. Болар нигездә Сатый Бәйрәмов (29 яшь), Сәфәргали Габделваһапов (28), Миңлебай Биктимеров (50), Тимер Баисланов (56), Рахманкол (49) һәм Сөбханкол (36) Шәрипов хуҗалыкларыннан тора. Әбүбар һәм Гали Юлдашовлар гаиләләре Минзәлә округының Шуган авылына күчеп утыралар[134]. Ясаклы татарлар төркеменә 1795 елда Муса Миңлебаев (22), Габдерәшит Мөслимов (51; улы Габделгазиз), Хәким Рәкәев (47; уллары Габделхәер, Габделвәли) хуҗалыклары (6 ир-ат) керә[135].

XIX гасыр башына караган чыганаклар авыллар үсешендәге кайбер үзгәрешләрне чагылдыра. Түбәндә аларның кайберләренә тукталып үтәбез.

1816 елда [Зур] Сукаешта 206 ир-ат (56 хуҗалык) исәпләнә. Төп халыкны типтәр сословиесендәге татарлар (141 ир-ат) тәшкил итә. Алар оброк түләмичә һәм килешү төземичә килеп утырганнар (чыганакта «*припушенные*

---

[132] Шунда ук, 24 сакл. бер., 390–392 б. а.

[133] Шунда ук, 23 сакл. бер., 144–146 б.

[134] Шунда ук, 24 сакл. бер., 394–394 б. а. Бу чыганакта авылның исеме ялгыш Чакмак дип язылган. Әлеге хата 1811 елгы ревизия документында төзәтелә (84 сакл. бер., 499 б.).

[135] Шунда ук, 84 сакл. бер., 125 б.

*безоброчно и без документов*»). Ясаклы татарлар (56 ир-ат) күпкә кимрәк була[136]. Шул чоргы чыганакта авыл ул Югары Сукаеш елгасының сул ягына урнашкан дип күрсәтелә. Сукаеш елгасында типтәр Мансур Гапсәламов тегермән тота.

Ревизия документы бу мәгълүматны тулыландыра төшә. Исемлектә Габделнәфыйкъ Габдерәхимов командасына караган типтәр сословиесендәге 141 ир-ат һәм 120 хатын-кыз (53 хуҗалык) теркәлгән. Болардан Сәйфулла Сәфәров (51 яшь), Мөхәммәтрәхим Морадымов (27), Габделкәрим Мансуров (65), Биктимер Зәммәтов (40), Вәлит Качкынов (54) икешәр хатын белән яшәгәннәр[137].

Лашман бурычын башкаручы (чыганакта «исправляющие лашманную повинность») ясаклы татарлар 1816 елда 56 ир-ат һәм 61 хатын-кыз (19 хуҗалык) тәшкил итә. Болар Бикмөхәммәт Уразаев (46 яшь; 4 хатынлы), Габделҗәлил (62), Сәйфелмөлек (41), Мөхәммәтрәхим (36) Юмаголовлар, Миңлекәй (45) һәм Хөсәен (37) Исмәгыйловлар, Юлдаш Йосыпов (57), Сәгыйть Сәгыйтов (45), Токтамыш (43), Йортбагыш (40) Үтәмешовлар, Миңлегол (44), Исламгол (43) Аднаголовлар, Мансур Мәксүтов (65), Низаметдин Хәмитов (43), Ихсан (1745–1812), Ибнеәмин (65) Ишмәтовлар, Габделлатиф Габдрәхимов (31), Габделфәез Габитов (31), Биктимер Исмәгыйлов (43) һәм Рәхмәтулла Үзбәковлар (32) була[138].

Түбән Сукаешта 1816 елда 74 ир-ат (25 хуҗалык) исәпләнә. Халыкның күпчелеген типтәр сословиесендәге татарлар (61 ир-ат) тәшкил итә. Болардан 23 ир-ат монда исәпләнсә дә, Әгерҗедә яши. Ясаклы татарлар нибары 13 ираттан тора[139]. Бу чорга моннан 7 ясаклы татар хуҗалыгы Әгерҗе авылына күчеп утыра. Авыл Түбән Сукаеш елгасының ике ягында урнашкан, анда агачтан салынган мәчет була. Монда 4 су тегермәне эшли. Беренчесе – Бикмәмәт Уразаев, икенчесе – Нәҗметдин Хәмитов, өченчесе – Туктамыш Үтәмешов, дүртенчесе М. Якуповның милке санала. Соңгысы – типтәр, калган өчесе ясаклы татар сословиесендә.

Ясаклы татарлар 1816 елгы ревизия документында 36 ир-ат һәм 31 хатын-кыз (15 хуҗалык) күрсәтелә. Болар исәбенә Габдулла Габбәсов (1769–1812), Котлыяр Мәһдиев (51), Гобәйдулла Котлыяров (28), Котлымөхәммәт Мәһдиев (48), Гыйззәтулла Котлымөхәммәтов (25), Фәйзулла Мәһдиев (43), Әмин (55), Рәхмәтулла (43), Рәфикъ (38) Биктимеровлар, Ишмөхәммәт Ярмөхәммәтов (48), Гобәйдулла Аптикәев (48), Вәлит Нигъмәтуллин (32),

[136] Шунда ук, И–1 фонд, 1 тасв., 450, 128 б.

[137] БР МА, И–138. 2 тасв., 168 сакл. бер., 608–621.

[138] Шунда ук, 197 сакл. бер., 257–265 б.

[139] Шунда ук, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 128 б. Ясаклы татарларның бу чыганакта күпкә аз күрсәтелүе, аларның башка авылга күчеп китүе белән бәйле. Бер чыганакта 7 ясаклы татар хуҗалыгының Әгерҗе авылына күчеп утыруы турында әйтелә.

Төхвәтулла Даутов (43), Хәсән (69) һәм Хөсәен (57) Рәфиковлар хуҗалыклары керә. Алар Кәкре Елга волостена карый һәм лашман бурычын башкара (чыганакта «исправляли лашманную повинность»)[140].

Банки Сукаешта 1816 елда 95 ир-ат (23 хуҗалык) яши. Күпчелекне типтәр сословиесендәге татарлар (85 ир-ат) тәшкил итә. Алар оброк түләмичә һәм килешү төземичә килеп утырганнар (чыганакта «*припушенные безоброчно и без документов*»). Ясаклы татарлар (10 ир-ат) сан ягыннан бик аз була[141]. Авыл Түбән Сукаеш елгасы буенда, ике яклап урнашкан. Анда агачтан салынган мәчет эшли.

Банки Сукаешның 1816 елгы ревизия исемлегендә Габделнәфыйкъ Габдерәхимов командасында торучы типтәр сословиесендәге 82 ир-ат һәм 74 хатын-кыз (32 хуҗалык) теркәлгән. Исемлектә Сәфәргали Габделваһапов (48), Миңлебай Биктимеров (1745–1812) һәм башкаларның хуҗалыклары күрсәтелә[142]. Күренгәнчә, беренче чыганак 1816 елдан соң кайбер үзгәрешләрне искә алган, шуңа күрә ир-атлар саны тәңгәл килми, ә хуҗалыклар саны кимрәк. Шуңа күрә белешмәләр төзегәндә төгәллек хас беренчел чыганакка (ревизия исемлекләренә) таянырга кирәк.

Банки Сукаешта ясаклы татарлар (10 ир-ат һәм 9 хатын-кыз; 5 хуҗалык) 1816 елда Муса Миңлебаев (42; улы Галиакбәр), Габдерәшит Мөслимов (71; улы Габделгази (аныкы Хәйбрахман)), Габделвәли Хәкимов (25: улы Габделгафур), Гаделша Хәкимов (18; аның туганы Габделлатиф), Габделкәрим Хәкимов (10) хуҗалыкларыннан тора. Алар Кәкре Елга волостена карый һәм лашман бурычын башкара (чыганакта «исправляли лашманную повинность»)[143].

Авылларның көнкүрешенә кагылышлы башка мәгълүматларга тукталыйк. Игенчелек һәм терлекчелек – халыкның төп шөгыле. Хатын-кызлар кыр эшләреннән буш вакытта йоннан, киндер басаларыннан җеп эрләгәннәр, киндер сукканнар һәм тукыма тукыганнар. Типтәр сословиесендәге ир-атлар Оренбург шәһәрендәге ике мең атлы типтәр полкына чират буенча хәрби хезмәткә алынганнар, полк чыгымнарын түләргә мәҗбүр ителгәннәр. Ясаклы татарлар казнага оклад (салым) түләгәннәр.

XIX гасыр уртасына авыллар зурая. 1859 елда Зур Сукаешта типтәр һәм башкорт сословиеләрендәге татарлар 316 ир-ат һәм 315 хатын-кыз (51 хуҗалык; Гобәйдулла (68) һәм Идрис (54) Сәйфуллиннар һәм башкалар) исәпләнә. Сословиенең соңгысына 4 ир-ат һәм 3 хатын-кыздан торган Төхфәтулла Рәхмәтуллин (35 яшь) гаиләсе карый. Ул чыгышы буенча Бәләбәй өязенең Муллино авылыннан, «Башкорт» гаскәренең 1859 елның 14 мар-

[140] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 197 сакл. бер., 318–324 б.
[141] Шунда ук, И–1 фонд, 1 тасв, 450 сакл. бер., 128 б.
[142] Шунда ук, И–138, 2 тасв., 168 сакл. бер., 376–385 б.
[143] Шунда ук, 197 сакл. бер., 346–348 б.

тында булган боерыгы нигезендә монда теркәлә. Ревизия алдыннан Кәкре Елгадан типтәр сословиесендәге татар Хәбибулла Корбангалиев (42) гаиләсе килеп утыра. Болар барысы «типтәрдән башкорт» (чыганакта «башкиры из тептярей» дип язылган), 23 нче кантонның 6 нчы юртасына карый[144].

Типтәр сословиесендәге татарларның 1855 елдан «башкорт» булып китүен Самара губернасы белешмә әдәбияты да раслый. 1859 елда Сукаеш елгасы буендагы Зур Сукаеш авылында 424 ир-ат һәм 472 хатын-кыз (189 хуҗалык) казна крестьяннары һәм «башкорт»лар теркәлә[145].

Түбән Сукаешта 1859 елда типтәр сословиесендәге татарлар 119 ир-ат һәм 151 хатын-кыз (18 хуҗалык; Юныс Сәйфетдинов, Габделмән Габделмәннафов, Мөхәммәтгәрәй Габделгафаров, Шәгәюп Әюпов, Рахманкол Ягъфәров, Ибраһим Биктимеров, Габделвахит Халитов, Тимербулат Ибниәминов һәм башкалар) тәшкил итә. Исемлек ахырында 1859 елда Чалпыдан күчкән ике хатынлы Гобәйдулла Мәҗитов гаиләсе теркәлгән. Барлык халык «типтәрдән башкорт» (чыганакта «башкиры из тептярей»)[146] дип язылган, чөнки 1855 елдан «Башкорт» гаскәрендә тора.

Типтәр сословиесендәге татарларның 1855 елдан «башкорт» дип языла башлавы Самара губернасы белешмә әдәбиятенда да чагыла. Аның мәгълүматы буенча, 1859 елда Ташкичү елгасы буендагы Түбән Сукаешта 139 ир-ат һәм 160 хатын-кыз (48 хуҗалык) казна крестьяннары һәм «башкорт»лар була[147]. Монда казна (дәүләт) крестьяннары дип элеккеге ясаклы татарлар аталган.

Банки Сукаешта 1859 елда 145 ир-ат һәм 159 хатын-кыз (30 хуҗалык) типтәр һәм башкорт сословиеләрендәге татарлар теркәлә. Беренчеләре «типтәрдән башкортка» (чыганакта «башкиры из тептярей»; Хисмәтулла Миңлеголов (44), Габделлатиф Габделгазин (52), Шаһиәхмәт Ишмөхәммәтов (52), Рәхмәтулла Азнакаев (1780–1857), Сатлыган Туркаев (46), Хәлилулла Хәмидуллин (37), Ишбирде Ишбулдин (39) һәм башкалар) әйләнгән. Шәрифулла Биктаһиров Оренбург казна палатасының 1850 елның 2 сентябрендәге указы нигезендә – Сәпәйгә, указный мулла Фәррухша Ишмурзин шундый указ (1859 ел, 14 март) нигезендә Күктәкәгә күчә. Башкорт сословиесенә 8 ир-ат һәм 9 хатын-кыздан торган Фәйзулла Хәкимов (72; указлы мулла) гаиләсе карый. Ул чыгышы буенча Бөгелмә өязенең Урсай авылыннан, «Башкорт» гаскәренең 1859 елның 14 мартында булган боерыгы нигезендә монда теркәлә[148].

---

[144] Шунда ук, И–138, 2 тасв., 757д. сакл. бер., 1–23 б.

[145] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. г. С. 23.

[146] БР МА, И–138, 2 тасв., 757д. сакл. бер., 25–38 б.

[147] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

[148] БР МА, И–138, 2 тасв., 757д. сакл. бер., 39–51 б.

Типтәр сословиесендәге татарларның 1855 елдан «башкорт» дип языла башлавын Самара губернасы белешмә әдәбиятенда да күрәбез. Аның мәгълүматы буенча, 1859 елда Әгер елгасы буендагы Банки Сукаешта 123 ир-ат һәм 121 хатын-кыз (50 хуҗалык) казна крестьяннары һәм «башкорт»лар була[149]. Монда казна (дәүләт) крестьяннары дип элеккеге ясаклы татарлар аталган. Әмма бу статистика гомуми халык санын төгәл яктырта дип әйтеп булмый. Алдарак 1859 елгы ревизия мәгълүматы буенча 145 ир-ат һәм 159 хатын-кыз яшәвен күрдек, моңа казна крестьяннарын да кушсак, халык саны тагын да күбрәк чыга.

XIX гасырның икенче яртысында Зур Сукаешның җәмигъ мәчетендә имам һәм мөгаллим хезмәтен Рәхмәтулла Фәтхуллин үти (1836 елның 18 декабрендәге указ белән расланган). Бу вакытта мәхәлләдә 424 ир-ат һәм 472 хатын-кыз исәпләнә.

Түбән Сукаешның бишвакытлы мәчетендә бу чорда мулла булмый, әлеге вазифаны Әгердән килеп Җәләлетдин Сәйфетдинов башкара. Монда 162 ир-ат һәм 172 хатын-кыз күрсәтелә.

Банки Сукаешның җәмигъ мәчетендә имам һәм мөгаллим вазифасын Камалетдин Фәйзуллин башкара. Әлеге вазифага ул 1853 елның 18 сентябрендә раслана. Авылда 155 ир-ат һәм 159 хатын-кыз була[150].

XVIII гасырның сиксәненче-туксанынчы елларында Зур Сукаеш ике мәхәлләдән тора. Беренче мәхәлләдә 359 ир-ат һәм 326 хатын-кыз була. Монда 1888 елның 28 июлендә расланган Шаһимәйлүн Габделмәннанов муллалык итә. Мөәзин вазифасын 1887 елдан Фәттахетдин Хәбибуллин башкара.

Икенче мәхәллә бу чорда 406 ир-ат һәм 382 хатын-кыздан тора. Монда озак еллар (1897 елдан алып 1919 елда вафат булганга кадәр) мулла вазыйфасын Тәкыйулла Сибгатуллин башкара. Ул тумышы белән Минзәлә өязенең Татар Суыксуы авылыннан (хәзерге вакытта бу авыл Актаныш районына керә) була. Мөәзин булып шулай ук озак вакыт (1871 елда расланган, 1905 елда вафат) Лотфулла Рәхмәтуллин тора[151].

Гасыр ахырына авыллар шактый зурая. 1897 елда Зур Сукаешта 272 хуҗалык, 674 ир-ат һәм 706 хатын-кыз исәпләнә. Авылның барлык биләмәләре 3426 дисәтинә тәшкил итә. Банки Сукаешта 84 йортта 208 ир-ат һәм 218 хатын-кыз яши. Алар 1250 дисәтинә җирдән файдаланалар. Түбән Сукаешта (ул «Малый Сукаеш» дип тә күрсәтелә) 79 хуҗалык, 185 хатын-кыз һәм 197 ир-ат була. Монда җир азрак – 1000 дисәтинә[152].

---

[149] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

[150] БР МА, И–295 фонд, 3 тасв., 5662 сакл. бер., 6, 11 б.

[151] Шунда ук, 2 тасв., 3 сакл. бер., 131 б. а.–132 б.; ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 782 сакл. бер.

[152] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 154.

Волость идарәсе Сарлыда урнашкан, ул 277 хуҗалыктан торган ике мәчетле авыл була. Икешәр мәчетле авыллар исәбенә тагын Югары Стәрлетамак, Түбән Стәрлетамак һәм Зур Сукаеш керә.

Стәрлетамак волостенда, югарыда күрсәтелгән авыллардан тыш, тагын 6 хутор була. Шуларның берсе хакында әйтеп үтик (калган хуторлар турында мәгълүматлар Үчәлле тарихында бирелә).

Зур хуторның (520,30 дис.) хуҗасы булып озак вакыт Зур Сукаеш кешесе Габделмәннаф (икенче чыганакта – Габделмәннан) Яркәев тора. 1897 елда биләмәсе варислары арасында бүленә. Уллары Кашшафетдин – 160,8 дисәтинә, Габделханнан – 158,5 дисәтинә, Шаһимәрдан (?) 134,8 дисәтинә җир хуҗасына әйләнә. Өчесе дә Зур Сукаешта яши[153].

1900 елда Зур Сукаешта 221 – типтәр, 71 ясаклы татар хуҗалыгы була. 10 нчы ревизиядән (1859 ел) соң ук җир «типтәр»ләрдә – 325, ясаклы татарларда 160 иманага бүленгән була, шуннан бирле иманалар саны үзгәрешсез кала.

Иманалар саны кайбер хуҗалыкларда өчтән алып алтыга кадәр булса, күпләрендә бер-икедән артмый. Имана күп булу, әлбәттә, кайбер өстенлекләр биргән: игенче, теләсә, чәчкән, я булмаса икенче берәүгә арендага бирә алган. Иманасы аз булып та, кайбер хуҗалыкларның зур гына мәйданда чәчүлекләре булу шуның белән аңлатыла.

Зур Сукаешта 10 дисәтинәдән артык мәйданда иген игүче хуҗалыкларны күрсәтеп үтик. «Типтәр»ләр арасында болар – Кашшафетдин Габделмәннанов (40,55 дисәтинә), Мөхәммәди Габдерәфиков (25,73), Габделханнан Габделмәннан улы Яркәев (19,57), Гыймадетдин Мифтахетдинов (16,89), Галәветдин Идрисов (16,16), Хөснулла Зәйнуллин (15,28), Мөхәммәтҗан Мөхәммәтрәхимов (13,44), Миңлехан Нигъмәтуллин (13,30), Шәйдулла Шәрифуллин (12,95), Садретдин Әюпов (12,76 дис.), Фәхретдин Мифтахетдинов (12,76), Фәттахетдин хәзрәт Хәбибуллин (12,23), Исмәгыйль Әфәндиев (12,20), Шәйхелислам Әфәндиев (11,90), Хөснетдин Бикмурзин (11,41), Хаҗиәхмәт Равилов (11,40), Кашшафетдин Җәләлетдинов (11,37), Әхмәтвәли Гобәйдуллин (11,24), Мөхәммәтҗан Дәүләтшин (10,71), Миргалим Габделгалимов (10,68), Фәйруша Хөррәмшин (10,47), Шаһимәйлүн Габделмәннан улы Яркәев (10,36), Шәрифулла Шәмсетдинов (10,26), Заһидулла Гыйззәтуллин (10,15), Әһлиулла Шәйдуллин (10,05). Ясаклы татарлар арасында зур мәйданда иген игүчеләр булып Йосыф Сәйфелмөлеков (48,48), Әхмәтша Мөхәммәтҗанов (28,76), Габдулла Якупов (18,14), Мөхәммәтша Корбангалиевлар (16,36) тора.

Югарыда күрсәтелгән хуҗалыклар таза, бай тормышлылар рәтенә керә. Алар өчен игенчелек – муллыкның төп чыганагы. Күпләренең иманалары аз

[153] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 798, 799 сакл. бер.; Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 153–154.

була, әмма арендага алу исәбенә алар чәчүлек мәйданнарын шактый киңәйтә алганнар. Бер-ике мисал китереп үтик. Мөхәммәди Габдерәфиковның (аңа 50 яшь) үз иманасы бер ярым тәшкил итә. Анда гына чәчсә, аның нибары 2,44 дисәтинә игене булыр иде. Әмма игенче үз авылдашларыннан – 18,29, читтән 5,00 дисәтинә арендага алып, гомуми чәчүлек мәйданын 25,73 дисәтинәгә җиткергән. Уңышның бер өлеше аренда хакын түләүгә китсә, калган өлеше үз ихтыяҗларына һәм сату өчен тотылган. Хуҗаның 5 эш аты, 6 сыеры, 20 сарыгы һәм башка маллары була. Ул 2 хатыны (25 һәм 45 яшьләрдә) һәм 2 кызы (12 һәм 15) белән гомер кичерә.

Кашшафетдин Габделмәннановның (40) исә иманасы бөтенләй бул-мый. Үз авылдашларыннан – 33,05, читтән 7,50 дисәтинә җирне арендага алып, барлыгы 40,55 дисәтинә мәйданда иген игә. Аның 11 эш аты, 10 сыеры, 25 сарыгы һәм башка маллары була. Ул алдарак әйтеп үтелгән хутор хуҗасы Габделмәннаф Яркәевнең уртанчы улы булса кирәк. Димәк, аның Зур Сукаештта иманасы булмаса да, авылдан читтәрәк зур гына шәхси җир биләмәсе була.

Бай һәм урта хәлле хуҗалыклар белән беррәттән, Зур Сукаештта ярлы хуҗалыклар да шактый күзәтелә. Аларның чәчүлекләре 3 дисәтинәгә чаклы була. Болар көнлекчелеккә йөриләр, ара-тирә авылдан читкә чыгып, еракларга барып акча эшләп кайталар. Шунсына игътибар итик, ярлы хуҗалыклар арасында 3 иманасы булган хуҗалыклар да була. Димәк, алар үз иманаларын арендага биреп, аз иген игүне кулай күргәннәр. Билгеле, арендадан кергән акча әлләни күп түгел, ул төрле салымнарны түләргә дә җитмәгән, ә менә үз басуларында мул уңыш үстереп, аны сатса, отыш күбрәк булыр иде.

Зур Сукаештта Гыйлаҗетдин Бикташев, Мөшәрраф Бикташев (65 яшь), Шәрәфетдин Бикташев (45), Гәрәйша Исмәгыйлов (60), Мөхәммәтшәрип Мөхәммәткәримов (68), Муса Мөхәммәтрәхимов (72), Хәкимулла Сафиуллин (60), Сәгъдетдин Туктаголов (41), Әхмәтша Исмәгыйлевның 2 улы – балта остасы, Һади Габдрахманов (28) – тегүче, Гыйззәтулла Латыйпов (55), Габделвәли Хәлиуллин (31) – итекче, Габделихсан Габдуллин (61) улы белән мич чыгаручы (ул шулай ук балта остасы да) буларак билгеле. Рус кешесе Андрей Конкин (32) тимерче булып эшләгән. Шакир Хәбибрахманов (40) авылдашлары арасында берничә төр һөнәр (тегүче, балта остасы, итек тегүче) иясе булуы белән аерылып тора. Камалетдин Хәбибуллин (52) калач пешереп саткан. Баһаутдин Шәрәфетдинов (44) кыш айларында үз аты белән базарларга байларның икмәген ташый торган булган. Авылда агач яру, кисү белән бәйле эшләр белән шөгыльләнүчеләр күп була. Болар арасында Гыйззәтулла Рәхмәтуллин (33), Шаһимәрдан Ярмөхәммәтовларны (31) күрәбез. Йосыф Сәйфелмөлеков (62) – 7, Мөхәммәтгәрәй Хәбибрахманов (56) 3 баш умарта тоталар.

Шунысы күзгә ташлана, Зур Сукаештта бу чорда 14 типтәр хуҗалыгы авылда яшәми, алар бәхет эзләп читкә, Оренбург губернасына чыгып киткәннәр. Болар арасында авылдан 10–15 ел элек чыгып киткәннәре дә

(мәсәлән, Шакиргәрәй Сәйфуллин, Гали Нәфыйков, Миңлегали Сафагалиев), күптән түгел генә кузгалганнары (Хаҗи Ахунҗанов, Хәйрулла Нәфыйков) да була. Нигездә, алар Троицк шәһәрендә эшкә урнашканнар. Әлеге шәһәр, мәгълүм ки, ул чакта алтын приискалары белән дан казанган.

Банки Сукаешта бу чорда 6 – ясаклы татар, күпчелеге (80) типтәр хуҗалыклары була. Болар арасыннан Фәсхетдин Хөснетдинов (чәчүлекләре 26,25 дисәтинә), Гәрәйша Хөррәмшин (24,41), Гарифулла Бәшәров (20,13), Сәгъдетдин Габидуллин (19,12), Идрис хәзрәт Җәләлетдинов (16,58), Зарип Сәгъдетдинов (16,00), Хәбибулла Исмәгыйлов (15,74), Хафиз Бакыев (15,63), Хәлиулла Гобәйдуллин (15,34), Мортаза Мөстәкыймов (14,27), Гобәйдулла (?) Исмәгыйлов (13,75), Әхмәдиша Хөррәмшин (13,24), Хуҗа Бакыев (13,15), Хәйрулла Зөлмөхәммәтов (12,92), Гыйззәтулла Бәшәров (12,74), Тәхаутдин Сәгъдетдинов (12,02), Динмөхәммәт Хисмәтуллин (11,71), Шәрифулла Салтыганов (11,65), Сафиулла Салтыганов (11,20), Ризван Гыйрфанов (11,04), мөәзин Кашшафетдин Садретдинов (10,62), Габдерәфикъ Насыйров (10,04) кебек хуҗалыкларның күбесе бай, таза тормышлы санала. Зарип һәм Әхмәтсафа Сәгъдетдиновлар – Мамадыш шәһәреннән, Исрафил Габдерәхимов Әгер авылыннан күчеп килгәннәр.

Зур Сукаештагы кебек, монда да төрле һөнәр ияләре күп була. Галим Ганиев (аңа 46 яшь), Сираҗетдин Гыймадетдинов (46), Фәйзулла Салтыганов (45), Мифтахетдин Шәрәфетдиновлар (44) – балта остасы, Шәрифулла Салтыганов (57) – тәгәрмәчләр ясаучы, Исхак Хаснуллин (25) – ташчы, Бәдигъ Исмәгыйлов (25) – тимерче һәм Фазулла Дәүләтгәрәев (30), Нигъмәтулла Сафиуллиннар (41) тегүче буларак билгеле. Югарыда күрсәтелгән Ф. Дәүләтгәрәев тегү машинасы сатып алган (ул башка кешеләрдә булмый). Гарифулла Гыйбадуллин (50) кыш айларында көл җыеп, аны Носовның заводына илтеп сата торган булган. Кайбер хуҗалыклар (Хәлиулла Гобәйдуллин, Хәбибулла Исмәгыйлов, Хафиз Бакыев, Хуҗа Бакыев, Хәбибулла һәм Шәрифулла Хәйруллиннар) кыш айларында үз атлары белән төрле йөк (мәсәлән, икмәк) ташып шактый акча эшләгәннәр. Хәйрулла Зөлмөхәммәтов (53) Зур Сукаешта урман каравылчысы булып хезмәт иткән. Габдерәфикъ Нәфыйков (54) Чәкән һәм Сәпәй базарларыннан күпләп икмәк сатып алып, аны башка җирләргә отышлырак хакка сату белән шөгыльләнгән.

1903 елда Түбән Сукаешта земство карамагындагы мәктәп ачыла, монда 1909 елдан авыл балаларын русча укырга-язарга өйрәтә башлыйлар. Укытучылар Екатерина Тавянская һәм Михаил Шашкин була. Укучыда, каян килгәннәр бу укытучылар, дигән сорау туарга мөмкин. Полковник Тавянскийның авыл янында 450 дисәтинә җирне биләгән хуторы булган. Екатерина, димәк, шул нәселгә карый. М. Шашкинны, күрәсең, монда земство җибәргән.

1905–1907 елгы рус-япон сугышына, истәлекләргә караганда, бик күп ир-атлар китә. Сукаештан исән-имин кайтучылар арасында Гыйльфанов

Җиһангир, Шәрифуллин Фәрхетдин, Мусин Сәлимгәрәй, Габдерәфиков Хәбибулла, Йосыпов Мирхәйдәр, Мөхәммәтшин Дәүләтша, Галиев Мостафа, Әхмәдиев Җиһанша, Әхмәтҗанов Илъяслар була.

1910 елгы статистик әдәбият Зур Сукаешта 321 хуҗалык, 780 ир-ат һәм 764 хатын-кыз күрсәтә. Авылның 3076 дисәтинә – уңайлы, 350 дисәтинә уңайлы булмаган имана җирләре, 2 тегермәне була. Банки Сукаешта 105 хуҗалыкта 283 ир-ат һәм 267 хатын-кыз яши. Аларга 1027 дисәтинә – уңайлы, 223 дисәтинә уңайлы булмаган имана туры килә. Түбән Сукаеш авылы кечерәк, монда 93 йортта 271 ир-ат һәм 247 хатын-кыз яши. Барлык имана 1000 дисәтинә тәшкил итә[154].

Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан мәчетләргә хезмәткә кайбер яңа кешеләр дә килә. Аерым алганда, Зур Сукаешның беренче мәхәлләсендә мулла вазифасын 1911 елның җәеннән Мөхәммәтхарис Мөхәммәтсабитов үтәргә керешә. Икенче мәхәлләдә мөәзин булып 1906 елда расланган Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтшәрипов тора.

Банки Сукаешның 1883 елда салынган җәмигъ мәчетендә Миңлеәхмәт Идрисов имам һәм мөгаллим вазифасын башкара. Ул 1877 елның 27 декабрендә туган, Самара губерна идарәсе тарафыннан 1902 елның 16 июлендә расланган. Мөәзин һәм мөгаллим хезмәтен 1898 елның 30 сентябреннан Кашшафетдин Садретдин улы Ярмәков үти. Ул үзе Сәпәй авылыннан, Миңлеәхмәт хәзрәттән өч яшькә олырак була[155].

Түбән Сукаештагы җәмигъ мәчеттә бу вакытта имам-хатыйп һәм мөгаллим булып Гаязетдин Миңлегазетдинов тора. 1867 елның 15 июлендә туган, Самара губерна идарәсе тарафыннан 1901 елның 12 сентябрендә расланган. Мөәзин һәм мөгаллим хезмәте Габделгазиз Габделханнановка йөкләнгән. Ул Гаязетдин хәзрәттән ике яшькә олырак, мөәзин вазифасына да аннан алдарак, ягъни 1891 елда ук билгеләнгән[156].

Сугыш башланды дигән хәбәр авылларны хафага сала. Озак та үтми, Зур Сукаешка волостьтан вәкил килеп, беренче мобилизацияләнүчеләр исемлеген укый. 1914–1915 елларда авылдан бер-бер артлы 77 кеше сугышка алына (архивтан әлеге кешеләрнең исемнәре теркәлгән документ таптык). Исемлек зур, шуңа карамастан, бу кешеләрнең һәрберсен күрсәтеп үтми мөмкин түгел, чөнки анда – бүгенге авыл кешеләренең бабалары. Болар – Әхмәтхаҗи Әхмәдиев, Миргалим Бикмөхәммәтов, Әхмәтгали Габделхаликов, Миңлехәйдәр Гыйззәтуллин, Әхмәтзакир Габделгалимов, Җиһангир Гыйрфанов, Шәйхеразый Җәләлетдинов, Хөҗҗәтелислам Идиятуллин, Солтангәрәй Исрафилов, Сәлимгәрәй Фәрухшин, Мирхәйдәр Йосыпов, Миргасыйм Хәмидуллин, Мөхәммәтҗан Гәрәйшин, Афзалетдин Сәйфуллин, Нәүширван Риз-

---

[154] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1910. С. 124.
[155] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 782 сакл. бер.
[156] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер.

ванов, Миңлегасыйм Хәлиуллин, Әхияр Габделгаффаров, Миңлехаҗи Шәрәфетдинов, Хәбибулла Шәрифуллин, Сәхабетдин Хөснетдинов, Шиһабетдин Идиятуллин, Фәхразый Җәләлетдинов, Хәлиулла Хөснуллин, Мөхәммәтзарип Мөхәммәтшәрипов, Миңлехарис Габдрахманов, Шәйхеразый Гыйрфанов, Нуриәхмәт Гәрәйшин, Миргалим Гәрәйшин, Шаһиәгъзәм Кәлимуллин, Бәдретдин Фәрхетдинов, Миңлехан Габделганиев, Гыйлаҗетдин Мөхәммәтшин, Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтгарифов, Мөхәммәтһади Әхмәдиев, Әгъләүтдин Габдрахманов, Фәрхетдин Шәрифуллин, Шәфыйгулла Әһлиуллин, Җиһанша Әхмәдишин, Миңлегали Муллагәрәев, Хәбибулла Габдерәфиков, Шәмсетдин Гыйлаҗетдинов, Габдулла Нигъмәтуллин, Хәйдәр Сәүбанов, Әхмәтҗан Мөхәммәтҗанов, Ибраһим Миңлебаев, Гыйззәтулла Шәрәфетдинов, Мөхәммәтзарип Шакиров, Миңлесалих Гыйниятуллин, Миңлегариф Мөхәммәтшәрипов, Габдрахман Габделханнанов, Мөхәммәтхан Габделмәннанов, Газизулла Гыйздуллин (?), Зарип Якупов, Мөхсин Камалетдинов, Кашшафетдин Камалетдинов, Мәүләветдин Шәрәфетдинов, Габделкадыйр Илъясов, Кашшафетдин Гыймазетдинов, Хөсәен Мөхәммәтдәминов, Мөхәммәтзакир Мөхәммәтгарипов, Шәмсимөхәммәт Гәрәйшин, Мөхәммәткәрим Мөхәммәдиев, Мөхәммәтзәки Ногманов, Кашшафетдин Идиятуллин, Зыятдин Гыйрфанов, Хәйретдин Фәрхетдинов, Мәрданша Җиһаншин, Фәрхетдин Мифтахетдинов, Сәхаутдин Сәйфуллин, Исламшәрип Зарифуллин, Харрас Хәсәншин, Миңлехарис Әһлиуллин, Әхмәтлатыйф Әхмәтвәлиев, Мирсаяф Гыйрфанов, Мөхлисулла Заһидуллин, Нигъмәтҗан Мөхәммәтҗанов һәм Ибнеәмин Гәрәев.

Әмма сугышка алынучылар саны моның белән генә чикләнми. 1915 елда төзелгән икенче исемлектә Зур Сукаештан тагын 32 кеше күрсәтелә. Бер башлагач боларын да атап китик: Закир Әюпов, Фәррахетдин Мифтахетдинов, Дәүләтша Мөхәммәтшин, Харис Әһлиуллин, Сәлимгәрәй Фәйрушин, Габдрахман Хәкимов, Харис Хәлиуллин, Сәетша Әхмәтшин, Мәүләветдин Низаметдинов, Гасыйм Хәлиуллин, Мөхәммәтҗан Мөхәммәтҗанов, Газый Мөхәммәтҗанов, Харис Якупов, Кашшафетдин Гыйзиятуллин, Садрислам Шакиров, Бәдретдин Фәрхетдинов, Хәбибулла Габдерәфиков, Габделхак Ханнанов, Хәйдәр Сәүганов (?), Мөхәммәтгәрәй Сәлимгәрәев, Сәйфулла Габдуллин, Гаделша Әхмәтшин, Габделхак Габдуллин, Шәйхевәли Ганиев, Габдулла Нигъмәтуллин, Лотфулла Хисмәтуллин, Габделханнан Мәннанов, Хәйретдин Фәрхетдинов, Шәйхеразый Гыйрфанов, Мирсәяф Гыйрфанов, Мәүләветдин Габдрахманов, Хөҗҗәт Гыймадетдинов.

Шулай итеп, 1916 елга чаклы Зур Сукаештан беренче бөтендөнья сугышына барлыгы 109 ир-ат алынганлыгы мәгълүм. Сугыш әле бетмәгән, калган чорда күпме кеше алынган соң? Күпме эзләп карасак та, кирәкле мәгълүматларны тапмадык. Шулай да, авылдан тагын йөзләп ир-атны корал тоттырып, патшаларның авантюрасында катнашырга мәҗбүр иткән булулары бик мөмкин. Чөнки сугыш җиле кагылмаган хуҗалык калмый ул чакта. Ә

күпме кеше һәлак булган? Бу хакта һәр төбәк буенча мәгълүмат туплап бару булмаган, аннары хәрбиләр «сер» саклаганнардыр, күрәсең. Бары аксакаллар сөйләве буенча гына чамаларга кала.

Калган авыллар буенча мәгълүматлар тагын да азрак. 1915 елның октябренда төзелгән исемлектә Банки Сукаештан 41 ир-ат (Гатаулла Гобәйдуллин, Асылгәрәй Дәүләтгәрәев, Бәдретдин Зөлмөхәммәтов, Нигъмәтулла Кәлимуллин, Исхак Мөхетдинов, Насыйбулла Сәйфуллин, Шиһабетдин Фәсхетдинов, Мөхәммәтдин Сәйфуллин, Галиулла Гарифуллин, Фәррахетдин Сәгъдетдинов, Гыйззәтулла Кәлимуллин, Гыйлаҗетдин Сираҗетдинов, Габделмәннан Габдерәфиков, Сәлахетдин Гайнетдинов, Мөхәммәтфатыйх Сабитов, Ишморза Мортазин, Мөхәммәтсабир Кашшафетдинов, Мөхәммәтзәки Габделбәдигов, Мөхәммәтфатих Мөхәммәтгатин, Әхмәтлатыйф Әхмәтшәрипов, Сибгатулла Гыйззәтуллин, Солтангали Мөхәммәтсадыйков, Шәйхетдин Фәсхетдинов, Зарифулла Хәбибуллин, Габдулла Гәрәйшин, Хисмәтулла Гарифуллин, Мөхәммәтша Мостафин, Гыйниятулла Гыйззәтуллин, Габдулла Фазуллин, Галиулла Зиннәтуллин, Мөхәммәдиша Хәсәншин, Габделхәким Миңлегалимов, Фәрхетдин Фәхретдинов, Миңлеәхмәт Мифтахетдинов, Садретдин Таҗетдинов, Габделмәннан Габделнәфыйков, Сәетгәрәй Сираҗетдинов, Галәүтдин Мөхетдинов, Мөхәммәтгариф Мөхәммәткәримов, Мөдәрис [...] Мөхәммәтов, Мәүләветдин Нигъмәтуллин) күрсәтелә. Тагын күпме булгандыр, моның очына чыгу мөмкин түгел.

Шул ук чорда (1915 елда) Түбән Сукаештан да 30 ир-ат сугыш яланнарында кан койган. Болар – Мәннан Ганиев, Хәбир Гыйльманов, Габдулла Габдерәфиков, Закир Игътисамов, Бәдретдин Җиһангиров, Хәйретдин Җиһангиров, Харис Галимов, Муллаян Гайнанов, Шиһабетдин Нәфыйков, Гыйззәтулла Сибгатуллин, Шакир Гыйльманов, Гарифулла Шәрифуллин, Миңлеәхмәт Фәхретдинов, Мөхәммәтгали Мөхәммәдьяров, Мөхәммәтгәрәй Вилданов, Гани Галимов, Сабир Абдуллин, Закир Зарипов, Илъяс Әхмәтҗанов, Исмәгыйль Әхмәтҗанов, Харрас Әхмәтгалимов, Сабур Хәлимов, Габделхак Кадыров, Әсхабетдин Җиһангиров, Сәлахетдин Шәйхетдинов, Хәсәнша Гәрәйшин, Гариф Зарипов, Миргазиян Хәйдәров, Гариф Садыйков һәм Гариф Галләмов[157].

Истәлекләргә караганда, рус-герман сугышыннан Шәрифуллин Фәрхетдин, Шәрәпов М., Шәрифулллин Хәбибулла, Фәрхетдинов Нурый, Калимуллин Шаһи һәм башка ир-атлар исән кайталар. Сугышка алынганнарның күпләренә кайту насыйп булмый.

Без икенче бөтендөнья сугышында һәлак булганнарны әледән-әле искә алабыз. Ә аңа чаклы сугышларда башларын салган татар ир-егетләрен хәтергә төшергәнебез бармы соң? Патшалар башлаган сугышларда кан койсалар да, алар безнең бабайлар, димәк, шундый ук игътибарга лаек.

[157] ТР ДА, 1124 фонд, 1 тасв., 28 сакл. бер.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында (1916 елда) хуҗалыклар санын алу үткәрелә. Зур Сукаешта 315 хуҗалык, 690 ир-ат һәм 791 хатын-кыз теркәлә. Соңгылары 101 кешегә күбрәк, чөнки шактый ир-ат сугышка алынган. Тире-як авылларда да шулай.

Банки Сукаешта бу вакытта 100 хуҗалыкта 219 ир-ат һәм 264 хатын-кыз яши. Бу исәпкә 11 рус (сугыш качагы) да керә. Түбән Сукаешта 86 хуҗалыкта 188 ир-ат һәм 246 хатын-кыз була.

1916 елда Стәрлетамак волостена югарыда күрсәтелгән авыллардан тыш, Сарлы (362 хуҗалык), Югары Стәрлетамак (319), Сөендек (219), Түбән Стәрлетамак (180), Әгер (179), Үчәлле (187) авыллары керә. Болардан тыш, волостьта тагын 4 имение (Майоровка, Зино-Мариинское, Горкино, Учаллинское) һәм 5 хутор (хуҗалары – Н.И. Дворников, М.И. Бүләков, Яркәевләр) була.

Банки Сукаешта гына түгел, башка авылларда һәм хутор-имениеләрдә дә качакларны һәм сугыш тоткыннарын күрергә мөмкин. Әгердә – 7, Сарлыда – 4, Югары Стәрлетамакта 1 качак, имениеләрдә – 9 качак һәм 11 сугыш тоткыны, хуторларда 3 качак яши.

Бу чорда да халыкның терлеге күп, игене мул була. Зур Сукаешта 596 ат (шул исәптән 481 эш аты), 649 мөгезле эре терлек (329 сыер), 1800 сарык һәм 265 кәҗә исәпләнә. Чәчүлекләр мәйданы 1428,6 дисәтинә тәшкил итә. Шуларның шактыен арыш (742,4 дисәтинә), калган өлешен солы (246,9), борай (121,25), бодай (154,5), карабодай (105,5), тары (52,8) һәм борчак (5,25) алып тора.

Чәчүлек мәйданының сугыш алды елларына караганда да зуррак булуын аренда мөнәсәбәтләренең киң колач алуы белән аңлатырга кирәк. Хуҗалыклар читтән генә арендага 847 дисәтинә җир алганнар. Халык саны арту шартларында да иманаларның күләме үзгәрмәү, шулай итеп, җирне күпләп читтән арендага алуга этәргән.

Банки Сукаеш халкы бу чорда 187 ат (шул исәптән 138 эш аты), 233 мөгезле эре терлек (109 сыер), 829 сарык, 94 кәҗә асрый. Барлык игеннәр 451,9 дисәтинә мәйданны били. Төп культуралар булып арыш (224,5 дисәтинә), солы (81,10), борай (67,10), карабодай (26,10), тары (18,30), борчак (18,30) һәм бодай (16,5) санала.

Түбән Сукаешта да мал-туар күп була. Бу исәпкә 137 ат (шул исәптән 122 эш аты), 153 мөгезле эре терлек (76 сыер), 494 сарык һәм 105 кәҗә керә. Басуларда арыш (176,5 дисәтинә), солы (73,9), борай (67,1), тары (26,75), карабодай (25,4), бодай (25,6) һәм борчак (9,6) игелә[158].

Түбән Сукаеш янында урнашкан имение «Майоровка» дип аталган. Аның хуҗасы дворян Георгий Михаил улы Товянский була. 1916 елны аның гаиләсе 2 ир-аттан (хуҗаның үзе белән) һәм 5 хатын-кыздан торган. Име-

[158] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 801 сакл. бер.

ниедә 9 ир-ат (шуларның алтысы – сугыш тоткыннары) һәм 9 хатын-кыз эшләгән.

Товянскийның хуҗалыгы зур була. Ул 28 ат (шуларның ундүрте – эш аты), 24 мөгезле эре терлек, йөзләп сарык асрый. Аның барлык чәчүлекләре 120,5 дисәтинә мәйданны алып торган. Болар исәбенә арыш (73 дисәтинә), солы (25), бодай (14), җитен (4), тары (3) һәм бәрәңге (1,5) чәчүлекләре керә.

Ул чорда уңыш күпме булган соң? Шул ук Тавянскийның 1914–1915 хуҗалык елында чәчүлекләре 103 дисәтинә була. Арышны ул 49 дисәтинә мәйданда чәчә. Симәнәгә 343 пот тота, көз көне 3900 пот уңыш (ягъни 11,4 тапкыр күбрәк) җыеп ала. Бер дисәтинәгә (дисәтинә = 1,09 га) 79,59 пот уңыш (1273,44 кг) туры килә. Мондый күрсәткечне начар дип булмый.

Бодай 26 дисәтинә мәйданда чәчелә. 156 пот симәнә китә, барлык уңыш 1500 пот тәшкил итә. Тагын 16 дисәтинә басудан 600 пот карабодай уңышы җыеп алына. Симәнәгә 80 пот киткән. Тары нибары 3 дисәтинә мәйданда чәчелә, 3 пот симәнәдән 100 пот уңыш алына. Җитен басулары 8 дисәтинә булган. 24 пот симәнәгә 500 пот уңыш туры килә. Бәрәңге 1 дисәтинә мәйданда игелә, яз көне симәнәгә 24 пот тотсалар, көз егерме тапкырдан күбрәк (500 пот) уңыш җыеп алалар[159].

Түбән Сукаеш кешеләре Тавянскийның яткын басуларын сыер-бозау көтүләрен йөртү өчен апрель-сентябрь айларына арендага ала торган булганнар. Моның өчен һәр баш малдан 60 тиен түләгәннәр. Көтүче Тавянскийның үзенеке була.

Земство карамагындагы мәктәп турында әйтеп үтелгән иде. Татарстан дәүләт архивында саклануч документ бу уку йорты турында өстәмә мәгълүмат бирә. Аннан күренгәнчә, 1916 елның 20 мартында Түбән Сукаеш кешеләренең җыены (чыганакта «сход») була. Староста Әхмәдиша Игътисамов катнашлыгында ир-ат һәм хатын-кыз татар училищеларының һәм рус-татар классының попечительләре сайлана. Мулла Газизула Фәхретдинов – рәис, Шәймөхәммәт Шәвәлиев – кассир, Әгъләметдин Хәкимов – әгъза, Гариф Тимербулатов сәркәтип итеп сайлана[160].

1918 елда Сукаешта авыл советы төзелә, аның беренче рәисе Хәбибулла Кәлимуллин була.

Зур Сукаешның икенче мәхәлләсендә 1920 елның 10 июнендә имам итеп М. Тәкыйуллин раслана. Башка мәхәлләләрдә бу вакытта элек сайланган дин әһелләрен күрәбез.

1921 елда Сукаешта беренче совет мәктәбе оеша. Истәлекләргә караганда, беренче укытучы Зыя хәлфә була. Мәктәп ул чакта Мөхәммәди бай йортында урнаша.

[159] Шунда ук, 800 сакл. бер.

[160] ТР ДА, 231 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер.

1920 елда халык санын алганда Зур Сукаешта 359 йортта – 1586, Банки Сукаешта 104 йортта – 439, Түбән Сукаешта 94 йортта 444 кеше яши. Авылларның соңгысында 25 рус кешесе дә була. Алты елдан тагын халык санын алалар. Бу юлы Зур Сукаешта – 214 йорт һәм 948 кеше, Банки Сукаешта – 69 йорт һәм 295 кеше, Түбән Сукаешта 61 йорт һәм 261 кеше исәпләнә. Зур Сукаешта яшәүчеләр арасында 4 рус кешесе дә була. Авыллар Бөгелмә кантоны Тымытык волостенда күрсәтеләләр[161].

Югарыда китерелгән мәгълүматлар 6 ел эчендә халык саны шактый кимүен күрсәтә. Моның төп сәбәбе – 1921 елгы ачлык. Авыллардагы халыкның яртысы диярлек ачлыктан кырыла ул чакта. Ачлыкка чаклы дәрәҗәдә булган халык саны, ничә еллар үтүгә карамастан (хәтта, утызынчы елларда да), инде башкача кабатланмый.

«Банки авылы 1921 елга кадәр ике урамлы булган. Хәзерге өске як кешеләренең бакча артында урнашкан урам, ачлык чорында күп кешеләр үлү сәбәпле, бетә, бөтен авыл кешеләре хәзерге урамга сыешып тора башлаганнар», дип искә ала үзенең 1992 елда язган истәлекләрендә Банки Сукаештан Сәхап Шәйхетдин улы Хөснетдинов.

Түбән Сукаешта егерменче елларда кредит ширкәте урнашкан була. Аның аша авыл хуҗалыгы машиналары (ургычлар, «Фордзон» тракторлары) кайтара башлыйлар.

1928 елда Зур Сукаештан Курай Елга поселогы аерылып чыга. 1929 елның 13 августында Зур Сукаешта «Тырыш» һәм «Сукаеш» колхозлары оеша. Югары очтан – 23, түбән очтан 86 хуҗалык колхозга керә. Беренче рәисләр Латыйпов Мәгъсүм һәм Тәкыйуллин Әдипләр була. 1930 елның көзендә 2 колхоз берләшә, ләкин оешып китә алмый, таркала. 1931 елда, коллективлашу киң колач алган чорда, Сукаешта тагын «Тырыш» колхозы оеша, рәисе Латыйпов Мәгъсүм була.

Банки Сукаешта колхоз оештыруда ярлылар комитеты әгъзасы Җиһаншин Моталлап һәм комсомол Сираев Гариф актив катнаша. 1930 елның язында колхоз оештыру җыелышында идарә әгъзалары һәм рәис сайлана. Камалов Фәез Камалетдин улы – рәис, Тәхин Әмирҗан хисапчы итеп сайлана. Колхозга «Кызыл Көч» исемен кушалар, ул ике бригададан тора. Гыйздәтуллин Сибгәтулла – беренче бригада, Гатин Сәлах икенче бригада бригадиры итеп сайлана. Җәләев Хәлфетдин – агротехник, Исхаков Юныс – амбар мөдире, Нәфыйков Мәннан ферма мөдире итеп билгеләнә.

Түбән Сукаешта башта артель оеша, 1933 елда ул колхозга кушыла һәм аңа «Кызыл Юл» исеме бирелә, беренче рәис Зарипов Гариф була.

Утызынчы еллар башында репрессияләр авыллардан күп кенә шәхесләрне аяныччлы язмышка дучар итә. Зур Сукаештан Яркәев Мәйлүн (1863 елда туган), Исхаков Салихлар (1880; икенче документта исеме «Сәйях» дип

[161] Шунда ук, Р–1296 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 33 б.

бирелә) кулаклыкта гаепләнә. Беренчесенең – 178, икенчесенең 211 сумнан артыграк мал-мөлкәте тартып алына. С. Исхаков мулла булганы өчен шушы язмышка тарый.

Дин әһелләре башка авылларда да эзәрлекләнә. Банки Сукаешта җирле хакимият вәкилләре Кашшафетдин Ярмәковның да йортына килеп, 253 сумлык мал-мөлкәтеп төяп китәләр. Бу вакытта аның янында хатыны Сабира (1879 елгы), олы улы Сәетәхмәт (1907), кечесе Зөфәр (1916), кызлары Әкълимә (1911), Хәкимә (1914) һәм Кадрия (1921) була. Мөәзин Миргалим Галимовның (1901) 35 сумлык мал-мөлкәте конфискацияләнә. Документта аның 1919 елның сентябреннән 1923 елның гыйнварына кадәр Кызыл армия сафларында хезмәт итүе хакында әйтелә, хатыны Хөршидә (1902) һәм 2 кызы күрсәтелә.

Банки Сукаештан тагын Мифтахов Гыймай (1856 елгы) да репрессияләнә. Аның 653 сум 50 тиенлек мал-мөлкәте тартып алына. 1906 елда жандарм чакырып бер ярлының йортын тартып алган, ә 1917–1928 елларда хезмәтче тоткан дигән «гаепләр» тагалар. Бу вакытта аның хатыны, улы Хөҗҗәт (1900), килене Мәстүрә (1905), оныклары Җәмил (1922), Сәетәхмәт (1926), Җәүдәтләр (1928) белән яшәп яткан чагы була.

Түбән Сукаешта шундый ук язмышка мулла Мөлеков Вагиз (1894) һәм мөәзин Ханнанов Газиз (1864) дучар була. Беренчесенең – 204, икенчесенең 40 сумлык мал-мөлкәте конфискацияләнә. Вагиз хәзрәтнең бу вакытта үзе белән хатыны Хәдичә (1900) һәм 3 улы (олылары – Әгъдас, Мәгариф) яши. Газиз мөәзиннең гаиләсендә хатыны Гайшә һәм кызы була.

Авылларның кайсына карыйлардыр, гаепләнүчеләр исемлегендә тагын мөәзиннәр Шәрипов Латыйф (1868 елгы) һәм Хәбибуллин Фәттахлар (1851) күрсәтелә. Беренчесенең – 205, икенчесенең 115 сум 15 тиенлек мал-мөлкәте конфискацияләнә.

Әлбәттә, репрессиягә дучар булучылар болар белән генә чикләнми. Барысының да исемнәрен ачыклау, чыганаклар җитмәү сәбәпле, мөмкин түгел.

Утызынчы еллар башыннан күмәк хуҗалык кырларында тракторлар күренә башлый. Беренче трактористлар Шакиров Салих, Шәйхетдинов Кыям, Закиров Зәки, Җаббаров Зәкиләр була. 1934 елда «Коммунар» комбайннары да кайтарыла. Һадиев Шәйхерази, Дәүләтшин Мөбәракша оста комбайнчылар булып китә. М. Дәүләтшин 1935 елда ук стахановчы исемен ала, районда беренче буларак Ленин ордены белән бүләкләнә.

1932 елда колхозда яшелчә бакчасына нигез салына, аның бригадиры Латыпова Галия, агрономы Булатов Салих була.

Бөек Ватан сугышы еллары – авыллар өчен гаять авыр чор. Сукаеш авыл советы буенча биш йөзләп ир-ат сугышка алына, җитештерү өлкәсендә төп авырлык хатын-кыз җилкәсенә төшә. Күп кенә хатын-кызлар (Авзалова Мәмдүхә, Дәүләтова Фәүзия, Мияссәрова Доха, Шакирова Мәүҗидә, Шәйхе-

разыева Бәһиҗә, Сафиуллина Иклимә, Кадырова Хәтирә, Әминова Галимә, Гәрәева Мәлләфә, Сәйфуллина Тәзкирә, Шәмсиева Мәптүха, Сәлахова Рәйсә, Солтанова Хафаза, Вәлиева Мөкәррәмә, Авзалова Фатыйма, Зыятдинова Фатыйма, Сәлахетдинова Рәйсә, Хәйдәрова Наҗия, Хәйдәрова Наилә, Шәрәфиева Зөлхәбирә һәм башкалар) тракторчы һөнәрен үзләштереп, авыр шартларга карамастан, зур хезмәт күрсәткечләренә ирешәләр.

Икенче бөтендөнья сугышында авыллардан бик күп ир-ат сугыш кырында ятып кала («Хәтер» китабы буенча, Зур Сукаештан – 160, Банки Сукаештан – 84, Түбән Сукаештан – 32, Курай Елгадан – 14). Банки Сукаештан сугышта һәлак булучылар арасында хатын-кызлар да була. Болар – Рәфикова Мөнширә Сәгыйр кызы, Сәгыйрова Мөхтәрәмә Сәгыйр кызы (1924) һәм Сираҗиева Хаҗия Галәветдин кызы (1920). М. Сәгыйровага фронтта сугышчылар өчен икмәк пешерү эше йөкләнгән була, 1943 елда Сумы шәһәрендә һәлак була.

Түбән Сукаешта туып-үскән Фатыйх Гариф улы Булатов сугышка кергәндә майор, полк командиры булып, сугышны дивизия белән командалык итеп тәмамлый. Генерал-майор Фатыйх Булатов (1902–1986) исеме хәзер күпләргә таныш. Зур Сукаеш урта мәктәбе 1997 елдан аның исемен йөртә.

Зур Сукаештан Миргалимов Мирхәт тә авыр сугыш сынауларын уза. Полковник дәрәҗәсен алган авылдашы белән монда хаклы рәвештә горурланалар.

Сугыштан соңгы елларда илдә барган үзгәрешләр авылларга да кагыла. Илленче еллардан колхозларны эреләндерү сәясәте башлана. 1950 елда Банки Сукаешның «Кызыл Көч» колхозына Түбән Сукаештан «Кызыл Юлны» кушалар. Берләштерелгән колхоз «Кызыл Көч» исемен ала, аның үзәге Банки Сукаеш авылында була. Монда Сәетов – рәис, Хөснетдинов – ревизия комиссиясе рәисе, Булатов хисапчы булып кала.

Бу ике авыл ун ел бер колхоз булып яшәгәннән соң, 1960 ел башында үзәге Зур Сукаешта булган «Тырыш» күмәк хуҗалыгы белән берләштерелә. Колхоз рәисләре булып төрле елларда Н. Хәбибуллин, Р. Гыйльманов, М. Минһаҗевлар эшлиләр. Әледән-әле хезмәт җиңүләре дә, хөкүмәт бүләкләре дә була бу чорларда. Механизатор А.Х. Булатов иң югары бүләккә – Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек була.

Авыл тормышында еш булмаса да, күркәм вакыйгалар булып тора. Шуларның берсе – авыл тарихына багышланган мәктәп музеен ачу. Экспонатлар, тарихи мәгълүматлар туплауда зур тәҗрибәле укытучы Әсхабиев Шәүкәт Афзал улы күп көч куя. Аның җитәкчелегендә укучылар читтә яшәүче данлыклы авылдашлары белән элемтәгә керәләр, төбәк тарихы буенча үзләренең белемнәрен арттыралар. Мәктәп директоры Хәбибуллин Рөстәм Җәүдәт улы музей эшчәнлегенә зур игътибар бирә.

1992 елда Зур Сукаешта – 474, Банки Сукаешта – 142, Түбән Сукаешта 83 кеше исәпләнә. Зур Сукаешта урта мәктәп, мәдәният йорты, почта

бүлекчәсе, фельдшерлык-акушерлык пункты эшли. «Тырыш» күмәк хуҗалыгының төп юнәлеше булып игенчелек һәм терлекчелек (ит, сөт җитештерү) кала. 1995 елның мартыннан күмәк хуҗалыкка Һадиев Әнис Харис улы җитәкчелек итә. Бүгенге чор авырлыкларына карамастан, колхоз төп күрсәткечләр буенча нәтиҗәле эшли.

1996 елда колхоз дәүләткә 41148 ц икмәк, 17558 ц шикәр чөгендере, 12151 ц сөт, 1169 ц ит сата. Моннан соңгы елларны да хуҗалык районда күп продукция җитештерүчеләр рәтендә кала.

Эшләгәннең ашы бар, дип юкка гына әйтмәгәннәр борынгылар. Җитештергәнен әледән-әле сатып, кергән табыштан вакытында хезмәт хакы түләп баргач, мондагы хезмәт кешесенең дә табыны мул, күңеле көр[162].

## § 6. Илбәк

Тәүге чорда авыл өч атама (Абдул, Әманәт түбәләре һәм Мансур) белән йөри. Алар, борынгырак булганга, XVIII гасыр документларында күбрәк телгә алына. Әмма вакытлар узу белән кулланылыштан чыгып онытылганга хәзерге атама өстенлек ала.

Авыл кайчан барлыкка килгән соң? Бу сорауга тәгаен җавап бирү мөмкин түгел. Шулай да XVIII гасыр документлары беркадәр ачыклык кертте.

1736 елда яңа барлыкка килгән Абдул авылына Мәләкәс елгасы буендагы Чады авылыннан Йосып Токмәтов (улы Йөзәй) гаиләсе күчеп утыруы билгеле[163]. Ике елдан шул ук Абдул авылына Арча юлының Мәләкәс авылыннан Госман Касаев, Үсәй Тәмәев, Бикбау Сәинов, Мостафа Сәинов, Микит һәм Бикән Кушаевлар, Абдул Токаев, барысы 8 ир-ат күченә[164].

Бу һәм башка кешеләр 1748 елда халык санын алганда Илбәк елгасы буендагы Абдулда яшиләр, Казан өязенең Арча юлына караган Мәләкәс һәм Чады авылларыннан күчеп утырганнар дип күрсәтелә. 24 ир-аттан торган ясаклы татарлар исемлегендә Госман (28; улы Адыл), Әрекәй (23; улы Ряхмул), Мөэмин (22; улы Хәлил), Гали (17), Аиткол (16) Касаевлар, Үсәй Мамаев (43; уллары Ишморат, Солтан), Бикбау (31; улы Рахманкол), Аиткол (20), Мөслим (17), Мөсәллим (14) Сәетовлар, Мостафа Сәетов (30; уллары Мортаза, Морадым), Мәсгут Сәитов (27), Микит (31), Бикәй (28) Кошаевлар һәм Йосып Токмәтов (53; улы Йөзекәй) теркәлә[165].

---

[162] Авыл тарихы 1990 нчы елларда язылды.
[163] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1154 сакл. бер., 332 б.а.–334 б.
[164] Шунда ук, 329 б. а.–330 б.
[165] Шунда ук, 1140 сакл. бер., 78–78 б. а.



*1738 елда Мәләкәстән килеп утыручылар исемлеге*

1762 елда Илбәк елгасы буендагы Абдул авылында яшәүчеләрнең Табын волосте старшинасы Мөэмин Мөслимов рөхсәтен алып монда килеп утырулары турында әйтелә. Исемлектә теркәлгән ясаклы татарларның күпчелеге (ике хатынлы Госман Касаев, Гали Касаев, Рәмкол Уразкәев, Ишморат һәм Солтан Үсәевлар, Бикбау Сәинов, Аиткол, Мәсгут, Мөслим Сәетовлар, Бикчәнтәй Кушаев һәм башкалар) Арча юлы Колмәт Котлыгошев йөзлегенә (чыганакта «сотня») карый. Монда ук Мәләкәс, Туймәт (Сөпханкол Ишмуратов), Паново (Исмәгыйль Сабанаев), Югары Мәләкәс, Урта Мәләкәс (Ибрай һәм Мөслим Мостаевлар), Урта Кәшер (Уракай Тукаев һәм аның улы Абдулла; Рәмкол Тләкәев йөзлегеннән) авылларыннан килеп утыручылар күрсәтелә[166].

Болардан тыш, 1762–1782 еллар арасында авылга йомышлы татарлар (32 ир-ат) күчеп утыра. Алар теркәлгән исемлектә дә авыл Илбәк елгасы буендагы Абдул («Абдулово по речке Ильбяк») дип атала[167].

1782 елда авыл административ яктан Минзәлә округыннан Бөгелмә округы составына күчерелә. Бөгелмә шәһәре авылга якынрак булуны күз алдында тотып кертелә бу үзгәреш.

1795 елда авылда (документта «Абдулова Илбяк тож») 20 хуҗалык исәпләнә. Сословиеләре буенча авыл халкы ясаклы (58 ир-ат һәм 64 хатын-кыз) һәм йомышлы (44 һәм 29) татарлардан тора. XIX гасыр башында Илбәккә бер «типтәр» гаиләсе күчеп килә.

1795 елгы ревизия документында авылда (чыганакта «Абдулово по речке Ильбяк») 58 ир-ат һәм 64 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 61 һәм 63) ясаклы татарлар теркәлә. Болар түбәндәге хуҗалыклар: Госман Касаев (1716–1792; уллары Әдел, Габделмән), ике хатынлы Гали Касаев (уллары Рәхмәтулла,

---

[166] Шунда ук, 1188 сакл. бер., 164–169 б.

[167] Татары Уфимского уезда (материалы переписей населения 1722–1782 гг.): справочное издание. 2 изд. испр. и доп. Казань, 2021. С. 113.

Габдерәшит, Габделваһап), Салтый Үсәев (56 яшь; улы Миңлегол), ике хатынлы Мөэмин Муллин (1723–1792; уллары Сәйфулла, Хәбибулла), тол хатын Карабаш Даутова (уллары Урманай, Фәйзулла, Рәхмәтулла), Ишмөхәммәт (43) һәм Бикмөхәммәт (41) Бикатаевлар, Морат Кушаев (1732–1787; улы Биктимер), Бикәй Иркенов (42), Ибраһим Мостаев (1737–1786; уллары Нигъмәтулла, Вәлит), тол хатын Хәзинә Солтанбәкова (улы Мөхәммәдьяр), Мөрсәлим Мостаев (46; уллары Мөхәммәтгали, Габделлатиф), Габдулла Уракаев (36; уллары Габделҗәлил, Габбәс), ике хатынлы Сәгыйть Балтаев (45; улы Халит), Рахманкол (1733–1791), Сәеткол (48), Габделмән (1752–1795), Габделхалик (30), Габделлатиф (25), Хәмит (19), Вәлит (15) Бикбововлар, Аиткол Әсәнов (70; улы Абдулла), Муса Сәинов (1715–1788; уллары Мортаза, Морадым, Рәим), Мөсәллим Сәетов (1741–1784; улы Габдерәхим), Габдессәлим (?) Бикколов (45; туганнары Гапсәлам, Габдерәшит), Сөпханкол Ишморатов (52; улы Хәмит), ике хатынлы Әсәй Тапаев (53; уллары Ибраһим, Мөсәгыйть). Рәхмәтулла Галиев хатынын шул ук Илбәк авылыннан алган (чыганакта «взята той же деревни Ильбяковой»)[168]. Бу факт авылның рәсми исемнән (Абдул) башка Илбәк дип тә аталуын күрсәтә.

Болардан тыш, 1795 елда Илбәктә (чыганакта «Абдулово по речке Ильбяку») тагын 44 ир-ат һәм 29 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 40 һәм 42) йомышлы татар исәпләнә. Хужалыкларны атап үтик: 1) ике хатынлы Хәмит Аптикәев (1744–1781; уллары Габделмән, Габделлатыйф, Габделвахит, Габделнасыр); 2) ике хатынлы Шәмәй Аптикәев (1732–1793; уллары Габдессәлам, Габдерәшит, Габдрахман); 3) ике хатынлы Рәфикъ Аптикәев (41 яшь; уллары Искәндәр, Мөхәммәт, Әхмәт, Рәхимкол); 4) Салих (48), Зәбир (42), Нәзир (1753–1795), Заһир (39) Әсәевлар; 5) Сәфәр Рысаев (1728–1789; улы Гапсәлам); 6) тол хатын Салиха Якупова (52; улы Мәннап); 7) тол хатын Сәгидә Бикинева (улы Фәйзулла); 8) Габделвахит Габделваһапов (20); 9) Хәлил (42) и Зәбир (39) Калмәтовлар; 10) Морат Арысланов (59); 11) Яхья Исмәгыйлов (48; уллары Мөхәммәтрәхим, Хөҗәмшәкүр, Даут); 12) Бакир Аитов (60; уллары Гобәй, Габидулла). Габдулгази Исмәгыйлов гаиләсе Димескәй авылына күченә, анда ул указлы мулла вазифасын башкара[169].

1816 елда Илбәктә (чыганакта «Абдулово Ильбяк тож») 98 ир-ат исәпләнә. Халыкның төп өлешен лашман бурычын башкаручы (чыганакта «исправляющие лашманную повинность») ясаклы (55 ир-ат һәм 71 хатын-кыз) һәм йомышлы (40 ир-ат һәм 35 хатын-кыз) татарлар (барысы 42 хуҗалык) тәшкил итә[170]. Алар белән бергә типтәр сословиесендәге татар

[168] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 27–32 б.
[169] Шунда ук, 22 сакл. бер., 311–315 б.
[170] Шунда ук, 197 сакл. бер., 578–590 б.

(1 ир-ат) һәм «отставной солдатлар» (2) яши[171]. Тирә-як авыллардагы кебек, Илбәктә дә бер мәчет була[172].



| | | |
|---|---|---|
| итого | 36 | 123. |
| с. Абдулово Ильбакчато в ней из татар. | | |
| Ясашных | | 55. |
| Служилых | 27 | 40 |
| тептярей | | 1 |
| отставных солдат | | 2. |
| Итого | 27 | 98. |

*1816 елгы мәгълүмат буенча да авыл Абдул исеме белән йөри*

XIX гасыр уртасында Илбәк атамасы еш кына мөстәкыйль кулланыла, мәсәлән, 1864 елгы статистик белешмәдә «Абдул» сүзе бөтенләй телгә алынмый.

Авыл ни өчен Илбәк дип атала башлый? Бу сорауга җавап бирүе авыр. Башка төбәкләрдә мондый исемле кешеләр документларда очраштыргаласа да, конкрет бу авылда андый кешенең булу-булмавы мәгълүм түгел. Аннан соң, авыл биләмәләре аша агучы елганың да Илбәк дип аталуын истән чыгармаска кирәк. Гидрографик термин тора-бара авылның төп атамасына әйләнгән булуы мөмкин.

XIX гасыр уртасына хуҗалыклар һәм халык саны шактый арта. 1859 елда Илбәктә 204 ир-ат һәм 222 хатын-кыз (64 хуҗалык) яши. Алар барысы казна (дәүләт) крестьяннары санала. Авылда элеккечә бер мәчет, 1831 елдан монда Мозаффар Габделкәримов мулла була[173]. Ревизиядә теркәлгән һәр ир-атка 15,1 дисәтинә җир тия.

1870 елгы мәгълүматлар буенча, Илбәктә су тегермәне эшләгән. Авыл старостасы Җиһанша Батыршин була. Документларда тагын Гомәр Минмөхәммәтов, Габдерәфикъ Габделваһапов, Хәлиулла Фәйзуллин, Габделкәрим Гәббасов, Сөләйман Вәлитов һәм Мифтахетдин Халитовлар телгә алына[174].

1882 елда Илбәктә яңа мәчет салына. Имам-хатыйп һәм мөгаллим вазифасын 1868 елдан Мирсадретдин Мөхәммәтәмин улы Рахманколов башкара.

[171] Шунда ук, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 129 б.

[172] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1874 сакл. бер., 293 б.

[173] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 23; БР МА, 295 фонд, 3 тасв., 5662 сакл. бер.

[174] ТР ДА, 979 фонд, 11 тасв., 232 сакл. бер.

Мөхәммәтфазыл Мөхәммәтсадыйков мөәзин һәм мөгаллим хезмәтендә (1874 елдан) була[175].

Нәкъ алар эшләгән чорда, 1889 елда яшь Ризаэтдин Фәхретдин бирегә имам итеп билгеләнә. 1891 елда ул моннан Диния нәзарәтенә казыйлык вазифасына эшкә чакырыла.

Гомеренең бу чоры турында Ризаэтдин хәзрәт үзенең «Тәрҗемәи хәлем» исемле хезмәтендә түбәндәгеләрне язып калдырган: *«1306/1889 елның 3 шәүвәл/21май, якшәмбе көнне, остазлар вә иптәшләр һәм үземнең укучы шәкертләремнән, кыскасы, бөтен мәдрәсә дөньясыннан аерылып, Кичучат авылына кайттым. 27 шәүвәл/14 июнь, чәршәмбе көн, гаиләм илә, имам булачак авылга (Илбәккә) күчеп киттек. Миңлебай авылында җизнәбез вә абыстаебыз илә күрешеп, икенче көндә Илбәккә ирешеп, Мөхәммәдсәлим бине Әюб исемле затның мәчет каршында булган йортына төштек, 10 рабигыльәүвәлдә/23 октябрьдә, дүшәмбе көн, үз йортыбызга күчтек. Бер мәктәп тә җитештереп, 20 рабигыль-ахир/ 12 декабрьдә сишәмбе көн сабак башладым. Уфа шәһәрендә Җәмгыяте шәргыядә хезмәт өчен билгеләнгәнгә, 1308/1891 ел 10 рәҗәб/7 февраль, пәнҗешәмбе көн, Илбәк авылы белән хушлашып чыгып киттек. Илбәктә торуыбыз 21 айдан бер микъдар артыграк, яки 627 көн булды»*[176].

1884 ел ахыры – 1885 ел башында Илбәк Минзәләбаш волостенда (аңа тагын Кәтем, Мәсгут, Урсалыбаш, Сөләй һәм Шарлама керә) зур авылларның берсе санала. Анда 132 хуҗалыкта 366 ир-ат һәм 377 хатын-кыз исәпләнә. Авылда 2 лавка була.

Илбәк авыл җәмгыятенең ул чорда 3309,7 дисәтинә имана җире була. Аның 1960 дисәтинәсен урман алып тора. Халык җир белән яхшы тәэмин ителгән. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка бүлгән очракта ул 24,3 дисәтинә туры килә. Бу күрсәткеч Кәтемдә – 15,3, Мәсгуттә 42,7 дисәтинә була[177].

1889 елда Илбәктә 142 хуҗалыкта 768 кеше яши. Авылда мәчет һәм 2 су тегермәне була. Дүртенче участок уряднигының тору урыны да монда. Якында гына сәүдәгәр Мөрсәлимовның имениесе урнашкан.

Бу чорда Минзәләбаш волостена Кәтем, Мәсгут, Илбәк, Урсалыбаш, Чубар Абдул, Сөләй, Буралы һәм Шарлама авыллары керә. Чубар Абдул һәм Буралы волостька 1885 елдан соң гына кертелә; аңа чаклы алар Уфа губерна-

[175] БР МА, И–295 фонд, 14 тасв., 11 сакл. бер.; 2 тасв., 3 сакл. бер., 136 б. а., 137 б.

[176] Ризаэтдин Фәхретдин. Фәнни-биографик җыентык. Казан, 1999. 29 б.

[177] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 162–169.

сы Минзәлә өязе составында тора. Соңрак әлеге ике авыл Минзәләбаш белән бергә яңадан Минзәлә өязенә кайтарыла[178].

Гасыр ахырына Илбәк беркадәр зурая. 1897 елда авылда 158 хуҗалык, 414 ир-ат һәм 396 хатын-кыз исәпләнә. Ул Мәсгут, Кәтем, Кәкре Елга, Сөләй һәм Урсалыбаш авыллары белән яңа оешкан Мәсгут волостена керә. Авылда элеккечә бер мәчет, ике мәктәп һәм 2 су тегермәне була. Имана җирләр 1941 дисәтинә тәшкил итә. Якындагы хутор хуҗасының – Мөрсәлимовның – җирләре 600 дисәтинә. Хутор аша агучы Мәллә елгасында аның су тегермәне бар[179].

1906 елның 9 ноябрендә патша министры П.А. Столыпин крестьяннарның община җирләрен биләүләренә яңа тәртип кертүче закон чыгара. Аның буенча, крестьян үз теләге белән общинадан чыгып, үзенә тиешле имана җирнең хуҗасы була алган. Әгәр дә ул җир төрле урында урнашса, аны бер урыннан бүлеп бирүне таләп итәргә хокуклы.

Столыпин законы турындагы хәбәрләр тиз арада Илбәккә дә килеп җитә. Кайбер урыннарда крестьяннарның, өяз хакимияте карарлары нигезендә, җирне хосусыйлаштыру турында документ алуларын да ишетә авыл халкы. Инде Илбәкнең үзендә Хаҗи Хәсәнов һәм Таҗетдин Рахманколовлар шундый ук документ артыннан йөри дигән сүзләр башта сәер тоелса да, анысына да ияләнә халык һәм кызыксынып эшнең ахырын көтә. Әмма озак көтәргә туры килми.

Столыпин указы турында ныклап белешкәч, 1907 елның җәендә Х. Хәсәнов һәм Т. Рахманколовлар үзләре куллана торган имана җирләрне шәхси милек итеп беркетү теләге барын авыл старостасына җиткерәләр. Староста бу хакта ишетергә дә теләми, җитмәсә Таҗетдинның үтенечен законда күрсәтелгән срок эчендә канәгатьләндерми. Моның белән килешмәгән Таҗетдин өязнең 1 нче участок земски начальнигы К. Товянскийга мөрәҗәгать итә.

1907 елның 5 сентябрендә әлеге начальник рәислегендә Таҗетдин Рахманколовның административ эше карала. Мәсьәләне җентекләп өйрәнгәннән соң шундый карар кабул ителә: «*Укрепить за домохозяином д. Ильбяковой Масягутовской волости Бугульминского уезда Таҗетдином Рахманкуловым в личную собственность состоящие в его пользовании участки земли в размере четырех душ* [...]»[180].

Шулай итеп, 14,95 дисәтинә сөрүлек җирләр Таҗетдинның шәхси милкенә әйләнә. Моннан башка, элеккеге кебек, печәнлекләрдән һәм көтүлекләрдән файдалану хокукына ия ул. Авылның 2 су тегермәне (алар арендага бирелә торган булган) китергән саф табыштан да аңа өлеш чыгарылачак икән.

---

[178] Список населенных мест Самарской губернии по сведениям 1889 г. Самара, 1890. С. 74–75.

[179] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 139.

[180] ТР ДА, 979 фонд, 9 тасв., 2 сакл. бер., 56 б.

1907 елның 20 октябрендә Бөгелмә өязенең земство съезды земски начальник карарын раслый һәм ул шул көннән гамәлгә керә. Авыл вәкилләрен һәм Рахманколовны бу карар белән таныштыралар, риза булмаган очракта жалоба бирү тәртибен күрсәтәләр. Авылдашлары бу карарга карата бернинди дәгъва белдерми. 1907 елның 8 ноябрендә аңа документларның копиясе бирелә.

Бу вакытта Таҗетдин Әюп улы Рахманколовка 55 яшь була. Ул хатыны Зөләйха (45 яшь), 3 улы, 4 кызы һәм килене белән яши. Аның сөрүлекләре Түбә басу, Биш каен басу, Ялгыз Каен басу исемле җирләрдә, барлыгы 28 участокта урнашкан. Шуңа карамастан, ул аларны шул килеш калдырта, шундый ук күләмдә бер басудан гына бүлеп бирүне таләп итми.

Земски начальникның Хаҗи Хәсәновка кагылышлы 16 август карарын исә Бөгелмә өяз съезды шул ук елның 20 октябрендә раслый. Шулай итеп, 20 дисәтинәдән артыграк иманасы аның шәхси милкенә әйләнә.

Илбәктә Хаҗи Хәсәнов һәм Таҗетдин Рахманколов кебек иманаларын шәхси милек итеп беркеттерүчеләр саны торган саен арта. 1908 елда мондыйлар исәбенә Габдерәхим Мөхәммәтсадыйков, Мәсәлим Хәкимов, Тимергали Мөстәкыймов, Баһаутдин Бадыкшанов һәм Сәрбиҗамал Мөхәммәтгалиева керә. 1909 елда бу исемлеккә тагын Шәйхелислам Игътисамов, Әхмәтсафа Сөләйманов һәм Мөхәммәтгәрәй Тимергалиев хуҗалыклары өстәлә. 1910–1913 елларда исә барлыгы өч дистәдән артык хуҗалыкның үз иманаларын шәхси милек итеп рәсмиләштерү турындагы үтенече канәгатьләндерелә.

Хосусыйлаштырылган җир хуҗалары арасында әледән-әле алыш-биреш булып торган. Берәүләр бурычларын түләү өчен я булмаса башка максаттан җирләрен сата, икенчеләре шундыйлар исәбенә үз биләмәләрен киңәйтә. Җир сатучылар 1911 һәм 1912 елларда аеруча күп була. 1911 елда иген уңмау аркасында күпчелек хуҗалыкларның ачлыктан интегүе бу очракта төп сәбәп булган дип уйларга кирәк. Җитәрлек икмәк запасы булмаганнарга ачтан үлмәс һәм симәнә өчен җирләрен өлешчә сатудан башка чара калмаган, күрәсең.

Сатып алучылар кемнәр соң? Иң эре сатып алучы – Харис Хафиз улы Хәлфин. 1911 елда аның биләмәләре Солтангәрәй Тимергалиевныкы исәбенә 3 дисәтинә 1218 сажинга арта. Шундый ук яисә аннан аз гына артыграк күләмдә җирләрне аңа 1912 елда Әхмәтсафа Сөләйманов, Габделхаликъ Габдерәфиков, Йомагол Җәләлетдинов, Шәйхелислам Игътисамов һәм Гәрәйша Гаделшиннар сата.

Миргазиян Мирсадретдин улы Рахманколов та эре сатып алучылар исәбенә керә. 1911–1912 елларда берешәр иманаларын (мондагы 1 имана 3 дисәтинәдән аз гына арта) 100–150 сумга аңа Сафиулла Нәҗметдинов, Таҗетдин Рахманколов, Ризван белән Зиннур Вилдановлар, Бәдигулла, Сәмигулла һәм Кәлимулла Сәгыйдуллиннар сата. Миргазиянның туганы булса кирәк, Мирсалихҗан Рахманколов та үз биләмәләрен киңәйтә. 1912 елда

Хаҗи Хәсәнов һәм Миңлегалим Габделвәлиев аңа берәр иманаларын саталар. Югарыда телгә алынган Гәрәйша Гаделшин тагын бер иманасын Н. Гыйльмановка сатарга мәҗбүр була. Менә шулай авылда хуҗалыкларның бер өлеше байлыгын арттырса, икенчеләре исә хәләл җирләрен сатып, торган саен ярлылана төшә.

Җирне хосусыйлаштыру киң колач алгач, общинадан бүленеп чыгучы яисә чыккан хуҗалыкларга тиешле күләмдәге җирне авыл биләмәләренең аерым участогыннан бирү мәсьәләсе килеп баса. Хосусый милекчеләр үз җирләренең бер урында туплануын тели. Чөнки биләмәләренең төрле урында булуы зур уңайсызлыклар тудыра.

Хафиз Хәлфин һәм аның иптәшләре үтенече буенча, 1913 елның 22 сентябрендә Бөгелмә өяз җир төзү комиссиясенең ачык утырышында аларга хосусыйлаштырылган имана җирләре күләмендә аерым участоктан җир бүлү мәсьәләсе карала. Ул вакытка Илбәктә 189 хуҗалыкның 49-ы общинадан чыккан була. Бүленеп чыгучыларның сөрүлекләре 321 дисәтинә 982 сажин тәшкил итә. Алар арасыннан Хаҗи Хәсәнов, Таҗетдин Рахманколов, Баһаутдин Бадыкшанов, Зиннәтулла Шәрифуллин, Бибисәйдә Ихсанова, Миңлегалим Хөснетдинов, Гариф Каһиров, Вафа Кәримов, Дәүләтша Гаделшин варислары, Йомагол Җәләлетдинов, Сафиулла Низаметдинов, Гыйззәтулла Хәлиуллин, Мөхәммәтфазыл Мөхәммәтзарипов, Хәйрулла Гайнуллин, Мәүлетбай Зарипов, Ризван белән Зиннур Вилдановлар, Сәрбиҗамал Мөхәммәтгалиева, Хәмидулла Насыйров, Сәлимгәрәй Галиәкбәров, Мәсәлим Хәлимов, Мөхәммәтгәрәй Габделвәлиев, Әхмәтҗан Хисмәтуллин, Закир Зарипов үзләренең Илбәктәге утарларын калдырып, «Тархан» дип аталучы урынга күчәргә теләкләрен белдерәләр. Чөнки хосусыйлаштырылган иманалары күләмендә биреләчәк яңа җирләр шул тирәдән булачак. Комиссия утырышында бу хуҗалыкларның теләкләре канәгатьләндерелә. Анда кабул ителгән карарда күчеп утыручыларга утар урыннары өчен җир бирү карала. Хәтта мәчет һәм зыярат өчен дә урыннар билгеләнә. Менә шулай 24 хуҗалыктан торган Тархан авылы барлыкка килә.

Мирсадретдин хәзрәт 1909 елда дөнья куя. 1913 елның 30 гыйнвареннан имам-хатыйп һәм мөгаллим вазифасы Гыйсметдин Шәйхетдиновка йөкләнә.

1916 елда Илбәктә 190 хуҗалык, 436 ир-ат һәм 492 хатын-кыз теркәлә. Сугыш тәмамланмаган, шуңа күрә ир-атлар хатын-кызларга караганда шактый аз.

Хуҗалыклар һәм халык саны буенча Илбәк волостьның күпчелек авылларыннан калыша. Бу вакытта Кәкре Елгада – 415, Сөләйдә – 322, Мәсгуттә – 261, Урсалыбашта – 197, Кәтемдә – 190, Тарханда 24 хуҗалык исәпләнә. Мәсгут волостенда тагын ике хутор була. Аларның хуҗалары – Г.Т. Мусин һәм Г.С. Мөссәлимов.

Гариф Талип улы Мусинның хуторы Илбәктән ике чакрым ераклыкта урнашкан була. Анда 16 ир-ат һәм 8 хатын-кыз яши. Хуҗаның гаиләсе 4

кешедән тора. Калган халыкны гаиләләре белән хезмәткәрләр (7 кеше) һәм ялланган эшчеләр (13) тәшкил итә.

Гариф Мусинның хутор хуҗалыгы шактый зур. Анда 1916 елда 25 эш аты, 45 мөгезле эре терлек (шул исәптән 12 сыер) һәм 100 сарык исәпләнә. Әйтергә кирәк, 1915 елда аның мал-туары күбрәк булган. Ул елны Гариф бай 37 ат, 200 мөгезле эре терлек, 433 сарык асраган. Аннан соңгы елны мал-туар санын хуҗа, ни сәбәпледер, шактый киметкән.

1915 елда Гариф Мусинның иген мәйданы 234 дисәтинә тәшкил итә. Аның төп өлешен арыш (120 дисәтинә) һәм солы (75), калганын борчак (18), бодай (15) һәм карабодай (6) алып тора. Ул барлыгы 12000 пот арыш, 4000 пот солы, 1200 пот борчак, 800 пот бодай һәм 400 пот карабодай җыеп ала.

1916 елда Гариф байның иген мәйданы 19,5 дисәтинәгә кимрәк. Арыш һәм солы шул ук күләмдә, ә менә борчак (12 дисәтинә), бодай (4,5) һәм карабодай (3) элеккегә караганда азрак игелә.

Елның ничек киләсен белеп булмый дипме, Гариф бай зур икмәк запасы тоткан. Аның амбарларында 1916 елда элеккеге еллардан калган 11000 пот (шуның 5000 поты сугылмаган) арышы була. Моннан башка, 60 пот арыш онын ул запас итеп тота. Байның солы запасы да шактый (барлыгы 2300 пот) була. Икмәкне ул һәр елны Бөгелмә һәм Карамалы базарларына илтеп саткан.

Илбәк янындагы икенче хуторның хуҗасы – Гариф Сафиулла улы Мөсәллимов. 1916 елда монда 4 ир-ат һәм 4 хатын-кыз исәпләнә. Хуҗаның гаиләсеннән (4 кеше) башка биредә яллы эшчеләр дә яши.

Гариф Мөсәллимов та мал-туар санын киметә. 1915 елда аның 9 аты һәм 25 мөгезле эре терлеге булса, 1916 елда бу сан бермә-бер кими. Ул хәзер нибары 6 ат һәм 8 мөгезле эре терлек тота.

Әмма иген мәйданын ул бераз арттыра. 1915 елда Г. Мөсәллимов арыш (37,5 дисәтинә), солы (7,5), борчак (3) һәм бодай (1,5) игә. Амбарларына барлыгы 2500 пот арыш, 500 пот солы, 200 пот борчак һәм 50 пот бодай салып куя ул. 1916 елда хуҗа иген мәйданын 3,5 дисәтинәгә арттыра. Хәзер ул борчак чәчми, ә менә солы мәйданын 15 дисәтинәгә җиткерә.

1916 елда Илбәктә 280 ат (шул исәптән 276 эш аты), 261 мөгезле эре терлек (227 сыер), 1404 сарык һәм 157 кәҗә исәпләнә. Чәчүлекләр мәйданы 910,9 дисәтинә тәшкил итә. Аның яртысын диярлек арыш (455,20 дисәтинә), калган өлешен солы (192,20), борай (118,20), борчак (81,10), бодай (40,20) һәм тары (24) алып тора[181].

Совет чорында үткәрелгән беренче халык санын алу Илбәктә 210 хуҗалык һәм 951 кеше күрсәтә. Алты елдан соң бу күрсәткечләр күпкә азрак – 145 һәм 646. 1921 елгы ачлыктан күп хуҗалыклар кырылган, ә аннан соңгы үсеш зур булмый. Авыл Бөгелмә кантоны Әлки волостена керә[182].

[181] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 497–499 сакл. бер.

[182] Шунда ук, Р–1295 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 108 б.

1924 елда Илбәк авылында беренче мәктәп ачыла. 1929 елда 5 хуҗалыктан колхоз оеша. Бераз соңрак авылда «Куйбышев» исемендәге колхоз барлыкка килә, аның беренче рәисе Хәбибуллин Хәлим була. Авыл Советы рәисе вазифасын Биккулов Нуриәхмәт башкара. Колхоз игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә.

1936–1941 елларда колхоз рәисе – Фәрукшин Мөбәракша, авыл Советы рәисе Авзалов Галләм була. Бөек Ватан сугышына Илбәк авылыннан 300 дән артык кеше сугышка китә, шуларның яртысы диярлек (144 кеше) һәлак була.

Бөек Ватан сугышы фронтларында илбәклеләр тиңдәшсез батырлык үрнәкләре күрсәтәләр. Алар арасыннан Әкрәм Искәндәр улы Вәлиев (1924–10.08.1975) Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек була.



*Советлар Союзы Герое Әкрәм Вәлиев (1924–1975)*

Әкрәм Вәлиев 1924 елның 18 апрелендә Илбәк авылында туа. Олы яшьтәге әтисе Насыйбулла Әкрәмгә 7 яшь вакытта мәрхүм була. Ярым ятим Әкрәм 1934–1935 елларда Уфада балалар йортында тәрбияләнә. Анасы Шәмсенаһар кабат кияүгә чыккач, Әкрәм авылга кайта, алар бәхет эзләп Себер якларына алтын приискаларына чыгып китәләр. Бөек Ватан сугышы башлангач Әкрәмнең үги әтисе Искәндәр фронтка китә һәм күп тә үтми һәлак була. 1942 елның сентябрендә 18 яшьлек Әкрәмне дә хәрби хезмәткә чакыралар. Сержант Әкрәм Вәлиев рота комсоргы булып хезмәт итә, 1943 елның 2–3 декабрьдә барган сугышларда дошманның ике «Пантера» тибындагы танкын юк иткән өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. Тагын бер айдан ул «Кызыл йолдыз» орденына лаек була. 1944 елның августында Латвияне азат итү өчен барган авыр сугышларда Айвиексте елгасын кичкән вакытта батырлык күрсәтә һәм югары бүләккә тәкъдим ителә. 1945 елның 24 мартында лейтенант Ә. Вәлиевкә Ленин ордены һәм Советлар Союзы Герое исеме бирелә. 1947 елда хәрби хезмәт срогын тутырып туган авылы Илбәккә кайта. Башта район үзәгендә эшли, ә 1950 елның гыйнварында авылдашлары аны колхоз рәисе итеп сайлылар. Тик озак эшли алмый, сугыш яраларыннан авырып китә.

Сугыштан соңгы елларда колхоз рәисләре әледән-әле алышынып торалар. Башта колхоз рәисе булып Кашапова Фәтхия (1945) эшли, аннары бу вазифаны Әхмәдиев Салих (1945–1949), Ибраһимов Муса (1949–1950), Вәлиев Әкрәм (1950–1953), Мәхупов Мөҗип (1953–1955), Хуҗин Гариф (1955–1958), Сәлимов Таҗетдиннар (1959 елдан) башкаралар.

1958 елда Илбәк авылында яңа мәктәп бинасы салына. Моның өчен 1949 елдан мәктәп мөдире булып эшләгән Сәгыйдуллин Заһидулла Сәмигулла улы зур тырышлык куя.

1960 елда колхозларны берләштерү чоры башлана, «Куйбышев» колхозын «40 лет Октября» колхозына кушалар. 1960 елдан Илбәк авылы «40 лет Октября» колхозының бригадасы исәпләнә, берникадәр вакыттан перспективасыз авыл санала башлый.

Әмма 1979 елда «Янтарь» совхозы оештырылу авыл үсешенә зур этәргеч бирә. Аның директоры булып Хәсәнов Идрис һәм баш хисапчы булып Хәсәнов Рәис эшли башлыйлар. Совхоз умартачылык белән шөгыльләнә башлый. 100 баш умарта белән 4 умартачылык ачыла. Шулай ук игенчелек һәм терлекчелеккә зур игътибар бирелә. 1981 елда совхоз директоры булып Мөхәммәдъяров Ринат Әзәл улы билгеләнә. Ул Илбәк авылын төзекләндерү өчен бик күп эш башкара. Авыл эчендә һәм авылга керү өчен юллар, буш калган нигезләргә таштан, бурадан йортлар салдыра. Терлекчеләр йорты төзелә һәм терлек биналары төзекләнә. Техника өчен мастерской һәм гараж салына. 2 катлы административ бина һәм күпер төзелә. Аннан соң директор вазифасын Шәйдуллин Ягъфәр (1984–1985 елларда), ә 1985 елның декабрь аеннан Закуанов Рөстәм Газизҗан улы башкара. Совхозның яшь җитәкчесе авыл өчен гаять мөһим обьектларны (балалар бакчасы, мәктәп, мәдәният үзәге, почта бүлекчәсе, саклык банкы филиалы) һәм җирле үзидарә Советын булдыруда күп тырышлык куя. Тора-бара Илбәк районда иң матур авылларның берсенә әверелә.

1988 елда 2 укучы белән Илбәк башлангыч мәктәбе үзенең эшен Фәния Вәкил кызы Закуанова мөдирлегендә башлап җибәрә. 1991 елда тулы булмаган урта мәктәпкә әйләнә. Шул елда авылда Советлар Союзы Герое Әкрәм Вәлиевкә һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларга һәйкәл куела. Терлекчеләр һәм игенчеләр өчен коттеджлар салына. 1992–1993 елларда авылга газ кертелә, юлларга асфальт җәелә.

Бала саны арту сәбәпле мәктәптә класс-кабинетлар җитми башлый. 1993 елда «Янтарь» совхозы идарә бинасын мәктәп карамагына тапшыра. Илбәк мәктәбе 1994 елда гомуми урта мәктәп итеп үзгәртелә, директоры Ф.В. Закуанова була. 1994–1995 елларда терлекчелек комплексы төзелеп тапшырыла. 1997 елда совхоз «Янтарь» ҖЧШ булып оеша.

1997 елның сентябренә Әлмәт «Торак төзелеше идарәсе» акционерлык җәмгыяте белән «Янтарь» ширкәте үз эченә балалар бакчасы, медпункт, китапханә, мәдәният үзәген берләштергән спорт, укыту, хезмәт тәрбиясе комплекслы бинасын төзеп тапшыралар. Укыту-тәрбия процессын уңышлы оештыру өчен яхшы җиһазланган информатика, чит теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, тарих, география, рәсем һәм сызым, математика кабинетлары, спортзал, спорт мәйданчыгы, ашханә һәм 2,2 га мәйданда мәктәп яны

тәҗрибә участогы булдырыла. 1997 елда Илбәк авылында НГДУ «Җәлилнефть»нең УТТ оешмасы ярдәмендә Баймөхәммәт чишмәсе төзекләндерелә.

1998 елның 1 апрелендә Илбәк жирле үзидарә Советы оеша. Совет членнары итеп 7 кеше сайлана, аның рәисе Закуанов Рөстәм Газизҗан улы була.

Җирле үзидарә Советы территориясенә Илбәк (89 хуҗалык, 285 кеше, 114,38 га җире), Ирекле (15 хуҗалык, 23 кеше, 18,3 га жире), Тархан (3 хуҗалык, 11 кеше, 32,2 җире), Тырыш (7 хуҗалык, 14 кеше, 27,0 га җире) авыллары керә. Монда барлыгы 335 кеше яши. 1998 елда Азнакай районы авыллары арасында Илбәк «иң чиста төзек авыл» исеменә лаек булып, беренче урынны алды.

1998 елда үзәк сберкасса филиалы ачыла, З.Р. Ярмиева контролер була. Тагын бер елдан почта бүлекчәсе ачыла, монда Х.Г. Хуҗина оператор вазифасын башкара. 2000 елның июнь аенда Азнакай районының «Көмеш су» программасы нигезендә авылга чишмә суы үткәрелә, «Янтарь» ҖЧШ рәисе булып Нурмиев Илгиз Тәлгат улы билгеләнә[183].

## § 7. Карамалы

Азнакай төбәге тарихында табигать атамасы авыл исеме булып китү очраклары шактый: Карамалы, Карамалы Елга, Мәлбагыш, Таллы Бүләк һәм башкалар. Һәр очракта авыл ни өчен шулай аталган дигән сорау туа. Карамалы тарихын өйрәнгәндә без моңа аеруча игътибар иттек.

Билгеле булганча, Карамалыдан ерак түгел Әсәй авылы урнашкан. XVIII гасыр ахырында (1795 ел) мондагы халыкның төп өлешен «типтәр»ләр (94 ир-ат һәм 84 хатын-кыз), калганын «башкорт»лар (43 һәм 29) тәшкил итә[184].

1816 елгы ревизия документында Әсәй авылында бары «типтәр»ләр генә күрсәтелә. Башкорт сословиесендәге кешеләр кая киткән соң?

Халык хәтерендә сакланган истәлекләр буенча, Карамалы авылы Әсәйдән күчеп утыручылар исәбенә барлыкка килгән. Бу, чыннан да, шулай. Мәктәп музеендагы кульязмада «башкорт»ларның хәзерге урынга 1805–1806 елларда күчеп утырулары турында әйтелә. Менә шуннан яңа авыл – Карамалы барлыкка килә.

Архив чыганагында Юрмый волосте Әсәй авылы биләмәчеләренең (вотчинникларының) яңа урынга җирне Генераль межалау тәмамлангач күчүләре турында әйтелә[185]. Бөгелмә өязендә бу чара XIX гасыр башында үтә.

[183] 1995 елда язылган авыл тарихының башлангыч чорына кайбер яңа мәгълүмат өстәдек. 1920 елдан соңгы чорны яктыртканда Илбәк авылы мәктәбе коллективы әзерләгән текстка таяндык.

[184] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 250–253 б.

[185] БР МА, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 127 б. а.

Димәк, Карамалының 1805–1806 елларда барлыкка килүе дөреслеккә туры килә.

Әсәй «башкорт»ларының яңа урынга күчеп утырулары җир мәсьәләсе белән бәйле. Хуҗалыклар саны арткан саен, якын-тирәдәге җирләр кими, ә бу исә һәр җир бүлүдә кыенлыклар тудырган. Шуңа күрә дә халыкның бер өлеше, рәсми органнар карары нигезендә, икенче урынга күчеп утыра. Елга буендагы әлеге урын элек-электән Карамалы Елга дип йөртелгәнлектән, яңа барлыкка килгән авыл да шулай аталган.



*Чыганакта «оной деревни выселились из деревни Асеевой после генерального межевания [земель]» дип әйтелә*

XX гасыр башына чаклы рәсми чыганакларда авыл нәкъ шулай, Карамалы Елга дип күрсәтелә. 1914 елда басылган бер статистик белешмәдә ул Карамалы дип кенә бирелә. «Елга» атама-кушымчасы тора-бара кулланыштан чыккан, рәсми органнар да моны таныган, дип уйларга кирәк. Шунысы кызык, Карамалы Елга атамасы бүгенге көндә дә бар, тик ул – 1920 елларда поселок буларак барлыкка килгән кечкенә авыл исеме. Карамалының кайчандыр Карамалы Елга дип йөртелүен хәзерге вакытта хәтта авыл картлары да хәтерләми. Истәлекләрдә авылның бер төрле (Карамалы), ә 1917 елга чаклы рәсми чыганакларда икенче төрле (Карамалы Елга) аталуы бу юллар авторыннан мәсьәләнең асылына төшенүен таләп итте.

1816 елда беренче тапкыр авылда (чыганакта Карамалы Елга) 67 ир-ат һәм 49 хатын-кыз (26 хуҗалык) теркәлә. Исемлек башында Мөхсин (49 яшь; ике хатынлы), Ихсан (34), Исхак (27) Гали (25; указлы мулла) Бүләковлар күрсәтелә[186]. Башка хуҗалыкларны санап үтәбез: Конгырбай Арысланбәков (1778–1813), Габделягъфәр Габдерәхимов (31), Габделмәҗит Бакиров (57), Зәбир Зөбәеров (41), Хәбибулла Баязитов (31), Габделхаликъ Яманголов (10), Солтанбәк Караголов (1743–1815), Нурулла Солтанбәков (39), Фәйзулла Солтанбәков (37; указлы азанчы), Госман Кадыров (44; ике хатынлы), Кыдрач Кадыров (31), Ильяс Кадыров (38), Абдул Караголов (1755–1812), Шәриф Караголов (65), Вәлиша Тимеров (37), Миңлегол Сабаев (75), Нәдерша Мөэминов

[186] Боларның атасы Бүләк Та[һ]иров Әсәй авылы биләмәчесе буларак 1789 елгы ике килешүдә (договорда) телгә алына (Кара: МИБ. Т. 5. М., 1960. С. 250–253).

(39), Хөрәмша Мөэминов (35), Исламгол Мөэминов (32), Мәхмүт Акколов (40), Кинҗәгол Акколов (27), Мөстәкыйм Мортазин (49). Юлдаш Курашов гаиләсе 1811 елда 9 нчы кантонга («Оренбург округы») күчеп утыра[187].

1850 елда Оренбург губернасы Бөгелмә өязенә кергән Карамалыда (чыганакта «Карамалы Илга») башкорт сословиесендәге 166 ир-ат һәм 156 хатын-кыз (35 хуҗалык) теркәлә. Алар 13 нче «башкорт» кантонының 3 нче юртасына карый. Алдарак телгә алынган указлы мулла Гали Бүләков 1843 елда мәрхүм булган. Габделкасыйм Фәйзуллин (42 яшь) 1828 елдан указлы мулла дип күрсәтелгән[188]. Мондагы җәмигъ мәчеттә имам һәм мөгаллим булып 1850 елдан Мөхәммәтситдыйк Мөхәммәдьяров тора. Мөәзин вазифасын Габделкасыйм Фәйзуллин башкара. Соңгысының уллары һәм оныклары Карамалы муллалары буларак билгеле[189].

1859 елның 26 июненә караган ревизия документында Самара губернасы Бөгелмә өязе составындагы бу авыл элеккечә Карамалы Елга дип языла. Монда башкорт һәм типтәр сословиеләрендәге татарлар 227 ир-ат һәм 206 хатын-кыз (36 хуҗалык) тәшкил итә. Ревизия документының титул битендә бу ике сословие татарлары «башкорт» дип язылган, чөнки 1855 елдан «типтәр»ләрне «Башкорт» гаскәренә кушалар. Шул чордан Карамалы халкы 23 нче кантонның 3 нче юртасы составына керә. Исемлек ахырында соңгы хуҗалык Бәләбәй өязенең Ямадыбаш авылыннан күчеп утырган указлы мулла М. Мөхәммәдьяров гаиләсе (3 ир-ат һәм 3 хатын-кыз; «типтәр»ләр) теркәлгән[190]. Ул килгәнче Карамалыда бары тик башкорт сословиесендәге татарлар гына яши. Әлеге ревизиядән соң җан башына 15 дисәтинә күләмендә җир бүленә.

1885 ел ахыры – 1886 ел башында Карамалы Сумароково волостенда зур авыллардан санала. Анда 412 ир-ат һәм 374 хатын-кыз (139 хуҗалык) исәпләнә. Сословиеләр буенча халык «башкорт»лардан (407 ир-ат һәм 369 хатын-кыз) һәм «типтәр»ләрдән (5 һәм 4) тора. Авылда бер лавка була, 35 хуҗалык 284 баш умарта тота.

Карамалы авыл җәмгыятенең 3315 дисәтинә (шуның 1326 дисәтинәсе Ык аръягында, Бәләбәй өязендә) җире була. Халык җир белән яхшы тәэмин ителгән. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка исәпләгәндә дә, ул 19,7 дисәтинә туры килә. Бары ике хуҗалыкның гына иманасы булмый. Имана җирләр, әйткәнебезчә, ир-атлар санына карап бүленгән. Моннан тыш, 1031,9 дисәтинә җир 133 хуҗалыкның шәхси милке санала. Алар аны, кирәк булса, сата алган.

---

[187] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 172 сакл. бер., 76–79 б.
[188] Шунда ук, 699 сакл. бер., 304–316 б.
[189] Шунда ук, И–295 фонд, 3 тасв., 5662 сакл. бер., 8 б.
[190] Шунда ук, И–138 фонд, 2 тасв., 757ж сакл. бер., 71–93 б.

Игенчелектән тыш, терлекчелек тә Карамалыда зур урын тота. Авыл халкы күп санда эш атлары (381 баш), мөгезле эре терлек (412), сарык (646) һәм кәҗә (331) асрый. Әмма, хуҗалыкларга карап, мал-туар саны шактый аерыла. 46 хуҗалык, мәсәлән, берәр, 53 хуҗалык икешәр-өчәр ат тота. Дүрт һәм аннан күбрәк атлы (22) бай хуҗалыклар азрак – 31.

Авыл халкының төп өлеше хәлле яши. Шул ук вакытта ярлы көн күрүче хуҗалыклар да була. Аларның эш атлары (7 хуҗалык) һәм кораллары (30-га якын) булмый, ә икесе йорт-җирсез көн күрә. Игенчелек белән бәйле төрле эшләргә яллану яисә һөнәрчелек белән шөгыльләнү бу хуҗалыклар өчен гадәти күренеш булып тора[191].

1889 елда Карамалыда 139 хуҗалыкта 810 кеше яши. Авылда мәчет һәм 2 су тегермәне була. Якында гына сәүдәгәрләр Белов һәм И.Н. Носов, мещаннар М. Бобров һәм Денисов, дворян П.Н. Ильинның имениеләре урнашкан[192].

Мещан Михаил Бобровны авылда белмәгән кеше, мөгаен, булмагандыр. Чөнки бик күп кешеләрдән ул 12 елга арендага җир ала торган булган. Икмәк үстереп, аны отышлырак бәягә сату – Бобровның төп шөгыле.

Гасыр ахырына Карамалы шактый зурая. 1897 елда авылда 172 хуҗалык, 559 ир-ат һәм 486 хатын-кыз исәпләнә. Бу күрсәткечләр буенча ул Сумароково волостенда дүртенче урында тора. Ә волостька ул чорда 11 авыл (икесе – татар, калганы урыс) керә[193].

1900 елгы мәгълүматларга таянып, авылның көнкүрешен тасвирлап үтик. Моннан алдарак, Карамалыда җәмигъ мәчет эшләп килүе хакында әйтелгән иде. Анда 1877 елдан Хөснетдин Габделкасыйм улы Солтанбәков муллалык итә. Әмма 1896 елда ул гаиләсен калдырып Оренбургка укырга китә һәм шуннан бирле читтә яши. 1900 елда авылда 52 яшьлек мулланың хатыны (36 яшь) һәм 8 улы (зурысына – 22, кечесенә 1 яшь) гомер кичерә. Аның хуҗалыгында 2 эш аты, сигез мөгезле эре терлек (шуның өчесе сыер), 17 баш сарык һәм 1 кәҗә була. Чәчүлекләре 20 дисәтинә тәшкил итә.

Авылның мөәзине – Мөхәммәтзакир (икенче чыганакта – Әхмәтзакир) Ситдыйков (47 яшь). Ул читтән күчеп килгән, Бәйрәкә мәдрәсәсен тәмамлаган. Монда ул балалар (барысы 30) укыту белән дә шөгыльләнә. Мөәзин хатыны (48 яшь), 3 улы һәм 3 кызы белән яши. Хуҗалыгы зур түгел.

Мөхәммәтзакир мөәзиннән тыш, авылда читтән килгән тагын ике кеше балалар укыта. Аларның беренчесе – Габделхак Ибраһимов (35 яшь). Аның

---

[191] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 258–265.

[192] Список населенных мест Самарской губернии по сведениям 1889 г. Самара, 1890. С. 85.

[193] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 155.

мәктәбенә 105 бала сабакка йөргән. Мөхәммәтзакир мөәзиннеке кебек, аның да хуҗалыгы зур булмый.

Укытучыларның соңгысы – Габделхаликъ Ибраһимов (32 яшь). Ул чыгышы буенча Сөендек авылы кешесе. Хатыны (29 яшь) белән бергә көз-кыш айларында (7 ай) өендә кыз балалар укыта. Әмма укытучылык белән ул буш вакытларында гына шөгыльләнә, ә болай күбрәк пыялачы буларак билгеле.

Карамалыда югарыда телгә алынганнардан тыш, читтән килеп төпләнгән тагын өч хуҗалык була. Алар барысы да – урыслар (П.Г. Дементьев, А.В. Горбунов һәм А.Е. Болотов). Соңгысы – сәүдәгәр, лавка тота һәм шул ук вакытта агач эше остасы да була.

Карамалыдагы сәүдәгәрләрнең икенчесе – Гариф Сәлимов (40 яшь). Аның да бакалея лавкасы була. А.Е. Болотовтан аермалы буларак, ул монда туып-үскән, сәүдәгәрлек төп шөгыленә әйләнгән.

Чәй-шикәр һәм башка вак-төяк тауарлар сатып алырга авыл кешеләре Гариф һәм Александр сәүдәгәр лавкаларына йөрсәләр, ярма ярдырырга кирәк булса, Гали байга мөрәҗәгать иткәннәр. Чөнки авылдагы бердәнбер ярма яргыч аның милке була.

Гали Дәүләтбаевның (46 яшь) хуҗалыгы авылда зурлардан санала. Ул хатыны (40), 3 улы һәм 3 кызы белән яши. Хуҗалыгында 11 эш аты, 6 сыер, 38 сарык, 7 кәҗә һәм 15 баш умарта була. Аның иманасында чәчүлекләр 17,75 дисәтинә тәшкил итә. 8 авылдашыннан арендага 24,5 дисәтинә җир алып, анда да мул итеп иген игә (21,5 дисәтинә). Тагын 2 дисәтинә чәчүлекләре читтән арендага алган басуларда була. Ул бер хезмәтче тота.

Кыш-көз айлары авыл кешеләре тукыма тукыганнар, җеп эрләгәннәр. Аннары аларны зәңгәр төскә манарга Фәйрүз Сәяффәровка (45 яшь) алып килгәннәр. Ул үз һөнәренең остасы саналган. Заказлары күбәйсә, 2–3 айга ярдәмче яллый торган булган[194].

Белешмә әдәбиятта бу төр кәсепчеләрнең хезмәте болай тасвирлана: «*Окраска производится таким образом: сначала протирается краска сквозь редкий мешок, для того, чтобы не было комьев, при чем по расчету на 2 фунта краски прибавляется 2 фунта ржаной муки. Эта смесь разводится в воде и оставляется в чану на 15–18 часов для скисания. Когда скисание закончится, то добавляется еще несколько ведерь воды, а затем, когда вода остынет настолько, что терпить рука, «мотушки» (пряжа) погружают в чаны (кубы). Для того, чтобы каждая «мотушка» покрасилась хорошенько, необходимо ее погружать раза 2–3*»[195].

[194] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 818 сакл. бер.
[195] Кустарные промыслы Уфимской губернии. Уфа, 1912. С. 95–96.

Ф. Сәяффәровның хуҗалыгы урта хәллеләрдән санала. Ул зур мәйданда (21,35 дисәтинә) иген игә, 2 ат, 3 сыер, бик күп вак-төяк маллар һәм 8 баш умарта тота. Гаиләсендә хатыны (40), 2 улы һәм 3 кызы була.

Инде манылган әзер тукымалардан күлмәк-ыштан яисә башка кием-салым тектерергә кирәк булса, авыл халкы Шәяхмәт Вилдановка (35 яшь) яисә Габделгалим Айчуаковка (41) барган. Беренчесе – ел буена тексә, икенчесе бу эшләрне бары кыш айларында гына диярлек (барысы 3–4 ай) башкара.

Тегүчеләр генә түгел, итек тегү остасы да була авылда. Габсаттар Хәкимов (62 яшь) бу һөнәр белән елга бер ай чамасы шөгыльләнгән.

Габсаттарның улы булса кирәк, аннан берничә йорт аша гына яшәүче Мофаздал Габсаттаров (35) чиләкләр ясап сата торган булган. Һөнәрчелек аның шактый вакытын (елга 5 ай) алган.

Иген мул уңган елны, авылда төзелеш эшләре киң колач җәйгән. Икмәк сатудан кергән акчага агач һәм башка төзелеш кирәк-яраклары сатып алганнар, балта осталары яллаганнар. Мондый осталар авылда берничә кеше була. Болар – Гали Сәетбатталов (48), Гариф Бадыкшанов (48) һәм Хөсәен Әхмәтвәлиев (30). Соңгысы пыялачы буларак та билгеле. Аннан башка авылда тагын бер пыялачы (Мозаффар Габсаттаров) була.

Аерым төр һөнәр ияләре исемлеге ахырында чабатачылар тора. Алар күп түгел, беренчесе – Әхмәткәрим Мөхәммәтов (47), икенчесе – Дәүләтгәрәй Шәмсетдинов.

Авылда күп мал-туар асраучы хуҗалыкларның шактый булуы күзгә ташлана. Мостафа Хәлиуллин (40 яшь), Габделгазиз Дәүләтбаев (49), Габделгани Дәүләтбаев (32), Габделгалим Айчуаков һәм тагын берничә хуҗалыкның эш атлары гына өчәр-бишәр баш исәпләнә. Әлеге кешеләрнең берәр хезмәтчесе була. Гариф Кәримов (45 яшь) – 7, Бәдретдин Әхмәтҗанов (53) – 7, Аймазетдин Аллабирдин (54) – 8, Габдрахман Галиәкбәров (50) 8 эш аты тота. Г. Кәримовтан башка, барысының да берәр ялчысы була.

Әмма болар иң эре хуҗалыклар түгел әле. Аеруча зурлар исәбенә Дәүләтбай Дәүләтшин, Әхмәтхуҗа Дәүләтшин, Вәлиәхмәт Игътисамов һәм Габдерәсүл Дәверов хуҗалыклары керә. Аларның һәрберсенә тукталып үтик.

Дәүләтбай Дәүләтшинга 29 яшь. Ул хатыны (23), кызы (4), атасы (75), анасы (65), 2 энесе (берсе солдатта) һәм җиңгәсе белән яши. Хуҗалыгында 31 ат (шул исәптән 6 эш аты), 32 мөгезле эре терлек (15 сыер), 100 баш сарык һәм 20 кәҗә була. Имана җирендә чәчүлекләре (чәчүлекләре тагын хуторында була, ул турыда алга табарак әйтелер) 28 дисәтинәдән артып китә. Яшь бай 5 ир-ат һәм бер хатын-кыз хезмәтче тота.

Әхмәтхуҗа Дәүләтшин (65 яшь) хуҗалыгы да зурлардан санала. Ул 20 ат (шул исәптән 13 эш аты), 37 мөгезле эре терлек (14 сыер), 120 баш сарык һәм 10 кәҗә асрый. Аның барлык чәчүлек мәйданы 40,90 дисәтинә тәшкил итә.

Иң зур умарталык (30 баш), мөгаен, Әхмәтхуҗа байныкыдыр. Д. Дәүләтшин кебек, ул да күп хезмәтче (3 ир-ат һәм 3 хатын-кыз) тота.

Вәлиәхмәт Игътисамов (45) та, Дәүләтшиннар кебек, зур мал-мөлкәткә ия. Аның хуҗалыгында 15 ат (шул исәптән 12 эш аты), 25 мөгезле эре терлек (4 сыер), 35 баш сарык, 16 кәҗә һәм 5 баш умарта исәпләнә. Чәчүлек мәйданының зурлыгы (36,49 дисәтинә) буенча, ул Дәүләтшиннардан гына калыша. Байның хуҗалыгында 4 ир-ат (икесе яшүсмер) хезмәтче эшли.

Габдерәсүл Дәверов авыл байлары арасында иң өлкәне (90 яшь) санала. Ул хатыны (60), 4 улы, кызы һәм 2 килене белән яши. Хуҗалыгында 15 ат (шул исәптән 11 эш аты), 17 мөгезле эре терлек (10 сыер), 120 баш сарык, 4 кәҗә һәм 17 баш умарта тота. Ул да шактый зур мәйданда (24 дисәтинә) иген игә. Әмма башкалардан аермалы буларак, хуҗалык эшләрен тулысынча диярлек (бер хезмәтче малайны исәпләмәгәндә) уллары белән башкарган.

Зур, бай хуҗалыклар турында сүз барганда, хезмәтчеләрнең күп булуын күрдек. Хезмәтче булып авыл кешеләре дә, мәсәлән, Сәхипгәрәй Гәрәев, читтән килүчеләр дә ялланган. Авыл халкының бер өлеше ел буена көнлекчелеккә йөри. Болар исәбенә Габделгазиз Садыйков (31 яшь), Габделгалим Сәетбатталов (33) һәм Шәйхетдин Шәмсетдинов керә.

Авыл ярлылары арасында чит төбәкләргә китеп төрле эшләргә ялланучылар (2 кеше) да була. Гыйльман Сәлмановның улы Самара губернасы Бозаулык өязендә – батрак, ә Нигъмәтулла Нәдершинныкы Мәскәүдә хезмәтче булып эшкә керә.

Карамалыда күп кенә (30-дан артык) хуҗалыкларның умарта тотуын билгеләп үтәргә кирәк. Умартачылык өчен шартлар гаять уңай була ул чакта. Шуңа күрәдер, 30 һәм аннан күбрәк баш умарта тотучылар (Әхмәтхуҗа Дәүләтшин, Әхмәтша Мөхәммәтҗанов) да була[196].

Карамалыда игенчелекнең торышын тасвирлаучы мәгълүматларга тукталып үтик. 1900 елның 1 октябрендә төзелгән документтан күренгәнчә, авылда солы, арыш, борай, борчак, тары һәм карабодай иккәннәр. Кара һәм соры туфраклы ашланган басуларда төп культура – арыш уңышы бер дисәтинәдән 25 (начар), 40 (уртача) һәм 50–60 (яхшы) потлап чыккан. Ә менә шундый ук туфракта, әмма тирес кертелмәгән басуларда арыш яхшы уңганда да 30–50 поттан артмый.

Икенче төп культура – солы уңышы белән дә шундый закончалык күзәтелә. Беренче очракта (басулар ашланган) унышның түбәне – 25, уртачасы – 65, яхшысы 90 пот тәшкил итә. Икенче очракта (басулар ашланмаган) туфракка карап, уңыш күпкә аерыла. Кара туфраклы басуларда яхшы уңыш – 50, комлы туфракта 80 пот тирәсе була.

[196] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 818 сакл. бер.

Калган культуралар (карабодай, борай, бодай, тары һәм борчак), арыш һәм солы белән чагыштырганда, шактый аз игелә. Карабодайны кара һәм соры туфракта, яхшы уңганда, 1 дисәтинәдән 60–70 пот алганнар. Комлы туфракта уңыш түбәнрәк (50 пот) була.

Карамалыда бөртеклеләрнең уңышын, кайбер авыллар белән чагыштырганда, югары дип әйтеп булмый. Азнакайда, мәсәлән, балчыксыл кара туфраклы ашланган басуларда төп культура – арыш уңышы бер дисәтинәдән 40 (начар), 90 (уртача) һәм 150 (яхшы) потлап чыккан. Күренгәнчә, шартлар бер үк төрле диярлек булса да, яхшы уңыш монда 90–100 потка күбрәк. Мондый зур аерманың сәбәбе нәрсәдә соң?

Карамалыда игенчелек технологиясе кайбер башка авылларга караганда түбәнрәк дәрәҗәдә була. Җирне нибары 2 карыш (1 карыш = 4,4 см) тирәнлектә (Азнакайда – 3,5 карыш) сукалаганнар. Басуларга 1897 елдан гына тирес кертә башлыйлар. Өч басулы чәчү әйләнеше системасы монда күпкә соңрак (1884 елдан) юл сала. Аңа чаклы булган чәчү әйләнеше чуар басу (документта «пестрополье») дип аталган.

Игенчелек кораллары исә тирә-як авылларныкыннан аерылмый. Кыр эшләре вакытында төп эш кораллары – сука, сабан һәм тырма. Тимер сабан авылда бер хуҗалыкта гына, ә чәчкечләр бөтенләй булмый. Игенчелек хезмәтен күпкә җиңеләйтердәй башка төр эш кораллары, 8 җилгәргечне исәпләмәгәндә, юк дәрәҗәдә.

XIX гасыр ахырынарак Карамалы тирәсендә хуторлар барлыкка килә. Алар арасында авылга якын булуы һәм зурлыгы белән А.П. Саватеевныкы аерылып тора. Ул 1882 елда Карамалы халкыннан сатып алган (сатып алучы дип аның атасы Саватей күрсәтелә) җир участогында, авылдан дүрт чакрым ераклыкта, Урсай елгасының уң яр буенда урнашкан була. Аның мәйданы 220 дисәтинә тәшкил итә. 1901 елда хуторда Александр Саватеевның 2 йорты, кухнясы, 3 амбары, бер кладовое һәм башка каралтылары була. Ул 21 ат (шуның 9 эш аты), 23 мөгезле эре терлек (10 сыер), 80 баш сарык, 2 дуңгыз һәм 15 баш умарта тота.

Игенчелек – Александрның төп шөгыле. Хутордагы игеннәр 61,5 дисәтинә мәйданны алып тора. Хуҗа күп санда эшчеләр яллаган. Кыр эшләре вакытында монда Карамалы һәм Митрәй авылы кешеләре эшләгән. Икмәкнең зур өлешен – кыш, ә калганын җәй – яңа уңыш өлгерер алдыннан саткан. Аның 1898 елда – 700, 1899 һәм 1900 елларда 1700-шәр пот икмәк сатуы билгеле.

Урсай елгасының уң ярындагы икенче зур хутор хуҗасы – алдарак телгә алынган Дәүләтбай Дәүләтшин. Әлеге хуторның мәйданы А. Саватеевныкыннан 10 дисәтинәгә зуррак. Ул да 1882 елда Карамалы авыл җәмгыятеннән сатып алган җир участогында урнашкан. Хутор 1889–1897 еллар арасында барлыкка килә.

Хуҗаның болай да авылда 3 йорты, 3 амбары, 2 сарае, бер кладовое һәм башка каралтылары була. Шул ук вакытта хутор хуҗалыгы да зур. Монда 2 йорт (берсе таштан салынган), 2 амбар, 4 сарай һәм башка каралтылар була. Ул су тегермәне дә тота. Байның үз ихтыяҗы һәм авыллардан килгән кешеләр өчен монда он тарттырганнар.

Әмма Дәүләтбай Дәүләтшинга иң зур табыш тегермәннән түгел, игенчелектән кергән. 1900 елда, мәсәлән, ул монда – 69, ә 1901 елда 57 дисәтинә иген (арыш, бодай, солы, борчак һәм карабодай) игә. Уңышның зур өлешен гадәттә кыш айларында Рус Шуганы һәм Сәпәй базарларында саткан. Бик аз күләмдә ул аны Бөгелмә базарына да алып чыккалаган. 1899 елда – 1500, 1900 елда – 1000, 1901 елда 1000 пот икмәк сатыла.

Авылда гына түгел, хуторда да байның мал-туары күп була. Анда барлыгы 50 ат (шул исәптән 28 эш аты), 24 мөгезле эре терлек (7 сыер), 128 баш сарык, 15 кәҗә исәпләнә. Аларны кышлату өчен ел саен болыннарда (мәйданы – 8 дисәтинә) бик күп печән хәзерләнгән.

Хуторның 34 дисәтинәсен урман-куаклыклар алып тора. Анда куе булып каен, имән, усак һәм юкә агачлары үсә. Агачларның яше 20 ел тирәсе, шуңа күрә алар киртә өчен генә яраклы. Монда хуҗаның ат көтүе дә йөргән[197].

Тагын ике хутор исә авылдан 6 чакрым ераклыкта урнашкан була. Аларның зурысы – дворян Николай Ильинныкы. Атасы Павел Ильин 1882 елда Карамалы халкыннан 4500 сумга 1500 дисәтинә җир сатып алганнан соң барлыкка килә ул.

Николай Ильинның ике зур хуҗалыгы (хуторы) була. Аларның берсе – монда, икенчесе (ул 460,10 дисәтинә генә, әмма төп санала) Әгерҗе авылы янында урнашкан. Баш контора төп хуторда (ул «Шкапский» дип атала) булса да, конторщик мондагысында яши.

Хутор янындагы 37,5 дисәтинә әрәмә Н. Ильин белән Карамалы халкы арасында низаг тудыра. Ике як та әлеге җирне үзенеке саный. Карамалы халкы аны П. Ильинга сатмадык дип тәкърарласа, Николай Ильин исә, атасы сатып алган җир участогына әрәмә дә керә дип, үзенекен итә. Соңгысы хәтта судка бирергә дә җыена. Әлеге низаг документта җир чикләре анык билгеләнмәгәннән килеп чыккан дип уйларга кирәк.

Петр Бобровның хуторы – күпкә кечерәк (75 дисәтинә). Карамалыдан көньяк-көнчыгышта яткан бу җирне ул 1894 елда Н.В. Николаевтан 1575 сумга сатып ала. Хутордан көнчыгышта штабс-ротмистр хатыны Анна Орлованың биләмәләре урнашкан. 1899 елда А. Орлова белән контракт төзеп, 360 сумга аның 30 дисәтинә җирен арендага ала. Үзенең хуторында һәм әлеге җирләрдә иген игеп, отышлырак бәягә аны базарларда сата торган булган[198].

[197] Шунда ук, 813 сакл. бер.
[198] Шунда ук, 812, 813 сакл. бер.

Авыл тормышында төрле бәла-казалар әледән-әле булып торган. Алар арасында еш кабатланганы – янгыннар. Статистик мәгълүматларга күз салсак, 1905–1912 еллар эчендә Карамалыда ун янгын чыгу очрагы теркәлгәнен күрербез. Барлыгы 85 хуҗалыкның йорт-каралтысына зыян килә. Иң зур янгын 1903 елда була. Ул чакта ярты авыл диярлек (74 хуҗалык) ут астында кала[199].

1910 ел Карамалы өчен зур вакыйга белән истәлекле – 2 нче җәмигъ мәчет ачыла. Аны салырга рөхсәт Самара губерна идарәсеннән 1909 елның 26 октябрендә, 5367 санлы отношение нигезендә бирелә. Яңа мәхәлләгә хатыйп итеп 1910 елның 27 декабрендә Габдерәфикъ Сәетягъфәров раслана. Аннан 18 көн алдарак мөәзин вазифасын Гайнетдин Сираҗетдинов үтәргә керешә. 1914 елның 18 ноябреннән имам һәм мөдәррис булып Мөҗәһит Хөснетдин улы Солтанбәков эшли.

Беренче мәхәлләдә элеккечә Хөснетдин Габделкасыйм улы Солтанбәков – муллалык һәм Әхмәтзакир Мөхәммәтсадыйков мөәзинлек итә. 1909 елның 12 июненнән Мирхатип Хөснетдинов икенче мулла вазифасын башкара. Хөснетдин хәзрәт озын гомер кичереп, 1923 елда 73 яшьтә вафат була[200].

Бу чорда Карамалы Сумароково волостенда зурлыгы буенча, Кәрәкәшледән кала, икенче урында тора. 212 хуҗалыкта 654 ир-ат һәм 430 хатын-кыз яши. Алар 3315 дисәтинә үз милкендәге җирдән файдалана. Волость идарәсе чиркәүле авыл Сумароковода урнашкан[201].

Совет чоры авыл тормышына күп үзгәрешләр кертә. 1920 елда Карамалы – 270 хуҗалыктан һәм 1394 кешедән торган авыл. Икенче совет халык санын алу вакытында (1926 ел) 244 хуҗалыкта 1317 кеше күрсәтелә. Моннан бүленеп чыккан Карамалы Елга поселогында 29 хуҗалыкта 136 кеше исәпкә алына. Авыл Бөгелмә өязе Азнакай волостена керә[202].

Репрессияләр башлангач авылдан иң беренчеләрдән булып Мияссәр Дусаев (мөәзин) һәм Харис Сәетовлар сөрелә. 1930 елда икенче категория белән раскулачивать ителгәч, мал-мөлкәтләре тартып алына, үзләрен исә Татарстаннан читкә алып китәләр[203].

---

[199] Поселенные данные о пожарности за 10 лет. 1903–1912 гг. Самара, 1914. С. 44–45.

[200] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер.

[201] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1910. С. 125.

[202] ТР ДА, Р–1295 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 107 б.

[203] Шунда ук, Р–1221, 3 тасв., 25 сакл. бер.

## § 8. Кәкре Елга

Кәкре Елга – элек-электән Азнакай төбәгендә зур урын тотып килгән авылларның берсе. Өч гасырдан артык тарихында үзенең кешеләре, хезмәт күрсәткечләре белән шактый танылган ул.

Кәкре Елга авылы кешеләре теркәлгән иң борынгы исемлек 1748 елга карый. Ул Кадермәт Теләнчин гаиләсеннән башлана. Аңа 75 яшь, Хәсән (50 яшь), Мостафа (40) исемле уллары була. Хәсәннең ир балалары – Шәрип (30; анықы Габделкәрим), Мөхсин (28), Габдессәлам (26), Габделмән (20), Габдулла (2), Мостафаныкы Габдрахман (6) теркәлгән. Кадермәт Теләнчинның туганнан туган энесе Гомәр Әзмәтов (25) була. Болардан соң Әлмәт Сәрмәтов («Сырметев»; 70), аның уллары Тимеркәй (45; аныкы Солтанморат, Сәлим, Миңлебай), Алтынбай (30), Кушай (25) күрсәтелгән. Исемлек ахырында Килмәкәй Юртаев (63) һәм аның уллары (Учюп (26), Йосыф (6), Кансөяр (2)) теркәлгән. Шулай итеп, Кәкре Елганың әлеге исемлегендә 22 ир-ат ясаклы татар күрәбез[204].


татара
Кадырметов Теленчин 75
у него дети
Асаин 50
Мустафа 40
Хасана дети
37462 Шарыпов 30
37463 Мухсин 28
37464 Абдусаломов 26
37465 Абдюлменов 20
37466 Абдулла 2
у Мустафы сын
37467 Абдрахманов 6

*Ясаклы татар Кадермәт Теләнчин гаиләсе теркәлгән 1748 елгы документ фрагменты. 1762 елдан алар типтәр сословиесендә теркәлә башлый*

Кадермәт Теләнчин һәм аның уллары – авылга төп нигез салучылар буларак билгеле. Шуңа күрә, 1762 елгы чыганакка таянып, бу нәсел турында тулырак мәгълүмат биреп үтик.

Кадермәт карт 1749 елда 76 яшьтә дөнья куя. Сигез елдан өлкән улы Хәсән дә вафат була. Хәсәннең Шәрип (1762 елда – 46 яшь), Мөхсин (44), Габдессәлам (42), Габделмән (36) һәм Габдулла исемле уллары кала. Шәрипнең үз хуҗалыгы, Габделкәрим (17), Габдеплатыйф (11), Габделваһап (9) һәм Габделмәҗит (3) исемле уллары була.

[204] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3793 сакл. бер., 14 б. а.–15 б.

Хәсәннең икенче улы Мөхсиннең, Шәриптән аермалы буларак, бары бер генә ир баласы – Габдерәшит (13).

Хәсән картның өченче улы Габдессәлам – Кәкре Елга мулласы. Мулланың өлкән улы – Габделгаффар (10), кечесе Габидулла (1) исемле. Алга таба китеп әйтик, нәсел агачының бу тармагыннан башка дин әһелләре дә чыгачак.

Хәсән картның дүртенче улы Габделмән дә өйләнгән, Габделҗәлил исемле 7 яшьлек улы була.

Кадермәт Теләнчиннән соң Әлмәт Сәрмәтов гаиләсе теркәлгән. Ул 1749 елда 71 яшьтә вафат була, нәселен уллары Тимеркәй һәм Алтынбай дәвам итә. Тимеркәйгә 1762 елда – 61 яшь, аның Солтанморат (26), Миңлебай (17) һәм Хәмит (4) исемле уллары була. 46 яшьлек Алтынбайның бу вакытта Габдерәшит (1) исемле бер генә улы күрсәтелә.

Кадермәт һәм аның нәселдәшләре – Кәкре Елга авылына нигез салучылар. Алар монда яши башлагач, озак та үтми, тирә-як авыллардан берничә хуҗалык күченә. Нәдер волостеның Туктар авылыннан – Биккенә Уразаев (46 яшь; улы Монасыйп) һәм Килмәкәй Юртаевлар (соңгысы – волость старшинасы), Якыйдан – Сөендек Шәрипов (36) һәм Нәдердән – Хәсән Мөслимов, Бакыйдан Габдессәлам (53; мулла) һәм Габделҗәлил (46) Сөләймановлар килеп утыра.

Килмәкәй Юртаев (1762 елда 79 яшь) гаиләсендә ир-атлардан Осип (Йосыф?; 42), Күчем (22) һәм Кансөяр (18) теркәлгән. Әлеге чыганакта авылда мәчет булуы турында әйтелә[205].

Кадермәт карт һәм аның нәселдәшләре кайдан һәм кайчан күчеп килгәннәр соң? Бу сорауга җавапны Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар» исемле хезмәтеннән табабыз.

«*Ерак бабасы булган Туеш Минзәлә ягындагы Бикбау авылында вә Байгилде бине Туеш Азалак авылында күмелгәннәр. Теләнченең Кадермәт илә Сәрмәкәй исемле угыллары Мәллә елгасының башында Кәкре Елга атлы бер авылга нигез салганнар. Кайбер җыентыкларда язылганнарга караганда, авылның нигезләнүе 1709 миләди/1121 һиҗри ел ахырында булган. Тирәягындагы җир, урман, печәнлекләрне һәм, гомумән, яхшы вә яман җирләрнең барчасын Надир бине Уразмәт (Уразмөхәммәд) атлы кешедән сатып алып, үзләренең милке иткән. Сәрмәкәйнең Әлмәт*[206] *исемле угылы, бу якларда*

---

[205] Шунда ук, 3801 сакл. бер., 1194–1196 б.

[206] «Сәрмәкәйнең Дусмәт (Дусмөхәммәт) исемле улы шушы якларда, беренчеләрдән буларак, Россия дәүләтенә сусар (байбак) тиресе белән ясак түләгән. Аның улы Алтынбай җиде бала үстергән: Исмәгыйль, Мәрханә, Габдеррәшит, Җәгъфәр, Ягъкуп, Яхъя, Тәхаветдин. Бертуганы Тимеркәй бине Дусмәтнең Миңлекәй исемле бер улы һәм чибәрдән-чибәр кызлары булган», дип яза Фәрит Яхин (кара: Яхин Ф.З. Әдәби-мәдәни тарихыбызда: гыйльми-текстологик эзләнүләр һәм тикшеренүләр. Казан: ТӘһСИ, 2018. 90 б.). Бу өзектә кайбер хаталар күзәтелә. Алдарак архив чыганак-

*беренчеләрдән буларак, Русия дәүләтенә сусар тиресеннән ясак биргән. Алтынбай бине Әлмәт бине Сәрмәкәйнең балалары Исмәгыйль, Мәрхәбә, Габдеррәшид, Җәгъфәр, Ягъкуб, Яхья, Тәхаведдин булып*[207]*, туганы Тимеркәй бине Әлмәт балалары: Миңлекәй һәм башкалар. Кадермәт бине Теләнче угыллары Мостафа вә Хәсән. Габдессәлам бине Хәсән замандашлары арасында бер мөдәррис булып танылып, Кәкре Елга авылында озак вакытлар укыту белән шөгыльләнеп, 1204/1790 елда вафат булган»*[208].

Әлеге мәгълүматлар китапта Кәкре Елга авылы мөдәррисе Габдессәлам Хәсәновның нәсел тарихын яктыртканда бирелә. Шәҗәрәне схемага салсак болай була: Туеш–Байгилде–Теләнче–Кадермәт–Хәсән–Габдессәлам. Димәк, Кадермәт Теләнчин – Туеш картның оныгының улы. Туеш карт – Бикбауда (хәзерге Минзәлә районы авылы), аның улы Байгилде Азалакта (Сарман районы) гомер сөргән. Байгилденең оныгы Кадермәт Кәкре Елгага нәкъ шул Азалак авылыннан күчеп килгән булуы мөмкин.

Бикбау авылы – Җәнәй, Азалак – Байлар, Кәкре Елга Нәдер волостена керә. Шулай итеп, шәҗәрә татар миграциясен чагылдыра, Азнакай төбәге авылларының барлыкка килүендә Байлар волосте халкы ролен чираттагы мисалда күрсәтә.

Ризаэтдин Фәхретдин хезмәтендә Кәкре Елганың Кадермәт белән Сәрмәкәйнең старшина Нәдер Уразмәтовтан сатып алган урман-жир биләмәсендә барлыкка килү тарихын бары тик риваять дип карарга кирәк. Нәдер старшина – төбәк тарихында тирән эз калдырган, чыгышы буенча Казан өязенең Арча юлы Адай авылына караган татар морзасы. 1735 елда хөкүмәт карары нигезендә хәзерге Әлмәт, Лениногорск һәм өлешчә Азнакай белән Бөгелмә районнары чикләрен кертеп ясаклы татарлар волосте оештырыла һәм аларның старшинасы исеме белән Нәдер волосте дип атала. Кәкре Елга аңарчы ук, Юрмый волосте биләмәчеләре кулында булган җирдә барлыкка килә. Нәдер волосте оешканда аның составына өлешчә юрмыйлылар (биләмәчеләр) рөхсәте белән яисә аннан башка килеп утырган, өлешчә аларга оброк түләүче татарлар да керә. Шуңа күрә риваятьтә Кәкре Елганың барлыкка килү тарихын старшина Н. Уразмәтов белән бәйләп карау бөтенләй үк нигезсез түгел[209].

---

лары Сәрмәкәйнең улы – Әлмәт, Әлмәтнеке Алтынбай дип күрсәтте. Нәкъ, Р. Фәхретдиннең «Асар» китабында язганча булып чыкты.

[207] 1795 елгы ревизия документында Алтынбай Әлмәтовның (79 яшь) уллары Габдерәшит (34), Мерәс (1786 елда вафат), Җәгъфәр (27), Яхья (25), Мәрхәбә (19), Якуп (17), Сәмигол (7), Митрәй авылы кешесенә кияүгә чыккан кызы Гөлгизәр күрсәтелә (кара: БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 24 сакл. бер., 150 б.).

[208] Ризаэддин Фәхреддин. Асар. 1 нче том. Казан, 2006. 75–76 б.

[209] Нәдер волосте тарихын бу юллар авторы махсус өйрәнде, киләчәктә аны аерым китап итеп чыгарырга өметләнә.

Югарыда сүз Кадермәт Теләнчин һәм аның белән бергә күчеп килгән ясаклы татарлар турында барды. Бу төркем соңрак типтәр сословиесендә теркәләчәк. Ясаклы татарларның икенче төркеме Казан өязенең Җөри юлындагы Кәрәкәс, Азалак һәм Иске Игенә авылларыннан 1722 (Азалактан) һәм 1738 (Кәрәкәстән) елларда күчеп килә[210], боларның сословиесе үзгәрмәячәк, дәүләт крестьяннары дип аталачак (алга таба сүз шулар турында барачак).

1748 елда яңа барлыкка килгән (чыганакта «новопоселенная») Кәкре Елгада түбәндәге 43 ир-аттан торган икенче төркем ясаклы татарлар теркәлә: 1) Рахманкол (53 яшь; улы Сөбханкол) һәм Бикмәт (63; уллары Абдикәй, Зәйнекәй) Тинмәтовлар; 2) Мөслим Бикмәтов (43; улы Исманкол); 3) Әбүбәкер Бигиев (72; уллары Биккенә (аныкы Салан), Мәсгут); 4) Абдул Ишмәтов (77; уллары Уразман, Рамазан, Касыйм, Рамаш, Гыймран); 5) Сөләйман Туйкин (78); 6) Абдул Мурслин (55); 7) Абдулхәлим Абдулкин (58); 8) Әмәкәй (52), Даут (20), Зәет (17) Ярмәковлар. Монда ук Абдул (0,5 яшь; Назир Ярмәков улы); 9) Абдул Гомәров («Амелков», 47; уллары Әхмәр, Мәхмүт); 10) Әмин Сөләйманов («Адмелка», 62; уллары Ишбулды, Монасыйп); 11) Мөслим Байбахтин (98; уллары Биктимер (аныкы Сәеткол), Морат, Сөбханкол, Рахманкол), ятим Моталлапны (13; Аднаш Иртуганов улы) уллыкка алган; 12) Абдул Мостафин (67; уллары Биккол, Бикмәт); 13) Рахманкол (16) һәм Биккенә (9; мәрхүм Госман Бигиев уллары); 14) Йөзәй (13; мәрхүм Кадермәт Уркин улы)[211]. Күпчелек хуҗалыклар Кәрәкәскә карый, беренче (Азалак авылыннан) һәм соңгы (Иске Игенә) хуҗалыклар гына башка авыллардан күчеп уттырган.

Кәкре Елга халкының әлеге төркеме, Казан өязенең Арча юлына караган төркемне дә кертеп һәм кайбер үзгәрешләр кичереп, 1762 елда 91 ир-аттан тора. Аларның килеп утыруы Юрмый волосте старшинасы Хасбулат Мөтеков белән бәйле. Югарыда сүз барган татарлар Җөри юлының Рәмкол Теләкәев, калганнары Арча юлының Токтамыш Сәфәров йөзлегенә (сотнясына) карый. Исемлектә беренче булып Бакир Бигиев (90; уллары Биккенә, староста Мәсгут, Мәксүт и Мәҗит) теркәлгән. Әлеге документтан Кәкре Елга кешеләренең Сара[й]лы (Мортаза Акаев), Сәмәкәй, Теләнче Тамак, Тымытык (Тимер Морзаев) авылларындагы башкорт сословиесендәге татарлар белән никах мөнәсәбәтләре күзәтелә[212]. Соңгы факт бу «башкорт»лар (волостьлардагы татар биләмәчеләре сословиесе шулай аталган) белән ясаклы татарлар арасында бернинди менталь аерма булмавын күрсәтә.

---

[210] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1155 сакл. бер., 674 б. а., 697. Бу төркем Казан өязе ясаклы татарларының 1722 елдан килә башлавын документ раслады, димәк, Р. Фәхретдиннең Кәкре Елга 1709 елда нигезләнгән дигән фикере чынбарлыкка туры килә.

[211] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1143 сакл. бер., 454–456 б. а.

[212] Шунда ук, 1207 сакл. бер., 477 б.; 1155 сакл. бер., 674 б.а.; 3795 сакл. бер., 316–323 б.

Шулай итеп, 1762 елда Кәкре Елгада 2 төркем ясаклы татарлар яши. Беренчесе – составына Кадермәт Теләнчин кергән Уфа өязе ясаклы татарлары (1762 елда 34 ир-ат), икенчесе – Казан өязе ясаклы татарлары (127 ир-ат). Уфа өязе ясаклы татарлары гасыр ахырынарак типтәр сословиесендә күрсәтелә башлыйлар. Элек Казан өязенә кергәннәр административ яктан Уфа өязенә күчерелә, әмма ясаклы татарлар (дәүләт крестьяннары) булып калалар.

Ясаклы татарларның Казан өязе төркеме 1722 һәм 1738 елларда күчеп килүен белгәч, Кәкре Елгага Уфа өязе ясаклы татарлары Кадермәт Теләнчин һәм Әлмәт Сәрмәтовлар 1709 елда нигез салган дип әйтә алабыз. Чөнки Казан өязе төркеме 1722 елда килә башлаганда үк авыл булган, шуңа күрә Ризаэтдин Фәхретдин хезмәтендәге бу дата (1709 ел) шик уятмый.

Е. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы башланганда авыл кешеләренең бер өлеше (ясаклы татарлар) Уфа өязе Казан юлы Нәдер волосте старшиналары Йосыф Нәдеров һәм Габделҗәлил Сәетовлар командасында тора. Й. Нәдеров һәм волостьның күп кенә авыллары патшага тугрылыклы кала, ә менә Кәкре Елга фетнәчеләргә кушыла.

Гасыр ахырында (1795 ел) Кәкре Елга чагыштырмача зур авыллардан санала. Бер документтагы мәгълүматлар буенча анда 68 хуҗалыкта 218 ир-ат һәм 243 хатын-кыз яши. Сословиеләр буенча алсак, халыкның күпчелеген ясаклы татарлар (48 хуҗалык; 142 ир-ат һәм 145 хатын-кыз), калган өлешен «типтәр»ләр (20; 76 һәм 98) тәшкил иткәнен күрәбез[213].

Әлеге мәгълүматларны тулыландырып үтик. 1795 елгы ревизия документында ясаклы татарлар 144 ир-ат һәм 145 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 131 һәм 137) теркәлгән. Исемлектә беренче хуҗалык булып Биккенә Бакиров (1722–1790; ике хатынлы), аның уллары Габдерәшит (46), Габдерәхим (25), Габделкәрим (19) язылган. Балтан Акбулатовның (63) улы Габдерәшит Балтанов (37; ике хатынлы) авылдашлары арасыннан «скаскоподатель» итеп сайланган. 1796 елда 2 ир-ат Корыалачык авылына (Стәрлетамак округы) күченеп китә[214], шуңа күрә ир-атлар башка чыганакларда 142 кеше күрсәтелә.

Болар ясаклы татарлар булды, типтәр сословиесендәге татарларга күчәбез. Шул ук 5 нче ревизиядә (1795 ел) алар 2 исемлектә теркәлгән. Беренче исемлектә 73 ир-ат һәм 97 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 56 һәм 78) күрсәтелә. Алар старшина Ишмөхәммәт Йөзәев командасына (1 нче санлы) карый. Исемлектә Габдрахман Мостафин (55; аның улы Нигъмәтулла), Шәриф (79; өч хатынлы), Мөхсин (77; ике хатынлы), мулла Габдессәлам (1790 елда вафат; ике хатынлы; олы улы Габделгаффар – мулла), Габделмән (1795 елда вафат), Абдулла (1791 елда вафат; ике хатынлы) Хәсәновлар, Солтанморат (59) һәм Миңлебай (50; ике хатынлы) Тимеркиннәр, Алтынбай

[213] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 293 б. а.
[214] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 214–228 б.

Әлмәтов (79), Усип (?75), Күчем (1790 елда мәрхүм), Кансөяр (51) Килмәкәевлар, Габдерәшит Биккенин (29), Кушим (мәрхүм) һәм Рәфикъ (42) Урайсәиновлар, Бикмәмәт (34) һәм Килмәмәт (мәрхүм) Киләкәевлар хуҗалыклары күрсәтелә[215]. Әлеге Урайсәиновлар һәм Киләкәевлар 1762–1782 еллар арасында килеп утырганнар. Аерым исемлек белән теркәлгән Хәлил Балтаев гаиләсе (3 ир-ат һәм 1 хатын-кыз) бирегә Өсәйдән күчеп килгән, старшина Зәбир Зөбәеров командасына (5 нче санлы) карый[216]. Ике исемлекне берләштергәч, Кәкре Елгада типтәр сословиесендәге татарлар 76 ир-ат һәм 98 хатын-кыз тәшкил итә.

Шулай итеп, төгәллек керткәч, 1795 елда Кәкре Елгада барлыгы 218 ир-ат һәм 243 хатын-кыз яши булып чыга. Сословиеләрне санап үткәндә, беренче итеп ясаклы татарларны (дәүләт крестьяннарын) күрсәтергә кирәк, чөнки алар күпчелекне тәшкил итә.

1816 елгы мәгълүматлар аерым игътибарга лаек. Кәкре Елгада 101 хуҗалык була. Аларның яртысыннан артыграгын ясаклы татар (56), калганнарын «типтәр» (45) хуҗалыклары тәшкил итә. 1795 ел белән чагыштырганда, халыкның гомуми саны ике тапкырдан күбрәккә арткан. Ясаклы татарлар – 136 ир-ат һәм 156 хатын-кыздан тора, Кәкре Елга волостенда санала. Алар (Габделкәрим Биккенин, Рәхмәтулла Мәҗитов, Гыймран Абдуллин, Минлигул Рамазанов, Хәсән Касыймов, Вәлиша Ишбулдин, Сәгыйть Бикколов һәм башкалар) лашман бурычын (чыганакта «лашманная повинность») башкаручылар дип күрсәтелгән. «Сказкоподатель» буларак, ревизия мәгълүматларын раслап документка Хәмит Мансуров кул куя[217].

Типтәр» сословиесендәге татарлар (121 ир-ат һәм 115 хатын-кыз) старшина Ишмөхәммәт Йөзекәев командасында тора. Хуҗалык башлыкларының исемнәрен күрсәтеп үтик. Болар түбәндәгеләр: 1) Нигъмәтулла Габдрахманов (50; ике хатынлы); 2) Фәтхулла Нигъмәтуллин (26); 3) Габделкәрим Шәрипов (70); 4) Габделваһап Шәрипов (62; ике хатынлы); 5) Галиакбәр Габделваһапов (30); 6) Нигъмәтулла Фәйзуллин (21); 7) Габделваһап Габделмәҗитов (37); 8) Габделхаликъ Габделмәҗитов (26); 9) Габделсадыйк Габделмәҗитов (24); 10) Габдерәфикъ Габделлатыпов (26); 11) Габдерәшит Мөхсинов (66); 12) Габделгаффар Габдессәламов (63); 13) Габдессаттар Габдессәламов (42; ике хатынлы); 14) Зәйнетдин Габдессәламов (36); 15) Шәмсетдин Габдессәламов (30); 16) Габдерәхим Габделмәнов (36; ике хатынлы); 17) Сәйфулла Абдуллов (42); 18) Хисмәтулла Абдуллов (28); 19) Ишкуат Солтанмратов (42; ике хатынлы); 20) Курамша Миңлебаев (32); 21) Габдессәлам Миңлебаев (29); 22) Габделнәфыйкъ Миңлекәев (26); 23) Габделлатыйп Габделнасыров (19); 24) Габдерәшит Алтынбаев (54); 25) Ягъфәр Алтынбаев (47); 26) Яхья

[215] Шунда ук, 24 сакл. бер., 147–152 б.

[216] Шунда ук, 403 б.

[217] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 197 сакл. бер., 547–563 б.

Алтынбаев (45); 27) Мәрхәбә Алтынбаев (39); 28) Якуп Алтынбаев (37); Сәмигул Алтынбаев (33); 30) Габделҗәлил Усипов (?62); 31) Габдрахман Габделҗәлилов (40); 32) Габдерәхим Кансөяров (48); 33) Сәйфулла Кансөяров (36); 34) Нигъмәтулла Кансөяров (25); 35) Төхфәтулла Кансөяров (21); 36) Фәтхулла Кансөяров (19); 37) Бикбау Кучемов (39); 38) Габдерәшит Биккенин (49); 39) Габделнәфыйкъ Рәфиков (30); 40) Әлмөхәммәт Кушимов (44); 41) Мөхәммәдьяр Кушимов (29); 42) Мөхәммәтрәхим Кушимов (26); 43) Биктимер Киләкәев (54). Ревизия документына «сказкоподатель» Габдерәшит Мөхсинов нәсел тамгасын куйган[218]. «Типтәр»ләрдән ике хуҗалыктан торган бер нәсел (Хәлил Балтаев; 6 ир-ат һәм 4 хатын-кыз) аерым исемлектә теркәлгән[219]. Шулай итеп, ике исемлек буенча типтәр сословиесендәге татарлар барлыгы 127 ир-ат һәм 119 хатын-кыз (45 хуҗалык) тәшкил итә.

1814 елның 30 август манифесты нигезендә типтәр сословиесенә язылган, Оренбург казна палатасының 1818 елның 17 август карары белән читтән («из границы») килеп утырган 2 кеше аерым ревизия документында теркәлгән. Алар Халит Даутовның хатыны һәм улы Әхмәтша (2) дип күрсәтелә[220].

Авылның көнкүрешенә кагылышлы мәгълүматларга тукталыйк. Игенчелек һәм терлекчелек – халыкның төп шөгыле. Хатын-кызлар кыр эшләреннән буш вакытта йоннан, киндер басаларыннан җеп эрләгәннәр, киндер сукканнар һәм тукыма тукыганнар. Типтәр сословиесендәге ир-атлар Оренбург шәһәрендәге ике мең атлы типтәр полкына чират буенча хәрби хезмәткә алынганнар, полк чыгымнарын түләргә мәҗбүр ителгәннәр. Ясаклы татарлар казнага оклад (салым) түләгәннәр. Авылдан дүрт чакрымерактарак, Мәллә елгасында, «типтәр»ләрнең тегермәннәре була.

Бу чорда мулла булып Шаһиәхмәт Габделгаффаров тора. Аңа чаклы бу вазифаны – атасы Габделгаффар һәм бабасы Габдессәлам башкара. Шаһиәхмәт нибары 7 ел эшли, 1833 елда муллалыктан алына[221].

XIX гасыр уртасына Кәкре Елга төбәктә иң зур авылларның берсенә әйләнә. 1859 елда анда 162 хуҗалыкта 508 ир-ат һәм 493 хатын-кыз яши. Әлеге күрсәткечләр буенча ул бары Стәрлетамактан (Югары һәм Түбән Стәрле еш кына шулай языла; 224 хуҗалык, 714 ир-ат һәм 743 хатын-кыз) һәм Азнакайдан (213; 549 һәм 554) гына калыша[222]. Элеккечә бер мәчет эшли. Шәрәфетдин Габделвахитов һәм Сәгъдетдин Габделҗаббаровлар – мулла, Шәмсетдин Габделвахитов мөәзин булып тора. Шәрәфетдин хәзрәт шул ук

[218] Шунда ук, 168 сакл. бер., 740–752 б.

[219] Шунда ук, 774–776 б.

[220] Шунда ук, 453–454 б.

[221] БР МА, И–2 фонд, 1 тасв., 2693 сакл. бер.

[222] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 22–36.

елның мартында гаиләсе белән Әсәйгә күчә; үзе, аннары улы Мәхмүт анда мулла булалар. Кәкре Елгада исә икенче мулла вазифасын 1864 елдан Мәйлүн Мөхәммәтгәрәев башкара[223].

1884 ел ахыры – 1885 ел башында Кәкре Елга 275 хуҗалыктан, 681 ир-ат һәм 658 хатын-кыздан тора. Ул Әлки, Кама-Исмәгыйль, Түбән Якый, Мәлбагыш һәм Моревка авыллары белән Әлки волостена керә. Хуҗалыклар саны буенча Кәкре Елга волостьта Кама-Исмәгыйльдән генә калыша. Авылда 3 хуҗалык лавка тота, сәүдә итә. 19 хуҗалыкта 88 баш умарта була.

Кәкре Елга авыл җәмгыятенең ул чорда 7401 дисәтинә уңайлы һәм 207 дисәтинә уңайлы булмаган җирләре була. Аның 2800 дисәтинәсен – сөрүлекләр, 1492 дисәтинәсен – печәнлекләр, 2009 дисәтинәсен – урман һәм 1300 дисәтинәсен йорт яны җирләре һәм көтүлекләр алып тора. Монда җир белән тәэмин ителү дәрәҗәсе шактый югары була. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка бүлгән очракта, ул 23,0 дисәтинә туры килә. Бу күрсәткеч волостьның башка авылларында ике-өч тапкыр кимрәк.

Хуҗалыклар буенча җирнең күләменә, ягъни иманалар санына игътибар итик. Авылда 265 хуҗалыкның иманасы була. Шуларның 115-ендә ул – берәр, 88-ендә – икешәр, 41-ендә – өчәр, 21-ендә дүртәр яисә аннан артыграк. Мондагы бер имана ул чакта 14,2 дисәтинә була, димәк, хуҗалыклар җир белән яхшы тәэмин ителгән. Ә менә эш кораллары исә 155 хуҗалыкта гына җитәрлек була, калганнарында – өлешчә (44) яисә бөтенләй юк (35).

Авыл халкы күп итеп эш атлары (540), мөгезле эре терлек (326), сарык (1138) һәм кәҗә (294) асрый. Әмма, хуҗалыклар буенча алсак, мал-туар саны төрлечә булуын күрәбез. Эш атларын гына алыйк. 61 хуҗалыкта алар бөтенләй булмый. Шул ук вакытта 66 хуҗалык – берәр, 88 хуҗалык икешәр-өчәр ат тота. Авылда 4 һәм аннан күбрәк атлылар да була. 30 хуҗалык дүртәр эш аты асраса, 20 хуҗалыкның исә аннан да артып китә.

Шунысына игътибар итик, Кәкре Елгада 58 хуҗалыкның ни эш аты, ни сыеры булмый. Өстәвенә, 26 хуҗалык йортсыз (янгын җиде йортны көлгә әйләндерә), тагын 5 хуҗалык землянкаларда яши. Андыйлар ярлылардан саналган.

Җире аз яисә бөтенләй булмаган һәм мал-туарсыз хуҗалыкларның күпчелеге үз авылдашларына һәм якын-тирә алпавыт имениеләре-хуторларына я булмаса авылларга төрле эшләргә ялланган, кайберләре һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Статистик мәгълүматлардан күренгәнчә, Кәкре Елгада 55 кеше (шуларның 19 читкә китеп) игенчелек белән бәйле эшләргә ялланган. Тагын 41 кеше (өчесе читтә йөреп) һөнәрчелек белән шөгыльләнә[224].

---

[223] БР МА, И–295 фонд, 4 тасв., 5304 сакл. бер.; И–138 фонд, 2 тасв., 757 сакл. бер.

[224] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 10–17.

Гасыр ахырында төбәкнең административ-территориаль бүленешендә кайбер үзгәрешләр була. Минзәләбаш, Мәсгут, Илбәк, Кәтем, Урсалыбаш, Сөләй һәм Шарлама авылларыннан торган Минзәләбаш волосте бетерелә. Минзәләбаш Чубар Абдул һәм Буралы авыллары белән бергә яңадан Уфа губернасы Минзәлә өязенә кайтарыла. Шул ук вакытта Мәсгут волосте оештырыла. Аның составына элек Минзәләбаш волостена кергән кайбер авыллардан тыш, Әлки волостеннан Кәкре Елга да күчә. Ә Шарлама, киресенчә, Әлки волостена керә.

1897 елда Кәкре Елга – 346 хуҗалыктан, 816 ир-ат һәм 826 хатын-кыздан торган авыл. Анда мәчет, 3 мәктәп эшли. Бу чорда Мәйлүн Мөхәммәтгалиевтән башка, Сәетбаттал Сәмигуллин да имам-хатыйп һәм мөдәррис вазифасын башкара. Беренчесенә – 61, икенчесенә 38 яшь була. Мөәзин хезмәте Гыйматдин Мөхәммәтшәриповка (аңа 53 яшь) йөкләнгән.

Авылның 6335 дисәтинә җире, 3 тегермәне була. Моннан бераз ерак-тарак Мөрсәлимовның (ул Мөссәлимов дип тә күрсәтелә) 600 дисәтинәдән торган хуторы урнашкан. Хутор аша агучы Мәллә елгасында ул тегермән тоткан. Кәкре Елга җирләрендә Бабин фамилияле кешенең дә тегермәне була.

Волостьта Мөрсәлимовныкы кебек зур җир биләмәсеннән торган икенче хуторның (570 дисәтинә) хуҗасы – дворян Головинский. Әлеге дворянның Тымытык волостенда да хуторы (534 дисәтинә) була. Исәп буенча өченче хутор Мөхәммәтсадыйковныкы дип күрсәтелә, әмма ул аның милке түгел. Урсалы елгасы буендагы 60 дисәтинә җирне ул Сөләй авылы кешеләреннән арендага алган.

Югарыда Кәкре Елгада 3 мәктәп булуы хакында әйтелгән иде. Шундый ук санда мәктәпләр Мәсгуттә генә була. Калган авылларда (Кәтем, Сөләй һәм Урсалыбаш) исә алар икешәр. Ир һәм кыз балаларның мәктәпләре аерым урнашкан. Монда шәригать кануннары гына түгел, кайбер дөньяви фәннәр дә өйрәнелгән.

Волость үзәге Мәсгуттә һәр җомга базарлар үткәрелгән. Тирә-яктан һәм ераклардан килеп сәүдә итүчеләрдән гөрләп торган авыл бу көнне. Эш кәгазьләре белән монда урнашкан волость идарәсенә килгәннәр. Земство станциясе дә биредә була[225].

1900 елда Бөгелмә өязендә хуҗалыклар санын алу үткәрелә. Өязнең статистика бүлеге хезмәткәрләре һәр авылда булып, хуҗалыкларны язып чыгалар. Соңыннан халык санын алу документлары архивка тапшырыла. Ни сәбәпледер, Татарстан дәүләт архивында Кәкре Елга авылы буенча бу документлар сакланмаган.

Бердәнбер документ 1901 елга карый. Анда тимерче Садретдин Исмәгыйлов хакында мәгълүматлар бирелә. Аның 15 ел элек төзелгән тимерчелеге була. Тимерче сүзләренә караганда, ул ел буена 200 сумлап акча

[225] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 139–140.

эшләгән. Шул ук вакытта чыгымнары да зур икән. Күмер сатып алу өчен генә дә 70 сумлап акча тотылган. Башка кирәк-яракларның бәясе 21 сумнан арткан. Боларга салым һәм страхование түләүләрен дә кушсаң, чиста табышның күпме генә каласын чамаларга була. Аңа сабан, тырма, урак, чалгы, тәгәрмәч, самауыр, комган, йозак, чиләк һәм башка тимер әйберләрне ремонтларга китерә торган булганнар. Ат дагаларга да монда килгәннәр. Ара-тирә заказ да алгалаган. Барлык кирәкле эш кораллары үз кул астында була аның[226].

Ул чорда әледән-әле янгын чыгып, хуҗалыкларга зур зыян китерә торган булган. 1903–1912 елларда гына Кәкре Елгада 8 тапкыр ут чыгып, барлыгы 62 хуҗалык яна. Иң зур янгыннар 1905 һәм 1908 елларда була. Беренчесеннән – 14, икенчесеннән 43 хуҗалык зыян күрә[227].

Авыл халкы печәнлекләр, утын һәм төзелеш материаллары сорап Кәтем урман хуҗалыгына (лесничествосына) мөрәҗәгать итә торган булган. Алар арасыннан бер документта түбәндәге кешеләрнең исемнәре телгә алына: Әхмәтгалим Әхмәтшин, Ногман Сабитов, Дәүләтша Хөрмәкәев, Кашшафетдин Миңлегалиев, Сафиулла Гарифуллин, Габдрахман Габсаттаров, Сәлахетдин Гарәфетдинов, Сафиулла Әхтәмов, Гыйлаҗетдин Хөснетдинов, Әхмәтҗан Әхмәдишев, Миһран Фәсхетдинов, Мөнәвир Ганиев, Мотыйгулла Сәхипгәрәев, Кашшафетдин Шиһабетдинов, Шиһабетдин Шәмсетдинов, Галим Ситдыйков, Мортаза Нигъмәтуллин, Әхмәтгалим Әхмәтшаһиев һәм Кәрим Әхмәтгәрәев[228].

1902 елда Гыйматдин мөәзин вафат була, ике елдан аның урынына Мәйлүн мулланың улы Әхмәтзәки мөәзин һәм мөгаллим итеп сайлана. Мәйлүн мулла үзе дә озак тормый, 1905 елның декабрендә дөнья куя. Ярты елдан имамлыкка Солтангәрәй Галиәскәров указ ала[229].

Бу чорда укыту эше элеккегечә югары дәрәҗәдә булмый, ахры, өч мәктәптән берәү генә кала. Алдарак әйтелгән Сәетбаттал мулла сәүдә белән шөгыльләнгән, Сәпәйдә склад-амбарлар тоткан, бу мәшәкатьләр аның күп вакытын алган дип уйларга кирәк.

1910 елда Кәкре Елга – Мәсгут волостенда иң зур авыл. Анда 382 хуҗалыкта 893 ир-ат һәм 901 хатын-кыз яши. Авыл шактый зур булуга карамастан, бары бер мәчет һәм аның каршында мәктәп эшли. Этап юлы авыл аша узганлыктан, монда этап йорты (пункты) урнашкан. Кәкре Елга һәм Кәтем җирләрендә Бабин, Мәрдәншин һәм Петров берәр тегермән тота. Кәтем авыл җәмгыятенең дә үз тегермәне була[230].

---

[226] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 990 сакл. бер.

[227] Поселенные данные о пожарности за 10 лет. 1903–1912 гг. Самара, 1914. С. 38–39.

[228] ТР ДА, 1124 фонд, 28 сакл. бер.

[229] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер., 104 б. а.–105 б.

[230] Список населенных пунктов Самарской губернии. Самара, 1910. С. 114.

1910 елның май ахыры Кәкре Елга халкы өчен аеруча истәлекле була – икенче җәмигъ мәчет салырга рөхсәт алына. Төзелеш ике елга сузылган, ахры, чөнки бу мәхәлләгә иң беренче мөәзин һәм мөгаллим булып Госман Шәйхетдинов 1912 елның ноябрендә раслана. Ә инде 1913 елның февраленнән имам-хатыйп һәм мөдәррис вазифасын Галимхан Гаделгәрәй улы Мәмлиев башкарырга керешә. Галимхан хәзрәт дөнья куйгач (1922 ел), имам итеп Госман мөәзинне куялар, ә аның урынына мөәзинлеккә 32 яшьлек Габделгазиз Сабирҗанов сайлана[231].

Билгеле булганча, 1906 елның 9 ноябрендә патша министры П.А. Столыпин крестьяннарга община җирен биләүдә яңа тәртип кертүче закон чыгара. Аның буенча, крестьян үз теләге белән общинадан чыгып, үзенә тиешле имана җиргә хуҗа була ала. Әгәр дә имана төрле урында булса, аны бер урыннан бүлеп бирүне таләп итә алган.

Кәкре Елга һәм Кәтем авылларыннан үз җирләрен хосусыйлаштыручы аерым кешеләр турында документлар юк диярлек. Әмма 1910 елда чыккан статистик белешмә мондагы җирләрнең хосусый милекчеләр кулында булуын күрсәтә. Кәкре Елга сәүдәгәре Минһаҗетдин Миңлеголовның үз иманасын шәхси милек итеп рәсмиләштерүе билгеле. Общинада калган хуҗалыклар булганмы, тәгаен билгеле түгел.

Алдарак Кәкре Елгада этап йорты урнашканлыгы хакында әйтелгән иде. Бөгелмә-Минзәлә юлыннан этап белән баручы тоткыннар һәм аларның сакчылары монда туктап хәл ала торган булган. Әлеге йортта кемнәр генә туктамаган да, күпме күз яше түгелмәгәндер!

1911 нче елның кыш аенда күпләрне сискәндергән вакыйга була – төбәкнең Яланкул авылы мулласы Зәкиҗан Шаһгәрәев (аның турында мәгълүматлар Күктәкә авылы тарихында бирелә) кулга алына һәм этап белән озатыла. Әлеге күренекле шәхес тоткынлыктан чыккач «Төрмәләр хатирәсе» исемле китап яза. Анда бик күп кешеләр, Кәкре Елгадагы туган-кардәшләре, аерым алганда, Фәезхан хаҗи телгә алына.

Фәезхан хаҗи белән гадәти булмаган шартларда очрашуы хакында Зәкиҗан Шаһгәрәев түбәндәгеләрне яза: «*Без инде Кәкре Елга авылына килеп җитәбез. Минем олаучы абзый кардәшем Фәезхан хаҗига төшүебез турында солдатлар белән сатулаша башлады. Күп сатулашканның соңында, солдатлар анда кереп чәй эчәргә, әмма кич этапный йортка барып куну шарты белән риза булдылар. Без барып туганым Фәезхан хаҗига төштек. Ул вакыт Фәезхан хаҗи кайсыбер кунаклары белән ишек алдында иде. Без кереп туктагач, алар безне танымыйча бераз карап тордылар. Чөнки алар безне болай гадәти рәвештә көтмәгәннәр. Аларча, мин арестан киемендә, җәяү, берничә мылтыклы, сөңгеле солдатлар арасында богаулы булган хәлдә булачак, имеш. Озак карап торгач, мине танып туганым Фәезхан хаҗи*

[231] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер., 112 б. а.–113 б.

*бөтен битен тутырган күз яшенә буялып һич сүз әйтә алмыйча килеп күреште. Шул арада өйдән туганым Шәрипҗан килеп чыгуга, әнкәй дә монда икәнне аңлап хәтсез шатланмыш идем. Өйгә керүгә рәфикамның да монда икәнен әйтеп мине янә шатландырдылар. Хәзер безнең дөнья тигезләнде. Яшь ярымлык улым Мөхәммәтришат та монда иде. Без монда рәхәтләнеп кунак булып, мунчалар кереп йөрдек. Ярый, бары бу авылда безнең агай-эне, кардәшләр бик күп булганнан, безнең монда икәнне яшерергә тырыша идек...».*

Күренгәнчә, З. Шаһгәрәевне Кәкре Елга белән бик күп җепләр бәйли. Монда аның өчен ихлас борчылалар, тиешенчә сый-хөрмәт күрсәтәләр. Менә шулай әлеге төбәкне сискәндергән вакыйга мәгълүм сәбәпләр аркасында Кәкре Елга тарихында да урын ала. Алда тасвирланачак тагын бер вакыйга язмабызда телгә алынган Минһаҗетдин Миңлегалиев белән бәйле. З. Шаһгәрәев кебек, бу шәхес тә төбәк тарихында тирән эз калдыра.

Билгеле булганча, 1905 елда Россиядә революцион хәрәкәт башлана. Патша хөкүмәте аны туктату өчен төрле чаралар күрә. Халык хәрәкәтен репрессияләр белән генә җиңеп булмасын аңлаган хөкүмәт шул елның декабрендә Дәүләт Думасына сайлаулар турында закон чыгара.

Патша законы гадел булмый. Ул Россиянең яртыдан күбрәк халкын сайлау хокукыннан мәхрүм итә. Хатын-кызларга, солдатларга, матросларга, укучыларга, җирсез крестьяннарга һәм батракларга сайлау хокукы бирелми. Законда алпавытларга һәм капиталистларга зур өстенлек карала. Алар Дәүләт Думасына эшче һәм крестьяннарга караганда да күбрәк депутат җибәрү хокукына ия була. Сайлауларның турыдан-туры үткәрелмәвен дә билгеләп үтәргә кирәк. Крестьяннарга дүрт баскычлы, эшчеләргә өч баскычлы, алпавытларга һәм буржуазиягә ике баскычлы сайлау системасы урнаштырыла. Алпавытлар һәм капиталистлар үзләренең вәкилләрен губерна җыелышына җибәреп, депутатларны шунда сайлый торган булганнар. Крестьяннар исә башта волость җыелышына вәкилләр җибәргәннәр, анда өяз җыелышына вәкилләр сайланган, аннары өяз җыелышында губернага сайлаулар үткәрелеп, бары губерна җыелышына үткән вәкилләр генә, ниһаять, үзләре арасыннан Думага депутат сайлаганнар.

Күренгәнчә, авыл кешесе өчен Думага депутат булып сайлану гаять четерекле булган. Шуңа да авыллардан сайланган депутатлар күп түгел. Алар арасында татарлар аз. I–IV чакырылыш Дәүләт Думаларына Самара губернасы татарларыннан депутатлыкка нибары ике кеше сайлана. Аларның беренчесе – Әлмәт авылы (хәзерге Әлмәт шәһәре) мулласы Һади Атласи. Ул 1907 елда II чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты булып сайлана. Татар халкының күренекле җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм тарихчы-галиме Һади Атласиның тормыш юлы һәм эшчәнлеге безгә әдәбияттан мәгълүм.

Самара губернасыннан чираттагы депутат – Кәкре Елга авылы бае Минһаҗетдин Миңлегалиев. Ул 1912 елда IV чакырылыш Думага сайлана.

Ф.А. Брокгауз һәм И.А. Ефрон чыгарган «Новый энциклопедический словарь» исемле китапның 14 нче томында Минһаҗетдин бай турында мәгълүматлар бик кыска: 1857 елда туган, өй шартларында белем алган, сәүдәгәр һәм җир биләүче. Думада мөселман фракциясендә тора.

Өстәмә мәгълүматларны ревизия документларыннан һәм башка чыганаклардан табабыз. Минһаҗетдин 33 яшьлек Миңлегали Галиәскәров гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Бу вакытта аның Шәмсебану исемле апасы һәм Мөхәммәтсадыйк исемле абыйсы була. Әлеге нәсел «Туеш шәҗәрәсенең» Хәсән тармагына карый. Шәриф Хәсәновның икенче улы – Габделлатыйф, Габделлатыйфның улы Галиәскәр була. Димәк, Миңлегали Хәсән карттан соң – дүртенче, ә Минһаҗетдин үзе бишенче буын булып тора[232].

Думага сайланганчы Минһаҗетдин Миңлегалиев Бөгелмә өяз земствосы депутаты – «гласные» сыйфатында шактый танылган, төбәкнең иҗтимагый тормышында актив катнашкан шәхес булган. 90 дисәтинә җир биләгән, 6 ат, 5 сыер һәм башка мал-туар асраган. Хезмәтче тоткан, урып-җыю вакытында көнлекчеләр яллаган. 1901 елдан алып мануфактура һәм бакалея товарлары белән сәүдә иткән[233].

IV чакырылыш Думада татарлар, Минһаҗетдинны да кертеп, нибары биш кеше була. Алар монда мөселман фракциясен тәшкил итә. Фракциянең рәисе – дворян Котлымөхәммәт Батыргәрәй улы Тәфкилев, секретаре – Ибниәмин Әхтәмов. Икесе дә Уфа губернасыннан сайланган. Мөселман фракциясендә торучы өченче депутат Габделлатыйф Хәбибулла улы Байтирәков та әлеге губернадан була. Ә менә фабрика директоры, җир биләүче Гайса Хәмидулла улы Еникәев Оренбург губернасыннан сайланган. Бу дүрт депутат элегрәк «Иттифак» фиркасендә торган.

Думадагы мөселман фракциясенең эшчәнлеге турында мәгълүматлар бик аз. Февраль буржуаз революциясеннән соң властька Вакытлы хөкүмәт килгәч, әлеге фракция эшчәнлеген активлаштыра. Аның каршында бөтен Россия мөселманнарының Үзәк бюросы (Центральное бюро мусульман всей России) оештырыла. Үзәк бюро бөтен Россия мөселманнарының корылтаен җыю турында карар чыгара. Әлеге карарны тормышка ашыру өчен урыннарда милли комитетлар да оештырыла.

1916 елда Россиядә авыл хуҗалыклары исәбен алу үткәрелә. Аның документларына таянып, Кәкре Елганың ул чордагы социаль-икътисади торышын кыскача тасвирлап үтик.

Авылда 415 хуҗалык, 829 ир-ат һәм 1020 хатын-кыз теркәлә. Әлеге саннар хатын-кызларның 191 кешегә күбрәк булуын күрсәтә. Шактый ир-ат су-

---

[232] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 24 сакл. бер., 147 б. а.–148 б.; 757 сакл. бер.

[233] Кәримов Т. Дума депутаты биографиясенә өстәмә штрихлар // Маяк, 1997 ел, 9 гыйнвар.

гышка алынган, шуңа күрә аерма зур. Тирә-як авылларда да шундый хәл күзәтелә.

Кәкре Елгада 817 ат (шул исәптән 749 эш аты), 649 мөгезле эре терлек (560 сыер), 4426 сарык һәм 233 кәҗә исәпләнә. Чәчүлекләр 2413,25 дисәтинә тәшкил итә. Шуның яртысыннан күбрәген арыш (1247,10 дисәтинә), калган өлешен солы (471), борай (270,10), карабодай (157,30), борчак (159,30), тары (56,20) һәм сабан бодае (52,25) алып тора. Ул Сөләй (322 хуҗалык), Мәсгут (261), Урсалыбаш (197), Илбәк (190), Кәтем (190) һәм Тархан (24) авыллары белән бергә Мәсгут волостена керә. Моннан тыш, волостьта тагын ике хутор була. Аларның хуҗалары – Г.Т. Мусин һәм Г.С. Мөссәлимов[234].

1920 елда үткәрелгән беренче совет халык санын алу вакытында Кәкре Елгада 454 хуҗалык һәм 2029 кеше исәпләнә. Әмма 1921 елгы ачлык шактый гаиләнең кырылуына китерә. Шуңа күрә 1926 елда, элеккеге белән чагыштырганда, күпкә аз хуҗалык (барлыгы – 356) һәм халык (1581) теркәлә. Авыл Бөгелмә кантоны Азнакай волостена керә[235].

Утызынчы елларда язмабызда телгә алынган депутат М. Миңлегалиевнең улы Галиәскәр «кулак» мөһере сугылып Себергә, Красноярск өлкәсенә сөрелә. НЭП елларында ул Бөгелмәдә яшәгән, сәүдә белән шөгыльләнгән. Пекарня һәм кибет тоткан. Аның торган йорты Бөгелмә шәһәренең Ленин урамындагы «Ашыгыч ярдәм» станциясе урнашкан җирдә була. Сөргеннән соң Уфа шәһәренә кайтып яши башлый; йорт сатып алып, өч баласын да укыта.

Миңлегалиевнең башка балалары да читтә гомер сөрә. Фәретдин исемле улы Урта Азиядә яши, шул китүдән яңадан кайтмый. Фатиха исемле кызы сөргеннән соң Әлмәткә якын бер поселокта улы Тимер белән яши[236].

Репрессия корбаннары болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Аларның исемнәрен һәм язмышларын ачыклау – киләчәк эше.

Бүгенге көндә Кәкре Елгада җиде йөзләп кеше яши. Урта мәктәп, мәчет, почта бүлеге, фельдшерлык-акушерлык пункты, клуб, китапханә һәм ике кибет эшли. Мондагы «Марс» күмәк хуҗалыгына күп еллар Хәбиб Әгъләм улы Баянов җитәкчелек итә. Югары нәтиҗәләре белән танылган бу хуҗалык җөмһүриятебездә алдынгылардан санала. Сүз уңаеннан әйтик, Хәбиб әфәнде – язмабыз башындарак телгә алынган Нәдер волосте старшинасы Килмәкәй Юртаев нәселеннән[237].

---

[234] ТР ДА, 993 фонд.

[235] ТР ДА, Р–1295 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 108 б.

[236] «Ак таплар»(Басылганга кире кайтып) // Маяк, 1997 ел, 21 август.

[237] Авыл тарихы 1996 елда язылды, соңгы чорда кайбер өстәмәләр кертелде.

## § 9. Күктәкә

Хәзерге Күктәкә элек өч өлештән (Күктәкә, Яланкүл һәм Икмән Елга) торган. Күктәкә һәм Яланкүл аерым авыллар буларак йөри, совет чорында гына соңгысының, Күктәкә белән кушылганлыктан, авыл статусы бетерелә. Ә менә Икмән Елга турында төбәктә яшәүчеләр бөтенләй диярлек белмәскә мөмкин, чөнки ул – Күктәкәнең борынгы очы. Аны рәсми территориаль берәмлек буларак 1875 елда җир межалаганда таныйлар. Ул чакта хәзерге территорияне өч авыл җәмгыятенә (Күктәкә, Яланкүл һәм Икмән Елга) бүләләр. Бу бүленеш 1917 елга чаклы рәсми рәвештә үзгәртелмәсә дә, Икмән Елга атамасы кулланылмый диярлек. Укучыга аңлашыладыр ки, Күктәкә турында мәгълүматлар биргәндә, без Яланкүлне һәм өлешчә Икмән Елганы читтә калдыра алмыйбыз.

Югарыда күрсәтелгән үзенчәлекне истә тотып, авылга кайчан нигез салынганлыгын ачыклыйк. Татарстан дәүләт архивында саклануčы 1900 елгы документ аерым игътибарга лаек. Аннан күренгәнчә, Яланкүл 1700 елда, монда сигез гаилә күченеп килгәч барлыкка килә. Документта сословиеләре – башкорт, милләте татар (чыганакта «разряд крестьян – башкиры, народность – татары») дип күрсәтелүче бу кешеләр – әлеге урынга иң беренче күчеп утыручылар.

1720 еллар тирәсендә Яланкүлдә яшәүчеләргә тагын җиде гаилә өстәлә. Болары да татарлар, тик сословиеләре (чыганакта «разряд») генә башка – типтәр.

1761 елдан Күктәкәдә 11 гаиләдән торган ясаклы һәм йомышлы («служилый») татарлар яши башлый[238].

Шулай итеп, авылның Яланкүл ягы борынгырак. Яланкүл белән Күктәкәне бербөтен итеп санаганда, авылга нигез салынган датаны һич икеләнмичә 1700 ел дип күрсәтә алабыз.

Ясаклы һәм йомышлы татарлар Күктәкәнең Икмән Елга өлешендә яши. 1764 елгы чыганакта Стәрле һәм Кәкре Елга авыллары белән беррәттән русча «Ик-Игень Илга тож» дип язылган авыл да күрсәтелә. Анда ул вакытта 36 ясаклы һәм 26 йомышлы ир-ат татар яши[239]. Бу авылның Икмән Елга булуы бик мөмкин. Күктәкәдәге Икмән Елгада да, монда яшәүчеләрнең дә сословиеләре охшаш булуын искә алырга кирәк. Безгә билгеле башка чыганакларда ул кабат телгә алынмый.

Авылның атамасы турында фикеребезне әйтеп үтик. Күктәкә Юрмый волосте территориясендә барлыкка килә. Бу һәм күрше волостьлардагы атамаларны күзаллау кайбер нәтиҗәләр ясарга мөмкинчелек бирә.

---

[238] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 884 сакл. бер.

[239] РБАДА, 1274 фонд, 196 сакл. бер.

Күктәкә атамасына охшаш яисә тәңгәл килгән авыл атамалары еш булмаса да, очрый. Күктау һәм Күктәкә, мәсәлән, шуларның кайберләреннән[240].

Алар ничек авыл атамалары булып киткәннәр соң? Авыллар, билгеле булганча, күпчелек очракта хуҗасы билгеле, әмма буш яткан җирләрдә барлыкка киләләр. XVIII гасыр башында Юрмый волостенда буш яткан җирләрнең һәрберсенең – елгамы, күлме, таумы яисә башка табигый урынмы – үз атамасы була. Бу атамалар аларның нинди дә булса үзенчәлекләреннән яисә шул урыннарга кагылышлы аерым фактлардан, вакыйгалардан чыгып үзеннән-үзе, стихияле рәвештә барлыкка килә.

Күктәкә авылы нәкъ шундый атамалы урында нигезләнгән дип уйларга кирәк. Болай фикер йөрткәндә Яланкүл авылы атамасының килеп чыгышын да күз алдында тотабыз. Авыл шундый атамалы күл янында барлыкка килә. XIX гасыр башларында, мәсәлән, күлнең озынлыгы – 50, киңлеге 30 сажин тәшкил итә. Аның суы чиста, хәтта эчәргә яраклы санала.

Бу күл атамасы, үз чиратында, ничек барлыкка килгән соң? Беренче карашка, гап-гади, яланда урнашкан яисә ялан кебек киң күлне аңлата шикелле. Әмма кайбер чыганакларга күз салу икеләнү уята. Аларның берсендә күл урысча «Илан-куль», икенчесендә «Еланлыкуль» дип бирелә. Үзеннән-үзе, күлдә еланнар тереклек итүдән чыгып бирелмәдеме икән бу исем, дигән уй туа.

Күчеп килүчеләрнең исемнәрен, кайдан килгәннәрен 1762 елгы ревизия документларына таянып белә алабыз. Алга таба шул документлар турында сүз барачак.

Шуны искәртеп үтик, бу документларда Күктәкә телгә алынмый, чөнки авыл атамасы хәзерге вариантта формалашып бетмәгән була. Хәзерге территориягә Казан өязенең Җөри юлыннан килеп утырган 3 төркем халыкның авыллары рәсми чыганакларда Иген Елга (чыганакта «Ик Иген Илга тож») һәм Яңа Иген Елга («Новой Ик Иген Илга тож») дип атала.

Иген Елга авылы ясаклы татарлары (1762 елда 25 ир-ат) Казан өязенең Җөри юлы Урта Иске (чыганакта «Среднее Уску»), Искебаш («Ускубаш»), Аксар («Аксарино Асеево тож»; хәзерге Зәй районы авылы) һәм Иркупер авылларыннан була. Исемлектә беренче булып Сөләйман Сөбәев (48 яшь; уллары Мөрсәлим, Мөстәкыйм, Мостафа) теркәлгән. Ул Урта Иске авылыннан, беренче хатыны Азнабикә Мөслимова (45; сословиесе буенча башкорт) Тымытык авылыннан, икенчесе (ясаклы татар) – Дүсемнән (Арча юлы). Урта Искедән тагын Мөслим Сөбәев (47; улы Сәгыйть), Ишембай Бикбов (18) һәм Биктимер Якупов (41; уллары Сәлим, Зәбир, Нәзир), Искебаштан – Әмир Ирбулатов (50; уллары Хәлил, Йөзекә[й]) һәм Сәлим Ямкин (44; улы Сәгыйть), Аксардан – Даут Алиев (31; уллары Габдерәшит, Габделмән, Габделҗәлил, Мостафа), Имәнлебаштан – Бикбау Миңлебаев (21; улы Мөлек), Иркупердән

[240] МИБ. Т. 4. Ч. 1. М., 1956. С. 268–287.

Ишбулды Пулатов (26) килеп утыралар[241]. Ясаклы татарларның монда килеп утырулары очраклы түгел: алар Юрмый волосте биләмәчеләре белән элек-электән тыгыз аралашып яшәгәннәр, никах мөнәсәбәтләре урнаштырганнар.

Иген Елгага килеп утырган икенче төркем йомышлы татар (26 ир-ат) сословиесенә карый, Салкын Чишмә (чыганакта «Новопоселенной Гареловый Елник Студеной Ключ тож»; Казан өязе) авылы кешеләре була. Исемлектә өч хатынлы Бакир Кадралеев (63 яшь; уллары Ибрай, Гомәр, Госман, Әбләзи, Габдессәлам, Габдерәшит, Габдрахман), Мәхмүт Токтаралиев (52; уллары Мортаза, Мостафа, Бикчәнтәй), Минкә Аитов (45; уллары Ишмөхәммәт, Бикмөхәммәт, Мөхәммәтдәмин) һәм соңгысының туганнан туган энесе Бикбау Рысаев (28) күрсәтеләләр[242].

Яңа Иген Елгага Урсалыбаш авылы ясаклы татарлары (11 ир-ат) нигез сала. Болар ике хатынлы Хәлил Муллин (42 яшь; уллары Габдессәлам, Баки, тәрбиягә алган улы Мерәс Уразаев), Аптикәй Салин (81; улы Габдерәшит (ике-хатынлы), оныклары Габделваһап, Габбәс), ике хатынлы Аит Исәнов (66; улы Әлмөхәммәт) һәм Рәкәй Надыров (23) була[243].

Югарыда сүз хәзерге Күктәкә территориясенә караган ике авыл (Иген Елга һәм Яңа Иген Елга) турында барды. 1762 елгы чыганакта тагын Яланкүл һәм Туймәк авыллары телгә алына, соңгысында яшәүчеләр соңрак Яланкүл авылына карый булып чыкты.

Яланкүлгә 1762 ел алдыннан Юрмый волосте старшинасы Хасбулат Мөтеков һәм башка биләмәчеләр рөхсәте белән адмиралтей促ствога беркетелгән йомышлы татарлар (14 ир-ат; Йосыф, Әмир һәм Бакир Сәиновлар гаиләләре) килеп утыра. Алар чыганакта русча «Бай Улаллары» дип язылган авылдан, Арча юлының Биккол Азиков йөзлегенә (сотнясына) карый[244].

Ык елгасы һәм Яланкүл күле янында урнашкан Туймәк (чыганакта «Тоймеково, что на озере Яланкуле, по реке Ику») авылында 1762 елда 49 ир-ат ясаклы татар яши. Исемлектә беренчеләр булып Саты[й] (18 яшь) һәм Күсәк (14; Исәнгилде Йосыпов уллары), Ямангол (30; «сукыр») белән Гайса (12; Табак Янсаев уллары) күрсәтелә. Туймәккә Әлкидән берничә гаилә (23 ир-ат; Сәфәр Уразмәтов һәм башкалар) һәм Корчайдан 5 ир-ат күчենә[245]. Димәк, барлык ир-атның яртысыннан азы гына (21) 1747 елга чаклы гына монда яшәгән, ә калганы (28) 1747–1762 еллар арасында күченгән булып чыга.

Ревизия материалларын анализлап, хәзерге Күктәкә авылы территориясенә күпчелек йомышлы һәм ясаклы татарларның 1747–1762 еллар арасында килеп утырганын белдек. Бу чыганакта Күктәкә атамасы телгә алын-

[241] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3795 сакл. бер., 309–310 б. а.
[242] Шунда ук, 313–314 б. а.
[243] Шунда ук, 311–312 б. а.
[244] Шунда ук, 412–413 б.
[245] Шунда ук, 488–492 б.

мады. 1795 елда мондагы күпчелек халык Иген Елга һәм Ал[л]абирде авыллары исемнәре белән 4 исемлектә теркәлә. Боларның һәрберсенә тукталып үтик.

Беренче исемлектә 28 ир-ат һәм 25 хатын-кыз йомышлы татар сословиесендә күрсәтелә. Авыл атамасы русча «Ик Иген Илги Алаберды тож» дип язылган[246].

Икенче исемлектә 7 ир-ат һәм 9 хатын-кыз йомышлы татар (Әзи Мәксүтов балалары һәм оныклары) теркәлгән. Бу юлы авыл атамасы русча «Алаберда Иген Илги» дип бирелгән[247].

Өченче исемлектә 47 ир-ат һәм 50 хатын-кыз йомышлы татар исәпкә алынган. Аларның берсе – ревизия исемлеген хакимияткә тапшыручы (чыганакта «скаскоподатель») Муканай Мостафин. Авыл атамасы чыганакта «Аллаберды Куры Ел[га] Тамак тож» дип күрсәтелгән[248].

Дүртенче исемлектә 27 ир-ат һәм 25 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 54 һәм 42) ясаклы татар теркәлгән. Исемлек башында Биктимер Якупов (1741–1785; уллары Сәлимҗан, Зәбир, Нәзир) гаиләсе турында мәгълүмат бирелә. Даут Галиев («Алеев»; 63 яшь) гаиләсен билгеләп үтик. Ул уллары Габделмән (42), Габделҗәлил (40), Сөләйман (7), киленнәре һәм оныклары белән яши. Мостафа, Рәхмәтулла һәм Габидулла Даутовлар 1793 елда Минзәлә округына караган Наратлы авылына күчеп утыралар. 20 ир-ат һәм 20 хатын-кыз 1787 елда Уфа наместничествосының казна палатасы указы нигезендә ясаклыдан йомышлы татар сословиесенә күчерелә. Болар – бертуган Ибрай, Габдерәхим, Әбләзи (фамилияләре күрсәтелмәгән), Балта Гомәров, Аблай, Шәфи һәм Мәхмүт Солтановлар, Мортаза Мәхмүтов, Ишмөхәммәт, Бикмөхәммәт һәм Гали Минкиннар. Авыл атамасы русча «Ик Ини[249] Елга озеро Алаберды тож» дип язылган[250]. Югарыда күрсәтеп үткән кешеләрнең икесе (Биктимер Якупов, Даут Галиев) 1762 елгы ревизия документында Аксар авылыннан күчеп килгән дип әйтелгән, авыл атамасы русча «Ик Иген Илга тож» дип язылган иде.

Шулай итеп, 1795 елда хәзерге Күктәкә урынында йомышлы һәм ясаклы татар сословиеләренә кергән 4 төркем халык яшәгән. Иген Елгага өстәп Аллабирде атамасы (гидроним) да кулланыла башлаган.

Тагын кемнәр яшәгән? 1795 елгы документта беренче тапкыр авылның хәзерге атамасы телгә алына һәм Бәләбәй округыннан типтәр сословие-

[246] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 22 сакл. бер., 162–163 б.
[247] Шунда ук, 223–224 б.
[248] Шунда ук, 185–189 б.
[249] «Игин» булырга тиеш. Бары бу чыганакта гына «Ини» дип языла.
[250] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 211–213 б.

сендәге татар Бикташ (27) һәм Ильяс (22) Рахманколовларның монда күченүләре турында әйтелә[251].

Яланкүлдә исә бу вакытта башкорт һәм типтәр сословиеләренә кергән татарлар яши. «Типтәр»ләрнең саны (33 ир-ат һәм 26 хатын-кыз) «башкорт»ларныкыннан (22 һәм 30) зуррак була.

1795 елгы ревизия документы буенча, Яланкүл «типтәр»ләре старшина Зәбир Зөбәеров командасында (5 нче команда) торалар. Исемлектә беренчеләр булып Саты[й] Исәнгилдин (51 яшь) һәм Ямангол Табаков (63) хуҗалыклары исәпкә алынган[252]. Болар алдарак Туймәк авылының 1762 елгы ревизия документында телгә алынган иде. Димәк, шул чыганакта күрсәтелгән Туймәк Яланкүл белән бер территориядә урнашкан, шуңа Туймәк атамасы әһәмиятен югалткан, кулланыштан чыккан. Алга таба Яланкүл дә Күктәкә белән бербөтен саналып, бу топоним да бөтенләйгә юкка чыга[253].

Яланкүлдә 1795 елда ясаклы татар Ярмөхәммәт Туйкин (41 яшь; Туйкә авылыннан күчеп килгән) гаиләсе яшәвен дә күрсәтеп үтик. Аның гаиләсе хатыныннан (Әгерҗедә туып-үскән), улы Хәбибулладан (7) һәм 2 кызыннан тора[254]. Ярмөхәммәт – Туйкә авылына нигез салучы йөзбашы Туйкә Абдулов улы. 1811 елда Яланкүлдә 12 ир-ат ясаклы татар исәпкә алына. Болар Зәйнелгабидин (38), Габдрахман (36) Мөхсиновлардан һәм Бакый Сөләйманов варисларыннан тора[255].

Ревизия документларыннан татарларның төбәккә характерлы күпчелек сословиеләрен күрдек. Аз санлы «башкорт» хуҗалыклары Яланкүлдә яшәгән, беренче күчеп килүчеләр дә шунда, күл буенда урнашкан.

1816 елда Күктәкәдә 3 сословиегә караган 117 ир-ат (54 хуҗалык) татар яши. Күпчелекне 2 исемлектә (беренчесендә – 55 ир-ат (25 хуҗалык), икенчесендә 54 ир-ат (26 хуҗалык)) теркәлгән йомышлы татарлар тәшкил итә. Болардан тыш, 6 ир-аттан (2 хуҗалык) торган типтәр сословиесендәге татарлар теркәлгән. Алар Юрмый волосте биләмәчеләре белән килешү төземичә һәм оброк түләмичә «мәңгегә» килеп утырганнар. Башкорт сословиесендәге 2 ир-ат (1 хуҗалык) татарлар Яланкүлдә теркәлгән булсалар да, монда яшиләр[256].

Шунысы игътибарга лаек, йомышлы татарлар күрсәтелгән 1816 елгы исемлекләрдә Күктәкә түгел, башка атамалар телгә алына. Беренче исемлектә 55 ир-ат һәм 89 хатын-кыз (29 хуҗалык) теркәлгән, лашман бурычын башкаручы йомышлы татарлар (чыганакта «служилые татары, исправляющие лаш-

---

[251] Шунда ук, 24 сакл. бер., 442 б.
[252] Шунда ук, 24 сакл. бер., 422 б.
[253] Кәримов Т. Күктәкә авылы тарихы (Ак таплар) // Аргамак. 1995. № 12. 78–93 б.
[254] Шунда ук, 23 сакл. бер., 266 б.
[255] 84 сакл. бер., 87–87 б. а.
[256] Шунда ук, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 124–126 б. а.

манную повинность») Аллабирде (чыганакта «Алаберды Куры Елга Тамак тож») авылында түбәндәге хуҗалыклардан тора: 1) Бохармәт Мостафин (73 яшь); 2) Габдерәшит Бохармәтов (52); 3) Моканай Мостафин (66); 4) Мөхтәр Моканаев (45); 5) Бохарай Мостафин (64); 6) Сә[й]фетдин Биктимеров (29); 7) Сәйфелмөлек Биктимеров (21); 8) Аднагол Бикколов (60); 9) Имангул Бикколов (50); 10) Рәмкол Бикколов (43); 11) Әхмәр Какашов (43); 12) Әхтәм Какашов (41); 13) Рәхмәтулла Гобәйдуллин (43); 14) Нигъмәтулла Гобәйдуллин (37); 15) Габделвахит Фәйзуллин (34); 16) Сәпәй Шәрипов (43); 17) Бикмөхәммәт Ишоков (22); 18) Якуп Шәрипов (34); 19) Субай Борханов (28); 20) Ибрай Йосыпов (74); 21) Габҗәлил Ибраев (49); 22) Әлмөхәммәт Ибраев (44); 23) Габделмәннан Габдерәззаков (51); 24) Габделкәрим Габдерәззаков (46); 25) Нәзир Таиров (56); 26) Габдерәшит Бүләкәев (57); 27) Габделхаликъ Йөзәев (52); 28) Мәҗит Йөзәев (41); 29) Сөбханкол Касыймов (30)[257].

Икенче исемлектә 54 ир-ат һәм 64 хатын-кыз (26 хуҗалык) теркәлгән, лашман бурычын башкаручы йомышлы татарлар (чыганакта «служилые татары, исправляющие лашманную повинность») Иген Елга (чыганакта «Ик Игин Илга Абышка Тамак тож») авылында түбәндәге хуҗалыклардан тора: 1) Вахит Габдерахманов (22 яшь); 2) Габдулла Әбләзов (22); 3) Моталлап Ибраев (69); 4) Ваһап Моталлапов (31; ике хатынлы); 5) Нигъмәтулла (1812 елда вафат; уллары Гобәйдулла, Гайнулла), Фәйзулла (46) һәм Рәхмәтулла (1813 елда вафат; уллары Гомәр, Әбубакир) Ибраевлар; 6) Мәһди (31) һәм Мөсәгыйть (22) Исмәгыйловлар; 7) Балтай Гомәров (48); 8) Мәхмүт Солтанов (58); 9) Байбүре (25; ике хатынлы) һәм Кәдрәле (23) Шәфиевлар; 10) Рәкәй Мортазин (43); 11) Ишмөхәммәт Биккенин (64); 12) Габдерәфикъ Габделкәримов (46); 13) Габдессаттар Габделкәримов (40); 14) Сәлимҗан Биктимеров (70; ике хатынлы); 15) Габделмән Даутов (62); 16) Габделҗәлил Даутов (60); 17) Гапсәлам Габдерәшитов (41; ике хатынлы); 18) Сәйфетдин Бикбов (19); 19) Габит Мөлеков (19); 20) Шәфи Гапсәламов (30); 21) Рәфикъ Габдерәшитов (43); 22) Уразай Габделваһапов (40); 23) Ихсан Габделваһапов (32); 24) Исхак Габделваһапов (30); 25) Миңлегол Габбәсов (35); 26) Бикчәнтәй Ишмөхәммәтов (1813 елда вафат)[258].

Күктәкә «типтәр»ләре 1816 елда 3 ир-ат һәм 4 хатын-кыздан тора. Болар – бертуган Бикташ (47; уллары Биккенә, Бикмөхәммәт) һәм Ильяс (42; уллары Гобәй, Фәтхулла) Рахманколовлар гаиләләре[259].

Яланкүлгә күчәбез. 1816 елда монда 3 сословиедән торган, 72 ир-ат (21 хуҗалык) татар теркәлгән. Башкорт (9 хуҗалык) һәм типтәр (8) сословиесендәге татарларның саны бер үк (32 ир-ат) була. Беренчеләре турында 2 ир-ат – Күктәкәдә, 3 ир-ат Сасыкүлдә яши дип әйтелә. «Типтәр»ләр Юрмый

[257] Шунда ук, 197 сакл. бер., 356–366 б.
[258] Шунда ук, 703–711 б.
[259] Шунда ук, 175 сакл. бер., 286–287 б.

волосте биләмәчеләре белән килешү төземичә һәм оброк түләмичә «мәңгегә» килеп утырганнар. Болардан соң ясаклы татарлар (8 ир-ат; 4 хуҗалык) күрсәтелә[260].

1811 ел белән чагыштырганда (34 ир-ат), типтәр сословиесендәге татарларның саны 1816 елда ике ир-атка кимрәк. 1811 елгы ревизия документына таянып, аларның исемнәрен атап үтәбез: 1) Саты[й] Исә[н]гилдин (67 яшь; уллары Якый (анықы Фәтхулла, Габидулла), Төхвәтулла, Хисмәтулла, Нигъмәтулла); 2) Габдулла Корманаев (25); 3) Рәмәй Йосыпов (51; улы Курамша); 4) Үзбәк Гомәров (44; уллары Хөсәен, Кормангали, Арыслан, Мөхәммәтгали); 5) Габдулла Исмәгыйлов (49); 6) Ишбулды Ишмәкәев (улы Мәвлекәй); 7) Габдессәлам Сәфәров (78); 8) Шәмәй Хасбулатов (26), шунда ук Габидулла (5; Бикчәнтәй Хасбулатов улы яши); 9) Миңлекәй (10; Миңлегол Аитмәмәтов улы); 10) Нигъмәтулла Йөзәев (32; улы Рәхмәтулла); 11) Зөбәер Бикколов (39); 12) Сәлим Сәетов (59; 1799 елда Банки Сукаештан күчеп утырган); 13) Габдрахман (66; улы Кәүсәр) һәм Рахманкол (56; уллары Рәхмәтулла, Нигъмәтулла) Мөрсәлимовлар; 14) Тойгын Ярмөхәммәтов (33; улы Дәүләтша); 15) Габдессәлам (1809 елда вафат; улы Гобәйдулла) һәм Габҗәлил (38) Госмановлар. Алар 5 нче типтәр командасына (старшина Габделнәфыйкъ Габдерәхимов) карый[261].



| | | | |
|---|---|---|---|
| 11 | Куптекъ въ ней | | |
| | Башкирцовъ — | 1 | 2. |
| | припущенныхъ оными навечность безъ договору и безъ оброчно | | |
| | тептярей — | 2 | 6. |
| | Служилыхъ татаръ | 25 | 55 |
| | Служилыхъ же тептяръ | 26 | 54. |
| | Итого | 54 | 117 |
| 12. | Еланкулева въ ней | | |
| | башкирцовъ — | 9 | 32. |
| | изъ коихъ 2 души живутъ въ деревне Куптекахъ, да 3 души съ деревни Сасыкуль, припущенныхъ оными навечность безъ договору и безъ оброчно. | | |
| | тептярей | 8 | 32 |
| | ясачныхъ татаръ | 4 | 8 |
| | итого | 21 | 72. |

*Күктәкә һәм Яланкүл авыллары татарларының сословиеләре һәм 1816 елгы исәбе күрсәтелгән документ фрагменты*

1816 елда Яланкүлдә тагын лашман бурычын (чыганакта «лашманная повинность») башкаручы ясаклы татарлар (8 ир-ат һәм 8 хатын-кыз; 4 хуҗалык) да яши. Болар исәбенә Зәйнелгабидин Мөхсинов (42 яшь), Габдрах-

[260] Шунда ук, 124 б. а.

[261] Шунда ук, И–138 фонд, 2 тасв., 84 сакл. бер., 334–335 б.

ман Мөхсинов (40; улы Хөббелхуҗа), Вәлит Бакиев (45; улы Фәйзулла), Хәмит (41; улы Габит) һәм Хәмидулла (41) Бакиевлар керә[262].

Күктәкәнең һәм Яланкүлнең көнкүрешенә кагылышлы 1829 елгы мәгълүматлар кызыклы. Игенчелек һәм терлекчелек – халыкның төп шөгыле. Хатын-кызлар кыр эшләреннән буш вакытта йоннан, киндер басаларыннан җеп эрләгәннәр, киндер сукканнар һәм тукыма тукыганнар. Ирләрнең бер өлеше (башкорт сословиесендә торганнары) чиратлашып (биш йорттан атлы ике кеше) ел саен Оренбург линиясендәге төрле крепостьларга хәрби хезмәт үтәргә йөргәннәр. Хезмәт иткәндә алар жалованье һәм «атларга ремонт алганнар». Типтәр сословиесендәгеләр исә Оренбург шәһәрендәге ике мең атлы типтәр полкына чират буенча хәрби хезмәткә алынганнар, полк чыгымнарын түләргә мәҗбүр ителгәннәр. Ясаклы татарлар казнага оклад (салым) түләгәннәр[263].

1859 елгы ревизия исемлегендә Күктәкәдә 11 ир-ат һәм 8 хатын-кыз (3 хуҗалык) типтәр сословиесендәге татарлар күрсәтелә. Болар Биккенә Бикташев (49), Фәтхулла Ильясов (52) һәм указлы мулла Фәрухша Ишмурзин (30; Банки Сукаешныкы) була. 1855 елдан «типтәр»ләр «Башкорт» гаскәренә беркетелгәнлектән, әлеге кешеләрнең сословиесе документның титул битендә – «башкорт», эчке битендә «типтәрдән башкорт» (чыганакта «башкиры из тептярей») дип язылган[264].

Әмма авылның төп халкын дәүләт (казна) крестьяннары (бу очракта элеккеге йомышлы татарлар) тәшкил итә. Алар һәм югарыда сүз барган типтәр сословиесендәге татарлар 1859 елда 214 ир-ат һәм 223 хатын-кыз (75 хуҗалык) тәшкил итә[265].

Яланкүлдә 1859 елда 105 ир-ат һәм 96 хатын-кыз (19 хуҗалык) исәпләнә. Болар башкорт (67 ир-ат һәм 54 хатын-кыз) һәм типтәр (38 һәм 42) сословиеләренә карый. Соңгылары «типтәрдән башкорт» («башкиры из тептярей»; Хисмәтулла Сатыев (55), Фәтхулла Якыев (67), Курамша Рәмәев (1798–1856; ике хатынлы), Хөсәен Үзбәков (60) һәм башкалар) дип язылган. Башкорт сословиесендәге татарларга Гомәр Мусакаев (42), Госман Мәксүтов (48), Габдерәхим (1780–1856) һәм Абдулла (56) Габделкәримовлар, Хәсән Салиховлар (63) һәм башкаларның гаиләләре карый. Исемлек ахырында Уразайдан күчеп килгән Фазулла Рәхмәтуллин теркәлгән[266].

---

[262] Шунда ук, 197 сакл. бер., 719–723 б.

[263] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 287–289 б.

[264] БР МА, И–138 фонд, 1 тасв., 757з. сакл. бер., 58–59 б. Кәримов Т. Күктәкә авылы тарихы (Ак таплар) // Аргамак. 1995. № 12. 78–93 б.

[265] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. г. С. 35.

[266] БР МА, И–138 фонд, 1 тасв., 757з. сакл. бер., 49–57 б.

Яланкүлдә тагын казна (дәүләт) крестьяннары (элеккеге ясаклы татарлар) яши, аларны да исәпләп 1859 елда барлыгы 130 ир-ат һәм 122 хатын-кыз (41 хуҗалык)[267]була.

1881 елда төбәк тарихында тирән эз калдырган вакыйга була. Юрмый волосте «башкорт»ларының буш яткан җирләре элек бу волостька кергән авылларга бүлеп бирелә. Яланкүл «башкорт»ларына 525 дисәтинә җир туры килә. Җан башына болай да шактый биләмәләре булганлыктан, алар аны сата башлыйлар. Аның зур өлешен тиз арада берничә кеше сатып ала. Шуларның берсе – Мөстәкыйм Габдерәхимов. Ул 1882 елның 16 мартында Коры Елга буеннан 539 сумга 179 дисәтинә 1600 сажин җир сатып ала. Бу җир аның улларына – Мөхәммәтдин, Шәйхетдин һәм Шәмсетдин Мөстәкыймовларга мирас булып калгач, алар аның бер өлешен (91 дисәтинә 1600 сажин) 1896 елның 8 маенда дворян Матвей Головинскийга саталар. Калган өлеше (89 дисәтинә) Шәйхетдин Мөстәкыймов хуторы буларак билгеле. 1900 елда, мәсәлән, хуторда аның усактан салынган йорты һәм бер сарае була. Бөртеклеләрдән арыш, солы, бодай, борай, тары, карабодай һәм борчак чәчкән.

М. Габдерәхимовтан бераз алдарак (февральдә) Коры Елганың уң ягыннан 181 дисәтинә 800 сажин җирне 544 сумга мещан Николай Сапожников сатып ала. Шул ук елның сентябрендә аның 50 дисәтинәсен ул күптәнге танышы (алар берара икәүләшеп җир сатып алырга җыенган булалар, әмма кайбер кыенлыклар килеп туу аркасында, әлеге танышы соңгы мәлне баш тарткан) коллежский асессор Александр Машкинга сата. Февральдән сентябрьгә чаклы җир бәясе шактый артканлыктан, аңа зур сумма (1000 сум) акча чыгарып салырга туры килә. Статистик чыганакларда аларның икесенең дә хуторлары күрсәтелә.

Коры Елганың уң ягыннан шул ук елны тагын Минзәлә өязенең Урыс Шуганы авылы крестьяны Иван Епишин да җир (34 дисәтинә) сатып ала. Аңа үз җирләренең зур өлешен 425 сумга Яланкүл «башкорт»лары Гыйззәтулла Хәбибуллин, Мөхәммәтвәли һәм Харис Хәсәновлар сата. Менә шулай, Яланкүл тирәсендә, исәп буенча, дүртенче хутор барлыкка килә. Хуторлар саны болар белән чикләнми, әлбәттә, алар хакында мәгълүматлар алга таба бирелер.

Буш җир мәсьәләсен хәл итү каршылыклар да тудыра. Яланкүл «башкорт»ларының бик азы гына аны үзләре сатып ала (мәсәлән, Гыйззәтулла Хәбибуллин 27 дисәтинәне). Шул ук вакытта халыкның бер өлеше югарыда телгә алынган җир сатулар белән килешми. Алар калган 103 дисәтинә җирне саттырмыйлар һәм үзара бүләләр[268].

---

[267] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. г. С. 35.

[268] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 881 сакл. бер.

1885 ел ахыры – 1886 ел башында Күктәкә һәм Яланкүл – Тымытык волостеның зур булмаган авыллары. Беренчесендә – 108, икенчесендә 69 хуҗалык исәпләнә. Бу күрсәткечләр буенча алар волостьта (аңа тагын Тымытык, Урсай, Сасыкүл һәм Чалпы керә) соңгы урыннарны алып торалар. Күктәкәдә 261 ир-ат һәм 272 хатын-кыз яшәсә, Яланкүлдә аларның саны (169 һәм 196) күпкә аз.

Күктәкә авыл җәмгыятенең (Икмән Елга белән бергә) 1596,9 дисәтинә имана җире була. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка исәпләгәндә, ул 11,7 дисәтинә туры килә.

Җир белән тәэмин ителү ягыннан Яланкүл өстен тора. Анда «башкорт»ларның имана җире – 1181,7, калган сословиеләрнең исә 415,2 дисәтинә тәшкил итә. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка бүлгәндә, «башкорт»ларда – 21,2, башка сословиеләрдә 12,6 дисәтинә туры килә.

Күренгәнчә, сословиеләр буенча алганда, җир белән тәэмин ителүдә «башкорт»лар аеруча зур өстенлеккә ия булган. 10 нчы ревизиядә (1859 ел) исәпкә алынган һәр ир-ат «башкорт»ка 15 дисәтинә җир бүленә, башка сословиеләрдә исә ул 6,6–7,2 дисәтинәдән артмый.

Җир белән азрак тәэмин ителү сәбәпле, башкорт дип аталмаган сословие хуҗалыклары (типтәр, ясаклы татар һәм башкалар) аны үз авылдашларыннан яисә читтән арендага алганнар. Үз авыл җәмгыятьләреннән арендага алучылар Күктәкәдә – 29 (486 дисәтинә), Яланкүлдә 8 хуҗалык (106 дисәтинә) була. Моннан тыш, ике авылдан барлыгы 14 хуҗалык читтән 77 дисәтинә сөрүлек һәм 65 сумга печәнлек җирне арендага алган.

Җирсез хуҗалыклар бик аз. Күктәкәдә – дүрт, Яланкүлдә нибары бер хуҗалыкның гына чәчүлек җире булмый. Аларның да берсе читтә яши.

Әмма имана җире булган хуҗалыкларның барысы да иген икми. Күктәкәдә – унбер, Яланкүлдә дүрт хуҗалык аны төрле шартларга (акча яисә икмәк белән түләү һ. б.) арендага бирүне кулай күргән.

Җирне сыйфатлы итеп вакытында эшкәртү өчен эш кораллары белән тулы тәэмин ителү мөһим. Күктәкәдә – 52, Яланкүлдә 41 хуҗалыкның эш кораллары җитәрлек була. Шул ук вакытта авылларның беренчесендә 16 хуҗалыкта алар өлешчә генә, ә 24-ендә исә бөтенләй юк. Яланкүлдә мондый хуҗалыклар шул тәртиптә 5 һәм 16. Алар җитмәгән эш коралларын авылдашларыннан хак түләп яисә башка шартларга килешеп алып торганнар.

Игенчелектән тыш, терлекчелек тә авылларда зур урын тота. Хуҗалыкларның күп санда эш атлары (Күктәкәдә – 136, Яланкүлдә – 153 баш), мөгезле эре терлеге (169 һәм 168), сарыклары (189 һәм 219) һәм кәҗәләре (110 һәм 70) була. Әлеге саннар эре мал-туарның Яланкүлдә, Күктәкә белән чагыштырганда, күбрәк булуын күрсәтә. Мондый аерма барлыкка килүдә Яланкүлдәге «башкорт» хуҗалыкларының роле зур, әлбәттә. Аларның (39 хуҗалык) эш атлары гына 117 баш исәпләнә.

Әмма, хуҗалыкларга карап, мал-туар саны аерыла. Эш атларын алыйк. Күктәкәдә – 35, Яланкүлдә 23 хуҗалыкта алар бөтенләй булмый. Хуҗалыкларның төп өлеше берәр (Күктәкәдә – 31, Яланкүлдә – 14) һәм икешәр-өчәр (31 һәм 20) ат тота. Дүрт һәм аннан да күбрәк атлылар (7 һәм 11) бик аз.

Шунысы күзгә ташлана, Күктәкәдә – 30, Яланкүлдә 19 хуҗалыкның ни эш аты, ни сыеры булмый. Өстәвенә, кайбер хуҗалыклар (8 һәм 10) йортсыз. Андыйларга авылда тормыш итү шактый авырга туры килгәндер, дип уйларга кирәк.

Имана җире аз яисә бөтенләй булмаган, яисә мал-туарсыз хуҗалыкларның күпчелеге үз авылдашларына һәм якын-тирә алпавыт имениеләренә я булмаса башка авылларга төрле эшләргә ялланган, кайберләре һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Статистик мәгълүматлардан күренгәнчә, Күктәкәдә – 17, Яланкүлдә 18 кеше игенчелек белән бәйле эшләргә ялланган. Һөнәрчелек белән шөгыльләнүчеләр күп (28 һәм 6) була. Ә менә авылдан читкә чыгып эшләүчеләр аз. Аларның да бары берсе генә һөнәрчелек белән шөгыльләнә. Калганнары (14 һәм 3) игенчелеккә бәйле эшләргә ялланган.

Әйләнә-тирәдәге бай табигать умартачылык өчен уңай шартлар тудырган. Күктәкәдә 11 хуҗалыкта – 52, Яланкүлдә 14 хуҗалыкта 107 баш умарта исәпләнә. Якын-тирә авылларда да умартачылык белән шөгыльләнүчеләр күп.

Сәүдә эшчәнлегенә игътибар итик. Тымытык волостендагы 22 лавканың бары берсе генә Күктәкә белән Яланкүлгә (ул соңгысында урнашкан) туры килә[269].

Моны якындагы авылларда лавкаларның күп булуы (Тымытыкта – 5, Сасыкүлдә – 5) белән аңлатырга кирәктер. Хуҗалык-көнкүреш өчен кирәк-яракны халык әлеге авыллардан да сатып алган. Аннан соң, озак та үтми, Күктәкәдә атна саен базарлар үткәрелә башлый.

1889 елда Күктәкәдә 107 хуҗалык һәм 540 кеше исәпләнә. Авылда элеккечә бер мәчет. Базарлар атнаның шимбә көнендә үткәрелә.

Яланкүлдә исә бу вакытта 66 хуҗалыкта 319 кеше яши. Монда да шулай ук бер мәчет күрсәтелә. Авылдан ерак түгел дворян В.А. Бекбулатовның имениесе урнашкан[270].

Дворян В.А. Бекбулатовның имениесе, төбәктәге күпчелек башка имениеләр һәм хуторлар кебек, 1882 елда барлыкка килә. Шул елда дворян В.А. һәм О.А. Бекбулатовлар Тымытык «башкорт»ларыннан Карамалы Елганың уң ягындагы һәм Коры Елга тирәсендәге җирләрне сатып алалар. 297 дисәтинә җир өчен алар 1782 сум түлиләр. 1900 елда әлеге имение, аның

[269] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 290–297.

[270] Список населенных мест Самарской губернии по сведениям 1889 г. Самара, 1890. С. 86–87.

үзеннән башка, улы (Александр) һәм кияүгә чыккан кызы (Е.В. Тавянская) исеменә дә рәсмиләштерелгән була[271].

Гасыр ахырына Күктәкә шактый зурая. Анда 1897 елда 136 хуҗалыкта 341 ир-ат һәм 355 хатын-кыз яши. Яланкүлдә, 1889 ел белән чагыштырганда, хуҗалыклар 12 гә, халык саны 95 кә арткан. Авылларның икесендә дә берәр мәчет була[272].

Төбәктә игенчелекнең торышын тасвирлаучы мәгълүматларга тукталып үтик. 1900 елның 8 сентябрендә төзелгән документтан күренгәнчә, Күктәкәдә һәм Яланкүлдә хуҗалыклар арыш, солы, карабодай, бодай, борчак һәм тары иккәннәр. Кара туфраклы ашланган басуларда төп культура – арыш уңышы бер дисәтинәдән – 25 (начар), 80 (уртача) һәм 100 (яхшы) потлап чыккан. Ә менә шундый ук туфракта, әмма тирес кертелмәгән басуларда яхшы уңган арыш 90 пот тирәсе чыга.

Икенче төп культура – солы уңышы белән дә шундый закончалык күзәтелә. Беренче очракта уңышның түбәне – 25, уртачасы – 85, яхшысы 130 пот тәшкил итә. Икенче очракта исә, шундый ук тәртиптә 20, 80 һәм 120 потлар.

Калган культуралар (карабодай, тары, бодай һәм борчак), арыш һәм солы белән чагыштырганда, шактый аз игелә. Карабодайны, яхшы уңганда, 1 дисәтинәдән 100 пот алганнар. Шул ук вакытта 70 (уртача) һәм 15 (начар) пот уңыш алу очраклары да була.

Борай һәм тары уңышы ничек булган соң? Ашланган басуларда борай бер дисәтинәдән 25 (начар), 80 (уртача) һәм 130 (яхшы) потлап чыккан. Тарының исә шундый ук тәртиптә 25, 80 һәм 120 потлар.

Ашланмаган басуларда борай уңышының түбәне – 20, уртачасы – 70, яхшысы 120 пот тәшкил итә. Тары уңышы исә ике очракта түбәнрәк (15, 70 һәм 100).

Күктәкә тирәсендәге җирләрнең бер өлеше ташлы кара туфрактан тора. Шуңа күрә монда бөртеклеләрнең уңышы күпкә түбәнрәк. Кайбер культуралар буенча яхшы уңыш 20 (солы), 30 (арыш, борай, карабодай) һәм 35 (тары) пот кына була.

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, бөртеклеләрдән күп очракта яхшы гына уңыш алынган. Әмма бу күрсәткечләрне, әйбәт булуга карамастан, Азнакай төбәге өчен иң югары дип әйтеп булмый. Азнакайның үзендә, мәсәлән, төп культура – арыш уңышы бер дисәтинәдән 40 (начар), 90 (уртача) һәм 150 (яхшы) потлап чыккан.

Уңыш мул булган елны икмәк гаиләне туйдырырга да, сатарга да җиткән. Әлбәттә, табигатьнең вакыт-вакыт көйсезләнүе игенчеләрне зур сынаулар алдына куйган. Мондый елларны җитәрлек икмәк запасы булмаганнарга аеруча авырга туры килгән.

---

[271] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 880 сакл. бер.

[272] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 161.

Авылларның икесендә дә электән үк берәр мәчет булуы хакында язмабызда әйтелгән иде. 1900 елда биредә Фәрухша Ишмурзин (Күктәкә)[273], Зәкиҗан Әхмәтгәрәев һәм Мөхәммәтзәки Ситдыйковлар (Яланкүл) муллалык итәләр.

Муллалар арасында иң өлкән яшьтәгесе – Фәрухша Ишмурзин (71 яшь). Аның гаиләсендә хатыны (68), кызы, улы, ике килене, өч оныгы, асрамага алган 2 улы һәм аларның анасы була. Ул 8 ат (шул исәптән 3 эш аты), 8 мөгезле эре терлек (6 сыер), 50 баш сарык һәм 3 кәҗә асрый. Аның имана җире юк, шуңа күрә ул авылдашларыннан һәм читтән арендага 24 дисәтинә җир ала. Җирнең зур өлешенә арыш (8 дисәтинә), калганына бодай (3 дисәтинә), солы (3 дисәтинә), борай (2 дисәтинә), тары һәм карабодай (берәр дисәтинә) чәчә. 6 дисәтинә җирне ул парга калдыра. Мулланың зур хуҗалыгында асрамага алынган малайлардан тыш, тагын 2 ир-ат хезмәтче эшли.

Муллаларның икенчесе – Зәкиҗан Әхмәтгәрәев (28 яшь) – чыгышы буенча Кама-Исмәгыйль авылыннан. Муллалар арасында татарча гына түгел, русча да грамоталы булуы белән аерылып тора. Ул хатыны (21), улы (3), кызы һәм асрамага алган улы белән яши. Хуҗалыгында 6 ат (өчесе эш аты), 6 мөгезле эре терлек (өчесе сыер), 8 сарык, 1 кәҗә һәм 9 оя умарта була. Фәрухша хәзрәт кебек, ул да арендага җир алып иген игә (6,08 дисәтинә). Аның бар хезмәтчеләре – шул асрамага алган малай да һәм тагын бер кыз бала.

Исәп буенча өченче мулла – Мөхәммәтзәки Ситдыйков (18 яшь). Ул үзенең 13 яшьлек энесе белән яши, гаиләсе юк. Яшь хәзрәт имана җирен авылдашларына арендага биргән, мал-туар тотмый.

Бу вакытта мөәзиннәр булып Габдулла Кәримов (Күктәкә) һәм Гыйззәтулла хәзрәт (Яланкүл) тора. Аларның беренчесенә – 25 яшь. Ул хатыны (23), улы, кызы, энесе һәм 2 анасы (мөгаен, атасы ике хатынлы булгандыр) белән яши. Габдулла мөәзиннең хуҗалыгында 6 ат (дүртесе эш аты), 7 мөгезле эре терлек (өчесе сыер), 15 сарык һәм 3 кәҗә була. Арендага җир алып иген игә.

Гыйззәтулла хәзрәт дин әһелләре арасында иң өлкәне (80 яшь). Ул хатыны (60) белән улы Кәрәмәтулла Гыйззәтуллин (28) гаиләсендә яши. Кәрәмәтулла – әтисеннән аермалы буларак – сәүдәгәр, авылда бакалея лавкасы тота. Мал-туары юк, ә чәчүлек җире 12,41 дисәтинә тәшкил итә. Иманадан тыш, аның 8,5 дисәтинә сатып алган җире дә була.

Лавка тотучылар һәм сәүдәгәрләр К. Гыйззәтуллин белән генә чикләнми. Әсхәбетдин Миңлекәев (48 яшь) савыт-саба һәм тимер әйберләр белән сәүдә итә, Күктәкәдә лавка тота. Ул хатыны (45), 6 улы һәм кызы белән яши. Хуҗалыгында 10 ат (алтысы эш аты), 11 мөгезле эре терлек (бишесе сыер), 50 баш сарык һәм 7 кәҗә була. Чәчүлек җирләре 15 дисәтинәдән арта.

Тагын бер лавка хуҗасы – Михаил Ключников (47 яшь). Ул Күктәкәгә Бөгелмә шәһәреннән күчеп килгән, монда хатыны (40), 2 улы һәм 2 кызы

[273] Фәрухша мулла тумышы белән Банки Сукаеш авылыннан.

белән яши. Хуҗалыгында сыер белән бозаудан башка мал-туары юк. Аның чәчүлек җирләре 9 дисәтинә тәшкил итә.

Авыл кешеләре арасында лавка тотмыйча, Күктәкә базарында даими сәүдә итүчеләр дә була. Габделсабир Ибраһимов (48 яшь) ел әйләнәсенә вак-төяк товарлар белән сәүдә итә. Солтангәрәй Шаһиморатов (50) исә базарда калачлар саткан. Вак сәүдәгәрләр арасында тоз һәм керосин сатучыны (Сөләйман Исмәгыйлов) да, балык сатучыны (Шәрәфетдин Шәрифуллин) да күрергә була.

Әмма Күктәкә базары беренче чиратта икмәк сәүдәсе үзәге буларак билгеле. Биредә кайбер эре сәүдәгәрләр үзләренең приказчикларын һәм икмәк амбарларын тотканнар. Мәсәлән, Хөсәен Фәйзуллин (40 яшь) – Минзәлә өязеннән сәүдәгәр Иван Горбуновның приказчигы. Ул Бөгелмә ягыннан күчеп килгән, Яланкүлдә хатыны һәм улы белән яши.

Күктәкәдә икмәк сәүдәсе белән күбрәк читтән килеп төпләнгән сәүдәгәрләр шөгыльләнә. Фәйзулла Мостафин (80 яшь) тумышы буенча Бөгелмә шәһәреннән; Күктәкәдә аның хуҗалыгы зурлардан санала. Ул 35 яшьлек улы белән ваклап икмәк сатып алу һәм аны күпләп сату белән шөгыльләнә.

Икенче сәүдәгәр – Хөснетдин Шәмсетдинов (58 яшь) – Күктәкәгә Балтач авылыннан күчеп килгән, монда арендага йорт алып сәүдә итеп ята. Хуҗалыгы зур түгел.

Тагын бер сәүдәгәр – Касыйм Кәримов (47 яшь) – төп Яланкүл кешесе булуы белән аерылып тора. Аның гаиләсендә хатыны (31), 4 улы һәм кызы була. Икмәк сәүдәсе күп вакытын алган, күрәсең, аның хуҗалыгы зур түгел.

Күктәкәдә һәм Яланкүлдә төрле һөнәр ияләренең күп булуы күзгә ташлана. Балта осталарын алыйк. Алар арасында Габдерәкыйп Вахитов (66 яшь), Җиһанша Әхмәтшин (56), Галиулла Нигъмәтуллин (64) һәм Мөхәммәтҗан Мөхәммәтрәхимовларны (55) күрәбез. Бу осталар артельга берләшеп төрле төзелеш эшләренә ялланганнар. Һәр ел саен диярлек эш эзләп якын-тирә авылларга һәм өязләргә дә барып чыга торган булганнар. Урман күп якларга агач кисәргә ялланучылар да (Нәфыйкъ Кәримов, Габделхак Кәримов) була.

Башка һөнәр ияләреннән итекчеләрне (Гәрәй Рахманкулов, Сафиулла Гайнуллин), чабатачыларны (Җиһангир Фәтхуллин, Һидиятулла Зәйнуллин, Нурмөхәммәт Бикмөхәммәтов), йон тетүчене (Гайфулла Фәтхуллин) һәм слесарьны (Габделхарис Фәварисов) күрергә була.

Якында гына зур елга (Ык) булу балыкчылык өчен уңай шартлар тудырган. Шуңа күрә авылда балыкчылар күп. Алар да, балта осталары кебек, язынкөзен артельга берләшә торган булганнар. Һидиятулла Гапсәләмов (62 яшь), Шакир Гайнуллин (60), Шаһимөхәммәт Шаһиәхмәтов (45), Солтангали Корбанов (41), Хәйрулла Хәлиуллин (42), Мөхәммәди Галиуллин (47) һәм Әхмәтвәли Әхмәтҗанов (27) оста балык тотучылар саналганнар. 10 кешедән торган артельга бер сезонга балык тотарга рөхсәт алу 10 сумга төшкән. Әмма

балык тотып, аны базарда сату бу чыгымнарны гына каплап калмыйча, өстәмә табыш та китергән.

Югарыда күрсәтелгән кешеләрнең төп өлеше балыкчылык белән елга 2–3 ай шөгыльләнә. Шул ук вакытта Яланкүлдән ике кеше (С. Корбангалиев, Х. Хәлиуллин) яздан алып көзгә кадәр (6 ай) Ыктан кайтып кермәгән диярлек. Хәйрулла Хәлиуллин, мәсәлән, елганың Яланкүл тирәсендәге урыны өчен елга биш сум түләп, күп вакыт шунда балык тотып яткан. Башка балыкчылар шикелле үк, ул да үзеннән арткан балыкны Күктәкә базарында сата торган булган[274].

Балык кына түгел, бал сатып торучыларны да еш күрергә мөмкин булган базарда. Умартачылыкның үсеше турында язмабызда бераз әйтелгән иде. Бер чыганакта, Яланкүлне күз алдында тотып, аның 1900 елгы торышы түбәндәгечә тасвирлана: «*Ульи долбленые, деревянные (колоды). С улья получается в год 12 фунтов (Россиядә фунт – 409,5 граммга тигез булган үлчәү берәмлеге. – Т.К.) меду и 2 фунта воску. Улей стоит – 60 коп. Улей с пчелами 4 рубля. Рой 1 фунт – с фунта 50 копеек. Мед сотовый 6 рублей пуд. Пропущенный мед – 5 рублей. Вощина белая – 13 рублей пуд. Вощина красная – 6 рублей пуд. Мед и вощина продаются на базаре в собственной деревне, а главным образом на ярмарках в городе Бугульме 14 го сентября, в селе Чекан 26 ноября, в деревне Бакалах Белебеевского уезда Уфимской губернии 22 октября. Пчельники находятся в общественном кустарнике по реке Ик. За места на пасеке (?) платят*»[275].

Төбәктә иң күп умарта тотучылар – Мөхәммәди Галиуллин (20 баш умарта), Вәлиулла Галиуллин (19) һәм Шаһимөхәммәт Шаһиәхмәтов (10). Башка умартачыларның исә ул күпкә аз. Мәсәлән, Әхмәди Хөсәеновның – 5, Мөхәммәтлатыйф Әхмәдиевнең – 4, Мөхәммәтгәрәй Әхмәтгәрәевнең 4 баш умартасы була.

1900 елда Күктәкәдә авыл старостасы – Сәйфулла Нигъмәтуллин (49 яшь). Ул хатыны (26), улы (5), 4 кызы һәм анасы белән яши. Хуҗалыгы зур түгел.

Авылда писарь да була. Әлеге вазифаны җәмәгатьчелек нигезендә Даут Колыев (42) башкара. Аның гаиләсе атасы, анасы, хатыны, 2 улы һәм 3 кызыннан тора. Атасы авылда иң өлкән яшьтәге кешеләрнең берсе – аңа 102 яшь. Д. Колыевның хуҗалыгы зурлардан санала. Ул 11 ат (дүртесе эш аты), 9 мөгезле эре терлек (бишесе сыер), 18 сарык һәм 3 кәҗә асрый. Аның иманасында – 6, арендага алган басуларда 20 дисәтинә чәчүлеге була.

Күктәкәдә элек-электән башлангыч мәктәп эшләп килгән. Монда мулла-мөәзиннәр балаларга сабак биргәннәр. Аларга Таһирмөхәммәт Гөзәеров (61) ярдәм иткән. Кулсыз һәм аксак Насретдин Исхаков (30) кыш буе монда каравылда торган. Моның өчен аңа барлыгы 5 сум акча түләгәннәр. Аның 75

---

[274] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 855 сакл. бер.

[275] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 884 сакл. бер.

яшьлек анасы өендә кыз балалар укыту белән шөгыльләнә. Монда мәктәпне тәмамлаган шәкертләрнең бер өлеше укуларын Тымытык мәдрәсәсендә дәвам иткән.

Янгын чыгу куркынычы булган җәйге чорда авыл җәмгыяте үз акчасына янгынчы яллаган. Озак вакыт үз атын җигеп янгынчы булып Корбангали Хөсәенов (70 яшь) эшли. Аңа бер җәйгә 30 сум түләгәннәр. Габидулла Шәрифуллин (42) исә шулай ук үз аты белән янгын каланчасында каравыл торган.

Ык елгасының Күктәкә турында күпер һәм паромны күрергә мөмкин булган. Елга аша чыгып йөрүчеләр Мөхәммәтгата Рәхмәтуллинга (38) һәм язмабызда телгә алынган Шаһимөхәммәт Шаһиәхмәтовка хак түләгәннәр. Чөнки күпер дә, паром да икесенең милке саналган һәм алар аны үз исәпләренә тотканнар.

Авылда берничә кеше мал-туар көтә. Галимулла Гатиатуллин (19 яшь) сигез ай буе сыерлар көткән. Аңа барлыгы 15 сум түләгәннәр. Атлар көтүче – Гатаулла Кәлимуллин (40). Ул сезонга 40 сум һәм 20 пот он алган.

Авылда ярлы хуҗалыклар шактый була. Андыйларның күбесе мондагы һәм якын-тирә авыл байларына һәм хуторларга төрле эшләргә ялланган яисә читкә чыгып киткән. Мәсәлән, Җәмил Миңлеяров (22 яшь) – Күктәкә, Вәлиулла Миңлеханов (30) һәм Рамазан Рахманколов (32) – Стәрле, Миңнегали Сәгыйтов (24) – Сарлы, Гатаулла Гапсәләмов һәм Фәррахетдин Шәрифуллин – Тымытык һәм Кәрәмулла Галәлетдинов (30) Мәсгут авылында яллы эшчеләр. Аларның хезмәт хаклары төрле күләмдә. Ф. Шәрифуллин, мәсәлән, еллык хезмәт хакын 12 сум күләмендә алган. Аннан күбрәк алучылар да була.

Якын-тирә хуторларда ялланып эшләүчеләр азрак була. Гатаулла Айчуаковның (42 яшь) авылда өе юк. Унике яшьлек кызын ул мондагы Хәлиулла байга хезмәтче итеп биргән, ә үзе берничә чакрым ераклыктагы Сапожников хуторында ел буена яллы эштә булган. Аның еллык хезмәт хакы 30 сум тәшкил иткән.

Күктәкә һәм Яланкүл авылы кешеләрен күрше Бәләбәй өязе авылларында һәм хуторларында да очратырга мөмкин булган. Хәбибулла Хәйбуллин (55 яшь) да, Т. Айчуаков шикелле, йортсыз. Ул хатыны һәм кызы белән Бoҗыр авылында ялланып эшли.

Әхмәтгали Усмангалиев (35 яшь) ел буена – Корчайдан, ә Сәетгәрәй Дәүләтгәрәев (40) Мостафадан кайтып кермәгән. Соңгысының шулай ук авылда өе юк. Ул биш елдан артык хатыны, улы һәм 3 кызы белән Мостафа авылы бае хуҗалыгында эшләп яши.

Насретдин Шамкаев (29 яшь) хатыны һәм анасыннан торган гаиләсе белән алпавыт Пальчиков имениесенә даими эшкә ялланган. Ул да йортсыз, алпавытның эшчеләр өчен салынган барагында яши. Сабит Биккенин да гаиләсе белән Бәләбәй өязендә яллы эштә була. Хатыны белән икесе елга 40

сум хезмәт хакы алалар. Мөхәммәтҗан Мөхәммәтрәхимовның (55 яшь) 25 яшьлек улы шулай ук бу өяздә эшкә кергән[276].

Тормыш никадәр авыр булмасын, халык мәшәкатьләрен бер читкә куеп, күңел дә ача торган булган. Сабан туйлары, җыеннар – аеруча көтеп алынган бәйрәмнәр. Төбәктә зур Сабан туе – Чалпыда, ә җыен исә Күктәкә ярминкәсендә уза торган булган[277].

1911 елның кыш аенда төбәктә күпләрне сискәндергән вакыйга була – Яланкүл мулласы Зәкиҗан Шаһгәрәевне кулга алалар. Бу хакта үзенең «Төрмәләр хатирәсе» исемле китабында ул болай яза: «*1911 нче ел 30 нчы гыйнвардыр, көндез сәгать тугызда, беренче участокның приставы, өч урядник, бер стражник һәм бер переводчик илә безнең йортка килгәннәр иде. Үземне урядник аты илән Күктәкә базарыннан бер полицейский барып алды. Становой пристав нәзакәт берлән генә үзенең ни өчен килгәнен, кайдан мәэмүр (боерыкны үтәүче. – Т.К.) булганлыгын сөйләде. Табигый, мин аңа һәммә ачкычларны биреп, һәммә урыннарны күрсәтә башладым. Ошбу көн тентү кичкә кадәр сузылды.*

*Кич берлән безгә Тымытыкка барырга кушып, үзе Тымытыкка китте. Мин бу язуларны А... дан перевод иттерәм, диде. Мин аңа каршы: мин аның переводына гына риза булмам шул, дигәч, алай булса үзең ышанган кешедән берәр кешене алып барырсың, диде.*

*Без ошбу көн ахшамнан соң Күктәкә имамы мелла Закир әфәнде Галиәкбәров илә Тымытыкка киттек. Без барганда пристав язуларны А... дан перевод иттереп тәмам иткән иде. Мелла Закир әфәндедән бераз нәрсә сорады да, бер дә сорарлык нәрсә тапмадым диеп протокол язып миннән кул куйдырды. Аннан соң без кайтып киттек.*

*Менә дүртенче февраль, җомга көн, көндез тугыз сәгатьтә янә әлеге пристав, өч урядник, бер стражник һәм А... илән килеп тентү башладылар. Бу юлы пристав әүвәлгесе кеби нәзакәтьле түгел, ачулы, караңгы иде.*

*Барыннан да артык А... игътинаэ илә (игътибар белән. – Т.К.) тентемәк, бик гади җөмләләрне дә бик куркынычлы иттереп тәрҗемә кыла иде. Җомга көн булу мөнәсәбәте илә мин приставтан җомга укырга чыгарга сорадым, пристав рөхсәт бирмәде.*

*Вакыйгадан мәчеттә җыелган халыкның хәбәрләре булгач, берничә картлар зур-зур чалмалары илә килеп кереп үзләре приставтан минем мәчеткә җомгага чыгуымны сорадылар. Рөхсәт итте. Ләкин А... ихтыярлы (ирекле. – Т.К.) була торып җомгага чыкмауны әһле тәнкыйть итә иде. Җомга вә шимбә көн тентү тәфтишләре соңында шөбһәле табылган китап-*

---

[276] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 855 сакл. бер.

[277] Шунда ук, 883 сакл. бер.

*ларны пичәтләп алып, үземне арестовайть иттеләр. Юлда Азнакай авылында туктап минем үтенечем буенча кардәшем Фатыйх әфәнде ханәсенә төштек. Кардәшләрем мәсьәләне аңлап байтак кына мөтәәссир (кайгы-хәсрәтле. – Т.К.) булмышлар иде. Бигрәк тә икенче мәхәллә имамы карт хәзрәтнең (Шакир хәзрәтнең) хис вә мәрхәмәт илә кызгануы, йөзеннән вә хәрәкәтеннән мәгълүм булуы илә бергә доносчик А... ны тәкбих (начарлык. – Т.К.) кылуыда илә мәгълүм иде. Пристав монда янә безне үзенең фатирына чакырып – килешмәгән җирләрен килештерү өчен, эшне исбат өчен булырга кирәк – янә бер подпись алды. Кичке сәгать сигезләрдә Бөгелмәнең полициясе астына барып та кердек* [...]».

Югарыда китерелгән өзектән күренгәнчә, Зәкиҗан Шаһгәрәев донос нигезендә кулга алына. Доносчы – Тымытык мулласы (цензура таләбе, я булмаса башка сәбәп аркасында автор аны А... дип күрсәтә, әмма архив документлары монда сүз Адылов турында баруын ачыкларга ярдәм итте). Аның турында мәгълүматлар Тымытык тарихында бирелә.

З. Шаһгәрәевне сак астына алуга нәрсә сәбәп була соң? Китаплар. Яланкүлдә балалар укытуы өстенә, ул аларга бушлай арзанлы китаплар да өләшә торган булган. Цензура рөхсәте белән басылган әлеге китапларда хөкүмәт өчен куркынычлы бернәрсә дә булмый. Шулай да аны кулга алалар, һәм ул берничә ай Бөгелмә, Минзәлә һәм Сарапул төрмәләрендә тоткынлыкта була. Зәкиҗан Шаһгәрәевне гаепләргә тырышу очраклымы соң? Юк. 1911 елда алдынгы карашлы дистәләгән мулла-мөгаллимнәр төрмәгә ябыла. Барысы да җәдитчә укытканнар, халыкның аң-белемен күтәрү өстендә эшләгәннәр. Ә мондый кешеләр патша хөкүмәте өчен куркынычлы исәпләнгәннәр. 1905–1907 елгы вакыйгалардан куркып-өркеп калган реакцион хөкүмәт халыкның аңы үсүне үзе өчен зарарлы санаган, шуңа күрә иҗтимагый хәрәкәттә актив катнаша башлаган мөселманнар арасында заманча, яңача укытуга зур шөбһә белән караган. Менә шуннан чыгып, муллаларга карата репрессия чаралары куллану очраклы булмаган, дигән нәтиҗәгә киләсең.

Зәкиҗан Шаһгәрәев төрмәдә озак утырмый, шул елның җәендә чыгарыла. Гаепләрлек дәлилләр булмауны хөкем органнары танырга мәҗбүр була. Төрмәдә ул вакытын бушка уздырмый: үзенең күргән-ишеткәннәрен көндәлегенә теркәп бара һәм ирекккә чыккач «Төрмәләр хатирәсе» исемле китап язып, аны бастыруга ирешә.

Әлбәттә, аңа иҗат эше ят нәрсә булмаган: шигырьләр һәм хәтта «Яңа дөньяга сәяхәт» исемле фантастик роман да язган. Кызганычка каршы, бу әсәре дә, башка язмалары да эзсез югалган, бары тик берничә шигыре генә югарыда телгә алынган автобиографик китабы аша билгеле. Дин, мәгърифәт, иҗтимагый фикер һәм әдәбият тарихында аның исеме, һичшиксез, лаеклы урын алырга тиеш.

«Төрмәләр хатирәсе»ндә Зәкиҗан Шаһгәрәев үзенең ике хатынын, 2 улын (яшь ярымлык Мөхәммәтришат һәм Әнвәр), туганнары Шәрифҗанны, Фәезхан хаҗины һәм башка кешеләрне атап үтә. Аның дуслары арасында Азнакай имамнары Мөхәммәтфатыйх Шакиров белән Мөхәммәтшакир Фәттахетдиновларны күрәбез. Өстәвенә, соңгысын З. Шаһгәрәев белән кардәшлек җепләре дә бәйләгән. Бөгелмә төрмәсендә яткан һәм этап белән барган чакта, З. Шаһгәрәев аның һәрдаим ярдәмен тоеп яшәгән. Хәер, бер Мөхәммәтфатыйх хәзрәт кенә түгел, бик күпләр, шул исәптән Һади Атласи Зәкиҗан Шаһгәрәевкә теләктәшлек белдерә, кулдан килгәнчә ярдәм итә.

З. Шаһгәрәев кебек муллалар тәэсире нәтиҗәсендә дип уйларга кирәк, төбәктә зур белемгә омтылучы яшьләр булуын билгеләп үтәргә кирәк. 1913 елда Шөгер, Әбдикәй (русча «Абдикеево») һәм Яланкүл авылларыннан Мөхәммәттәүфыйк Шәкүров, Камил Лотфрахманов һәм Гыйсмәтулла Гыйбадуллиннар үзләренең улларын 4 еллык Казан урыс-татар укытучылар мәктәбендә укытыр өчен Бөгелмә өяз земствосына стипендия билгеләүне сорап прошение язалар. Житеш тормышлы саналганлыктан, Камил Лотфрахмановның үтенече кире кагыла. Земствоның 1913 ел, 25 октябрь карары нигезендә, 120 сумлык бер стипендия булдырыла[278].

1916 елгы мәгълүматлар аерым игътибарга лаек. Ул елда Россиядә авыл хуҗалыклары исәбен алу үткәрелә. Күктәкәдә 149 хуҗалык, 299 ир-ат һәм 399 хатын-кыз теркәлә. Яланкүл бу күрсәткечләр буенча күпкә калыша. Анда 114 хуҗалыкта 261 ир-ат һәм 334 хатын-кыз яши. Беренче бөтендөнья сугышы тәмамланмаган, шуңа күрә ике авылда да ир-атлар хатын-кызларга караганда шактый аз.

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Тымытык волостенда качаклар күренә башлый. Аларның күпчелеге мондагы хуторларга килеп утыра. 3 ир-ат һәм 2 хатын-кыз качак Күктәкәдә сыену таба.

Авыр сугыш елларында да авыл халкы зур мәйданда иген игә һәм терлек асрый. Күктәкәдә 257 ат (шул исәптән 194 эш аты), 366 мөгезле эре терлек (156 сыер), 800 баш сарык һәм 176 кәҗә исәпләнә. Яланкүлдә исә 259 ат (182), 350 мөгезле эре терлек (140), 704 баш сарык һәм 120 кәҗә була[279].

Билгеле, хуҗалыкларга карап мал-туар саны нык аерылган. Бигрәк тә гаилә башлыклары сугышка киткән хуҗалыкларга авыр була. Аларның малтуары һәм чәчүлек җирләре азая.

Аерым хуҗалыкларга кагылышлы чыганаклар күп түгел. Шулай да Яланкүл «башкорты» Галиулла Габделхаликов хуҗалыгын тасвирлаучы

[278] Бюллетени справочного бюро отдела народного образования Самарской губернской Земской Управы [...]. С. 180–181.

[279] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 885 сакл. бер.

мәгълүматларга тукталып үтик. Аның гаиләсендә хатыны, 3 улы (берсе сугышка мобилизацияләнә), кызы һәм оныгы була. Ул 7 ат (шул исәптән 3 эш аты), 10 мөгезле эре терлек (4 сыер), 21 сарык һәм 3 кәҗә асрый. 1915–1916 елларда дүрт иманасында арыш, бодай, тары, карабодай, борчак һәм борай чәчә. 1915 елда уңыш түбәндәгечә алына: арыш – 350, бодай – 80, солы – 80, борчак – 80, борай – 60, тары – 24, карабодай – 23 пот. Чәчүлекләр мәйданы 11 дисәтинә чамасы[280].


Особое совѣщаніе для обсужденія и объединенія мѣропріятій по продовольственному дѣлу
ВСЕРОССІЙСКАЯ СЕЛЬСКОХОЗЯЙСТВЕННАЯ ПЕРЕПИСЬ 1916
Губернія / область
Уѣздъ / округъ
Волость / станица и пр.
Общество (сельское, поселковое, аульное и пр.).
Селеніе / выселокъ, аулъ, улусъ, имѣніе и проч.
Фамилія, имя и отчество домохозяина
Сословіе или разрядъ крестьянъ
Національность
Приписной, посторонній, бѣженецъ. (Подчеркнуть).
№ по списку домохозяевъ

*Китапта сүз барган Галиулла Габделхаликовның сословиесе башкорт, милләте – татар дип язылган 1916 елгы документ фрагменты*

Күктәкәгә якын кайбер хуторлар турында да мәгълүматлар биреп үтик. Алар арасында дворян В.А. Бекбулатовныкы аерылып тора. 1916 елда хуторда 11 ир-ат һәм 4 хатын-кыз исәпләнә. Дворян һәм аның хатыныннан башка, монда бер хатын-кыз хезмәтче һәм 12 ялланган эшче (өчесе сугыш тоткыны) яши. Ул 34 ат (шул исәптән 24 эш аты), 33 мөгезле эре терлек (17 сыер) һәм 50 баш сарык асрый. 1915 елда Виталий Бекбулатов арыш (90 дисәтинә), солы (22), бодай (15), борчак (15), карабодай (9) һәм тары (3) чәчә. Арыш – 4500, солы – 3280, бодай – 600, борчак – 900, карабодай – 90 һәм тары 210 пот җыеп алына. Икмәкне ул хутордан 25 чакрым ераклыктагы Урыс Шуганы авылы базарына алып барып саткан.

Мещан Г.А. Андреев хуторы да чагыштырмача зурлардан санала. 1915 елда мондагы иген мәйданы – 84 дисәтинә. Чәчүлекләрнең төп өлешен арыш

[280] Шунда ук, 886 сакл. бер.

(63 дисәтинә), калганын солы (15) һәм киндер (6) алып тора. Әлеге мәйданнан ул 8200 пот арыш, 1500 пот солы һәм 420 пот киндер җыеп ала. Григорий Андреевның да гаиләсендә ике генә кеше. Алардан тыш хуторда хезмәткәрләр (гаиләләре белән 6 кеше) һәм ялланган эшчеләр (8) яши. Болар арасында 5 качак һәм 3 сугыш тоткыны була.

Сугыш тоткыннары мещаннар Александра Сапожникова белән Мария Машкина хуторларында да эшлиләр. Әлеге хуторлар, Г.А. Андреевныкы белән чагыштырганда, күпкә кечерәк. Аларның беренчесендә чәчүлекләр – 24, икенчесендә 9,5 дисәтинә тәшкил итә.

Совет хакимияте урнашкач, авылларда советлар оештырыла. 1918 елның кыш азагында Күктәкә авыл советы рәисе булып 45 яшьлек Садыйк Миңлеханов тора. Әгъза итеп Сөләйман Колыев (40 яшь) сайланган. Яланкүлдә рәис вазифасын Габделхак Мостафин (47 яшь) башкара. Күктәкәдән Харрас Дәүләтгәрәев (32) Тымытык волосте башкарма комитетына әгъза итеп сайланган[281].

Язмабызда телгә алынган кайбер кешеләрнең алга таба язмышы белән танышып үтү укучылар өчен кызыклы да, гыйбрәтле дә булыр. Алар язмышында тоталитар дәүләт системасының кешегә мөнәсәбәте, ахыр чиктә, чын йөзе күз алдына килеп баса. Һәр язмыш саен – фаҗига...

Егерменче еллар ахыры-утызынчы елларда – дин белән көрәш киң җәелгән чорда – мулла-мөәзиннәрне эзәрлекләү, мөлкәтләрен конфисковать итү, кулга алулар, төрмәгә ябулар һәм авылдан сөрүләр массакүләм төс ала. Дин әһелләренең бик азы гына бу афәттән котыла. Күктәкә һәм Яланкүлдәге мулла-мөәзиннәрнең берсен дә, күрәсең, язмыш аямый.

Мулла Галим Дәминов (1860 елда туган) һәм мөәзин Габдулла Кәримовның (1885) иң беренче чиратта мал-мөлкәте конфискацияләнә. Беренчесе ул вакытта хатыны Мөнәвәрә, уллары Фатыйх, Таһир һәм кызы Мөзәянә белән яши. Аның 304 сум 50 тиен күләмендә мал-мөлкәте тартып алына. Аларны озакламый Магнитогорскийга сөрәләр.

Габдулла Кәримовның гаиләсе хатыны Хәдичә һәм улы Габдрахманнан тора. Аларның мал-мөлкәте күп булмый, ахры, конфискацияләнгәне нибары 55 сум бәяләнә. Ары таба язмышлары билгесез.

Миргасыйм Әхмәдиев (1881 елда туган) Яланкүлдә 1915 елдан мулла булып тора. 123 сумга бәяләнгән мал-мөлкәтен тартып алганда, ул хатыны Кәмәрлебанат, улы Таһир, кызлары Салиха һәм Сәүдә белән яши. Документта аның «сәнәклеләр» восстаниесендә командир һәм комендант ярдәмчесе буларак катнашуы да күрсәтелә. Ә моның өчен большевикларның, бу вакыйгадан

[281] ТР ДА, Р–1167 фонд, 1 тасв., 160 сакл. бер.

соң күпме еллар үтүгә карамастан, барыбер каты җәза бирүләре күпләргә мәгълүм.

Егерменче еллар башында Яланкүлдән Куштирәккә (Башкортстанның Бакалы районына керә) күчеп киткән мулла Зәкиҗан Шаһгәрәев тә репрессия корбаны. Истәлекләргә караганда, 1937 елда ул кулга алына һәм шуннан бирле аның турында бернинди хәбәр булмый.

З. Шаһгәрәевкә донос язып төрмәгә утырттырган Ш. Адыловның Әкрәм исемле улы да кулга алына. 1922 елдан 1926 елга кадәр ул кызыл мал белән сәүдә итә. 1933 елда колхозның икмәген урлап 10 елга хөкем ителә. Хатыны Бибикамал һәм кызы Җиһан яшәгән йорт конфискацияләнә – алар, протоколда күрсәтелгәнчә, «колхоздан куылып чишендерелә» («конфискацияне» татарча «чишендерү» сүзе белән алыштыру – ул чорның документация стиле).

«Колхоздан куылып чишендерелгәннәр» исемлегендә тагын элеккеге байларны да, аларның балаларын да күрәбез. 1930 елда Кәрәмәтулла Гыйззәтуллинны революциягә кадәр мануфактур белән сәүдә иткәне, ә НЭП чорында сепарат һәм молотилка тотканы өчен авыл советы сайлау хокукыннан мәхрүм итә. Тагын берничә елдан «кара исемлек»кә кертәләр.

Әгъләм Әсхәбиевне (1896 елда туган), элек җир биләүче булганы өчен, хатыны һәм кызы белән Магнитогорскийга сөрәләр. Минай Әсхәбиевнең (1891) 1917 елга чаклы сәүдә белән шөгыльләнгәнен, ә НЭП чорында хезмәтче яллап тотканын һәм сепараты булуын искә төшерәләр һәм «чишенделүчеләр» исемлегенә кертәләр.

Миргали Хәсәнов (1879 елда туган) хатыны, 3 улы һәм кызы белән Пермь шәһәренә сөргенгә озатыла. Җир биләүче булуын, аннары 1917–1927 елларда молотилка тотуын һәм хезмәтче яллавын гаеп итәләр.

Күпме гаилә йортсыз кала, туган авылларыннан куыла ул каһәрле чорда. Аянычлы язмышка дучар булган кешеләр – репрессия корбаннары исемлеге зур. Без аларның барысын да белергә тиеш. Чөнки аларның язмышы артында – безнең тарих[282].

[282] Моннан якынча өч дистә ел элек язган тарихи очеркның баштагы битләренә моңарчы аз кулланылган чыганакларга таянып, шактый зур өстәмәләр керттем (текстның калган өлеше үзгәрешсез калды). Күктәкә атамасының ревизия (халык санын алу) документларында беренче тапкыр 1795 елда кулланылуы ачыкланды

## § 10. Мәлбагыш һәм Түбән Якый

Мәлбагыш һәм Түбән Якый – табигатьнең матур җирендә, тауларга сыенып урнашкан уртача зурлыктагы янәшә авыллар. Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнары аша агучы Мәллә елгасы мондагы чишмәләрдән үзенә көч ала.


47906 [illegible] 30
47907 [illegible] 8
47908 [illegible] 27
47909 [illegible] 18
47910 [illegible] 46
47911 [illegible] 36
47912 [illegible] 45
47913 [illegible] 15
47914 [illegible] 13
47915 [illegible] 32
47916 [illegible] 13
47917 [illegible] 30
47918 [illegible] 18
47919 [illegible] 25
47920 [illegible] 28

*1739 һәм 1744 елларда Шурсак авылыннан килеп утырган ясаклы татарларның тулы булмаган исемлеге*

Мәлбагыш һәм Түбән Якый авыллары арасында күпмедер уртаклык була. Бу, беренче чиратта, географик атамага кагыла. Кайчандыр Мәлбагыш Югары Якый дип йөртелгән. Тарихка күз салсак, моның сәбәбе аңлашыла.

Бу авыллар халык санын алу чыганакларында 1 нче ревизиядән (1719 ел) соң телгә алына башлый. Монда бер төркем (21 ир-ат) ясаклы татарлар Казан өязенең Шурсак авылыннан 1739 һәм 1744 елларда күчеп утыралар. 1739 елда Ишмәй Аймәков (улы Гомәр) гаиләсе күченә, 1744 елда – калганнары (Әхмәр һәм Миңлебай Акмаевлар, Мәмәт Илмәтәв, Әммәт Килкин, Минкә [...]ачев[283] (улы Юртай), Уразман Уразаев, Мусай Балтаев, Сөләйман Балтаев, Рахманкол Ямамәтов, Йосып Әлмәков, Исмәгыйль Имәшов, Мөслим Акманаев, Абдул һәм Габдрахман Мәмәкәевлар, аларның туганы Мөслим Әлмәкәев, Габдерәззак Әлмәков, Касыйм Исәев, Бәшир Исмәгыйлов.

[283] 1762 елгы документта фамилиясе Карсачев.

Әлеге чыганакта авыл русча «По речке в вершине Мелле Девлетбахты Якеево тож» һәм Җөри юлындагы Туйкә Абдулов йөзлегенә карый дип язылган[284].

Аккүздән (Иж елгасы буендагы авыл) 1740 елда Габдрахман Юнысов (2 улы белән), Габдесәлим һәм Абдул Юнысовлар, Гомәр Рысаев, Токфәр Мөслимов, Гайса Үсәев, Хәлим Тукаев, Актык Кадермәтовлар, барысы 10 ир-ат килеп утыра. Әлеге чыганакта да яңа барлыкка килгән авыл русча «По речке в вершине Мелле в деревне Девлетбахте Якекеево тож» һәм Җөри юлындагы Туйкә Абдулов йөзлегенә карый дип язылган[285]. Әмма болардан 8 ир-ат Оренбург янындагы Сәет бистәсенә күченә[286].

Дәүләтбакты (Якый) авылында 1748 елда барысы 54 ир-ат ясаклы татар яши. Боларның күпчелеген югарыда әйтеп үткән Арча юлының Шурсак (бу чыганакта «Шубсак») авылыннан күчеп килгән Мөслим Акманаев, Ишмән Әймәков, Әхмәр Акманаев, Миңлебай Акманаев, Мәмәт Илмәтов, Яммәт Килкин, Минкә Ксачев, Уразман Уразаев, Муса Балтаев, Сөләйман Балтаев, Рахманкол Ямамәтов, Юсуп Әлмәков, Исмәгыйл Имәшов хуҗалыклары тәшкил итә. Казыяр авылыннан күченүчеләр Габдрахман Юлдашов, Рахманкол Юлдашов, Мәмәдәл Булатов, Зәет Балтаев хуҗалыкларыннан тора. Аккүз авылыннан Касыйм Хөсәенов, Аптык Кадермәтов, Күзләүдән (чыганакта «Деревня по речке Кузлев») Мөхсин Сма[и]ловларны күрәбез. Авыл исеме чыганакта «Новопоселенная по речке Чершане Мелли у деревни Дюлметбахты[287] Якеево тож»[288] дип язылган. Алдарак карап үткән чыганак белән чагыштырганда, кайбер исемнәрнең язылышында күпмедер аерма күзәтелә.

Шул ук 1748 елның тагын бер документында Якыйда («Якеево что на речке Менле») 26 ир-ат ясаклы татар теркәлгән. Исемлек Хәсән Тәмәев (60 яшь; уллары Имангол, Хөсәен), Сәет Ишеголов (70; улы Зәет) һәм аның нәселдәшләре Солтангол (8) и Юлдаш (5) Айдаголовлар, Ишкилде Гөләев (20), мулла Сәлим (30) һәм Мансур (25) Әмәкәевлар, Үтәгән (60; улы Кусадык) һәм Зәет (57; уллары Султангол, Үтәгол, Кинҗә) Сабанаевлар, Сөендек Шәрипов (20), Габделкәрим (37; уллары Ишморза, Мортаза) и Саликей (17) Габдрахмановлар, Ишим Бимурзин (45; улы Юлдаш) һәм аның нәселдәше Мерәс Илмурзин (1), Уразгилде (50) һәм Бигәш (30) Ишмәтовлардан тора[289]. Болар гасыр ахырында Түбән Якыйның типтәр сословиесен тәшкил итәчәк, кайчан килеп утырулары билгесез.

---

[284] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1154 сакл. бер., 270–271 б. а.
[285] Шунда ук, 1154 сакл. бер., 280 б. а.–281 б. а.
[286] Шунда ук 1155 сакл. бер., 494–494 б. а.
[287] Башка чыганакларда Дәүләтбакты.
[288] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1142 сакл. бер., 663–665 б. а.
[289] Шунда ук, 11–12 б.



*Якый ясаклы татарлары теркәлгән 1748 елгы документ фрагменты. Болар 1762 елдан соң типтәр сословиесендә теркәләчәк*

Якый (Дәүләтбакты) авылына караган тагын 2 ясаклы татар 1748 елда Нәдер волосте буенча 2 исемлектә телгә алына. Монда Уфа өязенең Ногай юлына караган Курсан авылыннан Ярмәк Ишмәтов (30 яшь) килеп утыра[290]. [Х]өсәен Миңлбаев (41) һәм аның уллары Габдессәлам (6) һәм Габделкәрим (3) Дәүләтбактыдан (чыганакта «Девлетбатлы») Тәйсуган авылына күченәләр[291].

1762–1763 елгы халык санын алу документлары Дәүләтбакты авылының Юрмый волосте территориясендә урнашуын, волость старшинасы Хасбулат Мөтеков булуын күрсәтә. Авыл халкы берничә исемлектә теркәлгән.

59 ир-аттан торган беренче исемлек башында Ишмән Аймәков (70 яшь; уллары Сөбхангол, Зәеш (анықы Фәйзулла), Габидулла) һәм ике хатынлы Габдрахман Юлдашов (59; уллары Казаи, Габдерәззак) гаиләләре турында мәгълүмат бирелә. Соңгысының икенче хатыны Уфа өязе Казан юлы Куян авылының башкорт сословиесендәге татар кызы була, үзе дә бер кызын шул сословие кешесенә кияүгә бирә[292].

1763 елда аерым исемлек белән Юрмый волостеның Дәүләтбакты (Якый) авылында ясаклы татарлар Сөләйман Балтаев (53 яшь; уллары Яумәт (анықы Гөзәер), Ярмәк, Япай) һәм Әхмәр Акманаев (67; уллары Салих, Габбәс, Ишмөхәммәт) гаиләләре (9 ир-ат) теркәлгән[293].

Шулай итеп, ике исемлектәге ясаклы татарлар барысы 68 ир-ат тәшкил итә, боларның сословиесе гасыр ахырында да үзгәрмәячәк. 1763 елда теркәлгәннәр 1795 ел алдыннан Мәлбагышка күчеп утырачак[294].

---

[290] Шунда ук, 2450 сакл бер., 248 б.

[291] Шунда ук, 2450 сакл бер., 252 б.

[292] Шунда ук, 3795 сакл бер., 368–373 б.

[293] Шунда ук, 374–375 б.

[294] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 153 б.

Бу ике авыл ясаклы татарларының Юрмый волостена каравын күрдек. Шул ук 3 нче ревизия (1762 ел) вакытында ясаклы татарларның Түбән Якый (чыганакта «Якиево, что на речке Мелле вершины») авылы буенча өченче исемлеге дә төзелә, болар старшиналар Йосыф Нәдеров белән Килмәкәй Юртаев командасына (Нәдер волосте) карый. Бу исемлеккә түбәндәге 34 ир-ат керә: Хәсән Тәмәев (76 яшь; оныгы Сөбханкол Иманголов), Мерәс Илмурзин (17), Сәет Ишиголов (86; улы Зәет), Ишкилде Кулаев (36; улы Якуп), мулла Сәлим Әмәкәев (46; улы Габдессәлам һәм туганы Минсур), Үтәгән Сабанаев (1686–1752; улы Кусадык (анықы Ишбулды)), Зәет Сабанаев (1689–1750; уллары Солтангол, Кинҗә (анықы Ишкилде)), Габделкәрим Габдрахманов (53; уллары Ишморза, Мортаза (анықы Габделваһап)), Сәликәй Габдрахманов (1729–1755; улы Әлкәй), Ишим Бимурзин (1701–1755; улы Юлдаш (анықы Мөхәмәдьяр)), Уразгилде (66) һәм Бигәш (46; улы Тәвәй) Ишмәтовлар, Зәй буендагы Бакый авылыннан күчеп килеп мәчеттә мулла вазифасын башкаручы Габдессәлах Сөләйманов (56; уллары Мөрсәлим, Әмир (анықы Яхья), Әхмәр, Назир), Габделҗәлил Сөләймәнов (46), Солтангол (1738–1757; улы Солтанморат) һәм Юлдаш (21) Айдаголовлар. Сөендек Шәрипов Кәкре Елга авылына күчеп утыра[295]. Әлеге исемлеккә кергән ясаклы татарлар 1795 елда типтәр сословиесендә күрсәтеләчәк.

Исемлекләрнең соңгысы (1762 ел, июнь) Казан өязенең Алат юлыннан күчеп килгән йомышлы («служилый») татарлар Якуп Мәмәткул улы Арысланов (56; уллары ике хатынлы Йосыф (анықы Назир), Мостафа, Миңлибай, Сәйфулла) һәм ике хатынлы Габделкәрим Мәмәтколов (46; улы Мәвлүш Мәмкәй) гаиләләреннән тора. Болар турында русча «перешедшие ис Казанского уезду Алацкой дороги ис починка Шаши, Кунер Другова Усаду и с деревни Мамашевой», дип әйтелә[296]. Бу исемлектә барысы 8 ир-ат теркәлгән.

Авыллар кайчан барлыкка килгән дигән сорауга ачыклык кертеп үтик. Татарстан дәүләт архивында саклanучы 1900 елгы документта Мәлбагыш авылы кешеләренең ерак бабалары Чистай, Минзәлә һәм башка өязләрдән якынча 150 ел элек күчеп утыруы хакында әйтелә. Мондагы җирләр ул вакытта старшина Нәдер Уразмәтов карамагында була. Шуңа күрә документта аларның килеп утыруы турында «поселились на свободной земле, которая считалась принадлежащей роду Надыра Уразметева» дип әйтелә[297].

Әлеге факттан чыгып, Мәлбагыш авылы кешеләренең ерак бабалары Нәдер Уразмәтов старшина итеп билгеләнгән чорда, ягъни 1730 елларда килеп утырган дип әйтергә була. Чыннан да, беренче ясаклы татарларның 1739 елда килеп утыруын алдарак телгә алган архив документы күрсәтте.

[295] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3801 сакл. бер., 1196–1198 б.

[296] Шунда ук, 3795 сакл бер., 376–377 б.

[297] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 82 сакл. бер.

Түбән Якый «типтәр»ләре 1840 елда бабаларының биләмәчеләр рөхсәте белән 170 елдан артык элек килеп утырулары турында әйтәләр[298]. Димәк, алар Юрмый волосте территориясенә якынча 1670 елда аяк баскан булып чыга. Бу чынбарлыкка туры килә, чөнки типтәр сословиесендәге татарлар төбәккә гадәттә биләмәчеләр (вотчинниклар) белән бер чордарак килеп утыралар.

1773–1774 елларда төбәктән күп кенә авыллар Е. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышында катнашалар. 1775 елның 16 февралендә Уфа провинциаль канцеляриясеннән Оренбург губерна канцеляриясенә җибәрелгән документта восстаниедә катнашкан урыс булмаган авыллар теркәлгән. Исемлектә Якый һәм Дәүләтбакты авылларын да күрәбез.

1795 елда Россиядә 5 нче ревизия үткәрелә. Авыллар беренче тапкыр Югары Якый (Мәлбагыш) һәм Түбән Якый дип күрсәтелә. Беренчесендә 78 ир-ат һәм 51 хатын-кыз йомышлы татарлар[299], 26 ир-ат һәм 19 хатын-кыз (8 хуҗалык) ясаклы татар исәпләнә.

Мәлбагыш ясаклы татарлары 1795 елгы ике ревизия документында теркәлгән. Беренчесендә Дәүләтбактыдан күчеп утырган Әшир Рахманколов (69 яшь; уллары Биккенә, Мөхәммәтсадыйк), Исәммәт Мәмәтов (46; улы Гидаятулла), Гомәр Миңлебаев (1742–1786; уллары Мәхмүт, Мәсгут) хуҗалыклары, барысы 7 ир-ат һәм 6 хатын-кыз теркәлгән[300]. Икенчесендә Аптикәй Кусадыков (1692–1785; уллары Мәвлүкәй, Абдулла), Ишмән Ишмәтов (48; уллары Монасыйп, Мөхәррәм, Мостафа), Япай Сөләйманов (54; улы Яхья, 1794 елдан рекрутта), Гөзәер (1754–1789; уллары Нәдерша, Батырша, Гаделша) һәм Зәбир (31; улы Габдерәшит) Яумәтовлар, Габделкәрим (27), Габделгази (25) һәм Ильяс (20) Габбәсовлар, барысы 15 ир-ат һәм 9 хатын-кыз исәпкә алынган. Болардан бары беренче хуҗалык кына монда электән яшәгән, калганнары Дәүләтбактыдан күчкәннәр[301]. Өченче төркем ясаклы татарларны Мәндәй һәм Мөхәммәт Абдуллиннар, Рәфикъ Мөслимов хуҗалыклары тәшкил итә, алар чыгышы буенча Дәүләтбактыга карый (бу хакта 1811 елгы документта әйтелә)[302].

Шулай итеп, Мәлбагыш Дәүләтбакты (Түбән Якый) ясаклы татарлары исәбенә шактый зурая. Аңарчы монда бу сословиегә караган бары бер генә хуҗалык була.

Түбән Якыйда 1795 елда 26 хуҗалыкта 91 ир-ат һәм 63 хатын-кыз яши. Авыл кешеләре өч сословиегә бүленгән. Аларның күпчелеген «типтәр»ләр

---

[298] Малоизученные источники по истории Башкирии. Уфа, 1986. С. 86.

[299] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 22 сакл. бер., 240–244 б. а.

[300] Шунда ук, 23 сакл. бер., 152–152 б. а.

[301] Шунда ук, 153–154 б. Күченүчеләр турында документта болай әйтелә: «вышеписанные Ишмен Ишметев с протчими нижеписанными людьми в сей скаске написаны по увольнению деревни Девлетбахты обывателями … на одной даче разстоянием в трех вершах».

[302] Шунда ук, 84 сакл. бер.

(20 хуҗалык, 59 ир-ат һәм 62 хатын-кыз), калган өлешен йомышлы татарлар (5; 27 һәм 29) һәм ясаклы татарлар (1; 5 һәм 3) тәшкил итә[303].

Ревизия документларына таянып, бу сословиеләрнең һәрберсенә тукталып үтик. Түбән Якыйда (чыганакта «Якеево Мелли реки») 1795 елда типтәр сословиесендәге 59 ир-ат һәм 62 хатын-кыз татар исәпләнә (1782 елда шул тәртиптә 53 һәм 54 була). Болар Нәдер волостеның старшина Ишмөхәммәт Йөзәев командасына (1 нче типтәр командасы) карый. Исемлектә Сөбханкол Иманколов (43 яшь; ике хатынлы), Якуп Ишкилдин (38; ике хатынлы), Кинҗә Зәетов (59; ике хатынлы), Юлдаш Айдаголов (54) һәм башка хуҗалыклар теркәлгән. Җирләрен Юрмый волосте биләмәчеләре алпавыт Сумароковка сатканнан соң, Якый халкы рөхсәтен алып монда Урта Ямаш авылыннан Рахманкол һәм Морат Ниязовлар килеп утырган. Мерәс Илмурзов гаиләсе Колшәрип авылына күчеп утыра. Нәзир Бикколовның варислары Бәләбәй округының Райман авылына, ике хатынлы З. Сәетов гаиләсе – шул ук округның Әнәс авылына күченәләр[304].

1795 елда Якыйда (чыганакта «Нижнее Якеево Куру Илга тож») беренче тапкыр 5 ир-ат һәм 3 хатын-кыз ясаклы татар (Габҗәлил (47) и Ибраһим (40) Әпсәламовлар гаиләләре) исәпкә алына. Алар монда Ямашбаштан (чыганакта «Ямашбаш Танатарово тож») 1787 елда күченәләр, чөнки җирләрен Юрмый волосте биләмәчеләре полковник Сумароковка саталар[305]. «Типтәр»ләр кебек, болар да Нәдер волостена карый.

Мәлбагыш һәм Түбән Якый авыллары атамаларының килеп чыгышы турында берничә сүз әйтеп үтик. Бу хакта сөйләгәндә өлешчә Мәлбагыш авылының сугыш һәм хезмәт ветераны С. Исхаков язып калдырган истәлекләргә таянабыз. Анда шундый бер риваять китерелә.

Бу якка беренчеләрдән булып Әхмәтяхья һәм Мөхәммәтяхья исемле бертуганнар килеп утыра. Вакыт узу белән боларның уллары һәм кызлары үсеп, үзләренә аерым тормыш коралар һәм, шулай итеп, Әхмәтяхья (җирле диалектта – Якый) белән Мөхәммәтяхья икесе ике ыру булып яши башлыйлар. Еллар уза, боларга каяндыр урыслар чукындырудан качып килгән тагын берничә гаилә татар килеп кушыла. Әхмәтяхья ыруы Мәллә елгасының түбән ягындагы, Мөхәммәтяхья ыруы аның югары ягындагы җирләрдә яшиләр. Түбән Якый һәм Югары Якый авыллары атамалары шуннан барлыкка килгән.

Түбән Якыйга каяндыр ике гаилә чуашлар да килеп утыра. Әмма алар монда озак яшәмиләр, ни сәбәпледер, күчеп китәләр. Югары Якыйга Идел буеннан мишәрләр килеп төпләнә. Алар күпсанлы булган, күрәсең, чөнки авылның кинәт зураюы күзгә ташлана. Бу хакта тулы сөйләгәнче, атамаларга кагылышлы фикерләрне әйтеп бетерик.

---

[303] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 193, 294 б.
[304] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 24 сакл. бер., 159–163 б.
[305] Шунда ук, 23 сакл. бер., 139–139 б. а.

Мәлбагыш 1917 елга чаклы әдәбиятта күбрәк Югары Якый атамасы белән йөри. Соңгысы Мәлбагыш атамасыннан аермалы буларак, мөстәкыйль кулланыла. Авылның хәзерге атамасы исә иярчен атама буларак кына, җәя эчендә күрсәтелеп килә. Шуңа күрә С. Исхаков истәлекләрендә Мәлбагыш атамасы авылга Николай патша чорында бирелә дигән фикер әйтелә.

Мәлбагыш – Мәллә елгасына таба агучы һәм шул елгага кушылучы инеш атамасы буларак та билгеле. Мәлләгә карап акканга күрә (Мәлләгә+багыш), кыскартылып Мәлбагыш (чагыштыру өчен, көнбагыш сүзенең килеп чыгышын алырга була) дип аталуы бик мөмкин. Болай фикер йөрткәндә, «багу, багыш» сүзләренең мишәрләр арасында (ә Мәлбагыш авылына мишәрләр килеп төпләнүе хакында әйтелде) кулланылуын да искә алырга кирәк. Гидроним тора-бара авыл атамасына әйләнгән.

XIX гасырның беренче чирегендә Югары Якый (Мәлбагыш) авылы шактый зурая. 1816 елда Югары Якыйда 170 ир-ат һәм 56 хуҗалык теркәлә. Халыкның төп Мәлбагышта яшәүче өлешен йомышлы («служилый») татарлар (104 ир-ат; чыганакта авыл «в деревне под названием Мальбагушевой» дип күрсәтелә), калганын ясаклы татарлар (64; ике исемлектә) һәм «отставной» солдатлар (2) тәшкил итә[306].

1816 елгы ревизия документында Мәлбагышның ике сословие татарлары бер исемлек белән бирелгән: башта – йомышлы татарлар (103 ир-ат һәм 97 хатын-кыз; Хәсән Тарьянов (39 яшь), Хәмит Шәрипов (57), Салих Сәетов (63), Морадым Мансуров (61), Сөбханкол Хөҗәмколов (55), Габделкәрим Назиров (53), Шәрип Гомәров (55) һәм башкалар, барысы 42 хуҗалык), аннары – ясаклы татарлар (35 ир-ат һәм 35 хатын-кыз; Мәвлүкәй Аптикәев (53), Монасыйп Ишмәнов (39), Зәбир Яумәтов (51), Батырша Гөзәеров (32), Габделкәрим Габбәсов (47), Биккенә Әширов (48), Исәммәт Мәмәтов (66), Мәндәй Абдуллин (63) һәм башкалар, барысы 17 хуҗалык). Барысы 138 ир-ат һәм 132 хатын-кыз (59 хуҗалык) исәпләнә. Алар Кәкре Елга волостена карый һәм лашман бурычын (чыганакта «лашманная повинность») башкаручы йомышлы һәм ясаклы татарлар санала[307].

Лашман бурычын башкаручы ясаклы татарларның (29 ир-ат һәм 28 хатын-кыз; 10 хуҗалык) икенче төркеме 1816 елда Югары Мәллә[308] авылында теркәлгән. Болар Нигъмәтулла Габделмәнов (49 яшь), Гыйсмәтулла Габделмәнов (27), Мөхәммәдьяр Гапсәламов (16), Таҗетдин Мөхәммәтов (45), Ишбулды Мөхәммәтов (34), Габдерәшит Шәрипов (47), Мөсәллим Шәрипов (60), Габдерәфикъ Шәрипов (43), Габидулла Мәмәтаев (42), Ишбулды Зәрәев (41) хуҗалыклары була[309].

[306] БР МА, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 129 б. а.
[307] Шунда ук, И–138 фонд, 2 тасв., 197 сакл. бер., 368–384 б.
[308] Чыганакта Мәлбагыш урынына әнә шулай, «Верхняя Мелля» дип язылган.
[309] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 197 сакл. бер., 163–168 б.

1816 елда Түбән Якыйда 115 ир-ат һәм 28 хуҗалык була. Боларның төп өлешен типтәр сословиесендәге татарлар (78 ир-ат) тәшкил итә. Калган халыкка йомышлы (31 ир-ат), почта ташучы (чыганакта «исправляющие почтовую гоньбу»; 2 ир-ат) һәм ясаклы (2) татарлар керә. 2 ир-ат «типтәр» аерым исемлектә һәм аерым авылда (чыганакта «Под названием Якиево Услы Княк Юлдаш речки Менли Крык Кулан тож») теркәлгән[310].

Әлеге чыганак мәгълүматын тулыландырып үтик. 1816 елгы ревизия исемлегендә Якыйның (чыганакта «Якеево») типтәр сословиесендәге татарлары (30 хуҗалыкта 78 ир-ат һәм 57 хатын-кыз; Мөстәкыйм Мансуров, Ишбулды һәм Габдулла Кусадыковлар һәм башкалар) старшина Ишмөхәммәт Йөзекәев командасында күрсәтелә[311].

Шул ук Якыйда (чыганакта «Якеево») 1816 елда 31 ир-ат һәм 27 хатын-кыз (13 хуҗалык) йомышлы татарлар Нәзир Йосыпов (61 яшь), Тимер Мостафин (45), Сәйфулла Якупов (59), Габидулла Тарзимин (59), Инсан Әмировларның (50) һәм башкаларның гаиләләре теркәлгән. Бертуган Тохфәтулла (19) һәм Гыйсмәтулла (14) Ибраһимовлардан торучы ясаклы татарлар бер хуҗалык тәшкил итә. Аларны да кертеп, Якыйдагы йомышлы һәм ясаклы татарлар 33 ир-ат һәм 27 хатын-кыз тәшкил итә. Бу халык Кәкре Елга волостенда исәпләнеп лашман бурычын (чыганакта «исправляющие лашманскую повинность») башкара[312].

1859 елда Түбән Якыйда типтәр сословиесендәге 181 ир-ат һәм 215 хатын-кыз (25 хуҗалык) татар исәпкә алына. Болар исәбенә Мәһди Мәсәев, Гыйззәтулла Фәйзуллин (22 яшь), Фәтхулла Кусадыков (68), Габделлатиф Рәфиков, Габделлатиф Ишкилдин, Габдерәхим Ишкилдин, Тохфәтулла Ишмурзин, Туйчы Ишмөхәммәтов (52), Бикмөхәммәт Динмөхәммәтов (52), Хәбибулла Ишмурзин (71), Нигъмәтулла Ишмурзин (67), Мифтахетдин Мөхәммәтгалиев (32), Мөхәммәтша Моратовлар (60) һәм башка хуҗалыклар керә. Исемлек ахырында Кичүчат авылыннан күчеп килгән Әхмәди Сөпханколов (46; указлы мулла) хуҗалыгы теркәлгән[313]. Аерым исемлектә Якыйның (чыганакта «Узлы Кияк речки Мелли, Крык Кулан тож») 2 күчеп киткән «типтәр» хуҗалыгы күрсәтелә. Бертуган Мөхәммәтситдыйк һәм Мөхәммәтзарип Йосыповлар Бәләбәй өязенең Япрык авылына, Мөхәммәтҗан Габделнәфыйков Бәйрәкәгә күченә[314]. Типтәр сословиесендәге татарлар 1855 елдан 23 нче кантонның 7 нче юртасы составында «башкорт» (чыганакта «башкиры из тептярей») санала, «Башкорт» гаскәрендә торып хәрби хезмәткә җәлеп ителә.

---

[310] Шунда ук, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 129 б. а.

[311] Шунда ук, И–138 фонд, 2 тасв., 168 сакл. бер., 720–727 б.

[312] Шунда ук, 197 сакл. бер., 244–250 б.

[313] Шунда ук, 757е. сакл. бер., 87–100 б.

[314] Шунда ук, 102–103 б.

Самара губернасы буенча статистик әдәбият 1859 елда Мәлбагышта 301 ир-ат һәм 321 хатын-кыз (82 хуҗалык), Түбән Якыйда 256 ир-ат һәм 254 хатын-кыз (87 хуҗалык) яшәвен күрсәтә. Авылларда берәр мәчет эшли[315]. Түбән Якыйдагы халык санына югарыда күрсәтеп үткән «типтәр»ләрдән тыш дәүләт крестьяннары да керә.

Әлеге статистик мәгълүматтан күренгәнчә, Мәлбагышта халык саны күбрәк булса да, хуҗалыклар азрак. Әледән-әле булып торган янгыннар ул чакта хуҗалыкларның шактый кимүенә китергән дип уйларга кирәк. Кайбер очракта зур зыян күргән хуҗалыклар саны берничә дистә тәшкил итә торган булган. 1876–1885 еллар эчендә генә, мәсәлән, Мәлбагышта – 16, Түбән Якыйда 63 йорт яна.

1885 ел ахыры – 1886 ел башында Мәлбагыш һәм Түбән Якый – Әлки волосте авыллары. Алардан тыш, бу волостька Әлки, Кәкре Елга, Кама-Исмәгыйль һәм Моревка авыллары керә. Моревка 1859 елгы статистик чыганакта күрсәтелмәде, димәк, ул яңа гына барлыкка килгән.

Волостьта иң зур авыллар булып Кама-Исмәгыйль (282 хуҗалык), Кәкре Елга (275) һәм Әлки (265) тора. Мәлбагышта 202 хуҗалык, 510 ир-ат һәм 522 хатын-кыз исәпләнә. Түбән Якыйда 148 хуҗалыкта 405 ир-ат һәм 408 хатын-кыз яши. Моревка исә нибары 7 хуҗалыктан тора.

Авыллар арасында Кәкре Елга имана җир мәйданының зурлыгы (7608 дисәтинә) белән аерылып тора. Башка татар авылларының исә ул 2–4 тапкырга кимрәк. Әлкинең – 3848,4, Кама-Исмәгыйльнең – 3467,3, Мәлбагышның – 2076,9 һәм Түбән Якыйның 1806,5 дисәтинә имана җирләре була. Моннан тыш, Түбән Якыйда бер хуҗалыкның 116,7 дисәтинә сатып алган җире дә була.

Биләмәләрнең мәйданы никадәр зур булса, аны бүлгәндә җан башына шулкадәр күбрәк тигән, әлбәттә. 10 нчы ревизиядә (1859 ел) теркәлгән ир-ат санына карап Кәкре Елгада бер иманага – 14,2, Әлкидә – 8,8, Кама-Исмәгыйльдә – 7,1, Түбән Якыйда – 7,1, Мәлбагышта 6,5 дисәтинә җир бүленә. 1885 ел ахыры – 1886 ел башында 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка Кәкре Елгада – 23,4, Әлкидә – 10,6, Түбән Якыйда – 10,4, Кама-Исмәгыйльдә – 10,3, Мәлбагышта 8,2 дисәтинә җир туры килә.

Мәлбагышта имана җирләрнең 374,3 дисәтинәсен печәнлекләр, 254,9 дисәтинәсен йорт яны җирләре һәм көтүлекләр, 49 дисәтинәсен урман алып тора. Түбән Якыйның урманы зуррак (253 дисәтинә) була. Авыл кешеләре аның бер өлешен (20 дисәтинә) кисеп чистарталар һәм шунда ел саен кыяр утырталар. Аның шактый өлешен якын-тирә зур базарларда (Әлмәт һәм Кармалы) сатканнар. Яңа Нәдер һәм Минзәләбаш волостьларында да кыяр үстереп сатучы авыллар була.

---

[315] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарской губернии. С.-Пб., 1864. С 23.

Яшелчә үстерү татар авылларында ул чорда яңа гына күренә башлый. Суганны, мәсәлән, бик сирәк авылларда утыртканнар. Аны гадәттә базарларда икмәккә алыштырып ала торган булганнар. Шуңа күрә Түбән Якыйда зур мәйданда кыяр үстерү традициясе аерым игътибарга лаек.

Кыяр үстерү географик атамада чагылыш таба. Авылның бер басуы Кыяр тавы дип аталуы да шуннан. Берничә хуҗалык тау битләрендәге җирләрне эшкәртеп кыяр чәчкән, һәм аны барып саклый торган булган, дип искә алалар авыл картлары.

Хуҗалыклар арасында сөрүлек җирне һәм печәнлекләрне арендага алу тамыр җәя. Мәлбагышта – 106, Түбән Якыйда 100 хуҗалыкның җирне арендага алуы мәгълүм. Башка авылларның да иманаларын арендага алучылар була. Алар Мәлбагышта – 71, Түбән Якыйда 24 хуҗалык. Бер дисәтинә җирне бер елга арендага алу 1,5 тән 2,8 сумга чаклы торган.

Печәнлекләр җитешмәү сәбәпле, Мәлбагыш һәм Түбән Якый авыл җәмгыятьләре казна урман лесничествосыннан зур гына җир участокларын (барлыгы 236,5 дисәтинә) арендага ала торган булганнар. Әлеге печәнлекләр хуҗалыклардагы ир-атлар санына карап бүленгән.

Мәлбагышта – 156, Түбән Якыйда 98 хуҗалык эш кораллары белән тулысынча тәэмин ителгән. Шул ук вакытта авылларның беренчесендә – 13, икенчесендә 15 хуҗалыкның алар өлешчә генә була. Мондый һәм бернинди эш кораллары булмаган хуҗалыклар – 36.

Мәлбагышта – 30, Түбән Якыйда 28 хуҗалыкның эш атлары бөтенләй булмый. Күп кенә хуҗалыкларда (ике авылга барлыгы 141 хуҗалык) алар бердән артмый. Икешәр-өчәр ат тотучылар Мәлбагышта – 69, Түбән Якыйда 31 хуҗалык. Дүртәр һәм аннан күбрәк атлылар аз. Андыйлар Мәлбагышта – 25, Түбән Якыйда 13 хуҗалык тәшкил итә.

Эш атларын гына түгел, башка мал-туарны да авыл халкы күп асраган. Мәлбагыштагы хуҗалыкларда мөгезле эре терлек – 316, сарыклар – 715 һәм кәҗәләр 238 баш исәпләнә. Түбән Якыйда 140 мөгезле эре терлек, 411 сарык һәм 197 кәҗә була. Әмма Мәлбагышта – 30, Түбән Якыйда 27 хуҗалыкның ни эш аты, ни сыеры булмый. Болар, мөгаен, ярлы көн күргәннәрдер.

Игенчелек һәм терлекчелек – авыл халкының төп яшәү чыганагы. Шулай да кайберәүләргә гаиләләрен туйдыру һәм салым түләү өчен үз хуҗалыкларының кереме генә җитми. Шунлыктан алар үз авылларында һәм читтә төрле эшләргә ялланганнар яисә һөнәрчелек белән шөгыльләнгәннәр. Игенчелек белән бәйле эшләргә ялланучылар Мәлбагышта – 36, Түбән Якыйда 28 кеше була. Түбән Якыйда бу кешеләрнең яртысы диярлек (11) башка авылларга барып ялланганнар. Мәлбагышта 17 хуҗалык – 70, Түбән Якыйда 16 хуҗалык 56 баш умарта тоткан.

Әлки волостенда сәүдә итүче хуҗалыклар шактый күп булуы күзгә ташлана. Волостьта барлыгы 22 лавка, шуның дүртесе – Мәлбагышныкы, икесе

Түбән Якыйныкы. Кибет хуҗалары күпчелек товарны Бөгелмәдән алып кайтканнар[316].

1889 елда Мәлбагышта 210 хуҗалыкта 1200 кеше яши. Авылда элеккечә бер мәчет, аның каршында мәктәп эшли. Авылның уңайлы җирләре – 2081, эшкәртергә уңайсызлары 311 дисәтинә тәшкил итә. Мәлбагыш елгасында 3 су тегермәне эшли.

Түбән Якыйга тукталыйк. Анда 150 хуҗалык һәм 870 кеше исәпләнә. Шулай ук бер мәчет һәм мәктәп була. Ә менә тегермәннәр азрак (2). Авыл янында хокук фәннәре кандидаты Л.Н. Ященконың имениесе була. Түбән Якыйның уңайлы җирләре – 1495, эшкәртергә җайсызлары 182 дисәтинә мәйданны алып тора[317].

Бу чорда Мәлбагышта имам-хатыйп һәм мөдәррис булып Әхмәтша Ильясов (1830 елда туган) эшли. Ул әлеге вазифага 1868 елның 10 августында расланган. Мөәзин һәм мөгаллим вазифасын Гали Габделгафуров (1842) башкара.

Түбән Якыйда имам-хатыйп һәм мөгаллим булып 1874 елдан Мәхмүт Әхмәдиев хезмәт итә. Мөәзин һәм мөгаллим итеп 1894 елда Әдһәм Мәһдиев расланган.

XVIII гасырда ук төзелгән мәчетләр инде тузган, аларны сүтеп, яңаларын салырга кирәк була. Моңа рөхсәтне Самара губерна хакимиятеннән Мәлбагыш халкы – 1875, Түбән Якыйныкы 1880 елда ала[318].

С. Исхаковның истәлек дәфтәрендәге мәгълүматларга караганда, Мәлбагыштагы һәм Түбән Якыйдагы мәктәпләр дүрт сыйныфлы була. Анда башлангыч белем алганнар. Бай һәм хәллерәк кеше балалары укуларын Бәйрәкә мәдрәсәсендә дәвам иткәннәр.

Гасыр ахырына (1897 ел) Әлки волостендагы авылларда хуҗалыклар һәм халык саны шактый арта. Мәлбагышта 237 хуҗалык, 645 ир-ат һәм 695 хатын-кыз исәпләнә. Түбән Якыйда исә бу вакытта 172 хуҗалыкта 463 ир-ат һәм 448 хатын-кыз яши. Анда тагын бер су тегермәне күрсәтелә[319].

1900 елгы мәгълүматлар игътибарга лаек. Мәлбагыш – М.Д. Безменев, А.Т. Чернов һәм А.А. Соловьева хуторлары, Моревка һәм Түбән Якый авыллары белән чикләшә. Мещан М.Д. Безменев хуторы – Әлки волостенда иң зур хуторларның берсе. Аның мәйданы 350 дисәтинә тәшкил итә. М.Д. Безменев аны югарыда телгә алынган хокук фәннәре кандидаты Леонид Несторович Ященкодан сатып ала. Хуторда хуҗаның йорты һәм су тегермәне була.

---

[316] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 34–41.

[317] Список населенных мест Самарской губернии по сведениям 1889 г. Самара, 1890. С. 61.

[318] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер., 104 б. а.–106 б.

[319] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 116–117.

Дворянка А.А. Соловьева хуторы зурлыгы буенча М.Д. Безменовныкыннан азга гына калыша (250 дисәтинә). Әлеге биләмәләрне аңа энисе байбикә Герасимова бүләк итеп бирә. Хуторда йорт һәм су тегермәне була.

Мещан А.Т. Чернов хуторы Әлки волостенда бәләкәйләрдән санала (69 дисәтинә). Хуҗа аны дворянка К.П. Черновадан сатып ала.

Түбән Якый авылына терәлеп диярлек Ибәтулла Бикмуллин һәм Мөхәммәтзарип Төхфәтуллин хуторлары (беренчесенеке – 180, икенчесенеке – 50 дисәтинә) урнашкан. Әлеге биләмәләрне алар 1891 һәм 1892 елларны Л.Н. Ященкодан сатып алалар. Сәүдәгәр И. Бикмуллин хуторы аша Туры Елга исемле бәләкәй чишмә ага. Ул анда 8 кешедән торган гаиләсе белән яши. М. Төхфәтуллин хуторы Танайка елгасы буенда урнашкан. Гаиләсе 2 кешедән тора[320].

Картлар сөйләвенчә, Мөхәммәтзарип бай – төп Түбән Якый кешесе. Аның улы Котлыкай хаҗи авылның зур сәүдәгәрләреннән берсе була. Ә менә Ибәтулла бай монда Казан ягыннан килеп төпләнгән.

1900 елгы документта Мәлбагышка һәм Түбән Якыйга кагылышлы шундый юллар бар: «*2 года тому назад 6 домов выехали в Турцию, по приглашению турецкого правительства, переданное чрезь окрестных мулл. Известий от переселенцев нет*»[321].

Төбәктәге татар авылларыннан Төркиягә яисә башка илләргә күчеп китүчеләр турында нинди дә булса мәгълүматларның моңарчы очраганы юк иде. Бу очракта авылны калдырып китүгә нинди конкрет сәбәп булган, моны ачыкларлык документлар юк. Әмма ул чорда Россиядәге урыс булмаган милләтләрне җәберсетүне күз алдына китерсәк, күп нәрсә аңлашылыр. Мөселманнарга, Төркиягә китегез, дип киңәш биргән карагруһ министрларны юкка гына бөек Тукай тәнкыйть утына алмаган.

Әлеге кешеләрнең язмышы ничек булган соң? Бу хакта С. Исхаковның истәлекләреннән беләбез. Автор түбәндәгечә яза: «*Безнең Мәлбагыш авылыннан дүрт кеше һәм Түбән Якыйдан ике кеше урыслар чукындырудан качып семьялары белән Төркстанга киткәннәр. Берничә елдан соң боларның өчесе кире авылга кайткан...*».

Документта да, С. Исхаков истәлекләрендә дә алты гаилә хакында сүз бара. Автор татарларның авылларын калдырып китүен патша хөкүмәтенең көчләп чукындыру сәясәте белән бәйли. Аларның санын гына түгел, Төркстанга күчеп китүләренең сәбәбен дә дөрес күрсәтә түгелме ул?

1907 ел – Мәлбагыш халкы өчен аеруча истәлекле дата. Икенче җәмигъ мәчет салырга рөхсәт алына. Бер елдан Юныс Мусин – имам-хатыйп һәм мөгаллим, Әхмәтхәбиб Әхмәтшин мөәзин итеп раслана.

---

[320] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 81 сакл. бер.; Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 118.

[321] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 82 сакл. бер.

Мәлбагышның беренче мәхәлләсендә бу вакытта түбәндәге дин әһелләре хезмәт итә: Әхмәтзакир Әхмәтша улы Ильясов (имам-хатыйп һәм мөгаллим; 1902 елдан), Мофаздал Әхмәтша улы Ильясов (имам һәм мөгаллим; 1905 елдан), Миңлегариф Галиев (мөәзин һәм мөгаллим; 1903 елдан).

Түбән Якыйда бердәнбер үзгәреш шул, 1901 елның 12 июнендә Әхмәтшакир Мәхмүтов имам һәм мөгаллим вазифасына раслана. Аның атасы, алдарак билгеләп үткәнчә, хатыйп булып хезмәт итә иде[322].

Яңа мәчет эшләп китүе бер вакыйга булса, икенчесе – базар ачырга рөхсәт алу. Мәлбагыш базары атнага бер тапкыр, сишәмбе көнне уздырылган, Әлки волостенда бердәнбер була ул. 1910 елда авылда 325 хуҗалык, 815 ир-ат һәм 834 хатын-кыз исәпләнә. Урядник та монда яши. Түбән Якыйда 206 хуҗалыкта 500 ир-ат һәм 460 хатын-кыз була. Мәлбагышта – 2, Түбән Якыйда 3 су тегермәне эшли. Ике авылда да иманалар хосусыйлаштырылган[323].

Авыллар тормышында төрле бәла-казалар әледән-әле булып торган. Алар арасында еш кабатланганнары – янгын чыгу. Статистик мәгълүматларга күз салсак, 1905–1912 еллар эчендә Мәлбагышта тугыз, Түбән Якыйда җиде янгын чыгу очрагы теркәлгәнен күрербез. Авылларның беренчесендә – барлыгы 145, икенчесендә 9 хуҗалык яна. Иң көчле янгын Мәлбагышта 1906 елда була. Ул чакны ярты авыл (122 хуҗалык) йортсыз кала[324].

Чираттагы, 1914 елны булган янгын ике авылны тәмам бөлдерә. Түбән Якыйда ут чыгып, авылларны чолгап ала. Барлык йортлар, мәчет һәм мәктәпләр янып бетә. Йортларны торгызу гаилә башлыклары сугышка алынган хуҗалыкларга аеруча авырга туры килә. Күпләр озак вакытлар землянкаларда яшәргә мәҗбүр була.

Язмабыз ахырында 1916 елгы мәгълүматларга тукталыйк. Ул елны Россиядә авыл хуҗалыклары исәбен алу үткәрелә. Мәлбагышта 346 хуҗалык 709 ир-ат һәм 900 хатын-кыз теркәлә. Түбән Якый бу күрсәткечләр буенча күпкә калыша. Анда 224 хуҗалыкта 433 ир-ат һәм 568 хатын-кыз яши. Беренче бөтендөнья сугышы тәмамланмаган, шуңа күрә ике авылда да ир-атлар хатын-кызларга караганда шактый аз.

Әлки волостенда, кайбер башка волостьлардагы кебек, качаклар булмый. Ә менә берничә сугыш тоткыны монда була. Алар Әлкидә (2 кеше) һәм хуторларда (3) көн күрәләр.

Ул чорда Әлки волостена тагын волость үзәге Әлкидән (437 хуҗалык) тыш, Кама-Исмәгыйль (453), Шарлама (79) һәм Танаевка (27) авыллары, Моревка (8) һәм Безменовка (12) поселоклары, хуторлар керә. 1900 ел белән ча-

[322] БР МА, И–295 фонд, 14 тасв., 11 сакл. бер., 13 б.; 2 тасв., 3 сакл. бер., 104–106 б.

[323] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1910. С. 97.

[324] Поселенные данные о пожарности за 10 лет. 1903–1912 гг. Самара, 1914. С. 28–29.

гыштырганда, хуторларның саны һәм, өлешчә, хуҗалары үзгәргән. Архив документыннан Мөхәммәтгали Закиров, Әсәдулла Бикмуллин, Г.А. Чернов, Е.Л. Стрелков, Н.А. Соловьев һәм А.М. Зернов хуторлары барлыкка килүен беләбез.

Авыр сугыш елларында да авыл халкы күп мәйданда иген игә һәм терлек асрый. Мәлбагышта чәчүлекләр арыш (521,15 дисәтинә), солы (260,08), карабодай (102,30), борчак (79,21), борай (59,30), тары (58,23), бодай (22,18), ясмык (2) һәм җитеннән (2) тора. Иген игү өчен шактый җирне (228,54 дисәтинә) авыл халкы арендага алган. Сатып алган җирләрдә 82,9 дисәтинә чәчүлекләр була.

Түбән Якыйда чәчүлекләрнең төре һәм мәйданы азрак. Анда арыш (250,31 дисәтинә), солы (147,7), карабодай (49,18), борчак (39,11), тары (33,2), борай (31,56) һәм җитен (51 сажин). Мәлбагыштагы кебек, чәчүлекләр арендага (36,35 дисәтинә) һәм сатып алган (125,05) җирләрдә дә урнашкан. Тик монда, күренүенчә, сатып алган җир нисбәте зуррак.

Мал-туар саны, чоры өчен, ике авылда да күп. Мәлбагышта 536 ат (шул исәптән 450 эш аты), 547 мөгезле эре терлек, 1559 сарык һәм 408 кәҗә исәпләнә. Түбән Якыйда исә 305 (247) ат, 370 мөгезле эре терлек, 860 сарык һәм 151 кәҗә була. Шунысы сәер, авылда бер хуҗалык, 2 дуңгыз баласы асрый[325]. Татар авылында мондый төр хайван тотучылар моңарчы очраганы юк иде әле. Авылда урыс яшәгән очракта да, җирле халык аңа дуңгыз асрарга рөхсәт итмәгән.

1918 ел ахырында Мәлбагыш авыл советы рәисе булып Мөсәгыйт Сабитов (26 яшь) эшли. Рәис урынбасары – Муллагали Гәрәйшин (37), сәркәтип Миңлезаһит Заһитов (27) була. Түбән Якый авыл советында рәис Нуретдин Әхмәтов (35), аның урынбасары Мөбәрәкша Мәрдәншин (37) һәм сәркәтип Мөбәрәкша Мөхәммәтшин (34) күрсәтелә.

Әйтергә кирәк, ул чорда советлар кечкенә авылларда да төзелә. Моревкада рәис – Иван Ефимов (33 яшь), аның урынбасары Яков Ларионов (42), сәркәтип – Поликарп Павлов (56); Безменовкада рәис – Яков Скрипник (33), аның урынбасары – Павел Кравченок (41), сәркәтип – Степан Дульский (40); Танаевкада рәис – Дмитрий Давыдов (35), урынбасар һәм сәркәтип Петр Мартынов (36) була[326].

Егерменче еллар башында Мәлбагыштан дистәдән артык хуҗалык яңа урынга күчеп утыра. Менә шулай Актүбә поселогы барлыкка килә. Җәмәгать эшлеклесе, Россия Дәүләт Думасының хәзерге чакырылыш депутаты Фәндәс Сафиуллин шунда туып-үскән.

1920 елда Мәлбагышта – 369 хужалык, 1672 кеше, 1926 елда 320 хуҗалык, 1523 кеше исәпләнә. Түбән Якыйда 1920 елда – 362 хуҗалыкта 1711 ке-

---

[325] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 102 һәм 103 сакл. бер.

[326] Шунда ук, Р–1167 фонд, 1 тасв., 160 сакл. бер., 104 б. а., 105 б.

ше, 1926 елда 205 хуҗалыкта 920 кеше яши (шуның 8-е урыслар). Актүбәдә 1926 елда – 208 (35 хуҗалык), Безменовкада – 74 (12), Моревкада – 66 (16), Танаевкада 313 (43) кеше теркәлә. Авыллар Бөгелмә кантоны Әлки волостена керә[327].

Егерменче гасырның икенче яртысында авылларыбыз кечерәйде, кайберләре (нигездә, урыслар яшәгәннәре) юкка чыкты. 1989 елда Мәлбагышта – 594, 1997 елда 646 кеше исәпкә алына. Авылда урта мәктәп, мәчет эшли. Түбән Якыйда 1989 елда – 373, 1997 елда 361 кеше яши. Моревка, Безменовка авылларының исемнәре генә торып калды. Ят халык барыбер моннан китте...[328].

## § 11. Мәндәй

Мәндәй – Азнакай төбәгенең Сарман районы чигендә, сөзәк таулар арасында, Мәллә елгасы буендагы матур җирләрдә урнашкан зур булмаган авыл. Әлеге географик урыны аркасында ул ераклардан ук күзгә ташлана.

Авылның табигатен һәм үткәнен тасвирлаган бер язмада болай языла: ««Текә тау», «Кара тау», «Шөгән тау» һ. б. – авылны сакларга калыккан баһадирлар кебек тезелгән. Түбәләрендә «чал чәчле» кылганнар җилферди. Күп еллар буе авыл тарихына шаһит бу таулар. Үзләре дә картайганнар, тәбәнәкләнеп калганнар. Картлар сөйләве буенча, тауларда казылган мәгарәюллар буенча Мөслимгә барып җитеп була, имеш»[329].

Мәндәй авылының барлыкка килүе XVIII гасырның икенче чирегенә карый. Авылның башлангыч исеме Мәллә елгасы буендагы Дүсем (чыганакта «Дусимово по речке Мелле») дип атала, ул Казан өязенең Җөри юлындагы Туйкә Абдулов йөзлегенә керә. 1735 елда монда Арча юлының 5 авылыннан ясаклы татарлар килеп утыра. Болар Үсәй Әсәйкин, Туймәт Үтәгәнов, Б. Байгилдин, Кусадык Бикчурин, Котлы Уразаев, аның энесе Бикмәт (барысы 24 ир-ат; чыганакта авылы «Воцкой по речке Юграш»)[330], Балтай Биктимеров, Исмәгыйль, Сәет, Касыйм, Абас, Бикмәтовлар, Али Зәеткин (чыганак-

---

[327] Шунда ук, Р–1295 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 108–109 б.

[328] Узган гасырда язылган бу тарихи очеркка XVIII гасыр – XIX гасырның икенче яртысы документларыннан яңа мәгълүматлар өстәдек, авылларның барлыкка килү даталарын тагын да ачыклый төштек. Мәлбагыш – 1739 елда, Түбән Якый 1670 еллар тирәсендә нигезләнгән дигән нәтиҗә ясадык. Авылның совет чорын өйрәнү һәм язу максат итеп куелмады.

[329] Исламова (Гарипова) Ф. Һәр нәселнең үткәне бер китап язарлык // Безнең гәҗит, 7 март 2018 ел.

[330] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1154 сакл. бер., 297–299 б.

та авылы «Бузан словет Такмаклы»)[331], Бәрәш Калдекришев (?), Иштерәк Үкәев (чыганакта авылы «Горной Враш»)[332], Арыслан Карманаев, Колмәт Кулаев, аның энесе Илмәтәй, Аит Корбанаев (Көек авылыннан) була[333]. 1742 елда тагын Биктимер Аднаголов, Курасач Купавин һәм Котлы Сәфәркиннар (чыганакта авыллары «Паново по речке Адаму») күчеп килүчеләр[334].



*1735 елда Мәндәй авылына нигез салган ясаклы татарлар төркеме теркәлгән документ фрагменты*

1748 елгы халык санын алу документында авыл яңа нигезләнгән Дүсем (чыганакта «Новопоселенное Дюсюмово до устья вершины Карамалы Буклу туш тож») дип атала, анда төрле авыллардан күчеп утырган 91 ир-ат (27 хуҗалык) исәпкә алына. Юбраштан («Воцкой по речке Юбраш тож») түбәндәге хуҗалыклар күченгән: 1) Хөсәен Әсәнкин (чыганакта «Үсән», 42 яшь; уллары Уразман, Уразмәт, Фәйзулла), аның туганы Хәлил (15; Әсән Туйбахтин улы); 2) Туймәт Үтәгәнов (40); 3) Баир Байгилдин (47; уллары Юлдаш (аныкы Морат), Адаш, Сәет), аның туганы Ишкенә (21; Байгилде Туйгилдин улы); 4) Мәсәдык Бикчурин (50; улы Биккенә); 5) Котлы Уразаев (87; улы Әмирхан (аныкы Гомәр, Габдерәззак)), аның туганы Бикмәт (48; улы Бикбау); 6) Әсән Исәнов (32; уллары Касыйм, Морадым, Габделмәзит), аның нәселдәше («племянник») Миңлебай (Арча юлы Бикчура авылыннан Дүсмәт Токмәтов улы); 7) Ибнәй Үтәгәнов (47); 8) Солтангол [И]сәнгилдин (74; уллары Ишәй, Ишкенә (аныкы Зәбир?), Абдул, Исәнгол, Абдул, Солтанбәк, Әмин, Гайса); 9) Янкә

[331] Шунда ук, 293–293 б. а. Әмма Исмәгыйль, Сәет һәм Касыйм Бикмәтовлар монда калмыйлар, ә Сәет бистәсенә күчеп китәләр (Кара: Шунда ук, 1155 сакл. бер., 483 б. а.).

[332] Шунда ук, 295–295 б. а.

[333] Шунда ук, 296–296 б. а.

[334] Шунда ук, 294–294 б. а.

Корбанаев (53; уллары Нияз, Митрәй, Гали); 10) Морат Камашов (40; уллары Мәсгут, Сөбханкол, Мәмәткол); 11) Мәвлүш Ишкәев (32; улы Дәүләт); 12) Туеш Котлышов (27; уллары Сауш, Габдессәлим); 12) Үсән Үтәгәнов (30; улы Гомәр), аның туганы Әсән (26); 13) Ибрай Полатов (24; уллары Иманкол, Имәт), аның нәселдәше («племянник») Мерәс (17; Арча юлы Көек авылыннан Котлыгош улы) һәм туганы Иманай (23); 14) Узмәт Исәнкин (37); 15) Сәмкә Рысов (42; улы Сәмәкәй). Тукмаклыдан (чыганакта «То[к]маклы, что словет Бузан») күченүчеләр: 16) Балта Биктимеров (25), аның энесе Япаш (20; Биктимер Чурашкин улы). Көектән («Куюк») күченүчеләр: 17) Арыслан Корбанаев (35; улы Исхак); 18) Колмәт (48; улы Әлмәмәт) һәм Иманай (31; уллары Мәвлүк, Уразман, Шәрип, Мансур) Кулаевлар, аларның нәселдәше («племянник») [И]смәгыйль (21; Бикмәт Яңабирдин улы); 18) Әсән Корбанаев (29; улы Ягъфәр). Арча юлы «Паново» авылыннан күченүчеләр: 19) Биктимер Аднаголов (55; улы Бикмәт), аның нәселдәшләре («племянники») Котлы (22) һәм Балтай (8; Сәфәр Иләев уллары); 23) Ярмәк Колачкин (48; уллары Бохар, Дүсмәт, Бәрәш), аның нәселдәше («племянник») Тукай (20; Үсәй Айтуганов улы). «Горной Вряж» авылыннан күченүчеләр 24) Баяраш Кудербышов (23; уллары Чүлүк, Калмәмәт, Әлмәмәт, Ибрай); 25) Иштирәк Үтәев (30). Тукмаклыдан (чыганакта «Бузан словет Томаклы тож») күченүчеләр: 26) Авәс Бикмәтов (31); 27) Али Зәетов (32)[335].

Авыл рәсми төстә Дүсем дип язылса да, Мәндәй дип аталу очрагы да күзәтелә. Бу атама Чалпының 1762 елгы ревизия документын өйрәнгәндә күзгә чалынды. Анда Казан өязенең Җөри юлына караган Мәндәй авылы ясаклы татары Баимов телгә алына[336]. Башка чыганакларда, Дүсем дип аталган авыллар икәү булганга, монысын – Мәллә елгасы, икенчесен Минзәлә елгасы буендагы дип күрсәтәләр.

Гасыр ахырынарак Мәндәй чагыштырмача зур авылларның берсе була. 1782 елда монда 123 ир-ат һәм 103 хатын-кыз, 1795 елда 115 ир-ат һәм 107 хатын-кыз исәпләнә. Авыл атамасы рәсми төстә «Дюсюмово Якши Каран Мендеево тож» һәм «Дюсюмово при речке Мелне при устье Буклы Тамак Верхние Карамалы Мендеево тож» вариантларында языла. 1795 елгы авыл исемлегендә теркәлгән кайбер хуҗалыкларны атап үтик: Шәрип (55 яшь) һәм Мансур (50; ике хатынлы) Иманаевлар, Балтай Биктимеров (1721–1783), Чурагол Мәвлүшев (46) Иманай Полатов (1723–1784), Әмин (49) һәм Гайса (48) Солтанголовлар, Сәгыйть (48) һәм Назир (44) Ишкениннәр, Абдул Солтанов (1724–1786), Мансур Ишкенин (45), Уразман (56) һәм Уразмәт (1742–1789) Хөсәеновлар, Әлмәмәт Дүсемов (1730–1787; уллары Биктимер, Биккенә),

[335] Шунда ук, 1142 сакл. бер., 656 б. а.–661 б. а. Югарыда карап үткән архив мәгълүматларында бер үк кеше исемен язуда аермалыклар булуына игътибар иттек. Исемнәрнең хаталы язылуы башка очракларда да күзәтелә.

[336] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3795 сакл. бер., 352–357 б.

Ишмөхәммәт (56; ике хатынлы) һәм Ишморат (43) Сәетовлар[337]. Якындагы Яхшы Каран (чыганакта «Якшикаран по речке Мелне») авылында бу вакытта 51 ир-ат һәм 54 хатын-кыз яши (Морза Ярмәков (68), Ибрай Байрәшов (49), Хәлил Исәнов (63), Сәгыйть Баимов (49) һәм башкалар)[338].

Мәндәй авылының 1795 елгы исемлегендә Әбүбәкер (1744–1783; уллары Сәйфулла, Фәйзулла, Гобәйдулла), Гомәр (1747–1790; улы Вәлит) һәм Гали (40; улы Гаделша) Милкиннәргә игътибар итик[339]. 1811 елгы ревизия документында Милкин фамилиясенең хаталы булуы күрсәтелеп, Мәндәевка төзәтеләчәк.

Ел саен Иштерәк (хәзерге Мөслим районы Ольгино авылы) заводыннан эшчеләр килеп, авыл янында бакыр рудасы чыгара торган булганнар. Мәндәй руднигы 1796 елда иң яхшысы санала – монда 2542 пот мәгдән (руда) чыгарыла (ягъни барлык чималның яртысыннан күбрәге). Аны атлар белән көн-төн заводка ташыганнар. Ул елны барлыгы 4470 пот мәгдәнне эретеп 79,14 пот чиста бакыр алалар[340]. Менә шулай чимал чыгара-чыгара тауларда мәгарә-юллар хасил булган.



*1811 елгы исемлектә – Мәндәй карт нәселен дәвам итүчеләр (берсенең фамилиясе «Мендеев» язылган)*

Авылның исеме кайдан алынган? Әлеге төп сорауга 126 ир-ат теркәлгән 6 нчы ревизия (1811 ел) документын өйрәнү ачыклык кертте. Авыл атамасы бирегә беренче килеп утыручы Мәндәй карт белән бәйле икән. 1811 елда монда Мәндәйнең улы Гали (56 яшь) һәм оныгы Гаделша (34; уллары Ибраһим, Ризван) яши. Мәндәй карт үзе исә бу вакытта исән булмый, 1782 елга кадәр дөнья куя.

---

337 БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 48 сакл. бер., 892–903 б. а.

338 Шунда ук, 904–909 б. а.

339 Шунда ук, 900 б. а.–901.

340 Шунда ук, И–138 фонд, 1 тасв., 1925 сакл. бер., 77 б. а.

Шул ук исемлектә янәшә Мәндәй карт нәселен дәвам итүче Әбүбәкернең уллары Сәйфулла (43 яшь), Фәйзулла (1771–1804) һәм Гобәйдулла (38) күрсәтелә[341].

Шунысы истәлекле, Мәндәй карт нәселен дәвам итүчеләр бүгенге чорда шактый икән. Шуларның берсе белән бу юлларның авторы 1994 елның җәендә Азнакайда чакта очрашты. «Авылыбыз тарихын Хәбибулла бабайдан күп белүче юктыр», – дип «Яланкүл» колхозы рәисе Хәмит Мөстәкыймов таныштырган иде безне. 76 яшьлек Хәбибулла Габделвәис улы Әбүбәкеров сөйләгәннәр шактый кызыклы булып чыкты.

Хәбибулла бабай баштарак, мин үзебезнең шәҗәрәне белмим, дисә дә, сөйли торгач, үз нәселенең тарихын шактый тулы белүен күрсәтте. Мәндәй картның тулы исеме Габделмәннаф икән. Аның атасы Исәнгол була. Габделмәннафкә, сугышта катнашканы өчен, патша указы нигезендә җир бүлеп бирелергә тиеш була. Бу эш артыннан башлап Исәнгол бабай үзе йөри. Әтисеннән: «Алабуга территориясеннән чыкмаска иде, җирнең әйбәте шушында», – дигән киңәш алып, Габделмәннаф буш яткан урман-кырларны эзләп чыгып китә. Оренбург, Урсай якларына барып җитә – җир юк. Йөри торгач, Яхшы Каран белән Чубар Абдул арасында, тауларга сыенып яткан урманлы-сулы урында туктала. Нишлисең, уңдырышлы җирләр күптәннән бүленеп беткән, башкача эзләүдә мәгънә юк. Землемерлар чакырып, авыл буласы җирнең чикләрен билгеләттереп картасын ясаттыра. Башта бик күп җирләр бирелә: Ташлыяр кырыена да барып багана кагалар, Баланлы-Өшегән буеннан да шулай итәләр, Чалпының Җамали коесыннан, Чуарның тау башларыннан да чик билгелиләр. Минзәлә башы ягына да менеп, чокырлар казып, шуларга яндырылган утын күмере һәм башка билгеле бер әйберләр күмеп, өстенә багана кагалар. Җирләр менә шулай законлаштырыла, тик озакка түгел: чикләрне кереп, кисә торгач, торган саен азая, ә инде соңгы кисүдә – колхоз оештырылганда – бик аз калдырыла. Землемерлар шундый киңәш биргән: «Җирегез бик зур, атыгыз аз, сез моның налогын түләп бетерәчәк түгел. Давай, калдырыгыз хөкүмәткә. Сезгә ашарлык җир булгач җитмәгәнмени».

Хәбибулла бабайның нәсел чылбыры түбәндәгечә: атасы Габделвәис, бабасы Шәрәфетдин, аның атасы Гобәйдулла. Гобәйдулла бабайның атасы Әбүбәкер булырга тиеш, шуннан калган безнең фамилия, дип әйткәнен, чынлап та, моны язмабыз башында күрсәтеп үтелгән архив мәгълүматлары раслый. Гобәйдулланың алты ир баласы була. Шәрәфетдин исемле улын 12 яшьтән хөкүмәт мәктәбенә укырга бирә, медицина буенча һөнәр алсын дип. Ул анда 25 яшькә чаклы укый, чынлап та, һөнәрле була, халыкта «лекарь Шәрәфи» исеме белән танылa. Мәндәй картның атасы Исәнгол Минзәлә төбәгендә яшәгән, авылы да үз исеме белән аталган. Безнең кешеләребез барып-килеп

[341] Шунда ук, И–138 фонд, 2 тасв., 102 сакл. бер., 414 б.

йөриләр иде ике арада, дип искә алды әңгәмә вакытында Хәбибулла бабай. Исәнгол карт уллары артыннан китмәгән, авылында калган[342].

XIX гасырның икенче яртысында Мәндәй авылы шактый үсә. 10 нчы ревизия (1858 ел) вакытында монда 158 ир-ат һәм 173 хатын-кыз яши. Күптәннән салынган җәмигъ мәчет эшли. Озак вакыт (1830 елдан) бередә имам һәм мөгаллим булып Габделнасыйр Хәмитов тора. Аның белән бер чорда (1836 елдан) Габдрахман Әхмәров мөәзинлек итә. Кечкенә генә Кытыс авылы да бу мәхәлләгә караган. Әлеге дин әһелләрен Габдрахман Галиәкбәров (1867 елдан, имам-хатыйп) һәм Мөхсин Габделфәизовлар (1873 елдан, мөәзин һәм мөгаллим) алыштыра[343].

Мөхсин мөәзин, кайбер истәлекләргә караганда, Чубар Абдул кешесе булган. Беркадәр мулла булып та торган, 1900 елда дөнья куйган.

1884 елгы мәгълүматлар буенча, Мәндәйдә 85 хуҗалыкта 485 кеше яшәгән. Аларның 2109,7 дисәтинә иманасы була. Шуның 1303 дисәтинәсен сөрүлекләр, 437,7 дисәтинәсен куаклыклардан торган урман, 269 дисәтинәсен печәнлекләр, калган өлешен (100 дисәтинә) йорт яны җирләре алып торган. Авыл халкы иген иккән, күп мал-туар (202 ат, 140 сыер һәм бозау, 161 сарык, 94 кәҗә) асраган. 4 хуҗалык умарта тоткан[344].

1892 елның җәе корылыклы була. Яланнарда үләннәр көя, басуларда игеннәр үсә алмый интегә. Өстәвенә, сабан ашлык басуына (мәйданы 282 дисәтинә) һәм уҗымнарга (217) тагын бер афәт килә. Корткыч бөҗәкләр (кобылка) ашарга үлән булмагач, иген басуларына ябырылалар. Алар барлык уҗымнарны, сабан ашлык басуының 10 дисәтинәсен ашап бетерәләр. Июнь ахырында бу афәтне үз күзләре белән күргән Минзәлә өяз идарәсе әгъзасы А.В. Пальчиков түбәндәгеләрне яза: «*Яровые хлеба поедены по корень, а рожь уничтожалась в колосе. Кобылка высасывала развивающееся зерно, а в некоторых случаях поедала вместе с колосом...*»[345].

Зыянның иң зур өлеше Мәллә елгасының уң ягында урнашкан авылларга (Мәндәй, Яхшы Каран, Михайловка, Удобновка, Баллытамак, Карамалы, Александровка һәм башкалар) туры килә. Корткычны бетерү өчен һәр авылның яше-карты яланнарга һәм басуларга чыга. Җәтмә сыман җайланмалар белән җилгә каршы тиз-тиз атлап әлеге бөҗәкләрне тотканнар һәм махсус савытларга җыеп барганнар. Бу көрәшне оештырган земство һәр пот

[342] Әбүбәкеров Хәбибулла Габделвәис улы (1908 елда туган) истәлекләре // Автор архивы.

[343] БР МА, И–295 фонд, 3 тасв., 7534 сакл. бер., 12–14 б.

[344] Сборник статистических сведений по Уфимской губернии. Приложение к Т. 3. Мензелинский уезд. Уфа, 1899. С. 8–13.

[345] Сборник постановлений Мензелинского уездного земского собрания 18-ой очередной сессии с 20 го по 31 октября 1892 года и доклады Мензелинской уездной земской управы с приложениями. Мензелинск, 1893. С. 421.

өчен 40–60 тиен акча түләгән. Күп вакыт һәм көч ала торган хезмәт өчен бу зур акча булмаса да, мәндәйлеләр барлыгы 48 пот бөҗәк җыеп юк итәләр.

Иген уңмаган елны да, башка елларны да авылдан күп кенә хуҗалыклар гаиләләрен туйдыру һәм салым түләү өчен акча юнәтү максатында төрле эшләргә ялланганнар. Бер ишләре кыр эшләре тәмамлану белән Самара-Златоуст тимер юлына барып вакытлыча кара эшче булып урнашканнар. Тулысынча үз исәбенә тукланып-торып эшләгән шартларда айга өч сумнан биш сумга кадәр акча төшә торган булган. Икенчеләре исә, кыш җиткәч, үз атлары белән йөк ташырга ялланганнар. Алар сезонга, ат башына исәпләгәндә, биш сумга чаклы акча эшләгәннәр. Болардан тыш, якын-тирәдәге эре җир биләүчеләргә (Пальчиковларга, Кукаркиннарга һәм башкалар) ялланып эшләүчеләр булган. Аларның көнлек хезмәт хакы җәй айларында утыз-илле тиен тәшкил иткән.

Беренче бөтендөнья сугышы алды елларында (1912–1913 еллар) Мәндәй – Александровка Карамалысы волостенда уртача зурлыктагы авылларның берсе. Андагы 147 хуҗалыкта 768 кеше яши. Иманалар 1884 елгы белән чагыштырганда азрак – 1432,75 дисәтинә. Аларның зур өлешен сөрүлекләр (950,90 дисәтинә) һәм печәнлекләр (257,81), калган өлешен урман (50), йорт яны җирләре (30) һәм көтүлекләр (50) алып торган.

Имана мәйданы кимүнең сәбәбе – җирнең бер өлеше (468 дисәтинә) хосусый милеккә әйләнгән. Мондый биләмәләр Мәндәй авылы кешеләре Ә.Х. Байчурин һәм М.М. Токтамышевларда була. Беренчесенең җире – 222,29, икенчесенеке 246,71 дисәтинә тәшкил итә. Байчурин биләмәсенең зур өлеше (90 дисәтинә) урманнан торган. Икесе дә, игенчелекне өстен күргәнлектән, мал-туарны бик аз тота.

Җир күләме хуҗалыкларга карап шактый аерылган. 12 хуҗалыкта – бик аз (3 дисәтинәгә кадәр), 20 хуҗалыкта исә бөтенләй булмый. 18 хуҗалыкның иманасы 3,01 дисәтинәдән 5 дисәтинәгә, 60 хуҗалыкның – 5,01 дисәтинәдән 10 дисәтинәгә, 13 хуҗалыкның – 10,01 дисәтинәдән 15 дисәтинәгә, 21 хуҗалыкның – 15,01 дисәтинәдән 20 дисәтинәгә, 3 хуҗалыкның 20,01 дисәтинәдән 30 дисәтинәгә кадәр була.

Иманасы аз яисә бөтенләй булмаган хуҗалыклар авылдашларыннан яисә читтән арендага җир алырга мәҗбүр булганнар. 1912–1913 елларда 67 хуҗалык 344,69 дисәтинә җирне арендага алган. Нәтиҗәдә авылда нибары 5 кенә хуҗалык иген икми.

Төп бөртекле культуралар арыш (273,78 дисәтинә), солы (131,8), борай (122,49), карабодай (53,65), борчак (49,40), бодай (24,41) һәм тары (22,51) санала. Башка төр бөртеклеләр бик аз (0,12 дисәтинә) игелә. Бәрәңге (5,14 дисәтинә) һәм киндерне (0,62) дә кертеп, барлык культуралар 683,20 дисәтинә тәшкил итә.

1884 ел белән чагыштырганда, авылда мал-туар арта, әмма күпкә түгел. Хуҗалыкларда 231 ат, 169 мөгезле эре терлек, 488 сарык һәм 64 кәҗә асрала. 9 умартачының 99 баш умартасы була[346].

1893 елның февраленнән Мәндәй җәмигъ мәчетендә имам-хатыйп булып Галиулла Идиятулла улы Крымов эшли. Тумышы белән ул Мөэмин Каратай авылыннан, мәдрәсә тәмамлаган. Галиулла хәзрәтнең эшчәнлеге аерым игътибарга лаек. Бу хакта сөйләгәндә аның кызы Асия ханым Крымова-Разиева (1913 елда Мәндәйдә туган, без белгәндә Чубар Абдул авылында яши иде) истәлекләренә һәм башка чыганаклардан алынган мәгълүматларга таянабыз.

Галиулла хәзрәт зур гыйлемле, тормыш яңалыкларыннан даими хәбәрдар һәм гаять эшлекле зат була. Мулла вазифасын башкарган чорда ул газета-журналлар алдыра, яңалыкларның һәм мәгърифәтнең киң таралуына күп көч куя. Менә бер мисал. Егерменче гасыр башында земстволар инициативасы белән авылларда кредит ширкәтләре оештырыла башлый. Мондый ширкәт уңышлы эшләсен өчен тиешле шартлар (халыкның ризалыгы һәм ышанычы, җитәкченең абруе һәм белеме) булу зарур. Галиулла хәзрәт бу яңалыкның вак игенче хуҗалыгы өчен әһәмиятен аңлатып, Мәндәйдә кредит ширкәте оештырырга халыкның ризалыгын ала һәм үзе үк аның идарәсенә рәис итеп сайлана. Шулай итеп, 1912 елның 25 маеннан Мәндәй кредит ширкәте эшли башлый. 1912 елның 6–12 июньнәрендә Минзәләдә, аннары Зәйдә (18–25 июнь) вак кредит оешмалары өчен өяз земство җыелышы карары нигезендә һәм губернатор рөхсәте белән хисапчылык курслары үткәрелә. Курсларны өяз һәм губерна земстволары, дәүләт банкының Уфа бүлеге инспекторлары һәм инструкторлары алып бара. Бөтен өяз буенча 22 тыңлаучы (слушатель) була, шуларның унысы имтихан тапшырырга теләк белдерә. Имтихан тотучылар арасында Галиулла Крымов һәм Минзәләбаштан Камил Вахитов та була. Икесе дә сынауны уңышлы үтеп, таныклык ала. Әлеге факт Галиулла хәзрәтнең күпкырлы белемгә омтылышын гына түгел, тормышка карашын да чагылдыра. Вак игенче хуҗалыкларына үзләрен саклап калу һәм тагын да ныгу өчен яңа эш алымнарын һәм уңай тәҗрибәне өйрәнүне кирәк саный ул. Галиулла Крымов оештырган кредит ширкәте авылга нәрсә биргән соң, дигән сорау туарга мөмкин. Кызганычка каршы, бу хакта мәгълүматларыбыз аз һәм алары да, башлыча, 1912 елга карый, шулай булса да берничә сүз әйтеп китик.

Оешкан көннән алып 1 июльгә кадәр чорда Мәндәй кредит ширкәте йөз әгъзадан тора. Бу вакытта аның дәүләт банкыннан әҗәткә алган төп капиталы ике мең сум тәшкил итә. Яңа гына оешкан булгач, төп үз капиталы булмый әле. Кергән акча тулысынча диярлек ширкәт әгъзаларының авыл хуҗалыгы

---

[346] Крестьянское хозяйство Уфимской губернии. Подворная перепись 1912–1913 гг. Уфа, 1914. С. 11–17.

белән бәйле ихтыяҗлары өчен файдаланыла: 110 сум мал-туар сатып алырга һәм 1855 сум арендага алган җир өчен түләргә тотыла[347].

Өстәп шуны әйтик, авылга тимер сабаннар һәм тырмаларны кайтаруны оештыручы да кредит ширкәте була. Бу хакта А.Г. Крымова-Разиева истәлекләре теркәлгән кульязма сөйли.

Авылга мәгърифәт нурларын иңдерү өчен дә күп тырышлык куя Галиулла хәзрәт. Аның тырышлыгы белән Мәндәйдә электән үк эшләп килүче мәктәп өчен 1914 елда яңа бина салына. Төзелеш Шыкмайдан Әхмәтҗан хәзрәт акчасына башкарыла, аның кызы – Галиулла хәзрәтнең хатыны[348]. Галиулла хәзрәтнең тугыз баласы була: Мирсәетшәрип (өлкәне; аны Чиләбедә аклар турап үтерә), Миргазиян (1945 елда сугышта һәлак була), Габделәхәт (укытучы, 1928 елда авырып үлә), Хәерлебәрия, Габделкотдус, Габделбари (укытучы, «халык дошманы» дип гаепләнә, сугышта катнаша, аннан яраланып кайткач, Чиләбе ягына җибәрелә, шуннан соң хәбәре булмый), Суфия, Асия, Әнисә.

Мәгърифәт турында сүз чыккач, 1912–1913 уку елына кагылышлы мәгълүматларга тукталып үтми булмый. Авылда ул чорда ике мәктәп була. Биналары гадәти авыл өйләреннән аерылмаган: агачтан салынган, бишәр тәрәзәле, берәр мичле, түбәләре такта белән ябылган. Беренчесенә, ир балаларныкына, 44 шәкерт сабакка йөргән. Хатын-кызлар мәктәбендә исә 40 бала укыган. Мәктәпләрнең мөдире булып Ризаэтдин Мөхәммәтшәрипов торган, ул үзе ир балаларны укыткан. Укыту иске ысулда алып барылган[349].

Мәндәйдә булган чакта бу юлларның авторына югарыда телгә алынган Р. Мөхәммәтшәриповның алтмыш биш яшьлек оныгы Өлфәт Сәгыйть улы Ризаэтдинов белән очрашып сөйләшергә туры килде. Аның истәлекләренә караганда, Галиулла Крымов Мәндәйгә килгәнче, мулла вазифасын берникадәр вакыт Ризаэтдин карт башкара. Муллалыкны Галиулла хәзрәткә тапшыргач, ул барлык вакытын балалар укытуга багышлый, мәктәп өчен аерым бина салынганчы аларны үз өендә укыта. Шәкертләр мәктәптә дүрт еллык башлангыч белем алганнар.

Мәктәпләргә бәйле тагын бер истәлекне А.Г. Крымова-Разиева кульязмасыннан табабыз. Анда кыз балалар мәктәбендә укытучы булып эшләгән Мәргубҗамал Вахитова хатирәләре теркәлгән. Кульязма авторына ул түбәндәгеләрне сөйләп калдырган: «*Чубар Абдулда укыта башлаганда бары*

---

[347] Сборник постановлений Мензелинского уездного земского собрания 38-ой очередной сессии с 30 октября по 12 ноября 1912 года и доклады Мензелинской уездной земской управы с приложениями. Мензелинск, 1913. С. 1437, 1424 (приложение).

[348] Әбүбәкеров Хәбибулла Габделвәис улы (1908 елда туган) истәлекләре // Автор архивы.

[349] Кильдибяков Г.Н. Магометанские школы (мектебе и медресе) в Мензелинском уезде Уфимской губернии. 1912–1913 учебный год. Мензелинск, 1913. С. 4–5.

*16 гына бала булды. Аның да алтысы Мәндәйдән килеп укыды. 1913–1916 елларда Мәндәйдә укыттым. Анда инде 40–43 бала булды. Галиулла Крымов тырыш кеше иде. Ул вакытта хөкүмәт ярдәме юк иде. Үз тырышлыгы белән бала башына акча салып, җитмәгәнен үзе түләп укыттырды»*[350].

Кыз балалар мәктәбендә укучылар саны турында нәкъ шундыйрак мәгълүмат алдарак телгә алынган Мөхәммәтһади Килдебәков китабыннан да китерелгән иде. Бу исә М. Вахитова сөйләп калдырганнарның ышанычлы чыганак икәнлеген раслый. Чынлап та, күпчелек башка мөселман уку йортлары кебек, Мәндәй мәктәпләре дә хөкүмәттән бер тиен ярдәм алмый. Киресенчә, хөкүмәт бирергә теләми. Мәгърифәт ихтыяҗларына бүленгән акча тулысынча диярлек урыс мәктәпләренә тотылган.

Беренче бөтендөнья сугышы елларына караган мәгълүматлар аз. 1915 елдан Мәндәйдә икенче мулла булып Хөснимөхәммәт Хәйруллин тора. Авылның Мәллә елгасында өч ташлы тегермәне була. Ул таштан салынган, янында гына амбары, икмәк киптергече һәм он тарттыру йорты урнашкан. 1916 елда тегермән Буралы авылы кешесе Хәбибулла (икенче чыганакта Латыйфулла) Төхвәтуллинда арендада була. Габдрахман Байголов лавка тоткан, бакалея товарлары (чәй, шикәр һәм башкалар) белән сәүдә иткән. Сәүдә әйләнеше 1915 елда 200 сум тәшкил иткән[351].

Беренче бөтендөнья һәм гражданнар сугышы еллары, аннан соң 1921 елгы ачлык авылга әйтеп бетергесез михнәтләр алып килә. Ачлыктан бик күп кешеләр кырылганлыктан, авыл кечерәя. 1920 елда 155 хуҗалык булып, анда 740 кеше яшәсә, 1926 елга шул тәртиптә 122 һәм 540 (тегермәндә яшәүче 11 кешене дә исәпләп) торып кала[352]. НЭП чорында халык бераз иркен яши, ә менә аннан соң репрессияләр, колхозлашу башлана.

1930 елда авылда колхоз оеша. Аңа халык тәкъдиме белән «Ялантау» исеме бирелә. Башта колхозга теләге булганнарның барысын да алсалар, торабара 1917 елга чаклы һәм НЭП чорында бераз хәлле яшәгән кешеләрне хокуксызлар исемлегенә кертеп, колхоздан чыгара башлыйлар. Раскулачивать ителүчеләр арасында элек сәүдә белән шөгыльләнүчеләр дә була. Күпләре раскулачивание белән килешми, үзләренең сайлау хокукларын торгызуны сорап урындагы һәм югары оешмаларга гаризалар яза. Шундыйлар арасында Мәндәйдән Әбүбәкер Ризванов та була. 1935 елда ул Чубар Абдул авыл советына үзенең гаризасы белән «Кыскача тәрҗемәи хәлем» дигән язмасын да бирә. Түбәндә шуны укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

«*1862 елда Мәндәй авылында [...] туганмын. 12 яшемдә атамнан ятим калып, агаларым тәрбиясендә торып үстем. Яшем җитү белән гаскәри хезмәткә алынып, анда 5 ел хезмәт иттем, аннан кайткач, 1888 елдан баш-*

[350] А.Г. Крымова-Разиева истәлекләре // Автор архивы.
[351] ТР ДА, 573 фонд, 1 тасв., 1 сакл. бер., 27 б.; 3 фонд, 1 тасв., 9410 сакл. бер., 4 б. а.
[352] Шунда ук, Р–1296 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 18 б.

*лап 1899 елларга кадәр гаять фәкыйрьлек белән тереклек иттем, 5–6 еллар атсыз тереклек иттем, ат юнәтеп алгач, бай җөге ташып, күрше боярларның сабанын сөреп, көлтәсен ташып көн күрдем, үземнең җирем булмаганга күрә, җирле кешеләрдән уртакка җир алып, иген эше белән шөгыльләндем.*

*1903 елларда тереклегем бераз рәтләнде, гаскәри хезмәттә русча сөйләргә өйрәнеп һәм русча кул куя белгәнлектән, 1904 елда Карамалы вулысының ярдәмче старшинасы булып сайландым, 1906 елда сәяси ышанычсыз саналып шул вакыттагы хөкүмәт тарафыннан судка бирелеп, суд 5 елга кадәр полиция нәзарәте астында калдырды, шул елларны, ягъни үзем старшина вакытта, балаларым яшь булу сәбәпле, җәйлектә иген эшләре эшләү өчен сезонный рәвештә яллы көч тоттым, бер кеше.*

*1910 елдан башлап һичбер яллы көчтән файдаланмадым, үз балаларым өлгерделәр, сату итмәдем, башка төрле доход китерүче кәсебем булмады. 1917 елга кадәр шул рәвештә тереклек иттем, 1917–18 елларда гаиләмдә 13 җан булып, шулардан 8 җан эшкә яраклылар иде, 13 җанга җир бирелде, булган җиремне гаиләм белән үзем эшләдем. 1917–1918 елларда вулыс Советы әгъзасы булып эшләдем. 1918 елда 1 балам – Олы Кәрәм – добровольны кызыл гаскәр сафына китте, шул көннән башлап совет хезмәткәре, 1919 елдан партия әгъзасы. 1 улым 1923 елда добровольны кызыл гаскәргә китте, шул көннән совет хезмәткәре – укытучы, 1 кызым – 1931 елдан укытучы, 1 улым – МТС хезмәткәре, 1 улым – колхоз әгъзасы авылда.*

*Балаларым коммунист булу сәбәпле, 1919 елда аклар тарафыннан, 1920 елда сәнәкчеләр тарафыннан бик күп җәфалар күрдем, анысын авыл халкы беләләр.*

*1930 елда колхоз оешканда беренче булып колхозга кердем, чөнки балаларым шулай куштылар.*

*Минем балаларым колхоз оештыруда башлап йөргәнгә күрә, кайбер аңсыз иптәшләр алардан үч алу нияте белән колхоздан чыгарып, үземне раскулачивать иттеләр, ләкин хөкүмәт органнары моны ялгыш санап, кире восстановить иттеләр. Ә инде шул ук старшина булган дип 1931 елда хокуксызлар исемлегенә керттеләр, ничә мәртәбәләр гариза бирсәм дә гаризамны югалта килделәр»*[353].

1935 елда әле репрессия машинасы тулы көчкә эшләми, шуңа күрә күпмедер өмет була. Әбүбәкер Ризвановның тырышлыгы бушка китми, тулысынча аклана. Улы Ризванов Фазыл колхоздан чыгарылган була, 1935 елның 13 маенда Тымытык райбашкарма комитеты аны яңадан колхозга алырга дигән карар кабул итә.

Югарыда сүз бер кеше язмышы хакында барды, ә күпме язмышлар тоталитар хөкүмәт корбаны булды: исемнәре генә түгел, хәтта төгәл саны да бил-

[353] Шунда ук, Р–5744 фонд, 1 тасв., 23 сакл. бер.

гесез. Әбүбәкер Ризвановның патша чорындагы тормышы, аннан соң күргәннәре күпмедер дәрәҗәдә башка шәхесләр язмышында кабатлануы белән дә игътибарга лаек.

Шул ук 1935 елда, мәсәлән, Гәрәев Миңлегол гаризасы да карала. «Ялантау» колхозы рәисе Хәкимов, авыл советы рәисе (?) Хәбибуллин биргән характеристикада аның турында түбәндәгеләр әйтелә: 1872 елда туган. 1917 елга чаклы урта тормышлы: кара-каршы өе, ике-өч аты, дүрт-биш сыеры, егерме-егерме биш баш сарыгы, келәте, мунчасы, җиде-сигез гектарга чаклы җир арендасы, ялчысы, өч-дүрт сезонный эшчесе була. 1917 елдан 1925 елга чаклы гаиләсе тугыз җаннан тора. Таш кладовое, таш амбары, агач келәте, бер подвалы, сигез-тугыз баш умартасы була. 1935 елда Бөгелмәдән төрле товарлар алып кайтып саткан вакытта, спекулянт дигән сылтау белән Баланлы Бүләк авылында тотылып, өстеннән җинаять эше кузгатыла. Тымытык райбашкарма комитеты Миңлегол Гәрәевкә сайлау-сайлану хокукы бирмәскә дигән карар кабул итә. Аның элеккеге сәүдәгәр, җир арендаторы булуы, кулаклыкта гаепләнеп 1931 елда 2 нче категория белән авылдан куылуы гаепләрлек материал дип күрсәтелә. Соңгы «җинаятен» дә искә төшерәләр. Шулардан чыгып, авыл советының хокук бирергә дигән карары юкка чыгарыла. Шулай итеп, Миңлегол карт гаиләсенә карата язмыш тагын да рәхимсезрәк булып чыга.

Язмыш элеккеге сәүдәгәрләрне генә түгел, кайчандыр мулла хатыны яисә балалары булганнарны да кыйный. Хәдичә Мөгыйнова Мәндәйнең икенче мулласы Хөсни Хәйруллин хатыны булган, әмма аннан 1922 елда ук аерылган. Шуңа карамастан, Хәдичә кулаклыкта гаепләнә, ә 1935 елда сайлау-сайлану хокукы турындагы гаризасы уңай хәл ителми. Улы Фуат колхоздан чыгарыла, авылда өйдән-өйгә төрле эшләргә йөреп тамак туйдырырга мәҗбүр була. Ул да хокуксыз кала[354].

Дәһшәтле 1941–1945 елларда Мәндәйдән 123 тән артык кеше сугышка китә, шуларның яртысыннан азы гына (46 кеше) исән кайта. Сугыш кырында һәлак булучылар исемлегендә Галиулла хәзрәтнең улы полковник Миргазыян Крымов (1891–1945) та була. Аның турында матбугатта берничә тапкыр язып чыктылар. Каһарман командирның тормыш һәм сугышчан юлы белән кызыксынучылар түбәндәге очерклар белән таныша ала: «Каһарман командир Крымов» («Кызыл таң», 1985 ел, 25 апрель), «Бөркет» (авторы – М. Вәлиев, «Маяк», 1987 ел, 7 ноябрь).

Сугыштан соңгы чорда «Ялантау» колхозын «Тукай исемендәге» колхозга кушалар. Колхозны бетерү Мәндәйнең социаль-икътисади үсешенә гаять тискәре йогынты ясады. Капиталь төзелеш эреләндерелгән колхоз үзәге Чубар Абдулда алып барылды: анда мәдәният сарае, колхоз идарәсе, торак йортлар һәм башка объектлар төзелә, юлларга асфальт түшәлә. Нәтиҗәдә,

[354] Шунда ук.

колхоз үзәге – Чубар Абдул үсте, ныгыды, ә Мәндәй исә үсүдән бөтенләй туктап, кечерәеп калды.

Соңгы дистә елдагы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр җиле авылларга да кагылды. 1991 елда мәндәйлеләр колхозны торгызырга карар итә, чөнки бары шул юл гына авылны юкка чыгудан саклап калачак иде. Колхозга яңа исем уйлап тормаска, элеккесе күңелгә ятышлы булганлыктан, аны калдырырга карар кылалар. Ә менә рәис итеп кемне кую мәсьәләсе, заман таләбенчә, тавышка куела. Берничә кандидатура арасыннан колхоз рәисе итеп Хәмит Салих улы Мөстәкыймов сайлана.

Яшь рәис җиң сызганып колхозның материаль-техник базасын булдырурга керешә. Чөнки техниканың төп өлеше «Тукай исемендәге» колхозда калдырылган, ә амбар-складлар моңарчы бригада саналган авылда булмый. Кыска гына вакыт эчендә күп эшләр башкара рәис: икмәк саклый торган амбарлар, Мәллә елгасы аша күпер, берничә торак йорт һәм башка объектлар төзетә. Машина-трактор паркы да сизелерлек ныгый. Район хакимиятенең (администрация башлыгы Әнәс Гатуф улы Исхаков) һәрдаим игътибарын һәм ярдәмен тоеп яши колхоз[355].

## § 12. Мәсгут

Авылның ничек һәм кайчан барлыкка килүе турында сорау тугач, бер нәрсәгә игътибар иттек. Азнакай төбәгендә шактый авыл (Чубар-Абдул, Мәндәй, Уразай, Урманай, Туйкә һәм башкалар) атамалары кеше исемнәре белән бәйле (алар фәнни әдәбиятта антропотопоним дип атала). Мәсгут авылының да шул исәпкә керүе көн кебек ачык. Телебезгә дин аша гарәпләрдән кергән әлеге исем «бәхетле, игелекле» дигән мәгънәне аңлата. Авылның кайсы елда нигезләнгәнен белер өчен әлеге кеше турындагы мәгълүмат әһәмиятлерәк кебек.

Әмма архив чыганагы авылга иң беренчеләрдән булып 1736 елда Чадыдан (Мәләкәс елгасы буенда урнашкан; бүгенге көндә Тукай районының Мәләкәс авылы) Аит Яңабирдин, Шәрип Минкин һәм Токтамыш Бикчуриннар килеп утыруын күрсәтә[356].

[355] 1994 елда бу тарихи очеркны язганда авылның кайчан һәм ничек барлыкка килүен ачыклап булмаган иде. Бары 2022 елда гына күп кенә документларны яңадан өйрәнеп, яңаларын җәлеп итеп, бу мәсьәләгә ачыклык кертә, Мәндәй 1735 елда нигезләнгән дигән нәтиҗә ясый алдык.

[356] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1154 сакл. бер., 332 б. а.–334.

Сүз уңаеннан әйтик, Шәрип Минкин нәселе бүгенге чорга чаклы барып тоташа. Менә бер шәҗәрә: Яңабирде (1645 ел тирәсендә туган) – Миңлекай (Минкә; 1671) – Шәрип (1718) – Зәбир (1748–1816) – Рәхмәтулла (1798) – Таҗетдин (~1835) – Миңлегалим (1873) – Ризаэтдин (20.09.1907) – Сәлман (1930–1977) – Камиль (1954). Камил Сәлман улы Галимов – «ЕлАЗ» АҖ генераль директоры.



*1736 елда Мәсгут авылына нигез салган ясаклы татарлар төркеме теркәлгән документ фрагменты*

Югарыда күрсәтелгән дата (1736) – Мәсгут авылына нигез салынган ел. 1739 елда тагын Кәчти Инкәевтән һәм аның авылдашларыннан торган зур төркем килеп утыра[357]. Менә шул кешенең олы улы Мәсгут исеме антропотопонимга, ягъни авыл атамасына әйләнә.

1748 елда халык санын алганда, Мәсгуттә 43 ир-ат ясаклы татарлар исәпләнә. Алар Казан өязе Арча юлына караган өч авылдан күчеп утырганнар. Исемлектә беренче булып Кәчти Инкәев (85 яшь), аның уллары Мәсгут (48; аныкы Габделкәрим, Абдулла) һәм Чирмеш (30; аныкы Сәгыйть, Сәлим) теркәлгән. Берничә кешедән соң аерым Мансур Мәсгутов (25) күрсәтелә.

Югарыда күрсәтелгән һәм тагын берничә нәсел (барысы 29 ир-ат), Киндерлекүл (бу чыганакта «Кардерикул») авылыннан була. Алардан башка тагын Мәләкәс (чыганакта «деревня по речке Мелекесь в вершине Сюндюковой пустоши»; 5 ир-ат) һәм Чады («деревня Чады по речке Мелекесь»; 9 ир-ат) авылларыннан килеп утыручылар күрсәтелә[358].

1762 елгы ревизия документында Мәсгут (чыганакта «Масягутово Илбязак тож») авылы ясаклы татарлары Уфа өязенең Казан юлына караган старшина Хасбулат Мөтеков (чыганакта «блис старшины Каспулата Мутюкова»)

---

[357] Шунда ук, 307 б. а.–308.

[358] Шунда ук, 1140 сакл. бер, 62 б. а.–65. Мәләкәс елгасы белән бәйле атамалар бүгенге көндә Тукай районына карый. Ясаклы татарлар киткәч, ул авылга керәшеннәр килеп утыра.

территориясенә якын яши дип күрсәтелә[359]. Болай язу авылның Юрмый волосте җирләрендә барлыкка килүенә ишарәли (старшина шул волостька карый).

Әлеге документта Мәсгут Кәчтиев (65; улы Мансур), Аит Яңабирдин (67; ике хатынлы), Шәрип Минкин (47) һәм башкалар (барысы 50 ир-ат һәм 40 хатын-кыз) теркәлгән. Исемлек ахырында берничә авылдан яңа күчеп килгән халык язылган: Чадыдан (Рыс Сәфәров, Исламкол, Абдик, Арыслан Минкиннар), Мәләкәстән («деревни по речке Мелекес»; Аит (37), Мерәс (23) һәм Зәет (15) Үсәновлар), Киндерледән («Мелекес Киндерле тож»; Зәет Касимов, Гадел Мерәсов һәм башкалар), Түбән Мәләкәстән («Нижний Мелекес Сюнчалеево тож Арской дороги»; Кәрим Юртаев һәм башкалар), Җөри юлына караган Мәләкәстән (Зәет һәм Чирү Сөләймановлар), Кабык Күпердән (Җөри юлы; Иманкол и Зәбир Пчәнкиннар һәм башкалар)[360].



*1762 елгы исемлектә иң беренче булып Мәсгут Кәчтиев («Масягут Кустеев») теркәлгән. Аның исеме авыл атамасы булып китә*

Шул ук 1762 елгы ревизия документында Сенат указы нигезендә ясаклы татарларның административ яктан Казан өязеннән Уфа өязенә карый башлавы турында әйтелә[361]. Моңарчы җан башыннан исәпләнгән салымны Казанга түләсәләр, хәзер Уфага түләргә тиеш булалар.

1782 елда Мәсгуттә (чыганакта «Масягутово Карамалы тож») 132 ир-ат һәм 146 хатын-кыз ясаклы татар исәпләнә. 1796 елның апрелендә ясаклы татарларның бер өлеше (35 ир-ат һәм 46 хатын-кыз) типтәр сословиесенә күчерелә, алар аерым теркәлгән ревизия исемлегендә авыл Миңлегол (чыганакта «Минлигулово, состоящая по речке Кирямат Илбяк тамак Писмян елга Мясягутово тож») дип күрсәтелә. Нәтиҗәдә 1796 елның апрелендә ясаклы татарлар 78 ир-ат һәм 75 хатын-кыз кала[362]. Типтәр сословиесенә күчкән Ракаевлар арасында гыйлемле һәм зур мөлкәтле Миңлегол була, аның исеме авыл атамасы булып китә. Шул кеше үз исеме белән аталган авыл исемлеге

[359] Шунда ук, 1188 сакл. бер., 125 б.

[360] Шунда ук, 125–136 б.

[361] Шунда ук, 123 б.

[362] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 287–294 б.; 24 сакл. бер., 486–490 б.

ахырында татарча «ошбу скаскага мин Миңлегол Ракай улы кулым куйдым» дип язган.

Мансур Мәсгутов варисларының һәм бертуган ясаклы татарлар Ракаевларның казна карары нигезендә типтәр сословиесенә күчерелү хакында шул ук ревизия документыннан беләбез. Анда болай дип әйтелә: «Оные татара Сагит, Мурсалим, Салих, Абдрешит и Миннегул Рякеевы с их семейством по учиненному в Уфимской казенной палате апреля числа 1796 г. определению выключены в тептяри, в котором звании по особо поданной скаске показаны»[363]. Шулай итеп, XVIII гасыр ахырында типтәр сословиесенә күчү мөмкинчелеге булган.

Ике сословие – типтәр һәм ясаклы татар – бер-берсеннән нәрсә белән аерылган соң? Төп аерма – куллана торган җирнең күләмендә. «Типтәр»ләрнең ул ике тапкырга диярлек күбрәк. Шуңа күрә ясаклы татарларның әлеге сословиегә эләгергә омтылышын аңларга була. Әмма казна «типтәр»ләр санын арттыруны торган саен чикли, ә инде XIX гасыр уртасына әлеге күпмедер өстенлек бирүче сословиегә күчү мөмкинчелеге бөтенләй диярлек бетерелә.

1816 елда Мәсгут авылында 146 ир-ат (41 хуҗалык) исәпләнә. Халыкның төп өлешен «типтәр»ләр (74 ир-ат) һәм ясаклы татарлар (61 ир-ат) тәшкил итә. Болардан башка, йомышлы татарлар[364] (7 ир-ат) һәм отставной солдатлар (2) күрсәтелә. Әлеге йомышлы татарларның күпчелеге (4 ир-ат) Татар Томбарлысы авылында яши[365].

Мәсгут авылының 1816 елгы ревизия документында типтәр сословиесендәге татарлар аерым Миңлегол (чыганакта «Минлигулово по речке Киреметь Ильбяк Тамак Письмян Зилга Масягутово тож») авылы исемлеге белән теркәлгән. Әлеге «типтәр»ләр (74 ир-ат һәм 75 хатын-кыз; 23 хуҗалык) тулысынча диярлек алдарак телгә алган Ракаевлардан тора. Исемлек ахырында указлы мулла Ихсан Габдессәламов (19 яшь) һәм аның хатыны (16) теркәлгән[366].

Шул ук 1816 елгы ревизия вакытында 61 ир-ат һәм 43 хатын-кыз (30 хуҗалык) ясаклы татар исәпкә алына[367]. Йомышлы татарлар (7 ир-ат һәм 9 хатын-кыз) Шәмгун Нәдеркин (59), Хәбибулла Мансуров (36 яшь) һәм Исмәгыйль Исхаков (26) хуҗалыкларыннан тора. Алар Томбарлы волостена карый һәм лашман бурычын башкаралар (чыганакта «исправляющие лашманную повинность»)[368].

---

363 Шунда ук, 23 сакл. бер., 287–288 б. а.

364 Йомышлы татарлар аерым Миңлегол (чыганакта «под названием Минлигуловой на речке Тукане») авылы исемлеге белән бирелә.

365 БР МА, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 129 б. а.–130 б.

366 Шунда ук, И–138 фонд, 2 тасв., 168 сакл. бер., 728–738 б.

367 Шунда ук, 174 сакл. бер., 734–739 б.

368 Шунда ук, 177–180 б.


Ревизская сказка
1816 года марта 2 дня Оренбургской губернии Бугульминского уезда деревни Минлигуловой по речке Киреметь Ильбяк Тамак Письмян Зилга Масягутовой тож ... мужеска и женска полу

*Авылның озын исеме (“Минлигулово по речке Киреметь Ильбяк Тамак Письмян Зилга Масягутово тож”) язылган 1816 елгы документның титул бите*

XIX гасыр уртасында Мәсгут авылы җәмигъ мәчетендә ике имам һәм мөгаллим эшли. Аларның беренчесе – Гатаулла Сабитов – әлеге вазифага 1848 елның 4 маенда раслана. Бераз соңрак, 1849 елның 29 мартыннан, З. Миңлеголов эшкә керешә[369].

Шул гасырның сиксәненче елларында төбәктәге авыллар, аерым алганда, Мәсгут өчен җир мәсьәләсе төп мәсьәләгә әйләнә. Моның сәбәбе түбәндәгедән гыйбарәт. 1868 елда авыл общинасына җир биләү хакында документ (русча «владенная запись») тапшырылган була. Анда мондагы халык дәүләт крестьяннары дип язылганлыктан, ул зур ризасызлык тудыра. Димәк, аларның җире дәүләтнеке һәм аннан файдаланган өчен алар казнага оброк түләргә тиеш булып чыга. Мондый эчтәлектәге документлар бирелгән тирә-як авылларның да халкы хафага кала. Өстәвенә, җир күләме киметебрәк язылган була.

Моның белән килешмәгән авыллар Сенатка жалоба да язып карый, тик вакыт үтә тора, ә нәтиҗә күренми. Ахыр чиктә мәсьәләне суд аша хәл итү гаделлекне торгызуда бердәнбер чара булып кала. Үзләренең ихтыяҗларын судта якласын өчен, һәр авыл адвокат яллый. Кайтарылачак җирнең һәр дисәтинәсе өчен алар адвокатларга берәр сумнан түләргә килешәләр. Әйтергә кирәк, ике як өчен дә мондый килешү шактый отышлы булып чыга.

Адвокат яллау өчен кирәкле сумманы булдыру максатыннан, 1884 елда Мәсгут халкы үз авылдашы Миңлегол Салиховка 600 дисәтинә җирне 7800 сумга сата (дисәтинәсен 13 сум исәбеннән). Әмма бу сумма гына җитми. Шуңа күрә алар Минзәлә мещаны Рязановка 350 дисәтинә җирләрен 12 елга

369 Шунда ук, И–295 фонд, 3 тасв., 5662 сакл. бер., 11 б. а.

арендага бирәләр. Моның өчен ул авыл җәмгыятенә ел саен 300 сум түләп барырга тиеш була.

Ниһаять, мәсгутлеләр җиргә үзләренең тулы хокукларын кайтаруга ирешә. Җир авыл җәмгыяте милке (казнаныкы түгел) дигән документ алгач кына тынычлана халык. Һәм озакламый аны яңадан иманаларга бүлүне оештыра. Әлеге вакыйга статистик әдәбиятта тулы тасвирланганлыктан, аның белән укучыны таныштыруны кирәк таптык. Документның стилистик үзенчәлекләрен һәм эчтәлеген тулы саклау максатыннан, тәрҗемә итмичә тәкъдим итәбез.

«*Масягутовская община переделила землю в 1885 году сроком на 12 лет, распределив надельную землю на все наличное население муж. пола, которого в момент передела оказалось 377 душ. Община первоначально разрезала поля на столбники, шириною в 80 сажень, для чего ежедневно в течение недели в сабан запрягали 3–4 лошади и проводили борозды, при чем один день ходили лошади одного десятка, на другой день другаго и т. д. Отмерив земли 1 двадцатисаженную веревку, ставили на этом месте кол, через другую веревку – другой кол и т. д. через 10 веревок, т. е. через 200 сажень рыли яму: «чтобы смешения не было». Старики размеривали землю 2 недели. При переделе земли община разделилась на 94 десятка, полагая в каждый десяток 4 души («шубага»), а десятки делились на отдельные хозяйственныя единицы. Жеребьи-дощечки, на которых вырезывалась тамга каждого десятка. Потом их клали в 2 ведра – на худую и хорошую землю. Во всех трех полях на каждую душу досталось по 6,5 дес. сороковых, или 8,5 дес. казенных*»[370].

Суд карары нигезендә Мәсгут авылына 1389 дисәтинә урман да кайтарыла. Ел саен 100 дисәтинәгә чаклы кисә торгач, аның мәйданы шактый кими. Үз ихтыяҗлары өчен генә түгел, күрше авылларга күбрәк сату өчен (еш кына арзан бәягә) киселә урман. Булган байлыкны бәрәкәтле тоту турында уйлаучы булмый. Бәлки, шуңадыр да, җирләре өязнең урыс һәм мордва авылларына караганда чагыштыргысыз дәрәҗәдә күп булуга карамастан, монда ярлы хуҗалыкларның саны артканнан-арта бара.

1884 ел ахыры – 1885 ел башында Минзәләбаш волостена кергән Мәсгуттә 146 хуҗалыкта 385 ир-ат һәм 379 хатын-кыз исәпләнә. Авыл җәмгыятенең ул чорда 7178,4 дисәтинә уңайлы һәм 6,4 дисәтинә уңайлы булмаган җирләре була. Аның 1661 дисәтинәсен урман алып тора. Халык җир белән яхшы тәэмин ителгән. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка бүлгәндә ул 42,7 дисәтинә туры килә. Бу волостьта иң югары күрсәткеч (чагыштыру өчен: Кәтемдә – 15,3, Илбәктә – 24,3 дисәтинә) санала.

Әмма иманалар саны, хуҗалыкларга карап, шактый аерыла. Авылда 135 хуҗалыкның иманасы була. Шуларның 83 ендә ул – берәр, 33 ендә – икешәр,

---

[370] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 30.

8 ендә – өчәр, 11 ендә дүртәр яисә аннан артыграк. Мондагы бер имана ул чакта 8,5 дисәтинә тәшкил иткән.

Унбер гаиләнең (хуҗалыкның) җире бөтенләй булмый. Аларның берсе читтә яши. Волостьның башка авыллары белән чагыштырганда, монда җирсез хуҗалыклар саны бераз күбрәк. Чөнки Мәсгуткә алты гаилә читтән күчеп килгән, ә мондыйларга имана тиеш булмый.

Авыл халкы күп санда эш атлары (354), мөгезле эре терлек (207), сарык (719) һәм кәҗә (153) асрый. Бу күрсәткечләр, волостьның башка авыллары белән чагыштырганда, югарырак. Монда иманасы булган һәр хуҗалыкка 4,3 эре терлек туры килсә, тирә-як авылларда 2,2–3,6 дан артмый. Моның сәбәбе – Мәсгут авылы хуҗалыкларының печәнлекләр һәм көтүлекләр белән яхшы тәэмин ителүендә.

Шулай да терлек тотуда аерма шактый зур була. 15 хуҗалыкта эш атлары бөтенләй юк. Шул ук вакытта 33 хуҗалык – берәр, 58 хуҗалык икешәр-өчәр ат тота. Авылда дүрт һәм аннан күбрәк атлылар да була. 16 хуҗалык дүртәр эш аты асраса, 13 хуҗалыкның исә аннан да артып китә. Ә менә 15 хуҗалыкның эш аты гына түгел, хәтта сыеры да булмый. Өстәвенә, 7 гаилә йортсыз (соңгы 10 ел эчендә янгыннардан 34 хуҗалык зыян күрә).

Мәсгуттә 17 хуҗалыкта 175 баш умарта исәпләнә. Дүрт хуҗалык лавка тота, сәүдә итә. 15 кеше һөнәрчелек белән шөгыльләнә. 18 хуҗалыктан төрле срокка игенчелек белән бәйле эшләргә яллanучылар була[371].

Авыл зурайган саен дини ихтыяҗларны үтәү өчен бер мәчет кенә җитми башлый. Шуңа күрә 1888 елның 10 июлендә җирле халык җыенында елганың каршы ягында исәп буенча икенче җәмигъ мәчет төзү турында карар кабул ителә.

Әлеге карар (приговор) Уфага мөселманнарның Диния нәзарәтенә җибәрелә. Губерна идарәсенең 1889 ел, 10 ноябрь карары (постановлениесе) Мәсгут авылында икенче мәчет булдырырга рөхсәт итә. Менә шулай элек бер мәхәлләдән торган авылда икенче мәхәллә барлыкка килә. Беренче мәхәлләдә исә 79 хуҗалык кала. Түбәндә аларның исемнәрен китерәбез:

1. Ризван Габделгаффаров (гаиләдә 5 ир-ат)
2. Фәйзулла Хәбибуллин (4)
3. Зиннәтулла Гатауллин (2)
4. Камалетдин Мөхәммәтҗанов (1)
5. Йосыфҗан Әхмәтҗанов (4)
6. Шәрәфетдин Гыймадетдинов (1)
7. Мөхәммәтгани Мөхәммәдиев (1)
8. Мөхәммәтшакир Мөхәммәдиев (1)
9. Мөхәммәтсафа Мөхәммәдиев (1)
10. Гыймадетдин Әлмәкәев (5)

[371] Шунда ук, 162–166 б.

11. Нәҗметдин Габделвәлиев (3)
12. Габделкасыйм Габделганиев (2)
13. Габделбәдигъ Габделганиев (2)
14. Габдессаттар Габделкәримов (3)
15. Сәхабетдин Садретдинов (2)
16. Йосыф Шаһимәрданов (2)
17. Мөхәммәтәмин Ишмөхәммәтов (4)
18. Гыймадетдин Низаметдинов (4)
19. Габдерәкыйп Исмәгыйлов (1)
20. Вәлиулла Нигъмәтуллин (1)
21. Насретдин Шәмсетдинов (2)
22. Габделханнан Габделхаликов (4)
23. Габделнәфыйкъ Габделхәкимов (1)
24. Габделкаһир Габделгаффаров (1)
25. Гайфетдин Гайнуллин (2)
26. Габделхәким Хәсәнов (5)
27. Хәлимрахман Хәбибрахманов (3)
28. Арслангәрәй Ибраһимов (2)
29. Гыйлаҗетдин Хисаметдинов (3)
30. Нәҗметдин Хисаметдинов (3)
31. Габделхәбир Габделгаффаров (1)
32. Миңлехан Гобәйдуллин (3)
33. Сираҗетдин Габдрахманов (2)
34. Шәмсолтан Шаһимәрданов (3)
35. Хәйрулла Фазуллин (1)
36. Шаһигалләм Шаһимәрданов (3)
37. Габделхәбир Габделганиев (2)
38. Шаһихөррәм Шаһимәрданов (2)
39. Мөхәммәткәрим Ибраһимов (1)
40. Габдулла Дәүләтшин (2)
41. Әхмәтвәли Габделкаһиров (5)
42. Шаһимәрдан Сәгъдетдинов (4)
43. Юныс Шаһимәрданов (3)
44. Шәрифулла Мөхәммәтҗанов (3)
45. Сабит Мөхәммәтҗанов (1)
46. Фәхретдин Низаметдинов (3)
47. Дәүләтша Фәйрушин (2)
48. Шаһиәхмәт Шаһимәрданов (4)
49. Мөхәммәтшакир Кәримов (2)
50. Әхмәтгәрәй Габдерәфиков (2)
51. Исрафил Мөхәммәтгәрәев (1)
52. Җәләлетдин Мөхетдинов (1)

53. Мөхәммәтсадыйк Хәсәнов (5)
54. Ногман Мөхәммәтҗанов (1)
55. Мөхәммәтшакир Мифтахетдинов (2)
56. Мөхетдин Габдуллин (5)
57. Мөхәммәтсадыйк Фәтхуллин (5)
58. Идрис Габделмәнов (4)
59. Исрафил Идрисов (3)
60. Даут Габделихсанов (4)
61. Исхак Габделихсанов (4)
62. Хөсәен Исхаков (5)
63. Минһаҗетдин Хәсәнов (2)
64. Җиһангир Хәсәнов (2)
65. Мәрданша Фәрухшин (4)
66. Хәмзә Дәүләтшин (1)
67. Фәрхетдин Габделҗаббаров (5)
68. Шәрифулла Габделҗаббаров (1)
69. Мөхәммәтхәсән Җиһаншин (2)
70. Исмәгыйль Мөхәммәтшин (3)
71. Сөләйман Мөхәммәтшин (2)
72. Мәхмүт Хәсәншин (2)
73. Әхмәтгәрәй Габделкаһиров (4)
74. Нуретдин Акмалетдинов (5)
75. Җиһанша Миңлеголов (4)
76. Габдессаттар Габделҗаббаров (2)
77. Мостафа Мөхәммәтсадыйков (2)
78. Габделшәфикъ Габделганиев (3)
79. Зәйнулла Мөрсәлимов (6).

Исемлек башында Ризван Габделгаффаровның күрсәтелүе очраклымы сон? Безнең күзәтүебезчә, әлеге кеше – язмабыз башында телгә алынган Мансур Мәсгутовның оныгының оныгы, ягъни бишенче буын вәкиле. Шәҗәрәне дәвам иткәндә, бүгенге авыл кешеләре арасында Ризван Габделгаффаровның да оныкларын (җиденче буын) табып булыр иде.

Икенче мәхәлләгә тукталыйк. Анда түбәндәге хуҗалыклар күрсәтелә:

1. Мөхәммәткәрим Мөхәммәтҗанов (2)
2. Хөснетдин Фәрхетдинов (2)
3. Мөхәммәтҗан Сабитов (1)
4. Гыйзетдин Нигъмәтуллин (3)
5. Баһаутдин Шәрәфетдинов (2)
6. Котлыәхмәт Таҗетдинов (4)
7. Миңлегалим Гайнуллин (6)
8. Фәтхулла Гыйбадуллин (2)

9. Җәләлетдин Габдерәхимов (2)
10. Миңлегали Миңлебаев (3)
11. Әхмәтша Мөхәммәтҗанов (2)
12. Хөснетдин Габдерәхимов (1)
13. Габдулла Мөрсәлимов (2)
14. Шаһиәхмәт Сабитов (3)
15. Сәлимҗан Сәхипов (1)
16. Сәхип Корбангалиев (3)
17. Әбүбәкер Сәйфуллин (3)
18. Салих Корбангалиев (3)
19. Госман Сәйфуллин (4)
20. Шәмсетдин Бәширов (4)
21. Фәрхетдин Нәзиров (4)
22. Низаметдин Гайнуллин (6)
23. Гайнулла Монасыйпов (3)
24. Мөхәммәтша Сәгъдетдинов (4)
25. Сабит Корбангалиев (4)
26. Хәмидулла Нигъмәтуллин (4)
27. Мөхәммәтҗан Ишмөхәммәтов (5)
28. Исмәгыйль Әлмөхәммәтов (4)
29. Ибраһим Әлмөхәммәтов (4)
30. Камалетдин Рәхмәтуллин (3)
31. Нигъмәтулла Гыйсмәтуллин (3)
32. Гыйбадулла Баязитов (3)
33. Шаһидулла Гыйбадуллин (3)
34. Миңлебай Тимербаев (1)
35. Садретдин Сабитов (2)
36. Вилдан Гыйбадуллин
37. Исламвәли Сәйфуллин
38. Гайфулла Гыйбадуллин
39. Хәйрулла Тимербаев (4)
40. Гайфулла Тимербаев (5)
41. Дәүләтша Мәрданшин (1)
42. Шәрәфетдин Низаметдинов (5)
43. Сафиулла Сабитов (2)
44. Шәрәфетдин Мөхәммәтҗанов (5)
45. Галиулла Гайфуллин (4)
46. Мөхәммәтгали Мөхәммәдьяров (2)
47. Гайнулла Гайнуллин (1)
48. Якуп Мөхәммәтшин (1)
49. Низаметдин Нәҗметдинов (1)
50. Хәсән Габделвахитов (3)

51. Йосыф Хисаметдинов (1)
52. Сәгъдетдин Садретдинов (3)
53. Нәбиулла Миңлебаев (1)
54. Гыйлаҗетдин Гыймадетдинов (2)
55. Габделшәкүр Гатауллин (1)
56. Җиһанша Сабитов (1)
57. Мөстәкыйм Мөхәммәтсадыйков (1)
58. Габделзаһир Рәхмәтуллин (2)
59. Сафиулла Сабитов (2)
60. Хөснулла Сабитов (2)
61. Габделихсан Идрисов (2)
62. Габдерәхим Габделгаффаров (5)
63. Мөхәммәтгали Әхмәдиев (1)
64. Әхмәтхан Әхмәтҗанов (2)
65. Хисаметдин Рәхмәтуллин (4)
66. Каһарман Мөхәммәтсадыйков (1)
67. Вәлиулла Сафиуллин (3)
68. Морзахан Зәйнуллин (3)
69. Әсәдулла Хәсәншин (1)
70. Раян Габделгаффаров (2)
71. Кәлимулла Төхфәтуллин (1)
72. Мөхәммәтгәрәй Хәсәнов (1)[372].

Югарыда китерелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, Мәсгут авылында 151 хуҗалыкта 417 ир-ат исәпләнә. Ул чакта авыл Минзәләбаш волостена керә. Анда 2 су тегермәне була. Якында гына сәүдәгәр Мөрсәлимовның имениесе урнашкан. Һәр атна җомга көнне авылда базарлар уздырылган. Мәсгут базарына Минзәләбаш волостена кергән авыллардан (Минзәләбаш, Кәтем, Илбәк, Урсалыбаш, Чубар Абдул, Сөләй, Буралы, Шарлама) һәм еракларда да килә торган булганнар[373].

Дин әһелләренә тукталып үтик. 1 нче җәмигъ мәчеттә имам-хатыйп һәм мөгаллим вазифасын 1873 елдан Фәрдетдин Миңлехәеров башкара. Шул ук елдан мөәзинлеккә Хөсәен Исхаков та раслана. Яңа салынган 2 нче җәмигъ мәчеткә 1890 елда имам-хатыйп һәм мөгаллим итеп 32 яшьлек Шаһимәрдан Миңлехәеровны куялар. Бер елдан биредә мөәзинлек эшенә Мөхәммәтша Сәгъдетдинов керешә. Соңгысы, беренче мәхәллә мулласы Ф. Миңлехәеров кебек, 1844 елда туган[374].

---

372 БР МА, И–295 фонд, 3 тасв., 12230 сакл. бер.

373 Список населенных мест Самарской губернии по сведениям 1889 г. Самара, 1890. С. 74–75.

374 БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер., 135, 136 б.

1894 елның 14 июнендә авылда зур янгын чыга. Күп каралтылар, шул исәптән 1854 елда салынган беренче җәмигъ мәчет тә көлгә әйләнә. Мәхәллә исеменнән Хәсән Җиһаншин һәм Гайфетдин Гайнуллин Уфага мөселманнарның Диния нәзарәтенә яңа мәчет төзергә рөхсәт сорап прошение язалар. Озакламый Самара губерна идарәсе бу мәсьәләне карый һәм үзенең 5 сентябрь карары белән авыл халкына мәчет салырга рөхсәт бирә[375].

Гасыр ахырына Мәсгут шактый зурая. 1897 елда монда 198 хуҗалыкта 525 ир-ат һәм 513 хатын-кыз яши. Бу вакытта Минзәләбаш волосте бетерелгән (Чубар Абдул, Буралы һәм Минзәләбаш авыллары яңадан Уфа губернасы Минзәлә өязенә кайтарыла), авыл волость үзәге булып тора. Яңа оешкан Мәсгут волостена, Мәсгуттән тыш, Кәтем, Кәкре Елга, Сөләй һәм Урсалыбаш авыллары керә. Алар арасында иң зурлары – Кәкре Елга (346 хуҗалык) һәм Сөләй (282).

Авылда элеккечә 2 мәчет була. Алар каршында өч мәктәп эшли. Мәсгуттә исәп буенча өченче су тегермәне корылган. Авылның барлык җирләре 6645 дисәтинә тәшкил итә. Якындагы хутор хуҗасының – Мөрсәлимовның – җирләре 600 дисәтинә. Хутор аша агучы Мәллә елгасында ул су тегермәне тота.

Су тегермәннәре Кәкре Елга (өч), Кәтем (ике), Сөләй (ике) һәм Илбәк (ике) авылларында да була. Мәсгут авылы җирләре аша агучы Мәллә елгасында Мусин һәм Журавлевлар үз тегермәннәрен булдыралар. Әлеге елгада тагын ике кеше тегермән тота. Аларның берсе – Бабин (Кәкре Елга җирләрендә), икенчесе – Мәрданшин (Кәтем).

Волостьта Мөрсәлимовныкы кебек зур җир биләмәсеннән торган икенче хуторның (570 дисәтинә) хуҗасы – дворян Головинский. Әлеге алпавытның Тымытык волостенда да хуторы (534 дисәтинә) була. Исәп буенча өченче хутор Мөхәммәтсадыйковныкы, тик аның милке түгел. Урсалы елгасы буендагы җирләрне (60 дисәтинә) ул Сөләй авылы кешеләреннән арендага алган була.

Волость үзәге Мәсгуттә элеккечә һәр җомга базарлар үткәрелә. Бу көнне авыл тирә-яктан һәм еракта килеп сәүдә итүчеләрдән гөрләп торган. Эш кәгазьләре белән дә монда урнашкан волость идарәсенә килгәннәр. Земство стансасы да биредә була[376].

1910 елда Мәсгут – 234 хуҗалыклы, 1074 кешедән торган авыл. Андагы 2 мәчеттә шул ук дин әһелләре эшли. Үзгәреш шунда – 1908 елның 29 гыйнвареннан 31 яшьлек Фәхрелислам Хөсәен угълы Нәдеров мөәзин һәм мөгаллим эшенә керешә.

1916 елгы Россия авыл хуҗалыклары исәбен алу мәгълүматлары аерым игътибарга лаек. Ул елны Мәсгуттә 261 хуҗалык, 546 ир-ат һәм 656 хатын-кыз теркәлә. Сугыш тәмамланмаган, шуңа күрә ир-атлар хатын-кызларга караганда күпкә аз.

---

[375] Шунда ук, 3 тасв., 13791 сакл. бер.

[376] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 139–140.

Хуҗалыклар һәм халык саны буенча Мәсгут волостьта өченче урында тора. Бу вакытта Кәкре Елгада – 415, Сөләйдә – 322, Урсалыбашта – 197, Илбәктә – 190, Кәтемдә – 190, Тарханда (авыл беренче бөтендөнья сугышы алдыннан барлыкка килә) 24 хуҗалык исәпләнә. Моннан тыш, Мәсгут волостенда тагын ике хутор була. Аларның хуҗалары – Гариф Мусин һәм Г.С. Мөссәлимов.

Авыл халкы күп терлек асрый һәм зур мәйданда иген игә. Монда 576 ат (шул исәптән 572 эш аты), 512 мөгезле эре терлек (469 сыер), 2630 сарык һәм кәҗә исәпләнә. Чәчүлекләр 2093,35 дисәтинә тәшкил итә. Шуларның яртысын диярлек арыш (1081,10 дисәтинә), калган өлешен солы (423,35), борчак (168,10), борай (159), карабодай (145,30), тары (70,10), бодай (46,30) һәм ясмык (0,10) алып тора[377].

1916 елда 2 нче мәхәллә мөәзине Мөхәммәтша Сәгъдетдинов дөнья куя. 1912 елдан монда ук мулла Фәрдетдин Миңлехәеров улы Габделбарый имам һәм мөгаллим вазифасын башкара. Әлеге һәм беренче мәхәлләдә дин әһелләре составында башка үзгәрешләр күзәтелми[378].

Совет чорында үткәрелгән беренче халык санын алу вакытында (1920 ел) Мәсгуттә 290 хуҗалыкта 1283 кеше теркәлә. Тагын алты елдан нибары 187 хуҗалык һәм 883 кеше күрсәтелә. Бу чорда булган ачлыктан әнә шулай күп гаиләләр югалту кичерә. Авыл Бөгелмә кантоны Әлки волостена керә[379].

Язмабызда телгә алынган Гариф Мусинга репрессияләр башлангач «кулак» мөһере сугыла. Ул гаиләсе белән авылдан чыгып китә, Бөгелмәдәге йортында яши, әмма аны моннан эзләп табалар. 1930 елда шулай ук Әхәт һәм Нургали Мусиннар да икенче категория белән раскулачивать ителә. Шәйхулла Әхмәдиев тә шундый аяусыз язмышка дучар була. Аларның малмөлкәте тартып алына, үзләрен товар вагоннарына төяп сак астында чит-ят җирләргә сөрәләр[380].

1929 елның октябрендә Мәсгут авылында «Кызылуракчы» исемендәге коммуна оештырыла. Аны оештыруда Шамил Әхмәдиев, Сабир Уразманов, Баһау Бадыкшиннар башлап йөриләр. Коммунаның 71 гектар җире һәм 7 аты була. Ләкин ныгырга өлгермәгән бу күмәк хуҗалык 1930 елда таркала. 1931 елда колхозлашу киң колач алгач, күмәк хуҗалык яңадан оештырыла, беренче председателе итеп Мөнир Закиров сайлана.

1937 елда авылда җидееллык мәктәп, медицина пункты, китапханә, мәдәният йортлары эшли. Җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчасы булдырыла, стадион төзү башлана.

[377] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 497–499 сакл. бер.
[378] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер., 136 б.
[379] ТР ДА, Р–1295 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 108 б.
[380] Шунда ук, Р–1221 фонд, 3 тасв., 25 сакл. бер.

Бөек Ватан сугышы башлану авылның үсешен туктата, күп гаиләләргә кайгы-хәсрәт алып килә. Тулы булмаган мәгълүматларга караганда, Мәсгут авыл советы территориясеннән 400 дән артык ир-ат сугышка китә. Мәсгут, Яхшыбай һәм Ирекле авылларыннан гына 148-дән артык ир-ат сугыш кырларында һәлак була.

Авыр сугыш елларында авыл хуҗалыгында төп авырлык хатын-кыз җилкәсенә төшә. Мәхдүмә Гайсина, Хаҗәр Гатауллина, Тәзкирә Зиннурова, Моназдаха Имамова, Фәгыйлә Мансурова, Мәрьям Мәҗитова, Дәрия Миннегалиева, Әзһәрия Мурзина, Җинан Рәхимова, Ниса Сираева, Разия Хәертдиновалар тракторист һөнәрен үзләштерәләр.



*Сугыш ветераны*
*Әсәдуллин Әхмәт*
*(1907–1988)*



*Сугыш ветераны*
*Хәйдәров Мирсалих*
*(1920–1998)*

1950 елда Мәсгут авылының күмәк хуҗалыгына Кызыльяр колхозын, 1957 елда – Ирекле колхозын, 1959 елда – Илбәк, Тырыш, Тархан колхозларын кушып, Октябрьнең 40 еллыгы исемендәге колхоз оештырыла. Күпмедер вакыттан бу зур колхоз структурасы үзгәрешләр кичерә, аерым «Янтарь» совхозы барлыкка килә. Октябрьнең 40 еллыгы исемендәге колхозның гомуми җир мәйданы 5740 га, «Янтарь» совхозыныкы – 1931 га тәшкил итә.

1996 елда Мәсгуттә биш йөзләп кеше яши. Авылда урта мәктәп була. Халыкның төп шөгыле булып игенчелек һәм терлекчелек санала[381].

[381] Узган гасырда язылган бу авыл тарихына шактый өстәмәләр кертү таләп ителде. Күпсанлы архив документларын кулланып, авылның башлангыч чор тарихын шактый тулыландырдым, аның 1736 елда Юрмый волосте биләмәләрендә барлыкка килүен ачыкладым. Авыл тарихына яңа мәгълүмат өстәү Мәсгуттә туып-үскән, бүгенге көндә «ЕлАЗ» АҖ генераль директоры вазифасын башкаручы Камил Сәлман улы Галимов белән хезмәттәшлек нәтиҗәсендә мөмкин булды (китапта аның шәҗәрәсе бирелә).

## § 13. Митрәй

Азнакай төбәгендә атамалары кеше исемнәре белән бәйле авыллар арасында Митрәй аерым игътибарга лаек. Бу исем татар шәҗәрәләрендә һәм ревизия исемлекләрендә ара-тирә очраштыргаласа да, барыбер ят кебек тоела. Әмма ничек кенә булмасын, бу чагыштырмача борынгы авылга нигез салучыларның берсе – Митрәй Килмәков. Аның турында тулырак мәгълүматка күчкәнче, авылның кайчан һәм ничек барлыкка килүен ачыклап үтик.

Бу җәһәттән Россия борынгы актлар дәүләт архивында саклanучы 1762 елгы документ төп чыганак булып тора. Анда авыл «деревня Новая, что на речке Стярли» дип язылган. Барлык халкы якынтирә авыллардан Икенче (1748) һәм Өченче (1762) ревизияләр арасында, Уфа провинциаль канцеляриясе указы нигезендә күчеп утырган. Исемлектә иң беренче булып Митрәй Килмәков күрсәтелә.



*Митрәй Килмәков күрсәтелгән 1762 елгы документ фрагменты*

Митрәй карт нәселен бераз яктыртып китик. Ул монда күчеп утырганчы Чалпы янындагы Наратлы авылында яшәгән, 1762 елда 86 яшьтә була. Аның үзе белән уллары Имангол (40 яшь) һәм Миңлегол (20) яши. Имангол өйләнгән, зур гаиләсендә уллары Ямангол (18), Сөбханкол (10), Рахманкол (8), Хуҗамкол (4), Рәхимкол (3) һәм Рәфикъ (2) була.

Исемлектә аерым күрсәтелгән Йөзәй Митрәев (52 яшь) Митрәй картның өлкән улы булса кирәк. Аның ир баласы юк.

Наратлы авылыннан күчеп килеп яшәүчеләр арасында тагын Солтангол Бикмәмәтов (28 яшь), Сәет Аюкаев (36), Күчәрбай Аитов (24), Дусмәкәй Ишмәтов (54) нәселләре күрсәтелә. Соңгысының Ярмөхәммәт (15) һәм Зөлмөхәммәт (8) исемле уллары була.

Күргәнебезчә, югарыда санап үтелгән биш нәсел арасында иң зурысы – Митрәй карт нәселе. Шуңа күрә авылның тора-бара аның исеме белән атала башлавы гаҗәп түгел. 1762 елда ул «Стәрле елгасындагы Яңа (ягъни яңа барлыкка килгән. – *Т.К.)* авыл» дип аталса, гасыр ахырынарак Яңа Митрәй дип күрсәтелә. Егерменче гасырда, төгәлрәк әйткәндә, 1926 елгы халык санын алу документында, авыл рәсми телдә беренче тапкыр хәзергечә, ягъни «Митрәй» дип кенә бирелә.

Авылда яшәүчеләрнең икенче төркеме Мостафа (хәзерге вакытта Башкортостан Республикасының Бакалы районына керә) авылыннан була. Ир-атлардан Мөслим Сөләйманов (19 яшь), Сәлиҗәгъфәр Сөләйманов (13), Шәмгун Сөләйманов (3) һәм Габдулла Мурзин (13) күрсәтелә.

Исемлек Гайсар Мөслимов (21 яшь) белән тәгәлләнә. Ул якындагы Стәрлетамак (хәзерге Югары Стәрле элек шулай аталган) авылыннан күчеп утыра.

Югарыда сүз барган документта 21 ир-ат исәпкә алынган. Сословиеләре буенча алар – ясаклы татарлар, соңрак Юрмый волосте старшинасы Биккенә Яушев командасында исәптә торалар[382].

Икенче исемлектән шул ук авылда (чыганакта «Новое Дмитрево тож») тагын бер башкорт сословиесендәге татар яшәве хакында беләбез. Анысы Нәдер волосте старшинасы Йосыф Нәдеров командасында күрсәтелә[383].

Шулай итеп, 1762 елда авылда барлыгы 22 ир-ат яши. Хатын-кызлар турында мәгълүмат юк, шуңа күрә алар күпме булган – билгесез. Ир-атлар саныннан чыгып, Митрәй – төбәктә иң кечкенә авылларның берсе, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Билгеле булганча, Е. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы (1773–1775 еллар) төбәкне читләтеп үтми. Риваятьләргә караганда, Чатыр тауда баш күтәрүчеләр хөкүмәт гаскәрләренә каршы сугышларга хәзерләнеп ятканнар. Нугайбәк һәм Бакалы ныгытмалары тирәсендә канлы бәрелешләр була. Митрәй дә, тирә-як авыллар да фетнәдә катнашучылар исемлегендә күрсәтелә.

Гасыр ахырына Митрәй авылы шактый зурая. 1795 елда анда 31 хуҗалыкта 139 ир-ат һәм 126 хатын-кыз яши[384]. Халык саны кинәт арту монда күпләп башкорт сословиесендәге татарлар яши башлавы белән бәйле. Аларның читтән килүе башка чыганакларда чагыла.

Нәтиҗәдә «башкорт» хуҗалыкларының саны ундүрткә җитә. Бу төркем 86 ир-ат һәм 80 хатын-кыздан тора. Авылның калган халкы – типтәр сословиесендәге татарлар (53 ир-ат һәм 46 хатын-кыз)[385]. Болардан башка, 1795 елда бирегә Бәләбәй округының Кинҗәкәй авылыннан (хәзерге Туймазы районы Райман авылы) Габделваһап Ибраһимов (51 яшь) гаиләсе, аның абыйсы Габдрахман Ибраевның хатыны, барлыгы 3 ир-ат һәм 6 хатын-кыз ясаклы татар күчеп килә. Бу чыганакта авылның исеме Яңа Авыл (чыганакта «Енаулево») дип язылган[386].

[382] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3801 сакл. бер., 492–494 б.; Крестьянская война 1773–1775 гг. на территории Башкирии. Уфа, 1975. С. 278.

[383] Крестьянская война 1773–1775 гг. на территории Башкирии. Уфа, 1975. С. 279.

[384] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 287 б. а.–294.

[385] Шунда ук.

[386] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 68–68 б. а.

Укучы игътибар иткәндер, Митрәйгә нигез салучылар ясаклы татарлар иде. Хәзер алар документта «типтәр»ләр дип күрсәтелә. Терминнарның икесе дә сословиене аңлата, әмма «типтәр»ләрнең җире күбрәк була. Еш кына сословие белән беррәттән милләт тә күрсәтелә (мәсәлән, «тептяре ис татар» дип).

Авылның көнкүрешенә кагылышлы мәгълүматларга тукталыйк. Игенчелек һәм терлекчелек – халыкның төп шөгыле. Хатын-кызлар кыр эшләреннән буш вакытта йоннан, киндер басаларыннан җеп эрләгәннәр, киндер һәм постау сукканнар. Ирләрнең бер өлеше (башкорт сословиесендә торганнары) чиратлашып (биш йорттан атлы ике кеше) ел саен Оренбург сызыгындагы төрле ныгытмаларга хәрби хезмәт үтәргә йөргәннәр. Хезмәт иткәндә алар жалованье һәм «атларга ремонт алганнар». Типтәр сословиесендәгеләр исә Оренбур шәһәрендәге ике мең атлы типтәр полкына чират буенча хәрби хезмәткә алынганнар, полк чыгымнарын түләргә мәҗбүр ителгәннәр. Ясаклы татарлар казнага оклад (салым) түләгәннәр[387].

1816 елда Митрәйнең (чыганакта «Новое Митреево») башкорт сословиесендәге татарлары юртовой старшина Хәлил Казбулатов командасына карый. Алар 21 хуҗалыкта яшәүче 83 ир-ат һәм 87 хатын-кыздан тора. Бу старшина командасына Яңа Урманайның да шул сословиегә караучы татарлары (48 хуҗалыкта 140 ир-ат һәм 151 хатын-кыз) керә[388].

Типтәр сословиесендәге татарлар саны күпкә азрак (53 ир-ат һәм 46 хатын-кыз; 19 хуҗалык) була. Ревизия исемлегендә беренче хуҗалык булып Миңлегол Митрәев (73 яшь; 60 һәм 55 яшьләрдәге ике хатыны, улы Габделхәким, кызы һәм килене күрсәтелгән) гаиләсе теркәлгән. Авылның исеме русча «Новая Енаулова тож» дип язылган, ревизия исемлеген раслап халык вәкиле («выборной») Рәхимкол Иманголов кул куйган[389].

Шуны күрсәтеп үтәргә кирәк, типтәр сословиесендәге татарларның саны алдагы ревизия белән чагыштырганда бөтенләй үзгәрмәгән. 1811 елгы ревизия мәгълүматы буенча алар 5 нче типтәр командасына (старшина Габделнәфыйкъ Габдерәхимов) карый, авылның исеме дә нәкъ шулай («Новое Енаулево тож») язылган. Типтәр сословиесендәге татарларның яртысыннан күбрәген Имангол (1799 елда вафат була) һәм Миңлегол (69 яшь) Митрәевләрнең балалары һәм оныклары тәшкил итә. Безнең исәпләүләр буенча, алар 33 ир-ат була[390].

Ясаклы татарлар 1816 елда 6 ир-ат һәм 4 хатын-кыздан тора. Ревизия исемлегендә Габделваһап Ибраев (71 яшь), Габделлатыйф (45), Габделгаффар (32) Габделваһаповлар, Сәеткол Аитов (63) гаиләләре теркәлгән. Авылның

[387] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 287–289 б.
[388] БР МА, И–138 ф. 2 тасв. 172 сакл. бер., 53 б.
[389] Шунда ук, 168 сакл. бер., 293–300 б.
[390] Шунда ук, 84 сакл. бер. 331–332 б. а.

исеме русча «Енаулова тож» дип язылган, ревизия исемлеген нәсел тамгасын салып раслаучы Габделваһап Ибраев була[391].



*1811 елда да авыл «Новое Енаулево тож» дип языла торган булган. Исемлек башында Митрәй карт нәселе теркәлгән*

Шулай итеп, 1816 елда Митрәйдә башкорт һәм типтәр сословиесендәге татарлар, бик аз санлы ясаклы татарлар яши. Кайбер авторлар сословиеләрне санап үткәндә икенче урынга ясаклы татарларны куялар[392], бу – дөрес түгел.

1834 елгы чыганак башкорт сословиесендәге татарларның күпчелеге (76 ир-ат һәм 76 хатын-кыз) биләмәче (вотчинник) булмавын күрсәтә. Биләмәче статусына бары тик 16 ир-ат һәм 18 хатын-кыз гына ия була[393].

---

[391] Шунда ук, 168 сакл. бер., 293–300 б.

[392] Кара: https://tatarica.org/ru/razdely/municipalnye-obrazovaniya/municipalnye-rajony/aznakaevskij-rajon/mitryaevo (мөрәҗәгать итү датасы: 2023 ел, 20 март).

[393] Шунда ук, 431 сакл. бер., 106 б. а.

1859 елның 26 июненә караган ревизия документында Митрәй авылының исеме русча «Новое Митряево Енаулово тож» дип бирелә. Бу вакытта 49 хуҗалыкта башкорт һәм типтәр сословиеләрендәге 347 ир-ат һәм 360 хатын-кыз татар исәпләнә. Ревизия документының титул битендә бу ике сословие татарлары «башкорт» дип язылган, чөнки 1855 елдан «типтәр»ләрне «Башкорт» гаскәренә кушалар. Шул чордан Митрәй халкы 23 нче кантонның 3 нче юртасы составына керә.

Башкорт сословиесенә 25 хуҗалык карый (Биктаһир Биктимеров, Корбангали Биктимеров, Курамша Туктаголов һәм башкалар). Исемлек ахырында Урманайдан (Хәмидулла Гаделшин, башкорт сословиесендәге указлы мулла) һәм Сәпәйдән (Нигъмәтулла һәм Гомәр Сәетколовлар) күчкән 3 гаилә күрсәтелә. Хуҗалыкларның яртысы диярлек типтәр сословиесендәгеләрдән тора (Гали Габделвахитов, Исмәгыйль һәм Ибраһим Хөҗәмколовлар, Афзалетдин Хафизов, Мөхәммәтгали һәм Мөхәммәткәрим Рәхимколовлар һәм башкалар)[394]. Болардан тыш, аерым исемлектә ясаклы татарлар теркәлгән була.

Статистик чыганак 1859 елда 404 ир-ат һәм 381 хатын-кыз (85 хуҗалык) яшәвен күрсәтә. Алар сословиеләре буенча казна крестьяннары һәм «башкорт»лар дип язылган[395]. Шулай итеп, монда «типтәр»ләр бөтенләй телгә алынмый: 1855 елда «Башкорт» гаскәре карамагына күчерелгәнлектән, статистик чыганакларда аларның сословиеләрен дә «башкорт» дип яза башлыйлар.

1884 ел ахыры – 1885 ел башында Митрәй (чыганакта Яңа Митрәй) Чәкән волостенда уртача зурлыктагы авыллардан санала. Анда 163 хуҗалыкта 478 ир-ат һәм 434 хатын-кыз күрсәтелә. Волостька тагын Чәкән, Каразирек, Урманай, Бәйрәкә һәм Кулчан авыллары керә.

Митрәй авыл җәмгыятенең ул чорда 2220,8 дисәтинә уңайлы һәм 218 дисәтинә уңайлы булмаган җирләре була. Аның 1284 дисәтинәсен сөрүлекләр алып тора. Волостьның башка авыллары белән чагыштырганда, монда җир белән тәэмин ителү уртача дәрәҗәдә. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка бүлгән очракта ул 10,8 дисәтинә туры килә. Бу күрсәткеч Бәйрәкәдә – 8,05, Урманайда – 18 дисәтинә.

Әмма хуҗалыклар буенча җирнең күләме, ягъни иманалар саны шактый аерыла. Авылда 162 хуҗалыкның иманасы була. Шуларның 63 ендә ул – берәр, 65 ендә – икешәр, 18 ендә – өчәр, 16 сында дүртәр яисә аннан артыграк. Мондагы бер имана ул чакта 6,9 дисәтинә тәшкил иткән, димәк, шактый хуҗалыкларның җире аз.

Эш кораллары белән тәэмин ителү дәрәҗәсе дә сизелерлек аерыла. 106 хуҗалыкта алар җитәрлек күләмдә була. Шул ук вакытта 23 хуҗалыкта өлешчә генә, ә унике хуҗалыкта бөтенләй юк. Мондый хуҗалыклар кирәкле

[394] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 757ж. сакл. бер., 39–70 б.

[395] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

эш коралларын авылдашларыннан хак түләп яисә башка шартларга килешеп алып торганнар.

Авыл халкы күп кенә эш атлары (271), мөгезле эре терлек (243), сарык (412) һәм кәҗә (94) асрый. Әмма хуҗалыклар буенча мал-туар саны шактый аерыла. Эш атларын гына алыйк. 20 хуҗалыкта алар бөтенләй юк. Шул ук вакытта 72 хуҗалык – берәр, 43 хуҗалык икешәр-өчәр ат тота. Авылда дүрт һәм аннан күбрәк атлылар да була. Тугыз хуҗалык дүртәр эш аты асраса, тагын сигезенең аннан да артып китә.

29 ярлы хуҗалыкта эш атлары да, сыерлар да булмый. Өстәвенә, унтугыз гаилә йортсыз (алар янгыннардан зыян күргән дип уйларга кирәк), тагын тугызы землянкада яши. Аларга тормыш итү шактый авырга туры килгән.

Имана җире аз яисә бөтенләй булмаган һәм мал-туарсыз хуҗалыкларның күпчелеге үз авылдашларына һәм якын-тирә алпавыт имениеләренә-хуторларга я булмаса авылларга төрле эшләргә ялланган, кайберләре һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Статистик мәгълүматлардан күренгәнчә, Митрәйдә 51 кеше (шуларның 8 читкә китеп) игенчелек белән бәйле эшләргә ялланган. Тагын 20 кеше (берсе читтә йөреп) һөнәрчелек белән шөгыльләнә. Авылда ике хуҗалык – лавка, унсигез хуҗалык умарта (89 баш) тота[396].

Гасыр ахырына Митрәй шактый зурая. 1897 елда монда 190 хуҗалыкта 533 ир-ат һәм 488 хатын-кыз яши. Авылда элеккечә бер мәчет була. Мәчетләр, 14 хуҗалыктан торган Кулчанны исәпләмәгәндә, волостьның барлык татар авылларында да була. Бәйрәкәдә – өч, Урманайда – ике, Каразиректә бер мәчет күрсәтелә.

Волость идарәсе Чәкәндә урнашкан. Монда яңарак кына ачылган земство шифаханәсе тирә-як авыл халкына медицина хезмәте күрсәтә. Аның штатында табиб һәм фельдшер тора. Табиб В.В. Вертельның 666 дисәтинә җире була, ул хуторда яши[397].

Чәкән үзенең ел саен 26 ноябрьдә уздырыла торган ярминкәсе һәм һәр атна шау-гөр килеп торган базары белән дан тоткан. Монда күрше өязләрдән дә сәүдәгәрләр килгәләгән. Бигрәк тә икмәк сәүдәсе киң колач ала. Хуҗалыкларда җитештерелә торган башка төр продуктларны (мәсәлән, бал) да, еракларда китерелгән тауарларны (сабын, төймә, затлы тукымалар һәм башкалар) да сатып алырга мөмкин булган. Шуңа күрә Митрәй халкы Чәкәнгә еш йөргән.

Җир җитмәү һәм иген уңмау (мәсәлән, 1897 елда) аркасында төбәктә күп кенә хуҗалыкларның матди хәле начарая. Ачлык елны Митрәйдә аларның шактые мал-туарын сатарга мәҗбүр була. Әмма аннан кергән аз-маз акча гы-

---

[396] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 298–305.

[397] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 59.

на җитми. Тәмам гаҗизлеккә төшкәч, кайберәүләр туган авылын ташлап читкә бәхет эзләргә чыгып китә. Түбәндә аларның берничәсен атап үтик.

Солтангәрәй Мөхәмmәтгәрәев (35 яшь) хатынын һәм ике баласын алып Богырыслан өязенә чыгып китә. Шуннан алар турында хәбәр булмый. Мөхәммәтвәли Хәбибрахмановның 28 яшьлек улы эш эзләп 1897 елда Оренбург губернасына юл тота. Шул китүдән ул авылга кайтмый. Ачлык елны Габделгази Гыйльмановның 22 яшьлек улы казна эшенә алына. Озак вакыт үтүгә карамастан, аннан бернинди хәбәр килми[398].

10 нчы ревизиядән (1859 ел) соң шактый вакыт узгач, Митрәйдә яңадан җир бүлү ихтыяҗы туа. Җир бүлү – күп вакыт таләп итүче һәм катлаулы эш. Халыкның төп өлешен тәшкил итүче «типтәр»ләр арасында ул болай үткәрелә. Алар 1894 елда 534 ир-аттан тора. Менә шул саннан чыгып, 1367,04 дисәтинә сөрүлекләрне җан башына унике елга бүләләр. Бер кешегә 2,56 дисәтинә җир туры килә.

«Типтәр»ләрнең әле тагын 51,3 дисәтинә сөрүлекләре була. Аның 10,3 дисәтинәсен муллага бирәләр. Ә калган 41,0 дисәтинә җир җәмгыять ихтыяҗлары өчен файдалануга калдырыла. Анда үстерелгән икмәк корылык елны алынган симәнә һәм азык-төлек ссудаларын кайтару өчен тотылачак.

1900 елның 25 сентябрендә төзелгән документтан күренгәнчә, Митрәйдә арыш, солы, карабодай, борай, бодай һәм тары иккәннәр. Кара туфраклы ашланмаган басуларда уңыш бер дисәтинәдән 20–25 (начар), 35–50 (уртача) һәм 60–80 (яхшы) потлап чыккан. Комлы-ташлы ашланмаган туфракта уңыш күпкә түбәнрәк була. Начары – 10–15, уртачасы – 20–25, яхшысы 30–35 потлар тәшкил итә.

Митрәйдә бөртеклеләр игелә торган басуларга 1894–1895 еллардан гына Чәкән алпавыты Мешкичев үрнәгендә ашлама (тирес) кертә башлыйлар. Ашлама кулланучы хуҗалыклар башта унлап кына булса, тора-бара аларның саны арта. 1900 елда йөзгә якын хуҗалык басуларга тирес чыгарган. Игенчеләр менә шулай ашлаган җирнең күбрәк уңыш бирүенә инана башлыйлар.

Игенчелек кораллары гадилеге белән аерылып тора. Җирне гадәттә сукалаганнар. Яткын җирләр булса, сабан белән сөргәннәр. Күбрәк сука куллануны туфракның йомшак булуы белән генә аңлату дөрес булмас. Төп сәбәп – атлар җитешмәүдә. Сукалаганда бер ат җиксәләр, сабанга ике ат таләп ителгән.

Җирне монда гадәттә 2–3 карыш (1 карыш = 4,4 см) тирәнлектә сукалыйлар. Комлы-ташлы туфракта гына сукалау тирәнлеге бераз кимрәк (1,5–2 карыш). Аннары икедән бишкә кадәр эз калдырып яхшылап тырмалаганнар. Өч аты булган игенче, аларны алыштыра-алыштыра, көнгә бер дисәтинә җир эшкәрткән.

---

[398] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 895 сакл. бер.

Язгы кыр эшләре гадәттә 7–10 апрельләрдә башланып май урталарына чаклы дәвам иткән. Бу чорда солы, карабодай, борай, тары һәм бодай чәчкәннәр. Җирнең уңдырышлылыгы шактый кимегәнгә күрә, бодайны бик аз хуҗалыклар гына игә. Арыш чәчеләсе җирләрне беренче сөрү унынчы июньдә, икенчесе июль ахыры-август башларында булган. Тәүге сөрүдән соң атна үткәч, җирне яхшылап тырмалаганнар һәм аннары кул белән чәчкәннәр.

Шулай итеп, кыр эшләре вакытында төп кораллар – сука, сабан һәм тырма. Тимер сабаннар һәм чәчкечләр Митрәйдә әле булмый. Игенчелек хезмәтен күпкә җиңеләйтердәй башка төр эш кораллары, берничә җилгәргечне исәпләмәгәндә, юк дәрәҗәдә.

XIX гасыр ахырында Митрәйдә бер мәчет булуы хакында әйткән идек. 1900 елда авылның указлы муллалары вазифасын Хөсәен Габделгафуров (аңа 62 яшь) һәм Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтдәминовлар (41) башкара. Хөсәен хәзрәт Митрәйдә туып-үскән; хатыны (55), 4 улы, 3 кызы, ике килене һәм оныклары белән яши. Аның дүрт иманасында – 7,92 дисәтинә, арендага алган басуларда 11,92 дисәтинә чәчүлекләре була. 4 эш аты, биш сыер һәм кырык биш сарык асрый.

Икенче мулла – Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтдәминов – Бәйрәкәдә туып-үскән, анда мәдрәсә тәмамлаган. Гарәп-фарсы телләрен яхшы белгән бу мулла Митрәйдә балалар укыту белән дә шөгыльләнә. Биредә ул хатыны, улы һәм ике кызы белән яши. Хуҗалыгы зур түгел.

Авылның мөәзине – Әхмәт Габделганиев (56 яшь). Мөхәммәтсадыйк мулладан аермалы буларак, ул монда туып-үскән. Зур гаиләсендә хатыны, уллары (дүрт), киленнәре (ике) һәм оныклары (дүрт) була. Бер улы Бәләбәй өязендә муллалык итә. Хәзрәтнең хуҗалыгы таза тормышлы булуы белән аерылып тора. Аның, биш иманадан тыш, 50 дисәтинә сатып алган җир-урман биләмәләре дә була. Җире мул булганлыктан, ул аның берникадәр өлешен арендага бирүне кулай күрә. Хуҗалыгында ике эш аты, биш сыер, 32 сарык һәм 10 кәҗә асрый. Кыр эшләре вакытында мөәзиннең басуларында йөзгә якын көнлекче бил бөккән.

Мөхәммәтсадыйк хәзрәттән тыш, Митрәйдә балалар укыту белән тагын Вәли Галләмов (52 яшь) шөгыльләнә. Кыш айларында аңа утызга якын бала сабакка йөргән. Ул ике хатыны белән яши, балалары юк. Аның хуҗалыгы ярлылар исәбенә керә. Анда нибары бер имана һәм сыер күрәбез.

Очын-очка ялгап бару өчен укытучылыктан кергән аз-маз хак (аны ата-аналар хуҗалыкта җитештергән продуктлар белән биргәннәр) кына җитми, әлбәттә. Шуна күрә Вәли Галләмов җәй айларында хуҗалыклардан чүпрәк һәм йомырка җыеп, аны Бөгелмә базарына алып барып сата торган булган. Бу шөгыль әлләни зур табыш китермәсә дә, үз-үзен аклаган. Чүпрәкне монда потын 15 тиеннән җыеп, базарда 20–50 тиеннән сатып җибәргән ул. Йомырканың дистәсе 10–15 тиен торган. Җәй буена укытучы мондагы алыпсатар-

ларга ун меңгә якын йомырка җыеп саткан. Һәр йөз данә йомырка биш тиен файда китергән.

Сүз уңаеннан әйтик, вак-төяк сәүдә белән авылда тагын бер кеше – Шакир Әхмәтов шөгыльләнә. Ул тәгәрмәчләр, чаналар һәм башка әйберләр саткалый.

Митрәй халкы кирәкле бакалея товарларын Мөхәммәтгали Мөхәммәтҗанов (55 яшь) лавкасыннан сатып алган. Таза тормышлы хуҗа хатыны, 3 улы һәм кызы белән яши. 4 иманадан тыш, аның 50 дисәтинә сатып алган җир-урман биләмәләре дә була. Тагын 8 эш аты, 17 сыер, 140 баш сарык һәм 8 кәҗә асрый. Өстәвенә, 8 баш умарталыгы да була аның. Кызу урак өстендә Мөхәммәтгали байның басуларында берьюлы йөз иллеләп көнлекчене күрергә мөмкин булган.

Алдарак телгә алынган Әхмәтша Габделганиев һәм Мөхәммәтгали Мөхәммәтҗанов кебек зур җирбиләүчеләр Митрәйдә тагын була. Алар арасында бигрәк тә Габделгали Габделганиев (61 яшь) аерылып тора. Байның сатып алган җир участогы 166,12 дисәтинә тәшкил итә. Шуның ун дисәтинәсе урманнан гына тора. Хуҗалыгында 7 эш аты, 31 сыер, 151 сарык һәм 17 кәҗә асрый. Йорт яны эшләрен 3 хезмәтче башкара. Уңыш җыю чорында ул барлыгы ике йөздән артык көнлекче яллаган.

Барлык җир биләмәләренең зурлыгы буенча икенче урында Әхмәтша Габделганиев (41 яшь) тора. Ул – 4 имана һәм 100 дисәтинә сатып алган җир участогы хуҗасы. Хуҗалыгында 6 эш аты, 25 сыер, 160 сарык һәм 29 кәҗә була. Йорт яны эшләрен 2 хезмәтче башкара. Әхмәтша байның бодай, арыш, солы, борай һәм тары чәчүлекләре 38,84 дисәтинә тәшкил итә. Печәнлекләре – 63, урманы 11 дисәтинә җирне алып тора.

Тагын бер зур биләмә хуҗасы – Насыйр Габделвәлиев (55 яшь). Аның 3 иманасы һәм 50 дисәтинә сатып алган җир участогы була. Байның эре малтуары да күп (4 эш аты, 5 сыер һәм башкалар). Умарталыгы исә 2 баштан артмый.

Мөхлисулла Ибәтуллинның (31 яшь) да хуҗалыгы зурлардан санала. Ул 8 эш аты, 9 сыер, 135 сарык һәм 5 кәҗә асрый.

Югарыда телгә алынган хуҗалыклар (Әхмәт Габделганиев, Әхмәтша Габделганиев, Мөхәммәтгали Мөхәммәтҗанов, Габделгали Габделганиев, Насыйр Габделвәлиев, Мөхлисулла Ибәтуллин) авылда иң зурлардан санала. Митрәйдә иң күп иген игүчеләр – алар. Насыйр Габделвәлиевнең, мәсәлән, чәчүлекләре 26,66 дисәтинәдән арта. Болар инде, әйткәнебезчә, таза хәлле хуҗалыклар катлавын тәшкил итә.

Урта хәлле хуҗалыкларга тукталып үтик. Бу катлауга Хөсәен Габделгафуров, Нигъмәтулла Ибәтуллин (36 яшь), Шаһидулла Ибәтуллин (33), Вәли Исхаков (50), Ихсан Исхаков (62), Мөхәммәтхаҗи Мөхәммәтшәрипов (50), Сәгъдетдин Камалетдинов (65), Хөснетдин Мөхәммәтҗанов (62), Хәсән Шәяхмәтов (60) һәм тагын ике дистәгә якын хуҗалык керә. Аларның берничәсе хезмәтче тота; күпчелегенең чәчүлекләре аренда исәбенә 10 дисәтинәдән

артып китә. Бу катлауны тәшкил итүче хуҗалыклар шактый мал-туар асрыйлар. Мөхәммәтхаҗи Мөхәммәтшәриповның, мәсәлән, 5 эш аты, 5 сыеры, 50 сарыгы һәм 8 кәҗәсе була.

Урта хәллеләр арасында бигрәк тә Сәгъдетдин Камалетдинов хуҗалыгы аерылып тора. Ул хатыны (40 яшь), 7 улы (берсе өйләнгән), килене һәм оныгы белән яши. 7 иманасында – 15, арендага алган басуларда 3 дисәтинә чәчүлекләре була. 3 эш аты, 3 сыер һәм 40 сарык асрый.

Авылның югарыда күрсәтелгән ике катлавы базар белән аеруча тыгыз бәйле. Аларның төп өлеше үзләреннән арткан икмәкне һәм мал-туарны сатарга алып чыга, байый. Капиталистик Россиядә авыл хуҗалыгы продуктларына кытлык бөтенләй булмауны менә шул катлауларның эшчәнлеге, тырышлыгы белән аңлатырга кирәктер.

Өченче, ярлы катлау (чәчүлек җирләре 4 дисәтинәгә кадәр) базар белән аз бәйләнгән. Аларның җитештергәне үз гаиләләрен туйдырырга көчкә җитеп барган. Еш кына алпавыт һәм кулак хуҗалыкларына төрле эшләргә ялланалар.

Иң түбән катлау – авыл пролетарийлары. Аларның чәчүлек җирләре бик аз (0,15 дисәтинәгә кадәр) яисә бөтенләй юк. Болар күп вакыт көнлекчелеккә йөриләр яисә батраклыкка ялланалар.

Кайбер батраклар турында аерым әйтеп үтик. Шәфикъ Садыйков (30 яшь), мәсәлән, авылдашы Әхмәтша Габделганиевта батраклыкта йөри. Читкә китеп эшкә урнашучылар да була. Әхмәт Нәфиковның 28 яшьлек улы – алпавыт Микулин батрагы. Габделгази Насыйров алпавыт Д.Ф. Симоновта бил бөгә. Габделгани Байгузин (40 яшь) – Урманайдан, Газизулла Хәмидуллин (38) Карамалыдан батраклыктан кайтып кермәгәннәр диярлек.

Билгеле дәрәҗәдә Митрәйдә һөнәрчелек тә үсеш ала. Беренче чиратта, агач эше осталарын күрсәтеп үтәргә кирәк. Алар арасында балта осталарын (Кусан (?) Исхаков, Якуп Йосыпов, Ильяс Йосыпов, Мөхсин Ильясов, Әхмәтҗан Садыйков) һәм тәгәрмәчләр ясаучыны (Әхмәт Әсәдуллин) күрәбез. Соңгысы монда Урманай авылыннан килеп төпләнгән.

Башка төр һөнәр ияләреннән мич чыгаручыларны (Галиулла Мөхәммәтгалиев, Шәрәфетдин Ситдыйков, Әюп Фазлыйәхмәтов), киез итек басучыны (Камалетдин Мозаффаров), итекчене (югарыда телгә алынган Якуп Йосыповның улы) һәм чабатачыны (Хәлиулла Мөхәммәтгалиев) күрәбез.

Митрәйдә тегермәнчелек белән дә шөгыльләнүчеләр була. Авыл тегермәннәрен Габделгалләм Вахитов, Мөхәммәтша Габдрахманов һәм Госман Габделлатыйпов арендага алганнар. Аларның хуҗалыклары урта һәм таза хәллеләр рәтенә керә. Габделгалләм Вахитов (42 яшь) 3 эш аты, 3 сыер һәм 20 сарык асрый. Аның барлык чәчүлекләре 11,92 дисәтинә мәйданны били. Тегермәндә ул үзе генә, кеше яллымыйча, эшли.

Мөхәммәтша Габдрахмановның (65 яшь) да хуҗалыгы зур. Аның ике дистәдән артык мал-туары (3 эш аты, 5 сыер һ. б.), 25 баш умарталыгы һәм 10,58 дисәтинә чәчүлекләре була. Ул да тегермәндә үзе генә эшли.

Өченче тегермән арендаторы Госман Габделлатыйпов (65 яшь) аеруча игътибарга лаек. Аның чәчүлекләре 23,96 дисәтинә тәшкил итә. Күп мал-туар (4 эш аты, 4 сыер һ. б.) асрый, 15 баш умарта тота. Тегермәндә һәм хуҗалыгында ике хезмәтчесе эшли. Таза тормышлы Госман Габделлатыйпов Митрәй байлары рәтендә йөри.

Бу бүлектә зур умарталыклары булган күп кенә хуҗалыклар телгә алынды. Әмма аеруча зур умарталык (100 баш) Шакир Шәрәфетдиновныкы (48). Мул тормышлы хуҗаның 21,37 дисәтинә чәчүлеге һәм ике дистәдән артык мал-туары (3 эш аты, 2 сыер һ. б.) була.

Вак умартачылар да шактый. Аерым алганда, бу исемлеккә Әхмәт Шәяхмәтов (75 яшь), Ихсан Исхаков (62), Габделвәли Галиев (50), Мөхәммәтхаҗи Мөхәммәтшәрипов (50), Әхмәт Нәфиков, Мөхәммәтҗан Әхмәтҗанов (58) һәм Хәсән Әхмәтҗанов (48) керә[399].

Шулай итеп, Митрәйдә халыкның игенчелек һәм терлекчелектән тыш та шөгыле күп булуы күзгә ташлана. Һөнәрчелек һәм умартачылык хуҗалыкларның өстәмә табыш чыганагы булып тора. Ә менә чәчүлексез йортларның кайберләре еш кына һөнәрчелек белән көн күргәннәр.

Авылның социаль-икътисади торышын тасвирлауны төгәлләр алдыннан тагын бер-ике мәгълүматка тукталыйк. 1900 елда Митрәйнең төп халкы 193 хуҗалыкта яши. Аларның 91 е «типтәр»ләр дип күрсәтелә. Болардан тыш, читтән килеп утырган 3 хуҗалык та була. Ә менә аерым исемлектә бирелгән 15 гаилә монда исәпләнсә дә, чынлыкта исә авылда яшәми. Аларның кайберләре, өйләрен сатып, күптәннән (хәтта дистәләрчә еллар элек) читкә чыгып киткән[400]

1907 елда Митрәй халкы икенче җәмигъ мәчет салырга рөхсәт ала. Яңа мәхәлләгә мулла булып 1908 елдан Хөсәен хәзрәтнең улы Әхсән раслана. Авыл тагын да зурайган: 1910 елда басылган белешмәдән күренгәнчә, 217 хуҗалыкта 593 ир-ат һәм 516 хатын-кыз яши[401].

Беренче бөтендөнья сугышы авылның социаль-икътисади торышына гаять тискәре йогынты ясый. Яралanучылар һәм бөтенләйгә сугыш кырларында ятып калучылар турында хәбәрләр әледән-әле килгәләп тора. Сугыш кайчан бетәр, бу турыда беркем дә белми. Билгесезлек-өметсезлеккә инфляция дә өстәлә, бәяләр торган саен котырып үсә.

Менә шундый шартларда Бөгелмә өязендә авыл хуҗалыклары исәбен алу (1916 ел) үткәрелә. Аның документларына таянып, Митрәйнең ул чордагы торышын кыскача тасвирлап үтик.

---

[399] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 895 сакл. бер.

[400] Шунда ук.

[401] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер.; Список населенных мест Самарской губернии (сост. Н.Г. Подковыровым). Самара, 1910. С. 131.

Авылда 257 хуҗалык, 591 ир-ат һәм 439 хатын-кыз теркәлә. Башка авылларда хатын-кызлар күбрәк булса, монда, киресенчә, алар азрак. Ә бит сугышка бик күп ир-ат алына. Статистикларның халык санын исәпләгәндә хата җибәргән булулары мөмкин.

Авыр сугыш елларында да авыл халкы күп терлек асрый һәм зур мәйданда иген игә. Митрәйдә 463 ат (шул исәптән 390 эш аты), 564 мөгезле эре терлек (284 сыер), 1482 сарык һәм 244 кәҗә исәпләнә. Чәчүлекләр мәйданы 1075,45 дисәтинә тәшкил итә. Шуларның яртысын диярлек арыш (523,9 дисәтинә), калган өлешен солы (150), борай (120,35), тары (111,35), бодай (81,3), карабодай (77,8) һәм борчак (10,8) алып тора[402].

Билгеле, хуҗалыкларга карап мал-туар саны һәм чәчүлек мәйданы нык аерыла. Бигрәк тә гаилә башлыклары сугышка киткән хуҗалыкларга авыр була. Аларның мал-туары һәм чәчүлекләре сизелерлек кими.

1916 елда Чәкән волостена Митрәйдән башка, Чәкән (404 хуҗалык), Бәйрәкә (904), Каразирек (283), Урманай (328), Кулчан (26) авыллары, Стәрлетамак (13), Белов (14), Микулин (17) поселоклары һәм Ярмәков (23) хуторы керә. Күренгәнчә, авыллар арасында иң зурысы – Бәйрәкә.

Волостьта ун һәм унга якын хуҗалыктан торган хуторлар һәм поселоклар бик күп. Хуторлар саны гына 18-гә җитә. Аларда 47 хуҗалык, 293 ир-ат һәм 231 хатын-кыз исәпләнә. Шунысына игътибар итик, монда качаклар (34 кеше) да, сугыш тоткыннары (59) да яши. Хутор хуҗалары арасында Д.П. Юсин, П.Е. Юсин, Д.Ф. Симонов, П.М. Турчанинов, А.М. Турчанинов, Б.А.Сафонов, П.А. Дворников, Е.А. Дворников, М.А. Дворников, Пивоваров, дворян Аитов, К. Мөлеков һәм М. Мөлеков фамилияләре күзгә ташлана.

Поселоклар – сигез. Аларда 40 хуҗалык, 104 ир-ат һәм 116 хатын-кыз күрсәтелә. Поселокларның иң кечкенәсе – ике, зурысы ун хуҗалыктан тора.

Чәкән волостендагы поселок-хуторларда яшәүче, сатып алган җирләре булган татар хуҗалыкларын аерым билгеләп үтик. Болар – Муллагали, Солтангәрәй һәм Исмәгыйль Ярмәковлар, М. Мортазин, Габделкаюм һәм Мостафа Мөлековлар, Миршәрип Әпсәләмов, Б. Габделгалиев һәм дворян Аитовлар[403].

1920 елда Митрәйдә 280 хуҗалыкта 1433 кеше яши. Әмма 1921 елгы ачлык әлеге күрсәткечләрне сизелерлек үзгәртә: 1926 елда монда 226 хуҗалык һәм 1142 кеше була[404]. Авыл Бөгелмә кантоны Азнакай волостена керә[405].

---

[402] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 917 сакл. бер.

[403] Шунда ук.

[404] Шуна ук, Р–1295, 12 тасв., 63 сакл. бер., 3 б.

[405] Авыл тарихы 1990 нчы елларда язылды.

## § 14. Сәпәй

Сәпәй – Чатыр Таудан сузылган тау тезмәләре итәгендә урнашкан уртача зурлыктагы авыл. Авылны икегә бүлеп, тау чишмәләреннән хасил булган инеш ага. Сәпәй белән Уразай арасында Вәрҗәде һәм Мачаклы инешләре кушылып, Стәрле елгасына коялар. Тирә-якта урман-куаклыклар, болынбасулар җәйрәп ята. Матур табигате белән бу урыннар элек-электән кешеләрне җәлеп итеп торганнар.

XVIII гасыр документларыннан күренгәнчә, бирегә Казан өязе Арча юлы авылларыннан берничә хуҗалык күчеп утыра. 1740 елда бер авылдан (чыганакта «деревня Побык речки»; Колмәт Котлыгошев йөзлегенә керә) Чатыр елгасы буендагы Сәпәйгә («Сапеево по речке Четыр») Гомәр Азаматовның күченүе мәгълүм[406]. Бу чыганакта Сәпәй яңа нигезләнгән авыл дип әйтелми, димәк, Арча юлы ясаклы татарлары килгәнче үк монда яшәүчеләр булган (бер чыганакта Сәпәйдә һәм тагын берничә авылда мәчет XVII гасыр ахырында төзелгән дип әйтелә).



*Сәпәйгә 1740 елда күчеп килгән Гомәр Азаматов теркәлгән документ фрагменты*

1748 елгы ревизия документында да Сәпәйнең Чатыр елгасы буенда урнашуы күрсәтелә, төрле авыллардан килеп утырган 16 ир-ат исемнәре бирелә. Югарыда телгә алган Гомәр Азаматовтан (29 яшь; уллары Мөсәллим, Файзулла) тыш, болар Көчек (чыганакта «деревня, что был починок Кучюк») авылыннан Киләй Башаев (53; уллары Балтай, Бикмәт һәм нәселдәше Башбәк), Ташлы Елгадан – Мортаза (23) һәм Әмин (2; Ибрай[407] Уразмәтов уллары), Кукмарадан (чыганакта «деревни Другой Кукмор») – Ишкенә Дүсмәтов (28; шунда ук нәселдәше Аптык Арысланов), Исәммәт Дүсмәтов (45; улы Исәнгол), Ишем Дүсмәтов (38; улы Биктимер), Ярмәк Иванов (38)) була[408].

1748 елгы ревизия документы Сәпәйнең Казан өязенә караган бер төркем халкын гына чагылдыра. Икенче төркем халык Уфа өязенең Байлар волостенда исәпләнгән ясаклы татарлардан тора. Алар турында 1748 елгы ревизия документы сакланмаган, түбәндә 1762 елгы чыганакка таянып исемнәрен күрсәтеп үтәбез.

---

[406] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1154 сакл. бер., 130 б.

[407] 1762 һәм 1795 елгы документларда Аблай дип язылган.

[408] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1140 сакл. бер., 71 б. а.–72 б. а.; 1188 сакл. бер., 144 б.

Байлар волостеның Сөендек Тукбаев командасында торучы бу ясаклы татарлар 1762 елда 20 ир-ат тәшкил итә. Болар түбәндәге хуҗалыклар: 1) Абдул Сәетов (мәрхүм; уллары Габдерәшит, Җәлил, Хәлил, тәрбиягә алган улы Мәксүт); 2) Сәлим Сәетов (37 яшь; уллары Сәгыйть, Сәмә[й]); 3) Габдулла Сәетов (30); 4) Котлымәт Колмәтов (29; уллары Котлы, Зөбәер); 5) Яугилде Колмәтов (26); 6) Габдрахман (мәрхүм; улы Мөстәкыйм) һәм Габдерәззак (31) Канышевлар; 7) Айдагол Тукташев (мәрхүм; уллары Әмир, Габдессәлам); 8) Туктамыш Балтаев (мәрхүм; уллары Арслан (аныкы Гобәй), Айдар, Гайсар). Ревизия исемлегенә халык вәкиле («выборной») Арыслан Туктамышев һәм староста Габдулла Сәетов үзләренең тамгаларын салалар (беренчесенеке «Т», икенчесенеке «Ш» хәрефенә охшаган)[409].

Моңарчы сәпәйлеләрнең бу төркеме ишлерәк була, әмма 1762 ел алдыннан 22 ир-ат (Гомәр (48 яшь), Мәсгут (29), Госман (43) и Йосыф (30) Мурзиннар һәм башкалар) төбәктәге Уразай авылына күчеп утыра[410].

Бу татарлар Байлар волосте командасында торсалар да, Юрмый волостенда яши дип күрсәтелә (мәсәлән, авылдашы белән никахлашкан Госман Мурзин[411]). Димәк, Байлар волостеннан күченеп китсәләр дә, элеккеге тәртип буенча шул волостьта исәпләнгәннәр. Шундый ук хәлне Азнакай авылы мисалында да күрдек.

1762 елда Сәпәйнең икенче төркем ясаклы татарларын элек Казан өязенә караган ясаклы (37 ир-ат) һәм йомышлы (18 ир-ат) татарлар тәшкил итә. Авылның исеме русча «Сапеево на речке Четыр[412] близкой Чалпы» дип язылган. Исемлектә беренчеләрдән булып өч хатынлы ясаклы татар Гомәр Азаматов (44 яшь) теркәлгән. Ул элек Арча юлының Колмәт Котлыгошев, хәзер Токтамыш Сәфәров йөзлегендә (сотнясында) тора. Ике хатыны ясаклы татар, өченчесе – Уфа өязенең Казан юлына караган Зияш авылыннан башкорт сословиесендәге татар кызы була. Бу ясаклы татарларның бер өлеше Кукмара (чыганакта «Другой Кукмари»; 2 ир-ат), Карашай Саклау (4 ир-ат; Нәдер Туганашев йөзлегеннән) һәм Шөкрәле (3; элек Арча юлының Колмәт Котлыгошев, хәзер Токтамыш Сәфәров йөзлегендә торалар) авылларыннан күчеп килә. Исемлек ахырынарак йомышлы (служилый) татарлар (18 ир-ат; Бакый Мәмәтов варислары (Абдулла, Әбдүк, Мусай, Арыслан, Шәрип, Мөхсин, Габдрахман), Шәфи һәм Зәйнигабдин Мостаевлар, Минлекәй Сөләев) теркәлгән. Алар барысы да Бикбулат авылыннан күчеп утырганнар, Казан өязе Арча юлының Дәүләт Аитов (аңарчы К. Янклычев) йөзлегенә карыйлар.

---

[409] Шунда ук, 3801 сакл. бер., 927–928 б.

[410] Шунда ук, 504–505 б.

[411] Шунда ук, 362 б.

[412] Елганың исеме Чатыр («Четыр»; Чытыр) булуына игътибар иттек. «Чатыртау» атамасының килеп чыгышы шул елгага бәйле булса кирәк.



*Чатыр («Четыр») елгасы буендагы Сәпәйдә ясаклы татар Гомәр Азаматов гаиләсе теркәлгән 1762 елгы ревизия документы фрагменты*

Әлеге ревизия документындагы никах мөнәсәбәтләрен чагылдырган мәгълүматлар аерым игътибарга лаек. Югарыда телгә алган Г. Азаматов кызы Мотыйганы (17 яшь) Юрмый волостеның Урманай авылында яшәүче башкорт сословиесендәге татар Раптан Урманаевка кияүгә бирә. Аптикәй Араслановның туганы Гөлйөзем (33 яшь) Сәпәй авылының башкорт сословиесендәге татарына – Исәнбай Мөслимовка кияүгә чыга. Өченче татарның кызы Юрмый волосте Сәпәй авылының ясаклы татары Госман Мурзин белән гаилә кора. Балтай Киләевнең (45 яшь) өченче хатыны Шәрсолтан Богданова Актаныш «башкорты» кызы була[413].

Югарыда китерелгән мәгълүмат Сәпәй авылының Юрмый волосте биләмәләрендә барлыкка килүенә ишарәли һәм шул чорда ук монда ике сословие (ясаклы татар һәм башкорт) татарлары яшәвен күрсәтә. Өстәвенә, шул волость составындагы Урманай авылының нигез салучысы Урманайның Раптан исемле улы булуын, аның Сәпәйнең ясаклы татары белән гаилә коруын белдек.

[413] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3795 сакл. бер., 359–363 б. а.; 1140 сакл. бер., 71–72 б.

Мондагы тоташ урман белән капланган җирләр ул чорда Юрмый волосте карамагында була. Шуңа күрә авылга аның халкы рөхсәте белән нигез салына. Моңа чаклы да бу җирләр буш ятмаган, әлбәттә. Кемнәрдер монда яшәгән, аннары башка якларга күчеп киткән. Төбәктәге археологик табылдыклар шул хакта сөйли.

Халык хәтерендә Сәпәй авылы атамасы килеп чыгу белән бәйле риваять сакланган. Авылда булган чакта укытучы-пенсионер Әслах Кашап улы Кашаповның кульязма авыл тарихыннан күчереп алдык без аны. Аның эчтәлеге түбәндәгечә.

Яхшы җирле урын эзләп йөрүче берничә кешедән торган төркем хәзерге «Кызлар тавы» дип аталган тауга килеп туктаган да, су эзләгәндә Олы чишмәнең чылтырап аккан тавышын ишетеп, шул якка юнәлгән. Үзләре белән килүче кызларын вакытлыча тау башында калдырганнар, шуңа күрә ул «Кызлар тавы» дип аталган. Соңыннан үзләре өчен яшәргә уңайлы елга буена урнашканнар. Башлап килүчеләрнең өлкәне Сәфәргали исемле булган, аны Сәпәй карт дип йөрткәннәр. Ул үлгәч, авылны аның исеме белән Сәпәй дип атаганнар.

Авыл кешеләреннән, башлап килүченең исеме Сәфәргалидән түгел, ә Сафиулладан алынган дигән фикер дә ишетергә туры килде. Әлеге исемнең диалекталь варианты Сәпи булып, тора-бара Сәпәйгә әйләнгән, имеш.

Емельян Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы (1773–1775 еллар) башлангач, төбәктәге күпчелек авыллар баш күтәрүчеләргә кушыла. Алар арасында Сәпәй дә була. Документта әлеге хәрәкәттә катнашкан авыл кешеләре (бер өлеше дип әйтик) ясаклы татарлар дип күрсәтелә. Алар старшина Габдулла Ягъфәров командасында торганнар.

XVIII гасыр ахырында Сәпәй халкы төрле сословие кешеләреннән тора. 1795 елда йомышлы татарлар 42 ир-ат һәм 38 хатын-кыз тәшкил итә. Алар турында Уфа казна палатасы указы нигезендә 1787 елда ясаклыдан йомышлы татар сословиесенә күчерелгән дип әйтелә[414]. Болар Абдулла (1709–1795) һәм Шәрип (1721–1790) Бакиевлар варисларыннан, Габдрахман Абдюков (47 яшь), Габдрахман Бакиев (66), бертуган Мәхмүт (37), Хәбибулла (31), Рәхмәтулла (31), Нигъмәтулла (30), Гобәйдулла (29) Мөхсиновлардан, Зәйнекәй Таев (37) гаиләләреннән тора. Соңгысының уллары Габделкәрим, Габдерәшит һәм Габделваһап казна палатасының 1797 елгы фәрманы нигезендә 1796 елдан Тубыл губернасының Томск шәһәренә күчерелә[415].

[414] Алар 1762 елда болай да йомышлы татарлар сословиесендә исәпләнә иде. Димәк, берара ул сословиедән чыгып торганнар.

[415] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 22 сакл. бер., 93–96 б.

Типтәр сословиесендәге татарлар 1795 елда 38 ир-ат һәм 36 хатын-кыздан тора һәм 5 нче типтәр командасына (старшина Зәбир Зөбәеров) карый[416], 1762 елда болар ясаклы татар сословиесендә иде.

Ясаклы татарлар 1795 елда 35 ир-ат һәм 37 хатын-кыз исәпләнә. Болардан Хәмит Үтәшев гаиләсе (2 ир-ат һәм 2 хатын-кыз) аерым исемлек белән теркәлгән[417]. Башкорт сословиесендәге татарлар нибары 8 ир-ат һәм 12 хатын-кыз тәшкил итә.

1816 елгы ревизия мәгълүматлары аерым игътибарга лаек. Күпчелекне типтәр сословиесендәге татарлар (хәзер алар барлыгы 21 хуҗалык, 69 ир-ат һәм 47 хатын-кыз) тәшкил итә[418]. 1814 елгы манифест нигезендә «типтәр» булып язылган, читтән килеп утырган ике кешелек гаилә 1818 елгы документта аерым теркәлгән[419]. Соңгысын да кушсак, барысы 70 ир-ат һәм 48 хатын-кыз (22 хуҗалык) булып чыга.

Йомышлы татарлар – 43 ир-ат һәм 49 хатын-кыз (12 хужалык; Гобәйдулла Биктимеров һәм башкалар), ә ясаклы татарлар шул ук тәртиптә 39 һәм 33 (13 хуҗалык; Рәхмәтулла Хәмитов һәм башкалар) исәпләнә[420]. Башкорт сословиесендәге татарлар 21 ир-ат һәм 18 хатын-кыз (7 хуҗалык; Сәлим Солтанголов һәм башкалар) тәшкил итә[421]. Авылдан бер чакрым ераклыкта, Вәрҗәде елгасында «башкорт» Вәлиша Биккенин тегермән тота. Авылның тимерчелеге дә була.

Авылның көнкүрешен тасвирлаган мәгълүматлар кызыклы. Игенчелек һәм терлекчелек – халыкның төп шөгыле. Хатын-кызлар кыр эшләреннән буш вакытта йоннан, киндер басаларыннан җеп эрләгәннәр, киндер, постау сукканнар. Ирләрнең бер өлеше (башкорт сословиесенә кергәннәре) чиратлашып (биш йорттан атлы ике кеше) ел саен Оренбург сызыгындагы төрле ныгытмаларга хәрби хезмәт үтәргә йөргәннәр. Хезмәт иткәндә алар жалование һәм атларга «ремонт» алганнар. Типтәр сословиесендәгеләр исә Оренбург шәһәрендәге ике мең атлы типтәр полкына чират буенча хәрби хезмәткә алынганнар, полк чыгымнарын түләргә мәҗбүр ителгәннәр. Тирә-як авыллардагы кебек, Сәпәйдә дә бер мәчет була[422].

XIX гасыр уртасына авыл шактый зурая. 1859 елда типтәр һәм башкорт сословиеләрендәге татарлар 166 ир-ат һәм 180 хатын-кыз (30 хуҗалык) тәшкил итә. Сословиеләрнең соңгысы нибары 36 ир-ат һәм 40 хатын-кыздан (5 хуҗалык) тора. Нигъмәтулла, Гали һәм Гомәр Сәетколовлар – Яңа Митрәйгә (3 нче юрта), Мөхәммәди Ишмөхәммәтов, Габделвәли Сәетколовлар

[416] Шунда ук, 24 сакл. бер., 386–389 б.
[417] Шунда ук, 23 сакл. бер., 20–24 б. а., 47 б.
[418] Шунда ук, 168 сакл. бер., 647–652 б.
[419] Шунда ук, 654–655 б.
[420] Шунда ук, 197 сакл. бер., 988–996 б.
[421] Шунда ук, 172 сакл. бер., 170 б. а.–171.
[422] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 250–253 б.

шул ук юртаның Бәйрәкә авылына күчеп утыралар. Исемлек ахырында Сәпәйгә күчеп килгән типтәр сословиесендәге татарлар Шәрифулла Бикташиров (38 яшь; Банки Сукаеш авылыннан) һәм Мөхәммәтрәхим Сәйфуллин (40; Әлкидән) хуҗалыклары теркәлгән. Ханморза Вәлишин 1863 елда Себергә сөрелә. Ревизия документының титул битендә бу ике сословие татарлары «башкорт» дип язылган[423], чөнки 1855 елдан «типтәр»ләрне «Башкорт» гаскәренә кушалар.

Типтәр сословиесендәге татарларны «башкорт» дип яза башлау Самара губернасы буенча белешмә китапларда да чагыла. Шуларның иң беренчесендә (1859 ел) Сәпәйдә 421 ир-ат һәм 457 хатын-кыз (130 хуҗалык) «башкорт» һәм казна (дәүләт) крестьяннары күрсәтелә[424]. Бу чыганак «башкорт» санала башлаган «типтәр»ләрне аерым күрсәтүне кирәк тапмаган.

Сәпәй авылы буенча сословиеләрне санап үткәндә, күпчелекне тәшкил иткән казна (дәүләт) крестьяннарын (элеккеге ясаклы татарларны) – иң башта, аннан соң гына «типтәр» һәм «башкорт»ларны атарга кирәк. Кайбер әдәбиятта моңа җитди игътибар бирелми, беренче итеп аз санлы «башкорт»ларны язалар.

1859 елда Сәпәйдә элеккечә бер мәчет була, базар эшли. Җәмигъ мәчеттә озак еллар (1826 елдан алып) имам һәм мөгаллим булып Мөхәммәтәмин Мөстәкыймов хезмәт итә. Аның улы Мөхәммәтшәриф тә 1853 елдан имам-хатыйп һәм мөгаллим вазифасын башкара[425].

Авылда җир соңгы ревизия (1858 ел) вакытында теркәлгән ир-ат (410) саныннан чыгып һәм сословиене күз алдында тотып, дәүләт крестьяннарына (элеккеге ясаклы татарлар хәзер шулай йөртелә) һәм «типтәр»ләргә җан башына 6,9 дисәтинә, «башкорт»ларга 15 дисәтинә исәбеннән бүленә.

1885 ел ахыры – 1886 ел башында Сәпәй Азнакай волостенда зур авыллардан санала. Анда 219 хуҗалыкта 524 ир-ат һәм 503 хатын-кыз яши. Бу күрсәткечләр буенча ул Азнакай белән Әсәйдән генә калыша.

Авылда 199 хуҗалыкның – имана, ике хуҗалыкның сатып алган җир участоклары була. Моннан тыш, күп кенә хуҗалыклар җирне (барлыгы 819,2 дисәтинә) арендага алганнар. Әлбәттә, чәчүлекләр мәйданы хуҗалыкларга һәм сословиеләргә карап шактый аерылган.

Авыл халкы бик күп мал-туар (567 ат, 527 мөгезле эре терлек, 1026 сарык һәм 287 кәҗә) асрый. 19 хуҗалыкта 107 баш умарта да була, 3 кеше лавка тота. Сәпәйдә кайбер хуҗалыкларның (барлыгы 28) йортлары юк. Моның

---

[423] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 757 сакл. бер., 57–75 б.

[424] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

[425] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35; БР МА, И–295 фонд, 3 тасв., 5662 сакл. бер.

сәбәбе – әледән-әле булып торган янгыннар. Шуның аркасында 1875–1885 еллар эчендә 50 хуҗалык зыян күрә[426].

1889 елда Сәпәйдә 222 хуҗалыкта 1183 кеше исәпләнә. Ни сәбәпледер, 2 мәчет күрсәтелә, чынлыкта исә берәү генә була. Һәр дүшәмбе базарлар уздырылган.

Билгеле булганча, земстволар медицина хезмәтен оештыру буенча зур эш башкаралар. Сәпәйдә 80 нче елларда авыруларны кабул итү бүлмәсе (приемный покой) ачыла, аңа табиб билгеләнә. Ул берничә волостька – хәзерге Азнакай районы чаклы зур территориягә – хезмәт күрсәтә. Аннан башка, авылда бишенче участок урядникгы да яши. Уңайлы җирләр 3059 дисәтинә, эшкәртергә яраксызлары (чокыр-чакыр, ташлы урыннар һ.б.) 113 дисәтинә тәшкил итә[427].

Гасыр ахырына (1897 ел) Сәпәйдә хуҗалыклар саны шактый арта. Анда 254 хуҗалык булып, 705 ир-ат һәм 687 хатын-кыз яши. Ир балалар өчен мәчет каршында мәктәп эшли[428].

Татарстан дәүләт архивында саклanучы хуҗалыклар исәбен алу документлары авылның 1900 елгы социаль-икътисади торышын тулырак кузалларга ярдәм итә. Беренче чиратта, бу чорда хезмәт иткән дин әһелләре турында мәгълүматлар биреп үтик.

Муллаларның өлкәне – Мөхәммәтгариф Мөхәммәтдәминов (55 яшь). Ул улы (19) һәм ике хатыны (45 һәм 20 яшьләрдә) белән тора. Аның хуҗалыгында 9 эш аты, 19 мөгезле эре терлеге (шул исәптән 10 сыер), 30 сарыгы һәм 8 кәҗәсе була.

Мөхәммәтгариф хәзрәтнең имана җире зур түгел, шунлыктан ул шактый җирне арендага ала. Аның бер зур җир участогы Чәкән волостенда, Шәрәфетдин Ярмәков хуторы янында була. Әлеге җир аңа икенче хатынын алганда бирнә итеп бирелгән. Мулла ике хезмәтче тоткан, моннан башка, кыр эшләре вакытында берничә айга ике эшче һәм көнлекчеләр яллаган.

Икенче указлы мулла – Мөхәммәтшакир Мөхәммәтдәминов (48 яшь) – югарыда күрсәтелгән Мөхәммәтгариф хәзрәтнең туганы булса кирәк. Аның гаиләсе зур, өстәвенә, өйләнгән 2 улы да атасы хуҗалыгында яши. Өлкән улы Мөхәммәтсафа (аңа 27 яшь) – мөәзин. Мөхәммәтшакир хәзрәтнең дә хуҗалыгы бай, әмма Мөхәммәтгарифныкы чаклы ук зур түгел. Бер хезмәтчесе була.

Әлеге муллалар укыту белән шөгыльләнгәнме, билгесез. Әмма авылда укытучылар була. Шуларның берсе – Вәлиулла Галиев (35 яшь). Ир балаларга көз-кыш (барысы 5 ай) сабак биргән. Хатыны кызларны укыткан. Укыту-

[426] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 10–17.

[427] Список населенных мест Самарской губернии по сведениям 1889 г. Самара, 1890. С. 59.

[428] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 111–112.

чылык белән шулай ук Әхмәтхан Әхмәтҗановның анасы (75 яшь) һәм улы (25 яшь) да шөгыльләнә. Хезмәте өчен балаларның ата-аналары үз хуҗалыкларында җитештерелгән азык-төлек (ипи, йомырка һәм башкалар) белән түләгәннәр. Әлеге гаиләләрнең иманалары һәм мал-туарлары бик аз була.

Авылда атна саен базарлар үткәрелү сәүдә эшчәнлеге үсүгә китерә. Сәпәй базары – төбәктә зур һәм киң билгеле базарларның берсе. Монда кемнәр генә килми дә, сәүдә итми. Сәүдә итүчеләр арасында, билгеле, Сәпәй кешеләре дә күп була. Аларның берничәсенә тукталып үтик.

Садретдин Мөхәмммәтшәрипов (55 яшь) бакалея тауарлары белән сәүдә итә, лавка тота. Зур хуҗалыгында күп эшләрне ике хезмәтчесе башкара.

Галим Габделхәкимов (60 яшь) калач пешереп сату белән даими шөгыльләнгән. Бу эштә хатыны (50) ярдәм иткән. Хуҗалыгы зур түгел: 1 эш аты, 2 сарык, 3,70 дисәтинә чәчүлекләр.

Калач белән сәүдә итү шулай ук Габделмәннан Габделвахитовның (38 яшь) да даими шөгыле санала. Хуҗалыгы Г. Габделхәкимовныкыннан әлләни аерылмый.

Мөхәмммәтгариф Зарипов (43 яшь) ярминкәләрдә һәм базарларда чәй, шикәр һәм икмәк сату белән даими шөгыльләнгән. Хатыны (40), 4 улы һәм 2 кызы белән яши. Хуҗалыгы зур, шуңа күрә бер хезмәтче тота.

Икмәк сәүдәсе белән тагын Мөхәмммәтша Мөхәммәдьяров (73 яшь) шөгыльләнә. Өлкән улы (33 яшь) белән моннан икмәк сатып алып, аны югарырак бәягә якын-тирәдәге ярминкәләрдә һәм базарларда сата торган булган. Улы үз гаиләсе белән атасы хуҗалыгында яши.

Мөхәмммәтшаның хуҗалыгы зур. 15 ат, 22 мөгезле эре терлек, 35 сарык һәм 4 кәҗә асрый. Иманасында, сатып һәм арендага алган басуларында чәчүлекләре 20 дисәтинәдән арта. Сатып алган җир участогы зур – 46,25 дисәтинә, хуҗалыгында бер хезмәтчесе була.

Идиятулла Галиуллин (38 яшь) көз һәм кыш айларында тимер-томыр әйберләр һәм савыт-саба белән ярминкәләрдә һәм базарларда сәүдә иткән. Бу шөгыле аның шактый вакытын алган, күрәсең, зур булмаган хуҗалыгында бер хезмәтче тота.

Госман Ибраһимов һәм Сәгыйтдин Низаметдиновлар чүлмәкләр сатканнар. Гали Госманов, Ш. Мөхәмммәтгалиевләр күн-тире белән сәүдә итә.

Ул чордагы Сәпәй базарында төрле тауарларны йөреп сатучыларны (асламчыларны) да күрергә мөмкин. Әлбәттә, алар арасында җирле халык вәкилләре дә була. Мәсәлән, Мөхәмммәтша Вилданов (38 яшь). Ул асламчылыкта ел буена диярлек (10 ай) йөргән.

Авылда һөнәрчелек зур урын тоткан. Шәрип Сөләйманов һәм читтән килеп монда яшәүче Иван Карабанов – тимерчеләр. Шәмсетдин Галиәкбәров күннән каешлар эшләгән, бу һөнәр белән ел буена шөгыльләнгән. Мөхәмммәтвәли Исламголов – итекче, Габделгани Гафаров, Мөхәмммәтшәриф Мөхәмммәтшәфиков һәм Гарифулла Галиевлар – тегүче. Соңгысының тегү машинасы

булган. Монда яшәүче Оренбург шәһәре мещаны Габдрахман Габделлатыйпов ел буена диярлек (11 ай) чабаталар (атнага 10 пар) үргән. Авылда берничә хуҗалык, мәсәлән, Камалетдин Мөхәммәтгалиев, күпләп йон тетү белән шөгыльләнә.

Югарыда кайбер хуҗалыкларның зур булуын билгеләп үткән идек. Мондый хуҗалыклар Сәпәйдә тагын була. Алар арасында Шәйхетдин Шәрәфетдинов (49 яшь) хуҗалыгы аерылып тора. Ул 28 ат, 12 мөгезле эре терлек, 100 сарык һәм 4 кәҗә асрый, 30 дисәтинәдән артык мәйданда иген игә. Ике хезмәтчесе була.

Фәрхетдин Сәйфетдиновның (37 яшь) да хуҗалыгы зур. Ул 9 ат, 35 мөгезле эре терлек, 29 сарык һәм 2 кәҗә тота, үзенең имана җирендә һәм байтак кешеләрдән арендага алган басуларда иген игә. Хуҗалыгында күп эшләрне хезмәтчесе башкара.

Ул чордагы авыл старостасы – Фәхретдин Низаметдинов (53 яшь). Хатыны (25), 4 улы һәм 3 кызы белән авылның «типтәр» ягында яши. 9,86 дисәтинә иманасына арыш, бодай, солы, борай һәм борчак чәчкән. 2 эш аты, 3 сыер, 4 сарык һәм 3 кәҗә асрый[429].

1907 елның көзендә Сәпәй халкы икенче җәмигъ мәчет салырга рөхсәт ала. Төзелеш эшләре озакка сузыла, ахры, 1910 елда гына хатыйп итеп Миргалим Мөхәммәтгариф улы Мөстәкыймов раслана. Тагын бер елдан туганы Миргали Мөстәкыймов мөәзин һәм мөгаллим вазифасын үтәргә керешә. Икенче имам булып 1916 елдан Әхмәтриза (?) Мәхмүтов хезмәт итә[430].

1910 елда Сәпәйдә 311 хуҗалык, 783 ир-ат һәм 762 хатын-кыз исәпләнә. 2 мәчетле, мәктәпле һәм базарлы авыл ул. Элеккегечә анда елга бер тапкыр ярминкә уздырыла. Сәүдәгәр Хәлфиннар (Теләнчетамактан), мулла Сәетбаттал Сәмигуллин (Кәкре Елгадан) һәм Евстафий бай монда зур күләмле тауар складлары, икмәк саклагычлары (амбарлар) булдыралар.

1913 елда земство шифаханәсе ачыла. Моңа чаклы авыруларны кабул итү бүлмәсе һәм бер табиб кына бар иде. Шифаханә төзелгәч, медицина хезмәткәрләре саны да арттырыла.

Кайбер хуҗалыкларда ат белән сугу машинасы (Якуп Йосыпов), урак машиналары (Миргалим Мөстәкыймов һәм Х. Гаффаров) күренә башлый. Алар кыйммәт торганлыктан, бай хуҗалыклар гына сатып ала алган.

1914 елның май ахырында Зәки Гыйльфановның авыл уртасындагы йортыннан ут чыгып, бик күп йорт, каралты-куралар яна. Көн бик кызу, ураза ае була. Өстәвенә, кешеләр кырда чак. Янгынны күреп, кайсысы атка атланып, кайсылары арбага төялеп, авылга чабалар һәм көч-хәл белән сүндерәләр.

Озак та үтми төбәккә, герман сугыш башлаган дигән, хәбәр килә. Авыл старостасы халыкны янгын каланчасы янына җыеп, мобилизовать ителү-

[429] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 25, 27 сакл. бер.

[430] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер., 158 б. а., 159 б.

չеләрнең исемлеген укый. Аннан соң базар урамыннан олауларга төялгән 20–30 лап ир-атны халык, тәкъбир әйтә-әйтә, елый-елый, сугышка озата. Менә шулай, озакка сузылган, авыл өчен гаять авыр булган сугыш чоры башлана.

Сугыш ихтыяҗлары өчен авылдан яхшы атларны алалар, сыер-сарыклар җыялар. Ир-атсыз калган хуҗалыкларга җир эшкәртү бик авырая, шуның аркасында күпчелек җирләр буш калып, аларны чүп баса. Авылга әледән-әле һәлак булучылар һәм әсир төшүчеләр турында хәбәрләр килеп тора. Менә шундый шартларда авыл хуҗалыклары исәбен алу үткәрелә. Сәпәйдә 1916 елда 330 хуҗалык, 724 ир-ат һәм 919 хатын-кыз теркәлә[431]. Күргәнебезчә, ир-атлар хатын-кызларга караганда күпкә аз.


Особое совѣщаніе для обсужденія и объединенія мѣропріятій по продовольственному дѣлу.

ВСЕРОССІЙСКАЯ СЕЛЬСКОХОЗЯЙСТВЕННАЯ ПЕРЕПИСЬ 1916 ГОДА.

Губернія / область: Самарск. Уѣздъ / округъ: Бугульминск.

Волость / станица и пр.: Азнакаевск. Общество (сельское, поселковое, аульное и пр.).

Селеніе / выселокъ, аулъ, улусъ, имѣніе и проч.: Сапеево

Фамилія, имя и отчество домохозяина

Сословіе или разрядъ крестьянъ: Башкир. Національность: татарин

Приписной, посторонній, бѣженецъ. (*Подчеркнуть*).

№ по списку домохозяевъ: 140

Имѣется въ польз… Единицъ (душъ и т. п.) надѣла. ПАШНИ: Десятинъ. Своей надѣльн. Своей купчей. Арендованной.

Итого посѣяно на всѣхъ земляхъ. Своихъ надѣльныхъ. Арендованныхъ надѣльныхъ. Арендованныхъ внѣнадѣльныхъ. Своихъ купчих.

Посѣвъ 1916 года. На земляхъ: Свекловица сахарная. Хлопокъ. Рисъ.

Скотъ въ 1916 году (во время переписи). Скотъ въ 1915 году (годъ назадъ). Лошадей. Крупнаго рогатаго скота. Мелкаго скота. Свиней.

*1916 елгы хуҗалыклар санын алу документы.*
*Сословиесе башкорт, милләте – татар дип язылган*

Советлар хакимияте урнашкач, Сәпәйдә авыл башкарма комитеты оештырыла. 1918 елның декабрендә Габдрахман Вахитовның авыл комиссары, Хәмзә Шахиевның авыл советы әгъзасы булып торуы мәгълүм. Бу чорда мондагы бер мең кешенең сайлау-сайлану хокукы була[432].

1920 елда халык санын алганда Сәпәйдә 349 хуҗалыкта 1698 кеше яши. Тагын алты елдан бу күрсәткеч күпкә кими: 269 хуҗалык һәм 1242 кеше торып кала[433]. Моның төп сәбәбе – 1921 елгы ачлык, икенчесе исә – халыкның бер өлеше Мачаклыбаш һәм Зирекле Елга поселокларына күченүе.

[431] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 38 сакл. бер.
[432] Шунда ук, Р–1167 фонд, 1 тасв., 160 сакл. бер., 793 б. а.–794 б.
[433] Шунда ук, Р–1296 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 3 сакл. бер.

Мачаклыбашта 1926 елда 90 кешедән торган 18 хуҗалык була. Соңрак «Җитез» исемле колхоз оеша. Аннары авыл озак еллар «Марат» колхозына керә, ә 1971 елдан «Кызыл Байрак»ка кушыла.

Зирекле Елгада 1922 елда 33 хуҗалык исәпләнә. Шул елның 12 апрелендә аның халкы җәмигъ мәчет салырга рөхсәт ала. Миргали Мөхәммәтшакир улы Мөстәкыймовны мөәзин итеп сайлыйлар. Монда 1960 елга кадәр «Зирекле Елга» колхозы эшли, аннары аны Сәпәйнең «Кызыл Байрак» күмәк хуҗалыгына кушалар.

1929–30 елларда сәпәйлеләр колхозга берләшәләр, аңа «Кызыл Байрак» дигән исем бирелә. 1930 елның 24 мартында колхозның беренче уставы кабул ителә, Сәяф Касыймов – рәис, Мәгъсүм Гарипов хисапчы итеп сайлана. Утызынчы-кырыгынчы елларда колхоз рәисе булып Харрас Хаббанов, Нурисафа Миргалиева, Зәйдулла Хәбибуллин, Мөхәммәтҗан Шакиров, Хәтим Нәбиуллин, Хуҗа Минһаҗевлар эшли. 1931 елда – беренче трактор, өч елдан беренче автомашина кайта. Әхмәтгали Сәлимгәрәев, Галәм Талибуллина, Вәсби Хәертдинова, Гариф Зарипов, Сафа Шәриповлар – тракторчылар, Сәет Асылов, Сафуан Нурмөхәммәтовлар шоферлар курсында укып кайталар.

Сугыш алды елларында колхоз районда алдынгылардан санала. Терлекчелек фермалары, кыр станнары төзелә. Клуб, уку йорты, шифаханә зурайтыла, яңа амбарлар салына.

Сугышка бик күп ир-ат алына, аның икенче елында авылда хезмәткә яраклы өч йөзләп кенә кеше кала, аларның да иллесен завод-фабрикаларга эшкә алалар. Сугыштан соңгы елларда колхозда яшелчә-җимеш үстерүгә дә зур игътибар бирелә.

Илленче елларда колхоз белән Әхмәтгали Сәлимгәрәев, Заһидулла Краснов, Гарәф Шәрәфетдиновлар җитәкчелек итә. Гарәф Низаметдин улы авылга 1955 елда Казаннан җибәрелә; бу чорда ил башлыгы Н. Хрущевның колхозларны ныгыту максатыннан утыз мең җитәкче җибәрү турында күрсәтмәсе була. Ул рәислек иткән чорда колхозның эш күрсәткечләре сизелерлек яхшыра, машина-трактор паркы корыла.

1949 елдан Сәпәй янында нефть разведкасы эшләре башлана, нефтьчеләр бу авылда торып эшлиләр. 1952 елда Зирекле Елга авылыннан бер чакрым көнбатышта районда беренче нефть вышкасы куела, нефть чыгарыла башлый.

1956–1957 елларда авыл тулысынча электрлаштырыла, су насосы станциясе төзелә (Әгер ягындагы тау артында). Нефтьчеләргә беренче унбер йорт салына (1957), авыл басуларында тоташ бораулау башлана, күп санда нефть вышкалары утыртыла.

1961–1969 елларда «Кызыл байрак» колхозы рәисе булып Салиха Хәмидуллина, аннары озак еллар Термос Рахманколов эшли. 1964 елда авылда сигезъеллык мәктәп бинасы төзелә башлый, аның директоры Әслах Кашапов була. Авылдан унлап кеше орденнар (шофер Миргазиз Хәбибуллин, тракторчы Гариф Мөхәммәтшин, шофер Марс Солтанов, комбайнчы Нәфис Закиров, шофер Ирек Сәлимгәрәев) һәм медальләр (Хәтирә Госманова, Әсма Хөснет-

динова, Рәзинә Гәрәева, Гөлсинә Гәрәева) белән бүләкләнә. 1975 елда административ бинага нигез салына, өч елдан 50 балага исәпләнгән яңа ясле бинасы ачыла. Ашлык склады, сыер, ат тораклары һәм башка каралтылар төзелә.

Хәзерге вакытта авылда биш йөз иллеләп кеше яши, урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, фельдшерлык-акушерлык пункты, балалар бакчасы, почта бүлекчәсе һәм кибет була. Мондагы «Кызыл байрак» күмәк хуҗалыгы игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә.

Бу язма тулаем әзер булып берничә ел үткәч, «Татарстан» журналында (1997 ел, 5 нче сан) Миргасыйм Касыймовның Сәпәй авылы тарихына багышланган язмасы дөнья күрде. Анда авылның 1917 елга чаклы тормышы тасвирлана. Архив чыганакларын җитәрлек өйрәнмәгәнлектән, автор авылның барлыкка килү тарихын дәлилле яктырта алмаган. Шулай да XIX һәм XX гасырлар буенча Миргасыйм ага шактый кызыклы мәгълүматлар бирә, аларны авыл тарихын китап итеп язганда кулланырга мөмкин. Үз авылы тарихын язуга өлеш керткән мөхтәрәм зат мактауга лаек.

Моннан алдарак шул ук журналда (1996 ел, 9 нчы сан) Дамир Асыловның Сәпәйнең үткәнен һәм атамаларын тасвирлаучы «Урман язмышы» исемле зур язмасы басылган иде. КПСС Үзәк Комитеты беренче секретаре, СССР Министрлар Советы рәисе Никита Сергеевич Хрущев белән бәйле атама («Хрущев урманы») тарихы киң яктыртыла анда. Илбашы 1964 елда төбәккә килеп киткәндә, «Күкчәчкә атавында» да булган, шуннан кайчандыр гаҗәеп матур бу урынга әлеге ят исемябышып калган икән. Автор язмасын түбәндәге сүзләр белән тәмамлый: «Бу көннәргә инде утыз ике ел үткән. Күкчәчкә атавына «Хрущев урманы» исеме дегет кебек сыланып калды. Өстәвенә кемнәрнеңдер тырышлыгы белән олы юл буена – шул турыга – багана утыртып, «Хрущевский лес», «Хрущев урманы» дип язып такта да беркеткәннәр. Хикмәт, әй, урманның исеме белән бергә төсе дә үзгәрде. Урманның теге вакыттагы яме киткән. Аланнарга нарат утыртканнар. Җиләклекләр, җимешлекләр юкка чыккан. Нарат урманы, бигрәк тә яшь наратлык караңгы бит ул, шунлыктан «Күкчәчкә атавы» элекке сыман яктылык сирпеп, балкып, үзенә чакырып тормый. Һәрхәлдә, җыр да, шигырь дә тудыра алмый күңелдә «Хрущев урманы». Чит исем! Ят исем! Килмешәк исем! Ул авылның үзенчәлекле биографиясендә тилчә кебек тора».

Өстәп шуны әйтергә кирәк, «Күкчәчкә атавы» кебек атамалар бөтенләй онытылганчы, китап-язмаларда теркәлсен иде. Атамалар дөньясы үзе генә дә үзенчәлекле тарихыбыз һәм мирасыбыз ул безнең[434].

---

[434] Авыл тарихы 1996–1997 елларда язылды. Соңрак кайбер чыганакларга таянып, бер өлешен яңадан анализлап, авылның башлангыч чорына җитди үзгәрешләр кертергә мәҗбүр булдым. Сәпәйнең дүрт сословиегә караган (типтәр, башкорт, ясаклы һәм йомышлы татарлар) татарлары буенча ревизия документларын тулырак кулландым. Текстның 1859 елдан соңгы чорны колачлаган өлеше шул килеш калды диярлек.

## § 15. Тымытык

Төбәкнең Ык буе авыллары арасында Тымытык – иң зурысы һәм тирән тарихлысыдыр, мөгаен. Заманында берничә дистә ел район үзәге булып торган, исеме җырларга кергән авыл ул.

Тымытыкның барлыкка килү тарихы шактый үзенчәлекле. Башкортстан Милли архивында саклanучы 1840 елгы документта авылда яшәүче ике төп татар сословиеләре – типтәрләр һәм башкортлар – телгә алына. Беренчеләре турында 150 ел элек биләмәчеләр (вотчинниклар) рөхсәте белән килешү төземичә килеп утырдылар (чыганакта «тептяри припущены башкирами-вотчинниками без всяких договоров более 150 лет»), дип әйтелә[435]. Димәк, 1840 елда 87 ир-аттан торган «типтәр»ләрнең ерак бабалары төбәккә XVII гасыр ахырында килгәннәр.

«Типтәр»ләрнең кайчан күчеп килүен ачыкладык, ә менә «башкорт» дип аталучы татарлар монда кайчаннан яши башлаган соң? Бу сорауга җавап бирмичә, авылга кемнәр һәм кайчан нигез салганын тәгаен әйтеп булмас иде.

Татарстан дәүләт архивында саклanучы 1900 елгы документлар моңа ачыклык кертә. Алар монда яшәүче «типтәр»ләрнең һәм ясаклы татарларның 200 ел чамасы элек күчеп утыруын күрсәтәләр. Бу XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башларына туры килә. Шунысына игътибар итик, «типтәр»ләр хакындагы документта, «первоначально поселились тептяри на башкирской земле, а потом припущенники» дигән юллар була. Беренче килеп утыручылар, шулай итеп, «типтәр»ләр булган.

Шунда ук тагын бер документ саклана. Монысында 170 ел элек 16 «башкорт» хуҗалыгы Уфа губернасыннан, ягъни Ыкның уң ягыннан, үз җирләренә (ул җирләр турында алга таба сүз кузгатырбыз) күчеп утырдылар дип әйтелә[436]. Димәк, әлеге сословие кешеләре авылда якынча 1730 елдан яши башлаганнар.

Шулай итеп, Тымытыкка XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башларында «типтәр»ләр нигез сала, ә башка сословие кешеләре исә алардан бераз соңрак күчеп киләләр.

Тымытык урта мәктәбендә саклanучы авыл тарихына багышланган кулъязмада шундый юллар бар: «Авыл, хәзерге урынга төпләнгәнче, ике нигез алыштыра. Башта ул Ык елгасының уң як ярында, «Кызыл тау» дип аталган урында урнаша. Бераздан «Иске йорт» дигән урынга күчә. Бу урын Ык елгасын буган плотина тирәсендәге Башкортстан җиренә урнашкан». Авылның урыны алышыну белән бәйле истәлек кайбер картлар хәтерендә бүгенгечә саклана. Алар сөйләвенчә, иске урыннан китүнең төп сәбәбе – Ык елгасы ташыганда әледән-әле су басулар.

[435] БР МА, И–2 ф., 1 тасв., 4619 сакл. бер.
[436] ТР ДА, 993 ф., 1 тасв., 883 сакл. бер.

Документларга мөрәҗәгать итсәк, Ык елгасының уң ягындагы зур гына мәйданда, чыннан да, авылның имана җирләре булуын күрәбез. Ә менә авылның элегрәк «Кызыл тау» я булмаса «Иске йорт» дигән җирдә урнашканлыгын дәлилләүче нинди дә булса тарихи чыганакның әлеге чаклы очраганы юк. «Очерки по истории Башкирской АССР» (Уфа, 1956) исемле китапның беренче томында бирелгән картада авыл Ык елгасының сул ярында күрсәтелә. Картаны И.А. Голубцов 1730–1750 елгы мәгълүматларга таянып төзегән.

Мул сулы Ык елгасы күп гасырлар дәвамында җирле халык тормышында зур роль уйнаган. Монда алар балыкчылык белән шөгыльләнгәннәр, тегермән тотканнар. Җәйләрен елга буендагы киң болыннарда печән чапканнар, урманнарда җиләк-җимеш җыйганнар, җәнлек аулаганнар, утын һәм төзелеш өчен агач әзерләгәннәр. Зур тегермәннәр янында, гадәттә, тегермәнчеләрнең йортлары, складлары булган. «Иске йорт» дигән атама шуннан килеп чыкмадымы икән?

«Иске йорт» дип аталган урында дистәдән артык хуҗалык яшәгән булуы да мөмкин. Чөнки Тымытыкка 1730 ел тирәсендә 16 «башкорт» хуҗалыгы күчеп утыруы турында язмабыз башында әйтелгән иде. Алар элгәре шул «Иске йорт» дигән урында яшәгән һәм әлеге атама шуның истәлеге булып калган дип фараз кылу да дөрес булыр кебек.

Авылның исеме «тымызык» дигән сүздән алынган. Төбәктә электән үк шундый атамалы күл булуы хакында кулъязма авыл тарихында әйтелә (XIX гасыр башларында да ул күл булган, бу хакта шул чор документларыннан беләбез). Ул күл тыныч, ягъни тымызык булган. Шул тирәдә барлыкка килгән яңа авылның күл исеме белән атала башлавы гаҗәп түгел. Ә менә «Тымызык» ничек «Тымытык»ка әйләнгән соң?

Билгеле булганча, Минзәлә диалектында «з» авазы урынына еш кына «д» авазы кулланыла. Ә «д» авазының күп очракларда саңгырау «т» тартыгына әйләнүе бу диалектның гына түгел, гомумән татар теленең архаик үзенчәлеге. Мәсәлән, борынгы татар әсәрләрендә («Нәһҗ-әл-фәрадис», «Нәсыйхәт-әс-Салихин» һәм башкаларда) «д» урынына «т» кулланылган[437]. Телнең шушы үзенчәлекләрен искә алсак, «Тымызыкның» «Тымыдыкка», аннары «Тымытыкка» әйләнүе гаҗәп тоелмас.

Тымытык авылының башкорт сословиесендәге татарлары беренче тапкыр 1744 елның 1 июнендә төзелгән килешүдә телгә алына. Биләмәчеләр Юлдаш Акчирмешов, Морзай Илкәев, Мостафа Купкасов үзләренең иптәшләре белән Юрмый олысы халкы ризалыгын алып, буш яткан җирләренә Казан өязе Мәлкән авылының яңа чукынган татарларына 10 хуҗалык булдырып

[437] Материалы по диалектологии. Казань, 1955. С. 185–187.

килеп утырырга рөхсәт итәләр. 1750 елда шул ук җирләр аларга озак срокка (25 ел) һәр ел 10 сум оброк түләп бару шарты белән бирелә[438].

Тымытык авылы кешеләренең Е. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышында катнашуы хакында мәгълүматларның әлегә чаклы очраганы юк. Тирә-як авыллар катнашканда, Тымытык читтә калмагандыр, әлбәттә. Якындагы Бакалы һәм Нугайбәк крепостьлары янында хөкүмәт гаскәрләре белән фетнәчеләр арасында канлы бәрелешләр була ул чакта.

1773 елда Юрмый олысы халкы Нугайбәк крепостенда яшәүче отставкадагы канцелярист А.М. Островскийга 250 сумга Ык елгасы тирәсеннән шактый зур мәйдандагы җирләрен сата. Документта ул җирләрнең чиге түбәндәгечә күрсәтелә: «*...верхняя межа по течению Ику реки по правую сторону Мосей враг, называемой лог, по тому логу по левую сторону прямо на Чугорышевской ключ, а от того на лесной мыс, а с него прямо до чернаго лесу; нижнея межа по течению вышеписанной же реки Ику по правую сторону, взяв от верхней межи, называемаго Мусей враг, нанизв на речку устье Кала-илгу, а от оной речки Кала-илги увалом, не захватывая только против деревни Рысаевой (Урсай. – Т.К.) сенных покосов, прямо на грань Нагайбацкой крепости, которая состоит на горе Камышлы-таве, а от оной по граням той же крепости до чернаго ж лесу; а на левой стороне по течению вышеупомянуемой реки Ику сенныя покосы, верхняя межа от называемаго Кара-Яру на Алексеевской альшняк на нижней мыс, а от него прямо на большую проезжую от деревни* ***Тумутуковой*** *к Нагайбацкой крепости дорогу, и по оной дороге до Сухояшевской дороги ж, лежащей на Калаилгинской перевоз, и по той дороге на усть речку Кала-илгу и на тот перевоз, с усадьбою и пахотною землею, и по тем межам с лесными и с сенными покосами, с рыбными ловли, хмелевым щипанием, звериными гоны*»[439].

Югарыда китерелгән өземтәдән күренгәнчә, Тымытыктан Нугайбәккә кадәрле Ыкның сул һәм уң ягындагы шактый җирләр яңа хуҗа кулына күчә. Әлеге җирләрдә соңрак урыс авыллары һәм хуторлары барлыкка килә. Документтан аңлашылганча, Тымытык Ык елгасының сул ягында урнашкан һәм аннан ерак түгел Кара Яр дигән урын да булган. Шулай итеп, XVIII гасыр дәвамында Тымытыкны һәрвакыт үзенең хәзерге урынында күрәбез.

Җир сатучылар шул ук документта үзләренең биләмәләре хакында «жалованную прадедам, дедам и отцам нашим по грамотам землю» дип әйтәләр. Димәк, әлеге җирләр Юрмый олысы халкына патша грамотасы нигезендә чама белән йөз ел элек (һәр буын арасын 25–30 ел дип алганда), ягъни XVII гасырның икенче яртысында бирелгән булган.

Әйтергә кирәк, А.М. Островский җирне бик арзан бәягә сатып алган. Ул җир сатучыларның тәҗрибәсезлегеннән, я булмаса акчага артык мохтаҗлы-

[438] МИБ. Т. 3. М., 1949. С. 479–480.
[439] МИБ. Т. 4. Ч. I. М., 1956. С. 376–377.

гыннан оста файдаланган, күрәсең. Һәм бер ел да үтми, нибары 250 сумга сатып алынган биләмәсен ул икенче берәүгә шома гына 1000 сумга сата[440].

Күренгәнчә, бу алыш-биреш аңа шактый зур табыш китергән. Җирнең яңа хуҗасы отставкадагы капитан И.И. Рушинский төп өлеше кара туфрактан торган бу уңдырышлы җирләрне үз чиратында башкаларга сатып тагын да зуррак табыш алып буласын башта ук чамалаган, дип уйларга кирәк. Менә шулай әлеге җирләр 1917 елга чаклы берничә тапкыр алыш-биреш объектына әйләнә.



*Тымытыкның типтәр сословиесендәге татарлары теркәлгән 1795 елгы ревизия документы фрагменты. Чыганакта **«деревни Тумутук тептери и бобыли татара»** дип язып, «типтәр»ләрнең милләте татар булуын күрсәткәннәр*

XVIII гасырның икенче яртысында Юрмый олысының старшинасы булып күпмедер вакыт Хасбулат Мөтеков тора, аннары аны Биккенә Яушев алыштыра. Алардан башка олысның дәрәҗәле кешеләре исемлегендә Нугайбәк Хәсәнов, Исмәгыйль Биккенин, Мөстәкыйм Мөслимов, Тимер Морзаев, Ибрай Әлкиев, Гайсар Яркәев, Зыяш Юлдашов, Абзай Сөләймәнов, Биккол Мөслимов һәм Ягъфәр Мөтековларны күрергә була. Аларның байтагы Пугачев явында катнаша. Исмәгыйль Биккенин отряд белән җитәкчелек итә. Бу отрядта Биккол

[440] МИБ. Т. 5. М., 1960. С. 29–30.

Мөслимов йөзбашы була. Нугайбәк Хәсәнов авылдашлары (ул үзе Чалпыдан) белән Нугайбәк крепостен, аннары Зәй каласын алуда катнаша[441].

XVIII гасырның икенче яртысында авыл халкы дүрт сословиедән – типтәр, башкорт, ясаклы һәм йомышлы («служилый») татарлардан торган. 1795 елда монда 50 хуҗалык исәпләнә. Халыкның төп өлешен «типтәр»ләр (53 ир-ат һәм 39 хатын-кыз)[442], йомышлы татарлар (43 һәм 44)[443], «башкорт»лар (42 һәм 46), калганын ясаклы татарлар (16 һәм 9)[444] тәшкил итә.

«Типтәр» Тимеркәй Уразгилдин христиан диненә күчеп, Нугайбәк крепостена күчеп утырырга мәҗбүр була[445]. Әлеге һәм башка фактлар Нугайбәк керәшеннәре формалашуда тирә-як авылларның роле турында сөйли.

Югарыда санап үтелгән төп катлаулар («типтәр», «башкорт», ясаклы татарлар), кайбер үзгәрешләр белән, 1917 елга чаклы күзәтелә. Татарстан дәүләт архивында саклануы халык санын алу документларында бу өч сословие кешеләренең милләте татар дип күрсәтелә. Ясаклы татарлар халык телендә «казан татарлары» дип йөртелгән. Кантон системасына үзгәрешләр кертелгәнче (1855 ел) Тымытык «башкорт»лары – 12 нче башкорт кантонында, «типтәр»ләр исә Бөгелмә өязенең 5 нче типтәр командасында күрсәтелә.

XIX гасырның беренче чирегенә авыл шактый зурая. 1816 елда анда барысы 4 сословиегә караган 231 ир-ат (65 хуҗалык) татар теркәлә: «башкорт»лар – 92 (17 хуҗалык), «типтәр»ләр – 64 (25), йомышлы татарлар – 60 (16), ясаклы татарлар 15 (7) ир-ат тәшкил итә. «Типтәр»ләр төрле елларга караган килешүләр нигезендә килеп утырганнар. Бер төркеме (24 ир-ат һәм 10 хуҗалык) биләмәчеләргә (вотчинникларга) һәрбер йорттан берьюлы 10 сум түләп яши башлаганнар, икенчесе (26 һәм 9) – ел саен һәрбер йорттан 10 тиен түләү шарты белән, өченчесе (4 һәм 2) – башта һәрберсеннән берьюлы 3 сум биреп, аннары ел саен һәрбер йорттан 10 тиен түләү шарты белән, дүртенчесе (10 һәм 4) – башта һәрберсеннән берьюлы 4 сум биреп, аннары ел саен һәрбер йорттан 10 тиен түләү шарты белән. Йомышлы татарлар (60 ир-ат) башта һәрберсеннән берьюлы 10 сум биреп, аннары ел саен һәрбер йорттан 10 тиен түләү шарты белән килеп утыра[446].

Тымытыкның башкорт сословиесендәге татарлары исемлегендә 1816 елда беренчеләр булып Мәгазь Байгильдин (72 яшь), аның улы Мәскак (38) һәм оныклары Йомагол (9), Морзагол (5), Бурангол (3) һәм Исәнгол (1), икешәр хатынлы Имангол (33) һәм Хисаметдин (31) Миңлеголовлар күрсәтелгән. Башка ике хатынлы ир-атлар исәбенә түбәндәгеләр керә: йөзче (сотник) Яхшыгол

---

[441] Бу кешеләр хакында өстәмә мәгълүматны кара: Вахит Имамов. Татарлар Пугачев явында. Яр-Чаллы, 1994.

[442] БР МА, И–138 ф., 2 тасв., 24 сакл. бер., 408 б.

[443] Шунда ук, 22 сакл. бер., 76–81 б.

[444] Шунда ук, 23 сакл. бер., 103–104 б.

[445] Шунда ук, 24 сакл. бер., 408 б.

[446] Шунда ук, И–1 ф., 1 тасв., 450 сакл бер., 124–124 б. а.

Морзаев[447] (44), Сәмигулла Үтәголов (46), йөзче Идрис Искәндәров (38), Тимәш Мостафин (72), Абиш Юлышев (38), Сәлим Миңлебаев (70) һәм указлы мулла Госман Сәлимов (43). Югарыда телгә алынган йөзче Идрис Искәндәровның атасы буларак Искәндәр Исергәпов (57) теркәлгән. Идристән башка, аның тагын биш улы була: Ильяс (37), Габделмәннаф (34), Гөзәер (20), Җиһанша (12) һәм Гаделша (9)[448]. Сүз уңаеннан әйтик, әлеге Искәндәр Исергәпов һәм аның улы Идрис – Татарстанның дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Равил Хаммат улы Зариповның әтисе яклап ерак бабалары[449].

Тирә-як авыллардагы кебек, Тымытыкта да бер мәчет була. Авыл Тымытык күле һәм тагын исемсез дүрт күл буенда урнашкан[450].

1859 елгы ревизия вакытында Тымытыкта 23 нче кантонның 4 нче юртасына караучы башкорт һәм типтәр сословиесендәге татарлар 359 ир-ат һәм 355 хатын-кыз (55 хуҗалык) тәшкил итә. Соңгылары (142 ир-ат) «типтәрдән башкорт» («башкиры из тептярей» (берсе 1835 елда үз теләге белән казаклыкка языла; чыганакта «поступил в казаки в 1835 году по собственному желанию», дип әйтелә) булып китә. Исемлек ахырында Яңа Кәшердән күчеп утырган Габделкәрим Габделҗәббаров (31) теркәлгән[451].


Ревизская Сказка.
Тысяча восемь сотъ пятьдесятъ девятаго года мая тринадцатаго дня Самарской Губернiи Бугульминскаго уезда 23го Башкирскаго Кантона № 4го Юрты деревни Тымутыковой, [illegible] башкирцахъ [illegible] рахъ изъ Тептярей. —

*Тымытык авылы буенча 1859 елгы ревизия документының титул бите. Аннан күренгәнчә, «типтәр»ләрнең сословиесе үзгәргән, алар «башкорт» (чыганакта «башкиры из тептярей») булып киткәннәр*

[447] Аның туганы Тимер Морзаев Кәкре Елганың 1762 елгы ревизия документында телгә алына (кара: РБАДА, 350 ф., 2 тасв., 3795 сакл. бер., 317 б.).

[448] БР МА, И–138 ф., 2 тасв., 172 сакл. бер., 13 б.а.–19 б.

[449] Равил Хаммат улы Зариповның атасы яклап тулы шәҗәрәсе болай: Исергәп–Искәндәр (1759) – Идрис (1778) – Мөхәммәтшәрип (1838) – Мөхәммәтзарип (03.01.1864) – Мөхәммәтзакир (14.02.1897; хатыны Миңсылу) – Хаммат (20.07.1926; хатыны Сәрвәр Әгъләм кызы) – Равил (20.06.1954), Нурия (1957) һәм Рәзинә (1960).

[450] РБАДА, 1355 ф., 1 тасв., 1874 сакл. бер., 287–289 б.

[451] БР МА, И–138 ф., 2 тасв., 757з. сакл. бер., 83–117 б.

Статистик чыганак 1859 елда 541 ир-ат һәм 537 хатын-кыз (104 хуҗалык) яшәвен күрсәтә. Алар сословиеләре буенча казна крестьяннары һәм «башкорт»лар дип язылган[452]. Шулай итеп, монда «типтәр»ләр бөтенләй телгә алынмый: 1855 елда «Башкорт» гаскәре карамагына күчерелгәнлектән, статистик чыганакларда аларның сословиеләрен дә «башкорт» дип яза башлыйлар.

1859 елда авылда 2 мәчет, 1836 елда ачылган мәдрәсә эшли. Икенче мәхәлләдәге биш вакыт намазлы мәчет 1835 ел алдыннанрак төзелә, монда шул елдан Йосыф Үтәголов мөәзин хезмәтен башкара.

Тагын бер мөәзин – Хисмәтулла Яхшыголов, әлеге вазифага 1836 елдан расланган. Бу дин әһелләре эшләгән чорда имам-хатыйп итеп 1862 елда Шәрәфетдин Галиәкбәров сайлана. Тагын бер елдан имам-хатыйп һәм мөгаллим вазифасына Әхмәтлатыйф Габделлатыйпов указ ала. Икенче мәхәлләдә имам хезмәтен (1865 елдан) Габделҗәмил Габделкасыймов башкара.

Мәчетләр шактый искергән була, шуңа күрә 1871 елда – икенче, 1873 елда беренче мәхәллә мәчетләре яңадан салына[453].

1885 ел ахыры – 1886 ел башында авыл зурлыгы буенча Тымытык олысында беренче урында тора, олыс үзәге санала. Анда барлыгы 335 хуҗалык булып, 926 ир-ат һәм 949 хатын-кыз яши. Сословиеләр буенча авыл халкы дәүләт крестьяннарыннан (йомышлы һәм ясаклы татарлар хәзер шулай атала; 369 ир-ат һәм 360 хатын-кыз), «типтәр»ләрдән (304 һәм 299) һәм «башкорт»лардан (253 һәм 290) тора.

Авыл җәмгыятенең 5339,2 дисәтинә имана җире булган. Ул җирләрнең бер өлеше (806,3 дисәтинә) Ыкның уң ягында, Уфа губернасы Бәләбәй өязе территориясендә урнашкан. Шунысы күзгә ташлана, сословиеләргә карап имана күләме нык аерыла. Иң зур җир, башкалар белән чагыштырганда, азрак санлы «башкорт»ларга (2533,5 дисәтинә) туры килә, ә менә элеккеге ясаклы татарларның (1371,8) һәм «типтәр»ләрнең (1433,9) ул шактый аз.

Шул ук сословиеләр буенча, әмма җан башына бүлгәндә, аерма тагын да сизелерлек арта. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-ат «башкорт»ка – 22,8, «типтәр»гә – 10,6, элеккеге ясаклы татарга 9,4 дисәтинә туры килә. Шулай итеп, «башкорт»ларның җирләре 2,1–2,4 тапкырга күбрәк.

Иманадан тыш, шактый хуҗалыкларның сатып алган биләмәләре дә була. Мондый җирләрнең гомуми мәйданы 2286,8 дисәтинә тәшкил итә. Шунысына игътибар итик, алар барысы да 94 «башкорт» хуҗалыгыныкы. Бу хуҗалыклар арасында аеруча зурларын күрергә мөмкин. Мәсәлән, Тымытыкка башка авылдан күчеп килгән мулланың (фамилиясе күрсәтелмәгән) сатып алган җире 308 дисәтинә тәшкил итә.

[452] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

[453] БР МА, И–295 ф., 3 тасв., 5662 сакл. бер.; 2 тасв., 3 сакл. бер.

Эре, бай хуҗалыкларга караганда, аз җирле, очын-очка ялгап яшәүче хуҗалыклар күбрәк була, әлбәттә. Андыйлар авылдашларыннан яисә башка авыл кешеләреннән арендага җир алырга мәҗбүр булганнар. Үз авылдашларыннан арендага алучылар арасында 9 «типтәр» һәм 37 «казан татары» хуҗалыгын күрәбез. Читтән арендага алучылар да – бу сословие вәкилләре. 57 «типтәр» хуҗалыгы – 224, ә 75 «казан татарлары» хуҗалыгы 403 дисәтинә сөрүлекләрне арендага ала. Печәнлекләр җитмәү сәбәпле, аларны да арендага алучылар була. Арендачылар җир хуҗалары белән гадәттә акчалата исәп-хисап ясый торган булганнар.

Игенчелек һәм терлекчелек – авыл халкының төп шөгыле, аның муллык чыганагы. Тымытыкта җирсез хуҗалыклар чагыштырмача аз (10) була. Авыл халкы күп санда эш атлары (700 баш), мөгезле эре терлек (747), сарык (965) һәм кәҗә (273) тоткан. Әйтергә кирәк, хуҗалыклар буенча мал-туар саны шактый аерылган. Эш атлары, мәсәлән, кайбер хуҗалыкларда (50 хуҗалык) бөтенләй булмый яисә берәр генә (104). Шулай да ике-өч (112 хуҗалык), дүрт (22) һәм дүрттән артык (37) эш аты асраучылар күбрәк була. 38 хуҗалык 175 баш умарта тота.

Игенчелек һәм терлекчелек төп яшәү чыганагы саналса да, кайберәүләргә гаиләләрен туйдыру һәм салым түләү өчен аннан килгән керем генә җитми. Шуңа күрә алар (56 хуҗалык) кыр эшләреннән буш вакытта игенчелеккә бәйле булмаган төрле һөнәрләр белән шөгыльләнгәннәр, өстәмә акча эшләгәннәр. 5 кешенең авылда лавкасы була.

Югарыда күп мал-туар асраган һәм шактый зур җирләре булган хуҗалыклар турында сүз чыккан иде. Мондый хуҗалыкларның бер өлеше (11 е) даими ялланган эшчеләр (15 кеше) тота. Әлбәттә, уңыш җыю чорында аларның басуларында көнлекчеләр дә эшләгән[454].

Тымытык XIX гасырның икенче яртысында зур олыс үзәге буларак кына түгел, рухияттә тоткан урыны белән дә киң билгеле авылларның берсенә әйләнә. Болай фикер йөрткәндә без, беренче чиратта, мәдрәсәне һәм аның эшчәнлеген күз алдында тотабыз.

Тымытыктагы шикелле зур мәдрәсәләр төбәктә күп булмый. Тәйсуган, Түбән Чыршылы, Бәйрәкә, Чалпы һәм Сөендек авыллары мәдрәсәләре белән чикләнә ул исемлек. Башлангыч белеме һәм укуларын тагын да дәвам иттерү уе булган шәкертләр монда башка авыллардан да килгәннәр. Мәдрәсә тәмамлаучылар, теләкләре булса, тагын бераз әзерлек алып, муллалыкка имтихан тота алганнар.

1885 ел ахыры – 1886 ел башына караган мәгълүматлардан күренгәнчә, Тымытык мәдрәсәсе 7 бинада урнашкан. Шәкертләрнең гомуми саны 300 дән арта. Мөгаллим хезмәтен башкаручы мулланың 10 ярдәмчесе (хәлфәләр) бу-

[454] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 290–297.

ла[455]. Алдарак телгә алынган муллалар бу чорда да эшли, шулардан Әхмәтлатыйф Габделлатыйпов мөгаллимлек иткән дип әйтергә нигез бар.

Тымытык мәдрәсәсенә тирә-як авыллардан гына түгел, бик ераклардан да килеп укыганнар. 1875–1885 елларда биредә булачак язучы Закир Һади белем ала. Ул 1863 елда Уфа губернасы Бәләбәй өязе Ярәмкә (хәзерге вакытта Башкортстанның Шаран районына керә) авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туган. Атасы, иген игү һәм умартачылык белән шөгыльләнүдән тыш, кыш көннәрендә балалар укыткан.

Закир Һади балачагын авылда уздыра, башлангыч белемне үз атасыннан ала. 12–13 яшьләренә җиткәч, 1875 елда Закирны Тымытык мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр. Ун ел вакытын ул монда уздыра. Хәлфәләрдән Хөснелгата Муратаев исемлесе анда җылы истәлек калдыра. Заманына күрә яхшы гына ачык фикерле бу хәлфә Закирны, аз булса да, кайбер фәннәрнең башлангычы белән таныштыра. Бигрәк тә аның шәкертләренә «иҗтиһад итәргә, барлык нәрсәне акыл белән уйлап, тикшереп карап ышанырга, укуны, белем алуны һәр җирдә һәм һәрвакыт дәвам иттерергә кирәк» дигән киңәшләр бирүе әһәмиятле. Закир Һади аның киңәшләрен хәтерендә нык саклый. Соңыннан үзенең «Официант» (1905) исемле хикәясендә шәкертләргә яхшылык теләүче бер хәлфә образын барлыкка китерә[456].

Тымытык мәдрәсәсе З. Һадиның зур белемгә ихтыяҗын канәгатьләндерә алмый. Уку-укыту эшләре тулысынча схоластикага нигезләнгән булу өстенә, шәкертләрнең тормыш шартлары да начар була. Әмма ничек кенә булмасын, мондагы уку белән бәйле тормыш З. Һадиның язучы булып җитешүендә билгеле роль уйный, күпмедер аның хикәяләрендә дә чагыла. «Җиһанша хәзрәт», «Бәхетле кыз», «Бәхетсез кыз», «Мәгъсүм» һәм тагын берничә әсәр иҗат иткән язучы татар әдәбиятында шактый әһәмиятле урын тота.

З. Һади Тымытык мәдрәсәсендә укыган чорда татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку-укыту эшләре иске метод («ысулы кадими») нигезендә алып барылган. Яңа метод («ысулы җәдид») белән укыту 80 нче еллар уртасында гына юл яра башлый. Бу ысулның өстенлеге шунда, ул дини белемнән тыш, география, тарих, хисап кебек дөньяви фәннәр укытуга зур игътибар бирә.

Татар мәктәп-мәдрәсәләре XIX йөзнең соңгы чирегенә чаклы тулысынча халыктан җыелган акча исәбенә яшәгәннәр. Бары 80–90 еллардан гына берничә өяздә земстволар инициативасы белән кайбер татар уку йортларына акчалата ярдәм күрсәтелә башлый. Әмма аны рус мәктәпләренә тотылган акчаның күләме белән чагыштырсаң, аерма, кем әйтмешли, җир белән күк арасы. Мәсәлән, 1885 елда Бөгелмә өязенең рус мәктәпләре ихтыяҗына 11 мең сумнан артык акча тотылса, Тымытык, Тәйсуган, Бәйрәкә һәм Түбән

---

[455] Шунда ук. 143 б.

[456] Гайнуллин М. Закир Һади (тормышы һәм иҗат юлы) // Закир Һади. Сайланма әсәрләр. Казан, 1957. 3–4 б.

Чыршылы мәдрәсәләренә нибары 500 сум гына бүленә. Башка татар мәктәпләре исә мондый ярдәмнән дә мәхрүм була.

Авыр, еш кына акчасызлык шартларында эшләсәләр дә, мәктәп-мәдрәсәләр аң-белем таратуда шактый гына нәтиҗәләргә ирешәләр. Моны урыс чиновниклары да танырга мәҗбүр. Тымытык олысын күздә тотып алар болай язалар: «*Грамотность этой волости выражается в следующих цифрах: грамотных мужчин 346, женщин 386, учащихся мальчиков 546 и девочек 585, или грамотных мужчин 22,5%, женщин 24,2% и общий % грамотных 23,4%. Этот % вдвое выше такового же по самой грамотной русской волости Спасской (10,7%) и выше средняго поуезднаго в 10,7%*»[457].

Совет чорында мулла-хәлфәләрдән көлү, аларны хурлау яман төс алган иде. Алар арасында төрлеләре булган, әлбәттә, шул исәптән Закир Һади оста сүрәтләгән Җиһанша хәзрәт шикеллеләре дә. Әмма аларның төп өлеше милләтебезнең мәдәнияте һәм рухияты өчен гаять әһәмиятле эш башкарган. Ерак бабаларыбызның башка милләтләр арасында, югарыда тасвирланганча, ике тапкырдан күбрәккә грамоталы булуы моның ачык бер дәлиле.

1889 елда Тымытыкта 329 хуҗалык булып, аларда 1894 кеше яши. 1885 ел ахыры – 1886 ел башы мәгълүматлары белән чагыштырганда, күрсәткечләр 6 хуҗалыкка һәм 19 кешегә кимегән. Гасыр урталарында авыл 2 мәчетле иде, хәзер өченчесе дә салынган (1887 елда). Авылдан ерак түгел мулла Гобәйдуллинның утары була[458].

Гасыр ахырына Тымытык шактый зурая. 1897 елда андагы 412 хуҗалыкта 1080 ир-ат һәм 1180 хатын-кыз яши. Олыс авыллары арасында зурлыгы буенча 573 хуҗалыктан, 2947 кешедән торган Чалпыдан гына калыша ул.

Тымытык – элеккечә өч мәчетле, зур мәдрәсәле авыл. Олыс идарәсе монда булганлыктан, авылда урядник һәм писарьлар да яши. Олыста бердәнбер земство стансасы шулай ук Тымытыкта урнашкан.

1897 елда Тымытык олысында 8 авыл исәпләнә. Зурлыгы буенча алар түбәндәге тәртиптә урнаша: Чалпы (5 мәчетле), Тымытык (3), Урсай (3), Күктәкә (1), Сасыкүл (1), Яланкүл (1), Мөслим (1) һәм Югары Җирекле (мәчете юк)[459].

Татарстан дәүләт архивында саклланучы 1900 елгы документлар авылның ул чордагы социаль-икътисади торышын тулырак күзалларга ярдәм итә. Югарыда олыс идарәсе хакында әйтелгән иде. Кемнәр хезмәт иткән соң анда? Урядник булып дворян И.А. Алферов (25 яшь) тора. Писарь вазифасын Бөгелмә өязе Петропавловка авылы крестьяны улы А.Н. Чудин (21) башкара.

---

457 Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 142.

458 Список населенных мест Самарской губернии по сведениям 1889 г. Самара, 1890. С. 87.

459 Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 111–112.

Ул Бөгелмә шәһәрендә өч класслы училище тәмамлаган. Аның ярдәмчесе итеп шул шәһәрдән крестьян улы М.П. Брагинны (18) билгелиләр. А.Н. Чудинның икенче ярдәмчесе – П.Д. Григорьев (36). Башкалардан аермалы буларак, ул өйләнгән. Чыгышы буенча Бөгелмә мещаны, шунда өяз училищесында укыган. Олысның тулысынча татар авылларыннан торуын искә алсак, шундый җаваплы урыннарда гел урысларны гына күрү сәер.

Авыл старостасы – Мөхәммәтзарип Мөхәммәтгалин (57 яшь). Монда туып-үскән, гаиләсе һәм хуҗалыгы зур. Хуҗалыгы нинди зурлыкта булуын күз алдына китерү өчен кайбер мәгълүматларга тукталыйк. Мөхәммәтзарипның үз иманасындагы чәчүлекләре зур түгел (7,92 дисәтинә). Әмма ул авылдашларыннан һәм читтән 38 дисәтинәдән артыграк басуны арендага ала. 14 баш эш аты, 8 сыер, 40 сарык, 2 кәҗә һәм күп кош-корт тота. Хуҗалыгында күп эшләрне хезмәтчесе башкара.

Тымытыктагы земство стансасын бертуган Салаватовлар[460] тота. Аларның өлкәне Шәһадәт (38 яшь) татар һәм рус телләрендә укый-яза белүе белән аерылып тора. Стансадагы 5 атның өчесе аныкы, икесе туганы Сәгадәтнеке була. Алар үзләренең атларын җигеп земство йомышларын үтәүче чиновникларны йөрткәннәр, почта ташыганнар. Билгеле, бу хезмәт өчен аларга хак түләнгән. Земство эше хуҗалыкка аз вакыт калдырган, күрәсең, шуңа күрә Салаватовлар хезмәтче яллаганнар.

Килеп-китеп йөрүчеләр Шаһидулла Ибәтуллинның (39 яшь) кунып чыгу йортына (русча «постоялый» двор) тукталганнар. Монда һәрвакыт ак күмәч сатылган, теләүчеләргә тамак ялгап алу мөмкин булган. Шаһидулланың хуҗалыгы зур түгел, шулай да ул хезмәтче тоткан. Гаиләсе ике хатыны һәм анасыннан торган, балалары булмый.

Юл йөрүчеләр Ыкның уң ягына яз, җәй һәм көз айларында акча түләп Шаһидулла Ихсановның (41 яшь) күпере аша чыкканнар. Шунда ук аның пароны була. Икесе дә 1892 елдан бирле аның үз милке саналган. Үзенә ярдәмгә 4 айга эшче дә яллый торган булган.

XIX гасыр ахырында Тымытыкта өч мәчет барлыгы хакында әйтелгән иде. «Башкорт» мәхәлләсендә указлы мулла булып Әхмәтлатыйф Габделлатыйпов (75 яшь) тора. Ул Уфа губернасы Минзәлә өязе Ирехтә олысы Салауз-Мухан авылында (хәзерге Мөслим районындагы авыл) туып-үскән, шул чорның шактый билгеле Стәрлебаш мәдрәсәсен тәмамлаган. 1900 елда ул ике хатыны, 3 улы һәм кызы белән яши. 2 улы Тымытык мәдрәсәсендә белем алган, ә берсе исә анда укуын дәвам итә. Өлкән улы Миргалим (38 яшь) – «ка-

---

[460] Совет хакимияте урнашкач, Сәлахетдин, Хәләфетдин һәм Афзалетдин Салаватовлар беренчеләрдән булып Ыкның уң ягына күчеп утыручылар, 1918 елда Яңа Тымытык авылына нигез салучылар рәтендә була (Электрон ресурс. Керү режимы: https://bakalzori.ru/articles/kultura-i-iskusstvo/2018-08-10/100-letniy-yubiley-sela-novyy-tumutuk-82508 (мөрәҗәгать итү датасы: 2023 ел, 20 март)).

зан татарлары» мәхәлләсендә мулла. Өйләнгән, әмма атасы хуҗалыгында яши. Әхмәтлатыйф хәзрәтнең мал-мөлкәте күп була. 100 башка якын мал-туар, шул исәптән 29 эш аты, 17 сыер, 19 сарык һәм 9 кәҗә асрый. 308 дисәтинә җир сатып алган. 1885 ел ахыры – 1886 ел башы мәгълүматларын бәян иткәндә шундый ук күләмдә җире булган исеме билгесез бер мулла турында әйтеп үткән идек, хәзер аның нәкъ Әхмәтлатыйф хәзрәт икәнлеге ачыкланды. Мулланың зур хуҗалыгында ел әйләнәсенә хезмәтчеләре (4 ир-ат һәм 4 хатын-кыз) эшләгән. Алардан тыш, кыр эшләре вакытында ул көнлекчеләр һәм берничә айга эшчеләр яллый торган булган.

Өченче мәхәллә имам-хатыйбы һәм мөдәррисе Сәетмөхәммәт Әхмәтлатыйпов (25 яшь) шулай ук Салауз-Муханныкы дип күрсәтелә, әмма аның Әхмәтлатыйф хәзрәтнең улы булуында шигебез юк. Ул Казанның атаклы Галиев мәдрәсәсен тәмамлагач, 1898 елда әлеге вазифага сайланган. Хатыны Уфа губернасы Бәләбәй өязенең Корыч олысына караган Килкабыз авылыннан (хәзерге Башкортстан җөмһүриятенең Бакалы районына карый). Сәетмөхәммәтнең хуҗалыгы зур булмый: дистәдән артык мал-туар һәм 5,5 дисәтинә чәчүлек.

Тымытык муллаларының күпчелеге – читтән килгән кешеләр. Икенче мәхәллә имамы Габделҗәмил Габделкасыймов (68 яшь) тумышы буенча Уфа губернасы Минзәлә өязе Кәлморза авылыннан (хәзерге Минзәлә районына карый) була. Вятка губернасы Сарапул өязе Әгерҗе авылы мәдрәсәсендә белем алган. Гаиләсе зур – ике хатыны, алты улы һәм 2 кызы була. Ул 3 эш аты, 3 сыер, 10 сарык, 2 кәҗә асрый, арендага 13,6 дисәтинә җир алып иген игә. Хуҗалык эшләренә хезмәтче яллаган.

Исәп буенча дүртенче мулла – Шаһиморат Шаһимәрдән улы Адылов – Вятка губернасы Алабуга өязе Салауш олысы Салауш авылында (хәзерге Әгерҗе районына карый) туган (1858 ел), Тымытык мәдрәсәсен, аннары Оренбургта татар укытучылар мәктәбен (татарская учительская школа) тәмамлый. Тымытыкка кайткач, 1892 елдан беренче мәхәлләдә имам һәм мөгаллим хезмәтен башкара, мәдрәсәдә рус телен укыта. 1900 елда ул хатыны (30), 2 улы (17 һәм 2 яшьләрдә) һәм 2 кызы белән яши. Алар бер хатын-кыз хезмәтче тоталар. Хуҗалыгы зур түгел: 2 эш аты, 1 сыер һәм арендага алган басуларда 11,27 дисәтинә чәчүлек. Ш. Адылов алга таба тагын бер телгә алыначак әле.

Икенче мәхәллә имам-хатыйбы һәм мөгаллиме (1897 елдан) Хөсәен Исмәгыйлов (35 яшь) төп авыл кешесе булуы белән аерылып тора. Ул мондагы мәдрәсәдә укыган, шунда ук русча да укырга-язарга өйрәнгән. Хатыны (22), анасы, улы һәм бертуганының улы белән гомер сөрә. Аның иген басулары 10 дисәтинәдән арта; кыр эшләре вакытында ул күпсанлы көнлекчеләр яллый торган булган.

Тымытык мөәзиннәренең өчесе дә шушы авылдан, Шәрәфетдинов фамилияле. Аларның икесе – Әхмәтзарип (37 яшь) һәм Әхмәтшәрип (27) – бер-

туганнар булса кирәк, чөнки аталары типтәр сословиесеннән. Мөәзиннәрнең гаиләләре һәм хуҗалыклары зур түгел; соңгысының гаиләсендә җитмеш яшьлек ата-анасы да яши. Әхмәтзарип беренче мәхәлләдә мөәзин һәм мөгаллим булып 1890 елдан хезмәт итә, ә менә Әхмәтшәрипнең указы булмый, ахры.

Мөәзиннәрнең өченчесе – Кашшафетдин Шәрәфетдинов. Ул 1851 елда туган, 40 яшьтә әлеге вазифага расланган. Хатыны (45 яшь) Каташ-Каран авылыннан, икесе дә балалар укыталар. Мөәзиннең зур гаиләсендә (6 бала) ике бертуган энесе дә яши. Аның берничә баш эре малы һәм 5 дисәтинәдән артык чәчүлеге була.

Бәләбәй өязе Иске Катай авылының 1893 елгы метрикәсендә Мифтахетдин Миңлегәрәевнең икенче кызы Рәйфәнең (18 яшь) Тымытык авылы мөәзине Әхмәтгариф мулла Әхмәтшакир улы (25) белән никахы теркәлгән. Димәк, Әхмәтгариф Әхмәтшакиров исәп буенча дүртенче мөәзин була[461].

Уку-укыту турында сүз чыккач тагын ике кешене билгеләп үтми булмый. Аларның берсе – Газиз Раянов (50 яшь). Ул башлангыч белем бирү мәктәбендә (документта «школа грамоты» дип күрсәтелә) укыта. Димәк, Тымытыкта мәдрәсәдән башка шундый уку йорты да булган. Мәктәп көз-кыш айлары (6 ай) эшләгән. Мөгаллимгә, билгеле, казна бер тиен дә түләми. Хезмәт хакын ата-аналар үз мөмкинчелекләреннән чыгып, хуҗалыкта җитештерелгән ризыклар (икмәк, ит, йомырка һәм башкалар) белән түләгән.

Г. Раянов – Тымытык мәдрәсәсен тәмамлаган укытучы. Хатыны (41 яшь), 2 улы (16; 8 яшьләрдә) һәм 3 кызы (19; 6; 2 яшьләрдә) белән яши. Мәктәп яшендәге балалары атасыннан укырга-язарга өйрәнәләр (алга таба китеп әйтик, бу нәселдән тагын укытучылар чыгачак әле). Хуҗаның икешәр баш аты һәм сыеры, 10 дисәтинәдән артык чәчүлекләре була.

Укытучыларның икенчесе – Хаҗи Мөхәммәтгалин (60 яшь). Ул Чалпы мәдрәсәсендә белем алган. Хатыны (55 яшь), 3 улы (16; 12; 8) һәм кызы (18) белән яши. Ирле-хатынлы үз өендә көз-кыш (7 ай) балалар укытканнар. Ир балаларны – хуҗа үзе, кызларны абыстайда белем алган хатыны укыткан. Берничә баш мал-туар, шул исәптән берәр ат һәм сыер асрыйлар, 7 дисәтинәгә якын мәйданда иген игәләр.

Күренгәнчә, уку-укыту традициясе Тымытыкта нык тамыр җәйгән. Тормыш мәшәкатьләренә карамастан, ата-аналар балаларын кулларыннан килгәнчә укытырга тырышканнар. Чөнки, халкыбыз әйткәнчә, наданлык – хурлык.

Югарыда хуҗалыкларның күпме җирләре яисә чәчүлекләре булганлыгы хакында мөмкин кадәр киң мәгълүмат биреп бардык. Әлегә чаклы иң зур биләмә хуҗасы Әхмәтлатыйф хәзрәт иде. Тымытыкта аннан да зуррак җир хуҗасы – Габдерәфикъ Кәлимулла улы Шәфиев (32 яшь). Аның Бөгелмә һәм Бәләбәй өязләрендәге биләмәләре 320 дисәтинәдән артып китә. Ул төп Ты-

[461] Кәрим Т. Җиде бабаңны бел, катайлым. Казан, 2020. 148 б.

мытык кешесе түгел, Татарстан дәүләт архивында сакланучы документта Бөгелмә сәүдәгәре дип күрсәтелә. Атасы Кәлимулла Гобәйдулла улы Шәфиев та сәүдәгәр булган, 1872 һәм 1887 елларда Ык буеннан 300 дисәтинәдән артык җир сатып алып, әлеге елганың уң ягында урнашкан имениесендә яшәгән (бу хакта Башкортстан Милли архивы документында әйтелә)[462].

Әлеге имение хакында 1895 елгы мәгълүматлар игътибарга лаек. Монда сәүдәгәрнең 2 йорты, ат абзары, амбары була. Барлык мал-туары – 2 эш аты да бер сыер. Ул ике хезмәтче һәм бер каравылчы тоткан. Һәр елны зур мәйданда (шактый җирне арендага да алган) иген игеп, Чаллыга икмәк алып барып саткан. Моның өчен күп кенә ат яллый торган булган.

Габдерәфикъ Шәфиевка кайтыйк. 1900 елда ул хатыны (29 яшь), 3 улы һәм 2 кызы белән үзенең усадьбасында яши. Элегрәк Кәлимулла Шәфиевныкы дип күрсәтелгән җир хәзер аның исемендә, димәк, атасы вафат булган.

Олыс үзәге һәм базарлы зур авылларның берсе буларак, Тымытык бик күпләрне җәлеп иткән. Сәүдәгәрләрне генә алыйк: алар кайдан гына килмиләр. Минзәләдән сәүдәгәр Миңлегәрәй Сәетбатталов Тымытык базарыннан күпләп икмәк сатып ала торган булган. Моның өчен ул приказчигы Могътәсим Шаһиәхмәтовның ике амбарын арендага ала, анда сатып алган икмәген туплый, аннары атлар яллап, якындагы төп складларының берсенә – Урыс Шуганына ташый. Әлбәттә, бу эшләрнең күбесен приказчигы башкара. Якынтирәдә (Күктәкә, Сәпәй, Чәкән авылларында) зур базарлар булу да Миңлегәрәй кебек сәүдәгәрләрне Тымытыкка җәлеп иткән.

Кайбер сәүдәгәрләр биредә лавкалар ачып төпләнеп калганнар. Шундыйларның берсе – Нурулла Хәбибуллин (55 яшь). Ул тумышы белән Казан губернасы Спас өязе Базарлы Матак олысы Иске Салман авылыннан. Ике хатыны (40 һәм 38 яшьләрдә), 4 улы һәм биш кызы белән яши. Татарча һәм урысча укый-яза белә. 2 улын (15 һәм 10 яшьләрдә), зур гыйлем бирү максатыннан, Казандагы бер мәдрәсәгә укырга җибәрә.

Нурулланың бакалея лавкасы – Тымытыкта иң зурысы. Анда приказчигы Шәмсетдин Шиһабетдинов (30 яшь) сәүдә иткән. Шәмсетдин Минзәлә өязенең Нөркәй авылында туган, Теләнчетамак мәдрәсәсен тәмамлаган.

Лавкадан тыш, Нурулла сәүдәгәрнең башка керем чыганаклары да була. Шуларның берсе – чаналар һәм буралар сату. Моның өчен ул урман участогы сатып алган һәм агач хәзерләттереп, аны осталарга чаналар ясарга һәм бура бурарга бирә торган булган. Ярма яргыч та сәүдәгәрнең байлыгын арттырган.

Авыл халкына акчага яисә башка шартка ярма ярдыру өчен дүрт айга хезмәтче яллаган ул. Сәүдәгәрнең хуҗалыгы да зур. Ул 11 эш аты, 3 сыер һәм 5 баш умарта тота. Үз яисә сатып алган җире булмый, шуңа күрә ул аны озак срокка (9–12 ел) арендага ала торган булган. Арендалаган басуларында

[462] БР МА, И–132 ф., 1 тасв., 911 сакл. бер.; ТР ДА, 993 ф., 1 тасв., 859 сакл.бер.

чәчүлек мәйданы 62,7 дисәтинә тәшкил иткән. Әлбәттә, ул басуларда көнлекчеләр, берничә атнага-айга ялланган эшчеләр эшләгән.

Зур мал-мөлкәткә ия булган сәүдәгәрләрнең икенчесе – Могътәсим Шаһиәхмәтов (42 яшь). Ул мондагы «казан татары» гаиләсендә туып-үскән, мәктәп тәмамлаган. Аның төп байлык чыганагы булып чәй һәм икмәк сәүдәсе торган. Бу максаттан ул чәй сата торган лавка һәм өч икмәк саклагыч (амбар) тота. Алдарак бу амбарларның икесен сәүдәгәр М. Сәетбатталовның арендага алуы хакында әйтелгән иде. Могътәсим сәүдәгәрнең лавкада – бер, амбарларда ике приказчигы була.

Сәүдәгәрнең хуҗалыгы зурлардан санала. 10 эш аты, 15 сыеры, 115 сарыгы, 30 баш умартасы, арендага алган басуларда 95,41 дисәтинә игене була. Кыр эшләрен көнлекчеләр һәм берничә айга-атнага ялланган эшчеләр башкарган. Алардан тыш, хуҗалыгында дүрт хезмәтче даими эшләгән.

Авылда тагын өч лавка була. Икесенең хуҗалары – төп Тымытык кешеләре. Боларның берсе – Зарип Хисмәтуллин (46 яшь), икенчесе – Насретдин Әхмәтханов (42). Алар вак-төяк тауарлар белән үзләре сәүдә иткәннәр, приказчиклар яллamaганнар. Хуҗалык эшләрен башкарыр өчен берәр хезмәтче тотканнар.

Өченче лавка хуҗасы – Бәгыйс Мозаффаров (38 яшь). Ул Уфа губернасы Минзәлә өязенең Наратлы-Кичү авылында (хәзерге Минзәлә районы карый) туган, Тымытыкта мәдрәсә тәмамлаган. Вак-төяк тауарлар белән үзе үк сәүдә итә. Башкалардан аермалы буларак, мал-туары һәм чәчүлекләре юк.

Сәүдәгәрләр исемлеге югарыда санап үтелгән кешеләр белән генә чикләнми. Лавка тотмыйча, монда һәм якын-тирә базарларда даими сәүдә итеп йөрүчеләр дә була. Шуларның берсе – Сафиулла Гыйззәтуллин (42 яшь). Ул тумышы буенча Казан губернасы һәм өязе Кармыш олысы Иске Кырлай авылыннан. Тымытыкта ике хатыны (35 һәм 30 яшьләрдә), 2 улы, 3 кызы белән яши. Дистәгә якын мал-туар, шул исәптән 3 эш аты һәм 2 сыер асрый, арендага алган җир участогында 6,56 дисәтинә иген игә. Сафиулла сәүдәгәр кыр эшләреннән буш вакытта кәрзин тотып, базардан-базарга йөреп вак-төяк тауарлар саткан.

Сафиулла кебек сәүдәгәрләр арасында төп Тымытык кешеләрен дә күрәсең. Хәсән Асылгәрәев (42 яшь) базарларда дегет, тоз һәм чабаталар сата торган булган. Хаҗи Сәгъдиев исә сатарга көрәкләр, касәләр, баулар һәм чабаталар алып чыккалаган. Алар икесе дә мал-туар тоталар, иген игәләр.

Атна саен базарлар үткәрелеп тору, Тымытыкта икмәк сәүдәсе үсүгә китерә. Аерым кешеләр икмәк сатып алу һәм аны югарырак бәягә күпләп сату белән шөгыльләнгәннәр. Берничәсе хакында әйтеп үтик.

Вәлиәхмәт Исмәгыйлов (52 яшь) һәм аның энесе (44 яшь, исеме күрсәтелмәгән) икмәк сәүдәгәрләре арасында аерылып торалар. Алар сәүдә белән һәр базар саен, димәк, даими шөгыльләнәләр; икмәкне үзләренең зур амбарында саклыйлар. Икесе дә гаиләләре һәм үз йортлары белән төп нигездә

бер хуҗалык булып яшиләр. Имана сөрүлеге аз (4,2 дисәтинә), шуңа да абыйлы-энеле бу ике туган зур җир участогын (70,6 дисәтинә) арендага ала. Бик күп мал-туар (5 эш аты, 5 сыер һәм башкалар) асрыйлар, 6 баш умарта тоталар. Сәүдә белән шөгыльләнү зур хуҗалыкны алып барырга вакыт аз калдырган, күрәсең, алар ике хезмәтче тоталар, ә кыр эшләре вакытында көнлекчеләр яллый торган булганнар.

Икмәк сәүдәгәрләренең чираттагысы – Шәкүр Хәбибуллин (43 яшь). Ул да шактый җирне (20 дисәтинә) арендага алып, барлыгы 21,5 дисәтинә мәйданда иген игә; 24 баш мал-туар, шул исәптән дүртәр эш аты һәм сыер тота. Кыр эшләре вакытында көнлекчеләр һәм берәр айга ике эшче яллаган. Елның күп чорын (7 ай) мондагы базардан икмәк сатып алып, аны югарырак бәягә күпләп Рус Шуганына һәм Минзәләгә алып барып сата торган булган. Аның зур икмәк саклагычы була.

Тагын бер сәүдәгәр – Хөсәен Әхмәтов (51 яшь) – икмәкне Чәкәннән һәм мондагы базардан сатып алып, күпләп Рус Шуганында саткан. Базарларда икмәк бәяләре арасындагы аерма хисабына шактый табыш алган. Сәүдә белән көз-кыш айларында, атнага өч тапкыр шөгыльләнгән. Уннан артык малтуары, шул исәптән икешәр эш аты һәм сыеры, 8 баш умартасы һәм 16 дисәтинәдән артык чәчүлеге була.

Бу чорга сәүдә эшчәнлеге генә түгел, һөнәрчелек тә зур үсеш ала. Һөнәрчеләр Тымытыкта шул кадәрле күп, барысының да исем-фамилиясен атап үтү мөмкин түгел. Шунлыктан, киң таралган һөнәрләр турында сүз барганда, кайбер кешеләрне генә күрсәтеп үтәргә мәҗбүрбез.

Иң башта тимер белән эш итүче осталарга тукталыйк. Алар арасында Якуп Зәйнетдинов (52 яшь) аерылып тора. Ул көмештән хатын-кызлар өчен төрле бизәнү әйберләре ясый. Тумышы буенча Казан губернасы Мамадыш өязе Сатыш олысы Париски-Уре авылыннан. Хатыны (45), 3 улы һәм 3 кызы белән яши. Өлкән улы – Оренбург, икенчесе Тымытык мәдрәсәсендә укый. Хуҗалыгы зур түгел: 4 баш мал-туар һәм 3,7 дисәтинә чәчүлек. Көз-кыш айларында оста үзенә ярдәмче дә яллаган.

Авылда өч тимерче була. Аларның икесе – Гариф Шәрипов (30 яшь) һәм Гариф Фәйрушин (33) – төп Тымытык кешеләре. Өченче тимерче – Хәлиулла Кәлимуллин (33) тумышы буенча Бөгелмә өязе Әлмәт олысы Әлмәт авылыннан. Мөхәммәди Кәримовның усадьбасын арендага алып, шунда йорт җиткезеп яши. Тимерчеләрнең мал-туары һәм чәчүлекләре аз.

Авылда киң таралган һөнәрләрнең берсе – агач эшкәртү. Бу төр һөнәрчеләр арасында арба ясаучы (Камалетдин Әфләтунов) һәм көпчәкче (Гәрәй Мөхәммәтҗанов) аерылып тора. Ә инде башка балта осталарын санап тормыйбыз – алар күп.

Күннән төрле әйберләр (итек, читек, кәвеш һәм башкалар) тегү дә үсеш алган. Итекчеләр арасында Сабир Раянов (30 яшь), Вәли Үлмәсколов (45),

Сәгыйдулла Рәхмәтуллин (50), Гали Хисмәтуллин (58) фамилияләре күзгә чалына.

Авылда ике хуҗалыкта тегүчеләр дә яши. Атаклысы – Гыймадетдин Әхмәтханов. Тымытыкта бердәнбер тегү машинасы аныкы була. Аның 3 улы (24; 22; 18 яшьләрдә) да атасы һөнәрен үзләштерә, өлкәне хәтта Уфага чаклы барып, андагы кешеләргә тегеп йөргән. Бөтен авыл диярлек ситсыдан күлмәкыштан һәм башка кием-салымны Әхмәтхановларда тектергән.

Киез итек басучылар – авылда берничә хуҗалык. Бу төр һөнәрчеләр исемлегенә Шәфикъ Мөхәммәдьяров (35), Закир Шәфиков (39), Гәрәй Шаһмәтҗанов (?60), Җәләлетдин Сәйфетдиновлар (65) керә. Алар бу эш белән көз-кыш айларында шөгыльләнгәннәр.

Башка төр һөнәр ияләре арасында калайчы (Сабир Зарипов), бау ишүчеләр (Зарип Вәлиев, Гариф Зарипов, Хөсәен Зарипов, Шакир Мөхәммәдьяров), чыпта сугучы (Шәрәфетдин Хисаметдинов), чабатачылар (Солтан Мөхәммәтшин, Нәфыйкъ һәм Латыйф Вахитовлар), миччеләр (Шагдән Шәрифуллин, Хөснулла Шәрифуллин) була.

Һөнәрчелек хуҗалыкларның бер өлеше өчен өстәмә керем чыганагына әйләнсә, ярлылары өчен төп яшәү чыганагы булып тора. Һөнәре булмаган ярлы хуҗалыклар якын-тирәдәге алпавытларда яисә бай авылдашларында ялланып эшләгән. Мисал өчен Исмәгыйль Ибраһимовны (53 яшь) алыйк. Аның мал-туары юк, ә чәчүлекләре – нибары 2,8 дисәтинә. 2 улы белән ул Уфа губернасы Бәләбәй өязе Нугайбәк олысындагы А.А. Андреев хуторына барып ел буена шунда бил бөккән. Ә өченче улы авылда янгын сараенда каравылда торган.

Кайбер ярлы хуҗалыклар күпмедер вакыт яисә ел буена бөтен гаиләсе белән алпавытларга хезмәт иткән. Гарифулла Исмәгыйловның (50) гаиләсе Ыкның уң ягындагы алпавыт Пальчиков хуторында – 8 ай, Гатиятулла Гыйсмәтуллинныкы (40) Нугайбәк олысы Чижевка авылы янындагы Габдерәкыйп Кәлимуллин хуторында ел буена эшләгән. Икесенең дә мал-туары һәм чәчүлекләре булмый.

Өстәмә керем чыганакларыннан тагын умартачылык һәм балыкчылык зур игътибарга лаек. Авылда 33 хуҗалык 148 баштан артыграк умарта тота. 1900 елда алар балның потын – 8, балавызның 12 сумнан сатканнар.

Балык тоту белән шөгыльләнүчеләр дә күп. Хәбибулла Зәйнуллин (42 яшь), Хәким Йосыпов (45), Зәйнулла Зәйнуллин (64) һәм башка оста балыкчылар яз, җәй, көз айларында шактый вакыт (35–60 көн) Ык елгасында күпләп балык тотып, үзләреннән артканын базарда сата торган булганнар[463].

Егерменче гасырның беренче ун елында мәчетләрдә кайбер үзгәрешләр була. Өченче мәхәлләдә хезмәт итүче Миргалим Әхмәтлатыйпов 1905 елдан беренче мәхәлләгә имам-хатыйп һәм мөгаллим булып күчә. Икенче мәхәл-

[463] ТР ДА, 993 ф., 1 тасв., 883, 857, 859 сакл. бер.

ләдә Габделҗәмил хәзрәт урынына имам һәм мөгаллимлеккә улы Габделгазиз раслана (1908 елдан). Өченче мәхәлләдә имам һәм мөдәррис вазифасына 1910 елда Миргазиян Әхмәтлатыйпов сайлана[464].

1912 елның 1 мартында Тымытыкта рус-татар земство училищесы ачыла. Монда укытучы итеп алдарак телгә алынган Шаһиморат Адылов билгеләнә. Дәресләр аның зур (13 тәрәзәле) йортында үткәрелгән. Ир һәм кыз балалар аерым укыганнар. Алар күпме булган, бу хакта тулы мәгълүмат юк. Бары 1914 елдан училищеда укучылар саны рус-герман сугышы качаклары балалары исәбенә бераз артуы билгеле. 1915 елның көзеннән Ш. Адылов урынына укытучы итеп М.А. Габделлатыйповны куялар.

Мәктәп-мәдрәсәле авылда тагын бер уку йорты – земство училищесы – булдыру хаҗәт идеме соң? Бу сорауга катгый гына «юк» дип җавап биргәндә игътибарны мәсьәләнең иҗтимагый-сәяси ягына юнәтик. Татар мәктәп-мәдрәсәләренә, билгеле булганча, казнадан ярдәм бик аз тәтегән. Пособиеләр күләмен билгеләү, аларны бирү системага салынмый. Тымытык мәдрәсәсе земстводан елга 200 сум күләмендә пособие алып килсә, 1893 елдан исә бу аз сумма да эләкми. Чөнки Бөгелмә өяз земствосы мәдрәсәләргә акча бүлеп бирүне (биргәне дә аз була, бу хакта алдарак әйтелде) туктата. Ә бит алар, татарларның төп уку йортлары буларак, халык ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндергән. Менә шундый шартларда земство Тымытыкта яңа уку йорты ача. Мөселман мәктәп-мәдрәсәләренә акча кызганган земство рус-татар училищесы өчен кирәкле акча тапкан. Чөнки мондый уку йорты булдыру патша хөкүмәтенең урыслаштыру сәясәтенә җавап биргән.

Земство уку йортлары, гадәттә, халык үтенечен искә алып ачыла торган булганнар. Тымытыктан халык түгел, ә Шаһиморат Адылов мөрәҗәгать итә мондый үтенеч белән. Булачак уку йортына үзе үк укытучы итеп билгеләнәчәген күз алдында тоткан ул, һәм шулай булып чыга да. Земство укытучысы эше шактый төшемле булган шул. Шаһиморат Адыловның тагын бер гамәле билгеле. 1911 елда аның доносы нигезендә Яланкүл авылы мулласы Зәкиҗан Шаһгәрәев кулга алына һәм Сарапул төрмәсенә ябыла. Бу хакта Зәкиҗан хәзрәтнең «Төрмәләр хатирәсе» исемле китабыннан беләбез, монда ул Адыловны «А...» дип күрсәтә (цензура шулай таләп иткән, күрәсең). 1917 елдан соңгы чорга караган архив документларын өйрәнгәндә, Шаһиморат Адыловның патша охранкасында «Татарин» кушаматлы агент булып торганлыгы ачыкланды[465].

1916 елны патша Россиясендә соңгы тапкыр авыл хуҗалыклары исәбе алына. Тымытыкта 516 хуҗалык, 1172 ир-ат һәм 1366 хатын-кыз теркәлә[466]. Беренче бөтендөнья сугышы әнә шулай ир-атларның азаюына китерә.

[464] БР МА, И–295 ф., 2 тасв., 3 сакл. бер., 164 б. а.–166 б.
[465] ТР ДА, Р–231 ф., 2 тасв., 8 сакл. бер.
[466] Шунда ук, 993 ф., 1 тасв., 885 сакл. бер.

Октябрь инкыйлабыннан соң, 1918 елның октябрендә өяздән вәкилләр килеп Тымытык олыс башкарма комитетына сайлаулар оештыра. Олыс советы рәисе вазифасына утыз яшьлек Галимҗан Кәлимуллин сайлана. Ярлы гаиләдә туып-үскән бу егет шактый дөнья күргән була: Хөсәен байга бил бөгеп тә тормышын ныгыта алмагач, Бөгелмә ягына чыгып киткән, аннары Донбасс шахталарына барып күмер чапкан, беренче бөтендөнья сугышында катнашкан. Күктәкәдән Харрас Дәүләтгәрәев (32 яшь), Урсайдан Сәхаутдин Шәмсетдинов (53), Тымытыктан Сабир Гәрәев (43), Зәйнетдин Гәрәйшин (53), Чалпыдан Сәмигулла Шәрифуллин (44), Мөслимнән Мөхәррәм Уразгилдеевлар (55) олыс советы әгъзалары итеп сайлана[467].

Авыл халкының бер өлеше Ыкның уң ягындагы биләмәләренә күчеп утыра, Яңа Тымытыкка (хәзерге Бакалы районы авылы) нигез сала. Сүз уңаеннан әйтик, 2018 елның 28 июлендә яңа тымытыклылар авылның 100 еллыгын билгеләп үттеләр[468].

1920 елда Тымытыкта 453 хуҗалыкта 2315 кеше исәпкә алына. Тагын алты елдан соң үткәрелгән халык санын алу 419 хуҗалыкта 1699 кеше яшәгәнен күрсәтә. Бу вакытта авылда руслар (14 кеше) һәм керәшеннәр (12) дә була.

Олыс буенча да күрсәткечләр шактый кими: 1920 елда – 20738, ә 1926 елда 14477 кеше теркәлә[469]. 1921 елгы ачлыктан бик күп халык кырыла, моннан соң шактый вакыт үтсә дә, халык саны элекке дәрәҗәгә кайтмый. Әлеге саннар шуны дәлилли.

1930 елда Тымытыктан Хаҗиев Хәерзаман, Фәйрушин Сәетша, мулла Җәмилев Газиз, мөәзиннәр Җәмилев Хәмит, Шәрәфетдин Кашшафетдин һәм Гомәров Нурлыгаяннар, «кулаклыкта» гаепләнеп, авылдан сөрелергә карар ителә. Хәерзаман НЭП чорында сәүдә иткән, сепаратор тоткан. Сәетшаның 200 дисәтинәдән артык җире, бик күп мал-туары булган. Беренчесенең – 428, икенчесенең 649 сумлык мал-мөлкәте конфискацияләнә. Мулла-мөәзиннәр исә урта хәлле тормыш алып барсалар да, дин әзәрлекләнү сәбәпле, «кулаклар» исемлегенә эләгәләр. Кашшафетдинның улы Сабир 1919 елда Кызыл Армия сафларында взвод командиры булып хезмәт иткән, әлеге факт аларны авылдан куылудан коткарганмы, мәгълүм түгел. Кашшафетдинга – 81, улына 41 яшь була. Сабирның хатыны Мөссәләмә белән биш бала (Әсхәт, Мөнҗия, Нәдирә, Җәүдәт, Әхәт) тәрбияләгән чагы була.

Яңа оешкан колхозларга техник ярдәм күрсәтү максатыннан, 1931 елда Тымытыкта машина-трактор станциясе (МТС) булдырыла. Шул ук елны

---

[467] Шунда ук, Р–1167 ф., 1 тасв., 160 сакл. бер., 234–236 б.

[468] Бу хакта Бакалы районы гәзитендә хәбәр ителә (Электрон ресурс. Керү режимы: https://bakalzori.ru/articles/kultura-i-iskusstvo/2018-08-10/100-letniy-yubiley-sela-novyy-tumutuk-82508 (мөрәҗәгать итү датасы: 2023 ел, 20 март)).

[469] ТР ДА, Р–1296 ф., 12 тасв., 63 сакл. бер., 33 б.

монда 12 «Фордзон» тракторы кайтарыла. Бөтен төбәк халкын гаҗәпләндергән вакыйга була бу. Трактор турында «шайтан арбасы» дигән сүзләр тарала.

1939 елда Тымытык районы 36 авылдан торган. Һәр авылда берәр колхоз була. Менә аларның кайберләре: «Тымытык», «Заветы Ильича», «Кызыл Чишмә», «Куйбышев», «Балан Бүләк», «Киров», «Ялантау», «Эконом», «Ирекле», «Октябрь», «Тельман», «Уразман», «Кызыл Йолдыз №1», «Кызыл Йолдыз №2», «Кызыл арык», «Бүләк», «Мелиорация», «Ишкәй».

Шул елның 1 гыйнварена район үзәге Тымытыкта 2569 кеше яши. Ә бөтен район буенча 1937 елда (1 гыйнварга) – 23775, 1938 елда 21902 кеше булган. Район территориясе 779 кв. км тәшкил иткән.

Урта мәктәп ул чорда Тымытыкта гына була. 1937 елда мәктәпкә яңа бина сала башлыйлар. Район үзәгендә тагын 25 ятып дәвалану урыны булган шифаханә, пекарня һәм типография була[470].

1958 елда Тымытык районы бетерелеп, авыл Азнакай районына кушыла. Шуңа карамастан, ул элеккечә зур авыл булып кала. 1992 елда, мәсәлән, анда 1449 кеше яши. Шифаханә, агач эшкәртү комбинаты, урта мәктәп һәм башка социаль-көнкүреш объектлары урнашкан.

Шулай итеп, Тымытык гасырдан гасырга үсә, тотрыклы авылларның берсе булып кала. Менә шундый авылларыбыз яшәсә, Татарстанның киләчәге дә бик ышанычлы һәм зур өметле булачак[471].

## § 16. Туйкә

Юрмый волосте биләмәләрендә XVIII гасырның беренче яртысында Казан өязеннән күченүчеләр дистәдән артык авылларга нигез салалар. Шундый авылларның берсе – Туйкә.

Хәзерге атаманың килеп чыгышы Казан өязенең Җөри юлында йөзбашы (сотник) дәрәҗәсен биләгән Туйкә Абдулов белән бәйле. Берничә иптәше белән ул монда Җөри юлының Әгерҗе авылыннан 1726 елда ук күчеп утыра[472]. Нигез салучыларның берсе һәм дәрәҗәле кеше булганга, авыл аның исеме белән атала.

---

[470] Шунда ук, Р–5747, 1 тасв., 175 сакл. бер, 11–18 б.

[471] Авыл тарихы 1996 елда язылды, төп игътибар борынгы чорга бирелде. Узган гасырда язган текстка яңа мәгълүмат өстәгәндә Тымытык авылында 4 татар сословиесе (типтәр, башкорт, ясаклы һәм йомышлы («служилый») татарлар) вәкилләре яшәвен ассызыклап үттек.

[472] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1155 сакл. бер., 482–482 б. а.


Собою перешед поселились тое ж
сотни в новопоселенно деревне
Стерле из своих больше [illegible]

| | | |
|---|---|---|
| 14386 | Тойка Абдуловъ | 13 |
| 14387 | Сарметь [illegible] | 16 |
| 14388 | Мустайко [illegible] | 4 |
| 14389 | Халейка [illegible] | 3 |
| 14390 | Амирь Абдуловъ | 11 |
| 14391 | Мустайка Уразаевъ | 21 |

в 1726

Итого перешедших 6

*1726 елда Туйкә Абдулов һәм аның иптәшләре Стәрле авылына нигез сала. Соңрак авыл аның исеме белән Туйкә дип атала башлый*

Җөри юлының Әгерҗе авылыннан Туйкәне дә кертеп, башлап алты нәсел күчеп килсә, соңрак, ягъни 1730 һәм 1740–1747 елларда, аларга тагын өч авыл (Сәет Елга, Кече Дөреш, Бизәкә) кешеләре өстәлә. Нәтиҗәдә, 1748 елда монда 86 ир-ат исәпләнә. Авыл «яңа нигезләнгән Стәрле» дип атала[473].

3 нче ревизия (1762 ел) документында авыл «яңа нигезләнгән Туйкә, шулай ук Стәрле» (документта «вновь поселенная деревня Тойкино Стерли тож») дип күрсәтелә. Анда тәүге килеп утыручыларның нәселенә кагылышлы байтак кызыклы мәгълүматлар бирелә. Түбәндә аларга аерым тукталып үтик.

Туйкә Абдулов (1712–1758) турында әйткән идек. Аның нәселен Яһүдә (1762 елда 11 яшь), Котчы (10) һәм Ярмөхәммәт (8) исемле уллары дәвам итә.

Авылда иң өлкәне – якындагы Балтач авылыннан күчеп утырган Якуп Тимкин (80 яшь). Шунысы игътибарга лаек, исемлек башында ул беренче булып теркәлгән. Документта Якуп картның 2 улы һәм оныклары күрсәтелә. Өлкән улы Нияз 1758 елда вафат була, аның хатыны (Бәзәкә авылыннан), уллары Габдессәлам (15) һәм Габделмән (4) кала. Икенче улы Кнәз (34) ике хатыны ([Барҗы]-Омга һәм Тойма авылларыннан), Исәммәт исемле өч яшьлек улы белән яши.

Сүз уңаеннан әйтик, Якуп Тимкин нәселен дәвам итүчеләр бүгенге көнгә чаклы билгеле. Бу түбәндәге шәҗәрәдән күренә: Тимкә (~ 1660 туган)–Якуп (1682)–Нияз (1728–1759)–Габдессәлам (1747–1787)–Габделмәҗит (1767–1816)–Вәлит (1796)–Йосып (1831)–Мөхәммәтсабир (1864)–Мөхәммәтнәҗип (1907–1942)–Раин (1933–1993)–Ришат (1965). Ришат Раин улы Сабиров – полковник, Әлмәт шәһәре һәм районы хәрби комиссары.

Якуп Уразов, Бакый Әлмәкәев (40), Морат Әлмәкәев (44), Абиш Токбердин нәселләре дә игътибарга лаек. Беренчесенең нәселен Киләк (24 яшь) исемле улы дәвам итә. Якуп картның оныгы (Шәпи) яңа гына туган, аңа нибары ике ай. Бакый Әлмәкәевнең яңа дөньяга килгән Бикмәмәт исемле улы

473 Шунда ук, 1142 сакл.бер., 651–656.

була. Морат Әлмәкәевнең (ул Бакыйның туганы, ахры) уллары икәү – Әюп (15) һәм Сатый (4). Абиш Тукбирдинның Сәгыйть (7) исемле улы кала.

Уразмәт Колмәтов нәселе авылда иң зурлардан санала. Уразмәт карт 1755 елда 96 яшьтә дөнья куя. Бу вакытта аның 4 улы (Рахманкол, Иманкол, Йосыф һәм Иман) була. Иманколның нәселен уллары Рәмгол (9 яшь), Рәфикъ (9), Нигъмәтулла (5), Сайкол (5) һәм Миңлегол (1) дәвам итә.

Югарыда телгә алынган Уразмәтнең туганы – Бикмәт. Ул 1755 елда 71 яшьтә вафат була. Аның 4 улы кала. Мәмәтнең – Габдрахман (20 яшь), Заһирмәтнең – Сәгыйть (9), Сәеткол (2), Сәйфулла (яңа туган), Абдулланың – Йөзекәй (15), Сәфәр (10), Бакыйның – Якый (14), Ягъфәр (8), Мәүлекәй (4) исемле уллары күрсәтелә.

Әлеге төп нәселләрнең менә шулай тармаклануы һәм үсүе вакытлар узу белән авылның зураюына китерә. 1762 елда анда барлыгы 103 ир-ат ясаклы татар исәпләнә. Бу санга Бәткегә (хәзерге Туймазы районы авылы) күчеп киткән Исмәгыйль һәм Ишмәт Дусаевларны, якындагы Балтачка барып утырган Корбанай Токмәтов гаиләләрен кертмибез[474]. Авыл Е. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышында катнашучылар исемлегендә дә күрсәтелә.

Күченүчеләргә карамастан, Туйкә уртача зурлыктагы авыл булып кала. 1795 елда мондагы 41 хуҗалыкта 118 ир-ат һәм 102 хатын-кыз яши. Бу исәпкә күпчелекне тәшкил иткән ясаклы татарлардан тыш, 10 кешедән торган башкорт сословиесендәге татар гаиләсе дә керә.

1795 елгы ревизия документына таянып, ясаклы татарлар турында тулырак әйтеп үтик. Туйкәдә 113 ир-ат һәм 97 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 128 һәм 104) ясаклы татар була. Исемлек Кнәз Якупов (67 яшь) гаиләсе турында мәгълүмат белән башлана. Шунда ук аның мәрхүм туганы Ниязның хатыны Мәрьям Булат кызы (68), уллары Габдессәлам (1787 елда мәрхүм) һәм Габделмән (37) булуы әйтелә. Габдессәламнең хатыны Тутия Сәет кызы (44; Туйкәдә туып-үскән), уллары Габделмәҗит (28) һәм Габделваһап (10), кызлары Мотыйга һәм Сәмига кала. Христиан диненә күчкән Исмәгыйль һәм Вәлит (1795 елда мәрхүм булган Шәрип Ниязов уллары) Нугайбәк крепостенә күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Тол хатын Гөлшәр Ягъфәр кызы үзенең күпсанлы балалары (Корбангали, Баттал, Каһарман, Ибраһим Сәгыйтовлар һәм башкалар) белән Уфа казна палатасы указы нигезендә (1787 ел) Оренбург янындагы Сәет бистәсенә сәүдәгәрлеккә языла. Ярмөхәммәт Туйкин гаиләсе белән Яланкүл авылына барып төпләнә[475]. Әлеге кеше авылга нигез салынучының улы буларак билгеле иде.

XIX гасырның беренче чирегендә авылның үсешендә зур үзгәрешләр күзәтелми. 1816 елда элеккегечә күпчелекне ясаклы татарлар (128 ир-ат)

---

[474] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3795 сакл.бер., 378–387 б.; 1155 сакл. бер., 476–481 б.; 1142 сакл. бер., 651–656 б.

[475] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 129–138 б. а.

тәшкил итә. Шулардан 107 ир-атның ата-бабалары Юрмый волосте биләмәчеләре белән килешү нигезендә берьюлы 40 сум түләп (чыганакта «на вечность по договору из платежа единовременно» дип әйтелә) килеп утырганнар. Туйкәнең тагын 2 кечкенә төркем ясаклы татарлары Карамалы (Чаганлы; «под названием Карамалы Чиганлы тож»; 13 ир-ат һәм 5 хуҗалык) һәм Каран Тамак (Стәрле; «Каран Тамак Стерли тож»; 8 ир-ат һәм 2 хуҗалык; монда ук 1 «отставной» солдат) дип аталган урыннарда яши. Болардан тыш, башкорт сословиесенә караган 4 ир-ат (1 хуҗалык) татар теркәлгән. Шулай итеп, барлыгы 133 ир-ат һәм 28 хуҗалык була[476].

1816 елгы ревизия документларында Туйкә авылы ясаклы татарлары 3 исемлектә күрсәтелә. Төп өлеше (105 ир-ат һәм 76 хатын-кыз; 38 хуҗалык) – Туйкә исемлегендә[477], икенче өлеше (8 ир-ат һәм 5 хатын-кыз; Гапсәлам Яркәев, Габделмән Яркәев һәм Габделхәким Габделмәнов хуҗалыклары) – Каран Тамак (Стәрле) исемлегендә[478], өченче өлеше (7 хуҗалыкта 13 ир һәм 26 хатын-кыз; Ишбулды, Сәхип, Рәхмәтулла Ягъфәровлар, Габделмәҗит, Габдерәфикъ Арыслановлар, Габделгафар Габделкәримов, Фәйзулла Зәетов) Карамалы (Чаганлы) исемлегендә теркәлгән[479]. Болар барысы лашман бурычын үтәүче Кәкре Елга волосте ясаклы татарлары санала.

Югарыда сүз ясаклы татарлар турында барды. Туйкәдә башкорт һәм типтәр сословиеләренә караган татарлар да яши, 1859 елда алар 27 ир-ат һәм 23 хатын-кыз (6 хуҗалык) тәшкил итә. «Типтәр»ләр Сәйфетдин Сәетколов (58 яшь; указлы азанчы) – Акбаштан, Габдерәхим Хәмитов (70; өч хатынлы) Әсәйдән күчеп утырган. Соңгысының 2 улын 1863 елда Себергә сөрәләр. Ревизия исемлегенең титул битендә бу ике сословие татарлары «башкорт», эчке битендә «типтәр»ләр «типтәрдән башкорт» дип язылган[480]. Болардан тыш, авылда 148 ир-ат һәм 160 хатын-кыз (41 хуҗалык) ясаклы татар яши. Авыл старшинасы (чыганакта «сельский старшина») Гыйбадулла Нигъмәтуллин була[481].

Типтәр сословиесендәге татарларны 1855 елдан «башкорт» дип яза башлау Самара губернасы буенча белешмә әдәбиятта да чагыла. Андагы мәгълүмат буенча, 1859 елда Туйкә (Аблай) 227 ир-ат һәм 250 хатын-кыздан (64 хуҗалык; казна крестьяннары һәм «башкорт»лар дип язылган) тора[482].

---

[476] Шунда ук, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 126 б. а.

[477] Шунда ук, И–138 фонд, 2 тасв., 197 сакл. бер., 435–449 б.

[478] Шунда ук, 169–171 б. Авыл исеме чыганакта «Каран Тамак Стерли тож» дип язылган.

[479] Шунда ук, 476–481 б. Авыл исеме чыганакта «Карамалы Чиганлы тож» дип язылган.

[480] Шунда ук, 757 сакл. бер., 140–144 б.

[481] СӨҮДА, 150 фонд, 1 тасв., 190 сакл. бер., 343 б. а.

[482] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

Казна крестьяннары дип элекке ясаклы татарлар аталган. Имам-җәмигъ һәм мөгаллим вазифасын 1851 елдан Әхмәткәрим Габделгаффаров башкара[483].

1884 ел ахыры – 1885 ел башында Туйкә Азнакай волостенда (аңа тагын Азнакай, Әгерҗе, Әсәй, Балтач, Сәпәй, Холмовка керә) уртача зурлыктагы авыллардан санала. Анда 122 хуҗалыкта 335 ир-ат һәм 323 хатын-кыз яши. Авылда бер лавка була.

Туйкә авыл җәмгыятенең ул чорда 1552,2 дисәтинә уңай һәм 137,8 дисәтинә унайлы булмаган биләмәләре була. Аның 1333,3 дисәтинәсен сөрүлекләр алып тора.

Монда җир белән тәэмин ителү дәрәҗәсе волостьның башка авылларына караганда сизелерлек түбән була. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка бүлгән очракта ул 11,85 дисәтинә туры килә. Бу күрсәткеч Азнакайда – 15,3, Сәпәйдә 14,3 дисәтинә.

Авылда 114 хуҗалыкның иманасы була. Шуларның 51 ендә ул – берәр, 41 ендә – икешәр, 13 ендә – өчәр, 7 сендә дүртәр яисә аннан артыграк. Бер имана ул чакта 6,9 дисәтинә тәшкил иткән. Димәк, авылдагы ярты халыкның җире җитәрлек күләмдә түгел. Сигез гаиләнең исә иманасы бөтенләй булмый.

Эш кораллары белән тәэмин ителүдә дә аерма шактый. 92 хуҗалыкта алар җитәрлек күләмдә, 10 хуҗалыкта өлешчә генә, ә 6 хуҗалыкта бөтенләй юк. Мондый хуҗалыклар кирәкле эш коралларын авылдашларыннан хак түләп яисә башка шартка килешеп алып торганнар.

Игенчелектән тыш, терлекчелек тә зур урын тота Туйкәдә. Авыл халкы күп санда эш атлары (248), мөгезле эре терлек (336), сарык (636) һәм кәҗә (117) асрый.

Хуҗалыклар буенча алсак, мал-туар саны шактый аерылуын күрәбез. Эш атларын гына алыйк. 20 хуҗалыкта алар бөтенләй юк. Шул ук вакытта 41 хуҗалык – берәр, 25 хуҗалык – икешәр-өчәр ат тота. Авылда дүрт һәм аннан күбрәк атлылар да була. 10 хуҗалык дүртәр эш аты асраса, 18 хуҗалыкның исә аннан да артып китә. Моннан башка, 13 хуҗалык 63 оя умарта тота.

Ярлы хуҗалыклар арасында төрле эш-һөнәр белән көн күрүчеләр күп була. Мәсәлән, 36 кеше игенчелек белән бәйле эшләргә яллана. Тагын 9 кеше һөнәрчелек белән шөгыльләнә[484].

Гасыр ахырына Туйкә беркадәр зурая. 1889 елда монда 129 хуҗалык һәм 825 кеше исәпләнә, 1897 елда шул ук тәртиптә 154 һәм 822. Авылда мәчет, мәктәп һәм 2 су тегермәне була.

Әлеге мәчет 1870 елда салынган. Монда 1868 елдан егерменче гасыр башына кадәр Мөхәммәтшәриф Моратов хатыйп һәм мөдәррис була. Аның белән бер чорда икенче мулла булып (1879 елдан) алдарак телгә алынган

---

[483] БР МА, И–295 фонд, 3 тасв., 5662 сакл.бер., 6 б.

[484] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 10–15.

Әхмәткәримнең улы Минһаҗетдин эшли. Мөәзин хезмәтен Габделгалим Сәйфетдинов (1857–1902 еллар), аннары аның улы Шәрәфетдин (1903 елдан) башкара[485].

Сүз уңаеннан әйтик, Минһаҗетдин хәзрәтнең уллары да әтисе һәм бабасы юлыннан китәләр. Шул ук мәхәлләдә Сәлахетдин – имам һәм мөдәррис (1910 елдан), Зыятдин мөәзин һәм мөгаллим (1913) була. Минһаҗетдин үзе озын гомер кичереп (ул 1848 елда туган), 1924 елда вафат була.

1907 елда Туйкәдә тагын бер мәчет төзелә. Яңа барлыкка килгән икенче мәхәлләгә имам-хатыйп итеп 38 яшьлек Муса Хөсәенов раслана. Аның белән бер елны Габдулла Хәйруллин да мөәзинлеккә указ ала[486].

1913 елда төбәктә гаять истәлекле вакыйга була. «Самара крестьян хуҗалыгын яхшырту җәмгыяте» («Самарское общество улучшения крестьянского хозяйства») яңа оешкан Туйкә кредит ширкәте аша Туйкә, Уразай, Әсәй һәм Балтач авылларындагы 44 хуҗалыкка мал чөгендере орлыгы өләшә. Моңарчы төбәктә чөгендер игелмәгән.

Шуңа күрә җирле халык өчен бу зур яңалык була. Нәтиҗәне һәркем диярлек зур кызыксыну белән көтә.

Менә көз җитә. Туйкә, Уразай, Әсәй һәм Балтач авылларында 31 хуҗалык беренче тапкыр чөгендер уңышын җыеп ала. 13 хуҗалыкта исә үсентеләрнең һәлак булуы аркасында уңыш булмый.

Туйкәдә чөгендер 13 хуҗалыкта үстерелә. Аларга 0,12 фунттан 1 фунтка (фунт – кадак, гөрәнкә, ягъни 409,5 граммга тигез булган үлчәү берәмлеге) кадәр орлык өләшенә. Статистиклар кем күпме орлык чәчкән һәм уңыш алганын язып баралар. Түбәндәге таблицада ул мәгълүматларны китерәбез.

Таблица 1. Туйкәдә беренче тапкыр мал чөгендере игүче хуҗалыклар (1913 ел)

| № | Хуҗалыклар | Чәчелгән орлык (фунт) | Җыеп алынган уңыш (пот) |
|---|---|---|---|
| 1 | Җамалетдин Сәхабетдинов | 0,5 | 4 |
| 2 | Миңлегалим Тәхаутдинов | 1 | 24 |
| 3 | Солтангали Тәхаутдинов | 0,5 | 7 |
| 4 | Шәрифулла Гыйбадуллин | 0,25 | 1 |
| 5 | Габделгалим Ганиев | 0,5 | 3 |
| 6 | Әхмәтгали Әхмәдиев | 0,5 | 3 |
| 7 | Газый Сафиуллин | 0,5 | 3 |
| 8 | Хәлиулла Гобәйдуллин | 0,5 | 4 |

[485] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С.110, 111; БР МА, И–295 фонд, 14 тасв., 11 сакл. бер.

[486] БР МА, И–295 фонд, 14 тасв., 11 сакл. бер.; 2 тасв., 3 сакл. бер.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 | Гайфулла Хәмидуллин | 0,5 | 3 |
| 10 | Габдерәфикъ Нәфыйков | 0,25 | 3 |
| 11 | Сәлимгәрәй Хәкимов | 0.12 | 2 |
| 12 | Шәрәфетдин Фәтхетдинов | 0,5 | 0,5 |
| 13 | Вәлиулла Мәһдиев | 0,5 | 10 |

Исемлектән күренгәнчә, Миңлегалим Тәхаутдинов һәм Вәлиулла Мәһдиев – иң күп уңыш алучылар. Башка авылларга килгәндә, Уразайдан Исламгали Солтангалиев – 40 пот, Балтачтан Габделвәли Исламголов 16 пот чөгендер үстерәләр. Шулай итеп, беренче ел булуга карамастан, чөгендерчеләр яхшы гына күрсәткечләргә ирешәләр. Моны статистиклар да таный. Алар әйтүенчә, уңышның күпме мәйданнан алынганы билгеле түгел, әмма орлык куе итеп чәчелгән һәм чөгендер җирләре зур булмаган. Шуңа күрә дисәтинәгә исәпләгәндә дә күрсәткечләр югары булачак икән.

Язмабызда телгә алынган «Самара крестьян хуҗалыгын яхшырту җәмгыяте» турында берничә сүз. Оешуына алтынчы ел гына булса да, бу җәмгыять (рәисе А.В. Тейтель) авыл хуҗалыгына яңа культура һәм технологияләр кертү, эшмәкәрлекне үстерү һәм пропагандалау буенча байтак эш башкара[487]. Төбәккә, һәм, әйтергә кирәк, Самара губернасының башка өязләренә дә чөгендер игүне кертү – әлеге күркәм эшчәнлекнең бер чагылышы.

Беренче бөтендөнья сугышы еллары – Туйкә тарихында тирән, җуелмас эз калдырган чор. Авыл күп кенә асыл ир-егетләрен сугышка озата, борчылып хәбәр көтә, бергә кайгыра һәм шатлана. Архив документына таянып, беренче мобилизацияләнүчеләрне атап үтик[488].

Таблица 2. Беренче бөтендөнья сугышына
алынган Туйкә ир-атлары (1914 ел)

| № | Мобилизацияләнүчеләр | Хуҗалык башында калучылар |
|---|---|---|
| 1 | Нигъмәтулла Гыйззәтуллин | Шәмсикамал Әхмәтхуҗина |
| 2 | Әһлиулла Шәрифуллин | Маһидә Әхмәтгалиева |
| 3 | Миңлегалим Шәйхуллин | Бибиҗамал Сәлимгәрәева |
| 4 | Ярулла Шәйхуллин | Миңлебәдәр Мөхәммәдиева |
| 5 | Җәләлетдин Сиражетдинов | Хөсникамал Яхина |
| 6 | Габделхак Ганиев | Гайнекамал Дәүләтбаева |
| 7 | Газый Сафиуллин | Шәмсенур Вахитова |
| 8 | Шәйдулла Галиуллин | Ф. Закирова |

[487] Самарское общество улучшения крестьянского хозяйства. Отчет о деятельности и состоянии средств общества за второе трехлетие его существования (с 7 ноября 1910 г. по 7 ноября 1913 г.). Самара, 1914. С. 9, 161–162.

[488] ТР ДА, 1124 фонд, 1 тасв., 28 сакл. бер., 57, 60 һәм башка битләр.

| | | |
|---|---|---|
| 9 | Хәбибрахман Әхмәтгалиев | Фәхриҗамал Мөхәммәтзарипова |
| 10 | Садыйк Тимергалиев | Фәхриҗамал Фәсхетдинова |
| 11 | Хәбибулла Гәрәев | Гайникамал Дәминова |
| 12 | Гайнанша Әхмәтшин | М. Солтангәрәева |
| 13 | Әхмәтсафа Латыйфуллин | Бибиҗиһан Басыйрова |
| 14 | Габделгани Шәйхелисламов | Миңлеҗамал Камалиева |
| 15 | Галим Габделганиев | Соруржан Әхмәтшина |
| 16 | Әфләтун Гыймадетдинов | Фатыйха Гыйниятуллина |
| 17 | Нуретдин Җамалетдинов | Миңлесафа Сәлимгәрәева |
| 18 | Фәйруша Фәрухшин | Шәмсенур Гашимова |
| 19 | Мөхетдин Гыймадетдинов | Миңлесорур Юнысова |
| 20 | Фатыйх Габделганиев | Габделгалим Ганиев |
| 21 | Сәлахетдин Фәсхетдинов | Таһирә Заһидуллина |
| 22 | Ситдыйк Садыйков | Фәхриҗамал Вәлиева |
| 23 | Җәләлетдин Мифтахетдинов | Шәмсекамал Әхмәтгәрәева |
| 24 | Шәрип Габитов | Кафия Миңлекәева |
| 25 | Ризаэтдин Фәттахетдинов | Гөлҗамал Шәйдуллина |
| 26 | Гыймаделислам Шәйхелисламов | Маһисорур Шакирова |
| 27 | Солтангир Муллагалиев | Бибиҗамал Мөхәммәтгалиева |
| 28 | Шәйхетдин Фәхретдинов | Рабига Шәйхелисламова |
| 29 | Мөҗәһит Минһаҗетдинов | Минһаҗетдин Әхмәткәримов |
| 30 | Рамазан Ризванов | С. Нәбиуллина |
| 31 | Газизулла Хәбибуллин | Талибә Миңлегалиева |
| 32 | Фәхрелислам Шәйхелисламов | Зифа Гыйрфанова |
| 33 | Габделхак Габделгалимов | Хөсникамал Яруллина |
| 34 | Гариф Шәрипов | Шәмсебанат Ибраһимова |
| 35 | Хәйдәр Мөхәммәтвәлиев | Мөхәммәтвәли Шәмсетдинов |
| 36 | Хафиз Зарипов | Бибиҗиһан Габдуллина |
| 37 | Мөхәммәтша Әхмәтшин | Шәмсеҗамал Әхмәтшина |
| 38 | Әхмәтхәбиб Садыйков[489] | Салиха Хәлиуллина |

Әлеге исемлек сугышка алынганнарның гаиләләренә Кәтем казна урман хуҗалыгыннан (лесничествосыннан) ягулык өчен бушлай агач алу максатыннан 1915 елның 8 февралендә төзелә. Аңа Азнакай волосте старшинасы Равил Тәхаутдинов (ул үзе Туйкәнеке, әлеге вазифада 1907 елдан), волость писаре вазифасын башкаручы И. Балашов һәм Бөгелмә өязенең 2 нче участогы земски начальнигы кул куйган. Исемлек лесничествога тапшырылгач, озак та үтми, утын кисәргә 257 нче номерлы рөхсәт билеты бирелә.

[489] Монда Сумароково волостендагы Карамалыдан күчеп килгән.

Документтан күренгәнчә, дәһшәтле сугыш җиле 1914 елда ук дүрт дистәгә якын хуҗалыкка кагыла. Берәүләрнең гаилә башлыклары – ирләре, икенчеләрнең уллары мобилизациягә эләгә. Ирләре сугышка алынган хуҗалыкларда төп авырлык хатын-кызларга (алар исемлектә кыз чактагы фамилияләре белән күрсәтелә) төшә.

1915 елның яз (1 апрель) һәм көз айларында авыл тагын 45 ир-атны сугышка озата. Кемнәр соң алар? Бу сорауга җавапны шул ук документтан табабыз.

Таблица 3. Беренче бөтендөнья сугышына алынган Туйкә ир-атлары (1915 ел)

| № | Мобилизацияләнүчеләр | Хуҗалык башында калучылар |
|---|---|---|
| 1 | Мәүлет Габделвәлиев | Нәфисә Шәрәфетдинова (хатыны) |
| 2 | Фәррах Шиһабетдинов | Шәмсениса Сөләйманова (хат.) |
| 3 | Галәветдин Гыймадетдинов | Сәхибкамал Нигъмәтуллина (хат.) |
| 4 | Сәлимгәрәй Гәрәев | Фатыйма Миңлегалиева (хат.) |
| 5 | Сәлахетдин Латыйфуллин | Хафиза Шәйхелисламова (хат.) |
| 6 | Зарип Галимов | Газизә Камалетдинова (хат.) |
| 7 | Зарип Латыйпов | Галия Шәрифуллина (хат.) |
| 8 | Закир Равилов | Шаһидә Шәрифуллина (хат.) |
| 9 | Шәйхелислам Муллагалимов | Хәдичә Хәлиуллина (хат.) |
| 10 | Миңлегалим Галимуллин | Гайниҗамал Заһидуллина (хат.) |
| 11 | Мөхәммәтгали Тимергалиев | Сәхипҗамал Хаҗиәхмәтова (хат.) |
| 12 | Заһидулла Кәлимуллин | Маһидә Шакирҗанова (хат.) |
| 13 | Мөхәммәтша Әхмәтшин | Зөһрә Габделкадыйрова (хат.) |
| 14 | Газиз Ганиев | Мәгъфүрә Дәүләтшина (хат.) |
| 15 | Нурислам Шәйхелисламов | Миңлегаян Мәүлетбаева (хат.) |
| 16 | Гайса Вафауллин | Хәлиулла Вафауллин (туганы) |
| 17 | Габдерәүф Габделбәдигов | Габделбәдигъ Габделвәлиев (атасы) |
| 18 | Зиннәтулла Гыйззәтуллин | Маһикамал Нәҗметдинова (хат.) |
| 19 | Фәйзулла Заһидуллин | Маһисара Мәвазилева (хат.) |
| 20 | Биктимер Бадыкшанов | Бадыкшан Игътисамов (ат.) |
| 21 | Габдессәлам Габделмәннанов | Ф. Гыймадетдинова (хат.) |
| 22 | Гайса Шәмсетдинов | Әсхәпҗамал Шәмсетдинова (туганы) |
| 23 | Миргали Әюпов | Фатыйма Кәнифова (хат.) |
| 24 | Мөхтәсим Миңлегалиев | Фәрваза Ибәтуллина (анасы) |
| 25 | Габделҗаббар Габдрахманов | Хәдичә Мөхәммәтвәлиева (хат.) |
| 26 | Фатыйх Галимуллин | Рәхимә Габдуллина (хат.) |
| 27 | Нургали Әхмәтвәлиев | Әхмәтгалим Әхмәтвәлиев (туганы) |
| 28 | Садретдин Сәетбатталов | Мәгъсүмә Әюпова (хат.) |
| 29 | Газизҗан Сәлимҗанов | Фәхриҗамал Мөхәммәтгалиева (ан.) |

| | | |
|---|---|---|
| 30 | Сәлахетдин Гәрәев | М. Биктимерова (хат.) |
| 31 | Мөхәммәдьяр Әхмәдиев | Гыйззинур Әхмәдиева (туг.) |
| 32 | Равил Ризванов | Якут Гомәрова (хат.) |
| 33 | Биктимер Хәлиуллин | Бибифаидә Әхмәтшина (хат.) |
| 34 | Кәлимулла Җамалетдинов | Мөгаллимә Хәйруллина (хат.) |
| 35 | Фәтхетдин Габделгамилов | Габделгамил Хәкимов (ат.) |
| 36 | Мәрдәнша Әхмәтшин | Бибикамал Хәйбуллина (хат.) |
| 37 | Исмәгыйль Җомаголов | Фәхрикамал Баһманова (хат.) |
| 38 | Хәйдәр Гайфуллин | Гайфулла Хәмидуллин (ат.) |
| 39 | Таҗетдин Фәрхетдинов | Фәрхетдин Гыймадетдинов (ат.) |
| 40 | Хәбибулла Гарифуллин | Гарифулла Хәмидуллин (ат.) |
| 41 | Габидулла Шәфигуллин | Шәфигулла Сафиуллин (ат.) |
| 42 | Биктимер Хөснуллин | Хөснулла Хәлиуллин (ат.) |
| 43 | Әхмәтгалим Хәсәншин | Хәсәнша Әхмәтҗанов (ат.) |
| 44 | Латыйфулла Нәбиуллин | Нәбиулла Вәлиуллин (ат.) |
| 45 | Михаил Николаев | Николай Михайлович Николаев (ат.) |

Шулай итеп, ел ярым эчендә генә авылдан 83 кеше мобилизацияләнә. 1916 һәм 1917 еллар буенча, кызганычка каршы, мәгълүматлар юк. 1915 елдан соң да шул чама кеше хәрби хезмәткә алынган дип фараз кылсак, авылда ир-улларын сугышка озатмаган гаиләләр бик аз кала түгелме? Шуннан гына сугыш афәте күпме кайгы-хәсрәт һәм авырлыклар алып килгәнен чамаларга була.

Сугыш башланган елны староста булып Заһидулла Кәлимуллин тора. Архивта Туйкә авыл җәмгыяте старостасы мөһере (анда «сельский староста Тойкинского общества Бугульминского уезда» дигән сүзләрне укырга була) сугылган документлар еш булмаса да, очрый. 1915 елның 1 апрелендә бер төркем авылдашлары (12 кеше) белән Заһидулла да мобилизацияләнә. Хуҗалыкны алып бару хатыны Маһидә (кыз чактагы фамилиясе Шакирҗанова) җилкәсенә төшә. Патша чорында авыл хужалыклары исәбен соңгы тапкыр алганда (1916 ел) Туйкәдә 201 хуҗалыкта 820 кеше яши. Монда 436 ат (шул исәптән 362 эш аты), 567 мөгезле эре терлек (280 сыер), 1532 сарык һәм 157 кәҗә исәпләнә. Чәчүлекләр мәйданы 691,57 дисәтинә тәшкил итә. Шуның яртысын диярлек арыш (320,30 дисәтинә), калган өлешен солы (110,38), бодай (81,11), карабодай (64,42), борай (49,52), борчак (39,34) һәм тары (26,50) алып тора[490].

Илдә совет хакимияте урнашкач, авылларда башкарма комитетлар оештырыла. Туйкә халкы 1918 елда авыл комиссары итеп Хәбибулла Биктимеровны, башкарма комитет әгъзалары итеп Мөхәммәтгали Тәхаутдинов һәм Шаһидулла Галиуллиннарны сайлый. Ике елдан халык санын алу үткәрелә. Туйкәдә 986 кеше теркәлә.

[490] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 37 сакл. бер.


Особое совѣщаніе для обсужденія и объединенія мѣропріятій по продовольственному дѣлу.
ВСЕРОССІЙСКАЯ СЕЛЬСКОХОЗЯЙСТВЕННАЯ ПЕРЕПИСЬ 1916 ГОДА.

Губернія, область: Самарская. Уѣздъ, округъ: Бугульминскій
Волость, станица и пр.: Азнакаевская. Общество
Селеніе: Туйкино
Фамилія, имя и отчество домохозяина: Ахматханнин Ахмадъ
Сословіе или разрядъ крестьянъ: башкиръ. Національность: татаринъ
Приписной, посторонній, бѣженецъ. (Подчеркнуть).
№ по списку домохозяевъ: 200

Скотъ въ 1916 году (во время переписи).
Скотъ въ 1915 году (годъ назадъ).

*1916 елгы хуҗалыклар санын алу документы.*
*Сословиесе башкорт, милләте – татар дип язылган*

Әмма аларның шактые 1921 елгы ачлыктан үлә. Шуңа күрә хәтта 1926 елда да, күпме вакыт үтүгә карамастан, халык элеккегә караганда азрак, барлыгы – 931. Авыл Азнакай волосте Бөгелмә кантонына керә[491].

Репрессияләр башлангач Туйкәдән дә читкә сөрелүчеләр була. 1930 елда, мәсәлән, Шәйдулла Галиуллин икенче категория белән раскулачивать ителә.

1989 елда Туйкәдә 331 кеше исәпкә алына. Әмма аннан соңгы елларда халык саны сизелерлек кими. 1997 елда монда нибары 259 кеше теркәлә. Авылда урта мәктәп эшли[492].

---

[491] Шунда ук, Р–1167 фонд, 1 тасв., 160 сакл. бер., 792–793 б.б.; Р–1296 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер.

[492] Авыл тарихы 1997 елда язылды. Шуннан соң ике дистә елга чаклы вакыт үткәч, бу юллар авторы кулына Гарәф Фәсхиев (1907–1978) язган Туйкә авылы тарихы килеп керде. Аны безгә Әлмәт шәһәре һәм районы хәрби комиссары полковник Ришат Раин улы Сабиров җибәрде. Әлеге 12 битлек хезмәттә Туйкәнең башлангыч чорыннан алып XX гасырның алтмышынчы елларына чаклы тарихы бирелә. Шунсы гаҗәп, Туйкә картның килеп утыру, «башкорт»тан җир эзләп йөрү тарихы архив документлары белән раслана. Гарәф Фәсхиевнең бу бик әһәмиятле язмасын килене Роза (1953–1983 елларда Туйкә мәктәбендә укыткан) тәртипкә салып, Туйкә музеена тапшырган булган. Бабасының истәлекләрен компьютерда җыеп бирүче Туйкә авылында туып-үскән, бүгенге көндә Менделеев районы Тихоново авылында урта мәктәптә җитәкче булып эшләүче Фәсхиева (Яһудина) Венера Индус кызы була. Гарәф Фәсхиевнең тарихны белеп, ата-бабаларыннан һәм авылдашларыннан ишеткән, үзе башыннан кичкән истәлекләрне кадерләп язып калдыруы гына түгел, аның хезмәтен халыкка җиткергән әлеге хатын-кызлар да сокланууга лаек.

# § 17. Уразай

Азнакай шәһәреннән ерак түгел, мәһабәт Чатыр тау итәгендә уртача зурлыктагы күркәм бер авыл урнашкан. Уразай дип атала ул, моннан тыш халык телендә Аю авылы дигән атамасы да бар аның. Рәсми чынакларда да авылның кайвакыт Аю дип язылуы күзәтелә (мәсәлән, 1795 елгы ревизия документында[493]).

Чатыр тау Татарстанның иң биек (321 м) ноктасы санала. Тауның исеме ничек һәм кайчан килеп чыгуы турында халыкта шундыйрак риваятьләр йөри. Аларның берсе Пугач яулары белән бәйле. Е. Пугачев гаскәренең бер өлеше тау башында чатырлар корып урнашкан да, шул вакыйга уңаеннан тауның хәзерге атамасы барлыкка килгән. Икенче риваять буенча, тауда бакыр рудасы чыгаручылар чатырлар корып яшәгәннәр һәм шуның истәлеге географик атамада сакланган. Әмма шул тирәдә Чатыр (тарихи чыганакларда русча “Четыр”) елгасы булуын күпләр, мөгаен, белми торгандыр. Тау исеме шуның белән бәйле булу мөмкинчелеген Сәпәй авылы тарихында күрсәтеп үттек.

Риваятьләрдән авыл атамасына бәйләнешле аеруча игътибарга лаек. Булачак авыл урынына беренчеләрдән булып Уразай карт килеп утыра. Биек тау һәм Стәрле елгасы арасындагы бу урынның тирә-ягы калын урман белән капланган була ул чорда. Төрле-төрле җәнлекләр, шул исәптән күп санда аюлар да тереклек иткән анда. Элгәре авылның ике төрле аталуы (Уразай һәм Аю) шуннан икән.

Инде дә документларга мөрәҗәгать итсәк, шуларның берсеннән Юрмый волостеның старшинасы Урманай Уразаев булуы хакында беләбез. Волость халкы ризалыгын алып, ул иптәшләре белән 1745 елның гыйнваренда үзләренең Зәй буендагы шактый зур җирләрен Аверьян Назар улы Ждановка сата[494]. Әлеге старшинаның этисе Уразай карт кайчандыр Уразай авылына нигез салучы икәнлеге шик уятмый. Гадәттә, яңа урынга күчеп килүчеләр арасында дәрәҗәле кеше булса, авыл шуның исеме белән аталган.

Уразай карт та улы кебек үк зур дәрәҗәле кеше булгандыр. Дәрәҗәнең күп очракта атадан улга күчүе ул чор өчен гадәти күренеш.

Аннан соң, Уразай авылы элек-электән Юрмый волостена кергән. Волость старшинасы – Урманай Уразаев Урманай авылына нигез салган булуы мөмкин. Бу ике авылга нигез салучылар арасында туганлык җепләре булу хакында истәлек халык хәтерендә бүгенгәчә сакланган. Мәсәлән, Урманай авылы тарихына багышланган фотоальбомда «Уразай авылына нигез салучы, хак булса, Урманай картның улы» дигән юллар була.

---

[493] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 215 б. а.

[494] МИБ. Т. 5. М., 1960. С. 185.

Монда бер генә нәрсә төгәл түгел. Киресенчә, Урманай үзе Уразай картның улы була. Нишлисең, гасырлардан гасырларга күчкән, бары халык хәтерендә сакланган истәлекләрдә мондый гына ялгышлыклар булгалый.

Боларны ачыклагач, Уразай авылына кайчан нигез салынган соң, дигән сорау туа. Урманай Уразаевның 1745 елда җир сату турында килешү төзегәнлеге мәгълүм булгач, аның атасы Уразай карт бу килешүгә чаклы, ягъни XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башларында яшәгән дип уйларга кирәк. Чөнки Уразайның улы Урманай – 1745 елга чаклы ук балигъ булган һәм зур дәрәҗәгә ирешкән кеше. Моны ачыклау исә, авыл чама белән XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башларында барлыкка килгән дигән фикер тудыра.

Уразай авылы халык санын алу документларында беренче тапкыр 1762 елда телгә алына. Ревизия исемлегендә күпчелекне бертуган Гомәр (48 яшь), Мәсгут (29), Госман (43) һәм Йосып (30) Мурзиннар һәм тагын берничә гаилә (барысы 22 ир-ат) тәшкил итә. Болар якындагы Сәпәй авылыннан килеп утырганнар (чыганакта «*в перепись написаны были в деревне **Сепеевой**, а ныне по указу из Уфимской провинциальной канцелярии жительствуют в деревне Мурзаевой*», дип язылган). Тагын Әлкәй (3 ир-ат) һәм Кала Елга (4) авылларыннан да килүчеләр була[495]. Болар (барысы 29 ир-ат) бу чыганакта ясаклы татар, аннан соңгы халык санын алулар вакытында типтәр сословиесендә күрсәтелә.



*Уразай авылы ясаклы татарлары теркәлгән 1762 елгы ревизия документы фрагменты*

Аз санлы башкорт сословиесендәге татарлар турында XVIII гасыр ахырына чаклы нинди дә булса мәгълүмат юк, әмма алар да бу чорда авылда яшәгән, дип фараз кылабыз. Чөнки биләмәче (вотчинник) Уразай картның чыгышы шул катлауга карый.

[495] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3801 сакл. бер., 504–505 б.

1795 елда авыл 33 хуҗалыктан тора. Халыкның төп өлешен «типтәр»ләр (72 ир-ат һәм 78 хатын-кыз; Гомәр һәм Мәсгут Морзаевлар һәм башкалар)[496] һәм ясаклы татарлар (37 һәм 35)[497], калган өлешен «башкорт»лар (19 һәм 16) һәм йомышлы татарлар (8 һәм 7)[498] тәшкил итә. Ясаклы татарлар халык телендә «казан татарлары» дип йөртелгән. Кантон системасына үзгәрешләр кертелгәнче (1855 ел) Уразай «башкорт»лары – 12 нче башкорт кантонында, «типтәр»ләр исә Бөгелмә өязенең 5 нче типтәр командасында күрсәтелә.

1816 елгы мәгълүматлар аерым игътибарга лаек. Авылда элеккечә типтәр сословиесендәге татарлар (103 ир-ат; 35 хуҗалык) күпчелекне тәшкил итә. Аларның бабалары Юрмый волосте биләмәчеләре белән договор төземичә һәм оброк түләмичә (чыганакта «без договора и безоброчно») килеп утырганнар. Башкорт сословиесендәге татарлар 9 хуҗалыкта (21 ир-ат) яши. Йомышлы татарлар 14 ир-ат исәпләнә, әмма болардан 4 кеше Сәпәйдә яши[499]. Тирә-як авыллардагы кебек, Уразайда да бер мәчет була.

Әлеге мәгълүматка берникадәр төгәллек кертик. 1816 елгы ревизия документында типтәр сословиесендәге татарлар 100 ир-ат һәм 103 хатын-кыз (37 хуҗалык) күрсәтелә. 1818 елда төзелгән аерым исемлек белән Габделгафур (2 яшь; Гали Гомәров улы), аның анасы һәм апасы теркәлгән. Болар хакимиятнең 1814 елның 30 августы манифесты нигезендә «типтәр» булып язылган, читтән килеп утырган кешеләр[500].

«Типтәр»ләрдән аермалы буларак, 1816 елда йомышлы татарлар ике исемлек белән күрсәтелә. Беренче исемлектә 7 ир-ат һәм 7 хатын-кыз (4 хуҗалык) теркәлгән. Аларга лашман бурычын башкару йөкләнгән (чыганакта «служилые татары, исправляющие лашманную повинность» дип язылган). Бу төркемгә Габделгафар Мәксүтов (1766–1815; улы Абдул), Габделхаликъ Мәксүтов (39), Мөхәммәдьяр Габдерәхимов (13; энесе Әхмәтҗан) һәм Габдрахман Әсәев (1747–1812; улы Габделлатиф (39; анықы Мөхәммәтшәриф, Мөхәммәткәрим)) керә[501].

Йомышлы татарларның икенче исемлегендә шулай ук 7 ир-ат һәм 7 хатын-кыз (5 хуҗалык) исәпкә алынган. Болар түбәндәге хуҗалыклар: 1) Бәшир Мансуров (43 яшь); 2) Әхтәм Мансуров (30; аның туганы Габделбәшир); 3) Гали Гомәров (аның уллары Габит, Әхмәт; боларның 1813 елдан кайда яшәве билгесез); 4) Рәхмәтулла Мәтколов (1764–1815; уллары Мөхәммәткәрим, Мөхәммәдьяр); 5) Фәтхулла Мәтколов (45; улы Зәйнулла)[502].

---

[496] БР МА, И–138 фонд. 2 тасв., 24 сакл. бер., 476–483 б. а.

[497] Шунда ук, 23 сакл. бер., 248–249 б. а. Болар турында Балтач авылы тарихына багышланган очеркта тулырак әйтелә.

[498] Шунда ук, 22 сакл. бер., 117–117 б. а.

[499] БР МА, И–1 фонд. 1 тасв., 450 сакл. бер., 126 б.

[500] Шунда ук, И–138 фонд, 2 тасв., 168 сакл. бер., 350–361 б.

[501] Шунда ук, 197 сакл. бер., 511–514 б.

[502] Шунда ук, 925–928 б.

Шулай итеп, ике исемлек буенча Уразайда йомышлы татарлар 14 ир-ат һәм 14 – хатын-кыз (9 хуҗалык) тәшкил итә. Икенче исемлектәге 1813 елдан кайда яшәве билгесез дип язылган Гали Гомәров хуҗалыгы Сәпәйгә күченгән дип уйларга кирәк.

Авылның көнкүрешенә караган мәгълүматлар кызыклы. Игенчелек һәм терлекчелек – халыкның төп шөгыле. Хатын-кызлар кыр эшләреннән буш вакытта йоннан, киндер басаларыннан җеп эрләгәннәр, киндер, тукыма тукыганнар. Ирләрнең бер өлеше (башкорт сословиесенә кергәннәре) чиратлашып (5 йорттан атлы ике кеше) ел саен Оренбург сызыгындагы (линиясендәге) төрле крепостьларга хәрби хезмәт үтәргә йөргәннәр. Хезмәт иткәндә алар жалованье һәм «атларга ремонт алганнар». Типтәр сословиесендәгеләр исә Оренбург шәһәрендәге 2 мең атлы типтәр полкына чират буенча хәрби хезмәткә алынганнар, полк чыгымнарын түләргә мәҗбүр ителгәннәр. Ясаклы татарлар казнага оклад (салым) түләгәннәр[503].

XIX гасыр уртасына авылда яшәүчеләр саны шактый арта. 1859 елда Уразайда типтәр (33 хуҗалык) һәм башкорт (22) сословиеләренә караган 328 ир-ат һәм 330 хатын-кыз (55 хуҗалык) татар теркәлә. Алар 23 нче кантонның 5 нче юртасына карый. Хөсәен Габдессаттаров (43) һәм Рәхмәтулла Фәтхуллин (59) указлы мулла вазифасын башкаралар. «Типтәр»ләр Ногман Гаделшин һәм Ибраһим Сәйфелмөлеков указлы мулла булып, беренчесе Кама-Исмәгыйль авылына, икенчесе Баулыга күчеп утыра. «Типтәр» Кәримулла Фазуллин Яланкүлгә барып урнаша. Ревизия исемлегенең титул битендә барлык халык «башкорт», эчке битләрендә күпчелеге – «типтәрдән башкорт» (чыганакта «из тептярей башкиры») дип язылган[504]. Барысын «башкорт» дип язуның сәбәбе булып «типтәр»ләрне 1855 елда «Башкорт» гаскәренә күчерү тора.

«Типтәр»ләрнең «башкорт» булып китүе Самара губернасы буенча белешмә әдәбиятта да чагыла. Андагы мәгълүмат Уразай (Аю) авылында 1859 елда 370 ир-ат һәм 403 хатын-кыз (98 хуҗалык) «башкорт» һәм казна крестьяннары яшәвен күрсәтә[505]. Казна (дәүләт) крестьяннары дип элеккеге ясаклы татарлар аталган.

Имана җир 1859 елда исәпкә алынган ир-ат санына һәм сословиеләргә карап бүленә: «типтәр»ләргә һәм ясаклы татарларга җан башына – 6,9, «башкорт»ларга 15 дисәтинә туры килә.

1885 ел ахыры – 1886 ел башында Уразай Азнакай волостенда зур авыллардан санала. Анда барлыгы 193 хуҗалык исәпләнә, 505 ир-ат һәм 497 хатын-кыз яши. Сословиеләр буенча алганда, күпчелекне типтәрләр (364 ир-ат

---

[503] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 250–253 б.

[504] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 757 сакл. бер., Л. 24–55 б.

[505] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

һәм 358 хатын-кыз), калганын башкортлар (127 һәм 124) һәм дәүләт крестьяннары (14 һәм 15) тәшкил итә.

Авыл җәмгыятенең 3 мең дисәтинәдән артык имана җире булган. Әмма сословиеләргә карап җир белән тәэмин ителү шактый аерылган: «типтәр»ләрнең 1696,3 дисәтинә җире булса, аз санлы «башкорт»ларның ул 1345 дисәтинәдән арткан, элеккеге ясаклы татарларга 83,7 дисәтинә туры килә.

Авылда йортлар хуҗалыклар санына караганда күбрәк (барлыгы 276) була. Алар барысы да агачтан салынган, кара-каршы йортлар да була.

Игенчелек һәм терлекчелек – авыл халкының төп шөгыле. Уразайда җире булмаган гаиләләр бик аз (6), аларның да бишесе читтә яшәгән. Хуҗалыклар күп санда эш атлары (455 баш), мөгезле эре терлек (459), сарык (643) һәм кәҗә (265) тота. Әйтергә кирәк, хуҗалыкларга карап мал-туар саны шактый аерылган. Эш атларын гына алыйк. Кайберләрендә (26 хуҗалык) алар бөтенләй булмый яисә берәр генә (55) була. Калганнарында ике-өч (56 хуҗалык), дүрт (13) һәм дүрттән күбрәк (27) эш атлары исәпләнә.

Игенчелек һәм терлекчелек күпләр өчен төп яшәү чыганагы санала. Әмма кайберәүләргә гаиләләрен туйдыру һәм салым түләү өчен бу гына җитми. Шунлыктан алар (40 хуҗалык) кыр эшләреннән буш вакытта игенчелеккә бәйле булмаган төрле һөнәрләр белән шөгыльләнгәннәр. Бигрәк тә акбур (алебастр) чыгару зур үсеш ала[506].

Бу – күп хезмәт сорый торган һөнәр. Белешмә әдәбиятта ул болай тасвирлана: «*Процесс производства при добыче алебастра сводится к следующему: наламывается порода (известняк) кусками большей или меньшей величины, тут же в обрыве горы делаются круглые ямы для обжига до 2,5 арш. в диаметре и до 3 арш. вглубь (по горизонтали) с выходом наружу. Порода складывается сводом, так что внутри образуется место для дров. Обжигание производится в течение 12 часов, затем камни вынимаются, разбиваются молотом и просеиваются на железном решете (грохоть). Иногда размол делается на мельнице, но полученный таким образом продукт менее прочен, чем раздробленный ручным способом*»[507].

Акбурга ихтыяҗ беркайчан да өзелмәгәнлектән, ул күп чыгарылган һәм сатылган. Күн заводлары приказчиклары исә аны еракларлардан килеп күпләп сатып алып китә торган булганнар. Шуңа күрә акбур чыгару һәрвакыт үз-үзен аклаган һәм шактый гына табыш китергән. Кайбер хуҗалыкларның еллык табышы 200 сумнан арткан. Мондый акчага яхшы гына 2 эш аты алырга мөмкин булган ул чакта.

[506] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 12–17.

[507] Кустарные промыслы Уфимской губернии. Уфа, 1912. С. 129.

Умартачылык белән дә шөгыльләнүчеләр күп була Уразайда. 24 хуҗалык 122 баш умарта тоткан. Ул чорда умартачылык өчен шартлар күпкә яхшырак булган: якында гына урман, хуш исле чәчәкле киң яланнар...

Монда сәүдә эшчәнлеге дә үсә. Азнакай волостенда (ул Әгерҗе, Азнакай, Әсәй, Балтач, Сәпәй, Туйкә, Уразай һәм Александровка авылларыннан торган) тугыз лавка булса, шуның дүртесе Уразайга туры килә. Кибет хуҗалары күпчелек товарны Сәпәй базарыннан һәм Бөгелмәдән алып кайтканнар.

1889 елда Уразайда 200 хуҗалыкта 1135 кеше яши. Авылда элеккечә бер мәчет эшләп килә. Уңайлы җирләр 2974 дисәтинә, уңайсызлары (чокыр-чакыр, ташлы урыннар һәм башкалар) 109 дисәтинә тәшкил итә[508].

Әлеге статистик әдәбиятта ни өчендер бер генә мәчет күрсәтелә. Ә бит авыл бу чорда ике мәхәлләдән тора. Беренче мәхәллә мәчетендә (ул 1880 елда яңадан салына) хатыйп вазифасын 1881 елдан Хаҗиәхмәт Хөсәенов башкара. Икенче мәхәллә мәчете 1881 елда төзелә. Монда хатыйп булып 1882 елдан Гарифулла Мөхәммәтшәрипов тора[509].

Гасыр ахырына Уразайда хуҗалыклар саны шактый арта. 1897 елда 233 хуҗалык[510], 630 ир-ат һәм 606 хатын-кыз исәпләнә. Бу күрсәткечләр буенча ул Азнакай волостенда дүртенче урында тора. Авылда 2 мәчет, бер мәктәп эшли.

Стәрле елгасы гасыр ахырында да мул сулы елгалардан санала һәм тегермән тоту өчен уңайлы була. 1897 елгы мәгълүматлар анда авылның өч тегермәне булуын күрсәтә. Шулардан беренчесе – Хөсәенов, икенчесе Хәлиуллин фамилияле кешеләрнең милке икәнлеге билгеле[511].

Татарстан дәүләт архивында сакланучы 1900 елгы документлар авылның ул чактагы тормышын тулырак күз алдына китерергә ярдәм итә. Шуңа күрә аларга махсус тукталып үтүне кирәк саныйбыз.

Авыл элеккечә Азнакай волостена керә. 1892 елдан волость старшинасы булып Уразайдан Мөхәммәтзәки Габсаттаров (40 яшь) тора. Аның гаиләсендә хатыны (35 яшь), анасы (80 яшь), 2 улы (3 һәм 13 яшьләрдә), 2 кызы (7 һәм 10 яшьләрдә) була. Үзенә җитәрлек мал-туар (4 эш аты, 3 сыер, 10 сарык һәм 1 кәҗә) тота, чәчүлек җирләре шактый зур мәйданны алып тора. Мәсәлән, арыш басуы гына 361,9 дисәтинә тәшкил итә. Җирнең бер өлешен ул авылдашларыннан һәм казнадан (Чалтаймас участогыннан) арендага алган була. Шул кадәр зур мәйданда иген игү бер кеше кулыннан гына килә торган эш түгел. Шуңа күрә кыр эшләре вакытында эшчеләр (16 кеше) яллый торган булган.

---

[508] Список населенных мест Самарской губернии по сведениям 1889 г. Самара, 1890. С. 59.

[509] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл. бер.; 14 тасв., 11 сакл. бер.

[510] Шул исәптән 169 хуҗалыкта типтәр сословиесендәге татарлар яши.

[511] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 111–112.

Бу елларда авылның писаре Мөхәммәтгалим Мөхәммәтгалиев (52 яшь), мәктәп укытучысы Закир Мөхәммәтлатыйпов (26) була. Язын (1 ай), җәен (3 ай) һәм көзен (1 ай) пожар караулында Шакир Шәймөгинов (46 яшь) тора.

Авылда элеккечә 2 мәчет. «Башкорт» очы мәчетендә Хаҗиәхмәт (бу чыганакта, ни сәбәпледер, исеме «Хаҗимулла» дип язылган) Хөсәенов (60 яшь) указлы мулла булып тора. Ул хатыны һәм 5 улы белән яши. Алар бер хуҗалык булып ике өйдә торалар, чөнки хәзрәтнең икенче улы (25) өйләнгән була. Мулланың барлык уллары диярлек – гыйлемле кешеләр. Икесе Казан һәм Бәйрәкә мәдрәсәләрендә белем алганнар, төпчек улы исә Бәйрәкә мәдрәсәсендә укуын дәвам итә.

Хаҗиәхмәт хәзрәтнең хуҗалыгы зур гына була: 5 эш аты, 11 баш мөгезле эре терлек, 34 сарык һәм 5 кәҗә. Имана җирендәге чәчүлеге 168,9 дисәтинә тәшкил итә. Моннан тыш сатып алган басуында да шактый гына чәчүлеге була. Әлбәттә, кыр эшләре вакытында ул күп санда (32) эшчеләр яллаган. Ә хуҗалыгында исә даими эшкә ялланган бер эшче эшләгән.

Шул ук мәхәлләдә икенче мулла булып Кашшафетдин Хөсәенов (34 яшь) тора. Аның гаиләсе зур түгел: хатыны (25) һәм кызы (3). Ә менә хуҗалыгы Хаҗиәхмәт хәзрәтнекенә караганда зуррак: 18 эш аты, 22 баш мөгезле эре терлек, 102 сарык һәм 11 кәҗә. Төп чәчүлеге 240 дисәтинәдән тора. Имана җире аз булганлыктан, ул 200 дисәтинә җир сатып ала.

Харис Хөсәенов (56 яшь) мәхәлләдә мулла ярдәмчесе санала. Гаиләсендә анасы (85), ике хатыны (55 һәм 35 яшьләрдә), бер улы (25 яшь) һәм 3 кызы була. Ул да күп санда мал-туар тота, зур мәйданда иген үстерә. Башкалардан аермалы буларак, аның 3 йорты, ирле-хатынлы даими яллы эшчеләре була.

«Типтәр» очында Гариф Шәрипов (53 яшь) указлы мулла була. Ул төп чыгышы белән Әсәй авылыннан. Семьясында хатыны, 2 улы һәм 4 кызы була. Аның хуҗалыгы зурлардан саналмый: икешәр йорты, эш аты, сыеры һәм 3,90 дисәтинә чәчүлеге.

Шул ук мәхәлләдә икенче мулла – Мөхәммәтзакир Шәмсетдинов (49 яшь). Ул ике хатыны (50 һәм 23 яшьләрдә), мәдрәсә тәмамлаган бер улы (23) һәм 3 кызы белән яши. Мулланың 3 өе һәм умарталыгы (4 баш) була. Ә менә мал-туары һәм чәчүлеге Гариф хәзрәтнеке чамасындарак. Бер даими яллы эшче тота.

Мәчетнең мөәзине булып Латыйфулла (дөрес исеме – Лотфулла) Галиуллин (40 яшь) тора. Ул дин әһелләре арасында бердәнбер ярлы кеше. Хатыны (27) һәм бер улы (8), 2 кызы белән яши.

Авылда 3 тегермән булуы хакында алдарак әйтелгән иде. Тегермән хуҗалары арасында зур байлыгы белән Солтангир Шонкаров (58 яшь) аерылып тора. Аның 3 йорты (берсе ике этажлы, икенчесе таштан салынган) була. Ул хатыны (30 яшь), 4 улы, 2 кызы, килене һәм оныгы белән бер хуҗалык булып яши. Тегермәне үзенең хуторы аша агучы Стәрле елгасында урнашкан. Барлык чәчүлек җире 1850 дисәтинә тәшкил итә. Аның 13 эш аты, 13 сыеры,

190 сарыгы һәм 25 кәҗәсе була. Хуҗалыкны алып барыр өчен ул ике даими яллы эшче тоткан. Ә инде кыр эшләре вакытында аның хуҗалыгында йөздән артык көнлекче эшләгән. Шушы зур хуҗалык һәм тегермәннән башка, С. Шонкаровның постау (сукно) басу машинасы да була. Билгеле, болар барысы да хуҗага зур табыш китергән. Тик шунысы гаҗәп, Шонкаровларның гаиләсендә укый-яза белүче кеше булмый. Байлык артыннан куып, мәктәп-мәдрәсәләрдә укуны кирәк тапмаганнар, күрәсең.

Икенче тегермәннең хуҗасы – Гатиатулла Галиуллин (53 яшь). Аның ике хатыны (49 һәм 22 яшьләрдә), бер улы (24 яшь) һәм 3 кызы була. Ул да авыл байларыннан санала. Таштан салынган 3 йорты, 4 оя умартасы була. Тегермәнендә даими яллы эшче тоткан; 6 аты, 8 сыеры, 17 сарыгы, 3 кәҗәсе һәм зур мәйданда чәчүлеге (124,7 дисәтинә) була. Кыр эшләре вакытында берьюлы шактый күп эшче (30 һәм аннан күбрәк) яллаган, шуларның берсе җәй буена аның хуҗалыгында даими эшләгән.

Өченче тегермән – Газизулла Хәлиуллинныкы (63 яшь). Ул кара-каршы йортта хатыны (63) һәм 2 улы белән яши. Мал-туары һәм чәчүлекләре аз була.

1897 елгы мәгълүматлар буенча тегермән хуҗаларының берсе Хөсәенов иде. 1900 елда аның хуҗалыгында тегермән күрсәтелми. Ул аны башка авыл кешесенә сатмадымы икән? Чөнки югарыда телгә алган тегермән хуҗалары төп Уразай кешеләре һәм аларның 1897 елда да тегермәннәре булган.

Авылдагы һәм якын-тирәдәге тегермәннәрдән халык зур файда күргән. Аларның күп булуы һәм үзара конкуренция шартларында эшләве аркасында тегермәннәр янында озын-озын чиратлар булмаган һәм он тарттыру да арзанракка төшкән. Тагын шунысын да онытмаска кирәк, тегермәннәр авылдан өч кешене эш белән дә тәэмин иткән. Аларның берсе (Мөхәммәтсабир Сәйфуллин) – Уразай, икенчесе (Хәбибулла Ягъфәров) – Азнакай һәм өченчесе (Хисмәтулла Рәхмәтуллин) Әсәй авыллары тегермәннәрендә эшләгәннәр.

1900 елда авылда бер генә лавка була. Аның хуҗасы – Солтан Солтангиров (37 яшь). Ул бакалея товарлары белән сәүдә итә, яшь чагында мәдрәсәдә укыган; сәүдәгәрнең, ни сәбәпледер, гаиләсе булмый. 5 эш аты, 3 сыер, 2 кәҗә тота һәм арендага җир алып зур мәйданда (410,6 дисәтинә) иген игә. Кыр эшләре вакытында күп (50-гә чаклы) эшче яллый, моннан тыш, даими эшчесе була.

Әлбәттә, авылда сәүдә белән шөгыльләнүчеләр саны бер С. Солтангиров белән генә чикләнми. Шәрифулла Галиуллин (35 яшь), мәсәлән, лавка тотмыйча, йомырка һәм вак-төяк товарлар белән сату итә. Аның гаиләсе зур түгел (хатыны, 2 улы һәм кызы), шулай да ике өе була. 3 эш аты, 3 сыер, 6 сарык һәм 2 кәҗә асрый. Барлык чәчүлек җире 10,5 дисәтинә тәшкил итә.

Авылда тагын ике алыпсатар була: берсе – Муса Хәсәнов (40 яшь), икенчесе – Әхмәтша Исхаков (43). Муса – ел буена, Әхмәтша исә кыш айларында гына вак-төяк сәүдә белән шөгыльләнә.

Авылда тимерчеләр һәм слесарьлар шактый була. Аларның исем-фамилияләрен атап китик. Габделгазиз Ганиев (55 яшь), Сәлимгәрәй Җиһангиров (39), Шәйхелислам Шәйхетдинов (39) – тимерче, Миңлегали Ганиев (43), Мостафа Мөссәләмов (30), Хәмзә Батыршин (21) слесарь булалар.

Кагыйдә буларак, җире, мал-туары аз кешеләрнең күпчелеге төрле һөнәр ияләре. Андыйлар арасында киез итек басучылар (Әмин Галимов, Хисаметдин Камалетдинов, Мөхәммәтша Хөррәмшин, Латыйп Хөррәмшин, Фәйруша Хөррәмшин, Фазулла Хәсәншин), тегүчеләр (Әхмәтлатыйп Вәлиуллин, Хәмидулла Ганиев), мич чыгаручы (Вилдан Моратхуҗин) һәм чабатачы (Зиннур Мостафин) күзгә ташлана.

Акбур чыгару XX гасыр башына туктаган, ахыры, телгә алынмый. Ә менә таш эшкәртүче (кисүче) берничә кеше күрсәтелә. Мондый һөнәрчеләр булу аркасындадыр, XIX гасыр ахырыннан авылда таштан салынган йортлар да күренә башлый. 1900 елга аларның саны биштән арта.

Авылда күп кенә хуҗалыклар (егермегә якын) умарта тоткан. Шактый кеше байларга ялланып эшләгән. Алар арасында Микулин волостендагы Елачич имениесенә, Чәкән байларына барып эшләүчеләр дә була[512].

Егерменче гасыр башында Уразай элеккечә зур авыллардан санала. Әмма 1909 елда булган 2 янгын авылга зур зыян сала: барлыгы 30 хуҗалык яна[513].

Бу чорда беренче мәхәллә мәчетендә кайбер үзгәрешләр була. Имам Мөхәммәтзакир Шәмсетдинов 1904 елның февралендә дөнья куя. Шул ук елның июленнән имам вазифасын Мөхәммәтгали Әхмәтҗанов үти башлый. Ике елдан хатыйп Хаҗиәхмәт Хөсәенов тә вафат була. Аның урынына (хатыйп һәм мөгаллим вазифасына) 1909 елда шул ук мәхәллә имамы Мөхәммәтзакир сайлана. Ә имам булып яңа кеше – Мөхәммәтсабир Мөхәммәтлатыйпов – раслана[514].

1910 елда Уразай 281 хуҗалыктан, 711 ир-ат һәм 688 хатын-кыздан тора. 2 мәчет, мәктәп, 4 су тегермәне, тире эшкәртү заводы эшли[515].

1916 елда Россиядә авыл хуҗалыклары исәбен алу үткәрелә. Уразайда 297 хуҗалык, 608 ир-ат һәм 756 хатын-кыз теркәлә[516]. Беренче бөтендөнья сугышы тәмамланмаган, шуңа күрә ир-атлар хатын-кызларга караганда күпкә азрак була.

Беренче бөтендөнья, аннары гражданнар сугышы һәм 1921 елгы ачлык авылның социаль-икътисади үсешенә гаять тискәре йогынты ясый. Күп кенә

---

[512] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 26 һәм 29 сакл. бер.

[513] Поселенные данные о пожарности за 10 лет. 1903–1912 г. Самара, 1914. С. 26, 27.

[514] БР МА, ф.И–295 ФОНД, 2 тасв., 3 сакл. бер., 14 тасв., 11 сакл. бер.

[515] Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1910. С. 93.

[516] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 38 сакл. бер.

хуҗалыклар таркала, халык саны бик аз арта. 1920 елда – 1465 (324 хуҗалык), 1926 елда исә 1402 (280) кеше яши. Авыл Бөгелмә кантоны Азнакай волостена керә[517].

1927 елда авылда мәчеткә дип әзерләнгән яңа бүрәнәләрдән һәм берничә йортның бурасын кушып 4 класслы башлангыч мәктәп өчен зур гына бина төзиләр. Бу эштә мөдир Миргазиян Ярмәков күп тырышлык куя. Ул чакта Хаҗи Кәримов укытучылык итә. Аның җитешә алмавын күреп, гомуми җыелышта Зәкиҗан Бәдертдиновны укыту эшенә тәкъдим итәләр. Аларга ай саен 25 сум хезмәт хакы түләнә.

1929 елда Уразайда 22 хуҗалык колхозга берләшә. Аңа авылның Чатыр тавы буенда урнашканын күз алдында тотып «Чатыр» исеме кушыла. Колхозчыларга уңдырышлы җирләр бүленә. Колхоз идарәсе кулак дип кулга алынган Гыйздәтулла өенә урнаша. Яз көне җирләрне эшкәртеп, колхозчылардан җыелган симәнә хисабына икмәк чәчелә һәм югары уңыш алына. Бу вакытта авыл советы рәисе Миргасим Хафизов, сәркатибе Мирзаһит Хуҗин була.

1930 елда колхозга авылның башка хуҗалыклары да керә. Колхозчылардан 4 бригада оештырыла, бригадирлар (Хәбир Хәлимов, Сәгыйр Харрасов) сайлана. Бу вакытта колхозның 2 су тегермәне, бер тула басу машинасы була.

Егерменче еллар ахыры-утызынчы еллар башында авылда ике дистәгә якын хуҗалык раскулачиваниегә эләгә. Мондый каһәрле язмышка дучар булган кешеләр авылдан сөрелә, аларның мал-мөлкәте конфисковать ителә һәм колхозга бирелә. Конфисковать ителгән сарыклардан Солтангир бай хуҗалыгында сарык фермасы оештырыла. Югарыда күрсәтелгән 2 су тегермәне һәм тула басу машинасы да элеккеге бай хуҗалыкларның (алар хакында 1900 елгы мәгълүматларны бәян иткәндә әйтелде) милке була.

Утызынчы еллар башында колхоз Азнакайдан бер ат молотилкасы ала. Моннан башка аның авыл байларыннан конфисковать ителеп алынган ике урак машинасы була. Игеннәр мул уңган 1933 елда күп икмәк сатып, колхоз шул акчага 3 сугу һәм 2 уру машинасы ала. Моның өчен идарә кушуы буенча Зәкиҗан Бәдертдинов һәм Сәлахи Гыйләҗев Абдулла авылы базарына баралар. Шул ук вакытта колхоз көлтәне үзе бәйли торган «самовязка» машинасын булдыру хәстәрен дә күрә: 7 «самовязка» машинасы Курай Елга, Сәпәй, Әлки, Мәлбагыш авылларыннан, Роза һәм Чатра поселокларыннан сатып алына. Менә шулай акрынлап «Чатыр» колхозы үзенең материаль-техник базасын ныгыта. Бу эшкә колхоз рәисе Әбрар Закиров күп көч куя.

1934 һәм 1935 елларда да икмәк уңа. Ә менә 1936 елда икмәк уңышы түбән була, бик күп мал-туар үлә.

1937 елда колхоз моңарчы күрелмәгән югары уңыш ала. Арышның гектарыннан – 27–29 центнер, бодайныкыннан 34 центнер икмәк җыеп алына. Колхозчыларның һәр хезмәт көненә 12,5 килограмм икмәк бирелә. Шул елны

[517] ТР ДА, Р–1296 фонд, 12 тасв., 63 сакл. бер., 4 б.

күмәк хуҗалыкның исемен алыштыралар – хәзер ул «Энгельс» колхозына әйләнә.

Колхозда төзелешкә зур игътибар бирелә: силос башнясы, фермалар салына. Рәис булып эшләүче Ә. Закировны Азнакайга прокурор ярдәмчесе итеп алалар, аның урынына Мирхаҗиян Шакировны сайлыйлар.

Немец фашистлары сугыш башлагач, Уразайдан бик күп ир-ат (300 гә якын) фронтка алына. Аларның 200 дән артыгы һәлак була. Сугыш кырларында ятып калучылар исемлегендә элеккеге колхоз рәисе Ә. Закиров та була. Ул сугышта кече лейтенант дәрәҗәсендә булып, 1944 елның 25 мартында Украина территориясендә барган сугышларда хәбәрсез югала.

Уразайдан 1939 елда Кызыл Армия сафларына китеп, сугыштан исән-имин кайтканнарның берсе Хаков Михаил Габделхакович (1921 елда туган) була. Сугыш беткәндә майор булса, аннан соң хәрби хезмәттә калып, полковник дәрәҗәсенә чаклы ирешә. Ике тапкыр «Кызыл Йолдыз» һәм башка орден-медальләр белән бүләкләнә.

Сугышта катнашучылардан тагын бер Хаковны билгеләп үтәргә кирәк. Хаков Миргасим Хакович (1910) сугышта күрсәткән батырлыгы өчен 1946 елда «Дан» (3 нче дәрәҗә) ордены белән бүләкләнә.

1941–1945 елларда колхоз белән Г. Сабирҗанов, Г. Хаков, сугыштан соң – Г. Хәбибуллин, илленче елларда Х. Сөләйманова җитәкчелек итәләр. 1959 елдан 1985 елның гыйнварена кадәр колхоз рәисе булып Г. Нәфыйков эшли. 1981 елның маеннан «Энгельс» колхозы «Азнакай» совхозына үзгәртелә. Совхоз «Руно» берләшмәсенә керә һәм сарык үрчетү белән шөгыльләнә башлый. Озакламый авыл тормышында тагын бер зур вакыйга була – 1986 елда яңадан Уразай авыл советы төзелә (1958 елда ул бетерелгән иде). Аның рәисе итеп күп еллар колхоз партоешма сәркатибе булып эшләгән Минзәки Әхмәтгәрәй улы Сәетгәрәевне куялар.

1985 елдан «Азнакай» совхозы белән Ринат Әзәл улы Мөхәммәдьяров җитәкчелек итә. Яшь директор авылның социаль-мәдәни йөзен үзгәртүне төп бурычларның берсе итеп куя һәм бу өлкәдә зур эш башкара. Аның кайгыртучанлыгы аркасында 192 укучыга исәпләнгән ике катлы типовой мәктәп төзелә (1988 ел), авылга газ кертелә (1989), асфальт юл салына (1992), совхоз эшчеләренә ике дистәдән артык квартира төзелә һәм башкалар. Совхозның материаль-техник базасы да ныгый: терлекчеләр йорты, ике катлы административ бина, үзәк котельный, 200 баш сыерга исәпләнгән бина һәм кайбер башка объектлар файдалануга тапшырыла. Тынгысыз җитәкче район һәм авыл советы депутаты итеп сайлана һәм, депутат буларак, район тормышында да актив катнаша.

Бүгенге көндә Уразайда 200-гә якын хуҗалыкта 500 дән артык кеше яши. Аларның йөздән артыгы балалар – авылның киләчәге. Яшь буын авылның үткәнен яхшы белсен өчен тарих укытучысы Хәмит Афзалетдин улы Хәйретдинов төбәкне өйрәнү музее оештырган. Бу эштә аңа әнисе, пен-

сионер-укытучы Мөшәрәфә Сафа кызы Сафина һәм өлкән яшьтәгеләр ярдәм күрсәтә. Яңа оешкан музей алдында авылның тарихын бүгенге һәм киләчәк буыннарга түкми-чәчми җиткерү бурычы тора. Үзенең бай тарихы белән Уразай моңа лаек[518].

## § 18. Үчәлле

Үчәлле – Азнакайдан егерме чакрым ераклыкта, Ык елгасы бассейнында урнашкан, зур булмаган авыл. Ике ярым гасырдан артык тарихы, күп вакыйгаларның шаһиты булган авыл ул.

1739 елда монда Шилнә елгасы[519] буендагы бер авылдан (чыганакта «Деревня по речке Шилне») 14 ир-ат ясаклы татар килеп утыра. Яңа барлыкка килгән авыл Салкын Чишмә (чыганакта «Деревня на речке Менли на Студеном Ключе») буенда урнашкан дип күрсәтелә[520].

Икенче ревизия (1748 ел) вакытында да ул Салкын Чишмә («Деревня на речке Мелле на Студеном Ключе») буенда урнашкан авыл буларак теркәлә. Мондагы халыкны шул ук Шилнә елгасы буендагы авылдан күчеп утырган ясаклы татарлар (23 ир-ат) тәшкил итә[521]. 1739 елгы мәгълүмат белән чагыштырганда, 7 хуҗалыкның берсендә генә (Балтач Туйматов гаиләсендә) яңа туган ир балалар булмый. Алар Уфа өязенә караган Кама арьягында яшәсәләр дә, җан башыннан салымны Казан өязе Арча юлы Колмәт Котлыгошев йөзлегендә (сотнясында) торып түлиләр.

Югарыда сүз барган документларда авылның хәзерге атамасы (Үчәлле) телгә алынмады. 3 нче ревизия (1762 ел) вакытында авыл беренче тапкыр Үчәлле дип атала. Түбәндә шул ревизия исемлегенә тукталып үтәбез.

1762 елда Үчәлледә Казан өязе Арча юлы Туктамыш Сәфәров йөзлегенә кергән 65 ир-ат ясаклы татар исәпкә алына. Исемлекнең беренче битләрендә Сәнкәй Морзабаев (82 яшь; уллары Мәмәт (аныкы Габдеш), Ямьмәт), Ишәй (70) һәм Бәдигъ (61; улы Апка) Иштирәковлар, Булат (23) һәм Ибрай (8) Бикмәтовлар, Балтач Туймәтов (50; улы Ишәли һәм тәрбиягә алган улы Ишмәй Ишмәнов), Алтан Аткасов (1747 елда мәрхүм; уллары Биктимер (аныкы Габдрахман), Гадел (аныкы Нәдер Зәбир, Бәшир), Арыслан), Илтәй[522] Исәкәев (1756 елда мәрхүм; улы Кангилде (аныкы Кансөяр, Сөяргол, Юма-

[518] Авыл тарихын 1995 елда яздым, соңгы чорда аның кайбер битләренә берникадәр яңа мәгълүмат өстәдем.

[519] Татарстанның Тукай районы биләмәләрендә ага.

[520] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1154 сакл. бер., 328–328 б.

[521] Шунда ук, 1140 сакл. бер., 65 б. а.–66 б.

[522] Башка чыганакта Илкәй дип языла.

гол)) хуҗалыклары теркәлгән[523]. Боларны авылга нигез салучы нәселләр дип әйтә алабыз, чөнки алар 1739 һәм 1748 елгы исемлекләрдә дә күрсәтелә.



*1739 елда авылга нигез салган ир-атлар*

Авылда ир-атларның элеккеге ревизия белән чагыштырганда өч тапкыр диярлек артуы яңа нәселләр күчеп килүе белән бәйле. 1748 елда монда Арча юлы Гәрдәле (Тимкәй Килкин һәм башкалар; 36 ир-ат) һәм Яңа Салагыш (Зәет Ермолаев гаиләсе; 4 ир-ат) авыллары ясаклы татарлары, Җөри юлы Каран авылыннан Уразман Ишимов күчеп килә[524].

Моннан башка, 1762 елгы ревизия документыннан авылның Хасбулат Мөтеков (чыганакта «*близ старшины Каспулата Мутюкова*») старшина булган территория янында барлыкка килүен беләбез. Башка чыганаклар әлеге кешенең Юрмый волосте старшинасы булуын күрсәтә.

Бу чыганак юкка гына старшина исемен телгә алмый: Үчәлле Юрмый волосте җирләрендә барлыкка килгән. Ясаклы татарлар әлеге волость биләмәчеләренә (вотчинникларына) ел саен һәр хуҗалыктан ун тиен түләп бару шарты белән, мәңгелеккә (чыганакта «по договору на вечность») килеп утырганнар[525].

Авыл атамасы турында сүз чыккач, беренче кешеләр Башкортстан ягындагы Учалы авылыннан күчеп килгәннәр, дигән фикер ишетергә туры килгән иде бу юлларның авторына. Күргәнебезчә, тарихи чыганаклар Үчәллегә нигез салучыларның күпчелеге хәзерге Тукай районы авылларыннан булуын күрсәтте.

---

[523] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3795 сакл. бер., 396–400 б.

[524] Шунда ук.

[525] БР МА, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 128 б. а.

Югарыда сүз барган исемлектә 65 ир-ат күрсәтелә. Икенче документ буенча, аларның бераз күбрәк (барлыгы 70)[526] булуы билгеле. 1762–1782 еллар арасында монда йомышлы («служилый») татарлар да килеп утыра. Бу чорда авыл административ яктан Уфа өязе составында күрсәтелә башлый.

Гасыр ахырына авыл бераз зурая. 1795 елда халык ике сословиегә карый. 66 ир-ат һәм 67 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 80 һәм 77 була) ясаклы татарлар дип атала. Исемлек башында Мәмәт Имашов (1740–1784; өч хатынлы) һәм аның варисы Рамазан (29 яшь) күрсәтелә. 8 кеше солдатка (рекрутка) алынган. Никахларның шактые күршедәге Бәләбәй округы авылларына (Катай, Сакат (2 никах), Сәрдек, Тархан, Туктагол, Тукай, Учтым) туры килә[527].

Икенче төркем халыкны йомышлы («служилый») татарлар (25 ир-ат һәм 13 хатын-кыз; 1782 елда шул тәртиптә 20 һәм 18 була) тәшкил итә. Исемлектә беренчеләр булып Капти Байтимеров (59 яшь; хатынының авылы чыганакта «Грибаново Сергацкой округи» дип язылган) һәм Әбләз Ләлүков (68; хатынының авылы «Камкино Княгинской округи») язылган[528]. Никах мәгълүматлары әлеге йомышлы татарларның ерак төбәкләрдән күчеп килүләренә ишарәли.

XIX гасырның беренче чирегендә авылның үсешендә зур үзгәрешләр күзәтелми. 1808 елда, төбәктәге «башкорт»лар белән төзелгән договор нигезендә, Үчәллегә берничә «типтәр» гаиләсе күчеп килә[529]. Бу чорга караган чыганакларда авылда мәчет булуы турында әйтелә.

1816 елда 83 ир-ат (27 хуҗалык) исәпләнә. Халыкның төп өлешен ясаклы татарлар (54 ир-ат; 17 хуҗалык) тәшкил итә. Авылда яшәүчеләрнең икенче төркеме элеккечә йомышлы татарлардан (27 ир-ат; 10 хуҗалык) тора. Болардан тыш, типтәр сословиесендәге татарлар (8 ир-ат; 2 хуҗалык) һәм 2 «отставной» солдат яши. «Типтәр»ләр Иске Нәдер (Сугышлы) авылыннан килеп утырганнар[530].

1829 елгы мәгълүматлар авылның көнкүрешен тасвирлый. Игенчелек һәм терлекчелек – халыкның төп шөгыле. Хатын-кызлар кыр эшләреннән буш вакытта йоннан, киндер басаларыннан җеп эрләгәннәр, киндер сукканнар һәм тукыма тукыганнар. Типтәр сословиесендәге ир-атлар Оренбург шәһәрендәге ике мең атлы типтәр полкына хәрби хезмәткә алынганнар, полк чыгымнарын түләргә мәҗбүр ителгәннәр[531].

Типтәр сословиесендәге татарлар 1855 елдан 23 нче «башкорт» кантонының 5 нче юртасына керә, шул сәбәпле чыганакларда «башкорт» дип языла

---

[526] Крестьянская война на территории Башкирии. Уфа, 1975. С. 288.

[527] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл.бер., 280–285 б.

[528] Шунда ук, 22 сакл. бер., 181–182 б.

[529] Малоизученные источники по истории Башкирии. Уфа, 1986. С. 90.

[530] БР МА, И–1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 128 б. а.

[531] РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 289–292 б.

башлый. 1859 елда алар 36 ир-ат һәм 34 хатын-кыз (4 хуҗалык) тәшкил итә. Болар – Райман Гөзәеров (53 яшь; монда ук туганнары Нуриман (54; хәрби хезмәттә булуын күрсәтеп «отставной казак из тептярей» дип язылган), Гарифулла (41), Сафиулла (33) яши), Гирфан Гөзәеров (68), Ногман Гөзәеров (61), Йосып Мөхәммәдьяров (61; ике хатынлы) хуҗалыклары. Вилдан Гөзәеров гаиләсе Сөләй авылына күчеп утыра[532].

Статистик чыганак Үчәлледә 1859 елда 144 ир-ат һәм 171 хатын-кыз (53 хуҗалык) казна крестьяннары һәм «башкорт»лар яшәвен күрсәтә[533]. Монда күпчелекне тәшкил иткән казна крестьяннары элеккеге ясаклы һәм йомышлы татарлардан, «башкорт»лар – элеккеге типтәр сословиесендәге татарлардан тора.

1884 ел ахыры – 1885 ел башына Үчәлледә 103 хуҗалык, 293 ир-ат һәм 304 хатын-кыз теркәлә. Авыл Югары Стәрле (документта авыл Югары Стәрлетамак дип күрсәтелә), Түбән Стәрле (Түбән Стәрлетамак), Сөендек, Сарлы, Әгер, Олы Сукаеш, Банки Сукаеш һәм Түбән Сукаеш авыллары белән беррәттән, Стәрлетамак волостена керә. Хуҗалыклар саны буенча волостьта соңгы урында тора.

Үчәлле авыл җәмгыятенең ул чорда 1033,5 дисәтинә уңайлы һәм 40,5 дисәтинә уңайлы булмаган җирләре була. 497 дисәтинәсен сөрүлекләр, калган өлешен печәнлек, йорт яны җирләре һәм көтүлекләр алып тора. Монда җир белән тәэмин ителү дәрәҗәсе чагыштырмача түбән. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка бүлгән очракта, «типтәр»ләрдә – 7,7 дисәтинә, элеккеге ясаклы татарларда 8,7 дисәтинә туры килә. Волостьның кайбер авылларында, мәсәлән, Сарлыда, бу күрсәткеч 27,4 дисәтинә тәшкил итүен искә алсак, җир белән тәэмин ителү дәрәҗәсе никадәр түбән булуын күз алдына китерүе кыен түгел.

Әмма хуҗалыклар буенча җирнең күләме, ягъни иманалар саны, шактый аерыла. Авылда 96 хуҗалыкның иманасы була. 55 хуҗалык – берәр, 34 – икешәр, 6 – өчәр, 1 хуҗалык дүрт иманага ия. Монда бер имана 6,9 дисәтинә тәшкил итә, димәк, бик аз хуҗалыклар гына җир белән яхшы тәэмин ителгән. Эш кораллары исә 79 хуҗалыкта гына җитәрлек күләмдә була, калганнарында – бөтенләй юк.

Игенчелектән тыш, терлекчелек тә зур урын тота Үчәлледә. Авыл халкы күп санда ат (273 баш), мөгезле эре терлек (295), сарык (513) һәм кәҗә (128) асрый.

Хуҗалыклар буенча алсак, мал-туар саны шактый аерылуын күрәбез. Эш атларын гына алыйк. 17 хуҗалыкта алар бөтенләй булмый. Шул ук вакытта 24 хуҗалык – берәр, 39 хуҗалык икешәр-өчәр ат тота. Авылда дүрт һәм аннан

[532] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 757 сакл. бер., 130–135 б.

[533] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. С.-Пб., 1864. С. 35.

күбрәк атлылар да була. 4 хуҗалык дүртәр эш аты асраса, 12 хуҗалыкныкы исә аннан да артыграк.

Шунысына игътибар итик, Үчәлледә 14 хуҗалыкның ни эш аты, ни сыеры булмый. Өстәвенә, 3 хуҗалык йортсыз (янгын 2 йортны көлгә әйләндерә). Болар авылның иң ярлы катлавын тәшкил итә.

Җире аз яисә бөтенләй булмаган хуҗалыкларның күпчелеге үз авылдашларына һәм якын-тирә алпавыт имениеләренә-хуторларга я булмаса авылларга төрле эшләргә ялланган, кайберләре һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Статистик мәгълүматлардан күренгәнчә, Үчәлледә 14 кеше (шуларның икесе читкә китеп) игенчелек белән бәйле эшләргә ялланган. Тагын 7 кеше һөнәрчелек белән шөгыльләнә.

Урман-болыннарга бай табигать умартачылык өчен гаять уңайлы булган. Шуңа күрә монда 25 хуҗалык 137 баш умарта тота[534].

Үчәлле халкы 1884 елда иске мәчетне сүтеп, яңасын сала. 1886 елдан монда Мөхәммәтшәриф Гайнуллин имамлык итә. Аның 1875 елда туган улы Мөхәммәтзакирның да бу мәхалләдә имам-хатыйп вазифасын башкаруы (1903 елдан) мәгълүм. Мөәзин булып 1881 елдан Мостафа Солтангалиев хезмәт итә[535].

Гасыр ахырына Үчәлле шактый үсә. 1897 елда 126 хуҗалык, 362 ир-ат һәм 367 хатын-кыз исәпләнә. Авылның барлык биләмәләре 1104 дисәтинә тәшкил итә.

Волость идарәсе Сарлыда урнашкан. 277 хуҗалыктан торган ике мәчетле авыл була ул. Икешәр мәчетле авыллар исәбенә тагын Югары Стәрлетамак, Түбән Стәрлетамак һәм Зур Сукаеш керә.

Стәрлетамак волостенда, югарыда күрсәтелгән авыллардан тыш, тагын 6 хутор була. Шуларның Үчәлле тирәсендә урнашканнарын күрсәтеп үтик.

Волостьтагы иң зур хутор хуҗасы – Бөгелмә мещаны Кәлимулла Гобәйдулла улы Шәфиев. 1881 елда ул Сарлы «башкорт»ларыннан 909 дисәтинә җир сатып ала. Әлеге биләмәсендә Кәлимулла бай 3 йорт, ат абзарлары, амбарлар һәм башка күп каралтылар салдыра. Монда ул иген игә, күп малтуар (42 ат, 33 мөгезле эре терлек, 170 сарык) асрый. Приказчигы, каравылчысы һәм алты батрагы була.

Печән чапканда һәм кызу урак өстендә Кәлимулла бай күпсанлы көнлекчеләр яллый торган булган. Үчәлле һәм тирә-як авыл кешеләре еш кына аннан арендага җир ала торган булганнар.

Дворян Александр Павлович Черкасовның да хуторы (ул Үчәлледән ике чакрым ераклыкта урнашкан, «Учаллинский» дип аталган) зурлыгы буенча аерылып тора. 1882 елда ук Сарлы «башкорт»ларыннан 724 дисәтинә җир

---

[534] Сборник статистических сведений по Самарской губернии. Т. 5. Бугульминский уезд. Самара, 1887. С. 252–257.

[535] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл.бер., 127 б. а.–128 б.

сатып алган була. Ике елдан 120 дисәтинәсен Югары Стәрле кешеләренә сата. Кәлимулла байныкы кебек, аның да хуторында 3 йорты, абзарлары, амбарлары һәм башка күп каралтылары була. Земстводан 170 сумга молотилка сатып алган. 16 эш аты, 3 сыер һәм башка мал-туар тота. Хутор белән каенатасы идарә итә, ә үзе даими Бөгелмәдә яши, өяз земство идарәсе әгъзасы булып тора. Алпавыт приказчик (ул Үчәлле кешесе) һәм 4 эшче яллаган. Кыр эшләре вакытында монда тирә-як авыллардан күпсанлы көнлекчеләр килеп эшли торган булган. Үчәлле, Сарлы, Сасыкүл һәм Югары Стәрлетамак кешеләре Черкасовтан еш кына арендага җир алганнар.

Үчәлледә җан башына тигән җирнең аз булуы турында әйтеп үткән идек. Шуңадыр, 40 кеше берләшеп поручик Николай Николаевич Козловскийның имениесен (1524 дисәтинә) арендага ала. Моның өчен алар елга 800 сум түлиләр. Әлеге биләмәнең 372,5 дисәтинәсен – басу, 140 дисәтинәсен урман алып торган. Урман мал-туар йөртү шарты белән арендага бирелә.

Үчәлле янындагы тагын бер җир биләмәсенең хуҗасы – Әсәй авылыннан Габдерәхим Габделкәримов. 50 дисәтинә җирне 1882 елда Сарлы «башкорт»ларыннан 250 сумга сатып алган. 20 дисәтинәсендә каен һәм имән урманы урнашкан.

Үчәлленең үзеннән дә 2 кеше зур җир биләмәләре хуҗасы була. Шуларның берсе – Маһиҗамал Абдуллина. Габдерәхим бай кебек, ул да 50 дисәтинә җирне 1881 елда Сарлы «башкорт»ларыннан сатып алган. Әлеге биләмәгә сөрүлекләр (20 дисәтинә), урман (10), печәнлекләр (10) һәм көтүлекләр (9,80) керә. 1896–1899 елларда хуҗа хатын арыш, бодай, солы, борай һәм борчак игә. Арышның дисәтинәсеннән 1896 елда – 49, 1897 елда – 64, 1898 елда – 24, 1899 елда 80 пот уңыш ала. Башка төр бөртеклеләр буенча да, борчакны исәпләмәгәндә, күрсәткечләр шул чамадарак. Корылык булган елда (1898) гына борай уңмый, ә бодай симәнәгә җитәрлек кенә чыга.

Икенче җир биләмәсе хуҗасы – мулла Мөхәммәтшәриф Гайнуллин. 1882 елда Сарлы «башкорт»ларыннан сатып алган җире шулай ук 50 дисәтинә. Әлеге биләмә сөрүлек (20,0 дисәтинә), урман (16,0), куаклык (1,5), печәнлек (6,0), көтүлек (6,0) һәм йорт яны җирләреннән (0,5) тора. Монда мулланың йорты (мал караучы өчен) һәм лапасы була. Күпсанлы мал-туарын көтәргә кеше яллаган. Көтүчегә сезонга 20 сум түләгән, аны ашаткан һәм 6,5 сумлык кием-салым (чабата, чапан, күлмәк, ыштан) биргән[536].

Татарстан дәүләт архивында саклanучы Бөгелмә өязе буенча хуҗалыклар санын алу документларына таянып, авылның 1900 елгы көнкүрешен кыскача тасвирлап үтик.

Мулла булып элеккечә Әсәй кешесе Мөхәммәтшәриф Гайнуллин (55 яшь) тора. Хатыны (39), 5 улы (өлкәне солдат хезмәтендә) һәм 2 кызы белән

[536] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 798, 799 сакл. бер.; Список населенных мест Самарской губернии. Самара, 1900. С. 153–154.

яши. Хуҗалыгы шактый зур була. Барлык чәчүлекләре 21,53 дисәтинә мәйданны били. Игеннәренең шактый өлеше (15,90 дисәтинә) сатып алган җир участогында, калган өлеше арендага алган басуларда урнашкан. 8 эш аты, 10 сыеры, башка вак маллары һәм зур умарталыгы (59 баш) була. Хуҗалык эшләрен 2 хезмәтчесе башкара.

Үчәлленең мөәзине – Мостафа Солтангалиев (45 яшь). Ул – төп шушы авыл кешесе, гаиләсе хатыны (40), 2 улы һәм 3 кызыннан тора. Аның да хуҗалыгы зур: 15,25 дисәтинә мәйданда иген игә, күп терлек (4 эш аты, сыер һәм башкалар) асрый. Ул да хезмәтче яллаган.

Авыл халкы Әхмәдиша Мөхәммәтшинны (42 яшь) староста итеп сайлаган. Земстводан яисә волостьтан вәкилләр килеп төшкән чакта, туп-туры аңа юл тотканнар. Авыл салымнарын вакытында түләп баруны тәэмин итү һәм башка вазифалар йөкләнгән бу старостага. Ул хатыны (38), 4 улы һәм 3 кызы белән яши. 9,34 дисәтинә чәчүлеге, 2 эш аты, сыеры һәм башка маллары була.

Хәлиулла Хәбибуллин (50 яшь) укытучы буларак билгеле. Әлеге хезмәте өчен ата-аналар түләгән. Укытучы 1900 елда 4,41 дисәтинә арыш, солы, тары һәм карабодай чәчкән. 6 кешедән торган гаилә өчен бу күп түгел, билгеле. Мал-туар асрамый.

Тирә-як авыллардагы кебек, Үчәлледә дә сәүдә белән шөгыльләнүчеләрне күрергә мөмкин. Габделгазиз Исмәгыйлов (38 яшь) бакалея лавкасы тота. Игенчелек һәм терлекчелеккә дә зур игътибар бирә. Барлык чәчүлекләре 13,63 дисәтинә тәшкил итә. Әлеге максат белән авылдашларыннан һәм читтән арендага шактый басу (11,13 дисәтинә) алган. 4 эш аты, 2 сыеры, башка вак маллары була. Хуҗалыкта күп эшләрне хезмәтчесе башкара.

Икенче сәүдәгәр – Габдрахман Нариманов (42 яшь), аның шулай ук бакалея лавкасы була. Хатыны (35), 3 кызы һәм анасы белән яши. Зур хуҗалыгын (15,50 дисәтинә чәчүлекләр, 4 эш аты, 4 сыер һәм башкалар) алып бару өчен хезмәтче яллаган.

Сәүдәгәрләрнеке кебек зур хуҗалыклар авылда дистә ярымга якын. Тагын бер Нариманов, Могыйнетдин исемлесе, 28,25 дисәтинә мәйданда иген игә. Ул 7 эш аты, 2 сыер һәм башка мал-туар асрый. Зур умарталыгы (30 баш) да була. Аның хуҗалыгында көн-төн 2 хезмәтче эшләгән. Хуҗа (аңа 56 яшь) 2 улы һәм 2 кызы белән яши.

Шәйхелислам Әхмәтҗанов (43 яшь) хуҗалыгы, зурлыгы буенча, Могыйнетдин байныкыннан аз гына калыша. 27,89 дисәтинә чәчүлекләре һәм күп мал-туары (5 (?) ат, 5 сыер һәм башкалар) була, хезмәтче тота. Гаиләсе 2 хатыны, улы, 2 кызы һәм анасыннан тора.

Габделгалим Әхмәтҗанов (югарыда телгә алынган Шәйхелисламның туганы булса кирәк) та зур мәйданда (20,76 дисәтинә) иген игә. 4 эш аты, 3 сыер, башка маллар һәм 5 баш умарта тота. Аңа 40 яшь, хатыны (30), 2 улы һәм кызы белән яши.

Күп иген игүче башка хуҗалыкларны да санап үтик. Хәйретдин Хөсәенов – 28,30, Фазлытдин Хөсәенов – 24,81, Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтшәрипов – 22,03, Насретдин Назыйметдинов – 22,30, Мөхәммәдиша Мөхәммәтшин – 17,50, Фәхретдин Рәҗәпов – 16,86, Төхвәтулла Рәхимколов – 16,53, Исмәгыйль Ибраһимов – 14,50 һәм Харис Әхмәтҗанов 12 дисәтинә чәчүлекләр хуҗалары булып тора. Хуҗалыкларында мал-туар да күп. Кайберләре – 5, хәтта аннан артык эш аты тота. Күпчелегенең бер яисә ике хезмәтчесе була.

Зур мәйданда иген игүче һәм күп мал-туар асраучы әлеге хуҗалыклар кулак (чәчүлекләре 15 дисәтинәдән арта) һәм таза хәллеләр (чәчүлекләре 10,01 дән 15 дисәтинәгә кадәр) катлавын тәшкил итә. Алар базар белен аеруча тыгыз бәйләнгән. Икмәк һәм мал-туар сатып шактый табыш алалар, байыйлар.

Урта хәлле хуҗалыкларга махсус тукталып үтик. Алар авылда алты дистә ярым тирәсе. Бу хуҗалыклар арасында бигрәк тә Якуп Назыйметдинов (9,80 дисәтинә), Хәйретдин Фәхретдинов (9,76), Вәлиәхмәт Нариманов (9,75), Ризван Райманов (9,75), Хәсәнша Габдуллин (9,51), Гайнан Райманов (9,50), Мортаза Гыйрфанов (9,25), Хөснетдин Мифтахетдинов (9,05), Әхмәтгәрәй Сәетбатталов (8,78), М. Мөхәммәтшин (8,76), Мифтахетдин Нариманов (8,50) һәм Хөснетдин Хөсәеновлар (8,29) аерылып тора. Калган хуҗалыкларда исә чәчүлекләр 4 дисәтинәдән 8 дисәтинәгә кадәр мәйданны били.

Урта хәлләләр базар белән аз бәйләнгән. Чәчүлекләре 8 дисәтинәдән 10 дисәтинәгә кадәр булган хуҗалыклар гына үзеннән арткан икмәкне базарга сатарга алып чыккалаганнар. Калганнарның җитештергәне үз ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек кенә була.

Ярлы хуҗалыклар (чәчүлекләре 0,15 дисәтинәдән 4 дисәтинәгә кадәр) авылда күпчелекне тәшкил итә. Алар үз хуҗалыкларында да, читтә ялланып та эшлиләр. Бу катлау кешеләре арасында эш аты һәм башка мал-туары булмаганнары бик күп. Кайбер мисаллар китерик. Әхмәтҗан Сәетбатталов – 2,58, Нургали Тимергалиев 2,51 дисәтинә мәйданда иген игә, икесе дә мал-туар асрамый. Чәчүлекләре шундый ук күләмдә булган Габдулла Габделлатыйпов башка авыл баена (Мәйлүн Мәннаповка) хезмәтче булып урнашкан.

Игенчелек һәм терлекчелектән тыш, билгеле дәрәҗәдә һөнәрчелек тә үсеш ала. Беренче чиратта, агач эше осталарын күрсәтеп үтәргә кирәк. Алар арасында балта осталары (Фәррахетдин Гыйлаҗетдинов, Әсәдулла Гарифуллин, Шәрәфетдин Шәмсетдинов, Әхмәтхаҗи Әхмәтҗанов, Салиҗәгъфәр Шәмсетдинов) аерылып тора. Башка төр һөнәр ияләреннән слесарьларны (Хөҗҗәтелислам Ихсанов, Шәйхелислам Ихсанов), киез итек басучыны (Хәсәнша Габдуллин) һәм йон тетүчене (Мөстәкыйм Мөхәммәтшәрипов) күрәбез.

Авылда ике кешенең (Насретдин Назыйметдинов, Мөхәммәтша Мөхәммәтшин) ат көче белән эшли торган тары-борай яргычлары була. Мөхәммәтшаны алпавыт Черкасов үзенә приказчик итеп эшкә алган.

Умарталыклары булган кайбер хуҗалыкларны алдарак телгә алган идек. Башка умартачыларны да күрсәтеп үтик. Хәйретдин Хөсәенов – 35, Фазлытдин Хөсәенов – 30, Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтшәрипов – 10, Әхмәтша Шаһимәрданов – 10, Гайнан Райманов – 8, Мөхәммәтша Мөхәммәтшин – 6, Маһижамал Абдуллина – 6, Насретдин Назыйметдинов – 6, Габделгалим Әхмәтҗанов – 5 һәм Исмәгыйль Ибраһимов белән Мөхлисулла Гарифуллиннар дүртәр баш умарта тоталар.

Шулай итеп, Үчәлледә халыкның игенчелек һәм терлекчелектән тыш та шөгыльләре күп булуы күзгә ташлана. Һөнәрчелек һәм умартачылык өстәмә табыш чыганагы булып торган. Ә менә чәчүлексез йортларның кайберләре еш кына һөнәрчелек белән көн күргәннәр.

Авылның социаль-икътисади халәтен тасвирлауны төгәлләр алдыннан тагын бер-ике мәгълүматка тукталыйк. 1900 елда Үчәлледә 141 хуҗалык теркәлә. Аларның күпчелеге (104) документларга – ясаклы татар (халык телендә Казан татарлары), калганы (37) типтәр дип язылган. Өч хуҗалык монда исәпләнсә дә, чынлыкта исә авылда яшәми. Ике типтәр сословиесендәге татар гаиләсе бирегә читтән килеп утырган. Аларның берсе алдарак телгә алган Мөхәммәтшәриф мулла иде, икенчесе Сөләй авылыннан Әдһәм Йосыпов була[537].

1909 елда Үчәлле халкы икенче җәмигъ мәчет салырга рөхсәт ала. Бу чорда авыл 173 хуҗалыктан, 453 ир-ат һәм 449 хатын-кыздан тора. Мәчет төзелеп беткәч, 1911 елда дин әһелләре сайлана. Миңлезакир Мостафа улы Солтангалиев – мөәзин һәм мөгаллим, Габдерәфикъ Габделгалимов имамхатыйп һәм мөгаллимлеккә раслана. 1918 елда Габдерәфикъ хәзрәт вафат булгач, имам итеп Имаметдин Мөгыйнетдиновны куялар. Совет чорында Мөхәммәтфатыйх Шәрипов (Бикташев) мөәзинлек итә[538].

Беренче бөтендөнья сугышы елларына караган мәгълүматлар күп түгел. 1916 елда хуҗалыклар санын алганда, Үчәлледә 187 хуҗалык, 411 ир-ат һәм 539 хатын-кыз теркәлә. Соңгылары 128 кешегә күбрәк, чөнки шактый ир-ат сугышка киткән була. Тирә-як авылларда да шулай.

1916 елда Стәрлетамак волостена, Үчәлледән башка, Сарлы (362 хуҗалык), Югары Стәрлетамак (319), Зур Сукаеш (315), Сөендек (219), Түбән Стәрлетамак (180), Әгер (179), Банки Сукаеш (100), Түбән Сукаеш (86) авыллары керә. Болардан тыш, волостьта тагын 4 имение (Майоровка, Зино-Мариинское, Горкино, Учаллинское) һәм 5 хутор (хуҗалары – Н.И. Дворников, М.И. Бүләков, Яркәевләр) була.

Волостьның кайбер авылларында һәм хутор-имениеләрдә качакларны, сугыш тоткыннарын күрергә мөмкин. Банки Сукаешта – 11, Әгердә – 7, Сар-

[537] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 790, 791 сакл. бер.

[538] БР МА, И–295 фонд, 2 тасв., 3 сакл.бер., 127 б. а., 128 б.

лыда – 4, Югары Стәрлетамакта 1 качак, имениеләрдә – 9 качак һәм 11 сугыш тоткыны, хуторларда 3 качак яши.

Бу чорда да халыкның терлеге күп, игене мул була. Үчәлледә 334 ат (шул исәптән 259 эш аты), 423 мөгезле эре терлек (192 сыер), 1370 сарык һәм 158 кәҗә исәпләнә. Чәчүлекләр мәйданы 1161 дисәтинә тәшкил итә. Шуларның шактыен арыш (478 дисәтинә), калган өлешен солы (236,30), борай (127,30), бодай (104,30), карабодай (88), тары (75,10) һәм борчак (52) алып тора.

Чәчүлек мәйданының сугыш алды елларына караганда да зуррак булуын аренда мөнәсәбәтләренең киң колач алуы белән аңлатырга кирәк. Хуҗалыклар 154,5 дисәтинә имананы һәм читтән 436,2 дисәтинә җирне арендага алганнар[539]. Халык саны даими арту шартларында да иманаларның күләме үзгәрмәү җирне күпләп, бигрәк тә читтән арендага алуга этәргән.

Октябрь инкыйлабыннан соң Үчәлледә авыл советы оештырыла. 1919 елның октябренда рәис вазифасын 50 яшьлек Гыйниятулла Төхвәтуллин башкара. Хафиз Шакиров – урынбасар, Шәмсемөхәммәт Шәйхелисламов секретарь була. Гыйниятулланың абыйсы Гыйззәтулла Төхвәтуллин Стәрлетамак волость башкарма комитетында рәис урынбасары булып эшли. Бер үк вакытта финанс һәм ЗАГС бүлекләрен җитәкли[540].

1920 елда Үчәлледә 201 хуҗалыкта – 988, 1926 елда 160 хуҗалыкта 718 кеше яши[541]. Ачлык афәте монда да авылның үсешенә зур зыян китерә, бик күп кешеләрнең гомерен ала. 1927 елда берничә хуҗалык Кызыл Йолдыз авылына нигез сала. Бу чорда Үчәлле Бөгелмә кантоны Тымытык волостена керә.

1929 елда «Уразман» күмәк хуҗалыгы оеша. Колхозга бу исем аерым хуҗалык вакытта күрше авыллар белән җир-межа өчен сугышканда һәлак булган кеше (Уразман) хөрмәтенә кушыла, дип әйтелә авыл тарихына багышланган бер кулъязмада.

Кулаклыкта гаепләүләр башлангач, 1930 елда Үчәлледән дә 5 гаилә авылдан сөрелә. Болар – мулла Закир Бикташев (1873 елда туган), мөәзин Фатих Бикташев (1883), мөәзин Закир Мостафин (1880), мулла Имам Мөгыйнов (1882) һәм Фәхретдин Фазлытдиновлар (1881). Закир хәзрәтнең гаиләсе зур була. Хатыны Хөббиҗамал (1894) белән 6 бала тәрбияләп яткан чакта шундый афәткә тарый алар. Исемлектә калган 4 гаиләнең дә составы, конфискацияләнгән мал-мөлкәте (сумнарда) күрсәтелә. Соңрак авылдан кайбер башка кешеләр дә читкә сөрелгән булуы мөмкин, чөнки әлеге мәгълүматлар бары бер елга гына карый.

---

[539] ТР ДА, 993 фонд, 1 тасв., 801 сакл. бер.

[540] ТР ДА, Р–1167 фонд, 1 тасв., 160 сакл. бер., 811 б.

[541] ТР ДА, Р–1295 фонд, 12 тасв, 63 сакл. бер., 33 б.

Сугыштан соңгы чорда «Уразман» «Ишкәй» (1951 елда) һәм «Якты Күл» (1960 ) колхозлары белән берләштерелә. Якты Күл – бер үк вакытта авыл исеме дә. Аңа 1927 елда Әлмәт төбәгенең Суркин авылы чувашлары нигез сала. Авыл урнашкан җирдә бик матур күл булган, ул хәзер дә бар, әлеге атама шуннан алынган. Монда 1992 елда 95 кеше (икесе – татар, калганнары – чуваш), башлангыч мәктәп, клуб, кибет була. Сыер һәм бозау фермалары эшли.

Ишкәй – башта колхоз исеме була, әмма соңрак авыл да шулай атала. Монда 1921–25 еллар арасында Уразайдан килеп урнашканнар, ул чакта авыл Текмәле дип йөртелгән. Әлеге атама шулай ук җирле үзенчәлекне чагылдыра. Бу урыннар вак имәнлектән торган. Кешеләр төзелеш өчен шул имәннән файдаланганнар, аны тезеп (тегеп) ихата ясаганнар, шуннан «Текмәле» атамасы барлыкка килгән. «Ишкәй» дигәне кеше исеменнән алынган дип фараз кылына. 1926 елда 9 хуҗалыктан торган Текмәледә – 46, 1992 елда 43 кеше яши. Клуб, кибет була.

Хәзерге вакытта авылда өч йөз иллеләп кеше яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, фельдшерлык-акушерлык пункты, почта бүлекчәсе, балалар бакчасы, кибет бар. Халыкның төп өлеше «Уразман» күмәк хуҗалыгында эшли[542].

## § 19. Чубар Абдул

XVIII гасырда Мәллә елгасы буенда күп кенә авыллар барлыкка килә. Шуларның берсе – Чубар Абдул. Аның башлангыч чор тарихы шактый үзенчәлекле. Шуңадыр, аңа кайчан һәм кемнәр нигез салган дигән сорауга җавап тапканчы, күп кенә чыганакларны өйрәнергә туры килде.

Бер документтан күренгәнчә, Чубар Абдул ясаклы татарлары «башкорт»лар белән договор төзеп (һәр хуҗалыктан 10 тиен оброк түләү шарты белән) 1733 елда килеп утыралар. Әлеге мәгълүматлар авылның мөхтәрәм кешеләре Мортаза Мөсәллимов, Гомәр Иштирәков һәм Зәбир Субаевлардан 1793 елда язып алына[543].

1748 елгы документта Казан өязе Җөри юлы Югары Якый авылы ясаклы татарлары Ибрай, Рысмәт һәм Йосып Ишмәтовларның, Дусмәт (40; улы Арыслан), Бикмәт һәм Гомәр (улы Габделгази) Ишбулатовларның, Рысай (36) һәм Госман (21) Илмәкәйкиннарның (барысы 10 ир-ат) 1742 елда үзләренең

[542] Авыл тарихын 1996 елда яздым, басмага әзерләгәндә аның башлангыч чорына шактый өстәмәләр керттем, аның 1739 елда нигезләнгәнен ачыкладым. Текстның 1859 елдан соңгы чорны эченә алган өлеше үзгәрешсез калды.

[543] РБАДА, 1324 фонд, 1 тасв., 1089 сакл. бер., 1350 б. а.

мондагы биләмәләренә (чыганакта «на своей вотчинной земле») күчеп утырулары турында әйтелә[544].

Шулай итеп, Чубар Абдул авылы 1733–1742 елларда формалаша, аңа ясаклы татарлар нигез сала.



*1742 елда авылга килеп утыручы ясаклы татарлар исемлеге*

Ясаклы татарлар кайсы яклардан килеп утырганнар? Бу сорауга җавапны 2 нче ревизия документыннан табабыз. 1748 елда яңа барлыкка килгән Абдулда (чыганакта «Новопоселенное Абдулово, что на речке Мелле») Казан өязе Җөри юлының Югары Якый авылыннан килеп утырган ясаклы татарлар (42 ир-ат) теркәлгән. Ревизия исемлегендә түбәндәге исем-фамилияләрне күрәбез: 1) Ибрай Ишмәтов (43 яшь; уллары Биккол, Шәрип), аның туганнары Рысмәт (35; уллары Габдрахман, Ирмәкәш, Мәмәнкол, Иманкол) һәм Йосып (25; улы Мөхәммәт); 2) Дусмәт Ишбулатов (62; уллары Арыслан (аныкы Азамат), Минкә); 3) Бикмәт Ишбулатов (55; уллары Роман (аныкы Рахманкол), Субай (аныкы Рахманкол), Сәгыйть, Мәскәү, Шәрип, Хәлил, Мөсәллим); 4) Гомәр Ишбулатов (45; уллары Габделгази, Габдерәшит); 5) Рысай Илмәкәйкин (58; уллары Бикбау, Габдрахман) һәм аның энесе Госман (43; улы Уразай); 6) Кадыйр (15) һәм Габделҗәлил (12; мәрхүм Тирәк Ишбулатов уллары); 7) Габделкәрим (17; мәрхүм Ишмәт Ишбулатов улы); 8) Габдерәззак (15; аныкы Ягъфәр), Шәрипкол (12), Туйгилде (8) һәм Якшимәт (2; мәрхүм Госман Ишмәтов уллары); 9) Туймәт (15; мәрхүм Аймәт Колмәмәтов улы); 10) Абдул (15; мәрхүм Ишмәт Ишбулатов улы)[545].

[544] Шунда ук, 350 фонд, 2 тасв., 1155 сакл. бер., 466 б.
[545] Шунда ук, 1143 сакл. бер, 314 б. а.–317 б.

3 нче ревизия документы (1762 ел, 26 июнь) кайбер үзгәрешләрне чагылдыра һәм яңа мәгълүмат өсти. Аннан күренгәнчә, Казан өязе Җөри юлы Иркәш Котыев йөзлегенә (аннан соң йөзбашы (сотник) Зәет Аитов була) кергән ясаклы татарлар Уфа өязе Казан юлы Табын волосте җирләренә килеп утырган. Бу хакта волость старшинасы Мөэмин Мөслимов һәм аның иптәшләре белән килешү төзелгән. Болар өч хатынлы Ирмәш Рысмәтов (29 яшь; уллары Мөхсин, Габделмән), Роман Бикмәтов (36; уллары Рахманкол, Рәим, Биктимер), ике хатынлы Субай Бикмәтов (чыганакта «Сюбей», 34; уллары Рахманкол, Сәмигул, Салих, Сәйфулла, Абдулла, Абдулхәер), Сәгыйть Бикмәтов (33; улы Туйчы), Мәскәү Бикмәтов (32; улы Бәшир), Хәлил Бикмәтов (25; улы Ибрай), Мө[р]сәлим Бикмәтов (23; улы Мортаза), Габделгази Гомәров (41; уллары Әмир, Зәбир, Нәзир), Кадыйр Тирәков (32; улы Фәйзулла), Габделҗәлил Тирәков (29) һәм Минкәй Дусмәтовлар (32; уллары Миңлебай, Иманай, Иманкол) була. Кәтем авылыннан монда Йөзәй Абдуллин (62 яшь; уллары Ишмөхәммәт, Мәхмүт) килеп утыра. Бу исемлектәгеләр барысы 36 ир-ат һәм 37 хатын-кыз тәшкил итә[546]. 1764 елда аерым исемлек белән исәпкә керми калган Рәфикъ (6) белән Әхмәрне (7; Рысмәт Ишмәтов уллары) теркиләр[547].

Әлеге документта авыл «Мәллә елгасы буендагы яңа нигезләнгән Абдул (Чубар Абдул)» дип күрсәтелә. Аның монда беренчеләрдән күчеп килгән Габделкәрим (Абдулкәрим) Ишмәтов исеме белән шулай аталган булуы бик мөмкин. Халык истәлекләренә караганда, авылга нигез салучы Абдул сипкелле булган, шуңа күрә аны Чубар Абдул дип йөрткәннәр.

Чубар Абдул авылы 1773–1775 елгы Крестьяннар сугышында катнашучылар исемлегендә теркәлгән. Авылда 100 кеше күрсәтелә, әмма бу санга тирә-як халкы да кергән, ахры.

1795 елда Чубар Абдул авылында ике дистәгә якын хуҗалык исәпләнә. Ясаклы татарлар 71 ир-ат һәм 76 хатын-кыздан тора. Авылда шулай ук типтәр сословиесендәге Шәрип Бәйрәшев гаиләсе яши.

Хуҗалыкларның иң зурысын Минкәй Дусмәтов (1728–1785) варислары тәшкил итә. Аның нәселен уллары Миңлебай (1795 елда 36 яшь), Иманай (1760–1788) һәм Иманкол (33) дәвам итә. Миңлебайның Гамбәр Әпсәләмова белән никахтан уллары Фәтхулла (1776–1785), Хәбибулла (11), Гобәйдулла (10), Фәтхулла (7), Гыйсмәтулла (6) һәм Гыйбадулла (2) һәм кызы туа. Иманай белән Иманколның ир балалары булмый.

Болардан соң бертуган Рахманколовлар теркәлгән. Аларның өлкәне Рәим (42 яшь) авылдашы Гөлзифа Ишмөхәммәтова белән гаилә корган, уллары Таһир (11) һәм Габделнасыйр (5) дөньяга килгән. Рәимнең энесе Биктимер бу вакытта солдат хезмәтендә була.

[546] РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1207 сакл., бер., 115–125 б.
[547] Шунда ук, 125 б.

Өченче хуҗалыкта Рәхмәтулла (53 яшь), Сәмигулла (1751–1785), Сәйфулла (1757–1785), Гобәйдулла (36), Бәшир (31), Кормангали (27), Нәзир (25) һәм Миңлебай (23) Субаевлар яши. Боларның кыз туганнары Үрмәт (Бәләбәй округы) һәм Чакмак (Минзәлә округы) авылларында кияүдә була. Рәхмәтулла ике авылдашы белән никахлашкан, уллары Шәмгун (20) һәм Мөхәммәтрәхим (11) туган. Сәмигулланың – Сәйфетдин (16), Сәйфулланың Габдессаттар (17) белән Габделгаффар (14) исемле уллары калган. Субай картның дүртенче улы Гобәйдулла Буралы авылы кызына өйләнгән. Бәшир Шуган авылыннан Сәмига Корычова белән гаилә корган, уллары Мөхәммәтшәрип (10), Мөхәммәтхәсән (6) һәм Мөхәммәтәмин (2) туган. Кормангалинең ир балалары юк, үзе солдат хезмәтенә (рекрут) киткән. Төпчек Нәзир һәм Миңлебай Субаевлар өйләнмәгәннәр.

Дүртенче хуҗалыкта ике хатынлы Туйчы Сәгыйтовны (36 яшь) күрәбез. Аның улы Габделвахит (1777–1785) һәм 5 кызы була.

Бишенче хуҗалык булып Хәлил Бикмәтов (60 яшь) нәселе тора. Хатыны мәрхүм булгач, ул Яхшыбай авылы кызы белән никахлаша. Улы Ибрайның (1760–1788) ир балалары булмый.

Алтынчы хуҗалыкта Мөрсәлим Бикмәтов (61 яшь) яши. Аның ике хатыныннан уллары Мортаза (36), Ягъфәр (31), Мостафа (28), Фәйзулла (21), Габделхаликъ (20), Габделлатыйф (17), Габделнәҗип (14) һәм Габделвәли (1787) һәм кызы Шәһәрзадә (Минзәлә округы Вәрәш авылы кешесенә кияүгә чыга) дөньяга килә. Мортаза авылдашы Гөлгизәр Туйкинә белән никахлашкан, уллары Мохтар (12 яшь), Мозаффар (10) һәм Габделнасыйр (6) һәм 3 кызы була. Ягъфәрнең Сафура Кадермәтова (Минзәлә округы Карамалы авылыннан) белән никахыннан Мөхәммәдьяр (5) туган.

Җиденче хуҗалыкта нәселне Габделгази Гомәров (1719–1788; өч хатынлы) варислары Зәбир (41 яшь) һәм Насыйр (40) дәвам итә. Зәбир ике хатыны (Мамадыш округы Баскан һәм Минзәлә округы Бикбулат авылларыннан), улы Биккенә (3) һәм кызы белән яши. Насыйрның ике хатыннан уллары Габдулла (15), Гобәй (11), Миңлебай (8) һәм кызы Зәбига (5) туа.

Сигезенче хуҗалык булып Кадыйр Тирәков (1734–1790) нәселе теркәлгән. Аның олы улы Фәйзулла (36 яшь) өйләнгән, 3 кызы була. Икенче улы Хәбибулла 1791 елда авылдан качып китә һәм шуннан соң аннан хәбәр булмый. Ирексездән, рекрутлыктан качмадымы икән, дигән сорау туа. Чөнки энесе Сәйфулланы, рекрут яше җиткәч тә, солдат хезмәтенә алалар. Кадыйр картның төпчек улы Фәтхулла (14) була.

Тугызынчы хуҗалык башлыгы Габделваһап Габделҗәлилов (25 яшь) өйләнмәгән, берүзе генә яши. Сеңелләре Сылубикә авылдашына, Асылбикә Тымытык авылы кешесенә кияүгә чыга.

Унынчы хуҗалык булып Гомәр Килмәкәев (45 яшь) нәселе тора. Аның зур гаиләсендә ике хатыны (үз авылыннан), уллары Мәүлекәй (27), Рәхимкол (26), Рәфикъ (24), Хәсән (1773) һәм Хөсәен (1774) һәм 4 кызы була.

Унберенче хуҗалыкта Бикмәт Туктамышев (1731–1793) нәселен уллары Нигъмәтулла (26 яшь) һәм Рәхмәтулла (19) дәвам итә. Беренчесенең хатыны Бикбулат авылыннан, улы Хәмидулла (1) була.

Уникенче хуҗалыкта Үтәгән Сөрмәтов (66 яшь) хатыны Зөләйха Якупова (Минзәлә округы Баламык авылыннан) һәм кызы белән яши. Аларның бер кызы Минзәлә округы Карман авылы кешесенә кияүгә чыга.

Унөченче хуҗалык Әпсәләм Ишбулдиннан (34 яшь), хатыны Сылубикә (авылдашы) һәм улы Габделнасыйрдан (3) тора.

Хуҗалыкларны карауны дәвам итик. 1795 елда Яһүдә Әхмәтовның (1753) уллары Төхвәтулла (12 яшь), Гобәйдулла (3) һәм кызы була.

Субай Хөсәенов (1714–1785) варислары булып Таһир (1751–1788) һәм Зәбир (41 яшь) кала. Бу нәселне Зәбирнең улы Заһир (10) гына дәвам иттерә ала, чөнки Таһирдан бары бер кыз бала кала.

Исемлек ахырында Әмировлар теркәлгән. Беренчесе Зәбир (50 яшь) ике хатыны һәм кызы белән яши. Икенчесе Ракайның (52) хатыны, уллары Рәфикъ (32), Хәбибулла (4) һәм Исмәгыйль (2) була. Өченчесе Габдҗәлилдән (1746–1786) нәсел калмый.

3 хуҗалык (1782 ел мәгълүматлары буенча 7 ир-ат һәм 12 хатын-кыз) Уфа казна палатасы указы нигезендә 1795 елда Гомәр авылына (Оренбург округы) күчеп утыра[548].

Чубар Абдул урта мәктәбендә сакланучы кулъязмада авылда күбрәк таралган нәселләр дип Нәзир, Хөсәен, Бәшир һәм Гобәй нәселләре әйтелә. Югарыда китерелгән нәселләр исемлегеннән күренгәнчә, алар XVIII гасыр ахырында яшәгән. Шәҗәрәсен яхшы белгән авыл кешесе югарыда тасвирланган нәселләр арасыннан үзенә кагылышлысын таба ала (исемлек тә шул максаттан бирелде).

XIX гасырның беренче яртысында Чубар Абдул элеккечә Оренбург губернасы Бөгелмә өязе составында була. 1816 елда монда лашман бурычын (чыганакта «лашманная повинность») башкаручы ясаклы (79 ир-ат һәм 51 хатын-кыз; 34 хуҗалык) һәм йомышлы (46 ир-ат һәм 48 хатын-кыз; 21 хуҗалык) татарлар яши. Алар Кәкре Елга волосте составына карый[549].

1851 елда әлеге Бөгелмә өязен яңа барлыкка килгән Самара губернасына кушалар. Озак еллар (кайбер үзгәрешләр белән) авыл да бу губерна һәм өяз составында була. Ахыр чиктә ул административ яктан Уфа губернасының Минзәлә өязенә күчерелә.

1859 елда Чубар Абдулның типтәр сословиесендәге татарлары (10 ир-ат һәм 10 хатын-кыз; 2 хуҗалык) 19 нчы кантонның 3 нче юртасына карый. Ревизия исемлегендә үзенең туганнары белән Гыймадетдин Хисаметдинов (18

[548] БР МА, И–138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 33–38 б.
[549] Шунда ук, 197 сакл. бер., 591–600 б.

яшь) һәм Хәбибулла Миңлебаевның (65) зур гаиләсе теркәлгән[550]. Әмма авылда яшәүчеләрнең абсолют күпчелеген дәүләт крестьяннары (элеккеге ясаклы һәм йомышлы татарлар) тәшкил итә.

